# АМИРХАН ЕНИКИ

**СОЧИНЕНИЯ**
в пяти томах

**4**

*Воспоминания*

Казань
Татарское книжное издательство
2003

# ӘМИРХАН ЕНИКИ

**ӘСӘРЛӘР**
биш томда

# 4

*Истәлекләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Е56

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Т.А.Миңнуллин, М.Х.Вәлиев, Н.С.Фәттах, Н.Т.Ильясова*

Е 56 **Еники Әмирхан**

Әсәрләр, 5 томда, 4 том: Соңгы китап. Истәлек-ләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 479 б.

**«Соңгы китап» дип аталган бу әсәрендә Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әмирхан Еники бала чагыннан башлап узган гасырның туксанынчы елларына кадәрге чорны эченә алган шәхси тормышына бәйләнешле истәлекләрен, күргән-кичергәннәрен бәян итә.**

ISBN 5-298-01279-5 © Татарстан китап нәшрияты, 2003



# СОҢГЫ КИТАП

## КАРГАЛЫ

«Язучыны аңлыйсың килсә,
аның туып үскән җиренә бар».

*Гёте.*

Гади генә әйтелгән бик дөрес фикер булса кирәк бу... Чынлап та, әдипне яки шагыйрьне туган-үскән җиреннән аерып аңлау мөмкинме?! Менә ни өчен, бөек Гётеның югарыдагы сүзләрен очратканчыга кадәр үк инде, минем туган җиремә кайтасым килә иде. Күп дистә еллар аша кайтып, бала һәм үсмер чакларымны күрәсем килә иде. Ниһаять, мин бу озын сәфәргә тәвәккәлләп чыктым. Шактый ук соңга да калдым шикелле, ләкин өлгереп булыр дип ышанам.

Уналты яшемә чаклы мин туган-үскән җиремдә, атам-анам канаты астында яшәдем. Менә шушы чорым мине кызыксындыра һәм тарта. Бу минем гөнаһсыз саф чагым. Сүз дә әнә шул бик кадерле, бик кыска, әмма, ни хикмәттер, шактый озын булып тоелган балачак турында барачак. Үзем турында да, мине чорнаган тормыш һәм кешеләр турында да мин бары чын дөресен генә язарга тырышачакмын. Бу исә бик озынга сузылган, әмма үтеп киткәне сизелми дә калган гомернең дәвамын аңларга да ярдәм итәр дип ышанам. Хәерле сәгатьтә!..

### БАБАЙЛАР ЭЗЕННӘН

Сүзне иң элек фамилиядән башлыйсым килә. (Бу уңай белән ерак тарихка да беркадәр күз салырга туры киләчәк.) Барлык рәсми документларда минем тулы фамилиям Еникеев дип языла. Тик язучы буларак кына мин аны, безнең әдәбиятта күптән килгән гадәт буенча, «Еники» дип кыскартып йөртәм. Хәзергә әле бу фамилияне йөрткән язучы бер мин генә.

Әмма Еникеев бик борынгыдан килгән һәм шактый күп таралган фамилия ул. Минем туган авылым Каргалының, мәсәлән, ярты халкы диярлек Еникеевләр иде. Гомумән, бу авылда һәркемнең фамилиясе — ата-бабасыннан күчеп килгән фамилия,— бездә үз атасының исемен фамилия итеп алу бөтенләй булмаган. (Һәрхәлдә, элек булмаган, ләкин безнең дәвердә сирәк кенә ала башлаганнар.) Шуңа күрә Каргалыда фамилияләр күп түгел. Иң күбесе Еникеевләр, аннары Терегуловлар, аннары инде Янгуразовлар, Утяшевләр, Сундюковлар китә. Тагын Мамлеевлар, Дивеевлар, Килмамитовлар да бар.

Безнең авыл башкорт җиренә унсигезенче гасырның ахырларында гына Тамбов губернасыннан күчеп килеп утырган. «Каргалы» дигән исемне дә аңа шушы яңа җиргә килеп утыргач кына биргәннәр, югыйсә тегендә, Тамбов җирендә чакта, авылның исеме «Иди» булган диләр. Димәк, безнең борынгы төп җирләр Россиянең үзәгендә, тагын да конкретлаштырып әйткәндә, Темников дигән шәһәр тирәсендә булган икән — без әнә шуннан чыккан халык. (Темников хәзер Мордовия республикасына керә.)

Ул җирләрдә торып калган Еникеевләр хәзер дә булырга тиеш әле. Шулай ук Пенза, Саратов өлкәләрендә дә аларны бар диләр. Әмма Уфа белән Казанда яши торганнары барысы да диярлек Каргалыдан чыккан Еникеевләр (үзе булмаса, атасы яки бабасы шуннан). Хәер, Каргалыдан таралган Еникеевләрне ерак Себердә дә, Урта Азиядә дә, Кавказда да — кыскасы, Советлар Союзының бик күп почмакларында очратырга була.

Кемнәр соң ул Еникеевләр? Нинди халык? Нинди тамырдан чыгып үрчегән һәм шулхәтле таралган алар? Бу сораулар мине һәрвакытта уйландыра иде. Ишетеп белүемчә, аларның нәсел очы бик ерактан килә икән, ә башкорт җиренә күчкәндә инде алар шактый ишле бер нәсел булганнар. Бу нәселдән төрле заманда зур гына дәрәҗәле кешеләр чыккан, мәсәлән, элек патша хезмәтендә алардан полковниклар, хәтта генераллар да булган, диләр. Революциягә чаклы ук Еникеевләрдән землемерлар, агрономнар, врачлар булуы да мәгълүм. Безнең әдәбиятта да алар күренеп китәләр: 1902 елда Нигъмәтҗан Еникеев дигән укытучы Гогольнең «Ревизор»ын татарчага тәрҗемә итеп бастыра. «Аң» журналында Сәетгәрәй Еникеевнең, кызганычка каршы, бик иртә үлеп киткән өметле шагыйрьнең, берничә шигыре басылып кала. 1905 елдан соң Дәүләт думасына да Каргалы кешеләреннән берәү сайлана — бу Гайса морза Еникеев. (Минем атама якын кардәш тиешле кеше.) Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк: Гайса

морза үткән гасырның ахырларында Уфа — Оренбург җирләрендә йөреп, бик күп башкорт җырларын язып алган һәм 1931 елны, үләр алдыннан, шуларның барысын да үз кулы белән Башкортстан хөкүмәтенә тапшырган. Аның үзен дә яхшы җырчы булган, диләр.

Революция вакыйгаларында һәм гражданнар сугышында актив катнашкан кешеләр дә бар. Шуларның берсе, мәсәлән, Нигъмәт Еникеев, Казандагы татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары — аны хәтерләүчеләр хәзер дә бардыр әле. Ә менә Исхак Еникеев дигән партия работнигы утызынчы елларның башында «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы булып торды... Аннары Хисмәтулла Еникеев дигән Каргалы кешесенең 1912 елны Лена вакыйгаларына катнашуы билгеле: ул баш күтәргән эшчеләр тарафыннан прииска хуҗалары белән сөйләшү өчен сайланган булган. Һәм шул чакта кулга алынып, төрмәгә дә ябылган. (Бу турыда архив материалы бар.)

Билгеле инде, Каргалыдагы башка фамилияләрдән, әйтик, Терегуловлардан да чыккан укымышлы һәм исемле кешеләр бик күп, ләкин бу очракта мин үз фамилиям белән генә чикләнергә мәҗбүрмен, чөнки сүз дә бит хәзергә минеке турында гына бара.

Тик, кызганычка каршы, мин үз фамилиямнең кайчан, кайдан килеп чыгуын моңарчы ачык кына белми идем. Гомумән, Каргалы халкының үткәне белән танышлыгым бик чамалы, бик өстән генә иде. (Каргалыда тусам да, миңа бит анда үсәргә туры килмәде.) Мәсәлән, безнең халык үзләрен «төмәннәр» дип йөртәләр. Ни өчен төмән, ни өчен, әйтик, мишәр түгел? Мишәрләр иленнән килгән халык ич, телләре дә мишәрчә, алайса, эш нәрсәдә?.. Дөрес, килеп чыгышлары белән алар татар-мишәрләр, моны берсе дә инкарь итми, ә шулай да үзләрен ни өчендер «төмән» дип атарга гадәтләнгәннәр. Хәтта «татар» сүзен беркадәр өнәп бетермәү дә сизелә — гүя ул аларга көчләп тагылган исем. Моның, билгеле, бик ерактан килгән ниндидер бер сәбәбе булырга тиеш.

Аннары Каргалының бер катлау кешеләрен «морзалар» дип атыйлар иде заманында. Еникеевләр, Терегуловлар, тагын берничә фамилия менә шул морзалардан санала иде. Бүтән фамилияләр, мәсәлән, Утяшевлар белән Янгуразовлар, морзаларга кермәгән. Шулай итеп, Каргалы халкы сословие ягыннан икегә бүленгән — күпмедер өлеше морзалар булса, калган өлеше гади халык булып саналган.

Хуш, ә безгә — Еникеевләргә һәм Терегуловларга — морзалык кайдан килгән соң? Һәм, гомумән, кем ул мор-

за[1], нәрсәне аңлата? Әгәр ялгышмасам, морза ул аерым хокук һәм өстенлек белән файдаланучы бер кеше. Әйтик, русның дворяны кебек. Димәк, җыеп әйткәндә, морзалар алар гади халыктан өстен торган үзенә аерым бер сословие. Ерак заманнарда алар хаким сыйныф — дәүләт терәге булганнар.

Шулай итеп, без фәкыйрегез дә чыгыш җәһәтеннән морза булабыз. Дворян, аксөяк — чыдап кына тор! Әле хәзер дә кайбер өлкән абзыйлар миңа беркадәр көлеп тә, әзрәк кенә үстереп тә «морзам!» дип дәшкәлиләр. Минем моңа үпкәм юк. Әйдә, шулай да булсын ди... Дворяннардан кемнәр генә чыкмаган, аңа китсә!

Тик шул кадәресе бар инде, безнең «морзалыкка» тагын бер сүз өстәгәннәр: чабаталы, ягъни чабаталы морза! Мәгънәсе ачык булса кирәк: морзасын морза син, әмма аягыңда мужик чабатасы! Тагы да ачыклый төшкәндә, аны болай аңларга кирәктер инде: әйе, «морза» дигән хәтәр исем бар барын, әмма аның реаль нигезен (көчен) тәшкил иткән байлык та (мәсәлән, җир-сулар биләү) һәм ниндидер зур өстенлек (привилегия) белән файдалану хокукы да юк, бирелмәгән. Бу җәһәттән караганда, рус дворяны белән Каргалы морзасы арасында чагыштырмаслык аерма ярылып ята. Юкка гына бит халык та, Каргалы морзаларыннан көлеп:

> Бәләбәйгә барганда итектән дә читектән.
> Бәләбәйдән кайтканда чабатага интеккән,—

дип такмак чыгармагандыр. Бәләбәй — безнең өяз шәһәре, Каргалы морзалары елына бер тапкыр шунда дворянский собраниегә бара торган булганнар.

Ләкин, ничек кенә булмасын, дәрәҗәле исем саклангап, титул рәвешендәрәк тагылып та йөргән (әнә Гайса морза дигән кебек), хәтта безнең авылны да тирә-якта «морзалар Каргалысы» дип йөрткәннәр. Әмма минем үзем өчен бу «морзалык» дигән нәрсә электән үк шактый караңгы, чуалчык бер мәсьәлә булып кала килде. Әлбәттә, аның бик борыннан килгән тарихы булырга тиеш, төрле чорларны, төрле хәлләрне дә кичергәндер ул (гел генә чабаталы да булып тормагандыр), ләкин, махсус эзләнмәгәч, болар барысы да миңа җир астында күмелеп яткан борынгы әйберләр шикелле билгесез иде.

Инде шушы китапны язарга җыенгач, мин һич югы үз фамилиямнең тарихын белер өчен эзләнә, сораша баш-

---

[1] Хәзер әдәбиятта күбрәк «мирза» дип язалар. Ләкин безнең Каргалыда «морза» диләр иде — мин дә шулай алам.— *Ә.Е.*

ладым. Ахырда үткән җәй Уфадан кызыклы гына бер материал табып кайттым. «Яңа Каргалы авылына ике йөз ел» дип атала ул. Ягъни Яңа Каргалының тарихы, тормышы һәм көнкүреше турында язылган очерклардан гыйбарәт зур гына бер кульъязма. Аны шушы авылдан чыккан югары белемле, өлкән яшьтәге бер төркем кешеләр — Әбүбәкер, Әхмәт, Гали, Гомәр һәм Кәлимулла Еникеевләр, Заһир Утяшев, Гыйниятулла Терегуловлар язганнар. Кереш сүзләрендә алар бу хезмәтне бик озак эзләүләр нәтиҗәсендә, тарихи документларга һәм елъязмаларга таянып язуларын әйтеп үтәләр. Кульъязма Каргалы халкының башкорт җиренә күчеп килгәнчегә кадәр булган борынгы тарихын да шактый ук тулы яктырткан. Менә шушы борынгы тарихка караган беренче кисәген профессор Гыйниятулла абзый Терегулов миңа инде биреп тә җибәрде. Билгеле, бу басылып чыккан хезмәт түгел, кульъязма гына, шулай да мин аны ышанычлы чыганак дип табам һәм аңардан файдалану бер дә язык булмас дип саныйм.

Хуш,ниләр таптым соң мин кульъязмадан?

Актара-карый торгач, минем өчен менә нәрсәләр ачыкланды: безнең бабайларның башкорт җиренә күчкәнче яшәгән урыннары чынлап та шул Тамбов губернасындагы (хәзерге Мордовия республикасындагы) Темников дигән өяздә булган икән. Алтын Урда заманында исә Темниковта Урданың гаскәр башлыгы, икенче төрле әйткәндә, «темниге» торган. Шунысы кызыклы, бу «темник» сүзе русның «темь», «тьма», ягъни бик күп дигән мәгънәне аңлатучы сүзеннән алынган, имеш.

Кайбер яңа тарихчыларның язуына караганда, татар-мишәрләр Темников тирәсенә монголлар явы вакытында килеп утырып калганнар, янәсе. Ләкин кульъязма авторлары бу версияне катгый рәвештә кире кагалар. Алар, иске тарихчыларга һәм борынгы елъязмаларга таянып, мишәрләрнең X гасырда ук инде көньяктан, ниндидер дала халыкларының кысрыклавы аркасында, бу якларга күчеп килүләрен исбат итәләр. Килгәннәр, төпләнгәннәр һәм шунда утырып та калганнар. (Бер Темников тирәсендә генә түгел, ә «мещера җирләре» дип йөртелгән шактый зур территориядә.) Башта алар Болгар дәүләтенә буйсынганнар, болгарларга ясак түләгәннәр, ләкин идарә итү эшләре үз кулларында булган.

1239 елны мишәрләр илен монголлар басып ала. Йөз елдан артык алар шулар кул астында яшәгәннәр, ясак түләгәннәр, әмма идарә итү эшләре һаман үзләрендә сакланган. Ягъни башка халыклардагы, мәсәлән, русларда-

гы шикелле үк, аларның үз бәкләре (князьләре) булган һәм шулар идарә дә иткәннәр.

XIV гасырның икенче яртысында Алтын Урда таркала һәм дәүләт буларак әкренләп юкка чыга. Әмма татар дигән исем кала. Бу исем белән рус елъязмалары Алтын Урда эчендәге төрки халыкларны, шул җөмләдән болгарлар белән мишәрләрне дә атаганнар (дөресрәге, монгол явы белән килгән ниндидер кабилә исемен тора-бара мондагы төрки халыкларга да күчергәннәр). Димәк, татар — безгә читтән тагылган исем. (Ихтимал, безнең халыкның татар дигәнгә озак вакытлар күнегеп китә алмавы шуңардан килә дә торгандыр.) Ләкин ничек кенә булмасын, шушы исем астында заманнар үтү белән зур һәм бөтен бер милләт хасил була (яки формалаша диик). Болгары да, мишәре дә шушы татар дигән бер милләткә керә.

Хәер, мин читкәрәк тайпылдым шикелле... Яңадан кулъязмага кайтыйк. Татар-мишәрләрнең яшәгән җирләре үзегезгә мәгълүм, рус җирләренә терәлеп үк тора. Мәскәүнең борын төбендә үк! Менә шуңа күрә дә булса кирәк, Алтын Урда таркалгач, татар-мишәрләр үзләреннән күп зур, көчлерәк Мәскәү князьлегенә ирексездән тартылалар, якынаялар һәм ахырда әкренләп аның кул астына кереп тә бетәләр. Шушы керүдән инде алар рус дәүләте эчендә гомерлеккә торып та калалар... Берничә гасырлар дәвамында, зур диңгез уртасындагы кечкенә утрау шикелле, татар-мишәр иле үзенең динен, телен саклап яшәп килә. Рус князьләре һәм патшаларның татар-мишәргә мөнәсәбәтләре төрле вакытта төрлечә була: башта, рус дәүләте кечерәк һәм зәгыйфьрәк чакта, алар татар-мишәрләр белән күпмедер дәрәҗәдә хисаплашалар, дусларчарак кыланалар, хәтта Касыйм ханлыгы дигән, баш-аягы белән Мәскәүгә буйсынган, вассал бер ханлык та төзеп бирәләр. Әлбәттә, бу «яхшылык», бу «юмартлык» бушка түгел — дәүләт эшендә бернәрсә дә бушка гына бирелми. Татарлар рус патшаларына бик кирәк әле. Рус дәүләте әле ул хәтле үк зур да, көчле дә түгел, ул әле төрле илләр белән бертуктаусыз сугышып торырга да мәҗбүр... Аңа бик күп гаскәр кирәк, аңа үзенең дәүләт чикләрен дә сакларга кирәк. Менә татар морзалары рус патшаларына шуның белән түлиләр дә инде: дәүләт чикләрен дә саклыйлар һәм русның барлык походларына да катнашалар (Казанны яулап алуда да дип өстик). Башта мөнәсәбәтләр әнә шундыйрак булган. Ләкин соңга таба, рус дәүләте зурайгач һәм көчәйгәч, татар морзаларының хәрби көч буларак кирәге бетә башлый, һәрхәлдә, бик

кечерәя. Шуңадыр инде әлеге Касыйм ханлыгын да ябып куялар... Кайчандыр Мәскәү патшалыгының чикләре булып исәпләнгән мещера җирләре Россиянең үзәгендә үк торып кала. Менә шуннан соң рус дәүләте XVI гасырның ахырында һәм XVII гасырның башларында мишәрләр илен чынлап торып колонизацияләштерергә керешә. Бер үк вакытта татар-мишәрләрне христиан диненә күчәргә (чукынырга) мәҗбүр итү дә башлана. Шулай итеп, мондагы халык үз язмышының иң авыр бер чорын кичерә... «Каргалы язмасы»ннан сөзеп алган кыскача гына мәгълүмат әнә шуңардан гыйбарәт. Сүз озынга китмәсен өчен миңа күп вакыйгаларны сикереп узарга туры килде.

Инде минем үз нәселемә күчик булмаса: ягъни Еникеевләр каян чыккан, кемнән башланган алар?

Кайчандыр, ерак заманда бу җирләрдә Бихан исемле бер князь (бәк) яшәгән. Шушы Биханнан тора-бара Кугушев, Акчурин, Кутуев, Муратов фамилияләре үрчеп, тармакланып чыккан. Ә Кугушевлардан берсенең исеме Күлдәш булган, Күлдәштән исә Еникей туган. Димәк, болай була: Бихан, берничә буын аша Күлдәш, аңардан Еникей... Бу Еникейдән тагын биш ир бала туган: Алакай, Идей, Терегол, Усангали, Иртуган[1]. Башкортстанга күчеп килгән безнең бабайлар менә шул Идей белән Тереголның дәвамы икән. Фамилияләре исә Күлдәш улы Еникейдән башланып китә. Шуннан соң инде ул үзгәрмичә буыннан буынга күчеп килә. Тора-бара Еникеевләрдән Терегулов фамилиясе аерылып чыга. (Югарыда Идей белән Тереголның бертуганнар икәнен күрдек.) Каргалы халкының да иң зур күпчелеге Еникеевләр белән Терегуловлар, һәм алар чынлап та үзара туганлык җепләре белән бик нык бәйләнеп, чуалып беткәннәр. Күрәсез, бу ике фамилия бик борыннан килә, шуңа күрә аларның күп таралуы гаҗәп тә түгел.

Биредә тагын шуны да әйтергә кирәк: Башкортстанда икенче бер тамырдан чыккан Еникеевләр дә бар икән әле (аларның яшәгән авылы — Яңа Бәшир, хәзерге Чакмагыш районында). Бу Еникеевләрнең нәсел башы князь Тенешев. Аның да Еникей исемле улы булган — менә шуңардан икенче тармак Еникеевләр үрчеп киткән. Ә Тенешевның үзенең нәсел очы кайдан, кемнән — бу кадәрлесен инде мин тикшереп, ачыклап тормадым. Һәрхәлдә, мишәрләрдәге күп кенә фамилияләр бер та-

[1] Исемнәр барысы да русча язылган. Татарча әйтелеше ничек «Идей»-ме, «Идәй»ме, Терегол — Түрәколмы — ачыклавы бик читен.— *Ә.Е.*

мырга барып тоташа — әнә Акчуриннар, Кутуевлар, Муратовлар Биханга барып тоташкан шикелле... Бәлки, князь Тенешевлар да шул ук Биханнандыр — Хода белсен!

Инде Каргалы кешеләренең үзләрен «төмән» дип йөртүләренә килгәндә, моны, минемчә, ике төрле аңлатырга була. Беренчедән, элек гомер сөргән җирләренә бәйләп, ягъни алар Темниковтан чыккан халык — «төмәнлеләр». Икенчедән, аларның элек кем булуларына карап та; билгеле ки, алар борын-борыннан хәрби хезмәт кешеләре булганнар, Алтын Урда заманында мең башы, ун мең башы булып торганнар, ә татарлар гаскәр башында торучыны кайчандыр «төмән» дип атаганнар. Миңа калса, менә шушы икенчесе дөресрәк булырга тиеш, ягъни алар нәселләре белән хәрби халык, алар — төмәннәр! Болай диюләрендә аларның үзләрен башкалардан аерырга теләү дә һәм кем булулары белән горурлану да ачык сизелсә кирәк. Монда тагын шуны да өстисе килә: мин белгән, күргән «төмәннәр» барысы да диярлек озын буйлы, төз, таза кешеләр, йөзләре дә аларның озынча, ак чырайлы, борыннары да бик туры... Кара сары, табактай түгәрәк йөзле, кысык күзле кешене минем аларда очратканым юк. Кыскасы, «төмәннәр»не монголлар белән бәйләү һич мөмкин түгел. Димәк, алар башка токым, башка тамырдан яралган халык (тарихчылар аларны кыпчак белән бәйлиләр, кыпчактан чыккан, диләр).

Ә менә «морзалык» аларга, чын булса, монголлар вакытында бирелгән, имеш. Миндәге кулъязмада шулай диелгән, ягъни морза сүзе Ираннан чыккан һәм төрки халыкларга монголлар аша кергән дип әйтелгән. Шулай да мин безнең нәсел монголларга чаклы ук инде ниндидер бер өстен таифә (каста) булгандыр дип уйлыйм. Алтын Урдага буйсынгач та аларның үз җирләренә үзләре хуҗа булып калулары, гаскәр башлыклары булып торулары һәм морза исеме белән йөрүләре шул иске дәрәҗәөстенлекнең дәвамы гына булса кирәк. Югарыда исемнәре телгә алынган Бихан да, аның токымы Кугушевлар да Алтын Урда вакытында да, соңыннан рус дәүләте кулына күчкәч тә һаман морза һәм князь булып кала биргәннәр. Димәк, буыннан буынга күчә торган нәрсә икән ул исем-дәрәҗә!

Билгеле инде, исем сакланса да, аның реаль эчтәлеге гасырлар дәвамында күп үзгәрешләр кичерә. Әмма әкренләп гел начарлануга табан. Бигрәк тә Петр I заманында татар морзаларын чикләү-кысу аеруча көчәя. Мишәр илендә «татар мәсьәләсе»н бер селтәнүдә хәл ит-

мәкче булып, бу патша 1713 елны хәтта шушындыйрак указ да чыгара: ярты ел эчендә бөтен татарларны чукындырып бетерергә! Чукынмасалар, җирләрен, ә морзалардан поместьеларын да тартып алырга!.. Ләкин бу дәһшәтле указ да көткән нәтиҗәне бирми, бары тик дәүләтен саклар өчен күп җир биләүче эре алпавытлар гына ашыгып чукыналар, әмма түбән хәлле морзалар (алар, әлбәттә, күпчелек) һәм гади халык үз диннәрендә нык торалар, чукынмыйлар. Шуңа ачудан булса кирәк, Петр I бөтен чукынмаган морзаларны һәм татарларны тота да казна крестьяннары итеп игълан итә. Шуның өстенә урман кисү, урман чыгару белән бәйләнгән бик авыр лашманчылык эшенә аларны ел саен куа башлый. Бу чорда татар-мишәрләр бик авыр шартларда яшәп, тәмам бөлгенлеккә төшәләр. Тик Петр I дән соң Екатерина II (Әби патша) вакытында гына, татарларны дин җәһәтеннән кысу бераз йомшара, ә кайбер фамилияләргә, шул җөмләдән Еникеевләр белән Терегуловларга да морзалыклары яңадан кайтарыла. Әмма элек биләгән җир-суларын кайтарып бирмичә генә... Ләкин ниндидер привилегияләре кайткан булырга тиеш, мәсәлән, морзаны солдатка алсалар, аңардан казарма идәнен себертмәгәннәр. Хәер, солдаттан башка шактый зур чиндагы хәрбиләр дә, зур гына дәрәҗәле чиновниклар да чыккан алар арасыннан — димәк, морзалыкның кайбер өстенрәк привилегияләре белән дә файдаланган булырга тиешләр. Шулай да морзалар дип аталган бу халыкның иң зур күпчелеге гади крестьяннар булган. (Газиз Гобәйдуллинның «Татарларда сыйныфлар тарихы» дигән китабында морзаларның һәм «йомышлы татарларның» ничек итеп бөлгенлеккә төшүләре бик ачык күрсәтелгән.)

Кыскасы, безнең бабайлар Темниковтан күчеп китәргә җыенган чакларында әле казна крестьяннары булып исәпләнәләр. Бу хәл аларның күченүләрен бик нык читенләштерә, чөнки патша хөкүмәте башкорт җирләрен читтән килгән һәм морза булмаган кешеләргә сатуны тыя. Шулай да алар тәвәккәлләп чарасына керешәләр. Башта ерак Темниковтан Уфа — Бәләбәй якларына йөргеннәр (ходоклар) килеп җир карыйлар, күпмедер карап йөргәннән соң, Каргалы дигән кечкенә елгачык буен сайлыйлар. (Башкортстан картасында күрсәтелгән Чәрмәсән елгасына килеп коя ул.) Елгачыкның уң ягында тезелеп киткән таулар, сул ягында җәелеп яткан кара туфраклы тигез ялан — иншалла, бәрәкәтле җир булыр, диләр карап йөрүчеләр... Җир хуҗасы башкортлар белән сөйләшүләр башлана. Ләкин әлеге морза булмаганнарга

җир сатмаска дигән патша указы килешүгә бик нык комачаулык итә. Шулай да, өметсез — шайтан дигәндәй, юлы табыла. Ике кеше — Чәрмәсәндә тегермән тотучы Әпсәләм Киекбаев белән хәрби сотник Әмирхан Хәлилов бу эшне үз өсләренә алалар. Икесе дә электән килеп калган морзалар, җир сатып алырга хаклары бар, шуңа күрә башкортлар белән сөйләшүне дә алар алып баралар. (Исемлек башына да иң элек үзләрен язып куялар.) Бары тик шулар аркасында һәм шуларга кушылып кына безнең бабайлар Канны башкортларыннан 14500 дисәтинә җирне илле ел срок белән арендага алуга, ниһаять, ирешәләр. Аренда договорын төзү үзе дә бик озакка сузыла — чын булса, сигез елга! Менә шуннан соң гына 1773 елны егерме хуҗалык (йорт) — ундүрте Еникеевләр, алтысы Терегуловлар — ничәмә гасыр гомер иткән җирләреннән кубып, хатыннары, бала-чагалары белән арбаларга төялеп, мал-туарларын куалап яңа җиргә — Каргалыкай буена күчеп киләләр. Алар артыннан башкалары да һәм башка фамилияләр дә күченә башлыйлар. Бу күчеnү дә бер ун елга сузыла. Ахырда кечкенә елгачык буйлап утырган Яңа Каргалы исемендәге «төмәннәр» авылы барлыкка килә. Һәм шушы авылда минем бабайларның яңа тормышлары, яңа тарихлары башлана.

Менә шул. Мин дә алдымда яткан кулъязманы, ашыкмыйча гына карап чыгып, ябып куйдым. Монда язганнар барысы да шуннан чүпләп җыеп алынды. Билгеле, анда кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар күп иде, ләкин аларның барысын да хәзергә калдырып торырга туры килде. Миңа бит безнең фамилиянең кайдан килеп чыгуын гына белергә кирәк иде, һәм шуның белән генә чикләндем дә диярлек... Әлбәттә, фамилия тарихы ул буыннар тарихы, әмма бик озын тарих. Шуңа күрә бик кысып-җыеп кына мин үзем турында болай дип әйтә алам: ерак гасырлар түреннән, гүя Азов диңгезе томаннары эченнән чыгып, ниндидер кабиләләрнең кысрыклавы аркасында, Ука, Мокшы елгалары буена күченеп килгән, шунда төпләнеп, күпмедер заманнар үзенә үзе хуҗа булып яшәгән, монголлар явыннан соң Алтын Урдага буйсынып, шуңа аты, коралы белән хезмәт иткән, морзалар сыйфатында өстенлек, дәрәҗә белән файдаланган, Алтын Урда таркалгач, иң якын күршесе — рус дәүләте кулында калып, аңа да хәрбиләр буларак хезмәтен күрсәткән, әмма соңга таба рус патшалары тарафыннан чукындыру максаты белән төрлечә кысу-изүләргә дучар ителгән, ахырда шул өзлексез кысу-изүләрдән котылу өчен төп җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган

«төмәннәрнең» бер гаиләсендә 1909 елның иске стиль белән февраль аенда мин дөньяга килгәнмен. Мәрхүм атам мин туардан бер ел элек кенә сатып алган Коръәннең ахыргы битенә түбәндәге сүзләрне язып куйган: «Бән морза Нигъмәтҗан Әсхәтҗан углы Еникеев алдым ышбу кәләм шәрифне 1908 елда 28 гыйнварда Эткол ярминкәсендә. Бәһасы 65 тиен көмеш һәм ушандук кәләми шәрифне 1909 елда 16 февральдә пәнҗишәмбә көн дөньяга килмеш углым Әмирханга һибә кылып бирдем. Алла Тәгаләдән озын гомер, бәхет һәм тәүфыйк сорап ышбу әл-мөсхаф шәрифне хәтме көтеп кылырга насыйп итсен иде. Амин».

## ИКЕ БӨРТЕК

Минем туып үскән җирем икәү — Каргалыда туганмын, Дәүләкәндә үскәнмен. Димәк, миңа аларның икесе турында да сөйләргә туры киләчәк. Дәүләкәнне мин Каргалыга караганда күп мәртәбә яхшырак беләм, әмма Каргалы ул минем туган туфрагым, бөтен нәсел-нәсәбем шунда яшәгән, барлык якын һәм ерак кардәш-ыруым да шунда яшиләр иде. Билгеле, сүз дә иң элек аның турында барырга тиеш.

Авылның тулы исеме — Яңа Каргалы, ләкин телдә Каргалы дип кенә йөртелә. Төрле якларда бу исемдә бүтән авыллар да — мәсәлән, Ырынбур Каргалысы, Чистай Каргалысы кебекләр — булганга күрәдер, ахрысы, безнең авылны «Уфа Каргалысы», «Бәләбәй Каргалысы», янә тагын «Морзалар Каргалысы» дип тә йөрткәннәр. Кыскасы, тирә-якта шактый мәшһүр авыл булган ул.

Инде Каргалының үзен, аның кешеләрен һәм атам-анамның анда яшәгән чакларын тасвир итәргә керешкәнче, башта ук бернәрсәне әйтеп куясым килә: мин атам-анама һәм якын туганнарыма моңарчы ничек дәшеп өйрәнгән булсам, бары тик шул рәвешчә язачакмын да. Хәзерге укучыларга бу, бәлки, бик сәер дә тоелыр, ләкин сабый чактан ук әйтеп өйрәнгәнне картайгач кына үзгәртәсем килми минем... Атамны — атакай, анамны — инәй, бабамны — бабакай, әбиемне — әбекай («к»ны йомшак итеп), абыйлар, апаларны — агакай, дәдәкай (атам-анамның бертуганнарын) һәм тутакай дип атаячакмын. Бу дәшү рәвешләре барысы да төмәнчә, тик «инәй» дию-ем генә башкортча, чөнки телем ачылган чакта, без инде Каргалыда түгел, Дәүләкәндә, башкорт өендә торганбыз. (Дим буе башкортлары «әсәй» димиләр, «инәй» диләр.) Әгәр телем Каргалыда ачылса, мин «анакай» дип дәшәргә

өйрәнеп киткән булыр идем. Хәер, Каргалының үзендә дә «инәй» диючеләр бар, ләкин бу форма кайбер киленнәрнең Каргалыга чит авылдан төшүләре белән бәйләнгән булса кирәк.

Инде төп максатка күчик. Менә минем кулда атакайның төзеп калдырган шәҗәрәсе саклана: башына «Еникеевләр нәселеннән хөрмәтле булган бабаларыбызның исемнәре һәм кайдан чыгышлары» дип язып куйган. Зур гына бөтен бер кәгазьгә иренмичә һәр буынның тармакланып дәвам итүен сызык һәм вак түгәрәкләр рәвешендә төшереп чыккан. Кагыйдә буларак, шәҗәрәдә ирләр тармагы гына күрсәтелгән, шулай да бер кешедән башланган бу тармаклар саны 47 гә җиткән. Иң баштагы дүрт кырлы беренче шәкел эченә «Хансуар бабай Еникеев» дип язып куелган. Бу Темников өязендә яшәп, шунда вафат булган бабабыз икән. Аның улы Бәшәр Еникеев Темниковтан башкорт җиренә беренче килеп утырган бабабыз була. (Шәҗәрәдәге урыны да Хансуар бабайдан соң икенче түгәрәк шәкел эчендә.) Димәк, атакай төзегән бу шәҗәрә бик ерактан башланмаган, асылда, ул Каргалыга күчеп килгәч кенә дәвам иткән һәм үрчегән буыннарны күрсәтә. Әлеге 47 тармак та яңа җирдә Бәшәр карттан тарала. Менә шул тармакларның берсе миңа да килеп җитә. Башы һәм дәвамы болай: Бәшәр — Хәсән — Әхтәм — Әхмәтҗан — Нигъмәтҗан — Әмирхан. Шулай итеп, мин яңа җирдә алтынчы буын икәнмен — бу 150 ел чамасы вакыт эчендә бер тармакның үрчүе... Калган тармакларга тукталып тормыйм, алар бик күп һәм әллә ни кирәге дә юк. Тик шунсы гаҗәп, минем атакай үзенең шәҗәрәсендә 47 түгәрәк ясап, шуларның һәркайсына Бәшәр карттан таралган кешеләрнең исемнәрен язып чыккан. Бернинди язма чыганакка таянмыйча, бары хәтердән генә! Дөрес, алар барысы да бер токым, бер авылда яшәүчеләр, ләкин шуларның бөтенесен исемнәре белән белү өчен нинди хәтер кирәк булгандыр инде. Югыйсә бит хәзер дәү әтисен онытучылар да күп.

Минем инәйнең шәҗәрәсе юк, шул сәбәпле аның ерак бабаларын мин белмим. Фамилияләре — Янгуразов. Темников өязендә Янгураз авылы булган, диләр, бәлки, нәсел очы шуннан килә торгандыр. Ләкин Каргалыдагы Янгуразовлар турында миңа шунсы ачык мәгълүм: беренчедән, алар Еникеевләр кебек морзалар түгел, икенчедән, аларны «мулла халкы» дип йөртәләр иде. Чөнки муллалык итү аларда буыннан буынга күчә килгән — Каргалының иң беренче мулласыннан башлап, мин белгән Гыйният муллага чаклы. Морзалар үзләре динне ихлас тотсалар

да, муллалык итәргә яратмаганнар — бу изге эшне бүтәннәргә тапшырганнар (көченгән чакта ук инде хәзрәтне дә арбага утыртып алып килгәннәр).

Инәйнең дә бабасы Габдрахман хәзрәт урта мәхәлләнең имамы булган, ләкин атасы Хәбибрахман нишләптер ата-баба юлыннан китмәгән, иген игү, мал асрау, шуның өстенә сәүдә дә итүне артыграк күргән. Гомумән, Янгуразовлар «мулла халкы» дип аталса да, аларның бөтенесе диярлек гади крестьяннар иде. (Мулла булу һәркемгә дә эләкми — вакансиясе бик аз аның.) Инәй ягыннан кардәш тиешле мин белгән Янгуразларның күбесе җир эшен яратып, җигелеп эшләүче таза тормышлы агайлар иде.

Минем атам Нигъмәтҗан Әхмәтҗан улы 1874 елны дөньяга килгән. Анам Бибихәдичә Хәбибрахман кызы 1872 елны туган. Димәк, ул атакайдан ике яшькә олырак булган. Җитеп килгән кыз чагында башта әнисе, аннары әтисе, илле яшенә дә җитмәс борын, үлеп киткәннәр. Инәй һәм ике сеңлесе — Мәрьям белән Кәримә — ятим калганнар. Аталары Хәбибрахман, әйткәнемчә, таза тормышлы кеше булган — эре нараттан кара-каршы салынган йортын мин дә хәтерлим әле — бабакайлар (Әхмәтҗан карт) күршесендә генә иде... Әмма кызлар кулында гына калган йорт-җир күпме генә сакланып тора ала?! Ахырда кардәш-ыру үзара киңәшләшәләр дә, хуҗалык таралмасын, кызлар да терәксез калмасын, дип, минем атакайны, егерме яше тулар-тулмас, инәйгә өйләндереп, Хәбибрахман бабай йортына кертәләр. Атакай үзе дә бу өйләнүдән бик канәгать булган икән, миндә сакланган язмаларында «Хәләл зәүҗәмә кушылу белән бәхетем алга китте» дип язып калдырган. Һичшиксез, инәй аңа бик кулай килгән һәм яраткан да ул аны... Шул яшьтән бәйсезлеккә ирешү, үз башына дөнья көтү һәм хуҗалык итү ул заманда, әлбәттә, зур бәхеттән саналган булырга тиеш. Инәйне бик сабыр, акыллы хатын, ди торганнар иде, ә атакайның инде бик дәртле, куәтле чагы — шулай булгач аларның килешеп, ятатышып тату гына «дөнья көтүләре» бер дә гаҗәп түгел. Әлеге яшьли генә калган ике балдызны да — Мәрьям белән Кәримәне үстереп, бик матурлап кияүгә бирәләр. Шул рәвешчә, шома гына бара тормыш, әкрен генә үтә гомер, ат-тун бар, мохтаҗлык юк, кардәш-ыру күп, кунак-төшем дә күп, туйлары да һаман булып тора. Әмма шушы тигез генә аккан тормышның бер зур кимчелеге була, хәер... бу турыда соңрак. Ә хәзергә шуны гына әйтәсем килә: атакай үзенең әлеге язмаларында, инәйгә өйләнеп, утыз биш яшенә хәтле Каргалыда үткәргән гомерен иң бәхет-

ле, иң хозур чагы итеп саный. Һәм мин моңа бик ышанам, чөнки атакай үлгәнче кадәр шул Каргалысын, андагы тормышын, кардәшләрен, дус-ишләрен сагынып яшәде.

Атакайны егет чагында бик чибәр булган, диләр. Хәер, мин белгәндә дә ул чибәр иде: урта буйлы, җыйнак гәүдәле, җиңел сөякле; кечкенә җирән сакал-мыеклы чиста ак йөз, бик килешле тулы гына иреннәр, бик туры борын һәм күксел-соры, зур гына күзләр — әнә шундый иде ул. Сиксәнгә җиткәндә дә ул сыгылып төшмәде, бөкресен чыгарып йөрмәде.

Аннары табигате белән дә егет кеше булуын сөйлиләр. Җитез хәрәкәтле, ачык күңелле, җор сүзле, уен-көлке яратучан иде, диләр. Ул матур гына җырлаган да, гармун да уйнаган, оста гына биегән дә. Туйлардан һәм мәҗлесләрдән аны бер дә калдырмаганнар. Бизәгән мәҗлесләрне!.. Хәтта аның яшь чакларын белүчеләрдән шуны да ишеткәнем бар: туй кайткан чакта, ул төпкә җигелгән атка йөзе белән тарантаска карап атлана икән дә кияү белән кәләшкә гармун уйнап бара икән. Бик үк ышанып та бетәсем килми моңа, әмма шулай да дәртле-кыю егетләр туй вакытында ниләр генә эшләмәгәннәр!..

Мин белә башлаган чакларда, атакай инде кырыктан узган кеше иде. Җигүле атка арты белән атланып баруларын күптән оныткандыр, билгеле, ләкин барыбер җырлый да, уйный да, кәефе килгәндә биеп тә алгалый иде. Эчке мәҗлесләрендә генә түгел, өйдә ялгыз утырганда яки ишегалдында эшләп йөргән чагында да җырларга ярата иде. Тик, ни хикмәттер, атакайның бу җыр-музыка сәләте миңа бер дә күчмәгән — мин җырлый да белмәдем, берәр уен коралында уйнарга да өйрәнә алмадым. (Хәлбуки мандолина белән скрипканы тотып караган чакларым булды, ләкин барыбер берни дә чыкмады.) Ә менә атакайның нечкәрәк тавыш белән сузып кына җырлаганын читтән генә тынымны да чыгармыйча, бик әсәрләнеп тыңлый торган идем. Мин, күрәсең, инәй ягына охшаганмын — инәй ягыннан берәүнең дә җырлаганын белмим. Үзенең дә җырлаганын миңа бервакытта да ишетергә туры килмәде. Хәер, ара-тирә өйдә ялгызы калып, тәрәзәдән тышка тик кенә карап торган чагында, ул әллә нигә бер, авыз эченнән генә мөнәҗәткә охшатыбрак нидер көйли иде, ләкин минем колак салганны сизсә, шунда ук туктый да торган иде.

Әйе, инәй төсе-бите һәм табигате белән дә бөтенләй башка иде. Кыз вакытында ул, әлбәттә, ямьсез булмагандыр. Чем-кара озын чәч толымнарын мин дә әле хәтер-

лим. Ләкин мин беләбашлаганда ул инде шактый йончыган һәм ямьсезләнгән хатын иде. Күзләре бозылган, кызарып тора, тешләре дә төшеп бетә язган, аркасы да бөкрәя төшкән иде. Яшерә алмыйм, башка малайларның әниләре чибәр, ә минеке ямьсез дип пошынган чакларым да булды — ләкин бу чын сәбәбен белмәүдән иде. Ә чын сәбәбе... хәер, ул турыда алдарак әйтелер...

Ә тормышлары бер дә начар булмаган. Иркен, мул яшәгәннәр. Атакай күбрәк кәсеп итеп йөргән. Бу эшкә ул яшьтән үк тартылган, чөнки бабасы Әхтәм карт та, атасы Әхмәтҗан да иген игү, мал асрау өстенә алыш-биреш итү белән дә шөгыльләнгәннәр. Дөрес, Каргалы үзе сәүдә җире түгел, атнага бер килә торган кечкенә базары да, соң гына җыелып, иртә таралып та бетә иде. Өч мәчетле зур авылда Гали байның таш кибетеннән башка бүтән кибет тә юк иде шикелле — белмим, истә калмаган... Бөтен халкы аның җиргә бәйләнгән, җир белән яшәгән (һәм җир өчен дип килгәннәр дә), ләкин һәрбер зур авылдагы шикелле монда да, базардан базарга йөреп, алыш-биреш итүчеләр дә аз булмаган. Билгеле, төрлесе төрле дәрәҗәдә — Гали бай кебек чардаклы, яшел түбәле өй, тимер ишекле таш кибет салдырган бик эресе белән беррәттән Кырлайчы Хәллә абзый кебек бөтен «товары» кечкенә сандыкка сыеп беткән җәяүле «сәүдәгәре» дә булган алар арасында. Гомумән, авыл кешесе тик ятарга яратмаган, хәрәкәттә бәрәкәт, дип, буш вакытында һаман базар чапкан, анысын алган, монысын саткан — ничек тә акча табарга тырышкан. (Ә акчаны ул бик яраткан.) Мин моны нэп вакытында үзем дә бик яхшы күреп калдым.

Менә минем атакай да, әйткәнемчә, малай чагында ук атасына ияреп, Дим буенда һәм Ачлыкүл ягында Акчуриннар[1] өчен йон җыеп йөргән. Үзенең әлеге язмасында ул, башкортлардан дусларыбыз күп иде, дип яза. Мәсәлән, Казанголда — Җәгъфәр карт, Ябалаклыда — Курмый карт, Кыдрачта — Сәфәргали агай, Буранголда — Җомагол карт — болар барысы да бай башкортлар, бик күп сарык, елкы биләгәннәр... Каргалыдан Дим буена кырык-кырык биш чакрым, Ачлыкүлгә утыз-утыз биш чакрым чамасы булыр, ул заманда бу җирләр күксел үлән дулкынланып яткан, төрән кермәгән тоташ кылганлы сәхрә булган да шул сәхрәдә ара-тирә башкортларның ак тирмәләр корып утырган җәйләүләре дә көтү-көтү утлап йөргән маллары гына очраган. Менә атакайның бабасы

[1] Сембер губернасындагы сукно фабрикаларының хуҗалары.— *Ә.Е.*

Әхтәм карт та, ул үлгәч, атасы Әхмәтҗан карт та шул башкортларга барып, ак тирмәдә ит ашап, кымыз эчеп, берәр атна кунак булып ятканнар. Ә кыш кергәч, башкортлар үзләре, дөя җиккән тар чаналарга ит-май төяп, Бүздәк ярминкәсенә барышлый да, ярминкәдән кайтышлый да безнең бабакайларга кереп, кунак булып китә торган булганнар. Әнә шулай күңелле, кызыклы итеп яза атакай бу аралашу-йөрешүләрне... Бик күп еллар узгач та, ул әллә кайчан үлгән башкорт дусларын «фәлән агаем да төгән җиңгәм» дип сагынып сөйли торган иде.

Инде өйләнгәч, атакай сәүдә эшенә җиң сызганып дигәндәй керешә. Үзеннән соң туган энеләре дә үсеп җитә, шуңа күрәдер, ахрысы, ул авыр крестьян эшеннән әкренләп читләшә, китә. Кибет ачып сату итми, базар йөри, ярминкәләрне калдырмый, нәрсә алып, нәрсә сатканын мин ачык кына белмим, ләкин зур байларга күбрәк тире-яры җыйган булса кирәк. (Моны аңардан калган әллә кайчангы иске, озын-тар гына исәп-хисап кенәгәсенә карап әйтәм. Ул анда елкы, үгез, кәҗә тиреләрен күпмегә сатып алганын гел генә язып барган.)

Әйтергә кирәк, атакай татарча бик әйбәт укый-яза белә иде. Вывескалар укырлык, адрес язарлык русчасы да бар иде. Татарча өслүбе дә әйбәт иде, соңгы гомерендә яшьлеген сагынып җырлар да, башыннан кичкәннәрне шигырь итеп тә язды хәтта. Срур тутакайның әйтүенә караганда, ул берничә кыш Төпкиле мәдрәсәсендә ятып укыган булган. Күбрәк укыса, бәлки, мулла, бәлки, мөгаллим була алган булыр иде. (Хәер, мулла булмас иде, нәселдә юк нәрсә, ә мөгаллимнәр күп чыккан безнең халыктан.)

Әмма ул сәүдә эшен яраткан. Ни өчен?.. Чөнки сәүдә итү аның өчен үзенә күрә бер хөрлек, бәйсезлек, булдыклылык билгесе булып саналган. Кыскасы, сәүдә итүдән табыш кына түгел, тәм дә тапкан. Билгеле инде, сәүдә эшен ул, һичшиксез, хәләл кәсеп дип санаган — Мөхәммәт пәйгамбәр үзе дә сәүдәгәр булган ич!.. Ни дәрәҗәдә оста сәүдәгәр булгандыр — бу кадәресе икенче мәсьәлә. Ул бит, асылда, хис кешесе иде, җыр яраткан, уен-көлке яраткан... һәм җан иясен дә бик ярата иде. Бервакытта да аның кулы җан иясенә күтәрелмәде — атка да ул сөеп, сыйпап кына дәшә иде. Кирәк чагында без тавыкны да күршеләрдән суйдыра идек.

Хәлбуки чын сәүдәгәрнең табигате башкачарак — корырак, катырак булырга тиеш түгел микән?.. Әйтә алмыйм. Ләкин ничек кенә булмасын, минем атакай чынлап торып сәүдә эшенә керешер өчен 1910 елның көзендә,

Каргалыдагы йорт-җирләрен калдырып, сәүдә үзәгенә әверелгән Дәүләкәнгә күчеп китә. Бу вакытта әле мин бишектәге сабый — бары яшь ярымлык кына... Бердәнбер, бүтән бала юк.

...Хәзер инде инәйнең кара шәлен ачарга да ярый торгандыр. Әйе, аны иртә бөккән, күзләрен бетергән рәхимсез сәбәп әнә шунда: тугыз бала табып, берсе-бер исән калмаган. Сабыйлар туып, күпмедер үскәч, нәкъ сөендерер һәм сөйдерер чакларында гына үләләр дә китәләр икән. Кайсы кызамыктан, кайсы чәчәктән, ләкин күбесе эч авыруыннан. Билгеле инде, ул заманда йогышлы авырулардан балалар күп кырылган. Ләкин бит һәммәсе дә түгел, берсе китсә, берсе калган. Ә менә инәйнең берсе дә калмаган — нигә, ни өчен аның башына гына мондый фаҗига?! Ис-акыл җитми бу хәлгә! Югыйсә, әйтүләренә караганда, һәркайсы туган чакта туптай таза да булган, имеш. Инәй үзе дә ара-тирә генә: «Мәрьямем бик матур булмакчы иде» яки «Тимербулатым бик тере — кулдан очарга гына тора иде»,— дип сөйләнеп куйгалый иде. Әмма ни үкенеч тотып кала алмаганнар шул, тугыз бала очканнар да киткәннәр!

Мине иң гаҗәпләндергәне — ул чактагы кешеләрнең наданлыгы һәм көчсезлеге. Каргалы бит инде зур авыл, укыган кешеләре дә аз түгел, ә менә белеп-аңлап ярдәмгә килүче дә, һич югы дөрес киңәш бирүче дә булмаган. Бер фельдшер кисәге булган шикелле, ләкин ул да корчаңгы атларны гына дәвалый белгән, имеш. Кыскасы, медицина юк, хәтта «морзаларга» да!

Хәзер сорашканда Срур тутакай (атакайның бертуган сеңлесе) миңа әйтә: җиңгәчәйнең сөте юк иде, баласын гел кулдан ашата иде, эч авыруын йоктыру күбрәк шуңардан килә иде, ди. Бәлки, дөрестер дә, тик минем бу хакта элек берәүдән дә ишеткәнем булмады. Инәй үзе хәсрәтен бер дә сөйләми иде, хәсрәте аның эчендә яшерен иде, һәм якыннан белгән кешеләр дә: «Хәдичәттәй бит ул ифрат та сабыр!» — дип әйтә торганнар иде. Әйе, ана кешегә сабыр итүдән башка ни кала?!

...Шуннан соң менә мин унынчы бала! Мине, корбаннар чалып, нәзерләр әйтеп, Алладан сорап алганнар. Мин, һичшиксез, яшәргә тиеш булганмын. Атакайның Дәүләкәнгә күчүе беркадәр шул теләк белән дә булмады микән? Чөнки балалары тормаган иске урынны ташлап китүне үзләренчә хәерлегә юраулары бик мөмкин. Яңа урында бит яңа өметләр дә туа...

...Ике елдан соң, унберенче бала булып, Илдархан исемле энем дөньяга килә. Тагын бер малай! Бичара инәй

өчен нинди зур бәхет дисәм, бу ничектер бер генә яклы булыр кебек. Юк, бәхет дигән нәрсә алай саф килеш кенә очрамый ул тормышта.

Бөтен кардәш-ыру, якын туганнар безне «ике бөртек» дип йөрткәннәр. Ике бөртек!.. Өсләрендә кан калтырап саклыйсы, үстерәсе бар әле аларны.

## ТӨП НИГЕЗ

Дәүләкәндәге тормышыбызны язганчыга кадәр, туган авылым турында күргән-белгәннәремне сөйләп бетерәсем килә. Күңелемдә шулай саклана — башта Каргалы, аннары инде Дәүләкән.

Каргалыда йөз илле елдан артыграк яшәп килгән нигезебез бар — бу минем бабакай Әхмәтҗан карт йорты. Менә шушы нигезгә атакай белән инәй еш кына кунакка кайта торган булганнар (Дәүләкән — Каргалы арасы ерак түгел, кырык чакрым чамасы гына). Инәй итәгендә энем белән мин дә, билгеле, кайтканбыз. Безне, ике бөртекне, тарантастан ук күтәреп алганнар, сөйгәннәр, кадерләгәннәр, әмма ләкин без аларны әле хәтердә сакларлык яшьтә булмаганбыз. Мин үзем, мәсәлән, бабакайлар йортын, андагы кайбер күренешләрне өзек-өзек итеп кенә дүрт-биш яшемнән хәтерли башладым шикелле. Ә тулырак, ачыграк һәм күбрәк тә итеп күрә-хәтерли башлавым җиде-сигез яшемә туры килә торгандыр. Һәм болары да бабакайлар ихатасыннан әллә ни ерак китмиләр.

Бабакайларның ихатасы (ишегалды) бик зур иде, иркен иде, күп җире бәбкә үләне белән түшәлгән иде. Тик кое тирәсе, абзарлар алды гына мал таптаудан үләнсез такыр иде. Урам буйлап яңа койма сузылган, өч капка баганасы басып тора, ләкин капка үзе ни өчендер юк... Әллә такталары, әллә куллары җитмәгән, Хода белсен!

Менә шул капкасыз баганалар арасыннан килеп кергәч, аз гына эчтәрәк, сул кулда бабакайларның алты почмаклы, калай белән япкан өйләре тора. Уң якта зур гына ак келәт, шул ук рәттә, ишегалдының түренә табарак, янә берме-икеме келәт, чилник (лапас), тагын ниндидер каралтылар, ә иң түрдә инде терлек абзарлары. Алар барысы да салам түбәле, тик келәтләрнең кыегына буй-буй киртәләр дә салынган.

Сул яклап исә, «капкадан» шактый эчтә, таза бүрәнәләрдән салынган, ләкин инде җиргә чүгә башлаган янә бер иске генә өй бар иде. Аш ызбасы дип йөртәләр иде аны, миче бик зур иде, кочак-кочак салам кертеп ягалар иде. Шул гөрләп янган утта Мәдинә җиңгәчәй зур чуен

тутырып бәрәңге (төмәнчә — бульба) пешерә иде. Терлекләр өчен булса кирәк, ләкин кайчагында безгә дә салып бирә иде. Без җыен ыбыр-чыбыр бала-чага түгәрәкләнеп утырып, агач табактагы кайнар бәрәңгене, үзебез азаплана-азаплана әрчеп, эре тозга тидереп, кара арыш ипие белән бик тәмләп ашый идек. Аннары бу өйгә кышның салкын көннәрендә туган бозауларны һәм бәрәннәрне ябып тоталар иде. Минем бәрәннәргә исем китә — алар өч-дүрт көннән инде бөтен өйне бетереп чаба башлыйлар, зурая төшкәч, мич башына хәтле сикереп меңәләр. Ә бозауларны озак тотмыйлар, бераз аяклангач та икенче бер җылы урынга күчерәләр... Соңыннан «аш ызбасы» юкка чыкты — кайчан, ни өчен сүткәннәрдер, белмәдем. Беренче герман сугышы вакытында утынга түгел микән?!

Истә калганы тагын — аш өеннән арырак кара мунча. Кергәч тә уң якта учак, учак өстенә чуерташ өелгән, шуңа терәлеп үк торган тәбәнәк ләүкә, ә каршыда кечкенә чалыш тәрәзә. Морҗа-мазар юк, якканда төтен чыксын өчен ишеген ачып куялар, шуңа күрә мунчаның бөтен эче корым сылагандай кап-кара. Ләкин, ни хикмәттер, бу кара корым кием-салымны буямый иде.

Бик кечкенә чагымда бабакай белән әбекайның мине шул мунчага алып керүләрен аз гына хәтерлим. Зур түгәрәк тазга утыртып юындыралар, аннары бастырып комганнан җылы су белән коендыралар. Ләүкәгә яткызып чабып та караганнар. Ләкин монысын мин бер дә яратмаганмын, имеш — разбой сала башлаганмын.

Ә менә унике-унөч яшьләремдә булган бер «вакыйганы» һич тә онытасым юк. Кышкы салкын көн иде. Абзаннан килгән кодача (җиңгәчәйнең сеңлесе) белән без икәү утын ташып, кара мунчаны ягып җибәрдек. Башта эче төтен күзләребезне кисте, тамак төпләренә утырды, аннары бераздан, учак ялкынланып янарга тотынгач, төтен кимеде, чыгып та бетте диярлек. Без мунчаның ишеген дә ябып куйдык. Кызу гына чытырдап янган утка карап янәшә утырабыз, нәрсә сөйләшкәнебезне хәтерләмим, тик шул чакта мин, ничектер тилереп китеп, калын гына киенгән кодачаны кочаклап үбәргә тырышып карадым. Кодача әллә ни ачуланмады да, бары: «Куй, маташма!» — дип кулымны гына алып ташлады. Ул инде буй җиткән таза кыз иде, бәреп очырса да, хәленнән килерлек иде. Ләкин очырмады — күрәсең, балага санады мине.

Кара мунча белән бәйләнгән «истәлекләр» шуның белән тәмам. Янә бабакайларның бөтен ишегалдына ямь биреп торган, урта бер җирдәрәк сиртмәле кое да бар

иде. Чатлы баганага тимер кендек белән утыртылган озын сиртмәнең җирдәге калынрак башына зур гына бүкән тагылган, ә югарыдагы нечкә очына таза бау, баугa шомарып беткән колга, колгага кара чиләк беркетелгән. Кое янында калын бүрәнәне чокып эшләгән су тулы озын улак тора, көтүдән кайткан сыерлар, сарыклар иң элек шунда йөгерешеп баралар. Кем дә булса кара чиләкне коега су алырга төшергәндә сиртмәнең калын башындагы әлеге бүкәнгә атланып, һавага күтәреләсе килә иде.

Коеның бурасы тәбәнәк иде, шуңадыр, ахры, безнең üше вак бала-чаганы ул тирәгә җибәрмиләр — кое үзенә тарта, дип куркыталар иде. Чынлап та, барып, коеның тирән караңгы төбенә иелебрәк карап торсаң, ничектер баш әйләнеп киткәндәй була иде. Әгәр шуннан тартып та алса? — Юк, белеп куганнар безне куркыныч-серле кое яныннан!

Иң артта — читәннән үргән, салам япкан терлек абзарлары, ләкин мин аларны яхшы белмим, чөнки, бердән, бәләкәй чагым, икенчедән, абзарлар җәй көне гел буш тора диярлек. Кояш баер алдыннан гына, сыер-сарыклар көтүдән, атлар эштән кайтып керәләр. Ә мине сыер сөзмәсен, ат типмәсен дип һаман саклыйлар иде.

...Абзарлар артыннан ук бәрәңге бакчасы башлана. Монысын яхшы хәтерлим, чөнки ызаны буйлап, җылыйомшак туфракка ялантәпи бата-бата, күп чаптым. Бакча бик озын, түбән таба сөзәкләнеп инеш ярына чаклы төшә. Яр астында инеш — Каргалы инеше, диләр аны. Ул бик сай, бик кечкенә, чуерташлар өстеннән сырланып ага — кайбер төшләреннән аяк чылатмыйча сикереп тә чыгарлык. Кер чайкарлык кына яту урыннары да бар. Кисмәк бүрттерерлек, кабык чылатырлык су җыелсын өчен кайбер җирләрен әзрәк ташлар белән дә буганнар.

Инеш кечкенә, тар булса да, үзәне шактый киң, ярлары да шактый биек. Язгы ташу вакытында кар суы шул ярларга сыеша алмыйча котырып, атларны агызып китәрлек булып килә, диләр, ләкин мин бу тыныч-юаш кына агып яткан инешнең андый чагын бервакытта да күрмәдем (язын-көзен без Каргалыга кайтмый идек).

Инешне кичеп, каршы яр өстенә күтәрелгәч, тар гына тугайлык башлана. Тугайлык тип-тигез, урыны-урыны белән бәләкәй генә урмандай кычыткан, алабута, шайтан таяклары үсеп утыра, чирәм җирләрендә бозаулар, казлар йөри, сугып киптергән зур-зур кизәк өемнәре тора.

Бу тугайлыкны тау итәге диярго дә ярый, чөнки аз гына баргач та биек, текә тау башлана... Тау гына түгел,

таулар! Инеш буйлап, бер сафка баскандай, тезелешеп килә бу ак маңгайлы кызыл таулар. Дәүләкәннән кайтканда иң элек әнә шул тауларны, аннары авылның нечкә манараларын күрәсең. Каргалы кешеләренең җырларына да кергән ул таулар.

Каргалыкай тавы киртләч-киртләч,
Киртләчләре бетәр кар киткәч.

Әйе, киртләчләр күп, болар — кәҗәләр таптап салган сукмаклар. Әмма тауның түбәсеннән итәгенә кадәр кар сулары ерып төшкән «сырлар» да җитәрлек.

Каршыбыздагы тауга кайчан менүемне хәтерләмим,— билгеле, кечкенә чагымда үзем генә менә алмаганмындыр инде, ләкин үсә төшкәч, Каргалы малайлары белән бергә, әлеге кәҗәләр төсле, ул тауларга күп менеп йөрергә туры килде. Безнең турыдагы Урталык тавы дигәненең өсте тип-тигез иде: рәхәтләнеп чап, уйна, көрәш! Борынрак заманда Каргалының җиткән кызлары һәм егетләре дә шушы тауга менеп төрле уеннар уйный, күңел ача торган булганнар. Ул заманны Срур тутакай бик яхшы белә һәм бик тәфсилләп, матур итеп сөйли дә. Кызлар бик горур, бик «строгий», ә егетләр бик тыйнак, әдәпле булганнар, имеш, сакчылы уйнаганда егет кызны куып җиткәч, кычкыртып кочакламаган, ә кул очын иңбашына тидереп кенә алган, имеш. Бәлки, бәлки... Ләкин мин үскәндә яшьләрнең тауга менеп уйнаулары беткән иде инде, тик ара-тирә генә аллы-гөлле чуар кызларның кояш баер алдыннан, тау түбәсендә тезелешеп, авыл өстенә карап утырганнарын әзрәк хәтерлим әле.

Соңрак, 1924—1925 елларда яшьләрнең җәйге уеннары ялан якка, тимер юл буендагы чирәмлеккә күчкән иде инде. Өч мәхәлләнең дә яшьләре шунда җыела иде. Егетләр, кызларның ниндиләре генә юк! Ул чакларда авылга Бәләбәйдән, Уфадан, Казаннан бик күп укучы яшьләр кайта иде. Алар арасында иске формаларын саклаган яшел фуражкалы, яшел тужуркалы картрак студентлар да очрый иде. Шәһәрчә киенгән бик сылу туташлар да бар иде. Авылчарак киенгәннәре дә бик көязыспайлар, шуның өстенә шактый кыю-шаяннар да иде. Каргалы яшьләренең әнә шул кичке зур уеннарын мин дә бер-ике тапкыр күреп калдым. Миңа ундүрт-унбиш яшьләр булгандыр, инде ис кергән, хыял әшли, күзләрем — кызларда гына! Тик, кызганычка каршы, мин әле кызлар арасына кереп китә алмыйм, мин әле егет булып җитмәгәнмен — кыюлык та, әрсезлек тә юк әле миндә. Шуның аркасындадыр инде мин Каргалы кызларыннан

бирәүгә дә гашыйк була алмыйча калдым. Ә егет булып өлгергәч, миңа инде туган авылыма кайтып йөрергә туры да килмәде. (Соңгы кайтуым 1924 елның җәендә булды шикелле.)

Әйе, Каргалы ул минем бала чагым. Хатирәләрем дә бала чакныкы. Иң элек, әнә югарыда язганча, бабакайларның иркен ишегалларын, келәт, кое, читән абзарларын, өй ишегеннән чыгуга каршыда гына басып торган мәһабәт тауларын күргәнмен. Шул ихата эчендә генә йөргәнмен, уйнаганмын, тавыклары, чебиләре белән танышканмын, аргач, каз бәбкәседәй, башымны үләнгә төртеп, йоклап та киткәнмендер, бәлки — бу минем әле бары ике-өч яшьлек чагым гына булгандыр. Азрак үсә төшкәч, урамга чыкканмын, күрше-тирә малайлары белән таныша башлаганмын. Бабакайлар йорты авылның нәкъ уртасында, каршыда гына иске агач мәчет — аны «урталык мәчете» диләр иде. Мәчет ихатасы кырыннан ук авыл зираты башлана. Анда иңкәйгән, кыйшайган иске кабер ташлары күп, яңалары бик аз, рәшәткәле каберләр дә күп түгел. Үсеп утырган агачлар бөтенләй юк диярлек, тик кайбер рәшәткәләр эчендә генә сирень куаклары күренә. Әмма зират өсте бер дә тапталмаган кылганлы куе чирәмлек иде. Чирәмдә җир җиләге күп була иде, ләкин аны нигәдер җыючы юк, бары без вак бала-чагалар гына курка-курка кереп җыйгалый идек.

Терәлеп торган күршеләребез — уң якта Бәлеш Усман, сул якта Әсәләй Шәрәфетдине. Усман абзый безгә якын кардәш — аның атасы белән минем инәйнең атасы бертуганнар. Үземне белә башлагач, иң беренче кереп йөрүем дә шуларга булды. Чиста җыештырылган якты, пөхтә өйләрен әле дә булса онытмыйм. Усман абзыйның өч улын беләм, шуның уртанчысы — Ибрай исемлесе — минем иң беренче уйнап йөргән дустым да иде. Яшькә күпмегәдер олырак, таза, базык малайга ияреп, мин Каргалының инеш буйларында, тау-чокырларында күп йөрдем. Ибрайның агасы өрлектәй таза Хәсән абзый танылган көрәшче иде. Ибрай үзе дә көрәшергә бик һәвәс иде, кыстый-кыстый мине дә көрәшергә мәҗбүр итә һәм, билгеле инде, чөеп кенә ташлый иде. Шулай да мин аңардан көрәшергә шактый ук өйрәнеп калдым һәм, бил ныгый төшкәч, үзем дә кайбер малайларны әйбәт кенә әйләндереп сала башладым. Хәзерге вакытта Ибраһим Янгуразов — отставкадагы полковник, Уфада тора, ә мин бары тик сержант кына. Күрәсез, чин ягыннан да безнең аерма бик зур.

Бабайкайлар урамы — авылның иң озын һәм иң төп

урамы — буе бер өч чакрымга сузыла торгандыр. Югары башы — югары оч, түбән башы түбән оч дип йөртелә. Һәр ике очта да якын һәм ерак кардәшләребез бик күп. Кайтып-китеп кенә йөргәнгә күрә, мин аларның бик якыннарын гына беләм: югары очтан, мәсәлән, Рәхмәтулла абзыйларны, Зүрәттәкайларны («тутакай» сүзе шулай кушылып әйтелә), түбән очтан Саттый җизниләрне, Сәгыйть бабакайларны... Ләкин алар барысы да диярлек мине һәм энемне беләләр иде, кунакка барганда яки үзләре килгәндә безне «Хәдичәттәйнең ике бөртеге» дип, сокланып, мактап, тәүфыйк теләп, башларыбыздан сөяләр иде.

...Хәзергә кадәр оныта алмыйм бик иртә күңелемдә уелып калган бер күренешне. Ул чакта миңа күпме булыр? — дүрт яшьләр чамасыдыр, шуннан да артык булмас. Җәйнең җылы-матур бер иртәсендә бабакай белән әбекай, читән тарантаска янәшә утырып, мине дә үзләре белән алып, каядыр барырга чыктылар. Каршыдагы мәчет тыкрыгыннан уздык, тимер юл аша чыктык, аннары такыр юлдан җирән алашаны әйбәт кенә юырттырып яшел кырлар буйлап киттек. Әйтәсе дә түгел, миңа бик күңелле, бик рәхәт иде. Бөтен тирә-ягым бик киң, бик якты — сулда тезелеп киткән Каргалы таулары, ә уңда һәм алда офыкка китеп югалган чуар иген басулары. Әбекайның итәгендә мин ялт-йолт каранып барам. Җирдән берәр кош күтәрелсә, шуңа башымны каерам, юл буенда берәр күбәләк талпынса, аңа да сузылмакчы булам. Шулай озак кына бара торгач, без ахырда ерак бер яланга җитеп туктадык. Хәзер менә чамалыйм, бу, мөгаен, Әркәсле яланы булгандыр — авылдан кыйбла тарафындагы ерак кырларны каргалылар әнә шулай дип йөртәләр иде. Без килеп туктаган җир тип-тигез сәхрә иде. Кайсы якка карама, бихисап чәчәкләр, ә җиргә төшкәч, мин куе үләнендә бөтенләй күмелә яздым. Тирә-ягымда ниндидер кортлар тонык кына безелди, ниндидер кошлар пырпыр очып китәләр, ә бер кошчык кайдадыр биектә шундый өздереп, шашынып сайрый ла, әйтерсең менә безне күрүдән шатлыгы эченә сыймый, мескеннең! Аның тавышы бер якыная, бер ерагая, гүя мине үчекли, ләкин мин аны күрә алмыйча йөдәп беттем. Мин әле ул кошчыкның тургай икәнен дә белми идем. Әмма миңа бик рәхәт иде, бик кызык иде — гүя мин моңарчы һич күрмәгән өр-яңа бер дөньяга килеп чыкканмын. Билгеле, хәйран калганмындыр инде, кая карарга, нәрсә эшләргә белмәгәнмендер... Йөрисем-йөгерәсем килгәндер, чәчәкләрне дә өзәсем килгәндер. Ләкин әбекай мине

ни өчендер үзеннән ерак җибәрми, гүя ашыкмаска кушкандай әкрен генә: «Чү, бәбкәм!» — дип әйтә тора.

Ә бабакай, атын тугарып, үләнгә җибәргәч, бераз читкә китеп, чирәмгә кара җиләнен җәйде дә намаз укырга керешге. Башта аягүрә, аннары тезләнеп укыды. Тирәягы куе үлән, шау чәчәк, менә шул үлән-чәчәкләр эченнән бабакайның нечкә муены белән кырпу бүреге генә күренә. Якты һавада күзгә күренмәс әлеге кечкенә кошчык талпына-талпына һаман өзелеп-өзелеп сайрый, үләндә йөргән җирән алаша да әледән-әле башын селкеп, тимер авызлыгын чыңлатып куя, ә без әбекай белән бер читтә нидер көткәндәй тын гына басып торабыз.

Ни хикмәттер, мин үскәч тә, олыгайгач та, хәтта менә картайгач та әнә шул күренешне — бабакайның үлән-чәчәкләр арасында тезләнеп намаз укуын һич оныта алмадым. Ниндидер бик якты бер эз калдырды ул минем бала күңелемдә. Бәлки, шул мизгелдә мин әйләнәмдәге сихри дөньяны ачыграк күрә, тирәнрәк тоя башлаганмындыр... Нәрсә дим, мин бит үзем дә үлән биеклек кенә бала, берни аңламаган, бернәрсә белмәгән бала гына. Тик менә хәзер уйлап куйгалыйм: шул бала чакта күргәнем миңа соңыннан иң авыр чакларда да дөньядан бизмәскә ярдәм итмәде микән?!

Бабакай белән бәйле тагын бер хатирәм саклана. Әлеге авылдан чыгып китә торган каршыдагы тыкрык буенда, мәчет ихатасы артында, аларның читән белән әйләндергән ындырлары бар иде. Ындыр әллә ни зур да түгел, урта бер җире тап-такыр... Менә шул ындырда көлтә таптатканны хәтерлим мин... Көз башы булгандыр инде, көннәр әле аяз, тымызык, бик җылы да иде. Ындырның тап-такыр уртасына бодай көлтәләрен, башлары белән эчкә каратып, зур түгәрәк итеп тезеп салганнар. Бабакай җигүле арбага минем ише ыбыр-чыбыр бала-чаганы төяп, шул көлтәләрнең башларын аты һәм арбасы белән таптатып, әкрен генә әйләнеп йөрде. Озак әйләндерде ул безне — тәмам кинәндек без бу рәхәткә! Көлтә таптату — ашлык сугуның бер ысулы икән ул. Ләкин моның белән генә эш бетмәде әле. Таптатканнан соң шул ук көлтәләрне хатын-кызлар чабагачлар белән алмаш-тилмәш дөпелдәтеп сугарга тотындылар. Бусы да бик кызыклы иде — дәртле сикерешә, күңелле тупылдаша чабагач башлары апайлар кулында!.. Ындырда иртә көзен ашлык сугу — бу авыл эшенең иң хозур чагы дияр идем мин...

Гаҗәп бу хәтер дигәнең! Күпме нәрсә онытыла, эзсез югала, ә кечкенә бер вакыйга гомер буена диярлек истә саклана. Ләкин менә бабакайның үзен ни сәбәптер ачык

кына күз алдыма китерә алмыйм. Дөресрәге, китерсәм дә, ничектер, еракта томанлы итеп күрәм. Ул юка гына гәүдәле, кәҗә сакаллы бер кеше иде, буйга да бәләкәй иде шикелле, һәм күпләр аны, очарга торган җиңел сөякле бик җитез карт иде, дип сөйлиләр. Бәләкәй булуына карамастан, мәчеттә ул бөтенесеннән калка биреп утыра икән. Холкы белән дә күкерт шикелле бик тиз кабынып китүчән иде, диләр. Улларын, киленнәрен утлы табага бастырырга яраткан булса кирәк. Ләкин бик тиз сүрелә дә икән. Андый чагында һәркемгә ачык чырай да тәмле сүз. Әбекайга ул, мәсәлән, «якты көнем!» дип кенә дәшә иде.

Мин аның озын ак күлмәк, кара камзул, йомшак кара читекләр киеп йөргәнен әзрәк хәтерлим. Тагын бернәрсә бик нык истә калган: кайнаган самоварны өстәлгә китереп куйгач, бабакай аның морҗасыннан утлы күмергә кечкенә лимон кабыгы төшереп җибәрә иде. Менә шуннан бөтен өй эченә гаҗәеп бер тәмле хуш ис тарала иде. Бу хуш исне минем әле дә булса онытканым юк, ләкин аңардан да битәр ул заманда авылда лимон булуына гаҗәпләнәм. Күрәсең, Бүздәк яки Дәүләкән базарыннан алып кайтканнардыр инде. Дәүләкәндә җиләк-җимеш подваллары да бар иде, аннары бик юка гына сурәтле кәгазьгә төрелгән лимоннарны Муллаҗан исемле агай, беләгенә кәрзин асып, урам буенча, «Лимон, кемгә лимон?» дип кычкыра-кычкыра сатып та йөри иде. Ансы да гаҗәп!

Бабакай турында белгәннәрем шушы урында өзелә дияргә дә ярый. Унҗиденче елның җәендә кыска гына каты авырудан соң, ул Каргалыда вафат була. Шулай итеп, мин бабакайның үлгәнен белсәм дә, ак кәфенгә төрелгән гәүдәсен үз күзем белән күрмәгәч, бу югалтуны артык авыр кичермәдем бугай. Дөрес, аңлыйм да, тоям да кебек: бабакай юк инде, базар саен диярлек безгә килмәс, безне — «ике бөртекне» — җитәкләп йөрмәс, юксынырбыз да, сагынырбыз да без аны, әмма чын хәсрәт дигән нәрсәне без әле юньләп белми идек.

Әбекайны инде мин яхшы ук хәтерлим. Бабакайдан соң әбекай дүрт ел яшәп, егерме беренче елны бездә, Дәүләкәндә вафат булды. Миңа ул чакта унике яшь, зиһен кергән, күңел күзе дә ачыла төшкән... Бүгенгедәй исемдә: егерме беренче елның гаять коры, эссе җәендә бездә ваба (холера) чире пәйда булды. Ара-тирә шул чирдән үлүчеләр дә була башлады. Ачлык әле килеп җитмәгән иде, әмма елның килеше бик өметсез, бик хәтәр иде.

...Беркөнне иртәнге чәй янында мин йокыда күргән төшемне сөйләдем: имеш, ниндидер читтән килгән ча-

панлы кешеләр безнең урамда өй саен дөя өләшеп йөриләр икән. Әле берәүнең, әле икенченең, әле өченченең ишегалдына кечкенә башлы, иләмсез зур дөяләрне кертеп, калдырып чыгалар икән... Шуны ишетү белән әбекай бик куркынып миннән сорады: «Ай бәбкәм, ул дәвәне безгә дә кертмәделәрме?» «Юк шикелле,— дидем мин, икеләнебрәк.— Безгә хәтле килеп җиткәннәрен күрмәдем». Шуннан соң әбекай бераз тынычланган кебек булды, шулай да авыз эченнән генә нидер укып, битен сыйпап куйды.

Әмма аның куркуы юкка гына булмаган икән. Сөйләгән чакта төшнең хәтәр мәгънәсен мин белми идем, белгән булсам, бәлки, сөйләмәс тә идем. Ә баксаң, төшкә кергән дөя ул Газраил, имеш! Берәр якының үләргә булса, шул юаш хайван төшкә керә, имеш!.. Дөрес, төшне минем алдымда юрамадылар — моны мин бары тик соңыннан гына белдем. Ә белгәч, ул хәерсез дөя безгә дә килеп җиттемеюкмы дип, үзалдыма озак кына азапланып баш та ваттым.

Ләкин ничек кенә юрама, ваба чире шулай да безнең өйгә килеп керде. Нәкъ менә әбекайга ябышты ул, һәм өч тәүлек дигәндә аны алып та китте. Зал белән янәшә кечкенә бүлмәбез бар иде — ул шунда ятты. Чире бик әшәке, бик каты булгандыр, ахрысы, чөнки атакай белән инәй көне-төне яныннан чыкмыйча аны карадылар. Көзән җыеруын басарга дип, берөзлексез кайнар су ташып тордылар... Фельдшер да килеп китте шикелле, ул киткәннән соң өйгә сасы карболка исе таралды. Тагын нинди чаралар күрелгәндер бу коточкыч үләткә каршы, белмим, истә калмаган, ләкин безне әбекай яткан бүлмәгә якын да җибәрмәделәр. Инде җан биргәч, карчыклар юып, кәфенләгәч кенә безгә: «Балалар, әбекаегызны күреп калыгыз»,— дип керергә куштылар. Ләкин мин кермәдем, йөрәгем җитмәде,— мин гел читтә, ишегалдында үземә урын таба алмыйча һаман йөреп тордым... Каргалыга безнекеләр ничектер хәбәр итеп өлгергәннәр, җирлисе көнне кырык чакрым җирдән, атын ак күбеккә батырып, Нигъмәтулла дәдәкай килеп җитте. Башка улкызлары килә алмадылар, күрәсең, хәбәр итәргә өлгермәгәннәрдер, аннары елы да бик хәвефле иде шул.

Әбекайны үлгән көнендә үк җирләделәр. Өйдән алып чыкканда, шактый гына кеше җыелган иде. Башта мәчеткә илтеп, яшел чирәмдә генә җеназа укыдылар, аннары мәет ташый торган сай, озын әрҗәгә салып, өстен палас белән каплап, илибатыр (элеватор) артындагы яңа зиратка алып киттеләр. Әрҗәнең баш-башыннан һәм аркылы таякларыннан күтәргән кешеләр әбекайны бик кызу алып

бардылар — безнең шәригать шулай куша икән. Картлар, муллалар утырган атлар арттарак калсалар, юрттырып куып җитәләр иде... Әле көзгә ерак, әле җәйнең уртасы гына, ә дөнья инде көйгән, саргайган иде ул елны... Үлән үзеннән-үзе уалырга тора, аяк астыннан вак чикерткәләр як-якка чәчри, хәтта кошлар да очмый иде.

Зиратка барып җиткәч тә, мин кабергә якынаерга кыймыйча кешеләр артында читтә генә тордым. Әбекайның гәүдәсен ләхеткә куйганда да якынаерга җөрьәт итә алмадым. Юк, булмаса булмый икән! Сынсыз, өнсез бер хәлдә идем мин, тик сизәм — яшьләрем генә үзлегеннән ага иде... Әйтергә кирәк, үлем-бетемнән бик нык ятсыну, үлгән кеше тирәсендә чуаласы килмәү, бигрәк тә мәет йөзенә карый алмау миндә гомерлеккә диярлек сакланып калды. Хәзер дә, ниндидер бер мәҗбүрият мәет янына барырга кушса да, мин аның йөзенә ничек тә карамаска тырышам. Әмма бу һич тә куркудан түгел. Кешенең тере кыяфәте һәм мәете шулхәтле бер-берсеннән ерак, гайре табигый нәрсә ки, мин, күрәсең, шуңа тиз генә ышана да, ияләшә дә алмыйм.

Шулай итеп, без әбекаебызны кинәт кенә югалттык та куйдык. Намаз арты саен ул: «Йа Раббем, кыска сырхау, ансат үлем бир!» — дип дога кыла торган иде. Менә кабул булды теләге... Хәер, сырхавы бик кыска булса да, җан бирүләре, ай-һай, ансат булмагандыр. Чире нинди бит — ваба! Ләкин бернәрсәгә торып-торып хәйран калам, ни хикмәттер, бу коточкыч чир безнең беребезгә дә йокмады, эләкмәде. Нәрсә генә саклап калгандыр — хәзергәчә аңлый алганым юк.

Безнең өйгә кергән бу беренче үлем иде, беренче зур мәет чыкты безнең өйдән... Һичшиксез, бик авыр кичердек без бу югалтуны. Бабакай үлгәннән соң, әбекай безгә ешрак килә һәм озаграк торып та китә иде. Шуңа күрә без, ике малай, аңа бик ияләшкән идек. Ул гәүдәгә тулы, таза карчык иде, холкы да сабыр-басынкы (бабакайның нәкъ киресе) һәм тәмле телле дә иде. Безне, тугыз баладан соң исән-имин генә үсеп килгән «ике бөртек»не, әлбәттә, бик аяган һәм яраткан булырга тиеш. Менә аның сабый чагыбызда башта мине, аннары энемне чөя-чөя әйткән такмагы:

Бабасының нисе бу — таута менәр таягы!
Әбисенең нисе бу — сөт өстендә каймагы!
Дәдәсенең нисе бу — кысып буар билбавы!
Тутасының нисе бу — энҗе-мәрҗән кулбавы!
Атасына ай кебек, инәсенә көн кебек,
Килеп киткән кунакларга куй б...дай юк кебек!

Әнә шулай үчтеки иткән ул безне... Моны мин, күп еллар узгач, Срур тутакайдан ишеттем. Хәзер инде үзем дә әбекай яшенә килеп җиткән кеше, әмма минем сабый чагым әнә шул такмагында саклана.

## ТУГАННАР

Бабакай белән әбекайдан соң миңа иң якын туганнар булып, билгеле инде, аларның уллары белән кызлары калды. Болар атакайның ике энесе — Нигъмәтулла белән Мөхәммәдъяр дәдәкай һәм ике сеңлесе — Рокыя белән Срур тутакай. Энеләре Каргалыда, сеңелләре исә Уфада торалар иде. (Кияүгә чыккач киткәннәр.) Аларның балалары да миңа шулай ук иң якын кардәшләр — туганнан туган гына, Каргалыча әйтсәк, тудыклар булабыз. Без барыбыз да бер заманда үстек. Югалтулар күп булмады, тик Рокыя тутакайның бердәнбер улы Әнвәр генә сугыштан кайтмады, аннары минем энем Илдархан кырык тугыз яшендә үлеп китте. Калганнарыбыз хәзергә исән әле... Яшь ягыннан тиңрәкләребез бала чактан алып шушы көнгә кадәр, араларыбыз ерак булса да, һаман очрашып, күрешеп тордык. Ләкин кайбер кече яшьтәгеләре белән минем үземә бик сирәк очрашырга туры килде — мәсәлән, Нигъмәтулла дәдәкайның Идиятулласын мин бала чагында гына бер күреп калдым.

Инде килеп шуны әйтергә кирәктер: бу якын туганнарның берсе дә Каргалыда тормыйлар, күптән алар төрлесе төрле якка таралып беттеләр. Уфа, Казан, Мәскәү, Алма-Ата, Ташкент, Севастополь, тагын кайлардадыр яшәп яталар. Йөз илле ел безнең бабайлар яңа җирдә таралмыйча яшәгәннәр, ә минем буын ун-унбиш ел эчендә таралды да бетте. Дөрес, Каргалыдан элек тә читкә китүчеләр аз булмаган, ләкин берсе китсә, бишесе калган, төп нигез һәрвакытта сакланган. Һәм китүчеләр шул нигезгә гел кайтып йөргәннәр... Безнең нигез исә сугышка хәтле үк бетерелгән иде. Хәзер авылга кайтсаң, кемнең капкасына сугылырга белмәссең. Хәер, нигезләреннән аерылучылар Каргалыда бер безнекеләр генәме соң?! Күп алар, бик күп... (Хәтерлисездер, «Туган туфрак» дигән хикәядә авылга кунакка кайткан Клара бабасының ташландык, буш йорты урынына исе китеп карап тора — бу уйлап чыгарылган нәрсә түгел, чыны шулай.)

Минем тудыкларның балалары читтә туып үсте, алар күптән өйләнеп яки кияүгә чыгып, үзләре инде балалар үстерде. Болар, безнең оныклар дип әйтик, Каргалыны, әлбәттә, белмиләр, күргәннәре юк, һәм күрергә бернинди

теләк тә, ихтыяҗ да юктыр, минемчә. Аларның бит үз «туган туфраклары» йә Казанда, йә Алма-Атада, йә Ташкентта... Әле Каргалының үзендә туганнар да аны исләренә төшерәләр, сагыналар микән? Барлык җепләр дә күптән өзелеп беткән бит инде. Хәер, бик сирәк кенә төшләренә керә торгандыр әле...

Инәйнең бер ир туганы да юк иде, ике сеңлесе — берсе Ташлыкүлдә, икенчесе Шәрлекулда иде. Шәрлекулдагы Мәрьям тутакайны мин бөтенләй белмим диярлек, ул иртә үлгән шикелле, аннары Шәрлекул Дәүләкәннән шактый ерак булганга күрә, без аңа кайтып та йөрми идек. Ә менә Ташлыкүлдәге Кәримә тутакайларга мин җәй саен кайтмыйча калмый идем. Кәримә тутакай белән Кәшшаф җизни безнең иң якын, иң яраткан туганнарыбыз иде. Ташлыкүл бер генә мәчетле авыл, җирләре тигез дала, туфрагы кара уылдык шикелле, игенне күп игәләр, уңышны да күп алалар иде. Гомумән, халык анда таза тормышлы иде, Кәшшаф җизниләр исә авылның иң хәлле кешеләреннән иде. Йортлары зур, калай белән япкан, келәт-амбарлары, лапас-абзарлары — барысы да таза-нык, ишегаллары бик иркен, өй янында матур гына бакчалары да бар — анда җәйнең эссе көннәрендә умарталар өзлексез гүү итеп тора иде. Мин аларга нэп елларында кайтып йөрдем, ләкин бервакытта да аларда ялчы-мазар күрмәдем. Бөтен эшне үзләре җимертеп эшлиләр иде. Кәшшаф җизнинең кул арасына керерлек ир баласы да юк иде, торганы кызлар һәм бөтен эш бары шул кызлар өстендә иде. Мәсәлән, миңа тиңрәк Наилә сабанын да сөрә, тырмасын да тырмалый, җитмәсә, әле атка да иярсез генә атланып йөри иде. Дөрес, дүрт кыздан соң Кәримә тутакай бер ир бала да тапты. Тәлгать исемле иде ул, Кәшшаф җизнинең үзе төсле тыныч кына, сабыр гына бер малай иде... Сугыш башланган елны гына Тәлгать Куйбышевтагы план-экономика институтын бетерә. Бетерү белән ирекле рәвештә фронтка китә һәм 1941 елның көзендә, Мәскәүне фашистлардан яклаган чагында, һәлак тә була. Бердән бергә тия, дип халык юкка гына әйтми икән... (Минем «Ана һәм кыз» дигән хикәям Тәлгатьнең үлгәнен ишеткәннән соң язылган иде.) Атасы Кәшшаф җизни әле утызынчы елларның башында ук кыска гына авырудан соң үлеп киткән иде. Тәлгатьне апалары карап үстерде. Сугышның каһәре аларга нык тиде — Әминә белән Һәммәюннең дә ирләре шулай ук сугыш кырында ятып калдылар.

Әйе, заманында мин Ташлыкүлгә бик теләп кайта идем. Кәримә тутакайның аш-суы бик тәмле була иде.

Алардагы шикелле куе сөзмәне, чөгендерле катыкны һәм күзәнәкләренә чык бөртегедәй май тулган тары беленен минем бүтән бер җирдә дә ашаганым булмагандыр. Аннары безне якын иткән тагын бер сәбәп — кызлары Әминә дә, Наилә дә безгә килеп, берничә кыш Дәүләкән мәктәбендә укыдылар. Кәшшаф җизни үзе дә базар саен диярлек килмичә калмый иде. Ул, мәрхүм, китап ярата иде, базарда очраган китапларның искесен дә, яңасын да җыеп алып китә торган иде.

...Еллар узды. Кәримә тутакай да күптән вафат. Дүрт кыз калганнар иде, шуларның өчесе хәзерге көндә исәннәр. Уфада төпләнеп, һәркайсы яңа квартирада бик әйбәт, тыныч кына яшиләр. Инде оныкларын үстерәләр... Тик, кызганычка каршы, Наилә генә иртәрәк китте, ә ул араларында иң акыллысы, иң булдыклысы иде, аңа буйсыналар иде барысы да.

Мин аларга һәрвакытта бик соклана идем. Бердәм, чыдам, тырыш булып чыктылар минем бу кыз туганнарым. Тамырлары нык ка күрәдер инде, яшьтән үк эштә чынык канга күрәдер. Авыр сугыш елларында ирләр сынды, алар сынмадылар. Язмыш аларны кая гына ташламасын, һәр урында тормышларын матур корып, тук-бөтен яшәделәр. Хәерчелек аларга бәйләнә алмады!

Ярый, тыныч Ташлыкүлдән шау-шулы Каргалыга яңадан килик әле... Әйткәнемчә, анда ике дәдәбез — Нигъмәтулла белән Мөхәммәдъяр калды. Без хәзер шуларга кайтып йөрибез. Шул ук йорт, шул ук ихата — барысы да искечә. Тик елдан-ел без үсәбез һәм үсә барган саен авылыбызны күбрәк беләбез.

Ике бертуган икесе дә герман сугышына алынган булганнар. (Без әле бәләкәй ул чакта.) Мөхәммәдъяр дәдәкай соңрак китә һәм, озак та тормыйча, чәнчә бармагын имгәтеп, борылып та кайта. Ничектер тиз ычкына дәдәбез!.. Мөгаен, берәр төрле авыруын тапканнардыр, югыйсә чәнчә бармак өчен генә җибәрмәсләр иде.

Ә менә Нигъмәтулла дәдәкай сугышның башында ук китә, Австрия фронтында күпмедер сугыша, ахырда чорналышта калып, пленга эләгә... Өч тапкыр пленнан кача ул, тик өченче качуында гына дошман кулыннан ычкына.

Аның фронттан кайтып керүе шактый кызыклы. Унҗиденче елның кара көзендә булса кирәк, безнең авыл турысыннан фронт ташлап кайтучы солдатлар төялгән эшелоннар үтә башлый. Шундый эшелоннарның берсеннән татар солдатлары: «Сезнең авылныкы Нигъмәтулла кайта-а! Арттагы эшелонда, хәбәр итәргә куш-ты-ы!» — дип кычкырып узганнар, имеш. Кемдер шуны ишетеп,

чаба-чаба әбекайларга килеп әйткән икән. Билгеле инде, өйдәгеләр бу яшендәй ялтырап киткән хәбәрдән башта сискәнеп-каушап, аннары чиксез шатланып, дәррәү аякка басканнар. Шунда ук ат җиктереп, якын туганнардан берәүне (Рәхмәтулла абзыйны булса кирәк) Бүздәккә чаптырганнар (ул заманда поездлар Каргалыга туктамыйлар иде), үзләре тиз генә мунча якканнар, тәкә суйдырганнар. Ләкин ул көнне, тәмам караңгы төшкәч, тирләп беткән ат буш кайткан... Өмет дигәнең гаҗәп нык, үҗәт нәрсә ул! Икенче көнне, өченче, дүртенче көнне дә атны Бүздәккә куалар, эшелоннар да һаман уза торалар, әмма ләкин Нигъмәтуллабыз юк та юк! Өйдәгеләр, бичаралар, аптырап, гаҗиз булып, саргаеп бер атна, ике атна, хәтта бер ай көтеп карыйлар, аннары инде килеп әйтүче ялгыш ишеткәндер дип, әкренләп өметләрен өзәләр. Әбекай озак-озак кына намазлык өстендә утыра, ә Мәдинә җиңгәчәй казан янында тавышын чыгармыйча гына ачы яшьләрен коя...

...Һәм менә, инде кыш кергәч, чатлама суык төннәрнең берсендә Нигъмәтулла дәдәкай узып баручы эшелоннан авыл турысында сикереп төшеп кала. Өстендә иске бушлат, аягында каткан итекләр, бөрмәле капчыгын иңенә аскан — тимер юлдан чана юлына чыгып, кызу гына шыгыр-шыгыр атлый-атлый, үзләренең ишегалларына кайтып керә. Аяк тавышын ишетеп, ике эт — Муйнак белән Алабай — баскыч астыннан өрә-өрә атылып чыгалар. Ләкин Нигъмәтулла дәдәкай бер дәшү белән өрүләреннән туктыйлар да янына барып бөтерелә, чиный, өстенә үк сикерә башлыйлар. Исең китәр этләрнең сизгерлегенә! Әйтерсең дүрт ел түгел, дүрт кенә көн хуҗаларын югалтып торганнар!

Хуҗа башта ишегалдын әйләнеп, каралты-кураларны, абзардагы малларны карап чыга, шуннан соң гына өй ишегенә килә. Бу вакытта әле өйдәгеләр ятмаган була — Мәдинә җиңгәчәй нидер бәйләп, әбекай исә сәкедә тәсбих тартып утыра. Тышкы ишекне кемнеңдер каты гына шакыганын ишетеп, җиңгәчәй үзе өйалдына чыга. Ләкин шунда ук борылып та керә. Артык каушаудан булса кирәк, ул төсе качкан хәлдә еламсырап: «Анакай, ишектә бер ир тавышы, әллә Нигъмәтулла инде...» — ди. Әбекай: «Ай Аллам!..» — дия-дия, әпен-төпен сәкедән төшеп, селкенә-селкенә чыгып китә. Һәм Нигъмәтулла дәдәкайны ияртеп керә... Сөйләшерлек тәкатьләре булмый, өчесе дә сәке кырыена утырып, елашып алалар, аннары гына өйдә хәрәкәт башлана. Тиз генә мич тә ягыла, самовар да куела, таба да чыжларга тотына. Дәдәкайның

аягына җылы пима бирәләр... Төн булуга карамастан, әбекай кушуы буенча, урам аша гына торган Гыйният мулланы чакырып, никах яңарталар. Көн яктыруга инде мунча да өлгерә.

Бу язмада уйлап чыгарылган берни дә булмаска тиеш, шуңа күрә әйтәсем килә: Нигъмәтулла дәдәкайның герман сугышыннан ничек кайтып керүен дә, күп еллар узгач, Мәдинә җиңгәчәй үзе миңа сөйләгән иде.

...Ике бертуган, әмма никадәр зур аерма! Бер анадан туып та бу хәтле бер-берсенә охшамаган братларны минем әле күргәнем дә юк диярлек. Кыяфәтләре үк башка: Нигъмәтулла дәдәкай урта буйлы, таштай тыгыз, какча гәүдәле, ә Мөхәммәдъяр дәдәкай буйга да кечерәк, гәүдәгә дә юанрак... Әмма иң зур аерма аларның табигатендә иде. Нигъмәтулла дәдәкай гаять җитез, кызу, тиктормас бер кеше булса, Мөхәммәдъяр дәдәкай, киресенчә, шактый басынкы, авыр кузгалышлы кеше иде. Һәм бу аерма ике туган арасында еш кына низаг та тудырган. Хикмәт шунда, Нигъмәтулла дәдәкай ялкаулыкның чын дошманы — үзе дә тынгы белмәгән, кешегә дә тынгы бирмәгән, шуның өстенә шактый кызу канлы да булган. Билгеле, әкрен, салмак, ваемсыз энесенә аңардан еш кына эләккән дә булырга тиеш.

Әйтәләр, Мөхәммәдъяр дәдәкай яшь чагында йокларга бик яраткан, дип. Уятмасалар, тәүлек буена да йоклый икән. Моны ялкаулыктан күргәннәр. Хәлбуки, Срур тутакайның әйтүенә караганда, бу аның шундый авыруы икән, тик үз вакытында моны берәү дә белмәгән.

Мөхәммәдъяр дәдәкай тыштан шулай мәнсез, пошамансыз булып күренсә дә, аның, минемчә, кызыксынган нәрсәләре дә бар иде. Мәсәлән, ул матур әйберләрне ярата иде, безгә килсә, шкафтагы төрле кызыклырак әйберләрне алып, әйләндереп-әйләндереп карый торган иде. Шулай ук китап актарырга, рәсемнәр карарга да ярата иде. Татарча да, русча да укый белә иде ул. Ашыкмыйча гына акыл да саткалый иде, үзенә күрә фәлсәфәсе бар иде аның...

Ә Нигъмәтулла дәдәкай дөнья куа, гәп сатып тик утыру кая ул — бөтенесенә өлгерергә кирәк. Кызу эш өсләрендә оек-чабатадан, алача ыштаннан, киез эшләпәдән өермәдәй бөтерелә иде. (Йоклаганда чабатасын да салып тормый икән.) Каргалы басулары һәм печәнлекләре шактый еракта, бабакайларның печәнлеге, мәсәлән, авылдан биш-алты чакрым, «болото» дигән җирдә иде. Нигъмәтулла дәдәкай ялгыз, унөч-ундүрт яшьлек кызы Зөләйхадан башка кул арасына керерлек беркеме дә юк. Калган

балалары үзе пленнан кайткач кына тудылар. Зөләйханы да ул бик иртә эшкә җикте.

Эшләргә, эшләргә! Эш аның өчен мәҗбүрият кенә түгел, җан таләбе дә иде шикелле, ничектер дәртләнеп, ләззәт табып эшли иде ул. Аныңча, эшсезлектән дә оят нәрсә юк. Менә шушы нигездә безгә дә аңардан «өлеш» чыккалый иде.

Җәйнең бушрак вакытында Нигъмәтулла дәдәкай Дәүләкән базарына да чаптырып килеп җитә иде. Кояш баер алдыннан гына килә. Кояш белән бергә торып базарга йөгерә, анда эшләрен бетергәч, кайтып ашык-пошык кына бер-ике чынаяк чәйне каплый да сары атын җигеп, капкадан ук юрттырып китеп тә бара. Ә без, ике малай, эшсез йөрибез, безнең ат та юк, сарык-кәҗә дә юк, бер генә сыерыбыз бар, ул да көтүдә. Кыскасы, печән чабасы да юк, урак урасы да юк. Димәк, безгә, үсеп килгән ике малайга, урам таптаудан башка эш тә юк. Билгеле инде, Нигъмәтулла дәдәкай мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Кул-аягы таза малайлар эшсез йөрсеннәр, имеш! Моның өчен ул атакайны да тирги, инәйне дә тирги, ә без инде аның күзенә күренергә дә куркабыз. Кайчагында исә, тиргәп кенә калмыйча, инәйгә туп-туры әйтә: «Җиңгәчәй, малайларның алмашка күлмәк-ыштаннарын карап бир, мин бу ике хөрәсән ялкавын алып китим әле булмаса, йөрмәсеннәр монда б... тибеп, миндә ипекәйнең тәмен белебрәк ашарлар!» — ди... Инәй дә риза була, ләкин икебезне дә түгел, мине генә җибәрә. (Ничек инде «ике бөртек»нең икесен дә җибәрсен ди?! Юк, булмый, ярамый!) Шулай итеп, Нигъмәтулла дәдәкай мине кабык арбасына утыртып, кырык чакрымдагы Каргалыга дыңгырдатып алып та китә торган иде.

Авылда эш бервакытта да бетеп тормый — иртә яздан кара көзгәчә. Кайчан гына кайтсаң да берәр «эш өстенә» туры киләсең, мәсәлән, кизәк суктырган чакка... Каргалының үз урманы юк диярлек, агачны бик ерактан китерәләр, шул сәбәпле бөтен авыл җәй башыннан ук күп итеп кизәк суктыра. Бу шактый авыр һәм пычрак эш. Иң элек тирес өемен түгәрәкләп җәеп, аңа мичкә-мичкә су ташып, бик нык чылаталар. Шул ук вакытта ыштан балакларын сызганган берәр ир кеше, җәем уртасына басып, озын тезгенле атны әйләндереп куа-куа тиресне озак кына таптата. Шулай чылата һәм таптата торгач, тирес тәмам йомшарып, измә хәленә килә. Аннары инде чират кизәк сугучыларга җитә.

Бу эштә күбрәк җиткән кызлар да үсмер малайлар. Ыштан балакларын тездән югары сызганып, күлмәк ит-

экләрен бөрмәләренә кыстырып, алар шома такта өстенә куелган пар калыпка тирес измәсен сәнәк яки куллары белән генә салып, таптый-таптый тыгызлыйлар да, шуннан калыпларын йөгертә-йөгертә читкә илтеп, чирәм өстенә каплыйлар. Кизәк тигез, елтыр гына кара кирпеч булып төшеп кала.

Миңа, кунак малай булганга күрәме, әллә көче җитмәс дипме, калыпның сыңарлысын гына бирәләр иде. Сыңарлы калып белән сугуы, әлбәттә, күп җиңел, ләкин мин бу эшне баштарак бер дә яратмадым. Тирескә кулларым белән керергә чиркана идем. Әчкелтем исеннән җирәнә идем. Әмма Нигъмәтулла дәдәкай кушкан эштән котылу юк, аннары башкалар эшләгәндә тик тору мөмкин дә түгел... Чиркаsuccesses-җирәнебрәк булса да тотынырга туры килә иде. Ә бераздан инде тиреснең үзенә дә, исенә дә әкренләп күнегәсең, парин! Хәтта әле көлешә-көлешә эшләгән кызлар янында, алардан калышмаска тырышып, җиңел калып белән кизәкне йөгерә-йөгерә чирәмгә илтеп салуы кызык та була башлый... Тирес җәеме никадәр зур булса да, ишле кулдан йолка торгач, без аны кояш баюдан күп элек бетереп тә куя идек. Шуннан соң кое янындагы озын улактан су сибешә-сибешә кул-аякларны бик әйбәтләп юабыз, кызлар мунча алдына кереп, чиста күлмәкләрен киеп, төзәтенеп чыгалар. Аннары инде ишегалдының тазарак, чирәмлерәк җиренә зур торыпша җәеп әзерләнгән табын әйләнәсенә җиңгәчәйнең каклаган ит турап пешергән өреле куе токмачын ашарга утырабыз. Барысы да — өреле токмач та, каймаклы катык та, бүген генә мичтән чыккан арыш ипие дә ашап туйгысыз! Ипекәйнең тәме монда башкарак икән шул! Аннары тагын, авыз бер генә минут та үз эшеннән туктап тормаса да, кызлар үзара гел кызык сөйләп шырык-шырык көлешеп утыралар. Кемнән, нәрсәдән? — кайчак аңламыйча да калам, тик миңа да төрттермиләр микән дип эчемнән генә борчылып куям. Ә шулай да бик күңелле, бик хозур!.. Тирес сугуның ахыры дип әйтәсем килә.

Әнә, шул рәвешчә, Нигъмәтулла дәдәкай мине «ипекәйнең тәмен белеп ашарга» өйрәтте. Бер кайтуда тирес суктырса, икенче кайтуда йә печәнгә, йә уракка алып бара иде. Кайчагында күрше малайларына ияртеп, ат куна да җибәргәли иде. Кыскасы, тик тотмый иде... Чын авыл эшен мин, асылда, бары шул Нигъмәтулла дәдәкай аркасында гына азмы-күпме белеп тә калдым. Дөрес, мин әле бик яшь идем, үсмер малай гына, өстәвенә тал чыбыктай нечкә-арык та идем, әмма ләкин аякка җип-җиңел оек-чабата киеп, шуңардан эш кешесенә әйләнүемне

тоеп, пакустагы үләнне агач тырма белән селкә-селкә җыеп йөрү минем өчен бик кирәкле дә һәм бик файдалы да булган икән.

Бу урында шуны да әйтергә кирәк, Нигъмәтулла дәдәкай никадәр кызу-кайнар кеше булмасын, ләкин ул бервакытта да тиктомалга кычкырмый һәм җикеренми иде. Ничектер менә киреләнергә урын калдырмаслык итеп, өзеп кенә куша белә иде. Инде сүзен тыңлаучыга һәм янып эшләүчегә аңардан да тәмле телле кеше юк диярсең. Ә безгә, бала-чагаларга, үзенекеме, күршенекеме — һич аермыйча, гел «бәбкәм» дип кенә дәшә торган иде. Минемчә, ул, асылда, йомшак-нечкә күңелле кеше булырга тиеш, чөнки мин аның йорт хайваннарына да шулай сөеп дәшкәнен ишетә идем. Әмма бер кабынып китсә, үзен-үзе белештермичә кешене тетеп ташларга да күп сорамый иде. Әлбәттә, теле белән. Хәер, җиңел кабынып киткән шикелле үк ул бик тиз кайтып та төшә иде: әле генә бөтенесен пыр туздырган дәдәбез, баксаң, кай арададыр сүрелеп тә өлгергән — берни булмагандай ачык чырай белән һәркемгә ягымлы дәшеп, дөнья бетереп йөри дә башлаган. Аннары сабыр холыклы җиңгәчәй дә аны, ярсу атны тыеп кына торгандай, гел тынычландырып кына тора иде.

Нигъмәтулла дәдәкай кебекләрне безнең Каргалыда, яшенә карамастан, «Егет кеше, удалой!» дип йөртәләр. Тәвәккәл, кыю, җитез, сүзгә тапкыр, туйлар һәм мәҗлесләр күрке — әнә шундый кеше иде Нигъмәтулла дәдәкай да. Өстәвенә, ул озын көйләргә шактый матур, моңлы итеп җырлый да торган иде. Гадәттә, аягүрә басып, бөеренә таяна биреп, тавышын әз генә калтырата төшеп, сузып җибәрә иде:

Утырдым ла көймәнең әй түренә,
Карадым ла суларның төбенә.
Су төпкәйләрендә һич кара юк,
Хак язганны күрми чара юк.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Аңа, Нигъмәтулла дәдәкайга, хак язганны, дөресрәге — язмаганны, ничек итеп күрергә туры килгәнен чираты җиткәч сөйләрмен әле. Ә хәзер башкасына күчик.

Мин Мөхәммәдъяр дәдәкай туен яхшы ук хәтерлим. Аны, шактый утырган егетне, егерменче елның салкын кышында түбән очтагы Мамлеевларның Хәнифә исемле кызына өйләндерделәр. Туйга Дәүләкәннән без дә кайттык. Миңа бары унбер яшь кенә, ләкин, шуңа да карамастан, бертуганның малае диптер, ахрысы, мине кияү егетләре арасына кертеп йөрттеләр. Башта әллә ничә пар

атта түбән очка туй китте. Кияү, өч кияү егете һәм мин — ярты кияү «егете» — өйдә калып тордык. Күп тә үтмәде, ат атланган бер егет, чаптырып килеп, кыз өендә никах укылганын хәбәр итте. Шуннан соң барыбыз да чыгып пар атка төялдек тә, тын авыл урамын дәртле кыңгырау тавышы белән сискәндереп, җил-буран уйнатып китеп тә бардык. Күчердәге дилбегә тоткан егет төптәге атның башын югары күтәрттереп, ә мичәүдәгесенең башын кырын салындырып кына алып барды. Үзенә күрә бер осталыктыр инде бу... Барып җиткәч, ишегалды түрендәрәк торган келәт сыманрак кечкенә бер өй каршында чанадан төштек. Кияү кергәнне көтеп утыручы кыз шушы өй эчендә икән. Каргалы туеның борыннан килгән мәҗбүри тәртипләре бар: иң элек без кулга-кул тотынышып, аллыартлы тезелештек. Беренче булып баш кияү егете, аның артыннан кияү үзе, аннары инде калганнарыбыз, иң койрыкта мин. Кияүнең өстендә яшькелт тышлы, бәрән эчле тун, башында кама читле бүрек, кулында кечкенә сандыгы — анда аның кодачаларга дигән исле сабын, ефәк чәчүргеч, түгәрәк көзге, тагынниндидер бүләкләре. Минем өстә дә тун, тик тышсыз кайры тун (хәзерге заман кешеләренең исләре киткән дубленка), ә башымда патша казаклары кия торган зәңгәр постау түбәле, озын йонлы, галәмәт биек бүрек. Билгеле, бу бүрек минем өчен махсус тектерелгән дә түгел, кибеттән башка үлчәп алган да түгел, бәлки, толчокта берәр исерек солдат кулыннан сатып алынган булырга тиеш (ул елларда кием-салымны толчоктан гына табарга да мөмкин иде). Бүрек күзләремне каплап тора, мин аны һич яратмыйм, кияргә хурланам, ләкин кимичә чарам да юк.

Хуш, кулга-кул тотынышып тезелешкәннән соң, баш кияү егете ишек тоткасын тотып торучы җиту-чая гына кыз белән нидер сөйләшеп алды. Барысы да көлештеләр, кызга бүләк бирделәр, шуннан соң гына кыз ишекне ачып, безне эчкә уздырды.

Кергәч, чәй табыны әзерләнгән өстәл тирәсенә утырыштык. Өстәл тулы өем-өем сый, чирек белән бал да тора... Яшь кәләшне без күрмәдек — ул чыбылдык эчендә утыра иде. Йоласы шулай, күрәсең, кияүне, мөгаен, чыбылдык эчендә каршы ала торгандыр... Теге җиту кыз безгә зур таба белән кайнар коймак кертеп куйды. (Ул кияү белән кәләшне шушында карау өчен махсус куелган икән. Бәлки, әле үзе дә яшь килендер.) Егетләр нигәдер ашыгалар иде, коймакны аннан-моннан капкалап, берәр генә чынаяк чәй эчтеләр дә, кияүгә хәер-дога теләп, урыннарыннан тордылар. Без чыгып киттек. Мөхәм-

мәдъяр дәдәкай, ни өчендер шактый ук кызарып һәм уңайсызланган төсле дә булып, кәләш янында үзе генә торып калды.

Аннары инде без, кияү егетләре, башка кунакларга кушылып, кыз ягыннан туй күтәрешкән кешеләрнең мәҗлесләренә йөри башладык. Арада мин, йоннары күземә кереп торган хәшәрәт бүрекле малай гына булсам да, әйтергә кирәк, мәҗлесләрдә игътибардан һәм сыйхөрмәттән бер дә читтә калмадым (чөнки кияүнең «читтән» кайткан якын туганы). Бу самогон заманы иде, ул чакта аны «күмүшкә» диләр иде. Башта руслардан ала торган булганнар, аннары инде үзләре дә «куарга» өйрәнгәннәр. Менә шул сасы нәрсәне миңа да әз генә эчертеп карадылар. Мин аңардан өтелдем, буылдым, үлә яздым, шуннан соң «тәкъдим» итүче булмады.

Туй, кыз ягында ике-өч көн дәвам иткәннән соң, егет өенә кайтты. Хәзер, егет ягыннан баручыларга ияреп, кызны озатучы туганнары да килделәр (аларны бездә «җиңгәли баручылар» дип әйтәләр)... Кышкы айлы кич иде, түбән очтан югары очка таба кыңгырау тавышлары белән бөтен авылны шаулатып килгән әллә ничә пар ат, ялгыз атлар бабакайлар ихатасына чаптырып ук килеп керделәр. Шул чакта кемдер мылтыктан да атып җибәрде. Каршы алучылар күп иде, кайтып керүчеләрнең күбесе кызмача иде, шуңа күрә буталыш, шау-шу да көчле иде. Кияү атын ишек төбенә үк китерделәр, киленне чанадан ак киез өстенә төшерделәр, Нигъмәтулла дәдәкайның кызы Зөләйха киленгә кашык белән бал-май каптырды. Икенче үрәчәле чанада кайткан килен әйберләрен — яшел сандыгын, урын-җирен — җырлый-җырлый өйгә керттеләр.

Туй кияү ягында да ике-өч көн барды булса кирәк. Билгеле, бу тарафта да туй күтәрешкән якын туганнар кыз ягын чиратлашып йөртеп, кунак иттеләр. Ләкин мин монда «кияү егете» түгел идем инде, башка балалар белән бергә буталучы малай гына, шуңа күрә безнең тарафтагы мәҗлесләрне күрмәдем дә диярлек. Һәм туйның кайчан беткәнен дә ачык кына хәтерләмим. Кияү өендәге соңгы мәҗлес тә, «җиңгәли килүчеләрнең» кайтып китүләре дә төнлә булган, ә без, ыгы-зыгыдан тәмам арган балачага, төрлебез төрле урында йоклап калганбыз.

Әнә шулай үтеп китте Мөхәммәдъяр дәдәкай туе да. Өйдә хәзер яңа кеше — яшь килен. Бусы инде миңа икенче җиңгәчәй — Хәнифә җиңгәчәй була. Ак чырайлы, юка-җиңел генә һәм бик җитез дә икән үзе. Ләкин оялчан әле, өй эчендә дә бөркәнчек ябынып, зурлардан

битен яшереп йөри. Басынкы, авыр кузгалышлы Мөхәммәдъяр дәдәкайга бик кулай килгән диләр аны... Чынлап та, алар соңыннан бер-берсенә ансат кына яраклашып һәм яратышып яшәделәр. Балаларны да күп үстерделәр: Хәмзә, Зәүҗән, Рәүф, Зәйнәп, Фәнүз — болар да миңа «тудыклар», ягъни иң якын туганнар.

Бу ике дәдәм турында тагын бер вакыйга минем хәтеремдә саклана — форсаттан файдаланып менә шуны да сөйләп үтәсем килә. Шул ук егерменче елның җәе. Мин янә Каргалыда. Кем белән кайтканымны белмим — атакай да, инәй дә янымда юк иде. Ә күргәнем, исемдә калганы менә нәрсә: өйнең зур як түрендә, агач кәнәфидә өч авыл карты һәм алар янында шәльяулык ябынган, укалы камзул кигән әбекай утыра. Алардан читтә, ишек төбендәрәк, Нигъмәтулла белән Мөхәммәдъяр дәдәкай басып кына торалар. Ә мин әбекай янында аңа елышып кына утырам. Өйдә киеренке тынлык. Бары әбекай гына ашыкмыйча нидер сөйли, ә картлар алларына караган килеш ара-тирә башларын гына селкеп куялар. Нәрсә турында сүз бара — мин әле белмим, тик бераздан гына төшенеп алдым: әбекай үзе исән чакта уллары белән кызларына аталарыннан калган мал-мөлкәтне бүлеп бирергә булган икән. Картлар исә менә шушы бик мөһим эштә аңа үзләренең гадел киңәшләре белән ярдәм итәргә тиешләр икән. Шуннан соң бар булган мөлкәтне — ат, сарык, сыер кебек аяклы малларны, абзар, келәт, лапас, мунча кебек каралты-кураларны, ниһаять, арба, чана, сбруй һәм шактый күп эш коралларын бүлгәләргә керештеләр. Башта әбекай үзе кемгә нәрсә бирергә теләвен әйтә, аннары картлар, үзара әзрәк мәслихәтләшкәннән соң, кыска гына итеп ризалыкларын белдерәләр: «Ярый, Аллага тапшырдык, шулай булсын! Игелеккә язсын!» — диләр (кайчагында сүз озаккарак та сузыла, ләкин гел риза булышу белән бетә).

Кемгә нәрсә тигәнен мин әйтә алмыйм инде, ләкин картлар хөкеме гадел булгандыр, ахрысы, чөнки шунда тыңлап торучы ике туганның берсе дә ризасызлык белдереп сүз әйтмәде. Моңарчы шома гына барды бу эш. Ахырда чират иң төп милеккә — шушы сөйләшеп утырган өйнең үзенә килеп җитте. Монсы инде шома гына узмады. Башта шуны әйтергә кирәк, бу өй 1906—1907 елларда гына салынган бик яңа өй иде әле. Бүрәнәләре дә юньләп каралырга өлгермәгән, түбә калае да шул килеш, бер тутыккан җире дә юк. Үзе алты почмаклы өй — зур ягы дүрт стеналы, кечкенә ягы зурысына кушып салынган өч стеналы... Зур (яки түр) якның урам-

га таба, ә кече якның ишегалдына чыга торган ишекболдырлары да бар. Менә шул өйне кемгә калдырырга яки ничек итеп бүләргә? Әбекай әйтә, мин Мөхәммәдъярымда калам, аңарда торачакмын, шуңа күрә зур якны аңа бирәсем килә, ди... Беразга авыр тынлык урнашты, башлап сүзен әйтергә берәү дә ашыкмый иде. Ләкин шул чакта — һич көтелмәгән бер хәл — Нигъмәтулла дәдәкай мич буена чүгәләде дә йөзен ике кулы белән каплап, тавышын ничек тә чыгармаска тырышып җыларга да тотынды. Бу хәлдән әбекай да, картлар да бер мәлгә тынып, тәмам аптырашып, югалып калдылар. Ә мине әллә нишләтеп җибәрде дәдәкайның җылавы, әйтерсең йөрәгемне кемдер кысып тотты, хәтта куркытып та җибәрде. Олы ир кешенең җылавын минем әле бер дә күргәнем юк иде. Картларның берсе, ниһаять, ипләп кенә әйтте аңа: «Нигъмәтулла, нишләвең бу, куй, ярамый... Сүзең булса әйт, әйтергә хакың бар, ә без тыңларбыз, мәслихәтләшербез, шулай булмыйча!» — диде. Шуннан соң Нигъмәтулла дәдәкай бераз тынып торды, әзрәк тынычлангандай булды, аннары борын очындагы эре яшь бөртеген сыпырып ташлады да, ашыкмыйча, тыелып кына сүзен әйтә алды: «Анакай, кәбәм, ни бит... Үзең дә беләсең, бу өйне мин иңнәремдә күтәрдем, мин бит бүрәнәләрен үзем кисеп, үзем урманнан ташыдым... Шуның өченмени миңа өч кенә стена?.. Өч атның да икесен Мөхәммәдъярга дидең, сүз әйтмәдем, инде өйдән мәхрүм итмәссең дигән идем, анакай, кәбәм!»

Әйе, бик киеренке, авыр бер ара иде бу... Мин Мөхәммәдъяр дәдәкайга карадым, ул ишек төбендәрәк таш сын шикелле басып тора, йөзе ак, тавыш-тыны юк. Нинди генә хөкем чыгарсалар да, алдан ук риза кебек,— шундыйрак бер кыяфәт иде аңарда. Әмма иң авыры, һичшиксез, әбекайга иде — хәлиткеч сүзне бит ул әйтергә тиеш. Зур улының һич көтмәгәндә йөзен каплап җылап җибәрүе һәм үпкә катыш әрнеп, ялварып әйткән сүзләре аңа нык тәэсир итте булса кирәк, ничектер кинәт кенә сүнеп-боекланып, тирән уйга калгандай, башын да салындырып, күпмедер вакыт сүзсез-өнсез генә утырды. Аннары үзалдына авыр гына бер сулап куйганнан соң, ашыкмыйча әкрен-тыныч кына яңадан сүзен башлады: «Нигъмәтулламның бу өйдә хакы күбрәк икәнен мин белмичә, кем белсен. Дөрес әйтә ул, иңнәрендә күтәрде... Ходай — шаһит, улларым икесе дә миңа газизләр... Ләкин мин аларның чамаларын да беләм бит. Нигъмәтуллам, иншалла, өйсез калмас, яңасын салырга да хәленнән килер. Ә Мөхәммәдъярга авыр булачак, төп нигездән аерырга

ярамый аны... Юк, Нигъмәтуллам рәнҗи күрмәсен, өйнең зур ягын Мөхәммәдъярга калдырыйк, шуңа сезнең фатиха бирүегезне сорыйм, кардәшләр!»

Билгеле, мин әбекай сүзләрен алтмыш елдан соң үземчәрәк яздым, әмма төп мәгънәсе шулай иде дип бер дә икеләнмичә әйтә алам. Әйе, ана кеше төпчек улының мәнфәгатен яклады, чөнки төпчек улы шуңа бик мохтаҗ, хәтта шуның өчен генә ул Мөхәммәдъярында калырга да тели иде. Ләкин картлар бу өй мәсьәләсендә үз хөкемнәрен әйтергә ашыкмадылар. Бер якны да кыерсытырга теләмичә, үзара җайлап кына мәслихәтләштеләр... Нигъмәтулла да хаклы, Гаффә (әбекайның исеме) тутайныкы да дөрес... Ничек итеп аларны килештерергә?.. Аннары мәсьәләнең бу ягы да бар: өйгә төп хуҗа кем? Төп хуҗа, әле үзе исән чагында, аналары инде. Димәк, аның ихтыяры беренче нәүбәттә искә алынырга тиеш. Шулайрак фикер йөрттеләр картлар һәм ахырда өйнең зур ягын Мөхәммәдъярга калдыруны тиеш таптылар. Ләкин шуның белән бергә Нигъмәтулла дәдәкайны юатып та, үгетләп тә әйттеләр: «Син, Нигъмәтулла, Мөхәммәдъяр түгел, син бөтенләй башка. Өч стенаны бик тиз дүрт тә итәрсең, теләсәң, алты почмаклысын да булдырырсың, еллар гына имин торсын. Бу дөньяда бөтен нәрсә фани — кешенең малы да, җаны да, тик аңа карап, арагыз бозылмасын, бер-берегезгә терәк булып тату гына яшәгез... Ә син, Мөхәммәдъяр, мал кадерен бел, әрәмшәрәм итмә, бетерүе ансат булса да, табулары бик читен... Атагыз мәрхүм нәселегездә хөрмәткә ия бер зат кеше иде, анагыз Гаффә тутай — ил каршында абруйлы бер карчык — аның хәер-догасын алып калырга тырышыгыз!» — диделәр. Ике бертуган бу нәсихәтне баш иеп кенә тыңладылар, күңелләрендә ни булгандыр — икесенең берсе дә авыз ачып сүз әйтмәделәр. Шуннан соң барысы да кул күтәреп озын гына дога кылдылар.

Әнә шулай уелып калды бу вакыйга минем хәтеремдә. Күп нәрсәләр онытылды, әмма, ни хикмәттер, бусы менә онытылмады. Бәлки, Нигъмәтулла дәдәкайның чүгәләп җылавы яки әбекайның хәсрәтле уйчан йөзе моңа сәбәптер — хәзер инде моны аңлавы да һәм аңлатуы да бик читен. Һәрхәлдә, бала чактагы аңсыз, әмма сизгер күңел эше бу — күргәннәрдән нәрсәнедер шунда ук ташлаган, ә нәрсәнедер бабай булгач та онытма дип саклаган.

Биредә тагын шуны өстәп әйтәсем килә: минем атакай мал бүлешкәндә өлешкә керүдән баш тарткан икән. Сәбәбен әйтә алмыйм, бәлки, сугыш елларында болай да бик нык какшаган хуҗалыкны таратып, авылдагы ту-

ганнарын артык зәгыйфьләндермәс өчендер, ә бәлки, андагы хуҗалыкка күптән катнашы булмаганга һәм көче кермәгәнгә күрәдер... Соңгысы дөресрәктер дип уйлыйм. Шулай да атакайга бер тарантас тигән иде шикелле, ләкин, атыбыз булмагач, ул тарантас та Дәүләкәнгә кайтмады.

Бер елдан соң инде әбекай үзе дә ваба авыруыннан кинәт кенә үлеп китте. Ачлык елны без Каргалыга кайтып йөрмәдек, шулай ук Каргалының үзеннән дә килүчеләр булмады кебек... Шуңадыр инде, мин андагы туганнарның бу афәтле елны ничек үткәреп җибәрүләрен белмим диярлек. Әлбәттә, җиңел булмагандыр, интеккәннәрдер, бәлки, ачыкканнардыр да, чөнки җир, бичара, чәчкән орлыкны да кайтарып бирмәде. (Ярый, алабутасы булды әле.) Бигрәк тә Мөхәммәдъяр дәдәкайга бик авыр килгәндер, бәхетсезлегенә каршы, бүлешкәндә тигән ике атның берсе нишләптер зыянлаган да булган. Шулай да алар ачлык тырнагыннан исән-имин котылганнар иде.

Минем яңадан Каргалыга кайта башлавым йә егерме икенче, йә егерме өченче елга туры киләдер, ахрысы... Мәгәр шуны яхшы беләм: әлеге төп йортта Нигъмәтулла дәдәкай үзе генә тора иде инде. Ике тәкә башы бер казанга сыймый дигәндәй, күрәсең, ике гаилә дә бер өйгә сыя алмаган. Ничек кенә булмасын, ике брат үзара килешкәннәр дә, Нигъмәтулла дәдәкай зират буендагы урамнан буш урын алып, шунда Мөхәммәдъяр дәдәкай өчен бүрәнәдән, салам белән япкан, җыйнак кына ызба торгызган. Янә өстәп бер ат та биргән. Шулай итеп, берберсеннән бик нык аерылган ике туган ике җирдә һәм ике йортта яши башлаганнар. Ихтимал, бу икесе өчен дә хәерлерәк булгандыр.

Мин инде кайтканда, билгеле, гел төп йортка кайта торган идем. Чөнки бу — әбекайдан калган йорт, сабый чактан ук мине шунда алып кайтканнар... Бөтен истәлекләрем дә бары шул төп йорт белән бәйләнгән. Күптән нигезе бетерелсә дә, минем аны онытканым юк һәм яңадан йөз ел яшәсәм дә онытмам дип уйлыйм.

Хәзер миңа атакайның ике сеңлесе турында да кыскача гына булса да сөйләргә кирәктер инде. Болар Рокыя тутакай белән Срур тутакай. Иң гаҗәбе шул: болар да ике бертуган братлары шикелле үк бер-берсеннән бик нык аерылалар иде. Бөтен яктан да. Рокыя тутакай табигате белән бик тыйнак, юаш, чынлап ачулана да, зарлана да белми торган, азга да канәгать, аздан да сөенә торган, бик саф күңелле һәм туган җанлы кеше иде.

Гәүдәгә дә чебеш кебек юка-ябык кына, шулай саклана ул минем күз алдымда... Ә Срур тутакай бөтенләй башка. Ул чибәр, сылу, үткер, яшьтән үк бик зиһенле, ирләрдә булмаган акыл үзендә, сүзе һәм тотышы белән кешене үзенә карата белә. Җырга, музыкага сәләтле, хәтта артистлык кабилияте дә бар аңарда. Кыскасы, гранд-дама!.. Хәзер Срур тутакайга сиксән алты яшь, ә хәтеренә һәм ачык зиһененә исең китәр... Алар арасындагы аерма тагын шуннан гыйбарәт: Рокыя тутакай укымыйча калган яки бик аз укыган, ә Срур тутакай үз теләге белән Уфага китеп пансионатта торып укыган, хәтта күпмедер вакыт Петербургта да булып кайткан. Укуын бетергәч, Каргалыга кайтып, учительница булган — балаларны русча укыткан (шуңа күрә «мөгаллимә» димим). Әйе, ул — үз заманының белемле һәм алдынгы туташы. Аңа мондый юллар ачылуының, минемчә, ике сәбәбе бар: беренчедән, аның яшьлеге 1905 елдан соң татар дөньясында башланган уяну, күтәрелү, мәгърифәткә омтылу чорына туры килә (ә безнең Каргалы кешеләренә укуга омтылу электән үк хас нәрсә), икенчедән, ул — туганнары арасында иң кечесе, төпчек кыз, җитмәсә, характеры да заманча тәвәккәл-кыю, шуңа күрәдер инде аның теләгенә каршы төшәргә базмаганнар (ә минем атакай исә аның укырга омтылуын һәрвакытта яклап килгән — моны Срур тутакай үзе дә әйтә)... Кыскасы, Срур тутакайның тормыш юлы бәхетле һәм матур башлана.

Ләкин инде Рокыя тутакайның тормышы бөтенләй икенче юлдан китә. Иң элек аны яшьли генә Ибәтулла исемле җизнәсенә кияүгә бирәләр. Эш шунда ки, Ибәтулла җизни башта әбекайларның дәү кызы Зөләйха тутакайга өйләнгән була. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, Зөләйха тутакай беренче баладан ук үлеп тә китә. Үзе дә, сабые да... (Аның исемен соңыннан Нигъмәтулла дәдәкайның беренче кызына кушалар.) Менә шуннан соң, безнең татардагы гадәт буенча, тол калган җизнигә балдызын бирәләр... Ибәтулла җизни өйләнгәч тә, Рокыя тутакайны Уфага алып китә һәм алар шунда әйбәт кенә тора да башлыйлар. Әмма ләкин бәхет дигәнең бер килмәсә килми икән ул яки килсә дә, көзге кояштай, бик тиз югала икән. Инде менә Ибәтулла җизнинең үзенә әҗәл чире эләгә — астыртын усал яман шеш чыга аның муенына. Өмет аз, котылу чарасы юк диярлек (хәзер дә юк әле ул), җизнинең хәле көннән-көн начарлана бара. Ахырда аны Каргалыга алып кайталар. Күпмедер вакыт аталары өендә ятканнан соң, 1917 елның январь башында, әйтергә кирәк, көтелмәгән бер чактарак, Ибәтулла

җизни, ниһаять, дөнья куя. Кырыкка да җитмәгән таптаза кеше!

...Көтелмәгән чактарак, дидем. Әйе, гаҗәеп бер хәл! Язмышның мәкерле шуклыгы димме, ничек итеп аңлатырга да белмим, ләкин Ибәтулла җизнинең үлүе... нәкъ менә Срур тутакайга никах укыткан көнгә туры килгән икән. Хәзрәтләр никах мәҗлесеннән чыгып, җеназа укырга киткәннәр. Шулай итеп, бабакайлар өенә зур шатлык тирән кайгы белән бергә, бер үк көнне җитәкләшеп килеп кергән... Хәер, моны әйтүе генә ансат.

Мин үзем, гәрчә туйга кайткан булсак та, бу хәлне һич тә хәтерләмим. Җиде яшьлек бала гына идем әле мин... Аннары кыш үзәге, бик салкын чак, Ибәтулла җизни, әйткәнемчә, аталарында вафат, гәүдәсен дә шуннан алып чыкканар, билгеле, безнең ише җылы өйдә утыручы вак бала-чаганың бернәрсә белмичә калуы гаҗәп тә түгел... Бары күп еллар узгач кына, Мәдинә җиңгәчәй миңа бу хакта сөйләде. Хәйран калып һәм аптырап, мин: «Ничек булды соң ул, ник туйны кичектермәделәр икән?» — дип сорагач, җиңгәчәй болай диебрәк аңлатты: әҗәлнең көнен-сәгатен алдан белеп булмый шул, ә туй көне Срурның каникул вакытына туры китереп, алдан ук билгеләнгән иде. Аш-сулар әзерләнгән, кунаклар чакырылган, хәзрәтләргә әйтелгән, инде тәгаенләнгән көне килеп җиткәч кенә аны ничек үзгәртәсең?.. Бик читен эш бит ул туй хәтле туйны кичектерүе... Алланың язганы шулдыр инде, ахыры хәерле була күрсен, диделәр дә никахны укытырга булдылар. Шатлыгы, кайгысы бергә узды шулай итеп.

Рокыя тутакай Ибәтулла җизнидән берсенән-берсе кечерәк өч бала белән кала. Әлбәттә, кайгы баштан ашкан... Һәм минем шушы урында Ибәтулла җизни турында кайбер ишетеп белгәннәремне әйтеп үтәсем килә. Ишеткәннәрем исә түбәндәгедән гыйбарәт: Ибәтулла Терегулов моряк булган, хәрби флотта хезмәт иткән, япон сугышында катнашкан. Минем тутакайларга (башта Зөләйхага, аннары Рокыяга) әнә шул кампаниядән кайткач өйләнгән икән. Яхшы ук грамоталы да булган ул.

Срур тутакайның сөйләвенә караганда, Ибәтулла җизни подпольедагы революционерлар белән бәйләнеш тоткан, имеш. Моның әсасы[1] менә нидән гыйбарәт: Уфа губернаторының канцеляриясендә җизнинең авылдашы Әхмәтсолтан Терегулов дигән кеше хезмәт иткән. Бу инде укыган кеше, статский советник, губернатор канцеляри-

[1] *Әсасы* — нигезе, төбе.

ясендә зур гына урын биләгән булса кирәк. Мәсәлән, Уфаның татар яшьләре спектакль яки концерт куяр өчен рөхсәтне губернатордан еш кына аның ярдәме белән алганнар. (Монысын миңа Хәсән Гобәйдуллин сөйләгән иде.) Һәм шушы кеше, ягъни Әхмәтсолтан Терегулов, Уфа социал-демократлары белән яшерен бәйләнештә торган. Цюрупа һәм Брюханов кебек күренекле большевиклар белән шәхси таныш та булган, диләр. Билгеле инде, губернатор чиновнигы белән подпольедагы социал-демократларның бәйләнеше ниндидер бер максатка хезмәт иткән булырга тиеш. Кыскасы, алар Әхмәтсолтан Терегуловтан үзләрен кызыксындырган мәгълүматларны алып торганнар булса кирәк. Шундый сүз дә бар: революционерларга берәр төрле куркыныч туа башласа, Терегулов аларга шуны алдан хәбәр итә икән[1]. Ләкин бу хәтәр эштә кем ашадыр элемтә тотарга кирәк булгандыр бит, чөнки губернатор чиновнигы үзе турыдан-туры бәйләнешкә керә алмагандыр инде. Һәм менә безнең җизни Ибәтулла Терегулов, Әхмәтсолтанга якын кеше, әнә шул элемтәче ролен үтәгән дә, имеш. Моның дөрес булуына дәлил итебрәк, Срур тутакай шундый бер кызыклы гына факт та китергән иде: Ибәтулла җизни төрле сылтау белән бер ел эчендә генә ундүрт мәртәбә тора торган фатирын алыштырган булган. Ни өчен?.. Билгеле, конспирация өчендер инде... Әлбәттә, болар барысы да сүз генә, кулыбызда бертөрле дә документ юк, ләкин бит кайчагында сүзнең дә ниндидер нигезе була. Мәсәлән, Әхмәтсолтан Терегулов революциядән соң да Уфада кала һәм совет органнарында хезмәт итә. Тазартулар вакытында да аңа тимиләр. Элеккеге патша чиновнигы булса да! Бу бит инде юкка гына түгелдер.

Ә безнең җизнигә килгәндә, ул япон сугышын күргән, хәрби флоттан кайткан кеше, димәк, аның күпмедер дәрәҗәдә революция рухы белән сугарылган булуы бик табигый. Андый кешеләр аз булганмыни ул заманда.

Җизнидән калган өч бала үсеп җитәләр. Кеше булалар, тик Рокыя тутакайга тагын да бер зур хәсрәт кичерергә туры килә — бердәнбер улы Әнвәр Ватан сугышында һәлак була. Чыдамлыгына исең китәр! Әнвәр турында сүз чыкканда, мин аның җылаганын бервакытта да күрмәдем. Тик шунда сүзсез генә елмая биреп утыра — әллә хәсрәтен яшерә, әллә Әнвәрен күз алдына китерә...

---

[1] Әхмәтсолтан Терегулов турында мин «Хатлар укыганда» дигән мәкаләмдә кайбер яңа фактларны да язып чыктым. «Казан утлары», 12 нче сан, 1983 ел.— *Ә.Е.*

Шулай зарланмыйча, сыкранмыйча гына үлеп тә китте ул... Ә калган икесе, Рауза белән Ләйлә, исәннәр. Болар минем иң яраткан туганнарым. Алар үзләре дә бик туган җанлылар. Бигрәк тә Рауза! Сугыш аркасында утырып калганга күрәмедер, бөтен игътибары-кайгысы аның туганнарына күчте.

Инде яңадан туй хәлләренә килсәк, минем, дөресен генә әйткәндә, искә төшererлек нәрсәм юк диярлек. Туйда, үзегез беләсез, өй эче тулы кеше, ыгы-зыгы, шаушу — кая монда җиде яшьлек малайга барысын да күреп бетерергә?! Тик бернәрсә хәтеремдә ачык саклана: Срур тутакайны кияү йортына аллы-артлы ике ат җигелгән ябык повозкада алып киттеләр. Мондый эченә кереп утыра торган чананы минем беренче күрүем, ихтимал, шуңадыр, ул онытылмыйча сакланган да. Хәер, тагын бернәрсәне әзрәк хәтерлим әле: бу — Гали бай йорты, чардаклы, яшел түбәле, авылда бер шәп, матур йорт. Срур тутакайны менә шул йортка китереп төшерделәр, чөнки җизни тиешле кеше шушында фатирда тора икән. Эчендәге бүлмәләренең ике якка ачылмалы биек, ап-ак ишекләре әле дә булса күз алдымда. Зур якты зал, бик күп кунаклар, өзлексез җыр-музыка, ләкин болар барысы да төштә генә кебек, хәтта мәҗлес хуҗасы җизнинең үзен дә ачык кына хәтерләмим. Бусы гаҗәбрәк тә инде, чөнки, никадәр бала булсам да, җизни дигән затны мин аера, күрә белергә тиеш идем. Ә бәлки, аерган-күргән булсам да, күптән онытканмындыр — алтмыш өч ел узып китте бит ул туйдан соң!

Әмма мин тора-бара әкренләп күрдем, белдем, таныдым бу яңа җизнине, һәм озак еллар дәвамында ул минем иң нык хөрмәт иткән кешем булып калды. Кем иде соң ул минем җизнәм?.. Иң элек шуны әйтергә кирәк: ул Каргалы кешесе түгел иде, читтән килеп, күпмедер торып, шунда гына Срур тутакай белән танышып, аңа өйләнгән кеше иде. Исем-фамилиясе аның — Шәрифҗан Хәмидулла улы Сүнчәләев. Тарихта күбрәк Шәриф Сүнчәләй исеме белән билгеле шәхес. Шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйнең бертуган агасы. Казандагы Учительская школаны бетергән, үз заманының укымышлы, алдынгы бер кешесе. 1917—1918 елларда революция вакыйгаларына якыннан катнашкан, Уфада Галимҗан Ибраһимов белән бергә «Ирек» газетасын чыгарышкан, Уфа губернасыннан Учредительный собраниегә депутат булып сайланган, Октябрь революциясеннән соң, Башкортстан республикасы төзелгәч, андагы мәгариф эшләре белән җитәкчелек иткән, егерменче елдан коммунист, күренекле

дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе... Уфада аның исеме белән аталган урам да бар.

Шәриф Сүнчәләй турында төгәлрәк һәм тулырак мәгълүматны Риза Ишморат истәлекләреннән алырга була — Риза аның шәкерте, миңа караганда да ул аны күптәнрәк һәм күбрәк белә. Минем исә күңелемдә ныграк, тирәнрәк сакланганы — Шәриф җизнинең саф кешелек сыйфатлары. Әмма ничек кенә итеп аңлатырга моны? Ул тыныч, сабыр кеше иде, бик мөлаем һәм тыйнак кеше иде, тавышы да йомшак, кешегә мөгамәләсе дә йомшак иде. Үзе озын гына буйлы, какча гына кеше иде, бик пөхтә киенеп, гел чиста кырынып йөри иде. Болары тышкы яклары, ә эчке яктан ул үтә әдәпле, инсафлы, нәзакәтле — кыскасы, аңарда гүя тумыштан ук килгән үзенә бер күркәм затлылык бар иде. Мондый ирексездән сокландыра, хөрмәт кузгата торган затлылык, гадәттә, иске интеллигентларда күбрәк очрый. Ул да чын мәгънәсендә интеллигент иде — бөтен яктан да! Ихтимал, шуңа күрәдер мин Шәриф җизнине үзем өчен үрнәк бер кеше итеп саный идем. Дөрес, аңа охшарга, аның төсле булырга тырышмадым, чөнки бу кадәресе кулымнан килмәс иде (һәм табигатемә дә сыймас иде), әмма җизнәмнең күркәм кыяфәте һәм чын кешелек сыйфатлары мине бозылып китүдән, түбән тәгәрәүдән ничектер тыеп килде. Ә андый куркыныч, яшерә алмыйм, минем тормышымда булгалады.

Бу урында ниндидер бер шәрехләү кирәклеген сизәм, югыйсә кайберәүләрнең җизнәңне артык мактап ташладың дип әйтүләре мөмкин. Ләкин хикмәт мактауда түгел, һәм андый теләгем дә юк минем. Хикмәт шунда ки, Шәриф Сүнчәләй һәм аның замандашлары — үткән гасырның ахырында туып, бу гасырның башында, дөресрәге ике революция арасында җитешкән кешеләр. Алар шул чорның азатлык рухы белән сугарылып, бик нык белем-мәгърифәткә омтылган һәм халыкка хезмәт итү максаты белән янган кешеләр. Һәм шушы хәл аларның идеалларын да, кешелек сыйфатларын да билгеләгән булса кирәк. Мәсәлән, Шәриф Сүнчәләйнең яки башка берәрсенең идеалы хөрлек икән, ул инде үз иркен сөю генә түгел, бүтәннәр иркен дә таныган, хөрмәт иткән; әгәр ул кешеләр арасында гаделлек булуын тели икән, иң элек үзе гадел булырга тырышкан һәм башкалардан да шуны көткән. Кыскасы, идеал белән гамәлне алар бер дип белгәннәр, аерып йөртмәгәннәр. Йә, бу һәр заманда һәрбер кеше өчен дә шулай булырга тиеш түгелмени? Күрәсез, бернинди арттыру, мактау юк монда.

...Фәлсәфә купкәрәк китте, кире артка чигеник әле булмаса... Каргалыда туй үтеп киткәч, бер-ике айдан соң яшьләр өчәүләп, ягъни җизни белән Срур тутакай һәм җизнинең энесе Сәгыйть кода (Сәгыйть Сүнчәләй), Уфадан безгә, Дәүләкәнгә кунакка килделәр. Март урталары иде шикелле, карлар эреп, ерганаклар юл ала башлаган кояшлы көннәр иде. Кунаклар хөрмәтенә бездә зур мәҗлес уздырылды. (Ул чакта безнең үз йортыбыз юк иде әле, арендага алган өч бүлмәле чибәр генә йортта тора идек.) Мәҗлескә Дәүләкәннең мөхтәрәм кешеләре чакырылган иде. Заманның мәгълүм ике зыялысы, ике яшь, чибәр егет, икесе дә тройка костюмнан, кара кәләпүшләрдән, берсе, җизни тиешлесе, гармунда, икенчесе, кода тиешлесе, скрипкада өздереп уйныйлар. Әйтәсе дә түгел, алар үзләренең бөтен килеш-килбәтләре, тотышторышлары һәм уеннары белән мәҗлес кунакларын тәмам әсир иткән, таңга калдырган булырга тиешләр. Мин моны көнендә генә белеп бетермәсәм дә, соңыннан ул мәҗлесне һаман искә төшереп сөйләгәннәрен күп ишеттем. Күрәсең, бу мәҗлес атакайның да дәрәҗәсен күтәреп җибәргәндер — кияве кем дә кодасы кем!

Әмма минем өчен иң истәлекле нәрсә — Сәгыйть абыйның бүләк итеп биргән ике китабы булды. Мин әле мәктәпкә йөрми идем, хәреф-мазар да танымый идем, шулай да бу китапларга бик сөендем. Икесе дә катыргы тышлы, эчендәге битләре шоп-шома, хрефләре дә эреачык һәм бит саен диярлек буяулы рәсем... Миңа әйтеп бирделәр: бусы — «Су анасы», ә бусы — «Борчак патша», язу таныгач укырсың, диделәр... Язу таныгач! — бу бит тиз түгел, мәктәпкә йөри башлагач кына, ә менә минем хәзердән үк беләсем килә: кем ул түбәтәйле малай, озын чәчле, шөкәтсез карчыгы кем тагын, ни өчен ул куркыныч карчык малайны куып бара?.. Ахырда көн саен шул китапларны карый торгач, атакай ярдәме белән булса кирәк, мин акренләп кенә хәрефләрне аера, таный башладым, аннары тора-бара хәрефләрдән әз-әзләп сүзләр дә оештырырга өйрәндем... Ул китапларны ничәмә-ничә тапкыр «сукалап» чыгуымны әйтә алмыйм, ләкин көз җитеп, беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кергәндә, мин инде ташка басканны шактый ук «сөрә» белә идем. Шулай итеп, Сәгыйть Сүнчәләй үз кулы белән миңа «тел ачкычы» биреп китте.

Туганнар һәм туйлар турында җитеп торыр, булмаса.

Хәер, тагын бер туйны әйтеп кенә үтү кирәктер, ахрысы. Бу — Абзан туе. Нигъмәтулла дәдәкай шул авылга мине, күчергә утыртып, балдызы туена алып барган

иде. Миңа инде җиде яшь түгел, ундүрт яшь иде. Бәлки, шуңа күрәдер, ә бәлки, җәйнең бик матур чәчәкле вакытында һәм илнең дә тук, тыныч, имин чагында булып узганга күрәдер, ул туй минем күңелемдә гомергә онытылмаслык якты, тирән бер эз калдырды. Күп еллардан соң мин Абзан туенда күргән һәм кичергәннәремне «Җиз кыңгырау» исемле хикәямдә тасвир да иткән идем. Ә кара дугага асып барган җиз кыңгырау әле дә булса миндә саклана.

Үзем менә бик озынга китә түгелме дип борчылам да, кыска да буласым килә, ләкин шуңа карамастан туктала да алмыйм: башлаган сүзне ничектер ахырына кадәр җиткерергә кирәк. Әйтик, шул ук туганнар турында... Әйе, аларның язмышлары да һәм гомерләре дә төрлечә булды. (Бу табигый хәл, кешеләр төрле вакытта туган шикелле, төрле вакытта дөньядан да китәләр.) Атакай белән Рокыя тутакай шактый картаеп үз түшәкләрендә үз әҗәлләре белән үлделәр. Срур тутакай, шөкер, яши әле һәм яшәр дә кебек, чөнки ул нык кеше, үзен карый да белә, яши дә белә. Ә менә Мөхәммәдъяр белән Нигъмәтулла дәдәкайның гомерләре шактый иртә өзелде. Фаҗигале рәвештә... Мөхәммәдъяр дәдәкайны сугыш вакытында хезмәт армиясенә алып, Уралга җибәргән булганнар — ул шуннан кайтмады. Әйтергә кирәк, авылына кайтып барган җиреннән югала ул. Вакыйга болайрак була: 1944 елның көзендә (шулай истә калган) минем атакай белән Мөхәммәдъяр дәдәкай һич уйламаганда-көтмәгәндә Свердловск вокзалында очрашалар. Атакай Куандыкта торучы Кәримә тутакай кызлары җибәргән «вызов» буенча шунда китеп бара, ә Мөхәммәдъяр дәдәкайның авыру сәбәпле хезмәт армиясеннән азат ителеп, өенә кайтып баруы икән. Ике бертуган бу очрашудан, билгеле, куаналар да, гаҗәпләнәләр дә һәм төрле яктан килеп тыгылган халык белән шыгрым тулы вокзалда күпмедер вакыт бергә дә булалар. Атакайның әйтүенә караганда, Мөхәммәдъяр дәдәкай бик бетәшкән булган, өсте дә сәләмә, ашарына да юк икән. Вокзал каршындагы кечкенә базардан атакай аңа, ничәдер йөз сумга, бер кирпеч икмәк тә алып биргән... Мөхәммәдъяр дәдәкайга кирәкле поезд алданрак килә, һәм ул кадерле «кирпечен» салган киндер капчыгын кулына урап тоткан килеш шул поездның бер тамбурына көч-хәл белән эләгеп, китеп тә бара... Һәм шул китүдән гаип — өенә кайтып җитми. Ни булган, берәр бәхетсезлеккә юлыкканмы, юлда-мазар үлеп калганмы? — белүче дә юк, күрүче дә юк һәм беркайдан бернинди хәбәр дә юк. Олы кеше су төбенә киткән таш кебек юкка чыга да куя. Соңыннан бу

бик сәер-серле хәлне искә төшереп юраган чакта, атакай әйтә торган иде: шул бер кирпеч икмәге башына җитмәде микән, бичараның? Ачлар, явызлар күп иде, бәлки, шундыйларның берәрсе икмәген тартып алып, үзен поездан бәреп төшергәндер, авыру кешегә күпме генә кирәк соң?! — ди иде. Хәер, югалган кеше турында төрлесен юрарга була, әмма чын дөресен генә белеп булмый беркайчан да.

Нигъмәтулла дәдәкайның язмышы тагы да аянычрак, тагы да фаҗигалерәк... Бусы инде колхозлашу елларында булган эш. Ул елларның гаять катлаулы вакыйгаларын, үтә кискен көрәшен сөйләп тору кирәк микән? Тарихтан һәм әдәбияттан без моны яхшы беләбез. Тик шуны гына әйтү кирәктер, ахрысы: авыл җирендә бу вакыйгалардан читтә калган, бу көрәшнең кискен җиле тимәгән кеше юктыр, булмагандыр ул чакта. Менә Нигъмәтулла дәдәкайга да тия ул, әмма ничек итеп?!

1930 елның октябрендә аны авыл советына чакырып алалар. Авыл советыннан, сине волостька чакырдылар, дип, Бүздәккә алып китәләр. Ә Бүздәктән инде Уфага озаталар һәм шул китүдән инде ул кайтмый — югала. Сәбәбе билгесез. Тагын юрарга гына кала. Кеше бит өеннән үз аягы белән чыгып китә, берни белмичә!.. Хатыны Мәдинә җиңгәчәйнең әйтүенә караганда, Нигъмәтулла дәдәкай ялган әләк корбаны булырга тиеш. Чынлап та, ул бит авылның бер бае яки кулагы түгел иде, гади бер середняк! Әмма бик тынгысыз вакыт, хәлләр киеренке, көрәш кискен, мондый чакта берәүнең үчлек белән чагуы да кешене харап итәр өчен җитә кала. Ә үч саклаучы зур авыл җирендә һәрвакытта табыла ул. Кызганычка каршы, аныңише хәлләр аз булмады ул чакларда.

Хәтерлисездер аның җырын: «Утырдым ла көймәнең, ай, түренә...» Тукта, мин әйттем микән, юк микән, Нигъмәтулла дәдәкай, пленнан качкач, төшендә уникe кыр казы күргән... Нәкъ уникe ел торып кала ул туган илендә үзенең гаиләсе белән... «Югалган» чагында кырыкның өстендә генә иде типсә, тимер өзәрлек, тынгы белмәс... дәдәкай!..

Аңардан дүрт бала калды — икесе кыз, икесе ир бала. Баш баласы Зөләйха, атасы югалганда, җиткән кыз иде инде. Калган өчесе аталары пленнан кайткач туган балалар. Арада зурысы — Бибинур, ә кечеләре Идюк (Идиятулла) белән Шамил; Идюк олырак, ә Шамиле атасыннан аерылганда кулда гына була әле. Мин инде бу балаларның нинди хәлдә калуларын, нинди газап-нужа кичерүләрен тәфсилләп язып тормыйм, чөнки тәфсилләп

тормыйча да укучы моны күз алдына китерә алачак дип ышанам. Тик шулай да аларның язмышлары турында кыскача гына әйтеп китмичә булмас, ахрысы.

Зөләйха, атасын алып киткәндә, Каргалыда булмый — Уфада укып йөргән чагына туры килә бу көтелмәгән хәл. Ләкин ел саен ул каникул вакытларында авылга кайтып, җәйге кыр эшләрендә атасына гел генә булышып, шул ук вакытта авыл яшьләре белән бергә спектакльләр, концертлар куюда да якыннан катнашып йөри. Әйтергә кирәк, ул авылның күзгә бәрелеп торган бер чибәре иде. Йөзе-бите, буе-сыны дисеңме — бер генә дә килмәгән җире юк иде аның. Шуның өстенә табигать аны башка әйбәт сыйфатлардан да мәхрүм итмәгән: атасы кебек бик матур җырлый, пианинода шактый ук оста уйный (Уфада Срур тутакайларда торган чагында үзлегеннән өйрәнгән), янә килеп акыл-зиһен, үзен тота белү җәһәтеннән дә күпләрдән аерылып тора. Бәлки, беркадәр тәкәбберлеге булгандыр, ләкин үз бәясен яхшы белгән кайсы гына кызда юк ул?! Тик моның хәтәр ягы да бар иде ул чакта — кызны үзенә карата алмаган егет тота да теләсә ничек аңардан үч ала. Үзеннән булмаса, атасыннан — бу түбәнлек, бу әшәкелек дип тору юк... Зөләйхага да әнә шундый янаулар булгалаган икән, ләкин яшьлеге аркасында ул аңа әһәмият кенә бирмәгән.

Әлбәттә, бу көтелмәгән коточкыч бәхетсезлектән Зөләйха ниләр кичергәнен бары үзе генә белә торгандыр. Әмма ул барысына да түзә, барысын да күтәрә. Башкача мөмкин түгел, таш белән бастырып куйсалар да, ничек тә изелмичә чыдарга кирәк. Авылга кайтып тормый, Мәскәүгә, Срур тутакайларга барып сыена, ә бераздан аспирантурада укучы, безгә кардәш тиешле Шәрәфетдин Еникеевкә кияүгә дә чыга. Башта алар Оренбургка китәләр, анда берничә ел торганнан соң Алма-Атага күчәләр. Ике баласы булуга карамастан, Зөләйха өзелгән укуын дәвам иттереп, институт тәмамлый. Шул рәвешчә, Шәрәфетдин казакъ университетында математика кафедрасы мөдире булып, ә Зөләйха педагогия институтында казакъ яшьләренә рус теле һәм әдәбияты укытып, Алма-Атада тыныч-матур гына яшиләр. Билгеле, ул тегендә «Каргалыкай буенда» калган инәсе белән энеләрен дә онытмый, аларга өзлексез ярдәм итеп тора, ә сугыш алдыннан барысын да үз янына, Алма-Атага китертә. Асылда, алар, Зөләйха һәм Шәрәфетдин, ике малайны «баздан» көн яктысына чыгарып, аякка бастыралар. Әйе, Шәрәфетдиннең Нигъмәтулла дәдәкай балаларына күрсәткән изгелеген һич тә онытырлык түгел. Алма-Атага

китергәч, җиңгәчәйгә бакчалы кечкенә бер өй алып бирәләр, һәм ул шунда булачак егетләре белән тыныч кына яши башлый. Аңарчы әле Бибинур, апасында торып, тулаш булып җитешә, институт бетерә һәм кияүгә дә чыга... Күпме мондый язмышлар безнең халыкта!

Бибинурның сугыш вакытында күргәннәре үзе бер тарих. Ләкин читкә тайпыласы килми — белешмә рәвешендә генә әйтеп китәргә туры килә. Бибинурның ире кызыл командир, сугыш башланганда алар ил чигендә торалар. Июнь таңында фашистларның беренче бомбалары алар өстенә ява. Бибинур, күкрәк баласын алып, ут астыннан котылып чыга, ә ире ил чиген саклап кала һәм шунда һәлак тә була. Озын чигенү-качу юлы, күпме куркыныч маҗаралы хәлләргә юлыгу, инде беттек дигәндә генә, билгесез, әмма изге күңелле кешеләр ярдәмендә котылып калу — баласын күкрәгенә кыскан яшь ана шуларның барысын да үз башыннан кичерә.

...Сугыш бетә, яралар әкренләп төзәлә, исәннәр һаман яши бирә. Бибинур да Казахстанның Талдыкурган өлкәсендәге бер район мәктәбендә озак еллар казакъ һәм уйгур балаларын укытып тора. Шунда әкренләп үзенә йорт кора, хуҗалыгын булдыра, ут астыннан алып чыккан малаен үстерә, Ташкентка җибәреп вуз бетертә — кыскасы, бер эзгә төшкән тормыш үз җае белән һаман алга таба тәгәрәмәктә, искечә әйтсәк. Хәзер инде Бибинур пенсиядә, яңадан иргә чыкмады ул, гомерен уздырган җирдән һәм мәктәбеннән читкә китмичә, шунда хөрмәт казанган карт мөгаллимә булып, ялгызы тыныч кына яшәмәктә. Ачы язмышның ахыры әнә шундый, рөхсәт итсәгез, бәхетле дияргә дә ярый, минемчә.

Идюк белән Шамилне 1934 елның салкын кышында миңа бер кайтып күрергә туры килгән иде. Ул чакта җиңгәчәй сүтеп алынган йортның бәрәңге базын землянка итеп, шунда ике баласы белән торып маташа иде. Бер чыбык заты да күренмәгән, кәфендәй ап-ак кар баскан ялан кадәр ихатаның читендәрәк әз генә чыгып торган калай морҗаны шәйләп, шуңа таба тар гына сукмактан барып, траншеядәй аралыктан түбән төшеп, землянкага барып кергәч, мин, атларга урын тапмыйча, ишек төбендә үк тукталып калдым. Бу чын мәгънәсендә баз иде, анда учак та казан һәм кечкенә бер сәке — башка берни дә юк... Сәкедә киндер күлмәк-ыштаннан, ялан-баш ике малай утыра, инәләре күренми, каядыр чыккан, ахрысы. Мин малайларга дәшәм — җавап бирмиләр, «Инәгез кайда?» дип сорыйм, юк, дәшмиләр. «Мин бит абыегыз булам, дәдәгез...» дип тә карыйм, барыбер тавышла-

рын чыгармыйлар, тик шунда күзләрен тутырып миңа карап торалар. Тагын шунысы гаҗәп: аларның бу карашында ятсыну да, уңайсызлану да һич сизелми, бары кешедән бизүгә охшаган ниндидер бер җан салкынлыгы гына чагыла иде. Менә җиңгәчәй дә кайтып керде, мине күреп исе китте. «Әй, Әмерханым, Әмерханым» дип җылап та алды. Мин исә бер теземне кочаклап, башымны юри югары каерып (гүя шулай иткәч, күздән яшьләр бәреп чыкмаска тиеш иде), таш сындай катып, сәке кырында тик кенә утыра бирдем. Җиңгәчәйдән юньләп берни сораша да алмадым, тәкатем җитмәде, хәер, ул үзе хәзерге хәлләрен бераз сөйләп аңлатты. Зөләйхадан ярдәм һаман килгәләп тора икән, шуның өстенә җиңгәчәй каен тузыннан сагыз кайнатып, хатын-кыз арасында саткалый икән, шулай итеп көннәрен көнгә ялгап баралар икән әле. Шөкер, ди, ачыкканыбыз юк, ди җиңгәчәй бичара!.. Татар хатыны шул.

Бу минем сугышка чаклы Каргалыга соңгы кайтуым иде. Күп еллар узгач, мин Ялтадан кайтышлый Севастопольдә Шамилне эзләп таптым. Землянкада дәшми утырган кечкенә малай хәзер чын ир-егет булган. Атасына бик охшаган, шундый ук чандыр, төз гәүдәле, аксылрак чырайлы, туры борынлы, бәлки, буйга бераз кайтышрак булыр... Атасы кебек җитез, хәрәкәтчән, ачык күңелле, сүзгә дә юмарт икән. Ул хәрби флотта хезмәт иткән, укыган, квалификация алган, мин күргәндә дә, хәрби корабларда электрик булып эшли иде. Өйләнгән, баласы бар. Севастопольнең үзендә яңа квартирада тора. Әйтергә кирәк, Севастопольдә теләсә кемне тотмыйлар, димәк, Шамил монда торыр өчен тулы ышаныч та казанган.

Атасын бөтенләй хәтерләми, әмма сурәтен генә булса да бик күрәсе килә икән. Миннән дә: «Атакайның карточкасы創 сездә булырга тиеш»,— дип кат-кат сорады. «Юк вет»,— дигәнгә дә ышанып бетмәде, гареп! (Каргалыча әйтсәк.) Хәлбуки Нигъмәтулла дәдәкайның солдатта чакта бер иптәше белән төшкән фоторәсеме бар иде, мин үзем дә аны ничектер күргән идем кебек, ләкин шул фоторәсем берәүдә дә юк, кая киткән, кемдә калган — һичкем белми. Ә Шамилгә бик кирәк икән ул бердәнбер «карточкы», атасын хыялында гына булса да терелтер өчен кирәк икән аңа! Мине вокзалга озата төшкәч тә, кыенсынып кына тагын шуны кабатлады: «Һич югы, фотосын гына күрәсе иде бит»,— диде. Мин инде берәр җирдән таба алсам, җибәрермен дип аны юаткан булдым.

Ә менә Идюкне (Идиятулланы) теге землянка базында күргәннән соң миңа яңадан бер генә тапкыр да күрергә

туры килмәде. Әмма беләм: ул да үсеп егет булган, армиядә хезмәт иткән, соңыннан заводта эшләгән, аннары бер рус кызына өйләнгән. Куйбышевтан ерак түгел Кинель дигән шәһәрдә үз йортында тора икән. Хатыны да шул Кинельдән, хатынының ишле туганнары да шунда яшиләр икән. Бәлки әле Идиятулла исемен дә үзгәрткәндер, хәер, кызыксынып сораганым юк, ә менә тормышы бик әйбәт дип ишеттем.

Мәдинә җиңгәчәй озак яшәде. Әмма бу озын гомернең үзенә тигән өлеше шактый кыска. Абзаннан Каргалыга килен булып төшкәч, Нигъмәтулла дәдәкай белән герман сугышына чаклы дүрт-биш ел торып кала. Дүрт ел солдатка булып тора, каенатасын һәм каенанасын карап, бөтен хуҗалыкны үз җилкәсендә алып бара. Нигъмәтулла дәдәкай пленнан кайткач, нәкъ унике ел алар тагын бергә торып калалар. Шуннан соң инде җиңгәчәй тол хатын булып картая. Дүрт баласы дүрт якта, ул шуларның әле берсенә, әле икенчесенә барып, кунаклап кайтакитә йөри. Ләкин гомеренең күбрәк өлешен Зөләйхада торып уздыра, аның балаларын үстерешә һәм сиксәннән узып, Зөләйха кулында вафат та була. Туып үскән җире аның Башкортстандагы тын гына аккан ямьле Түреш буенда иде, мәңгелек урыны исә Казахстанның гел селкенеп торган карлы-бозлы Алатау итәгендә. Берише татар хатынының типик язмышы түгелме бу?.. Хәер, мин һич тә гомумиләштерергә теләмимм, мин, кичерегез, бала чагымнан ук күңелемдә сакланган бер җиңгәчәм турында гына сөйләдем. Ташлы туфрагы мамык булсын аның!

...Якын туганнар хакында сүз хәзергә шуның белән тәмам. Нәтиҗә ясап, нәрсә әйтергә мөмкин?.. Без яшәгән дәвернең төрле чагы булды, төрле хәлләрне күреп үткәрергә туры килде, үкенечле югалтулар да, кызганычка каршы, аз булмады.

Ләкин мондый нәтиҗә ясау өчен генә «дәдәкай тарихын» язып тору кирәк идеме соң?.. Кирәк иде, чөнки минә миңа — язучыга кагыла ул тарих. Ә язучы юкны бар итмәскә, барын яшереп тормаска тиештер дип беләм. Бигрәк тә үзе турында тәвәккәлләп язарга тотынгач!

## УРАМ БУЙЛАП

Соңгы тапкыр Каргалының югары очыннан түбән очына кадәр ашыкмыйча гына бер узасым килә. Кайбер үзем белгән һәм кешедән ишеткәннәрне искә төшерер өчен. Кызганычка каршы, башта ук телгә алынган әлеге «Каргалы тарихы» тулысынча минем кулыма кермәде, шу-

ның аркасында Каргалының нәкъ менә үзенә караган өлеше белән миңа танышырга да туры килмәде. Ә ишеткән-күргәннәрдән генә чыгып сөйләү бик үк ышанычлы түгел — ялгышулар да, төгәлсезлекләр дә булырга мөмкин. Ләкин башка чарам юк, авыл тарихын яхшырак белүчеләр мине гафу итсеннәр!

Хуш, урам буйлап узабыз. Бу төп урам, бер өч чакрымга сузыла торгандыр. Һәрбер зур авылдагы шикелле ул монда да, инеш агымына карап, өчкә бүленеп йөртелә: югары оч, урталык һәм түбән оч. Билгеле, йөз илле ел дәвамында Каргалы бик нык үсә. Төп урам үзе дә һаман сузыла, аңа янәшә (параллель) урамнар да, шуларны аркылы кисеп узганнары да әкренләп барлыкка килә. Алар төрле исемнәрдә йөриләр. Мин белгәннәрдән, мәсәлән, югары очта зур гына Шатон урамы бар, урталык белән түбән оч арасында, инешкә таба Төбәк дигән җир дә бар. Моны Каргалының иң борынгы җире, диләр. Шулар кебек төрле исемдә йөргән урам яки урыннар аз булмаска тиеш, ләкин мин аларның күбесен ачык кына белмим. Мәсәлән, авылда «эт җыены» дип сөйләгәнне еш кына ишетә идем, ә кайда, нәрсә ул — шуны ничектер һаман белә алмыйча йөрдем. Бактың исә, «эт җыены» дигәннәре ул безнең бабакайлардан ерак та түгел, югары оч белән урталык арасындагы бер урын икән. (Кемнеңдер капка төбе булса кирәк.) Шунда кичкырын эштән бушаган ир-ат җыелып, тәмәке көйрәтеп, төрле мәзәк сөйләп, үткән-сүткәннән көлеп утыралар икән. Анда тел чарлаганнар, кызык уйлап чыгарганнар, күзләренә чалынган һәркемнең берәр көлке ягын тапканнар — кыскасы, халык «эт җыены» дигән исемне бик белеп таккан ул урынга. Бер генә мисал. Әйтик, авылда кемдер кемнеңдер кызын ярәшер өчен баш кода булып бара. Мондый мөһим вакыйга кешеләр теленә кермичә калмый, әлбәттә... Һәм озак та үтмичә, «эт җыены» бу вакыйганы менә болайрак ясап чыгара: сукыр Хәллә сукыр Хәсәннең сукыр атын җигеп, сукыр Усманның сукыр малаеннан сукыр Гомәрнең сукыр кызына баш кода булып барган... Менә шул. Ләкин бу «мәзәкнең» хикмәте шунда ки, ул коры уйдырма гына түгел, аның, ничек дим, үзенә күрә реаль җирлеге бар. Чынлап та, шул вакыйгага катнашучылардан берсенең күзенә кайчандыр ак төшкән, икенчесе тагын чепи күзле икән, өченчесенең дә бит-күз тирәсендә нindидер кимчелеге табылган, шуның өстенә, җитмәсә, җигеп барган атының да бер күзе ага торган булган. Һәм шул җиткән дә — бөтенесен җиңел кулдан сукырга әйләндергәннәр дә куйганнар. Тик авылның көлә-көлә эче генә катсын!

Ярый, «эт җыенын» да уздык ди. Сезне, бәлки, авылның гомуми күренеше кызыксындыра торгандыр — ничегрәк ул, төзекме, тазамы, матурмы? Әйтергә кирәк, Каргалының утырган җире табигатькә бай түгел: зур суы да, урманы да юк, әмма авыл үзе бөтен, таза иде. Йортларның күпчелеге кара-каршы салынган, такта белән япкан йортлар. Капка-коймалары да тактадан. Еш кына калай белән япкан зуррак, матуррак йортлар да очрый. Берничә чардаклы йортны да беләм мин. Шулай ук бер генә бурадан салынган, салам түбәле, җил капкалы өйләр дә бар иде, ләкин алар, унга бер дигәндәй, әллә ни күп түгел иде. Кыскасы, халыкның зур күпчелеге урта һәм уртадан өстенрәк тормышлы хуҗалардан гыйбарәт булганга күрәдер инде, авылның гомуми күренеше дә «уртадан югары» әйбәт, төзек кенә иде. Таш пулатлар булмаган кебек, читәннән үреп, балчык белән сылаган өйләр дә юк иде шикелле — һәрхәлдә, андый өйне мин хәтерләмим.

Каргалының бер кимчелеге булса, ул да аның яшеллеккә ярлылыгы иде. Агач бакчалары аз иде, җимеш агачлары бөтенләй юк диярлек, булса да шул сәрби дә сирень, миләш тә шомырт... Болары да сирәк йортларда гына. Бөтен авылның бакча дигәне — ул абзарлар артындагы бәрәңге мәйданы — менә ансыз инде бер генә йорт та юк иде. Каргалы «бульбасы» шәп иде — бәләктәй кызыл бәрәңге!

Әйе, Каргалы зур авыл. Өч мәчете бар, өч мәхәлләгә бүленә. (Авылның зурлыгына караганда, мәчетләр күп түгел иде.) Бу җиргә иң беренче килеп утыручылар егерме хуҗалык (йорт) булса, 1926 елда инде аның саны биш йөз егермегә җитә. Йөз илле ел эчендә әнә ничек үскән ул!.. Каргалының җире дә күп, басу-кырлары да еракта иде. (Җир мәйданы уналты мең гектарга җиткән дип ишеткәнем бар.) Мәгълүм булганча, революциядән соң, егерменче елларның урталарында артык зураеп киткән авыллардан иркенрәк җиргә күчеп утырулар башлана. Бу процесстан Каргалы да, билгеле, читтә калмый. Аның халкы да төрле тарафка аерылып чыга башлый һәм, шул рәвешчә, Каргалы җирендә кечерәк кенә яңа авыллар — елгачык үрендә «Каргалы баш», елгачык түбәнендә «Каргалы тамак», Әркәсле ягында «Бакча», Чабылтау артында «Зиреклебаш» — барлыкка килә. Янә тагын «Бишкиртек» дигәне дә бар, имеш, ләкин мин андый авылның барлыгын белмим — «эт җыены» уйлап чыгарган мәзәк кенә түгел микән? (Хәер, берничә йорт авыл очындагы киртләчле тау итәгенә күчеп утырганнар шикелле,

бәлки, шуларга бу «матур» исемне такканнардыр.) Шуның өстенә күпмедер хуҗалык Чиләбе өлкәсендәге «Чибәр күл» дигән җиргә дә күчеп китә. Мондый «аерылып чыгулардан» соң төп Каргалы үзе кечерәеп һәм сирәгәеп калырга тиеш иде. Ләкин мин кайтып йөргән чакларда, ул һаман искечә зур иде, тоташ иде, таралганы һич тә сизелми иде. Тыгыз утырган зур авыл үзенең йөзен тиз генә югалтмый, күрәсең. Әмма Каргалының чынлап үзгәрүе (дөресрәге, таралуы) сугыш вакытында һәм сугыштан соң башланды булса кирәк. Әйтергә генә ансат, Ватан сугышы фронтларында Каргалының биш йөз кешесе ятып кала. Теге вак авылларны кертеп исәпләгәндә дә бу коточкыч зур югалту! Алар барысы да бит йорт башы яки йорт терәге ирләр... Мондый югалтудан соң авылың бөтенләй юкка чыгып бетсә дә, гаҗәп түгел. Әмма Каргалының беткәне юк. Ул яши, өтелеп, сирәкләнеп калса да, һаман шул Каргалыкай буенда утыра ул. Тик кешеләре инде башка — сугыштан соң туган, өлгергән кешеләр. Борынгы картлар юк, беткән алар, булганнары исә минннән олырак яки минем яшьтәге картлар (бик күп малайлардан сирәк кенә сакланып калган замандашларым дияр идем мин аларны)... Шулай ук читтән килеп утыручылар да бар булса кирәк. Кайчандыр аерылып чыккан «Зиреклебаш»ны яңадан төп авылга күчергәннәр. Кыскасы, чишмә типкән, үлән үскән җирдә тормыш бетми — һаман дәвам итә ул. Бәрәкәтле җир кешеләрне үзенә җыя да, бәйли дә, тик аңа иминлек белән тынычлык кына булсын!

Хәзерге вакытта Каргалы терлек симертү совхозының бер бүлеге икән. Бу бик әйбәт хуҗалык булырга тиеш, чөнки Каргалының мал йөртерлек җирләре күп, элекке заманда да авылдан унбиш көтү чыга торган булган.

Һәрбер зур авылдагы шикелле Каргалыда да халык бик чуар иде. Барысы бер яктан килүләренә һәм телгореф җәһәтеннән бертөсле үк булуларына карамастан, алар арасында шактый зур аерма да яшәп килгән. Иң элек алар сословиеләргә бүленгәннәр: күпмедер өлеше морзалар, калганнары исә гади крестьяннар. Бу соңгылары да төрле тамырдан чыгып, төрле исемдә йөргәннәр: «Мулла халкы» (Янгуразовлар), «Азый халкы» (Азиевлар), «Бүре халкы» (Килмәмитовлар)... «Мулла халкы»ның исеме кайдан алынганын югарыда әйткән идем инде (минем инәй шул халыктан), «Азый халкы» дигәне кеше исеме белән бәйләнгән булса кирәк, ә менә «Бүре халкы» дигәнен мин күпме сорашсам да, ачык кына белә алмадым. Аларны усал, кара халык, диләр иде, шуның

өчен генә «бүре» кушканнармы әллә моның бик ерактан килгән башка берәр тамыры да бармы — билгесез[1].

Бу әйткәннәрдән тыш авылда бер үк фамилия йөрткән һәм бер тирәдәрәк оешып утырган ваграк төркемнәр дә бар иде — мәсәлән, Утяшевләр, Мамлеевлар, Сундюковлар... Боларның да беришеләре морза (Мамлеевлар), икенчеләре исә (Утяшевләр) бу дәрәҗәдән мәхрүм. Билгеле инде, сословиеләр арасында тигезлек булуы мөмкин түгел. Димәк, үзара мөнәсәбәтләр дә шуңа карап йөргән: морзалар үзләрен өстен санаганнар, «түбәннәр» белән аралашмаска тырышканнар, мәсәлән, «Бүре халкы»ннан кыз алмаганнар, кыз бирмәгәннәр. Гомумән, алар нәсел тикшерергә яратканнар, борын еш кына ишетелә торган «затлы» яки «затсыз» дигән төшенчә дә әнә шуннан килеп чыккан булса кирәк. Менә ни өчен морзалар элек-электән үк бары үзара (аерым очракларны исәпләмәгәндә) кыз алышып, кыз бирешеп килгәннәр һәм, нәтиҗәдә, Еникеевләр белән Терегуловлар бер-берсенә туганлык җепләре белән бик нык бәйләнеп, чуалып беткәннәр. Бу бәйләнешләрне минем атакай бик яхшы белә иде. Һәм мин аны бик гаҗәпләнеп тыңлый торган идем. Чөнки мин үзем «туганлык җепләре»н белү җәһәтеннән бик «аңгыра» булып чыктым, шактый якыннарның да кайсы яктан, ничек туган булуларын гомерем буена диярлек аерып бетә алмыйча йөдәдем.

Әйе, кайчандыр элекке заманда әнә шулай булган, әмма революциядән соң сословиеләр юк, бетерелгән иде инде. Минем үземә сословие мөнәсәбәтләрен күрергә дә, татырга да туры килмәде, чөнки мин үскән Дәүләкәндә байлар бар иде, ярлылар бар иде, ләкин морзалар юк иде. Каргалыга кайткан чакларымда гына «морза» сүзен ишеткәли идем, хәер, анда да инде берәү дә үзен исән баштан морза дип атамый иде. Хәзер барысы да бертигез, барысы да гади авыл халкы, крестьяннар... Әмма шулай булса да, «морзалык» дигән уй-караш кешеләрнең, ничек дим, каныннан чыгып бетмәгән иде әле, аратирә сүздә яки мөнәсәбәттә үзен сиздереп куйгалый иде.

Кечкенә бер эпизод — әле дә онытылганы юк. Мөхәммәдъяр дәдәкай туеннан соң, егерме икенче елның гаҗәеп матур килгән җәендә булса кирәк, мин, кемгәдер утырып, тагын Каргалыга кайттым. Ишегалдына үтеп, тарантастан төшүемә, француз бөркәнчек ябынган Хәнифә җиңгәчәй — яшь килен — җәһәт кенә каршыма килде

[1] Нурихан Фәттах, мәсәлән, борынгы төркиләрнең символы бүре булган, ди.— *Ә.Е.*

дә чүгенеп (ягъни реверанс ясап) миңа «Исәнмесез, кече морза!» — дип, ике кулын сузды. Мин бу көтелмәгән хәлдән шактый югалып калдым, кызарып-каушап кына җиңгәчәйгә кул бирдем, мәгәр шул минутта гына аның болай зурлап күрешүен ничектер аңлап та җиткермәдем. Тик бераздан гына минем бәләкәй башыма килеп җиткәндәй булды: кара, мин морза икәнмен ләбаса! Кече морза! Менә ни өчен яшь җиңгәчәй минем белән, гафу итегез, унөч яшьлек маңка малай белән чүгенеп, ике куллап күрешкән икән. (Безнең Каргалыда яшь киленнәр, киявенә туган тиешле ирләр белән күрешкәндә, хөрмәт йөзеннән әнә шулай чүгенеп алалар, ягъни реверанс ясыйлар иде. Бу аларда бик борыннан килгән гадәт. Хәзер юк, күптән беткән.) Шулай итеп, мин дә зур хөрмәткә лаек булдым. Дөрес, морза булуның хәзер өч тиенлек тә әһәмияте юк, моны бөтенесе белә дә торгандыр инде, ләкин шулай да борынгы гадәт буенча «морза» дип зурлап дәшүне онытып бетермәгәннәр, имеш! Соңыннан күпме күрешергә туры килсә дә, җиңгәчәйдән мин алай чүгенеп исәнләшкәнне бүтән инде ишетмәдем.

Ни өчендер минем атакай Каргалы халкын мактарга ярата торган иде. Затлы, төпле халык, ди иде, инсафлы, әдәпле, туган җанлы, ачык күңелле, укыган зур кешеләр дә чыккан, дип тезеп китә торган иде. Ихтимал, бу аның Каргалыда үткәргән ир-егет чакларын, өйләнеп бәхетле яшәгән вакытларын һәм якыннан аралашкан, йөрешкән дус-ишләрен сагынуы белән бәйләнгәндер. Картлыкка таба ул дус-ишләрнең күбесен югалтсаң, тормышың һаман авырая, күңелсезләнә барса, үткәннәрне сагынып утырудан башка тагын ни кала?! Сагынырлык үткәнең булу үзе бер зур юаныч! Әмма мин үзем яшьтән үк атакай сүзләренә ышанып бетмәдем, чөнки минем дөньяга күзем бөтенләй башка вакытта, башка шартларда ачылды. Әлбәттә, һәр җирдәге шикелле Каргалыда да яхшы кешеләр аз булмагандыр — бу кадәресен берәү дә инкарь итмәячәк (намуслылык, инсафлылык, гомумән, күп кешеләргә хас сыйфат, тик Ходай аны һәркемгә дә тигез бирмәгән). Шулай ук Каргалы халкының уку-белем ягыннан күрше-тирәдәге авыллардан өстен торуына да ышанырга була. Шулайрак танылган да Каргалы... Әмма ләкин бердәмлек белән татулыкка килгәндә, юк, монсы инде, туп-туры гына әйткәндә, иллюзия! Халыкның сословиеләргә бүленгәнен күрдек, һәм шушы сословиеләрнең үз эчендә дә кешеләр тигез түгел, күптән инде төрле социаль катлауларга бүленеп беткәннәр. Берәүләре баеган, берәүләре бөлгән, күпчелек исә шушы ике уртада.

Әлеге түбән сословиедән саналган «азый», «мулла», «бүре» халыкларының бик таза тормышлылары булган шикелле, «морзаларның» да атсыз-тунсыз азап чиккән фәкыйрьләре бар иде. Кыскасы, мәшһүр Каргалының үзендә социаль типларның төрлесен — баен, сатучысын, ярлысын, хәерчесен, укыганын, укымаганын күрергә, хәтта зимагуры белән карагын да очратырга мөмкин иде. Һәм кемнәр генә чыкмаган бу чуар халыктан — большевигы да (Нигъмәт Еникеев), меньшевигы да (Гомәр Терегулов), эсеры да (Хәллә Еникеев). (Билгеле, мин монда мисал өчен берәр генә фамилияне күрсәтү белән чикләнәм.) Бәс, шулай булгач, нинди бердәмлек һәм татулык турында сүз булырга мөмкин ди?! Антагонизм һәм көрәш — менә нидән гыйбарәт Каргалының да тарихы. Революция елларында, шулай ук колхозлашу вакытында бу көрәш гаилә эченә керә, ике туган арасында башлана. Срур тутакайның сөйләгәне әгәр дөрес булса, Каргалы кешесе Габдрәхим Еникеев, кызыллар Бохараны азат иткәннән соң, шәһәрнең беренче коменданты булган, ә шул ук вакытта аның бертуганы Искәндәр акларда офицер булып йөргән. Ике братның үзара талашканын элегрәк минем дә ишеткәнем бар иде, ди Срур тутакай... Югарыда мин Еникеевләрнең туганлык җепләре белән уралып беткәнен әйткән идем, әмма сыйнфый көрәш законы җепләрне генә түгел, чылбырларны да өзгәләп ташлады. Моның дистәләрчә мисалын китерергә мөмкин булыр иде, ләкин мисалсыз да бик яхшы аңлашыла торган хакыйкать.

Инде үзем белгән кайбер кешеләр турында сөйләп үтәсем килә. Заманында Каргалыда Рәхимҗан дигән зур бер бай булган. Мәкәрҗә ярминкәсенә олау-олау тиреяры илтеп, аннан чәй-шикәр төяп кайтып, сәүдә иткән, диләр. Атакай аны «Рәхимҗан җизни» ди иде, димәк, безгә кардәшлеге дә булган икән. Мин аңардан калган йортны да әзрәк хәтерлим әле. Ул бабакайлардан түбән очтарак, кайчандыр таза-шәп, ә хәзер шактый искергән, тузган калай түбәле зур бер йорт иде. Анда Рәхимҗан байның улы Камалетдин абзый тора иде. Картаеп барган кеше иде инде, атакай да аңа «Камалетдин абзый» дип дәшә иде. Менә шул зур колаклы, зур борынлы, битен эре сызыклар ерып төшсә дә, үзенчә ничектер мөлаем чырайлы һәм мәзәк кенә сүзле абзый нэп вакытында атна саен Дәүләкән базарына кырык чакрым Каргалыдан җәяүләп килә торган иде. Башында керләнеп беткән эшләпә, өстендә озын чабулы әллә иске бишмәт, әллә иске җилән, аягында читек өстеннән киндерә белән урап

бәйләгән чабата, кулында юан гына таяк,— арып-талып безгә килеп җиткәч, өйгә дә кереп тормыйча, тизрәк түбән баскычка «лып» итеп хәл җыярга утыра иде. Димәк, ул чакта аның аты-мазары булмаган. Арып килүенә карамастан, ул энем белән миңа ни өчендер гел генә: «Нихәл сез, очлыкайлар!» — дип дәшә торган иде. Күрәсең, үзенчә шаяртуы булгандыр инде...

Мин Камалетдин абзыйны чынлап кызгана идем, нигә килеп йөри, нигә атлы кешегә утырып килми? дип уйлана идем. Әллә утыртмаганнар, әллә үзе утырырга теләмәгән — Ходa белсен! Базарда ни эше калган дисәң, ул шунда тире-яры җыючыларга булышып, үзенә әз-мәз акча төшерә икән. Байлык — бер айлык, хәерчелек, саклап тотсаң, гомер буена җитә, диләр... Камалетдин абзый да әнә шундый хәерчелеккә дучар булган бер кеше иде. Һәм бөлгән байлар гадәтенчә салырга да бик ярата иде, мәрхүм!

Ә менә бай Гали Дәүләкән базарына шәп атта, яхшы тарантаста килә торган иде. Ул безгә керми иде, ләкин атын капка төбендә туктатып, тарантастан төшмичә генә атакай белән сөйләшеп китә иде. Мин дә аны шул чакта гына күреп калгалый идем. Тулы-таза гәүдәле, симезрәк шома битле, матур зур күзле бу кеше атадан калган мал белән түгел, ә үзенең зирәклеге һәм булдыклылыгы аркасында ничектер баеп киткән, имеш. Авылдагы иң матур йортны, янәшәсендәге таш кибетне, ишегалды түрендәге калай белән япкан амбарларны да ул инде үзе салдырган. Ләкин шулардан башка (әйтик, җир биләү, мал асрауга килгәндә) аның әллә ни зур байлыгы булмаган дип тә сөйлиләр иде. (Артык баеп китәргә, бәлки, өлгерә алмыйча да калгандыр.) Шулай да бөтен авыл аны «бай Гали» дип кенә йөртә иде. Колхозлашу башланганга кадәр үзенең шәп йортында торган — бу вакытта инде ул сату итмәгән, ә базар йөреп дәүләткә тире җыйган. Ләкин аның болай «тыныч» яшәве озакка бармаган. Байдан бушатылган йортны күпмедер вакыт китапханә итеп тотканнар, аннары ни өчендер мәктәп ихатасына күчереп, өен үзенә, чардагын үзенә аерым салып куйганнар... Йортның хуҗасы башта Архангельск якларында булып, шуннан соң Сәмәркандта озак кына торып, ахыры гомерендә Уфага кайтып, шунда вафат та була. Аның улы Касыймны бик әйбәт хирург диләр иде, ләкин ул да инде дөньяда юк.

Атакай белән Гали абзый — бер заман кешеләре, борыннан ук дус та булганнар, бер-берсен табышкач, соңгы көннәренә хәтле хат та язышып тордылар. Моннан берничә ел элек кенә атакайның кайчандыр Гали абзый-

га җибәргән фоторәсемен миңа Уфадан алып кайтып бирделәр. Урам фотографы гына төшергән рәсемнең артында җыр сыманрак «шигырь» дә бар. Менә шуннан бер генә өзек:

Бар иде безнең яшь вакыт,
Уйнап-көлеп йөргән шат вакыт.
Үткән гомерләрне сизми калдык,
Килеп җиткән, имеш, карт вакыт.

Бу юлларны язганда атакайга җитмеш биш яшь булган. Әйе, үткән шул инде, яшьлекләре генә түгел, заманнары, чорлары да күптән үтеп киткән... Һәм үтәчәк икән ул, кем генә булуыңа да карамастан!

Каргалының мин белгән кешеләре әле телгә алынганнар белән генә чикләнми, әлбәттә. Безнең кардәш-ыру күп иде, кайбер якыннарына мин малай чакта барып та йөри идем. Әйтик, Саттый (тулы исеме Гапсаттар) җизниләргә яки Сәгыйть бабакайларга. Боларның берсе безнең бабакайга, икенчесе әбекайга бик якын кардәшләр. Икесе дә бездән түбән очтарак торалар. Саттый җизниләрнең ишегаллары үзе бер ялан диярсең — ифрат зур иде, тапталмыйча яткан җирләрендә кыр чәчәкләре дә үсә иде. Малны да заманында күп асраганнар булса кирәк, утлауларындагы еллар буенча җыелган, тапталып-басылып беткән иске тирес зур бер тау булып өелгән иде. Без бала-чага шуның өстенә менеп уйный торган идек.

Саттый җизни турында кызык кына нәрсәләр сөйлиләр иде. Ата-анасыннан зур байлыкка ия булып калгач, аны минем бабакайның тутасына, яшькә үзеннән күп олы кызга өйләндергәннәр. Кияү әле чынлап та бик яшь булган, өйләнгәч тә малайларга ияреп чана шуарга йөри икән. Әгәр «җизнине» тау шуганда орсалар-җылатсалар, хатыны Гөлҗиһан табагач күтәреп чыга икән дә бөтен малайларны пыр туздырып куа икән. Бик үткенчая булган диләр яшь килен!

Болар борынгы кешеләр, үзләре генә түгел, балалары да күптән картаеп, үлеп беттеләр. Балаларының балалары инде картайдылар. Иң олысына — медицина докторы, профессор Гыйниятулла абзый Терегуловка хәзер сиксән тугыз яшь! Иң кечеләре — Мичурин шәкерте, Дәүләт премиясе лауреаты, профессор Хәсән Еникеев тә минем чамаларда булыр. Бу — Саттый җизниләрнең әлеге яландай ишегалдында аунап үскән малай. Аны шул чагын мин аз гына хәтерлим, ләкин соңыннан безгә бүтән беркайчан да очрашырга туры килмәде.

...Ә менә Сәгыйть бабакайларның ишегаллары тар иде, каралтылары рәттән тезелеп киткән иде — шулайрак

күз алдында саклана. Аның каравы яшел калай түбәле йортлары зур да, бик таза да иде. Бөтен җирдә тәртип, чисталык, ничектер шәһәр йортларын бераз хәтерләтә иде. Сәгыйть бабакайның ике улы — Гомәр белән Гали — учительләр иде, бәлки, аларның да бу йортка тәэсирләре булгандыр. Шулай ук Дәүләт думасы члены Гайса морза Еникеев тә — Сәгыйть бабакайның якын туганы. (Бертуганнар түгел микән?) Күрәсез, алар үзләренә аерымрак, мәдәнирәк (яки «затлырак») токым булганнар. Безгә кардәшлекләре, әйткәнемчә, әбекай ягыннан.

Гайса морза бервакытны Уфадан безгә (Дәүләкәнгә) дә килеп киткән иде. Зур гәүдәле мәһабәт кеше, йөзебите дә эре, чал чәчле, яланбаш, өстенә юка киндердән иркен күлмәк киеп, билен тар гына каеш белән буган. Атакай мине, аңа күрсәтер өчен булса кирәк, залга чакырып алды. Гайса абзый миңа ни өчендер русча дәште, мин, билгеле, аңа җавап бирә алмадым. Шуннан соң ул зур кулы белән минем башымны тотып, әкрен генә селкеткәндәй итте, ниндидер бер җылы сүз әйтте, ләкин мин бик кызарып, залдан тизрәк чыгып киттем.

Гайса морза Еникеевнең тарихы, минемчә, игътибарга лаек. Үзе ул учитель, аннары Оренбург байлары Хөсәеновларның баш доверенные, соңыннан опекуны булган кеше. Өченче һәм дүртенче Дәүләт думасына сайлангач, аның трибунасыннан еш кына изелгән вак милләтләрнең аң-белем, культура өлкәсендәге мәнфәгатьләрен яклап, аларга күбрәк хокуклар таләп итеп речьләр сөйләгән. Революциядән соң Вятка шәһәрендә, аннары Уфада торып, 1931 елны үз әҗәле белән вафат була. Аңа кагылмыйлар һәм тимиләр... Әле үткән гасырның ахырында аның Оренбург һәм Уфа губерналары буйлап борынгы татар-башкорт җырларын җыеп йөргәнен югарыда әйткән идем инде. Кыскасы, татар дөньясының катлаулы заманында яшәп, нидер эшләп, ниндидер эз калдырып киткән шәхесләрнең берсе. Алар аз булмаган — милләтенә үзләренчә хезмәт итәргә тырышкан һәм күптән онытылган шәхесләр...

Азрак читкә тайпылдым бугай... Каргалыдагы мин белгән якын кардәшләр, билгеле, барысы да алай бертигездән түгел иде. Кайберләре баерак, каберләре ярлырак, ләкин артык фәкыйрьләре юк иде шикелле, һәрхәлдә, миңа андыйларын күрергә туры килмәде. Әмма шулай да мине бик гаҗәпләндергән бер хикмәтле кардәшләребез бар иде. Алар дүрт брат: Хәсән, Хәллә, Гомәр һәм иң кечеләре Әбүбәкер. Бабакай ягыннан безгә бик якын кардәшләр. Мин Хәсән абзый белән Әбүбәкерне яхшы-

рак белә идем. Аларның йортлары урам аша, мәчеттән аз гына югарырак. Сирәк кенә булса да, шуларга кергәли идем. (Минем чамадарак бер кызлары бар иде — күрәсең, шуңа ияргәнмендер инде.) Ләкин, дөресен генә әйткәндә, аларның йорты мине беркадәр шомландыра торган иде. Ник дисәң, гаҗәп тә искергән, тузган, котсыз, шапшак бер йорт иде ул... Юк, аны һич тә фәкыйрьләр йорты дип булмый — кара-каршы салынган, такта белән япкан һәм кайчандыр ул таза-бөтен дә булгандыр, әлбәттә... Әмма хәзер шулкадәр бетәшкән, Ходаем, әйтерсең аңа йөз ел буена да кеше кулы тимәгән. Бүрәнәләре кап-кара, түбәсендә яшел мүк, тәрәзә пыялалары керосин табыдай зәңгәрләнеп тора. Болдыр баскычлары да, өйалдының идән такталары да күптән черек — басканда бер башы батып китсә, икенче башы күтәрелә... Инде ызбаның эченә кергәч, андагы тәртипсезлеккә, шакшылыкка исең китәр. Өйнең бөтен түрен иңләп алган киң сәке өстендә сәләмә юрган, каткан туннар буталып ята, ястык-мендәрләрнең тышы юк, бер кат сүрү генә, җөйләреннән мамыклар чыгып тора. Монда, күрәсең, урын җәю, урын җыю дигән нәрсә юк — кичтән менәләр дә яталар, иртән торалар да китәләр. Шулай ук чәй урынын да җыеп тормыйлар, каткан өстәлдә эчелгән чәшкәләре, ипи сыныклары, өсте ябылмаган сөтләре, ә өйдә умарта күчедәй чебен уйнап тора... Мич аралары, морҗа буйлары тулы таракан... Мин, гадәттә, бу өйгә курка-курка гына керә идем һәм тизрәк чыгып китү ягын карый идем. Һәм нигә болай икән дип бик аптырый да идем. Чөнки башка бер өйдә дә мондый өелеп яткан шапшаклык юк, иң ярлы дигәнендә дә үзенчә чисталык — җыештырган, себергән, бусагасына хәтле сап-сары итеп юган — аяк салмыйча атлап кермиләр дә. Ә монда? Әллә искиткеч мәнсезлек, әллә коточкыч ялкаулык, әллә баштан ашкан хәерчелек — аңлап булырлык та түгел. Дөрес, байлык юк инде ул, исе дә сизелми, ләкин бит аталарыннан мирас булып калган хәерчелек тә булмаска тиеш. Безнең бабакайлар нәселе электән үк таза хәлле булган, игенне дә күп иккәннәр, малны да күп асраганнар. Боларның аталары Каһарман карт та шул нәселдән ич, әнә йортның да алты почмаклысын салдырган бит заманында. Алайса, эш нәрсәдә соң?.. Соңыннан кызыксынып сорашкан чакта, минем атакай: Хәсәннәрнең хәерчелеге үтә ялкаулыктан, иҗтиһат итмәүдән, ата малын ашап бетерүдән, дип аңлата иде. Ләкин аларның җирләре күп, имеш, тик үзләре файдаланмыйча күбрәк арендага бирәләр, шуның белән яшиләр,

имеш. (Иксәләр дә, бер-ике дисәтинә арыш яки бодай да берничә таяк тары гына чәчәләр икән.) Бәлки, шулайдыр да, башкача ничек аңлатасың бу әкәмәт хәлне?!

Мин үзем Хәсән агайны (Каргалыча әйтсәк, агакайны) яхшы ук хәтерлим. Озын буйлы, нечкә аяклы, чандыр бер кеше иде ул, йөзе кара-тутлы, әзрәк шадрасы да бар. Үзе тапаган эре сасы тәмәкене җыен чүп-чар кәгазьгә төреп тарта, бармаклары тырнак төбенә хәтле кара-сарыга әйләнеп беткән була. Мин аның бервакытта да чалбар кигәнен күрмәдем (ахрысы, булмагандыр да), әллә кызыл, әллә көрән төстәге тупас киндердән теккән, төбе салынып төшкән ычкырлы ыштаннан йөри, башында ертык эшләпә, аягында чабата киндерәсе белән бәйләп куйган иске галош. Әмма ул морза-дворян! Ул шуны белә һәм шуңа карап үзен тота да. Искиткеч горурлык һәм тәкәбберлек үзендә! Шуның өстенә ул философ та әле. Мин аның чүгәләшеп тәмәке тарткан җирдә янындагы агайларга ашыкмыйча гына акыл сатканын тыңлап торганым бар. Әлбәттә, мин бернәрсә дә аңламый идем, әмма һәр сүзенә җитди мәгънә биреп, вәкарь белән сөйләвенә, ә агайларның килешкәндәй башларын селкә-селкә тыңлауларына караганда, сүз, һичшиксез, дөньякүләм зур мәсьәләләр турында барган булырга тиеш. Сөйли-сөйли дә ул, ахырдан, башын чөебрәк: «Шылай вет ул, абзыкайларым!» — дип куя. Янәсе, сез дә, мужиклар, белеп торыгыз!

Әнә шундый бөлеп бетсә дә, ямаулы киндер ыштаннан йөрсә дә, «морзалык» һавалыгын югалтмаган кызыклы бәндәләр сирәк кенә булса да очрый иде әле ул чакларда. Хәтта Каргалының үз саилчесе дә бар иде — шул ук Еникеевләрдән... Мин дә әле аны яхшы хәтерлим. Чын исемен ачык кына белмим, бәлки, Бикмөхәммәт булгандыр, ләкин бөтен авыл аны «Бирәхмәт» дип йөртә иде. Озын буйлы таза кеше, өстендә озын чикмән, башында җәен-кышын мескен бүрек, иңбашы аша зур гына киндер капчык аскан... Кулында шомарып беткән озын таяк... Капкадан килеп кергәч, ул тоныграк калын тавышы белән исәнләшә, хәл-әхвәл сораша, аннары баскычка утырып ашыкмыйча гына дога кыла. Сәдаканы бервакытта да сорап алмый, бирсәләр — хуп, бирмәсәләр, сүзе юк. Аның каравы үзе куеныннан кечкенә шешә чыгарып, бала-чагаларга, үсеп килгән кызларга бармак бите белән генә ислемай сөртеп китә иде.

Авыл халкы бу таза агайны диванага саный иде. Әмма ул дивананың иң юашы, иң зарарсызы, балалар шикелле үтә беркатлысы. Шуңа күрә аның исеме дә халык теленә

бер синоним булып кергән, ягъни артык беркатлы ваемсыз кешегә еш кына үртәп: «Их син, Бирәхмәт!» — дип әйтә торганнар иде. Ләкин чын Бирәхмәтнең үзеннән бервакытта да көлмиләр, рәнҗетмиләр, хәтта этләр дә аңа өрмиләр иде бугай... Бөтен табигате белән ул, ничек дим, кешеләрнең шактый тупасланган күңелләрендә ирексездән шәфкать-миһербанлык хисләре уятучы бер Алла бәндәсе иде.

Әйе, каргалы кешеләре бик төрле-төрле һәм, табигый инде, мондый авыл төрле вакыйгаларга да бай булган. Чорына карап, аның өстеннән дәһшәтле өермә-давыллар да узгалаган. Шуларның берсе гражданнар сугышы вакытында булып ала. Мәгълүм ки, 1919—1920 елларда Татарстан һәм Башкортстанның кайбер төбәкләрендә «сәнәкчеләр» дигән бер кара фетнә калкып чыга. Баштарак ул беркадәр җәелеп тә китә. Менә шул «сәнәкчеләр»нең зур гына бер төркеме Чакмагыш якларыннан Каргалы тирәсенә дә килеп җитә. Алар җидесигез чакрымдагы Сынны авылында тукталып, шуннан берничә җайдакларын Каргалыга «ультиматум» белән җибәрәләр: «Давай, сез дә безгә кушылыгыз!..» Ә Каргалы — зур авыл, исемле авыл, әгәр ул кушылса, тирәяктагы ваграк авыллар да күтәрелеп чыгачак, имеш. Нишләргә? Авыл хәрәкәткә килә, кайный, шаулый, ике көн өзлексез җыен дәвам итә. Берәүләр чыгу, кушылу ягында, икенчеләр катгый рәвештә каршы... Ахырда бәхәсне хәл итәр өчен, Каргалы мәктәбенең мөдире Гыйниятулла Терегуловны җыенга чакырып китерәләр. Әйтергә кирәк, сәнәкчеләрнең бер кабахәт эше — мөгаллим һәм мөгаллимәләрне үтереп йөрү булды, ә Каргалыда инде мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, халыкның укытучыларга хөрмәте зур, чөнки укытучыларны үзе күп биргән авыл. Гыйниятулла абзый, билгеле, халыкны сәнәкчеләргә кушылмаска өнди, кушыла калсалар, Каргалыны харап итәчәкләрен әйтә. Аннары сәнәкчеләр хәрәкәтенең контрреволюцион бер фетнә генә булуын, тиздән аның басылачагын яки үзеннән-үзе сүнеп бетәчәген аңлата. Халыкның бит күпчелеге каршы бу фетнәгә, юк, кушылу асла ярый торган эш түгел, Каргалы өчен бу гомерлек бер кара тап булып калачак. Һәм соңыннан ул җәзасын да күбрәк күрәчәк!

Менә шуннан соң җыен «кушылмаска» дигән карарын чыгара. Инде хәзер бу карарны Сынныда көтеп яткан сәнәкчеләргә җиткерергә кирәк. Кемгә тапшырырга моны? Әгәр чын булса, бу хәтәр эшне Нигъмәтулла дәдәкайга йөкләгәннәр икән. Ул яхшы атка иярсез генә

атланып Сынныга киткән, барып җиткәч, сәнәкчеләрнең башлыклары янына кереп тормыйча, тик авыл урамының бер очыннан икенче очына чаклы: «Халык, ишетегез! Каргалылар кузгалмый, каргалылар кушылмый!» — дип кычкырып узган, имеш. Аның артыннан сәнәкчеләр чыгып, Каргалы чигенә җиткәнче куа килгәннәр, ләкин куып җитә алмаганнар...

Моны миңа Нигъмәтулла дәдәкай югалганнан соң, Мәдинә җиңгәчәй сөйләгән иде. Чынмы, дөресме бу?.. Ышаныр өчен тагы кемнәндер ишетәсе килә иде. Ләкин кемнән, бик күп еллар узган, ул вакыйгаларның шаһитлары да калмаган диярлек... Һәм менә 1979 елның җәендә Уфага баргач, мин әлеге Каргалы җыенында халыкны сәнәкчеләргә кушылмаска өндәгән Гыйниятулла абзыйның үзеннән сорадым: «Нигъмәтулла дәдәкайның Сынныга җибәрелүе дөресме-түгелме?..» «Дөрес булуы бик мөмкин,— диде Гыйниятулла абзый.— Күп еллар узса да, яхшы хәтерлим, җыеннан соң күрше авылларга атлар чаптырдылар. Ә Сынныга Нигъмәтулланың җибәрелүенә мин бик ышанам, чөнки ул араларында иң кыю йөрәкле, алгыр кеше иде, мәрхүм...» Шулай диде Гыйниятулла абзый — вакыйганың үзәгендә булган кеше!

Инде Каргалы тарихыннан тагын бер борынгырак вакыйганы да искә төшерик. Бу — Әси карак вакыйгасы.

Хәзер ничектер, әмма мин малай чакларда Каргалыда Әсинең исемен һәм аның көен ишетмәгән кеше булды микән?! Аннан соң инде бик күп еллар узды, буыннар алышынды, Каргалы таралды — ихтимал, Әси үзе дә һәм көе дә әкренләп онытылгандыр яки онытылып барадыр. Ләкин бөтенләй үк онытылмасын иде ул. Түбәндә сөйләнәчәк вакыйганың моңа хакы бардыр дип ышанасым килә.

Хуш, кем соң ул Әси, кай заманда яшәгән һәм ниләр кырган? Атакай сөйләгәннәрдән һәм Срур тутакайның миңа биреп торган русча язмасыннан чыгып, мин кыскача гына шуны әйтә алам: үткән гасырның икенче яртысында Каргалыда Әсәдулла Хәбибулла улы Еникеев дигән бик гайрәтле, кыю, тәвәккәл һәм, әйтергә кирәк, үзенчә акыллы да бер кеше булган. Әси — аның кыскартылган исеме, шушы исем белән ул халык теленә кереп тә калган. Үзе морза, ләкин шул заманның милли һәм икътисади[1] кысулары нәтиҗәсендә булса кирәк, бу кеше караклык итү, талау юлына баса. Ялгыз башы гына түгел, ә Каргалы кешеләреннән үзенә бер шайка оештыра, шу-

[1] *Икътисади* — экономик.

ның оста, сак, хәйләкәр җитәкчесе булып таныла. Аның уң кулы — Сәлиәсгар Еникеев, Әсинең үзе кебек үк кыю да, батыр да булган... Бөтен «эшне» икәү корганнар, икәү алып барганнар. Урлау-талау мактаулы эш түгел, әлбәттә, ләкин хикмәт шунда ки, алар, ягъни Әси шайкасы, Каргалының үзендә беркемнең дә малына тимәгән, шулай ук якын-тирәдәге татар-рус авылларын да бервакытта да борчымаган. Алар бары бик еракка китеп, хәтта Оренбур һәм Самар губерналарына чыгып, шундагы боярларны талаганнар, чиркәүләрне басканнар. Күп вакытта талаган малларын Каргалыга да алып кайтмыйча каядыр юлда яшереп калдыра торган булганнар.

Ә авылның үзендә Әсәдулла агай — мөхтәрәм, өстәвенә бик диндар бер кеше, биш вакыт намазын калдырмый, мәчеткә дә чалмадан гына йөри. Үзенчә юмарт, миһербанлы да булган ул. Урлап кайткан атны суйса, итен еш кына ятимнәргә, фәкыйрьләргә өләшкән. Атакайның әйтүенә караганда, ул ерак кырларда кое казыткан, ватылган күперләрне төзәттергән. Аш мәҗлесе үткәргәндә гел генә: «Хәзрәтләр, алдыгызга килгән ризыкта бер локма харам нәрсә юк, тыныч җан белән ашагыз!» — ди икән.

Авыл халкы Әсәдулла агайның чын гамәлен, һичшиксез, белеп торган, әмма ләкин һичкем аңа бармагы белән дә төртеп күрсәтмәгән. Хәтта авылның мулласы да тел яшергән. Шулай да полиция, бик нык эзләнә торгач, ахырда Әси каракның эзенә төшә. Аннары таланган боярлар да һаман Каргалы ягына күрсәтеп, каракларны шуннан эзләргә кирәк дип әйтә килгәннәр. Берничә тапкыр куа да чыкканнар, ләкин Әсиләрнең атлары дөлдел шикелле берәүне дә артларыннан җиткермәгән. Әсинең үз аты, имеш, тезгенен муенына салган килеш абзар ышыгында һәрвакыт бәйләүсез генә торган. Берәр төрле хәтәр туа калса, Әси ишек төбенә чыгып сызгыруга, туры аты шунда ук юртып килеп тә җитә икән: Әси сикереп кенә атлана да исеп киткән җилдәй юк та була, имеш!

Полиция кешеләре еш кына Каргалыга тентү белән килә башлыйлар. Ләкин берни тапмыйча кире китәргә мәҗбүр булалар. Халыктан һәм авыл мулласыннан сорашып та бернәрсә белә алмыйлар. Хәтта бер тентүдән соң, шул ук төнне Әси, ярдәмчесе Сәлиәсгар белән бергә, Уфага барып, губернаторның махсус үзе генә җигеп чыга торган ике иң шәп атын да урлап китә. Шунда ук яңадан Каргалыга тентү килеп җитә, ләкин бу юлы да нәтиҗә шул ук: Әси намазлык өстендә, беркем бернәрсә күрмәгән, атларның монда эзе дә юк!

Әси шәүләсе артыннан болай бушка чабу тагын күпмегә сузылган булырдыр — әмма Каргалы өстенә килгән бер зур афәт аның тотылуын тизләтә. 1871 елны Каргалы якларында бик көчле корылык була, игеннәр кибеп бетә, халык икмәксез кала. Кышны уздырып, язга чыкканда инде авылда ачтан үлүчеләр дә күренә башлый. Менә шул ачларга ярдәм итү теләге белән Әсәдулла Еникеев үзенең агасы Хисмәтулланы иң якындагы Языков боярына үтенеч белән җибәрә. Үтенеч шул: господин Языков Каргалы халкына яңага хәтле берничә олау икмәк әҗәткә биреп торсын, яңа ашлык өлгерү белән кайтарачаклар — моны Әсәдулла Еникеев үз өстенә ала. Шуның белән бергә ул, Әсәдулла морза, моңарчы Языков имениесенә тимәгән шикелле, моннан соң да, тимәскә сүз бирә... Морза сүзе ант кебек үк нык булачак!

Языков үтенеч белән килгән Хисмәтулла агайны башта сабыр гына тыңлый, ләкин сабырлыгы бик тиз бетә башлый, бите-муены кан йөгергәндәй бүртеп чыга, аннары сикереп тора да Әсәдулланың үзен дә, барлык Каргалы халкын да «ворлар, разбойниклар» дип акырып-бакырып сүгәргә тотына. Ачтан кырылып бетсәләр дә, бер бөртек тә бирмәячәген әйтә һәм, ялчыларын чакырып, Хисмәтулланы имениесеннән төйгечләп озатырга куша. Ялчылар Хисмәтулла агайның кулларын каерып бәйләп, үтерә язганчы кыйнап, Каргалы юлына чыгарып ташлыйлар.

Билгеле инде, Языков боярының бу явызлыгын Әсәдулла җәзасыз калдырмый. Бояр имениесен ул яхшы белә, тик форсат кына көтә. Һәм озак та үтми, форсат үзеннән-үзе дигәндәй килеп тә чыга: имениедә бояр хатынының туган көнен бәйрәм итәләр. Тирә-яктан бик күп кунаклар җыела. Һәм шул ук төнне Әси дә туры атына атланып ялгызы гына бояр имениесенә юнәлә. Ләкин ул таларга бармый — үч алырга бара. Җәйге кыска төн, тирә-юнь тып-тын, зур йортның бөтен бүлмәләрендә ашап-эчеп ауган кунаклар йоклый — кунаклар гына түгел, эт булып арган хадимнәр дә төрлесе төрле урынга тәгәрәшеп беткәннәр. Менә шул чакта Әси туп-туры боярның йокы бүлмәсенә тәрәзәдән сүләндәй тавыш-тынсыз гына сикереп керә дә киң агач караватта тәмле генә гырлап яткан хуҗаның өстен кинәт ачып та ташлый. Бер кат нечкә озын күлмәктән генә яткан бояр шунда ук коты алынып күзләрен ачып җибәрә. Әси аңа иелеп, шыпырт кына әйтә: «Тавышыңны чыгарасы булма, ату, урыныңда ук буып үтерәм»,— ди. Аннары чигенә биреп, кулындагы чи каештан ишеп үргән кыска саплы озын камчысы белән: «Менә бу сиңа ачларга ярдәм

итмәгән өчен, мине, Әсәдулла морзаны, разбойник дип атаганың өчен, минем братым Хисмәтулла морзаны кыйнатып җибәрүең өчен!» — дия-дия чажлатып яра да башлый. Камчы сызгырып төшкән саен боярның нечкә күлмәге аша канлы юллар бүртеп чыга, үзе киң караватында еландай үрле-кырлы сикеренә, әмма үрсәләнеп ахылдаса да, кычкырырга батырчылыгы җитми. Камчыдан кеше үлми — бояр моны бик яхшы белә. Әси уңлысуллы яра-яра да кире тәрәзәдән сикереп юкка да чыга. Каргалыга ул кайтып тормый, күршедәге Галышево дигән рус авылына барып, шундагы дусларында яшеренеп ята.

Менә шуннан соң инде Әсине тотар өчен Каргалыга губернатор үзе җибәргән егерме кешелек кораллы отряд килә. Өч ай буена отряд Әсине һәм аның уң кулы Сәлиәсгарны эзли, көтеп тә ята, әмма алар икесе дә җиргә сеңгәндәй юкка чыгалар. Бары тик солдатлар киткәч кенә, Әси белән Сәлиәсгар өйләренә кайталар. Ләкин отряд кемнедер яшерен күзәтүче итеп калдырган булса кирәк, озак та үтми боларның икесен дә җомга намазыннан чыккан чакта тотып алалар һәм Уфа төрмәсенә озаталар.

«Әси карак» эше буенча тикшерү шактый озакка сузыла. Ике-өч губернадан җыелган материал нигезендә, «Әси шайкасына» катнашы булса да, булмаса да, Каргалының кырык-иллеләп кешесенә гаеп тагыла. Бу кадәр зур эш ачылгач, губерна суды, бөтен Каргалы халкын ерак Якутиягә сөрергә рөхсәт сорап, Петербургтагы сенатка мөрәҗәгать итә. Кыскасы, Каргалы дигән авылны моннан куарга, бетерергә кирәк. Бу хәбәр Каргалы халкын, билгеле, бик нык борчуга сала. Авыл шаулый, авыл аптырый — нишләргә, ничек итеп бу коточкыч афәттән котылырга? Ахырда күп сүзләрдән соң авылның берничә өлкән кешесе, мулласы һәм старостасы, яклау сорап, татар бояры Тәфкилевкә баралар. Тәфкилев морза — үзе дә зур алпавыт булу өстенә, патшаның ышанычын казанган һәм иң югары хөкүмәт даирәләре белән бәйләнештә торган кеше. Әлбәттә, ул рус боярларының мәнфәгатен сайлау ягында, ләкин бу очракта гаделсезлек бик ачык күренеп торганлыктан (Каргалының бөтен халкы да карак түгел ләбаса!), килгән вәкилләрнең гозерен тыңлап, сенат белән сөйләшеп карарга риза була. Шулай итеп, аның сөйләшүе нәтиҗәсендә сенат бөтен Каргалыны Себергә сөрүдән туктата, ләкин бер шарт белән: Каргалы халкы үзе Себергә сөрелергә тиешле кешеләрне күрсәтеп, шуларның исемлеген төзеп бирсен! (Күрәсең, тикшерүчеләр үзләре гаеплеләр белән гаепсезләрне аерып бетерә

алмаганнар.) Башка чара юк, авылны саклап калыр өчен сенат таләбенә риза булалар. Авыл үз кешеләрен яхшы белгәндер инде, менә шул нигездә Әси белән Сәлиәсгарның иң якын иярченнәреннән егерме кешене күрсәтеп бирәләр. Шул рәвешчә, Каргалыдан барлыгы егерме ике гаиләне, хатын, бала-чагалары белән бергә, Себергә (Якутск губернасына) сөргенгә куалар. Алар киткәндә, бөтен авыл кузгала, тәкбирләр әйтеп, хәер догалар теләп, карты-яше елашып, озатып калалар. Авыл халкының Әси каракка бернинди ачуы да, үче дә булмый, киресенчә, аны гайрәтле дә, үзенчә гадел дә бер кеше итеп яраталар һәм хөрмәт итәләр. Моның шулай икәнен халык арасында бик тиз таралып өлгергән «Әси карак» көе үзе дә ачык күрсәтеп тора. Бу көйне Әси үзе чыгарган, имеш, диләр. Һәрхәлдә, сүзләре аныкы булырга тиеш. Китәр алдыннан Каргалы тавына менеп, авыл өстенә карап җырлаган, имеш. Менә аның кайбер җырлары:

Менәр идем тауның башына,
Утырып җырлар идем кашына.
Киткән җирләрдин исән кайтсам,
Тарих язар идем ташына.

Туры атыкаем-малыкаем,
Атламыйсың, сикереп чабасың,
Туры атыкаем-юлдашкаем
Ятлар кулына инде каласың.

Бу бик моңлы озын көй. Минем атакай да аны еш кына җырлый торган иде. Хәзерге вакытта сиксән алты яшьлек апам Срур тутакай исенә төшергәндә әкрен генә җырлаштыргалый. Аның бу көйне һәм үзе белгән Каргалының тагын кайбер көйләрен җырчылардан кемгә дә булса биреп калдырасы бик килә иде. Минем үтенүем буенча, Мәхмүт Нигъмәтҗанов Мәскәүгә бер баруында Срур тутакайда булып, аңардан һәм якын туганыбыз Зөләйхадан ул көйләрне магнитофонга язып та алды. Бәлки, югалмас, бәлки, сакланыр да әле Каргалының ул борынгы гаҗәеп көйләре!

Әсәдулла Еникеев — «Әси карак»ның соңгы гомере турында берничә генә сүз. Егерме биш елдан соң ул Себердән Уфага кайтып, шунда үзенә йорт алып, күпмедер вакыт яшәп кала. Каргалыга да кайта ул һәм безнең өйдә кунак та булып китә. Ап-ак сакаллы, мәһабәт картның сезнең өйдән чыгып, җигүле чанага иpләп кенә утырып киткәнен үзем күреп тордым, агакай аның тун чабуларын кыстыргалап, капкага чаклы озатып калды, дип сөйләгән иде миңа Срур тутакай. Димәк, Әсәдулла үзе-

нең туган авылында искечә һаман да мөхтәрәм бер кеше булып саналган.

1907 елны Әсәдулла бабайны ни өчендер яңадан кулга алалар һәм шунда — Уфа төрмәсендә ул вафат та була. Билгеле, бу батыр йөрәкле кешене бары гади карак дип кенә тану дөрес булмас иде. Рус самодержавиесенә һәм боярларына каршы ниндидер ачу, үчлек ята, минемчә, аның бу хәтәр-кыю хәрәкәтендә. Кара реакция елларында патша хөкүмәтенең аны икенче тапкыр төрмәгә ябып, ниһаять, шунда үләргә мәҗбүр итүе дә әллә кайчангы караклыгы өчен генә булмас, әлбәттә. Ул заманда гади караклар һәр авылда диярлек очрап торган, әмма Әси кебек легендага әверелеп, җырларга кереп, халык хәтерендә яшәгәне меңнән бер генә!

Әсәдулла бабайдан һәм аның җырыннан аерылганчы, гомумән, Каргалы көйләре турында кыскача гына әйтеп китү кирәктер, ахрысы. Әйе, Каргалының үзендә генә җырлана торган көйләре бар иде. Мин аларны күбрәк атакайдан ишеттем — ул, мәрхүм, җыр сөюче иде. Шулай ук Нигъмәтулла дәдәкай да җыр сузарга бик һәвәс булган. Минем аның Абзан туенда җырлаганын һич тә онытасым юк. (Бу хакта мин, хәтерләсәгез, «Җиз кыңгырау» хикәясендә язган да идем.) Кызганычка каршы, Нигъмәтулла дәдәкайның җыры иртә өзелде.

Алардан соң мин ул көйләрне гел генә диярлек Срур тутакайдан һәм Зөләйхадан ишетә килдем. Без, якын туганнар, кайчагында ничектер туры килеп, Мәскәүдә җыелышабыз: Казаннан мин барам, Алма-Атадан Зөләйха белән Шәрәф, Уфадан Рауза яки Ләйлә килгән була... Бөтен кич буена диярлек Срур тутакайның борынгы әйберләр һәм рәсемнәр белән тулы, шунлыктан тыгыз, тәртипсезрәк тә бүлмәсендә җыр тыңлап, үткәннәрне сагынып утырабыз. Срур тутакай пианинода үзе уйнап, үзе җырлый — әкрен генә итеп, әмма бик җиренә җиткереп, үткәзеп җырлый. Уйнап-җырлап туктагач, безгә борылып, шул көй кузгаткан берәр вакыйганы яки кешене хисләнеп-дәртләнеп сөйләп тә ала.

Зөләйха да үзе уйнап, үзе җырлый — аның тавышы көчлерәк тә, иркенрәк тә. Атасы мәрхүм кебек башта тамак кыргалый, башын чөебрәк уйлана, шуннан җай гына башлап җибәрә — җыр хыялны ияртеп әллә кайларга алып китә, ә моңы әйтерсең юка гына ефәк булып йөрәкләргә йомшак кына урала да урала. Ул күбрәк «Ялан» көен җырлый, җырлап тынгач, әкрен генә: «Бу көйне атакаем печән чапканда еш кына җырлый торган иде»,— дип әйтеп куя.

Мин үзем җырдан мәхрүм кеше, әмма бик тиз тәэсирләнәм, беренче җырдан ук инде миңа яшьләремне тыю бик авыр була. Җыры да бит нинди — бәгырьгә төшәрлек!

Каргалыкай буе, ай, камышлы,
Камышлары аның тавышлы.
Еллар белән еллар бер үк түгел,
Быелгысы никтер сагышлы.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Кызык хәл: бик әсәрләнеп тыңлаганга күрәме, мин җырланган көйләрнең исемнәрен белә алмыйча кала идем. Менә «Әси карак» көе, дидем, «Ялан» көе, дидем (ләкин башкортның «Ялан җиркәе» түгел, бөтенләй башка),— тагын нинди көйләр? Тагын «Исмәгыйль җизни көе» дип бер моңлы озын көй җырлыйлар:

Казаннардин килгән, әй, җиз курай,
Ефәк калфак кигән кыз уйнай.
Үзе лә уйнай, үзе җырлай,
Күңелкәе аның кемне уйлай.

Аннары «Шәйсолтан», «Шакир көе» дигәннәре дә бар. Болар барысы да Каргалының саф үз көйләре, бүтән бер җирдә дә миңа аларны ишетергә туры килгәне юк. Шулай ук безнекеләр «Агач башы»н да бик яратып җырлыйлар, ләкин бусы инде читтән килгән булырга тиеш. Ул кайчандыр шактый таралган, хәзер исә онытылып бара торган бик матур көй, Фәйзи Биккинин уйнавында грампластинкага да язылып калган, тик аны бездә башкачарак — сузыбрак, бормалырак итеп җырлыйлар.

Каргалының үз көйләре барсы да башкорт көйләренә тартым — борылма-күчешләре белән өзелмичә сузыла, бер күтәрелә (көчәя), бер төшә (әкренәя) торган озын көйләр. Һәм шушы охшашлык мине еш кына уйландыра иде: нидән бу, башкорт җиренә күчеп утыргач һәм башкортлар белән аралаша башлагач кына туганмы алар? Ләкин болай уйлау бер дә нигезле түгел кебек. Безнең халык, күргәнебезчә, бик борынгы халык. Ике мәртәбә ул яшәгән җирен алыштыра — башта Азов диңгезе буйларыннан Россия үзәгенә, ә күпмедер гасырлардан соң башкорт җирләренә күчеп утырырга мәҗбүр була. Йә, әнә шул меңнәрчә чакрымнарга сузылган далаларны, урман-суларны арбалар шыгырдавын тыңлый-тыңлый үткән чагында, ул үзенең моң-зарын көйләргә салып җырламагандыр дисезме? Һәм аның бу җыр-моңнары буыннан-буынга күчә килмәгәнме әллә? Менә бу җыр үзе генә дә шул хакта сөйли түгелме?

Сибелеп тә төшкән, бөгелеп тә үскән
Юл буенда ялгыз бер бодай.
Газиз башны туган илкәйләрдән
Аермасын иде бер Ходай.

Юк, башкорт җиренә дә ул йөрәге, өметләре белән бергә үзенең җыр-көйләрен дә алып килгән, әлбәттә. Инде охшашлык бар икән, нигә моңа артык гаҗәпләнергә? Башкорт — асылда, дала халкы, безнең ерак бабайлар да кайчандыр далада яшәгәннәр. Башкортның тамыры кыпчактан диләр, безнең чыгышны да кыпчак белән бәйлиләр. Тарихның саргайган сәхифәләрен актара башласаң, бик хикмәтле нәрсәләр килеп чыгар иде. Менә бит хәтта телдә дә охшашлык юк түгел: башкорт «атай», «агай» ди, ә без «атакай», «агакай» дибез, ләкин болай дәшү безгә һич тә башкорттан кермәгән. Бик борыннан һәм бик ерактан килә ул. Аннары тагын башкортның яратып куллана торган «җиңгә» сүзе бар: өлкәнрәк хатыннарга, бигрәк тә ага тиешле ирнең бичәсенә гел генә «җиңгә», «җиңгәм» диләр. Безнең төмәннәр дә нәкъ менә кардәш тиешле өлкән кешенең хатынына «җыңкай» дип дәшәләр. (Бертуган агасының хатынына һәм җирдәге шикелле «җиңгәчәй» диләр.) Күрәсез, бер үк сүзләр, тик әйтелешләре генә төрлечә.

Дөрес, безнең төмәннәрнең теле башкортныкыннан гына түгел, күпчелек татарныкыннан да шактый нык аерыла. Бу тел, асылда, мишәр теленең бер диалекты булырга тиеш. Ләкин ул Касыйм татарлары, шулай ук Нижгар мишәрләре теленнән сизелерлек аерылып тора. Касыймлылар сүзне ничектер әйтеп бетермичә, бер-беренә ялгабрак һәм кабаланыбрак сөйлиләр, шуңа күрә аларны тиз генә аңлап та булмый. Каргалы төмәннәре исә сүзне өзеп, тулы әйтеп, авыз тутырып сөйләргә яраталар. Аннары каты мишәрләргә хас «ч» урынына «ц» кулланып (әйтик, «пыцак» дип) сөйләү дә аларда юк. Әмма күп сүзләрнең әйтелеше шулай да мишәрчә: ү(өй), үләнү (өйләнү), түән (төен), этәм (әйтәм), чаука (чәүкә), корыйк (койрык) һәм башкалар... Ә менә бу шактый еш әйтелә торган сүзләр Каргалыга гына хас түгел микән: малыкаем («җаныкаем» мәгънәсендә), әмән («гүя» урынына), гареп (гариб — «мескен», «бичара» мәгънәсендә йөри). Тегендә, Тамбов җирендә яшәгән чакларында рустан кереп калган сүзләр дә бар: ызба (өй), кучарка (кочерга — кисәү агачы), внука (онык) — шуның ишеләр тагын булырга тиеш. Мәсәлән, Каргалыга кайтып йөргәндә, мин малайлардан еш кына «пырт» дигән сүзне ишетә идем. «Әдә, пыртка киттек»,— дип, мине чакыра торганнар

иде. Баштарак һич тә аңлый алмадым: нәрсә булырга мөмкин ул «пырт» дигәннәре? Үзе, җитмәсә, авылдан шактый читтә дә икән. Ахырда, бер ияреп баргач, күрдем мин ул «пырт»ны, тегермән буасы икән ләбаса! Малайлар мине шунда су керергә чакырганнар икән... Ярый, безнеңчә — буа, Каргалыча «пырт» та булсын ди, ләкин кайдан килеп кергән ул әкәмәт? Хәер, сез аңлагансыздыр инде, русның «пруд» сүзе шулай кереп киткән икән безнең Каргалы теленә.

Билгеле, Каргалы халкының телендә генә түгел, көнкүрешендә, гореф-гадәтләрендә дә үзенчәлекләр җитәрлек күп. Бәйрәмнәре, туйлары, уеннары да башкачарак булган аның. Мәсәлән, яңа ел кергәч, айлы төндә су тулы чиләккә билгеләп салган кашыкларны ак кар өстенә чыгарып сибеп, бәхет сынау уены Каргалыдан башка тагын кайда гына бар икән? Җитмәсә, исеме дә «раштуа уены»! Ләкин мин биредә алары турында җәелеп тора алмыйм, чөнки, беренчедән, белүем чамалы, икенчедән, Срур Сүнчәләйнең Каргалы туен һәм уеннарын бик белеп, тәфсилләп язган кызыклы мәкаләләре безнең журналларда («Казан утлары» белән «Азат хатын»да) заманында басылып чыккан иде. Шулай булгач, язылганны кабатлаудан мәгънә юк, теләгән кеше үзе дә табып укыр.

...Каргалы турында тагын нәрсә әйтәсем калды? Бик күп еллар узды шул. Бала чак хәтере күргәннәрне ничаклы гына нык беркетмәсен, барыбер әкренләп бик күбесе онытыла-югала бара икән. Аннары хәтер сандыгы да кечкенә бит әле, бер биш-ун еллык «хәзинә» җыелгандыр инде аның төбендә, хәлбуки аннан соң алтмыш еллап гомер узып та киткән. Бик төптә калган шул бала чакныкы! Әмма ни аянычы: бала чактан ук туган туфрактан аерылып торгач, еллар үтү белән ул үзенең тансыклыгын һәм кадерен дә югалта башлый икән. Ләкин беркайчан да онытылмый. Юк, онытылмый! Менә ни өчен ишеткәннәремне генә булса да әйтеп бетерәсем килә. Алары да инде күп калмады.

Каргалы халкының туганлык җепләре белән үзара бик нык бәйләнеп, чуалып беткәнен кабатлап булса да әйтергә туры килә. Бабакайлар, әбекайлар, агакайлар, дәдәкайлар, җизниләр, кияүләр, җиңкайлар, җиңгәчәйләр — барсы да бит бер авылда яшәгәннәр, хикмәти Хода! Якын туганнарын аерыр өчен махсус сүзләре дә булган. Әйтик, ике бертуган балаларын «тудык» дигәннәр һәм үзара «тудыкай» дип сөйләшкәннәр дә (аеруча хатын-кызлар). Тудыклардан туганны «тумачи» дигәннәр. Тагын «трачи» дигәне дә бар икән әле — бусы инде тумачилардан

туган дүртенче буын (беренче буын бер ата-анадан туганнар). Ләкин гамәлдә бу сүз йөрми диярлек, чөнки туганлык бик ераклашкан, кемнең кемгә «трачи» булуын белүе дә бик читен.

Шулай ук картларга буйсыну, картларны хөрмәт итү дә көчле булган. Билгеле, бу гадәт — гомумән, татар халкына хас сыйфат, ләкин төмәннәрдә ул аеруча нык сакланган. Гаиләдә бабай үлсә, әби «баш» булып калган — аңа берсүзсез буйсынганнар. Һәр эштә диярлек бу шулай. Хәтта сөйлиләр: түр башында туксаннан узган әби калтыранып утыра. Юньләп күзе дә күрми, колагы да ишетми, акылы да инде әйле-шәйле генә. Шулай да аның ап-ак сакаллы улы — күптән кызларын биргән, улларын өйләндергән йорт хуҗасы бабай — берәр җиргә кунакка яки туйга барырга кирәк булса, иң элек әнә түр башында калтыранып утырган шул карчыктан сәкегә таянып, үрелеп, ипләп кенә рөхсәт сораган:

— Анакай, кәбәм, безне вет Ибәй кодаларга кунакка дәшкәннәр иде, рөхсәт итәрсез микән?

Карчык җавап бирергә ашыкмый, башын селкетеп утыра бирә, аннары йокысыннан айныгандай сорый:

— Нәстә әйтәсең?

— Кунакка дәшкәннәр иде, дим, рөхсәт итсәң...

— Кемгә?

— Ибәй... Ибәтулла кодаларга.

— Кем ул, нинди кода?

— Соң, үзебезнең Җәмилә киленнең аталарына инде... Түбән очка.

Карчык, тагын озак кына дәшми торып, кырыс кына әйтеп куя:

— Ярар, барырсыз... Тик дөньягызны онытып утырмагыз, якты күздә кайтыгыз!

Ак сакаллы картның әйле-шәйле анасыннан әнә шулай рөхсәт алуы — бу бер дә арттырып әйтелгән сүз түгел. Шулай булган заманында, картлар рөхсәтеннән (яки фатихасыннан) башка бер генә эш тә эшләмәгән.

Аннары төмәннәрдә хатын-кызлар да шактый ук хөрлек белән файдаланганнар. Карчыклар йөзләрен яшермәгәннәр, хатыннар олырак ирләрне очратканда, битләрен яулык чите белән генә каплый төшеп узганнар. Яшь киленнәр француз бөркәнчек ябынганнар, иренең туганнары белән күрешкәндә чүгенеп (реверанс ясап) кул биргәннәр. Кызны күрсәтмичә бирү яки егетен күрмичә чыгу кебек кыргый гадәтләр дә булмаган. Кыскасы, «кара йөзләр» кебек фаҗиганең Каргалыда булуы мөмкин дә түгел.

Инде исемнәр һәм кушаматлар турында берничә сүз. (Кушаматлар кайда гына юк ул, ләкин бу очракта үзенә күрә бер сере бар.) Хикмәт шунда, безнең Каргалыда фамилияләр аз, бер үк исемнәр бик күп. Үзенең һәм атасының исеме туры килгәннәр дә аз түгел. Шул сәбәпле монда кешеләрне кушаматсыз аерып та булмый. Әйтик, бер үк фамилиядә ике Кәлимулла бар икән, аның берсен Болаш Кәлимулла, икенчесен Гыжнай Кәлимулла дип йөрткәннәр. Кыскасы, кушаматсыз берәү дә юк. Хәер, бөтен авылга бер кеше булган диләр. Исеме аның Әхмәт икән. Менә шул абзый бер мәҗлестә: «Минем кушаматым юк, мин коры Әхмәт кенә»,— дип мактанган, имеш. «Әһә, алаймыни?!» — дигәннәр тыңлап утыручылар һәм шунда ук аны Коры Әхмәт дип йөртә дә башлаганнар. Мактану харап иткән абзыйны!

Ләкин бик күп кушаматларның «чыгышы» билгесез, махсус төпченмичә белеп тә булмый, шулай да кайберләренең «тарихы» мәгълүм. Мәсәлән, Кердеш Нури дигән кеше булган. Ул кайчандыр Мәмти (Мәфтүхә) исемле хатынга йортка кергән. Шуннан инде аңа Кердеш дигән кушамат тагылган. (Хәтта яңа сүз иҗат иткәннәр.) Яки Әйләнчек Сафины алыйк. Бу кеше берәр җиргә барыр өчен атын җигеп, ишек төбенә тарттыргач та, чыгып китә алмыйча, өе тирәсендә һаман әйләнә дә тулгана икән. Шуның өчен аңа Әйләнчек кушаматы бик урынлы тагылып та кала.

Кушаматлар, фамилия шикелле, атадан балага да күчкән. Әйтик, атасының кушаматы Бәлеш икән, малайлары да Бәлеш булып йөргән. Минем тагын Чөчеләр («төче» сүзеннән), Нәмиләр дип күпләп әйткәнне дә ишеткәнем бар — бу инде тоташ бер токымның кушаматы булса кирәк. Бер кушаматның хәтта фамилиягә әйләнүен дә ишеткән идем. Югарыда Болаш Кәлимулла дигән кеше телгә алынган иде — менә шуның бер улы атасының кушаматын тоткан да фамилиягә әйләндергән. Хәзер үзе дә, балалары да Булашевлар булып йөри икән.

Әйе, болар барсы да элек иде — миңа чаклы һәм мин бала чакта булган хәлләр. Аннан соң күп сулар акты, күп җилләр исте, буыннар алышынды, тормыш алышынды. Тулаем дөнья бик нык үзгәрде. Бу үзгәрешләрдән минем туган авылым Каргалы да читтә торып калмады, билгеле. Бөтен җирдәге шикелле, хәзер инде анда да бай да юк, ярлы да юк, һәр җәһәттән тигезлек, барсы да бер чама тук һәм мул яшиләр... Борынгы озын көйләр урынына кыска-дәртле көйләргә җырлый торганнардыр, иске уеннар да онытылып беткәндер — клубка йөри яки те-

левизор карый торганнардыр (бөтенесе булмаса да), кушаматларның да кирәге беткәндер, яңа буын бер-берсенә, ихтимал, «фәлән фәләнович» дип кенә дәшә торгандыр... Хәтта ялан-кырларның да исемнәре онытылып бетмәде микән? Ә матур иде ул, табигатьнең үзеннән алып, халык биргән исемнәр: Торна кичүе, Төлке чокыры, Үгез куагы, Бозау басуы, Әркәсле, Зирекле баш, Тозлы куш һәм башкалар, һәм башкалар. Хәзер алар совхоз җирләре, зур-зур участокларга бүленеп, беренче, икенче, өченче бригада басулары дип кенә йөртелә торганнардыр...

Озын сүзнең кыскасы, мин белгән өч мәчетле иске Каргалы юк ул. Дөрес, шул ук урында, шул ук исемдә кечерәк бер авыл тора, әмма бу инде башка авыл, яңа авыл.

Каргалы халкының читкә сибелүе турында сүз булган иде инде. Кайбер фамилияләр, мәсәлән, Еникеевләр белән Терегуловлар, анда бөтенләй диярлек калмаган да, имеш. (Хәер, бөтенләй үк булмас, монысына никтер ышанып бетәсем килми.) Һәрхәлдә, бик күпләр киткәннәр — бигрәк тә яшьләре... Һәм бик күптән, революциягә чаклы ук башланган да ул. Революциядән соң инде берәмләп кенә түгел, күмәкләп тә китә башлыйлар. Бу хәлнең, төрле социаль сәбәпләрдән башка тагын бер «гаепчесе», минемчә, школа булса кирәк. Эш шунда ки, Каргалыда әле үткән гасырның ахырларында ук инде русча укыту башлана. Мәчет каршындагы мәдрәсәдә мулла абзый балаларга дини сабак укытса, минем инәйнең атасыннан калган нарат йортта Ибәтулла учитель бары тик русча укыткан. Шулай итеп, авылда русча укый-яза белүчеләр һәм башлангыч белем алучылар елдан-ел әкренләп арта барган. Соңыннан Казан, Уфаларга китеп, укуын дәвам иттерүче кайбер яшьләр — әнә шул Ибәтулла учитель шәкертләре. Шулардан инде беренче врачлар, агрономнар, землямерлар чыга да башлый.

Бу гасырга кергәч, унынчы еллар тирәсендә булса кирәк, патша хөкүмәте татар-башкорт балалары өчен Каргалыда ком-таштан зур школа салдыра. Максат, билгеле, «инородецлар»ны русча укыту һәм тәрбияләү, шуңа күрә ул казна хисабына яши, читтән рус укытучылары китерелә. 1911 елда ачылган бу школа высшее начальное училище дип атала. Тирә-яктагы татар, башкорт авылларыннан күпмедер укучылар җыела, рус авылларыннан да укырга киләләр, ә Каргалының үз малайлары барсы да диярлек шунда кереп укыйлар. Зур, якты класс бүлмәләре, уку әсбаплары, тәҗрибәле укытучылар белән тәэмин ителгән школа үзенең шәкертләренә шактый

төпле белем бирә. Бетереп чыгучыларга югарырак уку йортларына керү өчен юл ачыла, ә бик күбесе школа биргән белем һәм хокук белән үзе укытучылык итә башлый. Каргалы укытучыларын ул заманда бөтен тирә-як авылларда очратырга мөмкин иде.

Менә шул школа аркасында, диясем килә, Каргалы яшьләренең күпләп читкә китүләре башлана да инде. Бигрәк тә егерменче-утызынчы елларда агылып китәләр. Бәләбәй белән Уфаны әйткән дә юк, Казан белән Мәскәүгә дә барып җитәләр. Уку, уку, кайда гына булса да, ничек кенә булса да уку! Әйтәсе дә түгел, мактаулы омтылыш! Алардан урта һәм югары уку йортларын бетергән күпме белгечләр илгә таралды. Бөек Ватан сугышында Каргалы кешеләреннән егерме полковник, унике врач булган, имеш — шуны да миңа әйттеләр (бер җиргә илле дүрт врач дип тә язып куйганмын, ләкин бусы артык күп, кеше ышанмас). Тора-бара алардан галимнәр дә чыкты. Хәзерге көндә дә бер Казанда гына Еникеевләр һәм Терегуловлардан берничә профессор бар. Татарның беренче медицина профессоры Әбүбәкер Терегулов та Каргалы баласы — Казан университетын 1911 елны ук бетергән булган. Фән өлкәсендә династияләр туды дип тә әйтергә мөмкин. Мәсәлән, Уфада Гыйниятулла абзый Терегулов үзе профессор, улы профессор, сеңелесенең кызы профессор — барсы да медицина докторлары. Гыйниятулла абзыйның энесе Искәндәр абзый Мәскәүдә Бауман институтының профессоры иде, ә кырыкка да җитмәгән улы — МГУ профессоры, дөнья күләмендә танылып барган галим, диләр.

Бер авыл өчен бу бик күпкә китте дип, бәлки, ышанмаучылар да булыр, ләкин мин һич тә арттырмыйм. Болар бит барсы да патша вакытында ук русча укыта башлауның нәтиҗәсе, әлеге школа чәчкән орлыклар. Башта аталары укыган, алар балаларына югары белем бирергә тырышканнар — шулай ялганып киткән инде ул. Аннары яшь буынның бик күбесе Каргалыда да тумаган.

Уйлыйм ки, әгәр Каргалыда үскән булсам, мин дә шул агымга ияреп киткән булыр идем, бу язучылык дигән шактый азаплы «кәсеп», бәлки, төшемә дә кермәс иде. Язасы килү теләген миндә Дәүләкән мәктәбе уятты, ә Каргалы школасында укучылар татар әдәбияты белән бөтенләй диярлек кызыксынмыйлар иде. Шуңа күрәдер инде дөньяга дистәләп врачлар, инженерлар, агрономнар биргән Каргалыдан бер әдип, бер артист, бер рәссам чыкмады. Хәлбуки сәнгатькә талантлы егетләр, кызлар бар иде, бик матур җырлаучыларны да, рәсем ясап мавыгу-

чыларны да мин үзем беләм, ләкин алар «шикле» эштән ышанычлырак һәм бәрәкәтлерәк эшне үзләренә сайладылар. Шулай да күп еллар узгач, сугыштан соң безнең сәнгать өлкәсендә, ниһаять, миңа адаш фамилия калкып чыкты: бу — композитор Ринат Еникеев. Үзенең әйтүенә караганда, аның атасы Әхмәтгәрәй Еникеев — Каргалыда туып үскән кеше. Әмма әнисе бөек Тукайга якын кардәш икән. Ихтимал, Ринатның зур музыкаль талантны әнисе ягыннан килә дә торгандыр. Ә бәлки, атасы ягыннан да юк түгелдер, ул тарафта да бит җырларга да ятканнар, көйләр дә чыгарганнар — без моны алдарак күреп тә уздык. Хәер, бу кадәресен инде Ринатның үзеннән ишетү яхшырак!

Тарихи дөреслек өчен шуны да әйтеп китү артык булмас, минемчә: әле революциягә чаклы ук яңа салынган таш школа бинасында яшь учительләр тарафыннан спектакльләр куелган, концертлар оештырылган. Революциядән соң исә, бөтен җирдәге шикелле, Каргалыда да бу эшләр аеруча җанланып китә. Бик теләп катнашып йөрүче яшьләр күп, спектакльләр, концертлар әледән-әле булып кына тора. Бер кайтуымда Каргалы спектаклен мин дә күреп киткән идем. Школаның киң, озын коридоры. Бер башына сәхнә корылган — шунда «Урал суы буенда» дигән спектакль бара. Коридорның калган өлешенә озын тар эскәмияләр тезелгән — аларда тыгызланып утырган тамашачылар. Алдагы рәтләрдә утыручылар спектакльне тыныч кына карасалар да, ишек төбендә бер дә тынычлык юк — кемнәрдер ни өчендер һаман шунда шаулаша. Шул чакта баш рольне уйнаучы егет залга: «Шауламагыз!» — дип бер кычкырып сала да аннары яңадан, һични булмагандай, үз ролен уйнап китә. Бик кызык булып тоелган иде бу миңа. Шуңа күрәдер, ахрысы, ул спектакльне мин бер дә оныта алмадым.

Шулай ук Уфаның үзендә 1908—1910 еллар тирәсендә һәвәскәрләр тарафыннан куелган спектакль һәм концертларда да Каргалыдан чыккан яшьләр шактый ук актив катнашканнар икән. Моны минем кулымдагы ефәккә басылган бер программадан ачык күрергә була: анда язылган фамилияләрнең күбесе Еникеевләр дә Терегуловлар. Шулар арасында яшь шагыйрь Сәетгәрәй Еникеев тә бар — ул скрипкада чибәр генә уйный торган булган. Бик яшьли генә үлгән авылдашым шагыйрь турында мин бу язманың башында кыскача гына әйтеп үткән идем инде.

Шул рәвешчә, Каргалы яшьләренең үзешчән сәнгатькә, гомумән, татар мәдәниятенә тартылуы азатлык җилләре

искән чакта нык кына көчәя, ләкин, җилләр исеп тынгач инде, бу энтузиазм әкренләп сүрелә һәм бетә. Аның караvы укуга, белем алуга омтылыш бик нык арта. Әлбәттә, укып белем алу, белгеч яки галим булу бик күркәм эш. Тик менә Каргалы үзе генә, мөгезен салган карт сыер шикелле, күпмедер вакытка кысыр кала. Әмма кысырлык ул мәңгелек түгел, үтә торган нәрсә — шулай юатасым килә сай инеш буенда тын гына утырган авылымны.

Илебез бик зур, кайда гына торсаң да, бер үк ватан, әмма шул чиксез ватанның тузандай бер ноктасы, карт әдип әйткәнчә, яшел бишеге — Каргалы да минем җанымда әнә шундый матур, кадерле, мәгәр томан белән өртелгән бер образ булып саклана. Ләкин «яшел бишек»-тән төшеп, кырыс дөньяга чыгып китүемә бик күп еллар узды шул инде, хәтта сагыну кебек бик табигый хис тә әкренләп сүнде, бетте диярлек. Менә туган авылымның урамыннан хыялым белән генә каранып узган булдым. Билгеле, күп нәрсәне танымадым, күп нәрсә онытылган, шул сәбәпле үткәннәрне искә төшерү белән генә чикләндем. Бабаларым гомер иткән нигез юк, мин туган йорт та юк, бала чагымда ялантәпи бәбкә үләнен таптап йөргән яландай иркен ихата үзе дә юк. Алар барсы да хәзер бары тик хәтердә генә, бары тик искә генә төшерергә мөмкин. Сирәк кенә кайткан чакларымда мин йортыбыз урынында буш яткан, чүп баскан җирне күреп, үземнең шушында тууыма ничектер ышана алмыйча китә идем.

Инде хыялда түгел, өнемдә булган эш. 1979 елның җәендә мин, Бөгелмә поезды белән Уфага барышлый, көндез Каргалы турысыннан уздым. Вагон тәрәзәсеннән китмичә карап бара торгач, авылга якынлашуымны тауларыннан белеп алдым. Атакай мәрхүмнең: «Тезелеп кенә киткән кызыл тауларым, өстегездә куян ауладым»,— дип җырлаганы ничектер искә төшеп куйды. Әйе, бу ак маңгайлы кызыл таулар мин бәләкәй чакта биек тә, мәһабәт тә кебек иде, ә хәзер вагон тәрәзәсеннән алар ничектер чүгеп тә һәм боекланып та калган шикелле күренделәр. Инде менә Каргалы үзе... Элек ул, ялгышмасам, тимер юлга бик якын иде, ә хәзер шактый ераклашкан, инеш буйлап кына таралып утырган бер авыл. Күрәсең, тимер юлга якын урамнар күчепме, китепме беткәннәр. Үзгәргән, нык үзгәргән... Каргалыкай!.. Поезд кызу узды, кирәгенчә күрергә өлгереп тә булмады. Шулай да, артка каерылып булса да, һаман авылның сирәк йортларын күреп калырга тырышып бардым.

Поезд, авылны үтеп киткәч, ерак та түгел Чәрмәсән

разъездында туктады. Вагоннардан сирәк-мирәк кенә кешеләр төште. Мин дә төштем һәм Каргалы юлына чыгып баручы олы гына яшьтәге ике хатынны туктаттым. Исәбем әзрәк сорашып, сөйләштереп алу иде.

— Сез Каргалыданмы, апайлар?

— Ийе, Каргалыдан...

Ләкин алар ашыгалар иде бугай — теләмичәрәк туктадылар. Шуңа күрә мин туп-туры гына сорадым:

— Сезнең Әхмәтҗан картны ишеткәнегез бармы?

— Кайсы Әхмәтҗанны? — диде минем соравыма каршы хатыннарның кечерәк буйлысы.

— Тәлпи Әхмәтҗанны, йорты урталыкта, мәчеткә каршы гына иде.

— Юк, белмибез, ишеткәнебез юк,— диделәр болар.

Хәер, белмәүләре гаҗәп тә түгел — бик күптән үлгән карт. Ләкин инде аның улын белергә тиешләр. (Хатыннарга илле биш-алтмыш яшьләр булыр.)

— Ә соң аның улы Нигъмәтулланы белә идегезме?

— Кайсы Нигъмәтулла тагын?

— Шул ук урталыкта яшәгән Татыра Нигъмәтулланы?

Хатыннар бер-берсенә карадылар, аз гына уйландылар, аннары башларын селектеләр:

— Юк, белмибез. Урталыкта андый Нигъмәтулла тормый.

— Хәзер тормый, ә элек тора иде.

— Ий, элеккесен кем белеп бетерсен, җаныкаем,— диде хатыннарның чандыр озыны.— Хәзер вет урталыкта мәчет тә юк, йорт та юк, сафхуз гаражлары анда.

Шулай итеп, бу авылдаш хатыннар минем бабамны гына түгел, үзләренә күпмедер замандаш булган дәдәмне дә белмиләр булып чыкты. Дөресен генә әйткәндә, моңа да артык исем китмәде. Нигә кирәк аларга дөньяда юк кешеләрне белеп тору?! Тереләрен белергә дә, бәлки, ихтыяҗлары юктыр — беткәнмени башка кайгылар?!

Инде мин алардан «Ә сез үзегез кем буласыз соң?» дип сораганны көттем, ләкин алар хатыннарга хас мондый кызыксынуны да күрсәтмәделәр.

— Ярый, апайлар, юлыгызны бүлдем,— дидем мин аларга, һәм алар үзара нидер сөйләшә-сөйләшә китеп тә бардылар.

...Тау битендәге үләннәрне селкетеп-тарап шаян гына җил исә. Ачы әрем исен китерә ул миңа — туган туфрак исен... Коры җирдә, эссе кояшта үскән ак әрем исе бик үткен була — бала чактан ук сеңеп калган бу таныш исне картайгач та бик яратам мин. Үзгәрми һәм бетми торган ис ул минем өчен!

# ДӘҮЛӘКӘН

## ДИМ БУЙЛАРЫ

Казаннан Дәүләкәнгә Бәләбәй аша да, Уфа аша да кайтып була. Бәләбәй аша шактый урау һәм мәшәкатьле: башта самолет белән Бөгелмәгә, Бөгелмәдән автобуста Бәләбәйгә, Бәләбәйдән инде поезд белән Дәүләкәнгә. Шулай да, мәшәкатенә карамастан, Бәләбәйне күрер өчен генә бу юл белән дә кайтып йөргәнем бар. Ләкин күбрәк, билгеле, Уфа аша йөрим.

Дәүләкәннән мин беренче мәртәбә ерактагы таш калага — бала чактан ук әлифба китабы белән бергә күңелгә кереп урнашкан мәшһүр Казанга 1925 елның августында чыгып киттем. Бу чакта миңа уналты яшь иде. Утыз икенче елга кадәр һәр җәйне атам йортына кайта идем. Соңгы кайтуым утыз дүртенче елның кышында булды. (Дөрес, бу вакытта инде атам-анам да Казанга күчеп килгәннәр иде.) Шуннан соң мин егерме ел Дәүләкәнемә кайтмыйча тордым. Нәкъ егерме елдан соң, ягъни илле дүртенче елдан башлап, минем өзелгән юлым яңадан ялганып китте. Һәм шушы вакыттан алып мин ике ел, өч ел саен диярлек берничә көнгә генә булса да, Дәүләкәнгә кайткалый торам. 1969 елны кайтып, шундагы иске дусишләр белән алтмыш яшем тулу бәйрәмен дә үткәреп киттем. Аннан соң да кайтып йөрүем өзелмәде һәм моннан соң да, иншалла, өзелмәс дигән өметем бар әле.

Бер уйласаң, бу сәер дә тоелырга мөмкин. Җитмеш елдан артык гомеремнең бары унбиш елы гына Дәүләкән өлешенә тия бит, калганы исә гел читтә, еракта узды. Әмма ул унбиш ел минем гомерем башы — иң саф, иң самими, иң гөнаһсыз чагым. Нәкъ шушы чакта адәм баласында хыял канатлана, мәхәббәт кабына түгелме соң?! Югыйсә җитмештән узгач та кайтып йөрү нигә кирәк икән?..

Ярты гасыр эчендә Дәүләкән халкы алышынып бетте диярлек. 1926 елны анда сигез меңнән артыграк кеше яшәгән булса, 1975 елда инде егерме меңнән дә артык киткән. Димәк, яртысыннан күбесе — мин киткәч үрчегән яки читтән килгән халык. Минем замандагы кешеләр юк, беткән яки берән-сәрән генә калган. Бик күп йортлар искерсә дә, үзгәрсә дә, миңа таныш, кемнәр торганын да яхшы беләм, әмма ләкин күптән инде ул йортларда хуҗалары гына түгел, аларның токымнары да яшәмиләр. 1969 елны туган көнемне үткәрергә кайткач, бер табынлык иске дус-ишләрне җыя алган идем, ә хәзер

анда мин белгән һәм мине белгән бары дүрт-биш кеше генә калды. Кыскасы, чын дөресен генә әйткәндә, Дәүләкән хәзер миңа үзе дә ят, халкы да ят. Кайткан чакларымда урамнары буйлап йөрим, әлеге ике-өч танышымда булам, районның берәр җитәкчесенә «визит вежливости» ясыйм, әлбәттә инде, Дим буена төшәм, үзем ишеп, ялгызым гына көймәдә йөрим, шул рәвешчә, берике көн әйләнәм-тулганам да электричкага утырып китеп тә барам. Минем бер кимчелегем бар: төрле җирләргә кереп, күренеп йөрергә, кыскасы, үземне афишировать итәргә бер дә яратмыйм. Дәүләкән яши, кайный, зур-зур эшләр башкара, ә мин анда узгынчы бер мосафир гына... Шулай булуы бик әйбәт, мин бит шомарган бакыр акчадай әйләнәм дә кайтам. Кемгә кирәк минем кайтып, күренеп йөрүләрем?.. Бары тик үземә генә... Әйе, тарта мине Дәүләкәнем, тарта, туган авылым Каргалыга караганда да ныграк тарта! Ни өчен? — үзем дә аңламыйм. Бәлки, бишектән алып үскән җирем, эчкән суым, йөргән сукмакларым шушында калганга күрәдер. Чыгып китүемә илле биш елдан артык (әйтергә генә ансат!) вакыт узуга карамастан, аның һаман онытылмыйча үзенә тартып торуын башкача ничек кенә аңлатасың?!

...Хәтерлим егерме елдан соң беренче мәртәбә кайтуымны... Июль ахыры, әллә август башы иде — Уфадан мин, тәмам караңгы капкач, Дәүләкән станциясенә килеп төштем. Якын туганнардан монда беркемебез дә юк, иске танышлардан кемнәр барын да ачык кына белмим — бу вакыт эчендә зур сугыш та үтеп китте, кешеләр язмышында нинди генә үзгәрешләр булмагандыр... Шуңа күрә мин тоттым да тимер юл каршындагы электән үк гостиница хезмәтен үтәүче бер генә катлы таш йортка юнәлдем. Барып, хәдимә хатынны уятып, үземә урын (койка) алдым. Ләкин минем ятып йокларга һич тә теләгем юк иде, кечкенә чемоданымны калдырдым да кире чыгып киттем. Инде төн уртасы якынлашадыр, Дәүләкән өстендә тулган ай, тулган айның томанлырак яктысы — миңа бик таныш ул! Мондый төннәрдә нигәдер бик ямансу була торган иде... Тукта, оныта язганмын, әле поездан төшеп, вокзал урамына чыккач та, мин бик тәмле бер хуш ис сизгән идем. Менә яңадан шул урамга килеп кергәч, бу гаҗәеп таныш һәм тансык ис бөтенләй аңкып тора башлады. Хәйран калдым — айлы төндә, Дәүләкән урамында... алма исе!.. Әнис белән антоновка исе!.. Кайдан бу?.. Нигә шулхәтле көчле аңкый ул?.. Бервакытта да алма исе болай таралганын мин һич тә хәтерләмим, чөнки бу тирәдә алма бакчалары юк — элек тә юк иде,

хәзер дә күренми алар... Дәүләкән җиләк-җимеш бакчаларына, гомумән, бик ярлы иде. Бигрәк тә татар, башкорт өлеше... Дөрес, ике бик зур алма бакчасы бар иде, шуларның берсе моннан ерак та түгел татар бае Кәримовларныкы, ләкин аның да «гүләнья» бакчасына әйләндерелгәнен ишеткән идем инде. Андый бакчада әнис алмагачлары хәзергә кадәр, ай-һай, сакланып торыр микән?! Шулай гаҗәпләнеп иснәдем мин бу хуш исне, иснәдем, ләкин кайдан таралуын артык тикшереп тормадым, чөнки алма исеннән дә кадерлерәк икенче бер нәрсәне тизрәк барып күрәсем килә иде. Вокзал урамыннан Дәүләкәннең төп урамына чыктым да югары очка таба карап киттем. Урам тып-тын, бер кеше заты юк, өйләрдә утлар күптән сүнгән, тик аларның кара күләгәләре генә җиргә ап-ачык булып яткан. Барысы да бик таныш өйләр, үткәннәрне күргәндәй, һәркайсына карап узам. Менә кирәк урынга килеп җиттем, менә каршысына туктадым — мин үскән безнең йортның дим... Егерме елдан соң менә каршысында басып торам. «Нихәл, таныйсыңмы мине?» дип дәшәсем килә... «Төн уртасында килеп йөрүем өчен гаеп итмә» диясем килә... «Түзмәдем шул, ялгыз аулакта гына күрәсем килде үзеңне!..»

Тордым шулай, тордым шикле кеше сыман аның каршысында басып, аннары теләр-теләмәс әкрен генә кузгалып киттем. Бу йортыбыз турында сүз алда күп булыр әле, тик хәзергә шуны гына әйтеп үтик: 1932 елның көзендә, Казанга күчәр алдыннан, атакай аны ниндидер бер оешмага сатып киткән иде. Күрше-тирәдә аерылыбрак торган йорт иде, чөнки ике катлы иде ул — аскысы җиргә кертебрәк, таштан, ә өске каты таза бүрәнәдән салынган иде. Һәммә җире бөтен, таза иде әле ул чакта. Ә хәзер күреп исем китте: йорт тәмам искергән, тузган, ничектер картаеп, боекланып киткән. Аскы катның штукатуры кубып беткән, өске катның бүрәнәләре арасыннан мүкләре иске бау кисәгедәй асылынып тора; урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган, парадный ишеге бөтенләй юк, аны иске такталар белән каплап ук куйганнар; урам ягындагы бакча рәшәткәсе дә юкка чыккан, үсеп утырган топольләрнең берсе дә калмаган, шунлыктандыр инде йорт үзе дә өстен салдыргандай бик ялангач күренә. Иясез малны эт җыймас, диләр иде, бу очракта бик дөрестер, ахрысы.

Билгеле, мин икенче көнне дә йортыбызны күрергә килеп җиттем. Бу юлы ишегалдына да кереп, бөтен җирен ашыкмыйча гына карап чыктым. Үзгәрешләр зур иде. Ишегалды яклап та матур гына бакчабыз бар иде — ул

юк, бакча кырында гына җәйге алачыгыбыз бар иде — ул да юк, эчтәрәк зур тәгәрмәч-чыгырлы коебыз бар иде — ул да юк. Бусы гаҗәбрәк, кое югалмаска тиеш иде; күрәсең, ишелеп төшкәндер дә күмеп куйганнардыр.

Мин инде өйнең эченә дә керергә яхшысынмадым. Өске катында ике, аскысында бер квартирант тора икән. Шулардан ике хатынны күрдем. Ишегалдында бөтенләй ят бер кешенең каранып йөрүе аларны бик гаҗәпләндерде булса кирәк, миңа үземнең кем булуымны, ни өчен килүемне аңлатырга туры килде. Шунда ук хәлемә кереп, хәтта кызганган төсле дә булып, квартирларын да күреп чыгарга чакырдылар. Нигәдер мин аларның бу яхшылыклары белән файдаланырга кыймадым. (Тышындагы үзгәрешләрне күрү дә җитәр, эчендәгесе... хыялымда сакланган килеш калсын, дидем, ахрысы.) Әзрәк сөйләшеп тә тордык, алар Дәүләкәнгә бездән соң килгән кешеләр икән, шуңа күрә безне белмиләр, аннары саубуллашып, капка сыман бер ачык урыннан чыгып киттем. Ләкин шул ук көнне фотограф ияртеп килеп, йортыбызны урам яктан гына булса да төшертеп алдым. Һәм шуннан соң гына Дәүләкәндә мин белгән кешеләрдән кемнәр барын-югын урам буенча йөреп дигәндәй ачыкларга керештем. Хәер, тагын бер нәрсә шул ук көннең иртәсендә үк ачыкланды: бу — әлеге мине хәйранга калдырган «алма» исе... Кәримовлар бакчасы дигән идем бит әле, менә шул Кәримовлар ихатасы белән янәшә, заманында ак кирпечтән салынган зур бер магазин бар иде. Һәм шушы магазинны, тагын нииндидер каралты-биналарны әйләндереп алган койма эчендә, хикмәте Хода, балалар аяк киеме тегә торган фабрика корып җибәргәннәр икән. Инде әйтсәм әйтим, әлеге борынны ярып кергән әнис исләре шул фабрикадан таралган нииндидер җилемме, лакмы исе булып чыкты!.. Белгәч, ирексездән көлеп җибәрдем. Юк, чынлап та, хуш исле фабриканың Дәүләкәндә эшләп ятуы күңелле бер сюрприз булды бит әле минем өчен...

Хуш, кай тарафтарак соң ул минем Дәүләкәнем? Башкортстанда икәнен беләсез инде, Уфа белән Бәләбәй арасында, Дим елгасының урта агымында утыра ул, Уфадан кузгалып, Агыйдел күперен чыккач та, поезд Дим буйлап китә. (Нәкъ шул күпердән чак кына өстәрәк Дим Агыйделгә килеп тә кушыла.) Тик поезд көнбатышка таба бара, ә Дим көнчыгышка карап ага. Бик матур, бик хозур урыннар. Димнең түбән агымы буе белән диярлек тоташ агачлык. Елга җәелеп үскән биек, юан тирәкләр арасыннан бормаланып ага, кайбер төшләрдә тимер юлга

якын ук килә, янәшә бара, аннары тагын карт тирәкләр ышыгына китеп югала. Тик ара-тирә генә аның куе күләгәләрдән зәңгәрләнгән өсте күренеп кала. Әнә шулай Алкино станциясен узганчы елга белән тимер юл һәркайсы үз юнәлешендә, янәшә баралар, ә Чишмәгә җитәрәк инде Дим каршы яктагы ерак сыртларга таба аерылып китә. Алда исә аның чакрымнарга җәелгән киң, тип-тигез тугае ачыла...

Минем атакай Дим елгасын Башкортстандагы иң якты елга дип әйтә торган иде. (Чөнки кояш чыгышына карап ага ул.) Чынлап та, Димнең өстендә, буеннан-буена, сыек рәшә сыманрак үзенә бер яктылык балкып тора. Моны бигрәк тә ерак сыртлар өстеннән караганда ачык күреп була. Әле дә хәтерлим, бала чакта Ташлыкүлдән кайтканда, Балкан тау итәкләрен узуга, бик ерактан ук юка гына аксыл ефәктәй нурлы томанга өртелгән Дим буйлары ачылып күренә башлый иде... Ходаем, нинди киңлек, нинди җылы-якты иркенлек! — бу күренештән күзләр генә түгел, күңелләр дә ничектер кытыкланып, җилкенеп китә торган иде.

Уфа белән Дәүләкән арасын туксан чакрым, ә Чишмәне нәкъ уртасында, диләр. (Хәер, минем чамалавыма караганда, Чишмә Уфага якынрак булырга тиеш.) Менә шул Чишмәдән чыгып киткәч тә, поездның сулъяк тәрәзәсеннән Дим үрендә күгелҗем томан эченнән бер тау күренә башлый. Бу — Ярыштау!.. Дәүләкән әнә шул тау каршысында инде. Ерактагы ялгыз тау ачылу белән мин үземне Дәүләкәнгә кайтып җиткәндәй тоя башлыйм һәм вагон тәрәзәсеннән китмичә тик шуңа карап барам (хәлбуки сәгатьтән артыграк барасы бар әле). Бу гадәтемә әйләнде дияргә ярый, чөнки Ярышның күренә башлавы минем өчен кавышу, ә күздән югалуы аерылышу билгесе ул... Чөнки Дәүләкәнгә җиткәнче Дим буенда Ярыштан башка дөнья өстенә ялгызы гына карап торган бүтән бер тау да юк. Бала чактан ук кайсы яктан гына кайтырга туры килсә дә, иң элек Ярыш ачыла, Ярыш озын юлдан ялыккан күңелләрне күтәреп җибәрә торган иде.

Ләкин шунсын да әйтергә кирәк, Дәүләкән нәкъ Ярыш каршында торса да, алар арасы шактый ук ерак әле: берсе Димнең сул ягында, ә икенчесе уң ягында, арада ике-өч чакрымга җәелгән тугай, тугай бетүгә — Көрмәнкәй тавы, һәм, шушы озын тәбәнәк тауны менеп, бер дүрт-биш чакрым киткәч кенә, Ярыштауның итәге башлана. Зур тау үзе дә ике катлы: иң элек, Димгә карап, озын сәкедәй бер тау сузыла, аннары, шул «сәке»-

нең нәкъ уртасына каплап салган казан шикелле, Ярыш үзе басып тора.

Мәһабәт, горур тау ул Ярыш! Теләсәң кай җиреннән аңа менеп тә булмый. Шулай да малай чагымда Дүртөйлегә караган ягыннан тырыша-тырыша түбәсенә менгәнем бар. Ул заманда аның турында төрле хикмәтләр дә сөйлиләр иде. Имештер, «ак патшага» каршы баш күтәргән башкортлар, Ярыш түбәсенә тупланып, шуннан карательләр отрядына каршы яман сугышканнар. Соңгы елларга чаклы анда уклар, ук башлары табыла торган булган. Аннары тауның нәкъ түбәсендә ялгыз кабер дә бар, аны нининдидер бер батыр кабере диләр — димәк, Ярыш турындагы сүзләр бөтенләй үк нигезсез булмаска тиеш. Мин үзем бер нәрсәне яхшы хәтерлим: Ярыш түбәсеннән Ачлы күл тарафындагы Балкан тавы ерактан күгәреп кенә күренеп тора иде. Аралары кимендә бер утыз-утыз биш чакрым булыр. Балкан да ялгыз тау, аның да үз легендасы бар («Зыятүләк белән Сусылу әкияте») — менә шул ике тау ике баһадир сыман бер-берсенә карап торалар да инде.

Әйе, гаҗәеп киңлек, иркенлек монда, таулар, елгалар, тугайлар, кырлар-яланнар — барсы да атлар чабып җитмәстәй булып күренә. Бер кайтуымда райкомның икенче секретаре иптәш Халиков мине үзе белән авылларга алып чыгып киткән иде. Яңа гына урып-җыю башланган чак иде. Башта бер совхозга бардык. Анда игенне шундый зур мәйданнарда үстергәннәр ки, җирнең бер башыннан төшкән комбайн икенче башына җиткәндә инде күздән югала. Исем китте шуңа... Иң әшәке юлдан да курыкмый торган «газик»та без күп җирләрне әйләндек. Иптәш Халиков белән сүзләр килешкән иде, коры, һавалы рәсмилек аңарда юк, гади, ачык күңелле, теләсә нәрсә турында рәхәтләнеп сөйләшеп була. Бер кулын сугышта өздергән, йөрәк тә таза түгел икән, ләкин яшь иде әле, дәртле кеше иде. Каргалыга да ул мине райком машинасында илтеп куйган иде. Әмма, ни кызганыч, икенче кайтуымда бу тынгысыз, авыр эштә янучы яшь кеше дөньяда юк иде инде. Чишмә районына, әнисе янына кайтып үлгән, диделәр.

Халиков минем өчен яңа кеше иде, һәм, гомумән, район оешмаларында эшләүчеләрнең бик күбесе якын-тирә авыллардан яки бөтенләй читтән килгән шундый ук яңа кешеләр иде. Дәүләкәннең үз кешеләре, һәрхәлдә, миңа танышлары, бик аз иде. Бигрәк тә җитәкчеләр арасында... Хәер, Дәүләкәннең үзеннән чыккан Зубарев фамилияле кеше дә райкомның беренче секретаре булып шак-

тый вакыт торган иде. Алтмыш яшем тулу көнен үткәргә кайткач, ул мине бик әйбәт каршы алып, кабинетында безнең белән (Казаннан Илдар Юзеев, Уфадан Вәзих Исхаков «юбиляр»ны озата килгәннәр иде) әңгәмә уздырып, кирәк кешеләргә тиешле боерыкларын биреп һәм ахырдан минем мәҗлескә килеп бераз гына утырып та киткән иде. Борис Михайловичның бу кешелекле игътибарын әле дә онытканым юк.

Билгеле инде, мин беренче нәүбәттә үземә якыннарны, үз тиңнәремне күрергә дип кайта идем. Ләкин, башта әйткәнемчә, алар да күп түгел, кемне сорама — ул юк, кайсы киткән, кайсы үлгән, кайберләре сугыштан кайтмаган... Әйе, аз табылды малай чак дуслары!

Хәзер исә шулардан бары ике генә кеше калды — Гомәр дә Әхтәм... Өченчесе Хәмит иде... Иң элек сүзем дә аның турында.

Хәмитне мин беренче кайтуымда ук эзләп таптым. Ул күптән инде Дим аръягындагы Иске Көрмәнкәйдә тора икән. Сугыштан кайткач өйләнгән, дүртме-бишме баласы бар, хатыны түгәрәк йөзле, сөйкемле, тулы гына башкорт бичәсе, Сәгыйдә исемле. Өе авыл урамының иң очында, тау итәгендә үк, аңардан соң башка өй дә юк. Шактый искергән, чалышая да төшкән, түбәсенең бер башы такта, эчкәре башы салам. Ишегалдында балчык белән сылаган читән алачыгы һәм салам япкан читән абзары бар. Башка каралтысы юк. Кыскасы, ярлырак авыл кешесенең өе-ихатасы.

Хәмит белән без бер елгы — яшьтәшләр. Ул Дәүләкән мәзине Нәбиулла абзый улы иде. Без бер урамда үстек, аларның өйләре дә бездән өстәрәк, дүрт йорт аша гына иде. Атасы Нәбиулла абзый — кара-көрән кеше, кечкенә кара сакаллы, тышкы кыяфәте белән бер дә дин әһеленә охшамаган иде. Һәм ул тормышта гади бер крестьян да иде, җәйге кызу эш өстендә чабатасын киеп, атын җигеп печәнгә дә, уракка да йөри иде. Үзенә күрә аты-туны, хуҗалыгы бар иде. Әмма төп эше, әлбәттә, мәзинлек итү, һәм халык өчен дә ул шулай — мәхәллә мәзине иде.

Ураза аенда без, малайлар, мәчет коймасы буена җыелып, аның кичке азан әйткәнен көтә идек. Ахшам тыңларга җыелу (кичке азанны шулай дип атый идек) үзе бер күңелле эш, ләкин мәзин абзыйның манарада күренгәнен көтеп алалмыйча зарыгып бетә идек. Ниһаять, башына ак чалма ураган мәзин абзый таш манара ишегеннән килеп чыга. Ләкин ул нигәдер ашыкмый әле, бераз кояш баешына карап тора, түш кесәсеннән сәгатен

чыгарып, аңа да карап ала, бары шуннан соң гына ике кулын колагына тидереп, манараны әкрен генә әйләнә-әйләнә, матур көр тавыш белән азан әйтә башлый. Без, аның тамак төбен каймак белән майлагандай көчле йомшак яңгыраган тавышын ишетүгә, дәррәү урыныбыздан кубып: «Азан әйтелде, азан әйтелде!» — дип кычкыра-кычкыра, өйләребезгә чабабыз, ә өйдә инде авыз ачар өчен табынга бөтенесе әзерләнеп куелган була торган иде.

Мәзин абзый малайларын да бик иртә эшкә җикте. (Хәмиттән башка тагын Фәрит исемле улы бар иде.) Шуңадыр, ахрысы, Хәмит эшсез йөргән урам малайлары арасында сирәк күренә иде. Безнең уеннарга да һәм төрле ямьле-ямьсез шуклыкларга да ул бер дә диярлек катнашмый иде. Аның каравы Хәмит бик зәһәр балыкчы иде, бәрәңге бакчалары су буена төшә, тагарак шикелле генә көймәләре дә бар, һәм менә иртә таңнан басмага кем төшеп утырган, аръякта кармакларын күтәреп кем йөри дисәң, мәзин малае Хәмит була торган иде. Озын җепкә тезгән ак таран, чабак, кызылканатларны да күп алып кайта иде — малайлар көнчелектән: «Ул балык догасын белә»,— дип әйтә торганнар иде... Менә шул сәбәпләр аркасында булса кирәк, миңа малай чакта Хәмит белән күп аралашырга да туры килмәде. Үзенә башка иде ул, безнең эше бушка урам таптаучы түгел иде.

Аннары тагын Дәүләкәндә иң беренче башлап тракторга утырган егет тә әнә шул Хәмит булды. Соңыннан, үзенең сөйләвенә караганда, Дәүләкән МТСына яңа гына кайткан «Фордзон» тракторына менеп утырган да һичкем өйрәтмәстән үзе белеп йөртә дә башлаган. Бәлки, әзрәк арттырадыр да Хәмит дус, әмма ничек кенә булмасын, тракторны бик тиз «иярләп» ала һәм сугышка киткәнче аның өстеннән төшми дә... Ләкин мин эзләп тапканда, ул инде Көрмәнкәй колхозында ат җигеп, төрле вак-төяк эшләрдә йөри иде. Бахыр, сугыштан бик нык яраланып кайткан. Җиң эчендә кулы булса да, ул бары тире белән сеңергә генә эләгеп тора икән. Госпитальдә врачлар кисик, дисәләр дә, Хәмит кистермәгән, менә хәзер үзе үк, ат җикәндә уң кулыма әзрәк ярдәме тия, дип куана. Сыкранмый, куана! Колхозда эшләүче фронтовикның бу куанычын аңларга була, минемчә.

Дәүләкәндә минем тагын бер якын дустым — Гомәр Зәйнуллин. Сафиулла абзый улы, безгә тагы да якынрак күршеләр — йортлары да урам аша гына иде. Кайткан саен мин иң элек Гомәргә барам, аны алып чыгып китәм, бөтен вакытымны диярлек аның белән бергә уздырам.

Ул Дәүләкәндә утырып калган иске сирәк танышларның иң якыны, үзе коммунист, район һәм өлкә газеталарына язгалап торучы, кыскасы, миңа иң кирәк кеше. Аның белән сөйләшеп йөри-йөри мин күп нәрсәләрне искә төшереп, хәтеремдә яңартам.

Көрмәнкәйдәге Хәмит дус янына да без гел Гомәр белән бергә бара идек. Күбрәк аргы якка чыгып, тугай сукмагыннан туры гына атлыйбыз, ләкин элегрәк берике тапкыр көймә белән дә бардык. Бормаланып аккан елга буйлап юл озынрак һәм агымга каршы ишүе дә авыррак, әмма аның каравы Димнең гаҗәеп матур җирләрен — текә кара яр буйлап сузылган әрәмәлекләрне, бөтен өсте ак, сары төнбоеклар белән түшәлгән тыныч култыкларны, куе таллыклар күләгәсе каплаган тар ерымнарны күреп узасың. Бөтен әйләнәдә тынлык, яктылык, болыннан чапкан печәннең хуш исе килә, атластай тыгыз якты елга бөтерелеп-уймакланып тын гына ага, ә бераз алдарак тип-тигез су өстендә кинәт сикергән балыкның сырты ялтырап кала... Көймә белән барганда Көрмәнкәй юлы әнә шундый ул.

Малай чакта әллә ни күп аралашмаган Хәмит кордашымны менә хәзер килеп белдем һәм бик тиз ияләштем үзенә. Ул гомере буе җирдән аерылмаган гап-гади авыл кешесе булып чыкты. Атасы кебек, төскә-биткә көйгән сөт касмагыдай кара-көрән, тик гәүдәгә кайтыш, үтә ябык, чандыр... Елмаеп кына сөйләшә, алгы тешләре юк, көлгәндә кызлар шикелле авызын кулы белән каплый. Хәер, тартынучан димәс идем мин аны, күргән-кичергәннәрен бер дә иренмичә сөйли, кәефе килсә, берәр озын көйгә карлыга төшкән тавышы белән сузып та җибәрә.

Тормышы да аның үтә гади, натуральный дип тә әйтергә мөмкин. Икмәк кенә колхоздан, калганы барсы да үзенеке. Балыкка йөрүне дә ташламаган икән.

Хатыны Сәгыйдә дә үзенә бик тиң килгән, чын авыл җиңгәсе, ачык, сүзгә юмарт, кунакчыл. Гәүдәгә ул Хәмиттән күп тазарак, әмма чебеш кебек ирен чын ихластан санлап, яратып тора булса кирәк — шулай сизелә.

Бервакытны шулай ашап-эчеп утырганда, Сәгыйдә Хәмитнең үз алдында ничек итеп аңа кияүгә чыгуын да сөйләп алды. Хәмит, хатынының сүзләрен җөпләгәндәй, ара-тирә көлгәләп, тыңлап кына утырды. Башта шуны әйтергә кирәк, Сәгыйдәнең беренче ире сугышта һәлак булган, аннары инәсе дә үлеп киткән, шулай итеп, атасы белән икәү генә торып калганнар. Күпмедер вакыттан соң Хәмит кайта, боларга килеп йөри башлый, Сәгыйдәнең атасы белән дуслашып китә, еш кына сөйләшеп уты-

ралар, эчкәләп тә алалар икән. Күрәсең, ялгыз солдат атай кешегә ошап киткән — көннәрдән бер көнне ул Сәгыйдәгә әйткән: «Кызым, һин, булмаһа, Хәмиткә сык!» — дигән... Сәгыйдә бераз уйлап торган да: «Юк, сыкмаем»,— дигән. «Ник?» — дип сораган атасы... Моңа каршы Сәгыйдә: «Һин дә эсәһең, ул да эсә, кәрәкмәй, сыкмаем»,— дип җавап биргән. Атай кеше шактый уйга калган. Аннары күпмедер вакыттан соң тагын иплэп кенә әйткән: «Хәмиткә сыкһаң, эсеүмде ташлаем»,— дигән. Моны ишеткәч, Сәгыйдә дә: «Ярай, уйлап карармын»,— дип әйткән... Билгеле, аның үз күңелендә дә нидер булгандыр инде, чөнки озак та үтмичә Хәмит бер килүендә боларда торып та калган.

— Шулай итеп, атаем димләүе аркаһында ошо Акъбирзин иптәшкә сыгып куйзым шул,— ди Сәгыйдә, сүзен очлап һәм Хәмитенә хәйләкәр генә күз атып.— Шөкер, ахырзан үкенергә тура килмәне, әйбәт кенә торып киттек, бына биш бала үстерәбез инде.

— Ә барлыгы унны тапты,— ди Хәмит, Сәгыйдәнең аркасыннан кагып,— молотчина минем бичә ул тарафтан, тик сабыйларыбыз гына барсы да тормады. Ату матьгерой буласы иде минем Сәгыйдәкәй!

Сәгыйдә оялуыннан бары кызарып кына куя һәм ашыгып тастымал башы белән битен сөртергә тотына.

Әнә шулай сөйләгән иде Хәмит бичәсе ничек итеп өйләнешүләрен. Гади авыл кешесе «ярату» сүзен, гадәттә, кулланырга яратмый, әмма ләкин ничегрәк итеп сөйләүләреннән алар арасындагы мәхәббәт хисен, һәрхәлдә, сизеп була. Аннары Хәмитнең сүз ахырында гына бичәсе белән мактанып куюы да яратышып торуының ачык бер дәлиле түгелмени?!

Моның кебек иркен, табигый сөйләшүләр алар өендә гадәткә кереп киткән иде инде. Дөрес, беренче мәртәбә барып чыккач, Хәмит бик гаҗәпләнеп, аптырап калды, хәтта азрак ятсынды да шикелле... Үзенең авыл очындагы иске генә өйдә гап-гади «мужик» булып яшәве өчен Казаннан кайткан язучы алдында, бәлки, беркадәр уңайсызлану да кичергәндер. Ләкин бу нәрсәләр барсы да бик тиз таралды, бетте, чөнки без бер урамда үскән күрше малайлары, һәм шушы нәрсә менә егерме биш елдан соң безне тагын якынайтты да куйды.

Килгән саен безне бу өйдә бик теләп, куанып каршы алалар, хәзинәдә бары белән чын ихластан сыйлыйлар. (Билгеле, без үзебез дә буш кул белән килмибез.) Хәмит шунда ук берәр тавыкны чалып, Сәгыйдәсенә тоттыра. Сәгыйдә ашка чаклы чәй өлгертә, Хәмитнең тотып кайт-

кан балыгы булса, шуны таба тутырып кыздырып китерә... Әмма әйтсәм әйтим сезгә, Казан балыкчылары, Дим балыгы кебек тәмле балыкны сез хәзер төшегездә дә күрә алмыйсыз. Бернинди хлор, нефть исе-тәме кермәгән чын, саф балыкны мин дә күптән оныткан идем инде. Гаҗәеп икән ул, ашап кына туйгысыз икән! Димдә генә сакланса кирәк мондый «патша заманыннан» калган балык, чөнки Димне хәзерге көндә Башкортстанның пычранмаган иң чиста елгасы диләр (һәрхәлдә, югары һәм урта агымы). Хәмит көлеп сөйли, безнең бу тирәгә дә килеп, нефть эзләп йөрделәр, бөтен балыкчылар, таба алмасалар гына ярар иде, дип эчләреннән теләп тордылар, ди. Нишлисең, балык белән балыкчының хәлен аңларга була!

Тик менә кымыз белән генә эшләр шәптән түгел икән, ә мин аны бик сагынып кайткан идем. Дөрес, Уфада әзрәк эчкәләргә туры килде, ләкин Дәүләкәндә кымыз юк — базарында да, ресторанында да... Һәм бу гаҗәп иде, чөнки Дим буе элек һәрвакытта үзенең кымызы белән дан тотып килде. Һәрбер башкорт авылында һәр йортта диярлек бия бәйлиләр, кымыз ясый торганнар иде. Көрмәнкәйне инде әйткән дә юк, аның бичәләре, Арча хатыннары Казанга катык ташыган шикелле, Дәүләкәнгә кымызны китереп кенә торалар иде. Шулай ук бу авылда һәр җәен Уфа, Казаннардан килгән кымызчылар да күп була иде. (Гомумән, бу тирәдәге авылларга — Шәрипкә, Казанголга, Япарга — җәй саен кымызчылар килмичә калмый иде.) Дәүләкәннең үзендә дә бия бәйләүче, кымыз ясаучы башкортлар бар иде, шуларның берсе, безгә йорт аша гына күрше, Арыслангәрәй агай ел да бия бәйләп, кымызчы да кертә торган иде.

Кымызны ул заманда сайлап эчә идек. Нинди авылдан, кайсы агайның яки җиңгәйнең кымызы бу — тәҗрибәле кешеләр шуны иң элек белергә тырышалар. Үзенә күрә хикмәте булгандыр инде. Уфадан киткәндә, Сәгыйть мәрхүм миңа, гадәтенчә шаяртып: «Син, Әмирхан дус, Дәүләкәнгә кайткач, кымызның председательгә дип калдырганын сорап эч, аларга һәрвакытта бары яхшысын гына калдыралар»,— дигән иде. Яхшы кымыз, мәсәлән, кылганда йөргән биядән була, диләр. Савып алгач, бия сөтен гөбедә күпме пешеләүнең дә әһәмияте бар, диләр. Яхшы кымыз артык кырку да, бик төче дә булмый, эчкәч, тамак төбендә каймагы утырып кала, кикергәндә әчесе борынны тәмле генә ярып чыга. Күп еллар узса да, әнә шулай сакланган хәтердә яхшы кымыз... Безнең үзебезгә аны бер агай Акколайдан китерә торган иде. Әйе,

кайчандыр элек күп иде кымыз, ләкин, ничаклы күп булса да, ул иң тансык эчемлек һәм кадерле сый булып санала иде.

Ә хәзер юк, беткән... Бер яктан, бу хәлне аңларга да була. Билгеле ки, үткән сугышның коточкыч авырлыгы атларга да килде. (...Ниләр генә күрмәй ир башы менән ат башы, дип җырлый башкорт үзе дә.) Авылларда ат көче җитмәгәч, үгезләрне, хәтта сыерларны эшкә җиктеләр. Ә савым бияне авыр эшкә җигәргә ярамый бит, шулай булгач, кымызның бетеп, онытылып торуы гаҗәпмени?!

Ләкин мин кайтып йөри башлаган чакларда, кымыз булырга тиеш иде инде (сугыш бетүгә дә ун еллап вакыт узды), кайбер авылларда бар, ясыйлар икән дип тә ишеткән идем, әмма стаканны яртылаш ак күбек белән тутырып, эчеп кенә җибәрергә туры килгәне юк әле...

Шулай да мин нәфесне котыртып торган бу салкын кымызга бер баттым батуын. Икенче кайтуымда булса кирәк, без Гомәр белән икәү көймәдә генә тагын Көрмәнкәйгә Хәмитне күрергә бардык. Гадәттәгечә, Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә безне бик җылы-якты каршы алдылар. Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашканнан соң, тиз генә самовар да куелды, учак та ягылды, ә Хәмит, сезгә кымыз алып килим әле, дип, ашыга-ашыга ферма өенә китеп барды. Шактый ук югалып торды хуҗабыз, әмма бик борчылып, буш кул белән кайтып керде. Кемдер инде, ферма мөдиреме, завхоз тиешле кешеме, Хәмиткә кырт кисеп: «Прсидәтел рөхсәтеннән башка бер шишә дә бирмим!» — дигән. Шуннан Хәмит председательне эзләп киткән — таба алмаган, яңадан әлеге кешегә килеп, төрлечә әйтеп, ялварып караган, әмма юк, һич кенә дә тегене күндерә алмаган... «Еракта кайткан кунагым өчен дип ялвардым үзенә,— ди Хәмит, үрсәләнеп.— Тыңламады бит, мөртәт, тотып ватасыңмыни ул сабаканы!» Ярый, хәерле булсын, дидек без Хәмитне юатып, эчмәгән кымыз түгел, монда болай да сыең җитәрлек! (Хәлбуки инвалид колхозчының шушындый чакта үз колхозыннан бер шешә кымыз да сорап алалмавы, әлбәттә, аянычлы хәл иде. Тыштан сиздермәсәк тә, моңа безнең дә кәефебез кырылды.) Шуннан соң юмарт күңелле хуҗаларыбызның чәен эчтек, мәен дә эчтек, изү чишеп, тирләп ашларын ашадык. Аннары кырга чыгып йөрдек, Көрмәнкәй тавына менеп, Дим буйларына карап утырдык. Көрмәнкәй тавының исеме бар икән — элек мин моны белми идем: Иван-сәй тавы, имеш! «Ни өчен мондый сәер исем?» — дип сорагач, Хәмит болай аңлатты:

кайчандыр борын башкортлар шушы тау башында килешеп, күпмедер җирләрен русларга чәйгә алмашып биргәннәр, янәсе. Чынмы, ялганмы — Хода белсен, әмма Иван-сәй тавының икенче ягында, Димнең бик матур борылып килгән җирендә, кечкенә генә рус авылы әле дә бар, күренеп үк тора. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә: башкортлар элек читтән килгән халыкларга зур су буйларындагы җирләрен сатмаганнар һәм бирмәгәннәр. Мәсәлән, Димнең урта агымында бер татар авылы да юк, барсы да читтә, ләкин рус авыллары сирәк кенә булса да очрый. Ихтимал, алар Столыпин вакытында килеп, утырып калганнардыр...

...Кояш шактый авышкач, без көймәбезгә утырып, агым түбәненә җиңел генә ишә-ишә, әйләнә-юньдәге хозурлыкка сокланып карый-карый, Дәүләкәнебезгә кайтып киттек. Икенче көнне якшәмбе иде — базар көн икән. (Элек базар сишәмбе көнне була торган иде.) Онытмас борын шуны әйтим: бу кайтуымда инде мин яңа гостиницага төшкән идем. Шул ук базар мәйданы янында ук (дөресрәге, элекке Марҗа базары[1] каршысында гына) ак кирпечтән салынган ике катлы озынча йорт, ике катында да тезелеп киткән номерлар, арада мөһимрәк кунаклар өчен бер урынлысы да бар — менә миңа да шундыен биргәннәр иде. Иртән торып, якындагы ашханәгә кереп, тамак ялгап чыккач, мин базарны да бер әйләнергә булдым. Хәзерге базар ул элекке зур мәйданның урта бер җирен койма белән әйләндереп алган иркен генә урын — шунда кибетләр, лареклар, ике озын гына такта лапас, берсендә ит-май, икенчесендә катыксөт саталар. Нэп заманындагы базарлар турында сүз булачак әле, ә бүгенге базар шактый ярлы-сүлпән иде, тирә-як авыллардан килгән халык та аз, алар китергән азык-төлек тә күп түгел иде. Һәм, әлбәттә, кымызның да исе дә юк иде... (Көрмәнкәй бичәләре дә хәзер кымыз урынына, көянтә башына элеп, бирегә сөт-катык кына китерәләр икән.) Кыскасы, базарны мин бик тиз әйләнеп чыктым. Шуннан нишләргә?.. Кайткан саен бер эшем — ул да булса Дәүләкән урамнарында таныш йортларны карап, үткәннәрне искә төшереп йөрү иде. Бүген дә менә шул гадәтемә буйсынып, тимер юл яръягына чыгып йөрергә булдым.

Тимер юл Дәүләкәнне урталай кисеп уза. Дим агымына карап әйткәндә, юлның уң ягында кайчандыр баш-

[1] «Марҗа базары» дип төрле яшелчәләр белән сату итә торган урынны атыйлар иде.— *Ә.Е.*

корт, татар, рус торса, сул ягында күбрәк немецлар тора иде. (Башкорт юк, татар бик аз, руслар да күп түгел.) Шуңа күрә ул якны, без үскән чакларда, «Нимич ягы» дип йөртәләр иде. Ул якта таза, матур йортлар, матур бакчалар күп иде,— хәер, Дәүләкәннең үткәне турында миңа сөйләргә туры киләчәк әле. Бүген исә мин тимер юллар аша атлый-атлый шул якка — «Нимич ягы»на чыгып киттем... Чыккач та анда, юлларга каршы, немецлардан калган беркатлы таш йортта райком бинасы. Кинәт уема килде, туктале, мин әйтәм, кереп чыгыйм, секретарьлардан берәрсен очратып булмасмы?.. Урам ишектән кердем, эчкәре уздым, тынлык, берәү дә юк кебек, ләкин бар икән — беренче секретарьның алгы бүлмәсендә бер кыз бала машинкасын әкрен генә тыкылдатып утыра. «Хуҗа үзе мондамы?» — дип сорадым. «Монда»,— диде кыз. «Керергә рөхсәтме?» Кыз мине белә иде инде. Шулай да ул башта үзе кабинетка кереп чыкты, аннары миңа рөхсәт итте.

Ул елларда, ягъни илленче елларның ахырында, алтмышынчы елларның башында Дәүләкәннең беренче секретаре таза, киң җилкәле, ир уртасы кеше — иптәш Тартыков иде. (Соңыннан аны Уфага авыл хуҗалыгы министры итеп күчергәннәр дип ишеттем.) Иптәш Тартыков безнең Татарстанда да күпмедер торып, эшләп киткән кеше икән. Ул мине әйбәт каршы алган иде. Бу юлы да ачык йөз күрсәтте, урыныннан торып кул да бирде. Утырдык, сөйләшеп киттек. Сүз башы итеп дигәндәй, мин иптәш Тартыковның якшәмбе көнне дә райкомга килеп утыруына бераз гаҗәпләнү белдердем.

— Нишлисең, өйрәнелгән, гадәткә кергән,— диде ул, ике кулын җәеп.— Срочный эш булмаганда, бөтен аппаратка ял бирәм, ә үзем менә өйдә утыра алмыйм, киләм шушында — аулакка!..

Шулай башланып китте безнең әңгәмә. Сүз нәрсә турында? Билгеле инде, беренче секретарь белән перспектива — киләчәк турында. Иптәш Тартыков менә шул хакта бик мавыктыргыч итеп сөйләгән иде. Күп еллар узганнан соң мин аның сөйләгәннәрен хәзер инде искә төшерә алмыйм, ләкин шулай да ике моменты ничектер хәтердә сакланып калган. Берсе — тугайларны сөреп, кукуруз чәчү мәсьәләсе иде. Мин, бераз килешмичәрәк, тугайлар печән бирә бит, элек Дим буйлары печән чүмәләләре белән чуп-чуар була торган иде, дигәч, ул көлемсерәп, балага аңлаткандай, тугайда печән уңышы бик түбән булуын, кукурузның ике-өч мәртәбә күбрәк уңыш бирүен төшендерде. Билгеле, мин аңа ышандым,

чөнки бу кукуруз «һөҗүме» башланган еллар иде, аннары бөтен ил күләмендә җәелгән «һөҗүм»нең инициаторы кем икәнлеге дә миңа бик мәгълүм иде.

Икенчесе — Дәүләкәннең үзе турында сөйләгәндә, иптәш Тартыков якын киләчәктә тугызар катлы йортлар салыначагын әйтте. Моңа да мин шактый гаҗәпләндем, Дәүләкән кебек кечкенә шәһәргә андый биек йортлар нигә кирәк икән дип уйладым. (Уфаның үзендә дә тугызар катлылар ул чакта яңа гына салына башлаган иде.) Ләкин күңелемдәге шигемне әйтеп тормадым. Хикмәте бардыр, җитәкчеләр белмичә эшләмиләрдер, дидем, эчемнән генә, хәтта әле Дим өстенә карап тезелгән биек йортлар Дәүләкәнне бик матурлар дип сөенеп тә куйдым.

Минем яхшымы-начармы бер гадәтем бар, җитәкче кеше янына керсәм, вакытын күп алмыйм дип борчыла башлыйм. Менә хәзер дә мин сүземне чикләп, рәхмәтемне әйтеп кузгалырга булдым. Иптәш Тартыков та артык кыстамады, ләкин кайчанрак китүем белән кызыксынды, тагын шулай кергәләргә кушты. Шул чакта, инде урыннарыбыздан торгач, минем ничектер тәвәккәлләп беренче секретарьга әйтәсем килде:

— Сез гаеп итмәгез инде,— дидем,— мин әле бернәрсәгә аптырап торам.

— Әйтегез, нәрсә икән ул?

— Әллә ни зур нәрсә түгел, ләкин шулай да...— дидем мин, әз генә икеләнеп.— Эш шунда, Казанга кайткач, якын дуслар миннән: «Дим кымызын эчтеңме?» — дип сораячаклар. Эчтем дисәм, ялганлау була, эчмәдем дисәм, ышанмаячаклар.

— Әлбәттә, ышанмаслар!

— Ләкин юк бит... Дәүләкәндә кымыз юк. Хәтта Көрмәнкәйдә дә булмады.

— Ник булмасын, бар, табабыз аны! — диде иптәш Тартыков, катгый рәвештә, һәм шунда ук телефон трубкасын алды.— Кем бу? Синме?.. Давай, тиз генә монда кил әле... Бер эш бар.

Озак та үтмәде — озын буйлы бер егет кабинетка килеп тә керде. Бу райкомның өченче секретаре икән.

— Гараждан машинаны алып чык,— диде Тартыков аңа.— Менә иптәш Еникеевне утырт та Көрмәнкәйгә сыздыр. Безобразие, безгә кунакка кайтып, кымыз да эчми китсә, ояты кемгә?! Абдуллиннан кәрзине белән алып бир!

— Була ул! — диде озын егет, өлгер генә.

Шулай итеп, мәсьәлә бик оператив хәл ителде, һәм миңа кабатлап рәхмәт әйтүдән башка эш тә калмады. Ә бер биш-ун минуттан без киндер түбәле «газик» маши-

насында Көрмәнкәйгә китеп тә бардык. Элек, мин малай чакта, Дим күпере Якорь буасыннан аз гына түбәнрәк иде, ә хәзер шактый еракка күчкән икән. Шул сәбәпле күп кенә җир әйләнеп, урап барырга туры килде. Көрмәнкәйгә җиткәч, машина туп-туры выжлатып авыл читендәге ялгыз кымыз өенә барып туктады. Егет машинадан төшүгә, өйдән эшләпәле бер агай килеп чыкты.

— Әзер кымызың бармы? — дип сорады егет аңардан, бернинди кереш сүзсез.

Агай каушабрак калды:

— Ни бит, кем иптәш, прсидәтелдән башка...

— Әйдәле! — диде егет, аның сүзен бүлеп, һәм беләгеннән тотып, өйгә алып кереп тә китте. Мин мыштым гына үз урынымда утырып калдым.

Өч минут та үтмәгәндер, агай бер кәрзин кымызны көчәнә-көчәнә күтәреп чыкты да машинаның йомшак урындыгына әйбәтләп кенә куйды.

— Булды бу,— диде егет, рульгә утырып һәм, борыла төшеп, миннән сорады: — Инде кая, Дәүләкәнгәме?

— Юк,— дидем мин,— монда минем бер дустым бар, шуңа илтегез.

— Кем ул?

— Хәмит Акбердин.

— Өен беләсезме?

— Беләм.

— Киттек алайса!

Һәм күз ачып йомганчы Көрмәнкәйнең тип-тигез урамыннан Хәмит өенә барып та җиттек. Әйтәсе дә түгел, егет «газик» машинасын авыллар арасында виртуозларча йөртергә тәмам өйрәнеп беткән икән. Иң мөһиме — шома йөртә, бәла-казасыз, һәм мине дә туп урынына чөеп азапламады. Кымызны да кәрзине белән егет үзе өйгә кертте. Хәмит ишегалдында йөри иде, бу хәлне күреп ул да шактый аптырап калды.

— Ничек булды әле бу?

— Булды инде,— мин әйтәм,— синең белән миңа райком күчтәнәче, беләсең килсә!

Егет шунда ук кире китмәкче иде, ләкин без аны җибәрмәдек. Кәрзиндә егерме шешә кымыз, ничек эчеп бетермәк кирәк?! Җыйнаулашып өйнең түр ягына кердек, утырыштык. Хәмит стаканнар китереп куйды, һәм без сагындырган тансык кымызны (һәрхәлдә, минем өчен) тәмләп кенә эчә дә башладык. Кымыз әле яшь иде, шуңа күрә сүс бау белән бәйләгән бөкесен чишеп ачканда, кинәт котырып китеп атып маташмады, бары тик җәһәт кенә күтәрелеп, күбекләнеп, күпереп кенә стаканнарга тулды.

Әмма яшь булса да, эчәр өчен өлгергән иде инде. Әчкелтемрәк куәте борынны да ярып чыкты, ә каймагы тамак төбенә дә ягылып калды. Агиш мәрхүм әйтмешли, председательнең үзенә диебрәк әзерләнгән булса кирәк.

...Беренче стаканнардан ук һәйбәт кымыз кузгаткан, инде онытыла да язган үткәннәрне искә төшерә башладык. Бар иде заманнар, бу авылның һәр йортында диярлек бия бәйлиләр иде. Көрмәнкәй бит ул, тимер юлга якын булганга күрә, һәр җәен кымызчылар килеп тула торган шактый ук мәшһүр бер авыл иде. Килгән бер кымызчы хәллерәк башкортның өен яки келәтен алып, ак киез җәйгән сәке өстендә мендәргә кырын таянып, көн саен хуҗаның кымызын эчә, алачыкта җиңгә пешергән яшь тәкә итен ашый, көн дә сөтен, маен, йомыркасын алып тора — кыскасы, пансионаттагы шикелле, бөтенесе бар, бөтенесе бер генә хуҗадан (бәлки, чәйшикәрдән башкасы). Шул рәвешчә, берәр ай хушланып, тазарып ятканнан соң кымызчы әфәнде хуҗага барсы өчен дә тиешле акчасын түләп, китеп бара һәм еш кына алдагы җәйдә дә шул ук йортка яңадан килә торган иде...

Минем истә әле: монда бер җәйне Нәгыймә Таҗдарова белән Нури Сакаев, Маһира Мирвәлиева белән Шакир Шамильский кымыз эчеп яттылар. Шулай ук матур җәйләрнең берсендә Казаннан Галимҗан Нигъмәти һәм Гомәр Гали дә хатыннары белән бирегә килгәннәр иде... Тагын бер онытылмас истәлек: 1924 елның җәендә булса кирәк, Көрмәнкәйдә Мәҗит Гафури, ә Иске Шәриптә минем җизни Шәриф Сүнчәләй белән аның энесе Сәгыйть Сүнчәләй кымызда булдылар. Һәр атнада диярлек алар Дәүләкән базары көнне кирәк-яракларын алыр өчен безгә киләләр иде. Көрмәнкәйдән Мәҗит агай да, билгеле, килеп җитә иде... Әле дә бик ачык хәтеремдә: таяк тоткан юка гына гәүдәле, ак чырайлы, кечкенә кара мыеклы Мәҗит агай, аксый биребрәк, безнең капкадан ук: «Сәгыйть!» — дип тавыш салып килеп керә торган иде. Тавышын ишетүгә, өйдән йә җизни, йә Сәгыйть абый чыгып аны каршы алалар иде. Минем әдәбият белән «җенләнә» башлаган чагым, шуңадыр инде Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй кебек танылган шагыйрьләрнең безнең өйдә булуы яки кереп кенә чыгулары да минем өчен, билгеле, зур бер куанычлы вакыййга булып кала иде[1].

---

[1] Быел Уфага баргач, Йосыф абзый Гәрәйдән ишеттем: бер җәйне Сәгыйть Рәмиев тә Көрмәнкәйдә кымыз эчеп яткан һәм шул чагында үзенең «Авыл» исемле мәшһүр шигырен язган икән. Хәтерлисезме:

«Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш...» — *Ә.Е.*

Әнә шулай күңелле истәлекләргә бирелеп, тәмләп кенә дүрт-биш шешәне бушатканнан соң, райком егетенә рәхмәтебезне әйтеп, аны озатып җибәрдек. Мин исә, кымызны эчеп бетерер өчен, Хәмиттә калдым. Бу дуамал эчемлек юлда селкетеп йөрткәнне бер дә яратмый, аннары җәй кызуында аны озак сакларга да ярамый. Сәгыйдә килен бер унлап шешәне шунда ук кар базына да төшереп куйды. Ә калган өч-дүрт шешәне алып, без Хәмит белән, Сәгыйдәнең ашы өлгергәнче, Дим аръягына чыгып килергә булдык. Аръяктагы тугайда, нәкъ Көрмәнкәй каршысында, Япраклы дигән зур гына күл бар — кайчандыр без, Дәүләкән малайлары, еш кына шул күлгә балыкка килә торган идек. Минем инде Япраклыда булмавыма, юләр әйтмешли, бер кырык ел бардыр — менә шуның ярында малай чактагы шикелле кармак салып утырасым килеп китте. Моның өчен бөтен кирәк нәрсә Хәмиттә бар, абзар артындагы черегән тиреслектән калай савытка бераз суалчан казып алдык та аның буялмаган иске генә көймәсендә аръякка чыгып та киттек. Тугайның әле чабылмаган куе үләнен ерып, күл буена бардык, таллар ышыгыннан әйбәт кенә тыныч урын табып, кармакларны сүтеп, бисмилланы әйтеп дигәндәй, безне зарыгып көткән балыкларны ялыктырмас өчен, тизрәк эшкә дә керештек. Ләкин, ни хикмәттер, балыклар безнең кармакларга ташланырга ашыкмадылар. Моның сәбәбен Хәмит шунда ук әйтеп тә бирде: хәзер нәкъ көн үзәге, балыкларның көн кызуыннан ялкауланып, тик кенә «ята» торган чаклары, диде. Шулай да ул үзе ничектер, ниндидер хәйләсен белеп, чибәр-чибәр генә кызылканатларны тартып чыгаргалады. Гаҗәп, утырган җиреннән кузгалып та тормыйча, эләккән балыгын ике тез арасына ашыкмыйча чыгарып кына сала! Балык та, канәгать кебек, артык тыпырчынмый да.

Әмма минем осталык та, сабырлык та җитмәде — баштарак калкавычтан күземне алмыйча утырсам да, һәм берничә тапкыр кармакны кинәт күтәреп җибәрсәм дә, балык үзе җимне ашап су төбендә кала бирде. Көлә белә микән ул минемише балыкчыдан?! Аннары мин, онытылып китеп, кармактан бигрәк, күл әйләнәсен ешрак күзәтеп утырдым. Кырык ел аз вакыт түгел, бу вакыт эчендә Япраклы да күпмедер үзгәрергә тиеш иде кебек. Без, Дәүләкән малайлары, мәсәлән, балык тотарга күлнең әнә каршы ягына килә торган идек. Ул якның кара яр буйлары ачык, таллыклар, куе камышлыклар юк диярлек, йөреп-сайлап утырыр урыннар күп иде. Ә хәзер без утырган бу ягында әрәмәлек тә таллык, су читен ләм

һәм төнбоек баскан була иде, кармак салыр өчен ипле урын табуы да бик читен иде. Ләкин Япраклы хәзер дә шул ук Япраклы икән, бернинди үзгәреш күрмим диярлек. Хәер, ничәмә йөз еллар яшәгән күл өчен кырык ел нәрсә ул, кеше кулы тимәгәч, торган сакланып... Кырык ел гомер безне генә танымаслык дәрәҗәдә үзгәртеп бетерде. Бер уйласаң, кызганыч та инде без, кайчан гына әле яланаяк, күлмәк-ыштаннан гына шушы күл әйләнәсендә кармак күтәреп йөрүче малайлар идек, ә хәзер? Юк, кыска, бик кыска адәми затның гомере! Әмма шушы кыска гына гомерле адәмнең кодрәте чамадан ашты — мең ел гына түгел, миллион еллар сакланып килгән табигатьне соңгы егерме-утыз ел эчендә генә дә ничаклы үзгәртеп, бозып бетерде. Һәм бу үзгәрешләр Япраклы күлнең тирә-ягында да бар. Әнә, каршы яктагы киң тугайны аркылы бүлеп, дамба сузганнар... Ни өчен, нинди максат белән? Ишетүемә караганда, кайчандыр Дәүләкәннән Стәрлетамакка юл салырга уйлаганнар һәм бу дамбаны шуның өчен күтәргән булганнар. Ләкин соңыннан юл үткәрүне бу төштә кирәксез табып, эшне туктатканнар. Ә дамба калган, хәзер ул, оборона ныгытмасы шикелле, бөтен тугайны ямьсезләп, күпме печән бирә торган болынны алып тора. Яки әнә Көрмәнкәй яклап Дәүләкән каршысындагы тугайда урман үстергәннәр. Бәлки, кирәктер, файдагадыр бу урман? — белмим, әйтә алмыйм. Әмма болынлык мәйданы бик нык кимеп калган. Кыскасы, үзгәреш бар, бөтен җирдә бар ул. Тик, кызганычка каршы, кеше дигәнең, гомере кыска булганлыктан, табигатьне үз кулы белән үзгәртүнең бөтен нәтиҗәсен генә яхшылап күрергә өлгерми — ул кадәресен инде шулай ук кыска гомерле балаларына уйларга һәм аңларга калдыра: кирәк булганмы бу, әллә юкмы?.. Гафу итегез, балык чиртмәгәч ниләр генә килми күңелгә!

...Ә шулай да эссе-бөркү, кояш каршыбызга борылды, кыздыра, мин яңадан таллар ышыгына күчебрәк утырдым. Юеш комга утырткан шешәне алып, әледән-әле кымызны эчәм, Хәмиткә дә салып бирәм, ләкин ул һаман: «Үзең эч!» — ди, күбрәк миңа тисен ди торгандыр инде. Шулай кысташып, әкрен генә сөйләшкәләп, бер-ике сәгать чамасы утыргач, балыкчым да урыныннан торды:

— Бер табалык булды, кузгалсак та ярый,— диде ул, кармагын урый башлап.— Сәгыйдәнең дә ашы өлгергәндер.

Мин дә, торып, кармагымны урадым. Хәмит нечкә талчыбыктан шеш ясап, балыкларын шуңа тезде. Ахырда кузгалдык. «Хуш, Япраклым, хуш! Тагын килеп, яр-

ларыңда утырырга язсын!» — дидем мин, эчемнән генә һәм кулымдагы ипи кисәген угалап, өстә генә йөзгән вак балыкларга ташладым.

Без кайтканда, Сәгыйдәнең ашы өлгергән, өстәлгә табын әзерләнгән иде. Ничә сынаганым бар: аның кулы аш-суга һәрвакытта юмарт, барсын да бик мул әзерли, үзе пешергән бодай икмәген дә зур телемнәр итеп ашъяулык уртасына өеп куя... Хәмит бер яртысын да чыгарды, аш хөрмәтенә берәр генә стопка күтәрдек. Шулай матур гына сыйланып һәм кунып, икенче көнне мин, һаман әле эчелеп бетмәгән өч-дүрт шешә кымызны алып, Дәүләкәнгә кайтып киттем. Бер тәүлек эчендә бер кәрзин кымызны бетереп карале — әйтергә генә ансат бу! Шуңа күрә дә онытылмас бер вакыйга булып калды ул минем өчен. Чөнки соңыннан күпме кайтып йөрсәм дә, миңа инде андый муллыкны яңадан күрергә туры килмәде. Аннары Көрмәнкәйдә кымыз ясау бетерелгән, бу эшне тагы да арырак — Дүртөйлегә күчергәннәр дип ишеттем. Кыскасы, Дим буеның мәшһүр кымызын сагынып сөйләргә генә калды.

Шулай да сүз бик озынга китте, тизрәк башкасына күчәсе иде. Әмма нишлим, Хәмит дустымнан һаман да аерыла алмыйм әле мин. Күңелдә онытылмый ятканны әйтеп бетерергә кирәктер инде. Әйе, мин кайткан саен аның белән очрашмыйча китми идем. Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә бик гади, бик садә кешеләр. Бернинди ясалмалык, кыланчыклык, хәйләкәрлек юк аларда... Көн итүләре дә саф авылча — икесе дә колхоз эшенә йөриләр, шуннан килгән белән генә яшиләр. Күзгә күренерлек байлыклары юк, әмма тамаклары тук — бәрәңгесе, сөтемае, кош-корты үзләренеке, барына канәгать булып, балачага үстереп, тыныч-тату гына тора бирәләр. Ничә кайтсам да, тормышлары һаман искечә, тик үзләре әкрен генә олыгая, балалары үсә бара, кайберләре инде читкә укырга китәргә дә өлгергәннәр иде.

1969 елның март башында Дәүләкәнгә туган көнемне үткәрергә кайткач, мин, билгеле, Көрмәнкәйдән Хәмит белән Сәгыйдәне дә мәҗлесемә чакырткан идем. Ресторан залында оештырылган менә шул мәҗлескә алар миңа күчтәнәч итеп бербөтен каз күтәреп килгәннәр иде. Казанга чаклы ук алып кайттым мин ул бердәнбер кадерле күчтәнәчне!

Соңгы очрашуыбыз, ялгышмасам, 1975 елны булды шикелле. Бу явымсыз бик коры җәй иде. Үләннәр кибеп бетте, малга азык юк, сарыклар җир кимерә, дип сөйләгәннәре хәтердә. Башта мин Бөгелмә аша Туйма-

зыга бардым. Туймазыдан якын туганым Ләләнең «Жигули» машинасы мине Бүздәк аша Дәүләкәнгә илтте. Бу юлны үзем сайлаган булдым, чөнки Бүздәкне дә күреп, Ачылы күл яныннан да узасым килгән иде. Туймазы — Уфа юлы бик шәп, киң, тигез асфальт, йөзеп кенә барасың. Әмма Бүздәктән Дәүләкәнгә борылгач, алтмыш километр чамасы юл бик алама булып чыкты. Юл шулхәтле ватык һәм тузанлы иде, әгәр каршыдан берәр машина үтеп китсә, соры калын болыт эченә чумгандай була идек. Барып җиткәч, чишенеп, өскә утырган тузанны бәрә-суга кагарга туры килде.

Бер-ике көннән без Гомәр дустым белән, күчтәнәчкә гастрономнан ансын-монсын алып, Хәмитне күрер өчен, җәяүләп кенә Көрмәнкәйгә киттек. Шулай ук эссе көн иде, җирдән дә кипкән үлән һәм кызган туфрак исе аңкып тора иде. Быелгы җәйнең болай коры килүенә борчылып сөйләшә-сөйләшә бара торгач, Көрмәнкәй очына килеп тә җиткәнбез.

...Сәгыйдә безне күптәнге дуслар итеп ачык йөз белән каршы алды, ләкин Хәмит үзе өйдә юк иде — күршедәге Дүртөйлегә киткән булган. (Колхоз идарәсен шунда күчергәннәр икән.) Хатыны өйгә керергә кыстаса да, без тышта, койма буендагы биек, куе агач күләгәсенә утырып, Хәмитне көтәргә булдык. Сәгыйдә шунда ук самоварын да куймакчы иде дә, тик без аңа бераз сабыр итәргә куштык. Шулай да Сәгыйдә борчыла һәм борчылуын яшереп тә тормый: «Эсеп кенә йөремәһә ярар ине»,— ди.

— Ә нишләп ул эчеп йөрергә тиеш әле? — дип сорыйбыз.

— Бында бөтәһе лә эсәләр,— ди Сәгыйдә.— Үткән байрам көнендә эсә башлаганнар иде, әле дә туктаганнары юк.

Ләкин без Сәгыйдәне тынычландырырга тырышабыз, Хәмит алай йөрмәс, ул инде яшь кеше түгел, дибез. Хатын үзе дә килешкәндәй була, кеше котыртмаса, үз башына эчеп йөрми иде, ди, тик шулай да Көрмәнкәй кешеләренең бер эчә башласалар туктый белмәүләреннән зарлана. Сүз уңаеннан без малайлары турында сорыйбыз. (Аның өч малае үсеп җиткән, олысы белән кечесе өйләнгәннәр дә инде, башка чыгып, аерым торалар икән. Яннарында хәзер ике кызы да бер малае.)

— Малайларым, шөкер, тәүфыйклы булып үстеләр,— ди Сәгыйдә.— Эсү менән дә шаярманылар...

Бигрәк тә уртанчы малаен мактый. Аның турында шундый кызык кына нәрсә дә сөйләп алды: ул, ягъни уртанчы малае, армиядә чакта Кремль сагында хезмәт

иткән, безнең җитәкчеләрнең күбесен үз күзе белән күргән... Егет яхшы хезмәт итүе беләнме, әллә булмаса, холкы-фигыле беләнме, шундагы бер татар полковнигына бик ошаган, имеш. Шултиклем ошаган, ди, полковник егетне армиядән бушагач та, Мәскәүдә калырга кыстый башлаган, хәтта кызымны сиңа бирәм, тора-бара квартир да алып бирермен, теләсәң, эти-әниеңне дә китерерсең, дигән, имеш. Егет шуларның барсын да хәбәр итеп, киңәш сорап, атасы белән инәсенә хат язган. Әмма Сәгыйдә моңа һич тә риза булырга теләмәгән: «Улым, балакаем, Мәскәүдә өйләнеп кала күрмә, үзебезгә — Көрмәнкәйгә кайт»,— дип язып җибәргән. Һәм егет, Мәскәүне ташлап, Көрмәнкәйгә кайткан, хәзер колхозда эшли икән, тик нигәдер өйләнергә теләми, ди Сәгыйдә.

Әнә шундый хикмәтле бер кыйсса!.. Без моңа ышандык, чөнки бу Сәгыйдә үзе генә уйлап чыгарырлык нәрсә түгел иде... Озак та үтми, Хәмит тә кайтып җитте. Куанышып күрештек, аннары өйгә кердек. Дустыбыз бер дә үзгәрмәгән, элеккечә ябык-какча, кара-көрән, каты кара чәчендә бер чал бөртеге дә күренми диярлек, үзе исә бик шат, бик дәртле күренә. Ләкин эчкәнен сизмәдек (хәер, әзрәк кенә бар иде шикелле). Без сөйләшкән арада, хатыны чәй дә өлгертте. Өстәлдә сөт, каймак, май, бер-ике дистә күкәй һәм өйдә пешкән бик тәмле бодай икмәге. Без китергән гастроном күчтәнәчләре дә өстәлгә куелды, әмма ләкин Сәгыйдәнең куе, салкын каймагы белән хуш исле икмәгенә ни җитә, Ходаем!.. Өйләрендә зур яңалык — кечкенә өстәлдә кызыл тастымал япкан телевизор! — Шактый ук кыйммәтле бу замана әйберсенә без игътибар итеп өлгергән идек инде.

— Көйләнде безнең эшләр, парин!.. Бичә белән икәү сәкедән генә карап ятабыз Уфа белән Мәскәүне,— ди Хәмит, көлеп.

— Байлык керә башлаган өеңә, Хәмит! — дибез без дә, шаяртып.

— Байлык ул түгел, байлык менә бу! — ди ул, икмәк сыныгын күрсәтеп.— Шушы булса, калганы табыла.

— Шөкер генә итәһе,— ди Сәгыйдә дә, иренә кушылып.— Авыр сактар үтте инде, малайзар үсеп етте, йәрзәмләшәләр, пинсиябез дә килеп тора, шөкер генә итәһе!..

Чәйдән соң Дим аръягына чыгып килергә булдык. Киткәнче Хәмит бер тавыкны, абзар ышыгында гына суеп, хатынына бирде. Аннары, өчәүләп, бәрәңге бакчасы буйлап кына Димгә таба атладык. Хәмитнең өе авылның иң читендә дип әйткән идем бугай. Моннан инде, сөзәк кенә

тау итәге башлана. Кайчандыр кымызчыларның шунда чыгып, хуш исле җылы чирәмдә кызынып ята торган җирләре... Быел, яңгырлар булмагач, тау итәге тәмам көеп беткән, атлаганда, көлгә баскандай, кайнар тузан бөркелеп кала.

Хәмитнең көймәсенә утырып, аръякка чыктык. Тугай буйлап киттек. Бу якта күлләр күп: теге бер килүдә кармак салып, кымыз эчеп утырган Япраклы күлнең аргы очына якынрак тагын бер кечкенә түп-түгәрәк күл бар — Алабуга күле ди идек без аны. Кечкенә булса да, бик тирән, дип әйтәләр иде... Япраклының бирге очыннан ерак түгел зур гына күлне ни өчендер Сасык күл диләр иде. Малай чакта без боларның барсына да еш кына килеп йөри идек, ә хәзер менә өч «бабай», кулларны артка куеп, салмак кына атлап барабыз.

Хәмит безне туры Сасык күлгә китерде. Монда аның салып куйган нәрәтәсе бар икән, шулай ук куе камышлык эчендә кечкенә генә каегы да тора икән. Менә шул каегына басып, ул озын колга белән генә этә-этә күлгә кереп китте дә, нәрәтәсен күтәреп, балыкларын бушатканнан соң, нәрәтә казыкларын кире утыртып, камыш арасыннан шуып кына ярга чыкты. Безнең күреп исебез китте: каек төбендә бәләктәй калын тыгыз кара балыклар тыпырдашып ята!.. Әз дә түгел, кимендә бер унбишләп булыр... Миңа, күптән инде тере балык күрмәгән кешегә, бу гүя бер могҗиза булып тоелды. Юк, чынлап та, Хәмит дусның һаман да әле балыктан бәхете бар икән.

Шуннан соң инде без тугайда озак юанмадык. Балыкларны юеш капчыкка салып, кайтыр якка борылдык. Әйтергә кирәк, кара балык ул бик затлы балык, бик тәмле, бик симез, кылчыгы да бик аз, су төбендә генә ята ул, кармакка бөтенләй эләкми диярлек. Шуңа күрә аны элек тә, Дим буйлары балыкка бик бай чакта да, сирәк күрергә, сирәк ашарга туры килә иде.

Әлбәттә, без кайту белән Сәгыйдә килен кара балыкны тиз генә чистартып, кыздырырга да тотынды. (Бу балыкны чистарту ансат — эчен ярып юасы гына.) Ә Хәмит шул арада салкын катыкны кое суы белән туглап, безгә бик тәмле «өреле» әйрән эчерде, аннары ашыкмыйча гына табын әзерләргә кереште. Озакламый өстәлгә аш та, тавык та, таба тулы балык та килде. Кулларны угалап, алдан ук эчке бер канәгатьләнү татып утырыштык. Монда «тост» дигән нәрсә дә, макташып утыру да юк, хуҗалар кыстый, без ашыйбыз, күңелгә ни килсә, шуны сөйлибез, берәр мәзәктән көлешеп тә алабыз — барсы да бик гади дә бик табигый!.. Бүген дә әнә шулай,

без килгәч кенә, тәрәзә капкачлары ачылган салкынча иске генә өйдә изүләрне чишеп, туйганчы ашап-эчеп, җәелеп, хозурланып утырдык. Тик иң ахырдан гына Хәмит дустыбыз ничектер бераз уйга калып, күңелсезләнеп киткән шикелле булды да, үзе үк башлап, карлыга төшкән тавышы белән сузып кына бер җырлап та алды:

Җил җилләйдер лә бурайдыр,
Буразнага сылайдыр.
Карлар китеп, язлар килгәч,
Күңел ямансылайдыр.

Әйе, бик моңаеп җырлады ул бу сәер җырын, һәм без ирексездән гаҗәпләнә дә калдык.

— Язлар килгәч, күңел күтәрелә торгандыр бит, Хәмит?..

Хәмит, гаепле елмаеп, авыр гына сулап куйды:

— Шулаен шулай да... тик кайчагында нигәдер бик ямансу да булып китә шул. Дөньяның иң матур чагын әллә күреп була, әллә юк тагын...

— Куй, юкты һөйләп утырма! — диде Сәгыйдә дә, ачулана төшеп.

— Бетте, карчык, бетте! — диде ул, бала шикелле йөзен аның аркасына яшереп... Бик аз гына авыр тынлык булып алды, ләкин без моңа игътибар итмәскә тырыштык. Берни булмагандай, шунда ук сүзгә дә керештек, яңадан бер капкалап та алдык, Хәмит үзе дә бик тиз җанланды — кыскасы, мәҗлесебез элеккечә күңелле генә дәвам итә бирде.

...Чәйләр дә эчеп, кояш та шактый түбәнәйгәч, без кайтырга вакыт җиткәнен искә төшердек. Элек балыкка йөргән юллардан узар өчен, Көрмәнкәй яклап кайтмыйча, Япраклы ягыннан әйләнеп, «пәриле» коесына да тиеп кайтырга булдык. Моның өчен Хәмит безне яңадан Дим аръягына алып чыгарга тиеш иде. Иң элек әле ул безгә калган балыкларны көчләп дигәндәй, сумкабызга салып бирде. «Минем нәрәтәгә көн дә кереп тора алар, ә боларын Гомәр бичәсе пешереп ашатсын!» — диде... Ә көймәгә утыргач, туры гына аръякка чыгармыйча, шакта безне Дим үренә таба алып китте. Иван-сәй тавының текә кызыл ярын узгач, анда Димнең киңәеп киткән читләрендә оя-оя төнбоеклар үскән гаҗәеп матур бер җире бар икән,— Хәмитнең менә шуны безгә күрсәтәсе килгән. Рәхмәт аңа моның өчен!.. Шуннан соң кире борылып, Көрмәнкәй турысына җиткәч, тугай ярына төштек. Хәмит безне шактый гына җир озата барды. Ахырда туктадык, «яңадан күрешкәнче» дип кулларны кысыштык... Шул

чакта Хәмит минем кулымны озаграк тотып, нигәдер кинәт кенә боекланып, туп-туры күземә карады. Һәм без ирексездән бер-беребезгә тартылып кочаклаштык. Беренче мәртәбә!.. Әлек җиңел генә аерылыша идек, ә бу юлы нәрсәдер нидер әйтте кебек безнең күңелләргә... Бераз киткәч, мин артыма борылып карадым. Хәмит исә һаман шул урынында басып тора иде. Минем туктаганны күргәч, ул миңа таба килә башлады, мин дә аңа таба атладым, һәм без тагын сүзсез генә кочаклаштык... Әнә шулай аерылыштык без... Әйткәнемчә, бу 1975 елның явымсыз коры җәендә булды.

Хәмит белән без хатлар язышып тормадык, вәгъдәләр дә бирешмәдек, кайткан чагымда шушы очрашулар безгә бик җиткән иде, яңадан исән-сау күрешүебезгә ышанып аерылыша да торган идек. Аның үз дөньясы, минем үз дөньям, шул сәбәпле даими бәйләнеш тотуның кирәген дә тапмаганбыздыр, ахрысы.

1978 елның июнь ахырында мин, вакытым бик тыгыз булуга карамастан, ике генә тәүлеккә тагын Дәүләкәнгә кайттым. Бернинди эшем-йомышым юк иде, бары өйрәнелгән гадәт буенча гына, чөнки Уфага кайтсам, Дәүләкәнгә барып килмичә түзә алмыйм. Бу юлы ничектер шулай туры килде ки, кайтып төшүем белән мин элек күршебездә үскән, яшьтән үк таныш Рабиганы очраттым. Һәм мена күрешеп, таныш-белешләрне сораша торгач, Рабига миңа, ниһаять, әйтте:

— Көрмәнкәйдәге Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә юк бит инде...

— Тукта, ни дигән сүз бу? — дидем мин, аңлап бетермичә.

— Алар... үлделәр шул! — диде Рабига, миңа карамаска тырышып.

— Үлделәр?! Кайчан, ничек?..— Мин тәмам аптырадым да калдым, колакларыма ышанмыйча торам, чынмы, ялган түгелме бу?.. Юк, ялган түгел, ди Рабига, ышанмасаң, әнә Көрмәнкәй бичәләреннән сораш, ди... Әмма минем аңыма һаман да әле барып җитми кебек, җитсә дә, һич кенә килешергә теләми кебек бу һич тә көтелмәгән гаять аяныч хәбәр белән.

Ләкин барыбер ышанырга да һәм килешергә дә туры килде. Әҗәл агач башыннан йөрми, диләр... Башта Хәмит үзе, кыска гына авырып, үлеп киткән, аннары, өч ай үтүгә, хатыны Сәгыйдә дә аның артыннан ияргән... нинди авырудан икәнен ачык кына белә алмадым. Сәгыйдә, мәсәлән, кан басымы күтәрелүдән зарлана торган иде, бәлки, үлеменә шул сәбәп булгандыр.

Сугыш инвалиды, сыңар куллы карт колхозчының үлүе бик гади вакыйга, ишеткәне — белгән, ишетмәгәне белми дә калган. Хәтта Көрмәнкәйдән өч кенә чакрым читтә торган Гомәр дә Хәмитнең үлүен берничә айдан соң гына ишеткән.

Минем үземә аларның бер-бер артлы диярлек үлеп китүләре бик вакытсыз да һәм бик мәгънәсез дә булып тоелды. Яшәргә тиешләр иде әле, яшәргә!.. Хаклары һәм гомерләре бар иде әле яшәргә!.. Тормышның әзрәк рәхәтен дә татып калырга!..

Юк, шулай да аңлавы читен бу дөньяны!.. Кеше үлә дә китә, гүя караңгы төндә бер генә минутка туктаган поездлан төшеп кенә кала. Аның төшеп калганын юлдашлары иртән торгач кына беләләр. Ә поезд һаман бара да бара — алда һәркемне үз тукталышы көтә... Шундый микәнни кешенең гомер юлы да?!

Хәзер инде Көрмәнкәйгә юллар өзелде. Икесенең берсе юк... Әмма аларның... каберенә мин әле барачакмын! Дөрес, ишеткәч тә үк мин моны эшли алмадым — ни сәбәптер, шул чакта аягым тартмады. Буш, ятим йортка барып керүдән курыктыммы — үзем дә белмим. Ә икенче көнне инде миңа Дәүләкәннән китеп тә барырга туры килде. Ләкин соңгы кайтуым булмас әле бу, булмаска тиеш, тик баш кына сау булсын!

Сез беләсез инде, менә егерме биш елдан бирле мин бу тарафларга кайтып йөрим. Дәүләкән ул минем уемнан һәм күңелемнән бер дә чыкканы юк. Сәбәбен аңлап та бетерә алмыйм. Сугыштан соң беренче мәртәбә кайтуымны аңлыйм, ул чагында бик сагынган идем, күпме еллар үскән, яшәгән җиремне күрмичә торган идем... Кайтып төшү белән айлы төндә карап йөрдем — Дәүләкәнем кадимге Дәүләкән, бер дә үзгәрмәгән диярлек, шул ук урамнар, шул ук йортлар, тик алар шактый искергән, тузганнар иде. Һәм халкы бик үзгәргән иде, искеләр аз калган, мин белмәгән яңалар бик күбәйгән иде.

Әйтергә кирәк, Дәүләкән шул иске хәлендә үзгәрмичә алтмышынчы елларның ахырына хәтле диярлек торды яки үзгәрсә дә, бик аз үзгәрде. Моның сәбәбен урындагы иптәшләр Дәүләкәндә зуррак промышленность юклыгы, аның һаман да икмәк бирә торган район үзәге булып кына калуы белән аңлаталар иде. Дөрес, Дәүләкәннең борыннан ук дан тотып килгән зур-зур тегермәннәре көне-төне эшлиләр, алар тартып чыгарган мәшһүр Дәүләкән оны илнең бөтен шәһәрләренә өзлексез китеп кенә тора — бу җәһәттән эшләр шәп бара иде булса кирәк. Һәм азмы-күпме үзгәрешләр дә шул тегермәннәр тирә-

сендә күренә: Якорь тегермәненә тимер юл тармагы кергән, шуннан ерак түгел комбикорма заводы төзелгән, ә элекке Гардер тегермәннәре янында ниндидер зур-зур биналар салынган иде. Әйткәнемчә, тегермәннәр Дәүләкәннең даны һәм горурлыгы!

Инде кечкенә шәһәрнең башка өлешенә килгәндә үзгәрешләр юк диярлек. Барлык район оешмалары, шул исәптән райком белән райисполком да байлардан калган йортларда яшиләр иде. Хәтта озак кына вакыт Дәүләкәннең үз клубы да булмыйча торды. Кайчандыр безнең заманда спектакльләр куела торган ике катлы Бәлдәй йорты нишләптер ишелеп төшкән (шулай диделәр миңа), ә аның урынына яңа бина салу төрле сәбәпләр аркасында елдан-ел кичектерелә килгән.

Әмма үзгәреш бер башланырга тиеш иде. Безнең заманда бер генә шәһәрчек тә нәкъ искечә сакланып кала алмый, иртәме-соңмы аңа да үзгәреш килә — килмичә хәле юк. Менә мин дә соңгы кайтуларымда (җитмешенче елларга кергәч) Дәүләкәннең шактый кызу үзгәрә башлаганын күрдем. Иң элек нәкъ үзәктәге иске йортларның һәммәсен дә сүткәннәр, алар урынына өч-дүрт катлы тартма йортлар салганнар; шунда ук райком белән райисполком өчен чибәр генә махсус биналар төзелгән, алар каршында иркен генә мәйдан калдырылган, чәчәкләр өчен зур-зур түтәлләр эшләнгән, агачлар утыртылган. Шул ук мәйданда, дөресрәге, элеккеге Марҗа базары түрендә, ничәмә елга сузылган соры төстәге үзе зур, үзе котсыз культура сарае да, ниһаять, салынып беткән. (Архитектурасы миңа бер дә ошамады.)

Шулай итеп, Дәүләкәннең базар белән янәшә үзәге кыска гына вакыт эчендә үзгәргән дә куйган. Миңа таныш йортлардан, Басыйр купецның ике катлы таш магазинын исәпләмәгәндә, берсе дә калмаган. Кызганып әйтүем түгел, ләкин кайберләре хәтердә озак сакланыр әле — мәсәлән, элекке Туманный!.. (Революциягә кадәр үк агачтан салынган кинотеатр.) Чөнки бу Туманныйга малай чакта да, егет була башлагач та, күп йөрдек, аннары минем үземнең аңа бәйләнгән кайбер истәлекләрем дә бар.

Кыскасы, минем Дәүләкәнем дә, башка җирләрдән соңга калыбрак булса да, үзгәрә һәм яңара. Мин моны кайткан саен күреп китәм. Билгеле, бу үзгәрешләрнең барсы турында да сөйләп тору бик озынга китәр иде. Ләкин берсе турында шулай да әйтмичә уза алмыйм. Кайчандыр, әле революциягә чаклы ук салынган Дәүләкән элеваторын бөтен республикада иң зурысы дип әйтәләр

иде. Чынлап та, аның кебек зур, биек элеватор тагын кайда гына булды икән? — миңа, мәсәлән, күпме юллардан узсам да, күрергә туры килмәде... 1979 елның җәендә көн өстенә генә кайткач, минем бер күренешкә исем китте: иске элеватор янына кай арададыр тагын бер элеватор салып куйганнар. Зурлыгын әйт син аның! Галәмәт!.. Иске элеватор бәләкәй генә булып калган аның янында!.. Моны күргәч, шунда ук уйлап та куйдым: кирәк нәрсәне бездә бик тиз салалар икән. Һәм Дәүләкән элеккечә республиканың икмәкне иң күп җыя һәм саклый торган урыны да икән!

Хуш, болар барсы да, әлбәттә, бик әйбәт... Ләкин бит мин Дәүләкәнгә туган-үскән туфрагым дип кайтам. Барсыннан элек миңа аның халкы якын һәм кадерле булырга тиештер бит инде. Җире-суы, кырлары-яланнары, тугайлары-күлләре, ниһаять, бормаланып аккан Димкәе кадерле булырга тиеш... Яшьлегем хатирәләре белән бәйләнгән урамнары, йортлары, мәктәп, клуб кебек урыннары миңа аеруча якын, тансык булырга тиеш түгелме соң!.. Нәрсә калган шуларның барсыннан?.. Каршыда мәһабәт Ярыш тавы басып тора, якты Дим салмак кына ага, тугайда күлләр җәйрәп ята, кайткан саен мин аларга текә яр башыннан сокланып һәм уйланып карап торам, янә тагын Дим өстендә, хәтта ялгызым гына булса да, көймәдә йөрмичә калмыйм. Ләкин табигать үзе, никадәр генә бай, гүзәл булмасын, кешегә карата салкын, битараф бит ул — аның өчен синең кайтуың да, китүең дә барыбер түгелмени?! Кеше кайта аңа, кеше сагына аны, чөнки кешенең үткәне шушында калган, шушында саклана... Минем өчен дә ул шулай, мин дә кайтып Дим ярына басу белән гүя үткәнемә күчәм, үткәнемне күрәм. Буерактагы үткәннәр турында сүз алда булачак әле, тик хәзергә бер генә нәрсәне искә төшерү белән чикләнәсем килә: мәсәлән, без яшь чакларда, җомга көн саен егетләр-кызлар бер-ике көймәгә утырышып, гармун һәм мандолинага кушылып җырлый-җырлый, Дим өстендә күңел ачып йөри торган идек. Сез беләсезме икән су өстендә җыр-гармун тавышларының никадәр дәртле-матур яңгыраганын?! Яр башында утырган картлар, карчыклар да сихерләнеп тыңлый торганнар иде... Әйе, кайчандыр иде бу, ә менә хәзер егерме биш ел буена кайтып-китеп йөрим, әмма Дим өстендә бер генә тапкыр да җыр, гармун тавышы ишеткәнем юк!.. Беткән, онытылган бу матур гадәт, ләкин аның каравы моторлы көймәләр ярларны ишә-ишә колак тондырып чабалар.

Әйе, үзгәрешләрнең төрлесе була — куандырганы да

һәм уйландырганы да. 1969 елны туган көнемне үткәргергә кайткач, мине озата килгән Илдар Юзеев һәм Вәзих Исхаков белән бергә Дәүләкәннең башкорт интернатында, аннары мин укыган татар мәктәбендә булган идек. Дәүләкән ул борыннан ук үзенә күрә бер мәгърифәт оясы иде. Революциягә чаклы ук инде анда зур мәдрәсә бар иде, ир һәм кыз балалар өчен аерым җәдит мәктәпләре бар иде, бу мәктәп-мәдрәсәләргә читтән дә килеп укый торганнар иде. Совет дәверендә исә монда педагогия училищесы һәм авыл хуҗалыгы техникумы яшәде, ә хәзерге вакытта республика күләмендәге механизаторлар мәктәбе эшләп ята. Билгеле ки, уку-укыту эшләренә безнең дәүләт бик зур әһәмият бирә, яшьләргә урта белем бирү инде ул закон белән кертелгән чара. Ләкин, ни гаҗәп, Дәүләкәндәге әлеге җитмеш-сиксән ел яшәп килгән татар мәктәбе кай арададыр бетерелгән, юк инде ул хәзер. Бу да бит үзенә күрә бер үзгәреш!

Тагын нәрсә әйтәсем калды?.. Утырам һәм уйланам. Дәүләкән миннән еракта... Онытырга вакыт түгелме икән инде үзен? Беренче тапкыр бу кечкенә шәһәрдән чыгып китүемә дә ничәмә дистә еллар тулып узды. Шулай булгач, аның миннән ераклаша һәм ятлаша баруы бик табигыйдер инде. Кайтып киткән саен мин бу хәлне ныграк тоям да түгелме соң?! Хәмит тә үлгәч, минем анда очрашып, сөйләшеп йөри торган бары ике кешем калды — Гомәр дә Әхтәм... Тагын сиксәнгә җиткән Муллагали абзый белән Зөләйха апа янына кереп, күрешеп чыгам. Башка юк, хәер, булса да безнең аралар шулкадәр ераклашкан, очрашып күрешү кирәклеген алар да, мин дә тоймыйбыз... Әнә шулай үзгәрә икән авылдашлар арасындагы мөнәсәбәтләр дә!

Әмма шуңа карамастан минем Дәүләкәнне оныта алганым юк. Соңгы елларга кадәр ул гел искә төшә торды, һаман мине үзенә тартты. Һәм мин форсат чыккан саен йә электричкада, йә машинада чакырылмаган кунактай барам да төшәм: «Әссәламегаләйкем, без менә тагын килеп җиттек!» Йә, гаҗәп түгелме?.. Баштарак әле Дәүләкәнгә бөтенләй кучеп кайтмаска микән дип уйлап куйган чакларым да булды. Ләкин мин мондый теләкнең ялгышлыгын һәм кирәксезлеген бик тиз аңладым, чөнки кайчандыр үскән, яшәгән, ярты халкы диярлек таныш булган җирдә хәзер инде бер килмешәк төсле соңгы гомереңне ялгызлыкта үткәрүе һич тә кызыклы булмас иде.

...Юк, шулай да нәрсә тарта, нәрсә бәйли соң мине һаман да бу җиргә?.. Менә шуны бик аңлыйсым килә. Минем шикелле Дәүләкәндә үсеп-яшәп тә читкә киту-

челәр аз түгел, Уфаның үзендә генә күпме алар. Ләкин шушы соңгы егерме ел эчендә берәрсенең кайтып күренгәне бармы? Юк бит... Хикмәт нәрсәдә соң?.. Әллә бик рәхәттә уздымы минем монда яшәгән чакларым?.. Һич тә алай түгел ич! Дәүләкәннең мине рәнҗеткән, елаткан чаклары да аз булмады — бигрәк тә үсеп егет булгач, ул миңа шактый газаплар китерде. Ләкин бик күптән булган хәлләр бит алар, онытырга да вакыттыр инде, начарын гына түгел, хәтта яхшысын да!.. Хәер, яхшысы онытылмый, әйтик, балачак, әйтик, иртә яшьлекнең беренче өметләре, беренче татлы хыяллары, беренче мәхәббәт газабы — болары саклана, болары онытылмаячак. Әйе, искә төшкәндә сагындырган, уйландырган, үкендергән хатирәләр!.. Менә шул хатирәләр эзеннән Мәҗнүн шикелле йөрим, ахрысы, мин... Бүтәнчә ничек аңлатыйм?.. Әгәр шулай икән, димәк, ул хатирәләрнең үзләренә дә чират җитте дигән сүз.

## ЭТКОЛ

Башта тарихка бер күз салыйк. Ягъни Дәүләкәннең борынгырак чагына. Бу кирәк, чөнки тарих ул кешеләр язмышының сүз башы. Минем өчен дә ул шулай.

...Үткән гасырның ахырларында Дим елгасының сулъяк ярында янәшә диярлек ике башкорт авылы утырган — берсе Эткол, икенчесе Дәүләкән. Кечкенә булган алар; ихтимал, башкортлар әле мал куып, күчеп йөргән чакларда кышлау гына булганнардыр. Кышлауның нәрсә икәне аңлашылса кирәк. Бу язын (язлауда), җәен (җәйләүдә), көзен (көзләүдә) мал йөртеп, кар төшкәч һәм суыклар башлангач, башкортларның кышлар өчен кайтып керә торган урыннары. Менә шул кышлаулар торабара, башкорт та утрак тормышка күчкәч, авылга әйләнгән булырга тиешләр.

Гадәттә, күп кенә авыллар беренче килеп утырган кешенең исеме белән атап йөртелә. Дим буенда да андый авыллар шактый — якын-тирәдәге Акколай, Ибрай, Көрмәнкәй, Шәрип, Исмәгыйль, Казангол, Япарларны әнә шундыйлардан дип әйтә алабыз. Эткол да кеше яки ыру исеме белән бәйләнгән булырга тиеш, чөнки «кол»га беткән исемнәр башкортта күп очрый. Ә Дәүләкәннең инде турыдан-туры Дәүләтхан исеме белән бәйләнгән булуын үземнең дә ишеткәнем бар иде.

Якты Дим буйларында башкортлар үзләре генә утырган — читтән килгән халыкларга зур су буйларына караган җирләрен сатмаганнар һәм арендага да бирмәгәннәр.

Терлек күп асраганга күрә, алар мул печән бирә торган болыннарын үз кулларында саклаганнар. Аннары судагы балык, тугайдагы җәнлек кебек байлыкларга да үзләре генә хуҗа булганнар. Электән үк бу якларга килеп утырган татар авыллары булса да, алар Димнән шактый еракта, тирән чокырлы кечкенә инеш буйларына урнашканнар. (Мәсәлән, Аюхан, Чуенчы, Карамалы һәм башкалар.) Дөрес, бу гасырга кергәч, Дим буенда рус авыллары күренә башлый, ләкин болар Столыпин күчереп утырткан авыллар булса кирәк.

Әйе, бу яклардагы башкорт җирләре кайчандыр чиксез иркен булган — сөзәк кенә үрләр күтәрелгән, үрләр төшкән, бөтен әтрафта тирән тынлык хөкем сөргән, тик төпсез күктә ялгыз тургай тавышы гына чыңлап торган. Минем атакай мәрхүм дә: «Мин малай чакта Каргалы белән Дәүләкән арасында бер генә авыл да юк иде, гомер бакый сука кермәгән ак кылганлы тоташ ялан гына иде»,— дип сөйли торган иде... Әнә шулай булган ул малай чакта, ә мин малай чакта инде бу кырык чакрымлык арада өч-дүрт рус авылы һәм күпмедер немец хуторлары бар иде. Кайчан башлана, кайчан шулай бик тиз үзгәреп өлгерә соң бу күпме заман тын гына яткан иркен-буш җирләр?

1880 елны нәкъ Эткол кырыннан гына Самар — Уфа тимер юлы уздырыла. Бу Россия үзәгеннән башланган мәшһүр Себер тимер юлының дәвамы. Тора-бара ул Уралны, Себер далаларын, тайга урманнарын, Саян тауларын да үтеп, Ерак Көнчыгышка хәтле барып җитә. Россия өчен бик кирәкле һәм бик әһәмиятле бу гаять озын юлны заманасына күрә шактый кызу салганнар. Халыкны эшкә авылы-авылы белән куып китергәннәр — хәтта кырык чакрымдагы Каргалы кешеләре дә атлары белән килеп җир казыганнар, балчык ташыганнар. Атакайның әйтүенә караганда, ул да яшь кенә малай көе балчык ташучыларга ияреп ат башында йөргән. Шуның өчен әле әзрәк кенә акча да төшергән. (Халыкны бушка эшләтмәгәннәр.)

Эткол кырында гына таштан яңа станция дә салына. Ләкин аңа Дәүләкән исемен бирәләр, күрәсең, бу исемне уңайрак һәм матуррак табалар. Русча ул «Давлеканово» дип атала.

Билгеле инде, Россия үзәгеннән килеп, Себергә чаклы узып киткән бу тимер юл моңарчы тын гына йокымсырап яткан Эткол — Дәүләкән җирләрен кинәт бик нык җанландырып һәм үзгәртеп җибәрә. Озак та үтми яңа юл белән мондагы бәрәкәтле җирләргә төрле халык

агылып килә башлый: руслар, хохоллар[1], немецлар һәм татарлар, әлбәттә... Күпмедер вакыттан соң, бары бер ел эчендә генә Дәүләкән әтрафында егермеләп рус-хохол авыллары һәм немец хуторлары барлыкка килә. Әгәр Эткол белән Дәүләкәннең үз халкы тимер юл ачылганчы 500 чамасы булса, 1897 елда инде халык саны 1500 дән артып китә.

Бу урында шуны әйтергә кирәк: татарлар күбрәк Этколның үзенә аерым семьялар булып киләләр. Кайсы яктан, нинди татарлар икәнен соңрак күрербез. Тимер юл ачылгач кына, бу якларга килеп утырган татар авылын мин белмим, ишеткәнем дә юк. Мондагы татар авыллары барсы да диярлек бик күптән килеп калган иске авыллар иде.

Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә тирә-якта иген игү бик нык арта, ә Эткол үзе бик җанлы бер сәүдә итү һәм ашлык чыгару урынына әверелә. Бигрәк тә хутор булып утырган немецлар игенне зур мәйданнарда чәчә һәм үстерә башлыйлар. Шулай ук яңарак килгән руслар белән хохоллар да иген эшенә җиң сызганып керешәләр. Татарлар исә монда күптән игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Борын-борыннан мал асрап яшәгән башкортлар үзләре дә «бидай»ны ашар өчен генә түгел, сатар өчен дә үстерергә тотынганнар. Кыскасы, икмәк төп байлыкка әверелә, икмәк барсына да җан өрә, бөтенесен хәрәкәткә китерә. Һәм бу якның моңарчы төрән кермәгән кара уылдыктай чирәм җирләре уңышлы да ишеп биргән булырга тиеш. Бер генә мисал: 1908 елны Дәүләкән станциясеннән ике миллион поттан артыграк ашлык озатыла, ә шул ук вакытта бөтен Уфа губернасыннан барлыгы алты миллион пот чыгарыла. Димәк, зур губерна җитештергән игеннең кимендә 30—35 процентын бер Дәүләкән үзе генә биргән була. (Бу мәгълүмат хәзер Дәүләкәндә чыга торган «Знамя» газетасыннан алынды.)

Менә шушы бөтен әтрафтан агылып керә башлаган игеннән нинди табышлар алып булачагын бигрәк тә немецлар алданрак күрәләр һәм бу табышны үз куларына эләктерер өчен зур өлгерлек тә күрсәтәләр. Берничә ел эчендә алар Дәүләкәндә зур-зур тегермәннәр салдырдылар: Гардер, Гауфлер, Войтец тегермәннәре, шулай ук Димне буып салган мәшһүр Якорь тегермәне әнә шундыйлардан. Боларның һәркайсы таштан, бишәр-алтышар катлы, биек кирпеч трубалары белән чын заводларны хәтерләтә.

[1] Ягъни украинлылар, ләкин мин бу очракта аларны шул заманда аталганча язарга булдым.— *Ә.Е.*

Дәүләкәнгә кайсы яктан гына килсәң дә, чиркәү, мәчетләрдән дә биегрәк булып иң элек әнә шул мәһабәт тегермәннәр күренә. Һәм болар инде авыл агаеның берничә капчык бөртеген түгел, ә берөзлексез олау-олау кереп торган гәрәбәдәй бодайны тартып чыгара... Тартканы да биткә кершән итеп сөртерлек ап-ак он — крупчатка! Шул онны зәңгәр пичәтле махсус капчыкларга тутырып, вагон-вагон Мәскәүгә, Петербургка, башка зур шәһәрләргә һәм чит илләргә озаталар. Күрәсез, Дәүләкән оны үзенең югары сыйфаты белән дөнья базарына да чыга. (Җәя эчендә генә шуны да әйтеп үтик: 1910 елны Ростов шәһәрендә оештырылган күргәзмәдә Якорь тегермәне шул оны өчен зур көмеш медаль белән дә бүләкләнә.)

Немецлардан кала Этколда руслар да зур тегермәннәр салдыра, шулай ук татар бае Үтәмишевләр дә немецларныкыдай биш катлы тегермән салдырып җибәрә. Ялгышмасам, революциягә чаклы тегермәннәр саны бер унга җиткән иде шикелле. Ә моның нәтиҗәсе шул була: беренчедән, бу хәтле күп һәм машина көче белән эшләүче тегермәннәр игенне Дәүләкән әтрафыннан гына түгел, читтән-еректан да үзләренә «суырып» дигәндәй китерә башлый, икенчедән, Дәүләкән инде бөртек җыеп озатучы гына булып калмыйча, асылда, яхшы сортлы әзер он җибәреп торучыга әйләнә. Менә бу соңгысы Эткол — Дәүләкән тормышына зур үзгәрешләр кертә. Иң элек тегермәннәр үз тирәсенә күп кешеләрне эшкә тарта, ягъни монда яңа хезмәт иясе — эшчеләр катлавы барлыкка килә. Мин дә әле әзрәк хәтерлим: күпме грузчик-ломовойлар шул тегермәннәрнең оннарын көне-төне станциягә ташый торганнар иде. Һәм боларның күбесе башкорт агайлары иде. Билгеле, грузчиклардан башка монда он тузанына батып, төрле эштә эшләүчеләр дә аз булмаган. Шулай ук төрле профессия кешеләре — мастерлар, механиклар, электриклар, конторщиклар да эшли бу тегермәннәр эчендә.

Аннары игенне зур мәйданнарда чәчеп үстерә башлагач, авыл хуҗалыгы машиналарына һәм эш коралларына ихтыяҗ да бик нык арта. Тиз арада Этколда машина һәм кораллар белән сату итә торган фермаларның бүлекләре бер-бер артлы ачыла башлый. Төрле урында таштан зур-зур складлар салына. Боларның да хуҗалары бөтенесе диярлек немецлар: Эльворт, Бюлер, Ремпель, Зудерман, Гап, Гельфрих һәм башкалар. (Эльвортның тимер юлга якын гына салдырган ике катлы, тезелеп киткән әллә ничә зур ишекле таш склады әле дә булса саклана.) Бу складларга машиналар — төрле зурлыктагы молотил-

калар, үзе ура, үзе көлтәсен дә бәйләп ташлый торган ургычлар, чәчкечләр, җилгәргечләр, чапкычлар, берничә төрәнле сабаннар, йөзле (дискалы) тырмалар, хәтта «Интернационал» дигән тракторлар да (шул заманда!) турыдан-туры Германиядән һәм Америкадан килеп тора. Шуңа күрәдер инде революциягә чаклы ук Дәүләкән тирәләре авыл хуҗалыгы машиналары белән иң нык коралланган җирләрдән саналган. (Бу материал да «Знамя» газетасыннан алынды.)

...Әнә шундый үзгәреш!.. Әйтәләр, Эткол — Дәүләкәндә иллеләп иген җыю-салу амбарлары гына булган, дип... Гаҗәп түгел, чөнки бөтен әтрафтан көзен-кышын ашлык өзлексез агылып кереп торган. Бу ашлыкны җыеп озатучылар арасында (тегермән хуҗаларыннан кала) зур рус байларын күрәбез — болар: Лашков, Тимофеев, Костюриннар... Мин әле бер-ике яһүдне дә беләм (дөрес, нэп вакытында) — аларның берсе Тяуш, икенчесе Свердлов иде... Ниһаять, революциягә чаклы ук Дәүләкәндә Уфа губернасындагы иң зур элеватор да салына.

Билгеле инде, мондый җирдә һәртөрле сәүдә-коммерция эшләре аеруча кызу үсә һәм җәелә башлый. Мәсәлән, 1914 елны Дәүләкән халкының утыз проценты тегеләй яки болай сәүдә эше белән бәйләнгән була. Зур шәһәрләрдәге шикелле, монда акча салу, акча алу өчен банк та ачыла. Монда «Зингер» дигән тегү машиналары белән сату итүче атаклы фирманың филиалы да урнаша. Немецлар сыра заводы да салдырып җибәрәләр, шәп булган диләр аларның сырасы, губернаның төрле якларына китә торган булган. Польдяев дигән бер мордва бае монда, таштан ике катлы итеп, ике зур йорт салдырган. Бу йортларны без Бәлдәй йорты дип атый идек. (Хуҗасының чын фамилиясен мин күптән түгел генә белдем.) Берсендә, тимер юлга карап торганында, гостиница белән ресторан булган икән. Икенчесе, базар мәйданына якыны, махсус клуб итеп салынган. Менә шуның сәхнәсендә 1917—1918 елларда татарча спектакльләр куела торган иде. Аннары Марҗа базарына каршы гына агачтан шулай ук махсус салынган кинотеатр да бар иде. Элек аның исеме «Модерн» булган, имеш. Этколда — модерн!.. (Хуҗасы чит илдән, мәсәлән, Америкадан килеп чыккан кеше булмады микән?) Ләкин без, татар малайлары, аны «туманный» дип кенә йөртә идек. Тик шуны онытмагыз: болар барсы да Эткол дигән башкорт авылында — ул заманда әле ул волость үзәге дә булмаган шикелле, чөнки безнең волость Казангол волосты дип аталган — бу инде Дим буендагы икенче бер башкорт авылы.

## КУПИЧЛАР

Инде сәүдәнең үзенә килгәндә, бу тармакта күбрәк татарлар өлгерлек күрсәтәләр. Эткол базарының мәйданы зур иде, ул, чиркәү яныннан башланып, Дәүләкән чокырына чаклы сузыла иде. Менә шул мәйданның уртарак бер җирендә ике-өч рәт тезелеп киткән таш кибетләр — барсы да диярлек татарларныкы. Араларында өч-дүрт яки биш-алты приказчик тоткан зур кибет хуҗалары да бар — болар: Сафа купец, Басыйр купец (кибете таштан, ике катлы), Борһан купец, Шәймәрдән купец... Алар кулында кызыл мал, галантерея, бакалея сәүдәсе. (Шәймәрдән купец үзенең йорты белән янәшә махсус китап кибете дә ачкан иде.) Кечерәк сәүдәгәрләрдән Зариф, Гатаулла, Сафиулла, Габидулла (Гыйбаш) купецларны күрсәтергә мөмкин. Боларның да сәүдәсе галантерея яки бакалея, ләкин араларында җиләк-җимеш белән генә сату итүчеләр дә бар иде. (Мәсәлән, Гыйбаш махсус подвал да ачкан иде.) Шулай ук итчеләр һәм тире-яры җыючылар да, традиция буенча, торганы диярлек татарлар иде. Ләкин татарлардан иң зур байлар — тегермән хуҗасы Үтәмишевләр белән җир-урман биләүче Нәбиулла Кәримов иде... Дөрес, сәүдә эшендә руслардан да зур купецлар булган, әйтик, Самсонов, Антимонов, Чигадаев, Решетников һәм тагын кемнәрдер — мин аларның барсын да белеп тә бетермим. Һәм, гомумән, читтән килгән халыкның күпчелеге руслар булганга күрә, монда алардан байлар гына түгел, төрле һөнәр ияләре дә, эшче-хезмәткәр дә башкаларга караганда күбрәк иде.

Инде яңадан татар «купичларына» килсәк, монда шундый бер кызык хәл күзгә ташлана. Иң элек, алар барсы да диярлек Казан ягыннан килгән татарлар. Икенчедән, алар бик түбәннән чыккан, тик башкорт җиренә килгәч кенә баеп киткән кешеләр. Бу шактый кызыклы күренеш, шул сәбәпле алар турында тулырак сөйләп китү артык булмас дип уйлыйм. Мисалларын китерик һәм безнең күршебез Борһан абзыйдан башлыйк. Ул Әлмәт ягы Өч Мунча авылыннан, яшүсмер чагында ук атасы аны Самарга илтеп, шунда очраган бер Дагстан баена малайлыкка биреп җибәргән. Күпмедер еллар ул ерак илдәге шул байда хезмәт иткән. Башта самавырчы малай гына булып йөргән, аннары әкренләп үскән, күтәрелгән, гадел хезмәт иткән, байга яраган, тиенләп акча туплаган, ахырда хуҗасының фатихасын алып, азмы-күпме җыйган «капитал»ын учлап, башкорт якларына юл тоткан. Эткολга килеп, яңарак кына уяна, җанлана башла-

ган бәрәкәтле җирдә үзенә «эш ачар» өчен бик әйбәт зәмин дә тапкан. Беренче герман сугышы алдыннан Борһанетдин Мөхәммәтҗанов Дәүләкән «купичларының» иң билгелесе, биш-алты приказчик тотып, иң затлы товарлар белән генә сату итә торган зур таш магазин хуҗасы иде. Товарны да — кызыл мал белән галантереяне — ул Мәскәүдән, Петербургтан, Варшавадан гына китерткән, сатып алучылары да «затлы» (дөресрәге, акчалы) халык,— чабаталы мужик аның магазинына керергә дә кыймаган, диләр. Әлбәттә, тиз арада бу рәвешчә күтәрелеп, баеп китәр өчен Борһан абзаң сәүдә эшенең нечкә серләрен бик яхшы белүче зирәк, уңган, тырыш кеше дә булырга тиештер инде. Шунсыз Өч Мунча авылыннан малайлыкка чыгып киткән хәерче татар иң бәрәкәтле җирдә дә мантый алмас иде...

1918 елның җәй башында без Борһан абзыйларга күрше булып күчтек. Аларның ишегаллары бик иркен иде,яшел чирәм иде, һәм шул чирәмдә, төрле төстәге чәчәкләр шикелле, бик пөхтә киенгән балалар йөгерешеп уйнап йөриләр иде. Бу балалар бер дә урамга чыкмыйлар иде, мин дә аларга керергә һич тә кыймый идем (капкалары да һәрвакытта бикле була торган иде), исемнәрен дә белмим, бары коймa ярыгыннан гына аларны бик кызыксынып күзәтә идем. Шул чакта ук инде араларыннан берсе — озын кара толымлы, нечкә кара кашлы, алсу-ак чырайлы өлкәнрәк кызлары — минем игътибарымны үзенә бик нык җәлеп тә иткән иде. Соңыннан мин бу Һаҗәр исемле кызга үлә язып гашыйк та булдым.

...Борһан абзый үзе кечерәк буйлы, җыйнак кына бер кеше иде. Бик пөхтә һәм чиста киенеп йөри иде. Аз сүзле, тыныч, горур — шулайрак күренә иде ул миңа. Унсигезенче елның җәендә таш магазины эшләгән булса кирәк, чөнки минем күз алдымда шундый бер күренеш бик ачык саклана: кичкырын урам уртасыннан Борһан абзый зур улы Галиулла белән, матурлап бәйләгән төргәкләр күтәреп, ашыкмыйча гына кайтып киләләр. Икесе дә бик шәптән киенгәннәр: Борһан абзыйның өстендә яхшы материалдан озын кәзәки, башында каракүлдән кырпу бүрек, ә Галиулла өстендә бик килешле тужурка белән чалбар, башында киң читле йомшак фетр эшләпә. Әйтергә кирәк, Галиулла төскә дә бик чибәр һәм аяк атлаулары да аның бик көяз иде. Ишегалдындагы вак балалар, аталарының кайтыр вакытын белеп, барсы да урамга йөгерешеп чыгалар, шаулап каршы алалар, әтиләре белән абыйларына тотынып, шунда ук кереп тә

китәләр. Капка ябыла, аркылы агачын яңадан шылдырып куялар, шуннан бер мәлгә ишегалды да тынып кала.

Бер уңайдан Борһан абзыйның үзе турында өстәп шуны да әйтәсем килә: бу аз сүзле кеше Дәүләкән купецлары арасында бердәнбер балыкчы иде. (Купец балыкка вакыт әрәм итәме соң!) Җомга көннәрен кибетләр ябык чакта, ул, озын кармакларын алып, берәр малаен ияртеп, көймәсе белән Дим үренә балыкка китә торган иде. Билгеле, аның бу һәвәслеге балыкны үзе тотып ашарга яратканнан гына булмагандыр инде. Төрлесен күргән кеше, бигрәк тә соңгы елларда күпне кичерергә туры килде аңа (бу хакта сүз булыр әле), бәлки, ул тын гына бөтереләп аккан Дим ярында утырып үзенә җан тынычлыгы тапкандыр. Ә җан тынычлыгы кемгә генә кирәкми ул?!

Хәзер икенче күршебез, бездән өстәрәк урам аша гына торган Гатаулла картка күчик. Ул хәзерге Арча районы Чиканас авылында туып, яшьли ятим калып үскән кеше. Үз авылында өйләнгәннән соң, яшь хатынын ияртеп, башкорт якларына бәхет эзләп чыгып киткән. Чуенчы авылыннан ерак түгел, Йосыф исемле бер байның утарында унбиш ел үзе дә, хатыны да ялчы булып хезмәт иткән. (Чуенчы — Дәүләкән районындагы зур бер татар авылы.) Димәк, бу очракта да бер үк язмыш: нужадан котылу өчен иленнән чыгып китү, кайдадыр еракта кемгәдер ялланып эшләү, искиткеч тырышлык, чыдамлык күрсәтә белү һәм шул рәвешчә, байга ярап, үзенә юл ачу... Утарда унбиш ел тир түккәннән соң, Гатаулла карт (хәер, ул чакта әле ир уртасы) гасыр башында Этколга күчеп килә һәм, шул ук Йосыф бай ярдәме белән сату итәргә тотына. Ләкин крестьян эшен дә ташлап бетерми: башкортлардан арендага җир алып иген дә игә, берничә баш ат, сыер, сарыклар да асрый. Бу вакытта инде аның бер-бер артлы үсеп килгән өч малае да була. Тырышкан — табар, ташка кадак кагар, дигәннәр бит. Бу акыллы мәкаль, әйтергә кирәк, картның үзенә дә, малайларына да бик тә туры килә. Күп тә үтми, Гатаулла абзый Эткол урамында чибәр генә йорт та торгыза, ишегалды буйлап таза каралтылар да эшләтә һәм базар мәйданында таштан кечерәк кенә кибет тә салдыра. Хәзер инде аны да «Гатаулла купич» дип кенә йөртәләр, хәлбуки, ишетүемә караганда, төп капитал Йосыф байныкы булган диләр иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, ярлы бер татарның «купичка» әйләнүен шулай ук Дәүләкәндә сәүдә эшләренең нәкъ кыза башлаган чагына туры килүе белән генә аңлатырга мөмкин. Билгеле, кеше үзе дә шуңа, һичшиксез, сәләтле булырга тиештер инде.

Яки менә Шәймәрдән Гайнетдиновны алыйк. Бу да башкорт җиренә Балык Бистәсеннән кечкенә кабык арба тартып килгән кеше. Башта кургаштан ясаган алка, йөзек, беләзек кебек нәрсәләр сатып йөргән. Баегач, Эт-колның нәкъ уртасында асты таш, өсте бүрәнәдән таза йорт салдырган, йорты белән янәшә, шулай ук таштан, махсус китап кибете дә ачкан. Кибетнең ишеге сырлы тимер калайдан — шылдырып кына югары күтәрелә торган иде. Бу йорт белән кибет фоторәсеме Казанның «Заман» календаренда реклама рәвешендә басылып та чыккан булган. Календарь битендәге бу рекламаны күптән түгел мин үзем дә күрдем: чибәрләп эшләгән урыс капканың бер ягында ике катлы яшел йорт, икенче ягында тимер ишекле таш кибет. Ә йорт белән кибет арасында тройка костюм, кара кәләпүш кигән, кулларын чалбар кесәсенә тыккан Шәймәрдән абзый үзе басып тора. Казан каласының атаклы бер бае диярсең.

Ләкин Шәймәрдән агайның төп сәүдәсе базар мәйданындагы икенче таш магазинында иде — анда өч-дүрт приказчик кызыл мал һәм галантерея белән сату иттеләр. Әнә шулай баеп киткән Шәймәрдән Гайнетдинов та, ягъни ул да шактый «түбәннән күтәрелгән» купич!.. Әмма гомере кыскарак булды бу купичның, 1918 елны Уфада, вакыты җиткәнен белгән шикелле, тифтан үлеп киткән, бичара! Шуңа күрә мин аны юньләп хәтерләмим дә диярлек.

Ә менә кайчандыр аның приказчигы булган Минһаҗ абзыйны мин инде бик яхшы беләм. Ул атакайның якын дусты иде, озак еллар башта Дәүләкәндә, соңра Казанда бергә аралашып гомер иттеләр.

Минем кулыма Минһаҗ абзыйның үзе турында язып калдырган истәлеге кергән иде. Шактый кызыклы язма. Тик мин ул язмадан үземә кирәк кадәресен генә чүпләп алырга мәҗбүрмен.

Минһаҗетдин Шәрәфетдин улы Әминов элекке Мамадыш өязе Бучирмә авылында дөньяга килгән. Атасы — авылның атсыз-тунсыз бер фәкыйре, бары ике имана җир биләгән, көзен-кышын шахтага китеп эшләгән. 1891 елны каты ачлык килгәч, Шәрәфетдин агай, җиде яшьлек Минһаҗетдинне җитәкләп, башкорт ягына чыгып китә. Пароходка утырырлык рәтләре булмагач, болар алты йөз чакрым араны җәяүләп кенә үтәләр. Әмма кечкенә Минһаҗетдин еш кына арый, атасы аны җилкәсенә атландырып та баргалый, берәр атлы куып җитсә, шуңа да утыртып җибәргәли. Ат хуҗасы берничә чакрым киткәч, малайны төшереп калдыра — Минһаҗетдин юл буенда

елый-елый атасын күтеп ала... Әнә шулай салкын кара көздә бик җәфа чигеп, арып-ачыгып, кайбер авылларны узганда, хәер дә сорашкалап, ахырда болар Стәрлетамакка барып җитәләр.

Ул елларда бу кечкенә өяз шәһәренең иң зур байлары Үтәмишевләр булган — Шәрәфетдин агай бераз хәл алганнан соң әнә шул байларга дворник булып эшкә керә. Үтәмишевләрнең ятим балалар өчен ачкан мәктәпләре дә бар икән — атасына ияреп килгән кечкенә Минһаҗетдинне менә шунда урнаштыралар. Икенче елны Шәрәфетдин агай Бучирмәдән хатыны белән дүрт баласын да Стәрлетамакка китертә. Котыйчык шикелле кечкенә фатирда укмашып дигәндәй тора башлыйлар. Минһаҗетдиннең әнисе Бибифатыйма җиңги дә шул ук Үтәмишевләрдә көнозын эшләп йөри, бер апасы да байның кияүләренә асрау булып керә — шулай итеп, болар, ниһаять, авыр нужадан чыгалар. Һәрхәлдә, тамаклары туя.

Әйтергә кирәк, Үтәмишевләрнең сәүдә эшләре бик киң җәелгән була. Ашлык та җыеп озаталар, чәй-шикәр сәүдәсе дә алар кулында, керосин, тоз, ташкүмер белән дә сату итәләр, шуның өстенә Уралның төрле завод-рудникларында һәм Әлшәй, Ыслак, Дәүләкән кебек базарлы авылларда кибетләр дә тоталар. Бөтен җирдә махсус куелган кешеләр эшли, ә Үтәмеш бай үзе шуларны карап, тикшереп кенә йөри.

Бай, Шәрәфетдин агайның бик тырыш, гадел кеше икәнен күреп, аны үзенә даими кучер итеп куя. Яңа кучер аллы-артлы итеп яхшы атлар җигелгән ябык чанада (повозкада) байны әлеге «точкаларга» йөртеп кенә тора. Әмма кышның бер суыгында Шәрәфетдин агай кулларын өшетә, озак төзәлә алмыйча җәфалана, ахырда ике кулының да урта бармакларын кисәләр. Мәгәр сәламәтлеген бер сындырган кеше, күрәсең, мантый алмый инде. Шәрәфетдин агай да, чынлап авырый башлагач, 1901 елны, семьясын алып, үзенең Бучирмәсенә кайтып китә. Һәм шул ук елны туган-үскән җирендә вафат та була. Ә Минһаҗетдин Стәрледә кала. Аңа инде унҗиде яшь, үз көнен үзе күрергә тиеш. Үтәмишевләр аны Дәүләкәндәге тоз, керосин, ташкүмер складына «баш» итеп җибәрәләр. Хезмәт хакы аена ун сум — Минһаҗетдин шуның алты сумын авылга, әнисенә җибәреп тора. Атасы кебек тырыш, гадел булганга күрә, байлар ел саен аның хезмәт хакын бер-ике сумга арттыралар, ул да ел саен әнисенә акчаны арттырып җибәрә, чөнки дүрт ятим анда, әнисе кулында, кош балалары шикелле күтеп кенә торалар.

Шик юк, Минһаҗ абзый кайчан да булса үзе дә «ку-

пичлыкка» чыгарга хыялланган булырга тиеш. Ул заманда бу һәрбер өлгер, уңган приказчикның хыялы иде. Әмма ләкин Минһаҗ абзыйның хыялы гамәлгә ашарга өлгергәнче, ул арада 1917 елның революциясе дә килеп җитә.

Шулай да нэп вакытында Минһаҗ абзый һәм аның үзе кебек элекке приказчиклардан алты кеше, «Алга» исеме белән ширкәт төзеп, Басыйр купец магазинында бер биш-алты ел гөрләтеп сату итеп калдылар. Шуннан соң инде хосусый сәүдә эшләре сүнде, бетте, һәм Минһаҗ абзый да үзенең аслына кайтты. Ягъни яңадан хезмәт кешесенә әйләнеп, калган гомерен төрле урыннарда эшләп уздырды.

Минһаҗ абзыйның үзе язып калдырган бу тарихы Казан якларыннан «бәхет» эзләп чыгып киткән ярлы татар өчен бик характерлы дип әйтәсем килә. Дәүләкән купецларыннан кемне генә алма, аның тарихы әнә шулай башлана. Хәер, бер Дәүләкәндә генә түгел, күп җирләрдә моның ише хәлләрне күрергә була. Шул ук Үтәмишевләр дә бит хәзерге Балтач районы Мәчкәрә авылыннан, ә Уфа миллионерлары Нәзировлар исә Казан арты Битаман авылыннан чыккан кешеләр. Әмма болар башка, болар инде җәennең бик эреләре!

Дәүләкән «купичлары» турында шушы китерелгән мисаллар да, бәлки, җитәр иде. Ләкин мин тагын ике кеше язмышы турында язмыйча үтә алмыйм — калдыруы кызганыч!

Аларның берсе — Сафиулла Зәйнуллин. Бу инде Башкортстанның үзендә (хәзерге Туймазы районы Арысланбәк авылында) туган кеше. Сигез яшендә ятим калгач, аны, Уфага китереп, Хәкимов дигән байга тәрбиягә бирәләр. Хәкимов Уфаның иң зур байларыннан, заманында шәһәр үзәгендәге куш манаралы мәчетне дә шушы бай салдыра. Бу кеше турында шундый кызыклы бер риваять тә ишеткәнем бар: имеш, ул үзе дә кайчандыр яшь чагында көтүче булган, диләр. Ахырда ничектер баеп киткәч, үзенең шул иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә чөйдә генә элеп тоткан; картка алар элек кем булуын гел генә исенә төшереп торганнар... Гыйбрәтле сабак бу, минемчә.

Сафиулла шушы байда үсеп, егет булгач, солдатка алына һәм сигез ел Польша җирләрендә хезмәт итеп кайта... Кайткач, бай аны, Нәфисә исемле Малмыж кызына өйләндереп, кулына күпмедер акча биреп, Дәүләкәнгә җибәрә. Башта Сафиулла Уфа баеның малы белән сату итә, аннары тора-бара кибет тә, товар да аның үзенә күчә.

(Сәүдәсе — бакалея.) Озак та үтми, Эткол уртасында башкорттан җир алып, зур гына йорт та, таза каралтылар да салдырып җибәрә. Шулай итеп, Дәүләкәндә тагын бер Сафиулла дигән «купич» пәйда була.

Кыскасы, бер үк язмыш кичергән, бер үк юл үткән татар сәүдәгәре, әмма кеше буларак ул бөтенесеннән дә бик нык аерылып тора иде. Тышкы кыяфәте белән үк — биленә зинар[1] буып, яланбаш йөри торган иде. (Татар сәүдәгәрендә моны күрмәссең.) «Кызыл купич» дисәм, арттырып җибәрү булыр, һәрхәлдә, прогрессив карашлы, заманга иярүче бер кеше иде ул. Динне танымады, мәчеткә йөрмәде, күршесе Искәндәр ахунны да гел тәнкыйтьләп кенә торды, диләр белгән кешеләр. Коръән укыту мәҗлесләренә дә бервакытта да йөрмәгән һәм үзе дә андый мәҗлесләр үткәрмәгән. Ике улын — Барый белән Гомәрне дә — ул дин сабагына йөртмәде, ә иң зур кызы Рәкыя апаны гимназиягә биреп укытты. (Татар кызларыннан бары икәү генә — Басыйр купецның Газизәсе белән шушы Рәкыя апа гына бездә гимназисткалар иде.) Калган балалары инде совет мәктәбендә укыдылар.

Ике революция (февраль белән Октябрь) арасында Сафиулла абзый еш кына митингларда ялкынлы нотыклар да сөйләгән. Билгеле, патша төшерүне хуплап, хөрриятне яклап!.. Әйткәнемчә, заман барышын тиз сизә торган кеше булган ул. Моны аның соңгы бер кыю гамәле дә ачык күрсәтте.

Нэп дигән нәрсә бетеп, «бөек борылыш» чоры башлангач, ягъни 1929 елны Сафиулла абзый Дәүләкәннең элекке приказчикларыннан «Урал» исемендә колхоз сыман кечкенә бер артель оештыра. Волость оешмалары бу артельгә унике чакрымдагы Конягин хуторы яныннан күпмедер җир дә кисеп бирәләр. Утызынчы елны Сафиулла абзый Дәүләкәндәге йортын сатып, яңа җиргә күчә, үзенә кечерәк бер өй салып керә, калган акчасына артель өчен өч ат һәм кайбер машиналар да сатып ала. Шунда ул, колхозның җитәкчесе дә һәм көтүчесе дә булып дигәндәй, бик тырышып эшләп маташа. Әмма колхоз бик бәләкәй, бик зәгыйфь була, бер дә мантый алмый, чөнки элекке приказчикларның җир эшенә дәртләре һәм сәләтләре юк диярлек, «колхозга» язылган унике кешенең дә бары алтысы гына яңа урынга күчеп утыра. Калганнары Дәүләкәннән килеп-китеп кенә йөриләр. Шул рәвешчә, бер-ике ел эшләп азапланганнан соң, бу «Урал» ахырда якындагы «Урта тау» колхозына

[1] *Зинар, зӳннар* — кӗлмӑк ӳстеннӑн буа торган чуклы билбау.

кушыла. Сафиулла абзый менә шул колхозда, гади колхозчы булып, 1938 елга хәтле эшли. Ә 1940 елны инде ул рактан үлеп тә китә. Шулай итеп, бу тынгысыз «купич» та ахыры гомерендә үзенең чын аслына кайтып, дөньядан үтә.

Дәүләкәндәге әлеге бердәнбер диярлек дустым Гомәр шушы Сафиулла абзыйның улы, һәм атасының бу гыйбрәтле тарихын да миңа ул сөйләгән иде.

Дәүләкән байларыннан икенче бер «хикмәтле» кеше — Нәбиулла Кәримов. Билгеле, читтән килгән татар, ләкин кайсы яктан — ул кадәресен белә алмадым. Сорашыр кеше дә калмаган. Мин үскәндә, Нәбиулла Кәримов үзе юк иде инде, ләкин йорт-җирләре саклана иде әле. Дәүләкәндәге ике зур алма бакчасының берсе менә шул Кәримовныкы иде. (Мәйданы бер-ике дисәтинә чамасы булыр.) Бакча эчендә үзе яшәгән матур гына агач өе бар иде. Соңыннан бу өйдә үлгән байның җитеп килгән ике улы (Гали белән Гомәр) яшәде, һәм аларга туган тиешле Исмәгыйль исемле бер чатанрак абзый зур бакчаның хуҗасы да, каравылчысы да булып торды. (Чатан булса да, алма урларга кергән малайларны сүләндәй[1] бик капыл эләктереп ала иде.) Анары шул ук бакча белән янәшә иркен ихатада махсус фатирчылар кертер өчен бик озын итеп салынган ике катлы агач йорты һәм таш магазины да бар иде. Янә тагын Имәнлек ягында аның зур гына урманы да булган — аны «Кәримов урманы» дип йөртәләр дә иде. Кыскасы, байлыкның төрлесен биләгән Нәбиулла Кәримов. Әмма ничек баеп киткән соң бу каяндыр Эткол авылына килеп чыккан кеше?.. Безнең атайлар сөйли торган иде, имеш, ул картада бик оста уйнаган һәм күз буу (ягъни гипноз) дигән хикмәтне яхшы белгән, дип. Мәсәлән, үзенә мәҗлескә җыйган мулла һәм картларның «күзләрен буып», аларның кәвеш-каталарын суда йөзеп йөргән үрдәкләр итеп күрсәтә икән. Кунаклар, астыбызга су керә дип, хәтта урыннарыннан сикереп торалар, имеш. Инде Нәбиулланың баеп китүе дә әнә шул сәләтләре (бигрәк тә картада отуы) аркасында булган, диләр. Һәрхәлдә, буш кеше булмаган бу абзый!.. Җиләк-җимеш үстерүнең нәрсә икәнен белмәгән бер җирдә шундый зур бакча үстерүе үзе генә дә ул кешенең һәртөрле сәләткә ия булуын күрсәтсә кирәк. Тик менә әҗәлдән котылу чарасын гына таба алмаган.

Шулай итеп, күргәнебезчә, Дәүләкән купецларының барсы да диярлек Казан ягыннан килгән һәм бик түбәннән чыккан кешеләр. Ягъни аларның берсе дә «по-

[1] *Сүлән* — селәүсен (урман җәнлеге).

томственный» сәүдәгәр түгел иде. Тагы да ачыграк әйтсәк, яңа урында яңа гына туган купецлар! Моның сәбәбен дә күрдек: Эткол дигән башкорт авылы кырыннан Себер тимер юлы уза, кечкенә авыл бик тиз арада җанлы бер сәүдә урынына әверелә һәм соңга калмыйча килеп җиткән өлгер, булдыклы абзыйлар, конъюнктурадан оста файдаланып, кыска гына вакыт эчендә күтәрелеп-баеп та китәләр. Әлбәттә, һәрбер читтән килүче монда «алтын тапкан икән» дип уйлау хата булыр иде. Юк, алтын җирдә аунап ятмый ул, бик сирәк кешегә генә очрый, шул сәбәпле читтән килүчеләрнең күбесе яңа байларда йә приказчик, йә хезмәтче булып эшләргә мәҗбүр иде. Аннары төрле һөнәр иясе — тимерче, тегүче, итекче, мич чыгаручы, пима басучы, извозчикларны алсак, болар инде асылда туграк җир, күбрәк эш эзләп килгән үзенә аерым бер «кәсепчеләр» иде.

Алар турында да сүз булыр әле, ә хәзергә купецлар турындагысын бетерәсем килә. Хикмәт шунда ки, бу төркемнең «эшчәнлек» дәвере шактый кыска булып чыкты, чөнки Дәүләкәндәге сәүдә-коммерция эшләре үзе дә бик кыска гомерле булды. Бары егерме-егерме биш ел гына... Октябрь революциясе килеп җиткәндә, татар купецларының күбесе кырык биш-илле яшьләр тирәсендә генә булгандыр (арада иң «карты» Гатаулла бабай — ул гына илледән узган). Билгеле, революция аларның эшен өзде, тамырларын кисте, ләкин бөтенләй үк аяктан екмады. Кибет-малларыннан аерылсалар да, йортларыннан аерылмадылар — тагын әле берничә ел искечә торып калдылар. Әмма нэп дигән нәрсә дә үтеп киткәч, алар инде бер социаль төркем булып яшәүдән туктадылар. Шул рәвешчә, бу кешеләрнең «купичлыгы» үз гомерләренә дә җитмәде. Аталары сәүдәгәр булмаган шикелле, сәүдәгәрлек балаларына да күчмәде. Балалар язмышы бөтенләй икенче эздән китте. Һәм без монда да бик гыйбрәтле хәлләр күрәбез.

...Яңадан Борһан абзыйдан башлыйк булмаса. Аның балалары күп иде, ялгышмасам, өч улы, биш кызы бар иде. Күрше-тирә белән дә артык аралашмыйча, ничектер бикләнебрәк тыныч кына яшәгән шушы гаилә, революция булуга, кинәт кенә таркала башлый. Иң элек әле революция алдыннан гына Борһан абзыйның җәмәгате Фатыйма абыстай үлеп китә. Бу инде таркалуның башы дигән сүз. Сигез бала, иң кечесенә ике-өч яшь кенә булгандыр, караучысыз һәм саклаучысыз кала. Шуннан соң озак та үтми, гражданнар сугышы башлангач, әлеге ата-

сына ияреп магазинга йөри торган бик чибәр, бик көяз уллары Галиулла тота да, кызылларга язылып, фронтка китә. Моны миңа соңгы очрашуда энеләре әйтте, хәлбуки мин үзем күптән үк инде Галиулланы кызыллар мобилизовать иткәндер дип уйлый идем. Ләкин кайсылай гына булса да, моны егетнең бәхетеннән санарга кирәк, чөнки кызыллардан соң Дәүләкәннең күп кенә яшьләрен аклар җыеп ала. Боларның барсы да диярлек Колчак армиясендә югалып бетә, ә менә Галиулла үзе дә югалмый, киләчәген дә югалтмый.

Аннары шул ук җәйне Борһан абзыйның зур кызы Заһидә апа үзләрендә фатирга куелган бер кызыл кавалеристка — янып торган җирән чәчле мишәр егетенә ияреп китеп бара. Бу инде «мисле» булмаган гадәттән тыш вакыйга! Шушы вакыйгадан соң Борһан абзый үзе дә, вак балаларын алып, Уфага китеп тора. Сугышлар бераз тынгач, ул балаларын кире Дәүләкәнгә кайтарып куя, ләкин үзе ни өчендер яңадан Уфага китә. (Бәлки, хәвеф-хәтәрдән сакланыр өчендер.) Шулай итеп, бер заман бу гаиләдә зурлардан берәү дә калмый, җыен ыбыр-чыбыр бала-чага. Иң олысы Гайшә апага унбиш-уналты яшьләр булыр, менә шул кыз инде атасы кайтканчы гаилә башы булып тора да. Бу авыр елларны алар ничек үткәргәннәрдер дә ничек көн иткәннәрдер — хәзергә кадәр төшенә алганым юк. Мәгәр шуны гына беләм: Борһан абзыйның элек беркем дә керергә кыймаган ябык капкасы хәзер һәркемгә ачык. Без, күрше малайлары, теләсә кайчан кереп йөрибез. Хәтта әле еш кына хуҗасыз йортта «аулак өй» дә ясый торган идек. Аларда бүлмәләр күп иде, без, шуның берсенә җыелып, төрле уеннар уйнап, кич үткәрә идек. Әйтергә кирәк, моңарчы сирәк аралашкан «купич» кызлары Әминә белән Хава да, уллары Зәкәрия белән Яхъя да бик ачык күңелле, уйнарга-шаярырга ярата торган тиңдәшләр булып чыктылар. Тик минем күңелне гел үзенә тартып торган Һаҗәр турында гына алай әйтүе дөрес булмас. Ул шактый һавалы-горур кыз иде, ә бәлки, миңа карата гына шулай булгандыр.

Берме-икеме ел үткәч, Борһан абзый Уфадан Хәдичә исемле чибәр, сөйкемле генә абыстайны балалары янына алып кайтты. Үзенә никахлы хатын, балаларына, үги булса да, ана (әмма бик әйбәт ана булды, дип сөйлиләр Борһан абзый балалары). Иш янына куш дигәндәй, абыстайга ияреп, Хәким исемле минем чамадагы улы да килгән иде. Гаилә яңадан бер кыек астына җыела, бергә оеша, искечә үк булмаса да, матур, тыныч кына тора да башлый. Тагын күпмедер вакыттан соң Гайшә апаны го-

мерен Сафа байда ялчылыкта уздырган Кәфи карт малае Хәйретдин абзыйга кияүгә бирәләр. Бик ярлы кешенең баласы булса да, Хәйретдин абзый элекке «купич»ка кайсыдыр яклары белән ошаган булса кирәк, чөнки озак та үтми алар бергәләп кибет ачып, шәп кенә сату итәргә дә керешәләр. Ләкин, әйткәнебезчә, нэп дигән «иркенлек» бик кыска булып кала, тиздән «бөек борылыш» игълан ителә, һәм Борһан абзыйның сәүдәсе дә ябыла, йорты да алына, семьясы да инде бөтенләйгә тарала. Зур улы Галиулланың Кызыл Армия сафына алынуын егет өчен бәхет дип юраган идек. Чынлап та ул шулай булып чыга да: Галиулла армия сафында партиягә керә, хәрби хезмәттән бушагач, Совет органнарында эшли, республиканың Учалы районында РИК председателе дә булып тора. Яхшы ук грамоталы, зиһенле егет, үсә-үсә, ахырда Башкортстан Үзәк Башкарма Комитеты секретариатының мөдире, аннары Совнарком каршындагы дини эшләр идарәсенең җитәкчесе булуга чаклы барып җитә. Ватан сугышы башлангач, ирекле рәвештә фронтка китә һәм 1943 елны каты сугышларның берсендә хәбәрсез югала. Күпме алар, хәбәрсез югалучылар! Ә менә аның улы Ирек көнчыгыш Сахалинда нефть берләшмәсенең начальнигы булып эшли икән. Моны миңа Галиулланың энеләре әйтте[1].

Шулай ук гражданнар сугышы вакытында кызыл кавалерист — мишәр егетенә ияреп киткән Заһидә апа, дүртме-бишме елдан соң, көтмәгәндә генә атасы йортына кайтып керә. Нык үзгәргән. Теге вакыттагы сылу туташ хәзер сулган гөлгә охшабрак калган иде. Бу юлы аны икенче бер мишәр абзыеерактан, каяндыр Пенза — Рузаевка якларыннан үз аты белән, арбасына утыртып, Дәүләкәнгә алып кайта. Билал исемле бу абзый теге кавалерист кебек шәмдәй төз, таза егет түгел иде инде. Яшькә дә шактый олы, өс-башы да иске, йөз-чырае да чытык (ияген-битен каты сары төк баскан), әмма ул яхшы күңелле, намуслы кеше булган булырга тиеш. Каядыр еракта адашып калган Заһидә апаны бәхетсезлектән йолып, ничәмә йөз чакрым җирдән атасы йортына китерүе шуны расласа кирәк. Бала газиз, Борһан абзый күпме хәсрәт чиктергән кызын да, мужик кыяфәтле бу килбәтсез киявен дә кабул итә, йортыннан аларга урын да бирә. Әмма кияве аның сәүдә эшләренә бөтенләй катышмый,

[1] Шулай ук энеләренең әйтүенә караганда, Галиулла сәхнә әсәрләре дә язгалаган, кайберләре исә вакытында уйналган да икән. Бу кадәресе миңа билгеле түгел иде.— *Ә.Е.*

һәрбер мишәр шикелле, ул да ат ярата һәм бөтен көнен шул аты белән нидер эшләп йөри.

Утызынчы елларның башында Борһан абзый үлгәч, аның салкын гәүдәсен ләхеткә куючы да шушы кияве була. Балаларыннан берсе дә бу вакытта юк, таралышып беткән булганнар.

Кайда алар? Кайсы якларга очтылар икән бу оясы туздырылган «чәүкә» балалары? Мине бигрәк тә күршедә бергә уйнап үскән, инде егет булып өлгергән Зәкәрия белән Яхъя язмышы кызыксындыра иде. Ләкин аралар ерак, Дәүләкән белән элемтә күптән өзелгән, кайтып йөрү түгел, һичкем белән хат та алышканым юк. Аннары ил эчендә төрле хәлләр булып узды, тормышта бик зур үзгәрешләр булды, ул арада Бөек Ватан сугышы да башланды. Бу вакытта бертуганнар да еш кына бер-берсен югалтып тордылар... Бары тик сугыштан соң илленче елларның урталарында гына мин башта Яхъяны, аннары Зәкәрияне, ниһаять, Уфада очраттым. Бу вакытта Яхъя шәһәр үзәгендәге бер ашханәдә мөдир иде. Әле сугышка чаклы ук бик чибәр Уфа кызына өйләнгән булган, хәзер инде бишмеалтымы баласы да бар икән. Билгеле, Ватан сугышында да булган, яраланган, күп кенә орден һәм медальләр белән бүләкләнгән, званиесе — гвардии майор!..

Зәкәрия «тарихы» минем өчен тагы да көтелмәгәнчәрәк булып чыкты: атасы кебек бәләкәйрәк буйлы, юка гына гәүдәле бу егет хәрби самолетта очучы-штурман булган икән ләбаса!.. Дөрес, ул фронтта булуын булмаган, ләкин ике төрле авиация мәктәбен бик уңышлы тәмамлаганнан соң, бөтен сугыш дәвамында үзе, инструктор буларак, авиация өчен штурманнар хәзерләгән... 1957 елны гына отставкага чыга, Уфага кайта, өйләнә, квартир ала, хәзерге көндә әйбәт пенсия белән матур гына торып ята... Зәкәрия дә, Яхъя да — коммунистлар. (Һәм хатыннары да аларның бертуганнар икән.) Менә шулай. Алма агачыннан ерак төшми, диләрме? Хәер, бу очракта «алмалар» агачтан шактый ерак тәгәрәгәннәр. Әмма сорты шул ук бит! Кайчандыр Өч Мунча авылыннан малайлыкка биреп җибәрелгән, соңыннан Этколга килеп баеп киткән Борһан «купич» улларының язмышы әнә шундый — нәкъ безнең заманча!

Яки менә каршыдагы күршебез Гатаулла бабай улларын алыйк. Мин аларның иң олысы Габдрахман абзый белән иң кечесе Хәбибрахманны яхшы беләм. Калган ике улын һәм ике кызын белмим диярлек, чөнки мин үсеп, кешеләрне ныграк таный башлаганда, алар юк иде инде. (Ике улының берсе гражданнар сугышы вакытында,

икенчесе берничә ел соңрак тәмам егет булып җиткәч кенә тифтан үлгәннәр. Шулай ук кызлары да иртә киткән бу дөньядан... Хәбибрахманның әйтүенә караганда, алар барсы да укырга бик сәләтле булганнар.)

...Иң өлкәне Габдрахман абзый, ничек дим, идеалист бер кеше иде. Ул иң яхшы мәгънәдәге мөгаллим иде. Тумыштан ук мөгаллим! Һәм аның өчен мөгаллим булудан да изгерәк, кирәклерәк бүтән эш дөньяда гүя юк та иде. Шуңадыр инде ул атасының сәүдә эшләренә бервакытта да катнашмады. Бөтен хыялы һәм максаты аның татар, башкорт халкын агарту иде — шушы эшкә бөтен тәне-җаны белән бирелгән гаҗәп бер кеше иде. «Укыгыз, туганнар, укыгыз!» — Безгә аның гел кабатлап торган сүзе дә әнә шул иде.

Мин дә аңарда бер-ике кыш укып калдым. Ул зур борынлы, тирән утырган зур соры күзле, нык-таза бәдәнле, урта буйлы җыйнак кына кеше иде. Дүрт сәгать укыта икән — дүрт сәгать гел аяк өстендә, бер генә минут та утырып тору юк. Әмма ничек укыта диген?! Тәмам онытылып, ялкынланып, чын артистларча!.. Бигрәк тә әдәбият дәресен. Иң яраткан шагыйре, әлбәттә, Тукай иде. Тукайның «Пар ат»ын яки «Теләнче»сен яттан шундый сөйләп җибәрә иде, без, хәтта тыңлап беткәч тә, авызларыбызны ябарга оныта идек. Һәм бездән дә шулай көчлематур итеп, ноктасын ноктага туры китереп, яттан сөйләтергә тырыша иде... Аннары табигать дәресләрен дә ул бик яратып укыта иде. Шәкертләрне көзен яки җәй башында кырга алып чыгып, үләннәр һәм чәчәкләр белән таныштырып йөри иде — безнең өчен иң күңелле дәрес тә шушы була торган иде.

Бу урында тагын бер яңалыкны искә төшерү артык булмас: Дәүләкән башкортлары, шулай ук татарлары да, яшелчә үстерүнең нәрсә икәнен белмиләр иде. Яшел суганны да алар Марҗа базарыннан барып алалар иде. (Ә Марҗа базары төрле яшелчәгә бик бай була торган иде.) Һәм менә шул мөселманнарга Дәүләкән туфрагында яшелчәне беренче үстереп күрсәтүче дә Габдрахман абзый булды. Аның кат-кат өндәве аркасында күрше-тирә татарлар, шулай ук кайбер башкорт агайлары да, ишегаллаларын киртәләп, суган, кишер, кыяр, кабак кебек нәрсәләр утырта башладылар. (Ә 1921 елгы ачлыктан соң инде бу эш үзеннән-үзе көчәеп китте.) Дәүләкән җире шәп, ни чәчсәң дә котырып үсә — бездәге көнбагыш та кабак төше хәтле була торган иде.

Габдрахман абзый, беренче хатыны тифтан вафат булгач, безнең Каргалы кызы Мәрзия апага өйләнде. Мәрзия

апа үзе дә мөгаллимә — Мөхәммәтша тегүче өенең кечкенә бер бүлмәсендә фатир тора иде. Туйлары да шушы йортта булырга тиеш иде. Без, бер төркем малайлар, туй килгәнен күрергә дип, Мөхәммәтша абзыйның капкасы төбенә җыелдык. Кышкы шактый салкын айлы төн иде, өйнең урамга караган өч тәрәзәсендә дә утлар яна, ак пәрдәләр тартылган, ләкин өйнең эчендә дә, тышында да мондый чакта була торган хәрәкәт, ыгы-зыгы бер дә сизелми иде. Без, күпме көтсәк тә, кыңгыраулы пар атларда туй килгәнен күрмәдек. Тик шактый вакыт үткәч, бер генә ат җиккән кашовкада Габдрахман абзый ялгыз үзе генә килеп җитте. Кемдер капканы ачып, аны ишегалдына уздырды. Шуның белән барсы да бетте, тынды... (Ә никахны көндез үк укытканнар икән — монысын соңыннан ишеттек.) Без дә салкын тын урамда бераз биешеп тордык та әкренләп өйләребезгә таралыштык. Туйларны күргән бар иде — андагы кызык, шаушу, җыр-музыка!.. Әмма боларның берсен дә безнең үтә тыйнак мөгаллимебез әллә белмәгән, әллә инде кирәк дип тапмаган.

Туйдан соң «яшьләр» Гатаулла бабайның ишегалды түрендәге иске өендә бергә тора һәм бергәләп укытырга да йөри башладылар. Аларның бәхете әнә шул эшләрендә иде, башкасын алар гүя тели дә, көтә дә белмиләр иде. Хәер, бер бик көчле теләкләре булган аларның — уку, уку һәм уку!.. Менә шушы теләк белән алар, шактый олы яшьтә булуларына карамастан, икәүләп, 1930 елны Уфага, Учительләр институтына укырга китәләр.

Авыр еллар, ике балалары бар, ничек укыганнардыр да ничек яшәгәннәрдер, Хода белсен! Ә укуны бетергәч, яңадан шул ук иске, изге эшкә — Габдрахман абзый Уфаның бер башлангыч мәктәбендә мөдир, Мәрзия апа исә шунда ук рус теленнән гади укытучы. Бу эштә инде аларның гомерлеккә «чәчләре чәчкә бәйләнгән»!

Илленче елларның уртасында, беренче мәртәбә Уфага кайткач, мин Габдрахман абзыйны электән үк таныш урамнарның берсендә, баракка охшаган озын агач йорттан эзләп таптым. Бераз гаҗәпләнеп, әмма бик сөенеп каршы алды ул мине... Миңа да гаҗәпләнергә туры килде: авыр еллар Габдрахман абзыйга да тирән эзен салып узган икән. Аннары үсеп җиткән ике улының Шамил исемле зуррагы фаҗигале рәвештә үлгән дип тә ишеткән идем. Әйе, хөрмәтле укытучым шактый ук картайган да, суырылган да, йөзе дә саргайган, күзләре дә эчкәрәк бата төшкән, ләкин үзе әүвәлгечә дәртле сөйләшә, елмая, сораша, әмма үз хәсрәте турында ник бер сүз әйтсен!.. Ми-

нем әдәбиятта яңадан күренә башлаган чагым иде, шуны белгәч, чын ихластан куанды ул... Без сөйләшеп утырган бүлмә бик тыгыз иде. Унике квадрат метрда дүрт кеше — үзе, Мәрзия апа, өйләнгән улы белән яшь киленнәре торалар. Ике карават (берсенә чаршау корылган), уртада өстәл, урындыклар, ишекнең бер ягында савыт-сабалар өстәле, икенче ягында киемнәр элгече — кыскасы, борылыр урын да юк. Мондый шартларда тору өчен нинди сабырлык кирәк!.. Уллары Искәндәр — урман хуҗалыгы институтын уңышлы тәмамлаган яшь белгеч. Ул, билгеле, квартир алу хәстәре артыннан йөри башлый. Шул арада Габдрахман абзый да авырып китә... Аны күбрәк килене карый — килен үзе, врач булу өстенә, бик кече җанлы, бик итагатьле кыз булып чыга. Шактый көч һәм вакыт сарыф итеп йөргәннән соң, аларга, ниһаять, өч бүлмәле квартир бирергә булалар. Шул чагында Габдрахман абзый улына әйткән:

— Искәндәр улым, әллә сабыр итеп торабызмы? Юеш подвалларда торучылар да бар бит әле, алардан элек яңаны алу безгә килешмәс! — дигән.

Соңыннан моны ишеткәч, минем дә ачынып әйтәсем килде: «Их, мөгаллим, мөгаллим, шулхәтле дә изге җан булырга ярыймы соң бу заманда?! Куй, йә кешеләрнең ачуын китерерсең!..»

Яңа квартирга күчкәч, Габдрахман абзый бер генә ел торып калган. Белмим, бу кыска гына вакыт эчендә ул иркенрәк квартирда торуның рәхәтен әзрәк татый алды микән, әллә булмаса һаман да шул «подвалларда яшәүчеләр»дән тартынып-оялып дөньядан китеп барганмы?!

Ә менә Мәрзия апа Габдрахман абзыйга караганда озын гомерле булды. Улы белән килене тәрбиясендә кадер-хөрмәттә яшәп, ул сиксән биш яшенә җиткәч дөнья куйды... Әйе, яхшылар да, начарлар да иртәме-соңмы бу дөньядан китәләр. Начары кеше буларак шунда ук онытыла, ә яхшысы гомер буена диярлек онытылмый. Әгәр аның кайбер сыйфатларын балаларында да күрсәң, кешеләргә ничектер ышаныч арта, тормыш үзе дә яктырак, рәхимлерәк булып күренә башлый. Быел Уфага кайтып, Искәндәр белән очрашкач, мин әнә шундый бик әйбәт, тансык, кадерле бер хис кичердем.

Гатаулла бабайның иң кече улы Хәбибрахман миннән өч яшькә олырак. Габдрахман абзый белән Хәбибрахман арасында туган балаларның үсеп, тәмам егет һәм туташ булып җиткәч кенә үлеп китүләрен әйткән идем инде... Ул заманда ике төрле чир — чахотка белән тиф — яшьләрне аеруча кырды. Картның да ике улын тиф, ике кы-

зын чахотка алып китте. Бер сабыйны югалту да хәзер ата-ана өчен зур фаҗига, ә тап-таза егетләр белән буй җиткән кызларны югалтуның хәсрәтен ничек кенә күтәрергә мөмкин икән?! Әйе, искиткеч чыдам булган ул чакта картларның йөрәге!..

Хәбибрахман үзе дә бала чактан ук тазалыкка туймады. Аның бер аягында сөяк туберкулезы иде, шуның белән ул берничә ел азапланды, берничә мәртәбә озак-озак кына больницада да ятып чыкты. Малай чагында аңа чабып, уйнап йөрергә күп туры килмәде. (Хәлбуки, әйтүенә караганда, чабарга бик яраткан.) Безнең уйнаганны да ул, капка төбенә чыгып, култык таякларына таянып, баганага сөялеп, читтән генә бик кызыгып карап тора иде. Менә шул авыруы аркасында, гәрчә урам аша гына торсак та, мин Хәбибрахманның малай чагын юньләп белми дә, күрми дә калдым. Тик бер тапкыр Дәүләкән читендәге больницага, кемнәргәдер ияреп, аның хәлен белергә баруымны гына әзрәк хәтерлим. Әмма аның каравы без икебез дә 1925 елны Казанга барып, шунда очрашкач, бик якынаеп, дуслашып киттек. Һәм бу дуслык гомеребез буена һич сүрелмичә, өзелмичә дәвам итте. Һәм хәзер дә шулай дәвам итә!

Больницада яткан чагында аның аягын кисмәкче дә булганнар, ләкин ул кисәргә бирмәгән аягын. «Үләсең!» — дигәннәр аңа. «Үз аягым белә үләм»,— дигән ул... Торып-торып шуңа исе китә һәм куана Хәбибрахман хәзер дә: «Миңа бит уникe генә яшь иде, ничек акылларым җиткән!» — ди. Аяк әкренләп булса да төзәлә, тик Хәбибрахман әзрәк аксый торган булып кына кала. Җитмеш биш яшьлек картым рәхәтләнеп йөрү генә түгел, дәрте килсә, яшь ханымнарның биленнән алып, танцевать та итеп җибәрә.

Хәбибрахман бала чактан ук укырга гаять сәләтле булган икән. Еллап авыруына карамастан, ул үзлегеннән укуын дәвам иттерә, ә аягына баскач, Бәләбәйгә барып, ике ел эчендә урта мәктәпне бетереп кайта. Егерме бишенче елны Казанга барып, университетның медицина факультетына укырга да керә. Имтиханнарын да җиңел генә бирә. Шулай итеп, моңарчы рәсемнәрдә генә күрергә туры килгән мәһабәт колонналы ак бинаның озын коридорында сары кайры тун, төпле пималар кигән, азрак кына шадра бер Эткол егете аксый-туксый укып йөри башлый. Әмма бу уку аңа, әйтергә кирәк, чын куаныч белән бергә зур газап та китерә. Ятимнең авызы ашка тисә, борыны бозга тия, диләрме, шуның шикелле, тырышып кына укып йөргәндә, аның сәламәтлеге яңадан на-

чарлана: әлеге чахотка дигән әшәке-хәтәр авыру үпкәләренә күчә — менә шул авыруы белән көрәшә-көрәшә укый ул... Соңгы курска җиткәндә инде ул кан төкерә иде, хәле бик мөшкел иде. (Бу чакта без аның белән Кирпеч заводы урамында, чокыр төбендәге бер йортта икәү бергә тордык.) «Кем кемне алдан бетерә инде, мин медфакнымы, әллә чахотка минеме?» — ди иде Хәбибрахман, еш кына көләргә тырышып. Менә шушы хәлендә дә ул, дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, медфакны бетереп чыкты һәм, чыгу белән артык бер көн дә тормыйча, Кырымга китеп тә барды. Бу утызынчы ел җәенең кояшлы бер иртәсе иде. Иске чемоданын һәм каеш белән буган медицина китапларын күтәрешеп, мин аны Казан вокзалында озатып калдым. Хәерле юл, хәерле сәгатьтә!..

Аның бар өмете Кырымда иде. Шунда эшләргә дә, шунда сәламәтләнергә дә тиеш иде ул. Ләкин китүенә берничә ай үтте микән, Кырымнан кайткан бер таныш миңа очрап, Хәбибрахманның авыр хәлдә больницага кереп ятуын сөйләп торды. Дөрес, ул үзе аны күрмәгән, ләкин кемнәндер шулай дип ишеткән. Мин моңа, билгеле, ышана калдым һәм Хәбибрахман белән бергә укыган, шул сәбәпле аның хәлен яхшы белгән кайбер иптәшләренә тизрәк хәбәр тә иттем. Уйлаштык-киңәштек тә, үзара акча җыеп, Хәбибрахманга җибәрергә булдык. (Башка ярдәм итәрлек чарабыз юк иде.) Хәбибрахман исә Кырымнан миңа нинди санаторийда эшли башлавын язган иде инде. Шул сәбәпле акчаны җыючы да, җибәрүче дә мин булдым. Ләкин нишләптер озак кына хәбәр булмыйча торды, күңелгә төрле шикләр килә башлады. Акчабыз барып җитмәдеме, әллә инде... соңга калдымы?.. Шулай ни уйларга белмичә хәвефләнеп торган чакта, ниһаять, егетебездән хат килеп төште. Бик күп рәхмәт әйткән, сезнең кебек дуслар булуына бик сөендем, дигән, ләкин юкка борчылгансыз, минем больницага кергәнем юк, әйбәт кенә эшләп ятам, сәламәтлегем дә ул хәтле үк начар түгел. Кырым һавасының шифасын да әкренләп сизә башладым инде, дип язган.

Җыеп җибәргән акчабыз күпме генә булгандыр инде, әмма Хәбибрахман аны гомере буена диярлек онытмады. Ә Кырымга китеп ул бик дөрес эшләгән икән. Кырым аны, чынлап та, аякка бастырды. Авыруын да җиңде, бәхетен дә шунда тапты.

1937 елны инде Хәбибрахман үзе миңа ярдәм кулын сузды. Үзегез беләсез, бу бик тынгысыз, хәвефле бер вакыт иде. Азәрбайҗанның бер районында ярты ел

эшләгәннән соң, минем, Бакуга килеп, кая барырга, нишләргә белмичә аптырап йөргән чагым иде. Хәбибрахманга кыскача гына хат яздым. Озак та үтми аңардан чакырып җавап та һәм юллык акча да килде. Безнең җиде ел инде күрешкәнебез юк иде. Хатын белән баланы Казанга озаттым да үзем Кырымга китеп бардым. Башта поезд белән Севастопольгә, аннан кечкенә пароходта Ялтага, Ялтадан җәяүләп кенә Кориез дигән җиргә... Уналты чакрымлык бу араны, һич тә таныш булмаган бик әйләнчек юлдан бер дә адашмыйча, мин җиңел генә барып та җиттем. (Яшь чак шул! Хәбибрахманның исе китте, ник хәбәр итмәдең, дип тиргәп тә алды. «Эмка» машинасында гына каршы алмакчы булган икән ул мине...)

Яшь чаклар өчен җиде ел аз вакыт түгел. Бу вакыт эчендә Хәбибрахман сәламәтлеген ныгыткан, таза ирләр төсе кергән үзенә, азрак шадра йөзе дә тулыланып, шомарып киткән һәм иң мөһиме — бик матур яшь кенә Кырым кызына өйләнгән, инде ике баласы да бар икән. Әмма мине тагын да гаҗәпләндергәне һәм сөендергәне — ул, баксаң, фиркасыз көенә Партия Үзәк Комитеты карамагындагы иң шәп санаторийның баш врачы да булып өлгергән!.. (Кырымга барып йөрүчеләр бу санаторийны белергә тиешләр — ул Кориез дигән җирдә. «Тау кояшы» дип атала иде.) Хикмәт нәрсәдә? Хикмәт шунда ки, Хәбибрахман, Гатаулла карт малае, шактый тиз арада үзен яхшы, төпле врач итеп кенә түгел, санаторий эшен бик оста оештыручы чын, тырыш җитәкче итеп тә таныта. Шуңа күрә дә ул җитмеш яшенә чаклы бөтен гомерен төрле җирдәге зур санаторийларда гел баш врач булып уздырды. (Билгеле, Кырымда чакта ук партиягә дә керде.) Бары сугыш вакытында гына семьясы белән Татарстанга кайтып, Арчадагы немец әсирләре госпиталенең начальнигы булып торды. Врач эше — кешене, аның кем генә булуына карамастан, дәвалау, үлемнән коткару — шуңа ул врачлык дипломын алган чакта ук ант та иткән. Терелеп, аякка басып, сугыш беткәч, иленә җибәрелгән немец солдатлары хәрби гимнастерка өстеннән ак халат кигән, көне-төне алар өчен аксый-аксый чапкан, тырышкан бу татар начальнигын һәм аның кул астында эшләүче врачларны, шәфкать туташларын, бәлки, әле хәзер дә рәхмәт укый-укый исләренә төшерә торганнардыр. Әгәр кеше булсалар, әлбәттә!

Әзрәк читкә тайпылдым шикелле. Хуш, мин бит әле Кырымда, Хәбибрахманның кунагы... Санаториенең ремонтка ябылган чагы икән, ял итүчеләр юк, миңа ул бик

чибәр бинадан бик шәп җиһазлы иркен бер бүлмә бирде, шушында рәхәтләнеп тор, ял ит, диде. Үзе ул ремонт эшләре белән төрле якка гел йөреп тора иде. Ләкин күрә: миңа аңардан башка бер дә күңелле түгел, шуннан соң кая гына барса да, ул мине үзеннән калдырмас булды. Ул елларда машиналар күп түгел иде әле, шулай да Хәбибрахманның персональ машинасы бар иде. (ЦК санаториеның баш врачы бит!) Утырабыз да китәбез. Монда юллар әйләнмәле дә борылмалы. Бер якта киерелеп яткан зәңгәр диңгез, икенче якта текә-текә кыя таулар... Күп йөретте Хәбибрахман мине, Кырымның бөтен матур җирләрен күрсәтеп чыкты. Әмма бу йөрүләрнең минем өчен иң әһәмиятлесе — Галимҗан Ибраһимовны күреп китү булды. Авыру әдипне Хәбибрахман бер-ике тапкыр үз санаториена алып, дәвалаган-караган, шуның аркасында алар арасында бик әйбәт якын мөнәсәбәт тә урнашып калган. Ялтага барган саен Хәбибрахман әдип янына кереп, хәлен белеп чыга торган иде. Минем китәр вакыт якынлашкач, ул мине дә, кыстый-кыстый, Галимҗан ага янына алып керде. Бу турыда мин «Әдипнең терелеп кайтуы» дигән мәкаләмдә язган идем инде, шул сәбәпле яңадан кабатланасым килми, тик шуны гына әйтергә тиешмен ки, олы әдип белән күрешү-сөйләшү һәм аның шул чактагы кыяфәте минем хәтердә гомерлеккә диярлек сакланып калды. Күңел түрендәге бер хәзинә дияр идем мин моны... Хәбибрахман мине ике айга якын җибәрмичә үзендә тотты, төрле очрашулар да (мәсәлән, Такташның беренче хатыны Гөлчирә Хәмзинә белән) аз булмады, ләкин боларны искә төшерә башласам, бик читкә кереп китәрмен дип куркам. Сүз Дәүләкәннән ерак китмәскә тиеш.

Әйткәнемчә, Хәбибрахман бөтен гомерен санаторийларда эшләп уздырды. Соңгы бер егерме елын Звенигородтагы МК санаториеның баш врачы булып эшләде — бары җитмеш яшенә җиткәндә генә пенсиягә чыга алды. Бу санаторийның бинасы да иске заманның бер бай аристократыннан калган, зур парк эчендәге ак колонналы бик шәп сарай. Бирегә килеп ял итүчеләр дә карт большевиклар белән югары урындагы работниклар — үзенә аерым бер контингент дияргә була. Егерме ел буена шушы «контингент»ка ярар өчен баш врачның ниндирәк кеше булырга тиешлеген сөйләп тору артык, минемчә. Әмма шунысы гыйбрәтле: бу зур санаторийда ул бердәнбер татар, ләкин бөтенесе аңа түбәнчелек белән «Хәбиб Гатауллович» дип кенә торалар. Шушы үзе генә дә кешенең эштәге авторитетын гына түгел, аның кайбер баш-

ка якларын да аңлатса кирәк. Ул — РСФСРның атказанган врачы.

Хәбибрахман белән минем дуслык, күргәнебезчә, бик борыннан килә. Бу дуслык һәрвакытта бик саф, бик җылы булды, аңа бервакытта да әз генә дә кер-тап төшмәде. Мәскәүгә яки Малеевкага барсам, без очрашмыйча калмыйбыз: йә мин аның янына барып чыгам, йә ул үзе минем янга килә. Серләребез килешә, сөйләшеп туймыйбыз — өч көн тоташтан сөйләшсәк тә, сүзебез бетмәс кебек. Ул миңа бик әйбәт киңәшләр бирә, аеруча сәламәтлекне ничек итеп саклау турында, тик мин, юньсез, аның әйткәннәрен үти генә белмим... Хәбибрахман ул, гомумән, бик ярдәмчел, агасы Габдрахман абзый кебек, шулай ук атасы кебек тә дип өстисем килә. Гадәттә, без бит купецта кешелек сыйфаты күрергә өйрәнмәгәнбез, әмма шушы Гатаулла «купич», егерме беренче елның коточкыч ачлыгында тәмам үлем чигенә килеп җиткән тол хатын Лотфия җиңгине ике малае белән үзенең йортына кертеп, аларга җылы урын бирә, ризык бирә. Ике малайның олысы — Фәтхелислам, кечесе — Миңнеислам; аталары исә грузчик Мансур агай 1918 елны тифтан үлгән. Лотфия җиңги бик юаш, бик тыйнак бер хатын иде, бичара! Хәерчелек баштан ашкан, җөйләре сүтек ике мендәрдән һәм сәләмә юрганнан башка һичниләре юк — менә шуларны Гатаулла карт ач үлемнән коткарып кала.

Фәтхелислам да, Миңнеислам да минем бергә үскән дусларым иде, алар турында алда сүз булачак әле. Тик бу урында әйтәсем килә: алар соңыннан кем булып, нинди дәрәҗәгә ирешсәләр дә, Гатаулла бабайларын бервакытта да онытмадылар. Чөнки кемгә бурычлы булуларын бик яхшы аңлыйлар иде.

Купецларның Гатаулла карт кебек ярлылыктан байлыкка ирешкәннәре рәхим-шәфкатьтән бер дә мәхрүм түгелләр иде — мин моның мисалларын ишетеп тә, күреп тә беләм. Аннары кеше нинди сынаулар аша үтә һәм ничек үтә — шуны да онытмаска кирәк. Утызынчы елларның башында Гатаулла картны йортыннан чыгаралар, ләкин ул бүтәннәр шикелле Дәүләкәнне ташлап китми. Төнге каравылчы булып эшкә керә, ә көндезләрен «Заготконтора»ның атларын карый. Эш-хезмәт — аның стихиясе, күргән, татыган ул аны, шул сәбәпле «купич»лыктан кире кара эшкә күчү аның өчен зур бәхетсезлектән саналмаган... Хатыны Рокыя апай да тегү артелендә эшли, ударница дип аны газетага да мактап язалар. Шулай яшиләр алар. Карт сиксән биш яшенә хәтле эшли, аннан пенсия ала башлый. Туксаннан да узып китә

ул! 1937 елны мин аны Кырымда күргәндә (Хәбибрахман янына кунакка килгән чагы), аңа җитмеш җиде яшь иде. Кечерәк буйлы җыйнак кына карт, иңбашлары әзрәк салынкы, кара-көрән муенында аркылы-торкылы сызыклар, шуңадыр, ахрысы, ул бөтен торыш-килбәте белән каты агач тамырын хәтерләтә иде. Хәбибрахманның әйтүенә караганда, бабай, бәлки, йөзгә дә җиткән булыр иде, ләкин, бәхетсезлегенә каршы, кышкы томанлы көннәрнең берсендә ул, тимер юл аша чыкканда, поездга тапталып һәлак була... Чиканастан бәхет эзләп чыгып киткән ярлы татарның язмышы әнә шулай тәгәлләнә.

Әйтергә кирәк, Дәүләкәннең нәкъ уртасыннан узган тимер юлда моның ише фаҗигале үлемнәр ара-тирә һаман булгалап тора икән, чөнки бу юлда хәрәкәт гаять көчле, озын авыр составлар биш-ун минут саен диярлек коточкыч тизлек белән бер-бер артлы үтеп кенә торалар. Кайткан чакларда мин моны үзем дә күреп, бик курыкканым бар. Дөрес, сугыштан соң шактый вакыт узгач, юллар аша биек тимер күпер салдылар, ләкин адәм дигәнең, күпергә менеп-төшеп йөрисе килмичә, хәтәр җирдән туры гына үтеп китәргә ярата... Һәм кайчагында авыр составның ажгырып килеп җиткәнен сизми дә кала...

Сүз моңарчы татар «купич»ларының балалары турында барды. Алар күп һәм барсы турында язып торуның, минемчә, кирәге дә юк. Шуңа күрә мин мисал өчен үземә бик яхшы таныш булган ике күршебезнең уллары белән генә чикләндем. Ләкин шулар мисалында да «купич» балалары турында билгеле бер нәтиҗә ясарга була.

Иң элек шуны әйтергә кирәк, сәүдәгәр балалары без кичергән заманның мәгълүм бер чорында «чит элемент» булып саналалар иде. «Чит элемент»ка эшкә керүе дә авыр, уку йортларының да ишекләре ябык иде. Шуңа карамастан аларның берсе дә сукбайга әйләнмәде, начар юлга кереп китмәде, кыскасы, юкка чыкмады. Дөрес, егерменче елларның ахырларында алар берәм-берәм каядыр китә, тарала башладылар һәм озак кына югалып та тордылар. Еллар узды, заманнар үзгәрде, чыгыш өчен кагулар да бетерелде, ниһаять, Бөек Ватан сугышы да үтеп китте. Менә шуннан соң «купич» малайларының исән калганнары берәм-берәм табыла башлады. Кайсы врач, кайсы инженер, кайсы сәүдә яки хуҗалык эшендә, күбесе партиягә дә кергән. Гаҗәп иде бу, бигрәк тә минем өчен, чөнки мин үзем дә шулар җөмләсеннән, ләкин алар кебек үземә тиз генә һәм ансат кына юл ера алмадым. Күрәсең, миңа караганда акыллырак булганнардыр инде. Һәрхәлдә, дөресен әйтергә кирәк, бу «купич» то-

кымы, рус әйтмешли, чынлап та, бик «живучий», бик тырыш һәм сәләтле дә булып чыкты. Мисаллары җитәрлек. Фамилияләрен атау кирәк тә түгел.

Мин менә Дәүләкән купецлары турында шактый озын итеп сөйләдем. Чөнки татар халкының кая гына барсаң да очрый торган бу төркем кешеләренең язмышы шактый гыйбрәтле, моңарчы безнең мемуар әдәбиятында юньләп чагылганы да юк, шул сәбәпле алар турында белгәннәремне язып калдыру бер дә язык булмас дип санадым. Ләкин укучыларга минем бу язганнарым бер генә яклы булып тоелмасын өчен әйтәсем килә: һәр җирдәге шикелле үк, Дәүләкәндә дә сәүдәгәрләргә караганда хезмәт ияләре, әлбәттә, берничә тапкыр күбрәк иде. Алар турында хәзергә сүз бармый икән, моның сәбәбе бер генә: мин үскәндә яшәгән хезмәт иясенең язмышында зигзаглар юк диярлек. Революциядән соң аның язмышы бары яхшыга таба үзгәрде. Бу инде күп тапкырлар кабатланган хакыйкать. Ә китап, үзегез беләсез, күп кабатлауны яратмый.

## ОЛЫ ЮЛ ӨСТЕ

Дәүләкәннең янә бер кызыклы ягы — авылга да охшамаган, кала да булып танылмаган, әмма бик җанлы сәүдә үзәгенә әверелгән шушы җирдә күптөрле милләт халкы яши иде. Башта әйткәнебезчә, аларны бирегә әлеге Себер тимер юлы төрле яктан тартып китергән. Төп халкы башкорт, аннары татар, рус, немец, яһүд, чуваш, тагын берән-сәрән һәртөрле милләт кешесе — хәтта монда үз йорты белән торучы чегән дә һәм Кавказ якларыннан килеп чыккан самоварлар ямаучы чиркәс тә бар иде. Чегәннең эше-кәсебе нәрсә булгандыр, белмим, ләкин бездән артык ерак та түгел урамга буй салынган шактый чибәр яшел йортын яхшы хәтерлим. Һәр елны бу чегән, кар китеп кырлар яшәргәч тә, ике атын киндер көймәле зур арбасына җигеп, шуңа әллә нихәтле төеннәрен һәм бер оя бала-чагасын төяп, каядыр читтә йөрүче үз чегәннәре янына чыгып китә, бөтен җәен шулар белән бергә бер таборда уздыра, тик салкын көз җиткәч кенә, яңадан үз йортына кайтып керә торган иде.

Сан ягыннан халыкның күпчелеге мин үскәндә руслар иде. Алардан кала башкорт белән татарлар, аннары немецлар һәм башкалар китә. Башта, әлбәттә, төп халык күпчелек тәшкил иткән. Ләкин читтән килүчеләр арта барган саен, милли состав бик тиз үзгәрә. Кызганычка каршы, бу хактагы иске мәгълүматларны мин таба алмадым.

Дәүләкән (дөресрәге — Эткол) арта-зурая башлаган чакта, бу халыклар бер-берсеннән аерылыбрак утырганнар. Мәсәлән, Этколның буеннан-буена сузылган иң төп, иң озын урамында тоташтан диярлек башкортлар белән татарлар яши. (Алар арасында рус йортлары бик сирәк иде.) Шул ук урамның бары югары очында гына күбрәк руслар тора иде. Янә тимер юлга караган чиркәү урамы тоташы белән русларныкы иде. Вокзал тирәсендә, Дәүләкән чокыры буендагы урамнарда да руслар күпчелек иде, ә менә «выгон» дигән җирдә инде бары руслар гына иде.

Немецларга килсәк, болар инде тимер юлның аръягында үзләренә аерым бер төбәк булып утыралар иде. Шуңа күрә бу төбәкне «нимеч ягы» дип кенә йөртә дә идек. Алар ягына барып чыксаң, бөтенләй икенче бер бистәгә кергәндәй буласың. Монда урамнар киң, яшел чирәм, йортлары да, каралтылары да ак кирпечтән, таза-матур, һәркайсында җиләк-җимеш бакчасы, ишегаллаларында оя-оя төрле эре чәчәкләр үсеп утыра. Бөтен җирдә тәртип, чисталык. Мин хәтта малай башым белән аларның бер йортына тәмам гашыйк та булган идем. Йорт без Чагыл тавына үтеп йөри торган урам өстендә иде. Аның бик матур чардагы да һәм вак кына пыяла өлгеләрдән торган верандасы да бар иде. Үзе ул ап-ак йорт, әмма нечкә бизәкләр белән сырлап эшләнгән кәрнизләре, тәрәзә башлары, веранда рамнары — барсы да ачык сарыга буялган, шунлыктан бөтен йорт ничектер бик җиңел дә, бик нәфис тә булып күренә иде. Җитмәсә әле, веранда каршындагы бакча уртасында су атып тора торган түгәрәк фонтаны да бар иде. Мин бу йорт яныннан узып кына китә алмый идем, туктап аңа карап торырга ярата идем һәм, үскәч, хәлемнән килсә, мин дә шушындый йорт салдырырмын әле, дип хыяллана да торган идем. Билгеле, кысыр хыял иде бу, әмма матур йортларга соклану миндә шул чактан ук сакланып калмады микән?! Чөнки кай илгә, кайсы шәһәргә генә барып чыксам да, иң элек аның йортларын карап йөрү минем гомерлек гадәтемә керде дияргә ярый. (Матур йорт, матур йортта матур тормыш һәм матур кешеләрне күрәсе килү — бу бит, чынлап та, бик мавыктыргыч!)

Илленче елларның урталарында Дәүләкәнгә кайтып йөри башлагач, кайчандыр мине шулхәтле сокландырган бу йортны күреп исем китте. Аны май заводына әйләндергәннәр. Янәшәсенә таштан аран шикелле нәрсә салып, шуның белән тоташтырганнар. Стенасын ватып, ишек уйганнар. Челтәр өлгеле верандасы юк, элекке би-

зәкләреннән берни дә калмаган. Кыскасы, нәфис кыз шикелле теге йорт тәмам өтелгән бер карчык кәяфәтенә кергән. Әйләнәсендә бидон төяп килгән арбалар, машиналар — койма буйлары, ишегалды тапталып, чүпләнеп беткән... Акылым җитмәде минем бу күренешкә... Май заводы, әлбәттә, бик кирәкле нәрсә, ләкин аның өчен Дәүләкәндә бу йорттан башка да тазарак, гадирәк берәр бина табылмас идемени? Күрәсең, гүзәллек белән нәфәсәтне саклау турында уйлап караучы да булмагандыр инде. Материал ихтыяҗга матурлык киртә була аламыни?! Билгеле, юк.

Немец малайларын бик усал дип әйтә торганнар иде. Урамнарына барып чыккан чит малайларны, бигрәк тә рус малайларын гел тукмап җибәрәләр, имеш. Ләкин без үскәндә алар ягыннан күпме үтеп йөрсәк тә, «нимеч» малайлары белән бервакытта да очрашырга да, бәрелешергә дә туры килмәде. Гомумән, очрамыйлар иде, кайда алар, нишлиләр — Хода белсен! Тик ике катлы ак кирпеч мәктәпләре яныннан узганда, шуның иркен ихатасында бик пөхтә киенгән немец балаларының артык шауламыйча гына таган атынуларын яки куышып уйнауларын күреп китә идек. Зурраклары, күрәсең, тегермәндә яки хуторда эштә булганнардыр инде. Алар безнең кебек бушка урам таптамыйлар иде.

Әйе, немецлар башка халык иде. Иң зур тегермәннәрнең хуҗалары алар, төрле сәүдә фирмаларының хуҗалары алар, хутор биләп, зур мәйданнарда иген игүчеләр дә алар иде. Революциягә кадәр ул шулай булган, революциядән соң байлары кая киткәндер — ул кадәресен белмим. Әмма калганнары һаман әле үзләренә аерым бер төбәк булып яшиләр, гыйбадәтханәләре дә, мәктәпләре дә аерым — бары үзләре өчен генә. Татар, башкорт, хәтта рус белән дә аралашу, йөрешү юк иде бугай. (Билгеле, эш, алыш-биреш мөнәсәбәтеннән башка.) Һәм гаҗәп хәл: шушы «өстен» милләтнең бер чибәре белән миңа шулай да бераз гына «гулять» итеп алырга туры килде.

Читкә чыгыбрак булса да, мин бу вакыйганы сөйлим әле: бер төрләндереп алу зарар итмәс, югыйсә сизәм, «хикәятнамәм» бик коры бара кебек.

Бу «роман», дип әйтик инде, мин егет булып, Казаннан Дәүләкәнгә кайтып йөргән чакларда, ягъни 1927—1928 елларда булып алды. Кыз Лида исемле иде. Әгәр ул «нимеч ягы»нда торса, билгеле, бернинди очрашу да, танышу да булмаган булыр иде. Ләкин аның әтиләре татар-башкорт ягында, тагы да төгәлрәк әйткәндә, Якорь тегермәне янында торалар иде. (Ә Якорь тегермәне ул

немецлар Димне буып салдырган иң зур, иң мәшһүр тегермәннәрнең берсе иде.) Ихтимал, Лиданың әтисе элек тегермән хуҗаларының берсе булгандыр, әмма Совет вакытында инде ул шунда белгеч-мастер буларак эшли иде. Торган йортлары да аларның бик шәп таш йорт иде. Янә килеп, шул ук тегермән территориясендә безнең Гөлсем исемле бер назлы гына кызыбыз да тора иде. Һәм шунда ук «кызыл почмак» дип аталган зур гына бүрәнә йорт та бар иде — без, татар яшьләре, менә шул йортка җыелышка-мазарга баргалый да торган идек. Билгеле, ул чакта әле безнең арада бернинди немец кызы да, марҗа кызы да булмый торган иде. Ләкин шулай да теге Лида дигән «нимеч» чибәре безнең килеп-китеп йөргәнне һаман күргәли икән. Һәм ни сәбәптер шул чакта аның күзе миңа төшкән. Гөлсемнән кызыксынып: «Бу егетегез кем?» — дип сораган, аннары бер дә кыенсынып тормыйча, үзе белән таныштырырга да кушкан. Шулай итеп, Гөлсем безне таныштырды.

Йә, шуннан соң ни булды? Бик яхшы хәтерлим: иң беренче эш итеп без, Лида теләге белән, Димдә өчәүләп көймәдә йөрдек. Мин ашыкмыйча ипләп кенә ишәм, Лида каршымда утыра, ә Гөлсем көймәнең иң түрендә, гүя безгә игътибар итмәгән булып, авыз эченнән әкрен генә нидер көйләп бара. Ул безнең җыр яратучан бер моңлы кызыбыз иде. Лиданың өстендә ак ефәктән юка гына кофта, кара юбка, аягында нәрсә иде — хәтерләмим. Күзләрем гел аның йөзендә. Әйтергә кирәк, ул бер дә немец кызларына охшамаган иде. Немец кызлары бит, гадәттә, йә аксыл, йә җирән чәчле булалар, ә бу нәкъ чегән кызыдай чем-кара чәчле, нечкә кара кашлы, кара энҗедәй кечерәк кенә күзле, әмма йөзе сөттәй ап-ак һәм бик чиста да иде. Әлбәттә, ул бик матур, бик нәфис кыз иде — биле дә чегәннәрнекедәй нечкә, күкрәкләре дә тулы гына иде. Хәтта колагындагы алкалары да, чегән кызларыныкы шикелле, зур түгәрәк алкалар иде. Мондый сылу белән минем әле беренче танышуым, шуңа күрә миңа аның алдында үземне «тота белү» бер дә җиңел түгел иде. (Бигрәк тә русча тел зәгыйфьлеге мине бик «изә» иде.) Лида, шуны сизгәндәй, күбрәк үзе җанланып нидер сөйләнә, ә мин тырышып-тырышып ишүемне генә беләм. (Биргән сорауларына да баш кагып «да», «нет» белән генә чикләнәм.)

...Кызларымны мин Кара яр ерымы аша Димнең үренә алып чыктым. Бераз бара төшкәч, анда елганың киңәеп киткән бик матур урыны бар иде. Күпме генә килеп йөргән урын булмасын, әмма матурлык ул күргән саен

барыбер сокландыра. Кызларым да бик куандылар, мин ишүдән туктадым, көймәне агым ихтыярына куйдым. Тирә-ягыбызга каранып, сокланып, рәхәт татып утырабыз. Көймә әкрен генә яр читенә якынлашкач, Лида яңа гына ачылган ап-ак эре төнбоек чәчәкләрен озын саплары белән бергә судан суырып-суырып алды. Төнбоек чәчәкләре суда чакта бик матурлар, әмма өзгәч алар бик тиз шиңәләр... Кыскасы, без көймәдә бик күңелле йөреп кайттык.

Шуннан соң?.. Шуннан соң без тагын берничә тапкыр очрашып, кичен читтәге буш урамнарда йөрдек, айлы төндә берәрсенең капка төбендәге күләгә караңгылаган эскәмиясендә иңне-иңгә терәбрәк утырдык. Минем бәхеттән, кызым шат күңелле иде. Сөйләнә, көлә, шаярта, кыскасы, бер дә «скучать» итми иде. Һәм миңа да инде аның көенә җайлашып, үземне беркадәр хөр тотарга, көләргә, хәтта сүзен табып көлдереп тә алырга туры килә иде. Дөрес, башта ук бер нәрсә минем өчен бик ачык иде: бу очрашып йөрүләрнең җитди төс алуы, тирәнгә кереп китүе һич тә мөмкин түгел. Аерма бик зур. Асылда Лида өчен бер татар егете белән «йөреп карау» ул кызыклы мавыгу гына булырга тиеш иде. Мин моны ничектер сизә идем һәм үземне аңа һич тә тиң кеше итеп санамый идем. Шуның өстенә әле мин үзебезнең егетләр һәм кызлардан да шактый уңайсызлана идем. Белә калсалар, берәүләре: «Әмир әнә кем белән чиерттерә икән, малай!» — дип көләчәкләр, ә икенчеләре, ихтимал, каты гына хөкем дә итәрләр иде. Ул елларда үтә актив комсомоллар берәр егет белән кызның, коллективтан аерылып, ялгыз йөрүләрен бер дә яратмыйлар иде.

Әмма кыз әйбәт, кыз матур, кыз яратырлык иде, ләкин инде минем тиздән китәр вакытым да килеп җитте. Һәм шул чагында немец кызы тагын бер көтелмәгән кыюлык күрсәтте: бик киенеп, көязләнеп, җитмәсә, сеңлесен дә ияртеп, ул мине озатыр өчен вокзалга килде. Берәүдән дә — озата төшкән атам-анамнан да, якын дусларымнан да һич тә тартынып тормыйча, аларны шактый хәйранга калдырып, минем белән килеп күреште, бик мөлаем итеп хәерле юл теләде, кулындагы бердәнбер куе-кызыл чәчәген дә миңа сузды: «Казанга барып җиткәнче ташламагыз!» — диде. Поезд кузгалып киткәндә дә, ул минем якыннарым арасында, булачак кәләшем шикелле, кечкенә ак кулъяулыгын селки-селки озатып калды. Мин белә алмаган, мине бик гаҗәпләндергән әнә шундый кыз иде ул Лида!

Икенче елны кайтсам, туташым кияүгә чыккан икән

ләбаса! Шулай диделәр дусларым миңа... Кайчан, кемгә?.. Кемгә булсын, бер немец егетенә, билгеле... Бу хәбәр күңелемне бик тырнады тырнавын, әмма артык гаҗәпләндермәде. Лида, әлбәттә, үз кешесенә чыгарга тиеш иде, ләкин болай ук тиз булыр дип һич тә көтмәгән идем. Әле тагын чибәр-сылу белән матур гына йөреп калырмын дигән өметем бар иде. Мин бит инде бер яшькә булса да олаеп, үсә төшеп, шәһәрчә әйбәтләнеп (сүзгә дә бераз остарып) кайткан идем. Кызлар белән бик йөрисе килгән чак, алай гына түгел, үземә «яр табу» турында уйлана, эзләнә дә башлаган чак, ләкин, ни хикмәттер, миңа уңышсызлык артыннан уңышсызлык килә дә тора. Кече яшьтән үк мине күпме «саргайткан» Һаҗәр дә былтыр ук бер Ыслак егетенә иярде дә китте, инде менә үзе башлап миңа күз аткан кызым да тоткан да үзенең «нимеченә» чыгып куйган. Их, ышан син бу кызларга!

...Шулай да без очраштык. Бик тын, җылы бер төн иде. Танырдай кеше күзенә күренмәс өчен без башкорт Дәүләкәненең иң читтәге аулак урамында озак кына йөрдек. Кемнеңдер коймасы буендагы косаркага (печән чапкычка) туры килеп, шуның калай идәненә утырып та тордык. Лида кияүгә чыгуын бик җиңел аңлатты: «Вакыт җитте, шуңа күрә чыктым»,— диде. Мин: «Нигә мине көтмәдең?» — дигән булдым. «Ә син көтәргә куштыңмы соң?» — диде ул, шелтә белдергәндәй итеп. Әйе, хак сүзгә җавап юк!.. Ләкин кузгалыр алдыннан, Лида үзе миңа сарылып, кайнар сулап: «Әйдә, һич югы, бер үп мине!» — диде. Бу безнең иң беренче һәм иң соңгы бик дәртле, әмма гөнаһсыз үбешүебез булды. Шуннан соң мин, тилебәрән орлыгы ашаган малай кебек, кыек-мыек атлап, бәхет дигән нәрсәне нинди җиңел табып та һәм югалтып та була икән дигән уйдан хәйран калып, үзебезнең очка кайтып киттем.

Икенче көнне без, татар яшьләре, Бәлдәй йортына репетициягә җыелган идек. Шул чакта кемдер кереп миңа: «Әмир, сине тышта көтәләр»,— дип әйтте. Кемнәр, дип сорагач, серле генә итеп: «Чыккач күрерсең»,— диде. Мин бераз аптырап, ләкин аны-моны уйламыйча чыксам, клуб ишеге төбендә өч егет басып тора. Бик яхшы киенгән таза егетләр. Берсе — ак чырайлы, саргылт чәчлесе — буйга да озынрак, күкрәк-җилкәгә дә киңрәк... Мин шунда ук аларның немец егетләре икәнен сизеп алдым. Әлбәттә, яхшы ният белән килмәгән болар, дип уйладым, эчемә салкын курку да йөгерде, ләкин кире борылып кереп китмәдем. Озын буйлысы, миңа беравык туп-туры карап торганнан соң, кырыс кына сорады: «Ты Амир?..»

«Да, я Амир!»[1] — дидем мин... Шуннан соң ни булды? Шуннан соң берни дә булмады. Егетләр тагын бераз миңа карап тордылар да, артык бер хәрәкәт тә ясамыйча, борылып киттеләр дә бардылар. Мин бу эшкә бик гаҗәпләнеп, баскан урынымда торып калдым. Өч егетнең озын буйлысы, һичшиксез, Лида кияве булырга тиеш иде бит... Берниндиянау юк, кул күтәрү юк, ни өчен генә ике иптәшен ияртеп килде икән ул?! Хәер, мин моның серен тиз аңладым: аңа мине күреп, танып китү кирәк булган — менә ни өчен килгән ул!.. Һәм мин дә моны хәтәр бер кисәтү дип аңларга тиеш идем. Әйе, хәзергә алар миңа тимәделәр (чөнки көпә-көндез клуб алдында кеше кыйнап китү үзе куркыныч эш), әмма бер күреп, танып киткәч, моның өчен башка уңай җае чыкмасмыни?!

Кыскасы, шушы вакыйгадан соң Лида белән очрашу бетте, өзелде. Икебез өчен дә ул кирәкми һәм ярамый иде. (Лида өчен бигрәк тә.) Дөрес, бу «өзелешү» минем күңелдә үкенү хисе катыш нindидер бер ямьсез юшкын да калдырды, әмма нишләмәк кирәк?! «Роман»ның ахыры башыннан ук билгеле иде инде.

Ләкин Лида белән очрашулар бетсә дә, соңыннан миңа аның хакында кайбер нәрсәләр ишетергә туры килде. Иң элек мондый бер хәл: шул ук 1928—1929 елларда булса кирәк, хутор биләүче һәм Дәүләкәннең үзендә торучы күп кенә немец семьялары дәүләт органнарының рөхсәте белән Германиягә яки Америкага күчеп китә башладылар. Шул чакта Лиданың кияве дә ата-анасы белән бергә океан аръягына китеп бара. Ә Лида, йөкле булганга күрә, эти-әниләрендә (алар беркая да китмиләр) калып тора. Кияве исә аны соңрак кайтып алырга тиеш була. Ләкин инде ул яңадан безнең якларга кайта алмаган, чөнки бер киткәч кире кайтулары мөмкин булмаган, күрәсең. Шул рәвешчә, Лида Дәүләкәндә бөтенләйгә торып кала. Кем белә, бәлки, үзенең дә китәсе килмәгәндер. Дим буйлары аның да туып-үскән җире, эти-әнисе янында, баласы да бар, әллә кайдагы билгесез илгә чыгып китү нигә кирәк аңа?.. Хәер, белеп әйтүем түгел, миңа бит боларның берсен дә аның үзеннән ишетергә туры килмәде.

Еллар узды, күп нәрсәләр еракта калды — онытылды, кемнең генә тормышында нинди генә үзгәрешләр булмады. Әмма шулай да язмыш дигәнең тагын бер мәртәбә Лиданы минем исемә төшерде.

---

[1] Дәүләкәндә бөтен яшьләр мине Әмир дип кенә йөртәләр иде ул чакта.— *Ә.Е.*

...Хәтерлисездер, бу язманың башында мин үземнең алма исе аңкып торган айлы төндә Дәүләкәнгә кайтып төшүемне язган идем. Күпме еллар узгач, беренче кайтуым... Мин төн уртасында таныш урамнар буйлап йөрдем, үзебезнең йортны барып карадым, ә икенче көнне иртән базар янындагы ашханәгә ашарга кердем. Ашханәнең мөдире миңа бик якын кеше — тимерче Миңлегалим бабай кызы Мәһирә булып чыкты. Без кече яшьтән үк бер-беребезне беләбез, күршеләр булып тордык, озак еллар бергә аралашып, бергә йөреп үстек... Ләкин ашханәдә беренче мәртәбә очрашкач, Мәһирә мине танымады. Йөземә карап торып та таный алмады. Тик исемемне әйткәч кенә исе-акылы китте. Димәк, чирек гасыр эчендә без никадәр үзгәргәнбез икән. (Хәер, мин үзем Мәһирәне күрү белән үк танытдым.) Әмма хикмәт шунда ки, безнең бер өстәлдә бик җанланып, шатланып сөйләшүебезне ашлар бирә торган тәрәзәдән янә бер хатын карап торган. Ул хатын Лида булган!.. Шушы ашханәнең повары икән ул. Ләкин мин аны күрмәдем, беренче керүемдә дә, соңыннан атна буена кереп, ашап чыккан чакларымда да күрмәдем. Билгеле инде, аның шушында, кухня эчендә генә булу ихтималы минем башыма да килмәде. Килүе мөмкин дә түгел иде. Ә ул мине күргән — күргән һәм таныган! Ләкин, мин чыгып киткәч, Мәһирәгә бик нык кисәтеп әйткән, зинһар өчен, минем монда икәнемне аңа әйтә күрмәгез, дигән. Һәм Мәһирә миңа әйтмәде, мин берни белмичә китеп тә бардым. Гүя урман эчендә янәшә генә узган кешене күрмичә үткән шикелле — ни үкенеч!.. Бары тик икенче тапкыр кайтуымда гына Мәһирә миңа бу хәлне көлеп сөйләде. Әмма бу вакытта Лида Дәүләкәндә юк иде инде, каядыр Украинага, кияүдәге кызы янына киткән булып чыкты. Әйе, язмаса язмый икән ул! Мәһирә сөйләгәннәрдән миңа бик ямансу булып китте, теге вакытта Лиданы миннән яшергәне өчен үзенә хәтерем дә калды. Шул чакта әйткән булса, мин Лиданың үзенә сиздермичә генә аңа карый алган булыр идем. Ләкин соңыннан инде, тынычлана төшкәч, миндә: «Ә бәлки, Лида күренмичә дөрес тә эшләгәндер»,— дигән уй туды. Һичшиксез, ул да үзгәргәндер, нык үзгәргәндер, ә хатын-кыз үзенең никадәр үзгәргәнен бик яхшы белеп тора ул... Инде менә күрмәгәч, ерак яшьлектәге гүзәлсылу немец кызы, Дим читендәге нәфис ак төнбоек чәчәгедәй, минем хыялымда һаман да әле саклана.

Ярый, миңа бер юаныч, ә укучыга азрак ял биргән бу сагышлы истәлектән инде кире төп мәсьәләгә кайтыйк. Сүз бит Дәүләкәндә яшәүче төрле милләтләр турында бара

иде. Әйткәнемчә, мин үскән елларда халыкның күпчелеге руслар иде. Байлары да күбрәк, һәм алар татар купецларына караганда байлык җәһәтеннән күп өстен, көчлерәк тә булганнар. (Бигрәк тә ашлык җыеп озатучылары.) Зур таза йортлар, ишегалды буйлап сузылган амбарлар, тотып тыя алмаслык шәп аргамаклар аларда иде. Әле революциядән соң масленица бәйрәмендә аларның киң-тирән кашовкаларга тәңкәле сбруйлар белән җигелгән тройка яки пар атта урам буйлап буран уйната-уйната чапканнарын минем үземә дә күрергә туры килгән иде. Рус байлары арасында бик каралары, бик усаллары да булган (мәсәлән, Костюриннар турында шулай дип сөйлиләр иде), ләкин андыйлары гражданнар сугышы вакытында аклар белән сызганнар булса кирәк. Һәрхәлдә, мин аларны күреп белмим, бары ишетеп кенә беләм.

Шулай ук русның хезмәт иясе дә байларына караганда күбрәк иде. Болар — тегермәннәрдә һәм тимер юлда эшләүчеләр, төрле хезмәткәрләр белән вак һөнәрчеләр... Янә килеп, күпмедер интеллигенциясе дә бар иде: гимназия укытучылары, врачлар, конторщиклар әнә шундыйлардан. Кыскасы, төрле милләт халкы җыелган Дәүләкәндә руслар күбрәк тә, өстенрәк тә, һәр җәһәттән алдынрак та иде. Шуңа күрәдер инде монда унҗиденче елның революция вакыйгаларына иң актив катнашучылар да башлыча алар булган. (Контрреволюция тарафдарлары да һәм революция өчен көрәшүчеләр дә иң элек алардан чыккан.) Совет властен контрреволюциядән яклар өчен кораллы отрядны да алар оештырган. Дәүләкән Советының беренче председателе итеп Николай Кириченко дигән кеше сайланган. Гражданнар сугышы башланып киткәч, Дәүләкән аша да сугыш өермәсе узган, берничә тапкыр кулдан-кулга да күчкән һәм, билгеле инде, бу каты, канлы көрәштә корбаннар да аз булмаган. Вокзалдан ерак түгел, кечкенә бакча эчендә алар күмелгән туганнар кабере бүген дә исән-сау тора. Кыскасы, революция вакыйгаларына катнашкан рус иптәшләрнең корбан киткәннәре дә һәм исән калганнары да мәгълүм — аларның берсе дә онытылмаган. Район газетасы «Знамя» битләрендә төрле бәйрәмнәр уңае белән алар турында истәлекләр дә басылып чыккалый. Бу гүзәл эш. Әле быел гына (1981 елның июнь аенда) райкомның элеккеге беренче секретаре иптәш Тартыковның Дәүләкән тарихын яктырткан һәм берничә номерга сузылган шактый бай материалы басылган иде. Бу материалда да без шул ук революция каһарманнарын күрәбез: болар Иван һәм Николай Кириченко, Архип Мещеряков, Алексей

Астафьев, Василий Крайнов, Нестер Шуваев, Иван һәм Федор Ивановлар... Тик мине бер нәрсә гаҗәпләндерә: ни сәбәптер истәлекләрнең берсендә дә татар һәм башкорт исемнәре очрамый. Алардан да булгандыр бит. Революция вакыйгаларыннан бер халык та читтә торып калмады лабаса! Һәр халыктан агы да, кызылы да, хәтта яшеле дә булды диярлек. Дөрес, мин үзем күрдем, беләм дип шаһитлык итә алмыйм, чөнки ул чакта җиде-сигез яшьлек малай гына идем әле. (Малай чак өчен бер елның да аермасы бик зур. Мәсәлән, унҗиденче елны бик томанлы гына хәтерләсәм, унсигезенче елны инде шактый ук ачык искә төшерә алам.) Шулай да Дәүләкәндәге революция вакыйгаларына катнашкан берничә татар кешесе миңа да мәгълүм. (Кайсын ишетеп, кайсын үзем күреп беләм.) Шуларның берсе — Нәбиулла Кәримов кияве Мөхәммәтҗан Закиров. Күпереп торган кара мыеклы, тулы ак йөзле бу мәһабәт чибәр кеше унсигезенче елның җәендә Советка икмәк җыяр өчен продотряд белән авылларга чыгып китә. Отряд зур булмый — бары иллеалты кешелек кенә... Мәсәй дигән шактый кара типтәр авылына баргач, җыенга чакырылган халык, кулаклар коткысына бирелеп китеп, боларның барысын да кыйнап үтерәләр. Котырган, кайнаган халык эчендә алар, күрәсең, коралларын да худка җибәрергә өлгерә алмыйча калганнар. Дәүләкәнгә хәбәр килеп җитә, һәм шунда ук яхшы коралланган зуррак отряд, Мәсәйгә барып, канлы җинаятьне башлап җибәрүчеләрне чүпләп, җыеп та ала. Үтерелгән иптәшләрнең гәүдәләрен Дәүләкәнгә алып кайтып, вокзал янындагы әлеге туганнар каберенә бик зурлап күмәләр. Тик шулардан бердәнбер татар кешесе Мөхәммәтҗан Закировны гына нигәдер аерып, шәригать кушканча җеназалап, мөселман зиратына җирлиләр. Бәлки, шуңа күрә дә аның исеме онытылып, хәзерге истәлекләргә керми дә торгандыр?! (Дәүләкәннең ул зираты күптән бетерелде, аның өстенә урам-урам йортлар салынды.)

Революция вакыйгаларына якыннан катнашкан икенче бер кеше — бу Борһан купец приказчигы Кәрим Сабиров. Митингларда еш кына сөйләгән, әйбәт оратор булган, диләр. Ләкин шуңардан башка ул тагын кем булган, нәрсә эшләгән — бу кадәресен тәгаен генә белеп әйтүчене мин таба алмадым. Хәзерге истәлекләрдә аның да исеме юк. Хәлбуки, кайбер танышларымның әйтүенә караганда, Кәрим Сабиров егерменче елларның башында волисполком председателе булып торган икән. Бу инде, әгәр дөрес булса, Дәүләкәндә беренче урындагы кеше дигән

сүз. Әмма ни өчен «онытылган» соң ул? Бәлки, моңа анық фаҗигале үлеме сәбәптер?.. Елын ачык кына хәтерләмим, һәрхәлдә, җәй көне булган эш, Кәрим абзый Дим буендагы Казангол авылына барып чыга. Төшкән кешесендә (аны Исхак мулла дип сөйләгәннәр иде) ашапэчкәннән соң, хуҗаның атын җигеп, болынга китәләр. Куе үлән ат корсагына җиткән болын юлында күпмедер вакыт тугайны карап йөргәч, бер җирдә туктап, түгәрәк «табын» итеп кенә печән чабалар, шуны, кочак-кочак җыеп, арбаларына төйиләр дә кире борылалар. Кайтканда, Кәрим абзый дилбегәне үзе тота. Ләкин, күрәчәгенәдер инде, башкортның шактый чыгымчы аты ишегалдына килеп кергәндә генә нәрсәдәндер өркеп китеп, арба күчәрен капка баганасына эләктерә дә боларны йөге-ние белән аударып та җибәрә. Хуҗа читкә сикереп өлгерә, ә дилбегә тоткан Кәрим абзый үткен чалгы өстенә эче белән килеп төшә. Аны шунда ук, арбага салып, Дәүләкән больницасына китерәләр, ләкин, кызганычка каршы, врачлар берни дә эшли алмыйлар, чөнки Кәрим абзыйның ярасы бик тирән булып чыга, һәм, озак та тормыйча, ул шунда җан да бирә. Кабере әлеге бетерелгән татар зиратында иде. Яшь иде әле Кәрим абзый, күп булса утыз бишләр тирәсендә генә булгандыр, Миңнекамал исемле бик сөйкемле хатыны һәм миннән күпмегәдер яшьрәк Суфия исемле чибәр генә кызы торып калды. Соңрак мин аларга барып та йөрдем. Аларда бервакытны Хәлил Наилский дигән артист торды — менә шуның янына баргалый идем мин... Бу хакта, чираты җиткәч, сүз булачак әле.

Дәүләкәндәге революция вакыйгаларына күпмедер катнашы булган татар кешеләреннән мин монда мисал өчен үзем белгән ике генә исемне телгә алдым. Әгәр казына-тикшерә башласаң, аларны шактый табып булачак. Ләкин бу инде күп вакыт сорый торган үзенә аерым бер эш.

Инде минем балалык хәтеремдә менә шундый бер күренеш саклана: яз башы, бик якты кояшлы көн; Эткол урамыннан мәчеткә таба сафларга тезелгән шактый халык, яшел һәм кызыл байраклар күтәреп, эреп боткадай саргайган карны ера-ера, узып бара. Иң алдан яхшы киемле ниндидер таза кешеләр белән бергә кама тун өстеннән яшел чапан кигән, башына кызыл түбәле ак чалма ураган очлы сакаллы безнең мулла бабай да салмак кына атлый, ә сафларның ике ягыннан күзләре тонган малайлар көтүе бата-чума йөгерә. Менә шундый бер тамашаны мин авызымны ачып, үзебезнең капка

төбеннән карап калдым. Нинди тамаша икәнен, әлбәттә, аңламадым, тик шул ук көнне бик дәртләнеп кайтып кергән атакайдан «Патшаны төшергәннәр ләбаса!» дигән сүзне ишеттем. Халыкның нәмаешка[1] чыгуы әнә шул уңай белән булган икән. Һәм бу нәмаеш үзе дә ниндидер зур бер яңа бәйрәмнең башыдыр төсле булып тоелган иде миңа шул чакта...

Ә менә Октябрь вакыйгалары безнең Дәүләкәндә ничегрәк узганын һич тә хәтерләмим. Аяк атлый алмаслык пычрак, салкын көз булганга күрәме, халыкның урамнарга чыгып, байраклар күтәреп йөргәнен дә белмим — булмады шикелле. Шулай да базар тирәсендәге кайбер йортларга кызыл байрак эленгән иде. Әмма ләкин бу чын революция Дәүләкәнгә әнә шулай сизелмичәрәк килсә дә, аның әһәмияте һәм нәтиҗәсе гаять зур булган икән. Дустым Хәбибрахман әйтә, ул миннән өч яшькә олырак, самодержавие вакытында татар, башкортка мөнәсәбәтнең ничек булуын үзе күреп калган: «Октябрь көннәрендә без иң элек милли изелүдән котылуыбызны сиздек,— менә шуның шатлыгы бүген дә әле минем хәтеремдә саклана!» — ди. Ә бит Октябрь революциясе милли азатлык белән бергә хезмәт ияләренә иҗтимагый азатлык та китерде. Бәс шулай булгач, бу азатлык өчен көрәштән Дәүләкәннең татары һәм башкорты читтә торып кала аламы соң? Әлбәттә, юк!

Ярый, булмаса яңадан үзем күргәннәргә кайтыйм әле. Мин үскәндә (ягъни егерменче елларның башында) малайлар арасындагы «милли мөнәсәбәтләр» ничегрәк иде?.. Дөресен генә әйткәндә, бик үк татудан түгел иде. Мәктәпләр аерым, укулар аерым, бергә аралашып йөрү, уйнаулар да юк иде. Рус малайлары күбрәк чиркәү урамында һәм Эткол урамының югары очында торсалар, без инде шушы урамның мәчеткә якын өлешен һәм түбән очын «биләп» тора идек. Тел киртәсе дә көчле иде әле, татарча гына укыгач, русча белүебез «кәлә-мәлә»дән узмый иде. Аннары борыннан сакланып калган «милли дошманлык» та (хәзергечә әйтсәк, антагонизм да) үзен сиздергәли иде. Мәсәлән, без руслар очына барып чыксак, аларның малайлары еш кына безгә һөҗүм итәләр, инде берәр рус малае безнең тирәгә килеп чыкса, без дә аны әзрәк дөмбәсләмичә җибәрми идек. Гадәттә, һәр якның берәр бик кыю, усал малае була — шул башласа гына, бүтәннәр дә «дошман»га ташлана. Безнең якта иң кыю, иң көчле-батыр малай Арыслангәрәй агай улы Та-

[1] Демонстрацияне ул елларда «нәмаеш» дип язалар иде.— *Ә.Е.*

һир иде. Үзе ул сугышырга атлыгып та тормый кебек, әмма инде бер тотынса, арысландай сугыша иде. Шулай да малайларның кайберләре катнашырга курка, бүтәннәр тәпәләшкәнне читтән генә карап тора, һәм соңыннан каршы як, ни хикмәттер, күбрәк әнә шундый «битарафларны» эләктереп алып, үчен кайтара торган иде. Ә Таһирга ялгыз очраса да тимиләр, киресенчә, еракtан ук аңа «А, Тагирка!» дип хөрмәт белән дәшәләр. Әйе, гаҗәеп бер малай иде Таһир!.. Аңарда, ничек дим, искиткеч тән сәләте бар иде, ягъни ул корыч чыбыктай теләсә ничек бөгелә-сыгыла, үзе гаять җиңел, җитез һәм көчле дә иде. Ундүрт-унбиш яшеннән ул, көзен кар төшкәч, атасына ияреп, төлке, бүре сугарга йөри башлады. Комачтан (Димнең Эткол турындагы култыгы) атларын, бияләрен эчереп менгәндә, ул иң кызу-усал кола айгырның сыртына аягүрә генә басып кайта иде. Әгәр без үскәндә яшьләрне спортка тарту булса, Таһир, һичшиксез, башкортның берәр төрле чемпионы булган булыр иде. Ләкин язмыш аңа башка төрлерәк юл сайлады: колхозлашу чорында Арыслангәрәй агайны семьясы белән Себер ягына сөрделәр — каядыр Кузбасс тирәсенә бугай... Сугыштан соң Таһир Дәүләкәнгә бер тапкыр кайтып та киткән булган. Өсбашы бик әйбәт иде, яхшы урында эшли булса кирәк, дип сөйләделәр. Югала торган егет түгел иде ул! Тик менә бер-ике ел элек кенә Таһир үлгән дигән хәбәрне ишеттем. Ләкин нигәдер күңелем ышанып бетмәде минем бу хәбәргә...

Ә безнең малай чактагы «милли тәпәләшүләргә» килгәндә, искедән йогып калган ул шаукым комсомол эшләре көчәйгәч, пионерлар хәрәкәте дә тугач, әкренләп бетте дияргә ярый. Хәер, бу вакытта инде мин Дәүләкәннән киткән идем.

Хуш, тагын нәрсә?.. Әнә тимер юл буендагы калкулык өстендә бик матур зур ак чиркәү тора, күршесендә генә комташтан салынган ике катлы гимназия. Менә шул гимназиягә рус балаларының барып-кайтып йөрүләрен мин әзрәк хәтерлим әле. Малайларының өстендә ике яклап җиз төймә тезелгән күк шинель, аркаларында иңнәре аша каешлап кигән тартма сыман күн букча[1], ә кызлары тар билле, киң итәкле бишмәттән (хәзергечә әйтсәк, пальтодан), муеннарына кара мехтан тегелгән кечкенә муфта дигән нәрсә асып, кулларын шуңа гына тыгып йөриләр. Бу гимназия укучылары — әллә инде торганы бай балалары гына иде — барысы да берт-

[1] *Ранец.— Ә.Е.*

өсле, барысы да матур, көязләр. Кая ул безнең татар шәкертләренә аларга җитү?! Без бик чуар идек, кемдә билле бишмәт, кемдә кайры тун, аякларда йә пима, йә ката (хәтта чабата да), тик бау белән аскан киндер букчалар гына бертөслерәк иде.

Янә килеп, русларның бәйрәмнәре бик кызыклы була торган иде. Иң элек һәр бәйрәмдә чиркәү чаңнары авыл өстендә өзлексез яңгырап тора. Һәм бу иң калыныннан алып иң нечкәләренә хәтле алмаш-тилмәш яки бөтенесе бергә яңгыраган чиркәү чаңында нindидер бер көч-тылсым бар кебек иде. Хәтта менә мин вәсвәсәдән бик курыккан татар малае күңелендә дә ул чаң авазлары тантаналы да һәм ямансу да сәер бер тойгы уята иде. Шуңадыр, ахры, мин яшьтән үк чиркәү чаңнарын ирексездән шомланып, әмма яратып тыңлый идем.

Ләкин хәтердә иң нык сакланганы — русның кыш үзәгендә була торган крещенье бәйрәме. Каты суыклар вакыты, Дим инде бер аршын чамасы каткан да була. Иң элек әнә шул каты бозны суы чыкканчы чабып, Дим өстенә зур бер тәре ясыйлар. Тәренең аяк очында түгәрәк бәке уялар. Чиркәүдән иконалар, хоругвилар, тагын әллә ниләр күтәреп чыккан халык һәм поплар Иордан тыкрыгы буйлап боз өстенә төшәләр. Шуннан соң озак та үтми, пар ат җиккән тирән кашовкада, зур толыпка төреп салган көрәк сакаллы бер русны боздагы тәре янына китерәләр. Шыр ялангач рус бабайны толып эченнән чыгарып, бер кулына элмәкләп бау кидерәләр дә тәре очындагы әлеге түгәрәк бәкегә өч тапкыр чумдырып алалар. Салкын судан тартып чыгаргач та, аңа стакан тутырып аракы бирәләр, шунда ук яңадан чанага салып, зур калын толыпка (дохага) әйбәтләп урыйлар. Өстенә тагын бер толып ташлыйлар, шуннан соң пар ат аны каядыр чаптырып алып та китә.

Бу тамашаны мин берничә кыш рәттән үз күзем белән күрдем. Дәүләкән — бәләкәй җир, чиркәү дә бездән ерак түгел, шул сәбәпле рус бәйрәмнәрен гел күреп үстек. Русның зур бәйрәмнәре — масленица, пасха, троица — барысы да бик җанлы, кызыклы була торган иде. Әмма иң кызыклысы әнә шул карт русны чатнама суыкта бәкегә батырып алу иде — без малай-шалай, катып-туңып бетсәк тә, бу тамашаны күрмичә китми идек.

Инде сүз ахырында мондый бер вакыйганы да искә төшереп үтик булмаса. Вакытында Дәүләкәнне озак шаулаткан шактый хикмәтле вакыйга ул! Эш болай: безнең урамда, Зариф абзыйларның ишегалдындагы бәләкәй өйләрендә Хәдичә исемле диндар гына бер тол карчык

ике кызы белән тора иде. Ә аның Миһран исемле җиткән улы Меделанский дигән зур бер рус баенда кучер булып эшли. Меделанский — читкә ашлык җыеп озатучы, шул сәбәпле ул еш кына Мәскәүгә яки Петербургка китеп торгалый икән. Монда йорт саклап бик тулы да бик алсу яшь хатыны кала. Яшь хатынның күз алдында көн саен кара ефәк мыеклы, яшь имәндәй таза егет ваемсыз гына эшләп йөри. Һәм ялгызлыктан интеккән хатын егеткә карап җан тынычлыгын җуя башлый. Егет тә тыштан гына ваемсыз икән, ә эченнән аның да хыялы ак калачтай хатында, имеш! Ситуация, үзегез дә күрәсез, шактый хәвефле. Әмма нәфес дигәнең коточкыч нәрсә бит ул!.. Кемнең генә аны җиңә алганы бар! Озын сүзнең кыскасы, күпмедер вакыттан соң алар арасында яшерен «мәхәббәт» тә башлана. Кайнар мәхәббәт көннән-көн тирәнәя, тирәнәйгән саен ачыла да бара, ниһаять, халык теленә дә керә, һәм бу инде аларны шактый ук читен бер хәлгә дә куя. Ахырда хатын егеткә әйтә: «Болай ярамый бит, фаш булып беттек, безгә хәзер венчаться итәргә кирәк, мин иремне ташлыйм, ә син безнең дингә күчәргә тиешсең!» Егет, йомры баш, тиз генә чамалап ала — бу бикәчкә ияреп байлык та киләчәк бит, һәм, артык икеләнеп тормыйча гына, риза да була. Шулай итеп, Меделанский үзе читтә чакта, безнең Миһранны Дәүләкән чиркәвендә бик тантаналы рәвештә чукындырып та куялар. Исемен дә ансат кына Миронга әйләндерәләр һәм шуннан соң «православный» Миронны православный Мария белән «венчать» та итәләр. (Бу эшнең чиркәү таләп иткән кагыйдәләре нинди булгандыр — вакыйганы сөйләүчеләр белмиләр. Әмма Миһранның чукынуы да, рус хатынына өйләнүе дә дөрес, булган эш.)

...Берзаманны карт бай Меделанский Дәүләкәнгә кайтып төшә, ләкин, өендәге хәлләрне белгәч, көне-сәгате белән кире Петербургка китеп тә бара. Әйтәләр, байның пайтәхеттә үз сөяркәсе булган, диләр. Бәлки, дөрестер дә, чөнки мондагы йорт-җирен һәм хатынын алай җиңел генә ташлап китмәс иде. Әмма ничек кенә булмасын, чукынган татар рус баеның хатынына да, йортына да, мал-мөлкәтенә дә полный хуҗа булып кала, хәтта Меделанский дигән фамилияне дә үзенә ала. (Мирон Меделанский! — начар түгел бит?!) Дәүләкән күләмендә дә шаккатыргыч бер вакыйга була, шау-шуы да аның берничә айга сузыла.

Ә Хәдичә карчык ничек соң? Ул, бичара, ни хәлдә? Башта ул һич тә ышанмый, ә ышангач, чак җаныннан аерылмый. Улы (Миһран) килгәч, карчык сыгылып төшеп сорый икән:

— Әй улым, улым, чынлап та чукындыңмыни?

— Пока гына,— дип әйтә икән Миһран, гармушкалы итекләре белән идән буйлап шыгыр-шыгыр йөри-йөри.

— Ни дигән сүзең ул?

— Ну, вакытлы гына.

— Вакытлы гына буламыни?

— Була, инәй, кирәккәч була!

Һәм карчык бу сүзләрдән ничектер тынычлана төшә, күршеләренә дә: «Миһранымның иманы эчендә, тыштан гына ул урыс булып йөри»,— дип сөйләнеп, үзен-үзе юата да икән.

Ә көннәрдән бер көнне Миһран атлас-ефәкләргә төренгән, хушбуй исләре аңкып торган ястыктай тулы-йомшак «киленне» инәсенә күрсәтергә дә алып килә. Җитмәсә әле татарча дәшәргә дә өйрәткән.

— Дорогая инай! — ди икән «килен», кечкенә карчыкка бик ягымлы елмаеп.

«Инай» сүзе халык арасына да тарала. Әгәр марҗа киленне күрсәләр, «әнә инай килә» дип көләләр икән.

Әнә шундый вакыйга булып ала Дәүләкән «каласында». Революция алдыннан була бу эш, ә менә революциядән соң Мирон Меделанский ни эшләгән, байдан калган йортын, хатынын нишләткән, кая куйган — шуны миңа ачык кына белеп әйтүче булмады. Хәер, байлык өчен чукынучылар аз югалдымыни ул заманда!

Инде бик озынга киткән бу бүлекне Дәүләкәннең төп халкы — башкортлар турында язып төгәллисем килә. Моңа мин бик теләп керешәм, чөнки башкортны яхшы ук беләм дип әйтә алам. Рәттән утырган өч күршебезнең икесе башкорт иде. Уңда Миңнегәрәй агай (аңа хәтле Сылубикә җиңгәй), сул ягыбызда Борһан купец аша гына Арыслангәрәй агай йорты. Миңнегәрәй агай белән исә бер ишегалдында торып, бер капкадан йөрдек... Хәтерләсәгез, «Каргалы» өлешендә дә мин безнең бабайларның борыннан ук башкортлар белән аралашып һәм йөрешеп яшәүләрен язган идем. Дәүләкәндә инде бу читтән торып аралашу гына түгел, ә бер үк җирдә бер халык булып диярлек яшәүгә әйләнгән иде. Дин бер, тел бик якын[1], бер үк мәчеткә йөриләр, бер үк мәктәпләрдә укыйбыз. Аерма юк иде дип әйтергә җыенмыйм, аерма — исемнәрендә үк, хәтта каршылыклар да юк түгел, әмма Дәүләкән шартларында бу ике халык бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән иде.

---

[1] Дим буе башкортларының теле хәзерге башкорт әдәби теленнән шактый ук аерыла.— *Ә.Е.*

Әле башта ук язып үткәнемчә, бу тирәләрдән Себер тимер юлы узганчыга хәтле Эткол белән Дәүләкәндә башкортлар үзләре генә яшәгәннәр. Күп итеп мал асраганнар, умарта тотканнар, җәнлек аулаганнар, кирәк кадәр генә иген дә иккәннәр. Шулай ук тирә-яктагы зур базарларга һәм ярминкәләргә йөреп, алыш-биреш тә иткәннәр. Ләкин, нигездә, зур үзгәрешләр кичермичә, борынгычарак беркөе генә яши биргәннәр. Инде авыллары кырыннан гына үткәрелгән тимер юл, паровоз гудоклары тын даланы сискәндереп уяткандай, моңарчы үз җаена салмак кына аккан башкортлар тормышын да бик нык үзгәртеп җибәрә. Иң элек, күргәнебезчә, яңа юл белән Эткол-Дәүләкәнгә төрле халык килеп тула, шулар аркасында хуҗалык, сәүдә эшләре шактый кызу җәеләкөчәя, кыскасы, Эткол дигән бәләкәй генә башкорт авылында кинәт кенә капиталистик мөнәсәбәтләр үсеп, куәтләнеп китә. Билгеле инде, бу мөнәсәбәтләр, төрле якка сузылган спрут кулларыдай, башкортларны да үз «кочагына» тартып ала. Беренче нәүбәттә без моны нәрсәдә күрәбез? Шуны онытмыйк, мондагы җир-суларга башкорт хуҗа, димәк, Дәүләкәнгә кем генә килмәсен, нәрсә генә эшләргә уйламасын, ул иң элек башкорттан җир сатып алырга тиеш булган. Шунсыз бер казык та кага алмаган. Шулай ук Дәүләкән әтрафындагы яңа рус авыллары да һәм немец хуторлары да башкорттан алган җиргә килеп утырган. Шул рәвешчә, башкорт үзенең иркен җирләрен азлап та һәм күпләп тә сатарга тотынган яки инде арендага биреп торган. Бу җир сату-алу эшләре ул чакта бик кызу барган булырга тиеш, чөнки халык арасында ул турыда һәртөрле көлке һәм аяныч сүзләр күп сөйләнә иде. (Әйтик, кемдер кемнедер алдаган, кемдер кем беләндер судлашкан һ.б.) Миңа калса, бу әле Дәүләкән тарихының ныклап өйрәнелмәгән бер сәхифәсе.

Аннары килеп, Этколның үзендә үк зур базар ачыла. Тора-бара ярминкәсе дә була башлый. Тирә-яктагы башкортлар еракка китмичә, шушы базарга аяклы малын да, тире-ярысын да, итен-маен да чыгара. Базар стихиясе бик гаҗәп бит ул — бөтенесен дә үзенә тартып китерә... Тагын да иң мөһиме — Дәүләкән ашлык җыеп озату урынына әверелгәч һәм зур-зур тегермәннәр дә эшли башлагач, башкортлар да иген игүне арттыралар, «бидайны» инде алар товар итеп, йөге-йөге белән китереп саталар. Башкорт кулында тагын бер байлык — ул да булса печән. Дим буе болыннарына алар үзләре генә хуҗа иде. Болынны сату юк, арендага да бирми яки беразын гына бирә, анда да елына карап кына. Болынны башкорт

бик саклый, үлән әзрәк күтәрелгәч тә, чабынга терлек кертми һәм кешедән дә таптатмый иде. Чабар вакыт якынлашкач, алар атналар буенча ат менеп яки җәяүләп әллә ничә чакрымнарга җәелгән болынны күзәтеп-карап кына йөриләр. Шушы уңай белән мондый бер кызык та көлеп сөйлиләр иде. Имеш, башкорт агае болында бер русны тотып алган һәм яман ачуланып аңа әйткән, янәсе:

— Ләштер-лөштер атлаеш, засим бесән таптаеш?

Иты наша ялан бит, колак төпкә салам бит!

Эш колак төпкә хәтле үк барып җитмәгәндер инде, әмма әйтергә кирәк, печән ул башкорт өчен ишле малына бердәнбер азык та һәм шактый табыш китерә торган байлык та. Шуңа күрә дә терлектән дә, кешедән дә таптатмыйча саклаган ул аны. Печән чабу башкортларның уракка караганда да иң зур, иң киеренке эш өсте — бөтен авылы, бөтен хатын-кызы һәм бала-чагасы болынга чыга иде. Ирләр, торналардай тезелешеп, куе-тыгыз үләнне чош та чош чабалар, хатын-кызлар бер-ике көн җилләгән пакусларны чүмәләгә өяләр, егетләр, үсмер таза малайлар тагы да кибә төшкән чүмәләне ат белән кибәнгә тарттыралар. Һәм менә берзаман Дим тугае оста агайлар куйган очлы башлы түгәрәк кибәннәр белән чоп-чуар була торган иде. Ә көзен-кышын Дәүләкән базарында шул хуш исле «бесәнне» бары тик башкортлар гына сата иде.

Хәер, башкортның тагын кымыз дигән бик әйбәт бер байлыгы бар бит әле. Ихтимал, элек үзләре генә эчкәндә кымыз әллә ни зур байлыктан да саналмагандыр, әмма ләкин Дим буйлап тимер юл узгач, бия сөте чын бер табыш чыганагына әйләнә. Чөнки мәшһүр елганың балыклы саф суы, чәчәкле-хуш исле болыны-яланы, каймактай йомшак һавасы, көннәр буе тигез генә кыздырган кояшы, шуның өстенә һәртөрле азыкның муллыгы һәм арзанлыгы үпкәсенә сихәт эзләүчеләрне бу тирәләргә күпләп тарта башлый. Кымызчылар диләр аларны. Ансат туры юл булгач, алар Уфадан гына түгел, Казаннан, Самарадан, Мәскәүдән, хәтта Петербургтан да Дим буйлап тезелгән башкорт авылларына киләләр. Иптәш Тартыковның язуына караганда, кымызчылар керткән һәрбер йорт хуҗасы җәенә йөз сумлап акча алып кала булган. Ә ул заман өчен бу шактый ук зур табыш.

Димәк, яңа юл белән вагоннарга төялеп башкортларга да байлык килгән?.. Юк, ашыкмыйк әле... Әлбәттә, тимер юл — прогресс, алга китеш, үзгәрткән, җанландырып җибәргән ул җирле халыкның да тормышын, ләкин барысына да бертигез байлык белән бәхет китергән дип уйлау зур хата булыр иде. Гомумән, байлык беркайчан

да кешеләргә тигез бирелмәгән, башкортларда да борын-борыннан ук бае да, ярлысы да булган, ә тимер юл аркасында җанланып киткән алыш-биреш эшләре (икенче төрле әйтсәк, капиталистик мөнәсәбәтләр) ул аерманы отыры тирәнәйткән генә. Дөрес, күп җир-су биләүче, күп мал асраучы башкортлар булган. Әмма мин үскәндә, алар да бик сирәк калганнар иде инде. Дәүләкәннең иң бай башкорты Дәүләткилде агай иде, диләр. Эткол урамының урта бер җиренә салынган иң шәп, иң матур, чардаклы йорт та аныкы иде. (1919—1920 елны булса кирәк, бу йортның зур як башында без бер кыш сабак та укыган идек.) Ялан-дай ишегалды, зур-зур абзарлар, тимер ишекле таш амбар — бер сүз белән генә әйткәндә, аныкы кебек йорт-җир татар «купич»ларында да бик сирәк иде.

Кем булган, ничек баеган ул Дәүләткилде агай?

Таш магазин да ачмаган, сату да итмәгән, әмма, күрәсең, элек-электән үк җиргә-суга бай булгандыр инде. Ләкин иң мөһиме — ул волостной старшина булып торган кеше, ихтимал, шушы урыны аңа дәүләтне китергәндер дә... Күп сулар акты ул заманнардан соң! Дәүләткилде агай үзе дә һәм бичәсе дә революциягә чаклы ук, барсын да калдырып, бу фани дөньядан китәләр. (Әйтергә кирәк, бик яшәрдәй чакларында.) Алардан калган Рокыя исемле кыз белән Локманхәким исемле малайны атайларының инәсе Фәрхи карчык карап, тәрбияләп үстерде.

Локманхәкимне мин яхшы беләм, бер урамда үстек, ятимлек ничектер йөзенә чыккан тыйнак-юаш кына бер малай кебек иде. Егерменче елларның ахырында ул Дәүләкәннән китә, кая китә, нишләп йөри — белүче юк. Тик күпмедер вакыттан соң бер хәбәр шулай да безнең колакларга килеп ишетелә: Локманхәким паровозда «качагар» булып йөри икән. Дәүләкән станциясендә аны күреп калучылар булган, имеш. Булыр, ник булмасын?! Дәүләткилде малаена да каядыр эшләргә, дөньяда яшәргә кирәк ләбаса!.. Һәм соңыннан аның кочегар булып йөрүе дөрес тә булып чыкты.

Күп еллар узгач, без — олы яшьтәге ике агай — ниһаять, Уфада очраштык. Очрашуыбыз Дәүләкән «егетләренең» берсендә, күңелле генә бер мәҗлестә булды. Каршымда кечерәк буйлы, кап-кара чәчле, арык кына бер кеше утыра һәм мин аңа бик гаҗәпләнеп карыйм — шушымы кайчандыр минем белән бергә уйнап үскән Локманхәким?.. Ул бит тулы-түгәрәк кенә битле малай иде, гәүдәгә дә таза булмакчы иде — еллар, еллар әнә ничек үзгәртә икән кешене!.. Әмма иң гаҗәбе бу түгел әле.

Минем хәтердә сакланган малай чагындагы ятимлек, нәүмизлек, мескенлекнең аңарда эзе дә калмаган. Хәзер ул үзен бик иркен, бәйсез тотучы, гаять җор, тапкыр сүзле, мәзәкчән бер кеше иде. Бөтен мәҗлес дәвамында кунакларны гел үз авызына каратып, өзлексез көлдереп утырды... «Кем син, Локманхәким?» — дип сорау кирәкми дә иде,— дәүләт-байлык белән бәйләнгән үкенечле ачы язмыш күптән онытылган, ә хәзергесеннән исә ул мотлака канәгать! Мин башкача уйлый алмадым.

Дәүләкәндә икенче таза тормышлы башкорт безнең якын күршебез Арыслангәрәй агай иде. Нәп елларында аның өч-дүрт аты, бер кола айгыры, тагын күпмедер колын-тайлары бар иде. Ялгышмасам, ике бия бәйли иде, икеме-өчме сыер савалар иде. Тагын сарыклары, бәрәннәре... Хәер, кем санаган аларын?! Йорты урамга буй, кара-каршы салынган такта түбәле гадәти генә бер йорт. (Хәзерге механизаторларның йортларына җитми, һәрхәлдә.) Кара-каршы өйнең уртасында иркен генә өйалды, ишегеннән керүгә, сул кулда зур гөбе тора, бияне саугач та сөтен шул гөбегә кертеп салалар. (Чын булса, бияне көненә биш тапкыр савалар икән.) Һәм кергәнчыккан һәрбер кеше, бала-чагага хәтле, гөбедәге кымызны пешкәк белән бер-ике тапкыр гына булса да болгатып ала. Моны пешеләү диләр. Әнә шулай өзлексез пешеләп торсаң гына, кымыз тизрәк тә һәм шәбрәк тә булып өлгерә икән. Шуңа күрәдер инде, хәзерге башкорт өйләреннән аермалы буларак, Арыслангәрәй агай өеннән җәйнең эссе көннәрендә әчкелтем тәмле кымыз исе киләп тора торган иде.

Арыслангәрәй агай үзе дә эре-таза, нык кеше иде. Һәм табигате белән дә ул ачык, көр күңелле, шаян-шат бер кеше дә иде дип өстисем килә. Шуңа күрәдерме, без малай-шалай, хөрти генә кешедән курыксак та, бу пәһлевандай дәү кешедән бер дә курыкмый идек. Чөнки ул бөркет, без чебен, ә бөркет себен тотмай, диләр башкортлар үзләре дә.

Ул бервакытта да капка-койма буендагы сукмактан йөрмәс, бары урам уртасындагы ат юлыннан гына йөрер иде. Әгәр кызмачарак та булса, җилән чабуларын җилбәгәй җибәреп, бүреген күз өстенә төшереп, урамга сыймагандай шаулап, гайрәт орып, өенә кайта торган иде. Юлында очраган яшь бичәләргә шаяртып сүз катмыйча узмый ул, ә уйнап йөрүче малайларга туктап карап тора да ни өчендер бармак янап китә иде.

Шуның өстенә Арыслангәрәй агай бик маһир аучы да иде. Беренче кар төшү белән ул, киң күкрәкле, нечкә

билле кола айгырын иярләп, озын саплы чукмарын биленә кыстырып, эчләре эчкә кереп беткән ике бурзаен ияртеп, бүре сугарга чыгып китә торган иде. Мин аның бүрене ничек итеп сугып алуын күптән инде «Бөреледә ниләр бар» исемле очеркымда язган да идем, шуңа күрә биредә яңадан кабатлап тормыйм. Кыскасы, агаебыз чыккан саен берәр бүрене ат койрыгына тагып алып кайта, тиресен тунап, озын колгага элеп, капкасына беркетеп куя — бу дан билгесе! Үткән-сүткәннәр авызларын ачып: «Һи, Арыслангәрәй тагын бүре суккан лабаса!» — дип исләре китеп узалар, ә безнең ише малайлар, күшегеп, ачыгып бетсәләр дә, капка төбен ташлап китә алмыйлар — тере бүренең үзен күргәндәй, алар тәмам дөньяларын оныталар. Монда ниләр генә сөйләнми дә, нинди генә бәхәсләр купмый иде шул чакта!

Арыслангәрәй агай улы Таһирны да ундүрт-унбиш яшеннән үк үзе белән бергә ауга йөртә башлады. Таһир, әйткәнемчә, бүре сугарлык көчле, гайрәтле малай иде. Һәртөрле уенда, көрәштә, йөгерешүдә ул иң беренче — аны җиңгән яки узган бүтән малай безнең арада юк иде. Шуның өстенә ул бит Арыслангәрәй агайның җыен кызлары арасында бердәнбер төпчек улы, атасының куанычы һәм мактанычы, шуңа күрәдер инде, бәлки, Таһир шактый гарьчел малай да иде. Дөрес, үзе башлап тиктомалга берәүгә дә тими иде, әмма инде берәрсе аз гына аның ачуын китерсә, кинәт кызарып, шунда ук салып та җибәрә иде.

Без йорт аша гына күрше идек, бөтен малайлык чорыбыз Димдә, тугайда, урамда, мәктәптә бергә үтте. Егерме бишенче елны мин Казанга китеп бардым, ләкин һәр җәйне Дәүләкәнгә кайта торган идем. Бу инде безнең малайлыктан чыгып, егет булып килгән чагыбыз. Сагынышып очрашкач, тагын бергә йөрүләр, сөйләшүләр, күңел ачулар — хәзер инде, билгеле, мыек төрткән егетләрчә! Таһир кечкенә гармунда чибәр генә уйнарга да өйрәнгән, өстендә әйбәт тужурка, аягында күн итек, кызлар белән дә шаяргалый башлаган икән инде. Кыскасы, Дәүләкәннең бер шәп егете булмакчы иде, әмма ләкин кырыс заман аның язмышын тота да үзенчә хәл итә: утызынчы елларның башында Таһирны атасы белән бергә ерак Себергә озаталар. Шуннан соң инде без очраша алмадык.

Әйтергә кирәк, Дәүләкән башкортларыннан бүтән Себергә җибәрелүче булмады да шикелле. Һәрхәлдә, ишетергә туры килмәде. Миңа калса, Дәүләкәндә баеп киткән башкортларга караганда, бөлгәннәре күбрәк иде... (Монда сүз башлыча Этколның үзендә торучы башкортлар турында

бара, ә төп Дәүләкән ул гади бер авыл, андагы башкортларны мин бик аз беләм...) Әмма бөлгенлек аларга революциягә чаклы ук килгән, чөнки кинәт башланган яңа шартларга күбесе тиз генә яраклаша алмаган. Җирен саткан, малын саткан, ә менә акчасын саклый белмәгән, ахрысы. Эткол кырыннан гына үткән тимер юл белән бит һәртөрле күз кызыктырырлык товар гына түгел, «ак патша»ның аракысы да килгән, «бива»ны да Дәүләкәннең үзендә үк ясый башлаганнар. Шулай итеп, ансат кына кулларына кергән акча тиз генә чыгып та киткән. (Күрәсең, рус яки татар кебек акчасын оборотка кертә белмәгән. Мәсәлән, Дәүләкәндә кибет ачып сату иткән бер генә башкортны да мин белмим, юк иде бугай.)

Бөлгенлеккә төшкәннәрен кайдан, нәрсәдән күреп була?.. Әйтик, менә яландай ишегалды, чыбык-чабык белән генә япкан читән абзарлар, абзар артында киртәләгән иркен утар — димәк, кайчандыр монда ишле мал кышлаган. Ә хәзер терлек юк, абзарлар буш, утар да буш, анда ята-ята череп туфракка әйләнә язган тирес кенә... Шушының ише «хуҗалыклар» безнең урамда ук бар иде. Ерак китмичә, мисал өчен, бездән урам аша гына торган Солтанай агай йортын алыйк. Янәшә ике йорт, берсе калай, икенчесе такта белән япкан — димәк, бу хуҗа кайчандыр таза тормышлы булган. 1918 елны без аларга күрше булып күчкәндә, Солтанай агай үзе юк иде инде. Тимергали исемле энесен аклар алып киткәннәр, ул шуннан кайтмады. Кызыл түбәле йортта Солтанайның бичәсе ике улы белән тора иде. (Такта түбәлесен, бәләкәй ишегалды белән бергә, ачлык елы алдыннан Хәсән исемле бер вак сәүдәгәргә сатканнар иде.) Тол хатын һәм ике үсеп килгән малай чибәр генә йортта калсалар да, шактый фәкыйрьлектә яшәделәр. Аларның инде бер сыердан башка бүтән терлекләре юк иде. (Бәлки, берничә сарыклары булгандыр.) Ә бит ихаталарының зурлыгына карaганда, атлар, сыерлар, сарыклар кайчандыр монда аз тормаган... Күрәсең, Солтанай агай бу фани дөньядан аерылганда, барлык малын «очлап» бетерергә өлгергән инде. Аны бик эчкән диләр. Ә эчкән кешенең, кем әйтмешли, малы да бетә, үзе дә бетә.

Ике малайның берсе Мөхәммәтгали, икенчесе Муллагали исемле иде. Мөхәммәтгалинең бер аягы гарип иде, чатанлап йөри иде. (Исереп кайткан атасы моның кечкенә сабый чагында ялгыш аягына утырган дип сөйлиләр иде.) Шуңа күрәме ул бик нечкә күңелле, юаш кына бер малай иде. Безнең урам уеннарына юньләп катнашмый да, күбрәк ялгызы гына, кармак күтәреп, Дим буенда

йөрергә ярата иде. Балыктан бәхете бар иде аның... Күрше-тирә малайлары әле яңа торып кына чыккан булалар, ә Мөхәммәтгали инде, талчыбыкка тезгән чабакларын, тараннарын күтәреп, яр буеннан чатанлый-чатанлый менеп тә килә торган иде. Тагын бер яшерен хикмәте — ул да булса, безнең бу тыйнак-сүзсез иптәшебез күптән инде шигырь язу белән дә мавыккан икән. Әйтергә кирәк, уеннан башканы белмәгән малайлар арасында утырып шигырь язу бик сирәк очрый торган хәл иде, булса да болай кызык өчен юри шаяртып кына, чөнки чынлап шигырь язу ул гади кеше эше түгел, аның өчен син йә Тукай, йә Гафури булырга тиешсең. (Мәктәптә безнең иң күп укыган һәм ятлаган шагыйрьләребез.) Ә Мөхәммәтгали менә юри түгел, чынлап язган, күңелендә аның шигърият чишмәсе ачылган, шуңардан моңсу-боек җанына юаныч та тапкан. Хәлбуки минем дә, ниндидер бер яшерен кодрәткә буйсынып, кыяр-кыймас кына «каләм тибрәтә» башлаган чагым иде. Һәм шушы уртак «серебез» аркасында без аның белән шактый якынаеп, дуслашып та киткән идек.

Минем күңелдә якты бер хатирә саклана. 1926 елның җәендә Фәтхелислам белән икәү Казаннан ялга кайткач, Мөхәммәтгалине дә ияртеп, без Дәүләкәндә элек бергә укыган иптәшебез Гобәйдулланың чакыруы буенча Мәрвәр утарына кунакка барырга булдык. (Мәрвәр — Гобәйдулланың атасы, утар хуҗасы.) Ләкин безнең уналты-унсигез чакрымдагы утарга җигеп барырга атыбыз да һәм арбабыз да юк иде. Шулай да Мөхәммәтгали, йөри торгач, кемнәндер ат тапты, ә мин ерак түгел күршебез Рәхимҗан «купич»тан, ялынып-ялварып дигәндәй, аның рессорлы тарантасын алып тордым. Шулай итеп, без өч шәкерт, биек тарантаска бәләкәй генә атны җигеп, җәйнең матур бер иртәсендә юлга да чыгып киттек. Башта егетләрчә бик кызу гына бармакчы идек, ләкин тискәре, ялкау атыбыз, безне тыңламыйча, күбрәк атлап кына барды. (Яратмады, ахрысы, «купич»ның биек тарантасын.) Без инде, кеше аты булгач, аны артык чыбыркыларга да кыймадык. Әмма барыбер озын юлыбызны күңелле-хозур гына үтеп, көн төшлектән авышканда, Мәрвәр утарына барып та җиттек.

Утар хәйран калырлык матур җирдә иде. Бөтен тирәягы ерактан ук сөзәк кенә түбәнәеп килгән шау чәчәкле тигез ялан. Утарның озын киртәләр белән генә әйләндереп алган ихатасындагы калай түбәле зур гына йортны да, иркен салынган каралтыларны да гүя шушы бер дә тапталмаган чирәм өстенә китереп кенә утыртканнар —

бөтен җирендә чәчәк тә үлән генә... Ә түбәндә куе әрәмәлек арасыннан кечкенә инеш бормаланып агып ята. Инешне кичеп чыгуга, шактый биек, текә тау күтәрелә. Бу ялгыз тау, аның тирәсендә инеш ярыннан башка бер генә калкулык та юк. Тауларга мин һәрвакытта соклана торган идем, әмма ялгыз тауларның бик борыннан саклап килгән, бары үзләре генә белгән тирән серләре бар кебек, шуңадыр, ахрысы, алар күңелдә ирексездән үзенә бер кызыксыну, соклану уята... Әнә тауның нәкъ түбәсендә таза-юан бер агач та (имән булса кирәк) сакта торгандай үсеп утыра. Юк, чынлап та, хәйран матур, күңелле, сөйкемле бу утарның бөтен әтрафы! (Шушы утар күренешен мин бик күп еллардан соң «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндә дә чагылдырырга тырышкан идем.)

Гобәйдулла дус безне үзенчә бик куанып каршы алды, бәләкәй атыбызны да көлә-көлә тугарышты. Ул һәрвакыт шулай муенын сузыбрак, башын аз гына калтыратып көләргә ярата торган иде, мәрхүм! Атны, тугарып, абзар ышыгына бәйләгәч, без әле рессорлы тарантасыбыз янында юл хәлләрен бераз сөйләнгәләп тордык. Аннары Гобәйдулла үзе генә өенә кереп китте. Беренче мәртәбә татар утарына кунакка килгәнгә күрәдерме, без, ниндидер бер ятсыну тоеп, кыенсыныбрак калган идек. Ни булыр, ниләр күрербез, хуҗалар безгә ничек карарлар дигән шөбһәле уйлар иде шикелле безнең һәркайсыбызда. Озак та үтми, Гобәйдулла чыгып: «Әйдәгез, егетләр, өйгә керик!» — дип, безне чакырды. Яшел чирәмдә генә комганнан кулларны югалап, рәшәткә башына элгән озын сөлге белән сөртенеп, өс-башның да тузанын бераз сыпыргалаштырып, Гобәйдулла артыннан өйнең түр як башына уздык. Шәһәрчә дияρлек бай гына җиһазлы иркен зал, урта бер җирдәрәк ак эскәтер япкан зур өстәл, аңа каршы стена буенда яшел бәрхет тышлы озын диван, ә калган өч ягында биек артлы венский урындыклар. Дустыбыз йомшак диванга утырырга тәкъдим итеп караса да, без инде каты урындыкларны үзебез өчен «уңайрак» күрдек. Утырыштык. Залда берәү дә юк. Өстәлгә инде чәй әсбаплары куелган. Төрле ризык-сыйларны Гобәйдулла чаршау корылган бүлмә ишегеннән үзе барып ала. Аңа шул ишектән ике туташ бөтен нәрсәне биреп тора. Чаршау ачылганда гына күренеп киткән бу туташлар бик матурлар кебек иде. Ләкин, ни кызганыч, аларның күренгәләве безнең өчен бик тансык, бик кадерле, әмма вакытсыз өзелгән үкенечле бер төш шикелле генә булып калды. Кемнәр алар, ни өчен Гобәйдулла аларны залга чакырмады, безгә күрсәтмәде — без моны

һич тә аңлый алмадык. Күрәсең, бу йортта әле борынгы тәртипләр нык саклана.

...Ниһаять, өстәлгә ялт иткән сырлы ак самовар да килеп утырды. Шулай дүртәү генә утырып һәм күңелле генә итеп чәй эчәргә керештек. Хуш исле кытай чәен чынаякларга Гобәйдулла үзе ясап, куе сөт өстен дә агач кашык белән үзе салып, безгә бирә торды. Мондый матур кызлары булган бай йортта әдәп белән, чаманы белеп кенә сыйланырга кирәклеген онытмасак та, без, юл килеп ачыкканга күрә, өстәлдәге һәртөрле тәмле камыр ашларын ирексездән шактый ук урдык бугай. Тик Мөхәммәтгали генә гадәтенчә тыйнакланып утырды — сизгәнегез бардыр, бәлки, нечкә күңелле гарибрәк кешеләрнең бер сыйфаты инде бу...

Чәйдән соң без инеш буена төшеп киттек. Ике янәшә бүрәнә генә салынган тар басмадан сай инешне үтеп, әрәмәлек арасында карагат, бөрлегән өзеп капкалагач, әлеге биек тауга юри иң текә җиреннән үрмәли-үрмәли менә башладык. Еш кына аяк таеп китә, түбән шуып та киткәлибез, шулай да, бер-беребезгә кул бирә-бирә, ахырда менеп җиттек. Тау башындагы ялгыз агач, чынлап та, бик мәһабәт таза имән иде, ләкин без аның куе үләнле күләгәле төбенә утырмадык. (Гобәйдулла, монда кара елан булгалый, диде.) Без, күгелҗем сыек томан эченә китеп әкрен генә эреп югалган ялан кырларга карап, тауның сирәк кенә үләнле нәкъ текә кашына утырдык. Моннан ачылган манзара гаҗәеп иде, серле һәм тылсымлы иде. Без ул вакытта барыбыз да шигырь яза идек, хәтта мин дә... Ә табигать бит ул шигърият сарае, шигъриятне табигатьтән һич тә аерып булмый торгандыр инде... Монда да, тау кашына утырып, каршыбыздагы манзарадан сихерләнгәндәй аз гына тын калып торганнан соң, безнең күңел һәм сүзләребез үзеннән-үзе шигырьгә күчте. Гобәйдулла шактый шомарган «шагыйрь» иде инде, күбрәк «һөҗү» (сатирик шигырьләр) яза торган иде. Яттан укуны да ул башлады. Тыңладык, көлдек тә, үзебезчә фикерләребезне дә әйткән булдык. Аннары Мөхәммәтгалидән үтендек. Ул аз гына уйланып торганнан соң, аягүрә басып, шунда ук җитдиләнеп, безне дә оныткандай каядыр еракларга төбәлеп, ашыкмыйча гына үзенең берничә шигырен укыды. Без башларыбызны каера төшеп, бик кызыксынып, хәтта беркадәр көнләшеп тә аны тыңладык. Әйбәт иде аның шигырьләре, гади генә язылган кебек, әмма бик үтемле иде... Инде миңа чират, ләкин Мөхәммәтгали артыннан минем нигәдер укып торасым килмәде, тик дуслар бәйләнеп кыстаганга күрә

генә тар кәгазьгә язган ниндидер бер әйберемне шунда укыган булдым[1].

Билгеле, тау башында укылган шигырьләрнең бер юлы да хәтердә сакланып калмаган һәм бу гаҗәп тә түгел. Күпме еллар узып китте ул чаклардан соң! Яшьлек белән картлык арасы кошлар да очып җитә алмаслык ара ул! Әмма шулай да менә хәзер әйтәсем килә: әгәр Мөхәммәтгали, үкенечкә каршы, бу дөньяны вакытсыз ташлап китмәсә, тора-бара аңардан, бәлки, чын бер башкорт шагыйре дә чыккан булыр иде. Инде шагыйрьлек барып чыкмаса, берәр төрле белем иясе булып китәр иде, чөнки ул, әйткәнемчә, укырга сәләтле, акыллы егет иде. Тик бичараны гариплеге һәм артык йомшак табигате харап итте булса кирәк.

...Кояш та җир читенә әкрен генә, тыныч кына якынлашып бара икән инде... Түбәндә күз җитмәс киңлекләр, ялан-басу түрләренә китеп югалган тар юллар; соры тузан бөтерелми бу юлларда, бөтен әтраф тын, саф, пакь — юк, белмәгәнбез ул чакта без моның чын кадерен, чын бәясен!.. Табигатькә без бик күнеккән идек, бик сирәк аңа соклана торган идек, хәзер генә ул сыкранып ах-вах иткән булабыз... Ахырда кузгалдык, шуа-шуа таудан төштек, инешнең салкын суында битләребезне чылатып алдык. Кайткач тагын дүртәү генә кичке ашка утырдык. Бая хыялларыбызны котыртып өлгергән туташлар бу юлы да безгә күренмәделәр. (Гобәйдулланың әтисен дә күрмәдек, өйдә юк икән, Чуенчы базарына киткән.) Шулай итеп, монда Гобәйдулла үзе генә хуҗа иде, үзе генә каршы алды, үзе генә әйбәтләп сыйлады һәм озатып та җибәрде. Әнә шулай узды безнең татар утарында бердәнбер кичебез. Икенче көнне иртәнге чәйдән соң, без инде рессорлы зур тарантаска җиккән бәләкәй атыбызда Дәүләкәнгә таба тырт-тырт кайтып бара идек.

Солтанай агайның икенче улы Муллагали исә бөтенләй башка «тип» иде. Яшькә минем чамада булыр, ләкин миңа аның белән бик аз аралашырга туры килде. Мәктәпкә йөрүен дә ачык кына хәтерләмим — йөрсә дә бер-ике кыш кына йөргәндер. Урам аша гына торуларына карамастан, Муллагалине юньләп күреп тә булмый иде. Безнең уеннарга да бөтенләй диярлек катнашмый иде. Кыскасы, аның укуда да, уенда да кайгысы булмады шикелле... Сәбәп нәрсәдә? Ә сәбәп башкорт малае өчен бик табигый дә бик гади: аңа бик каты «ат җене» кагылган иде, бар белгәне

---

[1] Буй киселгән тар кәгазьгә баскычлап шигырь язуны мин Казанда күреп кайткан идем инде.— *Ә.Е.*

тик ат, ат, ат кына!.. Атлар кайда — Муллагали шунда, башка җирдән аны эзләмә дә! Хәлбуки аларның үз атлары юк иде. Шуңа күрә Муллагали көн саен диярлек Арыслангәрәй агай ишегалдында көн буе шуларның атлары тирәсендә чуала иде. Билгеле, аны куучы юк, атлар бар җирдә малай кешенең чуалуы бик табигый нәрсә, аңа юньләп игътибар да итмиләр. Шуның өстенә ул әле кул арасына керергә, үзенчә нидер эшләргә дә тырыша. Әйтик, хуҗаның үз улы Таһир урамнан керәсе килмәгәндә (уеннан аерылуы жәл!), Муллагали еш кына кола айгырга атланып бияләрне, тайларны Комачка сугарырга төшерә. Бусы инде аның өчен үзе бер бәйрәм! Һәм иң мөһиме — атлар аны таныйлар, аны үз итәләр — бу инде куаныч кына түгел, чын горурлык та!.. Әнә шулай үтә кеше ишегалдында, кеше маллары тирәсендә малайның көннәре.

1921 елның рәхимсез каты ачлыгы үтеп киткәч, ничектер шактый тиз арада илгә муллык килде. Моны Ленин керткән нэп (яңа экономик политика) нәтиҗәсе диделәр. Нәкъ шул елларда безнең Муллагали дә, ниһаять, атлы булу бәхетенә иреште. Бу вакытта ул ныгып өлгергән уналты-унҗиде яшьлек таза егет иде инде. Һәм шушы яшеннән йөк ташучы булып эшли дә башлады. Егет максатына иреште дияргә ярый — ат бар, атай заманыннан калган кабык арба бар, капчык күтәрергә таза арка да бар — тагын ни кирәк?! Иң мөһиме — ул хәзер үз атын җигеп йөри, үзе «хуҗа». Атка гына түгел, агасына да, инәсенә дә, чөнки «акса»ны да хәзер ул таба! Һәм без, «урам таптаучылар», аңа инде көнләшеп тә карый идек.

Менә бу безгә күрше бөлгән башкорт Солтанай агай малайларының язмышы. Әмма андыйлар Дәүләкәндә аз түгел иде. Алар инде онытылып та беткән. Тик шуны әйтергә кирәк, тегермәннәрдән тимер юлга йөк ташучыларның бик күбесе, Муллагали шикелле, бер атлы башкорт агайлары иде. Язгы-көзге пычракларда казылмалы юллардан бичара атларның көянтәдәй бөгелеп, өзелердәй булып йөк тарткаларын миңа күп күрергә туры килде. Алар сыртына төшкән чыбыркыны Ходай үзе башка җан иясенә күрсәтмәсен. Ни хикмәттер, токымы шундыйга күрәме, башкорт аты, әйтик, немец яки хохол атларына караганда, бәдәнгә кечерәк тә, арыграк та, әмма инде чыдамлылыгына исең-акылың китәр! Чамасыз авыр эш өстенә, бахырга, минемчә, ашату-карау да җитми иде. Мәсәлән, хуҗасы базар каршындагы чәйнигә «җылынып» чыгар өчен кереп китә, ә аты аның җиргә ташлаган бүрек хәтле генә печәнгә башын иеп, күзен йомып тик кенә тора да тора. Көн буе да тора ала ул шул хәлендә!

...Ниләр генә күрмәй ир башы менән ат башы, дип җырлый башкорт үзе дә. Сүз монда йөк ташучы грузчик агай һәм аның үзенә караганда да ныграк интеккән аты турында барды, әмма, сез беләсез инде, кеше язмышы да, ат язмышы да бертөсле генә була алмый. Миңа, мәсәлән, шул ук башкортларның җыеннардан-җыеннарга йөреп даны таралган сөлектәй чабышкы атларын да, киң тугайларда бияләр көтүен куалап, саклап йөртүче, һичкемне якын җибәрми торган бик зәһәр өер айгырларын да күрергә туры килде. Әйе, алар гәүдәгә зур түгел. Ләкин инде гаять җиңел сөякле, бик чая — тынгысыз атлар иде, мәхлуклар!

Менә миндә борынгы бер фото-открытка саклана. Дәүләкәндә чыгарылган, өске читенә «бия саву» дип тә язылган. Фоторәсемдә җәйге башкорт ишегалдының бер почмагы күрсәтелә. Артта утарга чыга торган җил капка, аңа тоташып киткән биек кенә читән койма. Менә шул җил капкадан бирерәк ике агай басып тора. Шуның берсе — озын куллы, озын буйлысы, кыяфәтенә караганда, һичшиксез, хуҗа булырга тиеш: башында — яңа кара түбәтәй, өстендә — ак күлмәк, кара камзул, кара чалбар, аягында — кәвешләр. Аңардан чак кына уңдарак башына ак яулык ураган, өстенә әдрәс камзул кигән бичә, чүгәләп, муенына озын корык салган ап-ак бияне савып тора. Икенче ак бияне кемдер ялыннан тотып (рәсемдә аның куллары гына күренә), саудырырга чиратын көтә. Менә шушы ике ак бия арасында хуҗаның малае — яше чама белән унике-унөчтә булыр. Башында тасмалы яңа эшләпә, өстендә бер очтан ябык якалы кара пинҗәк белән кара чалбар, аягында күн итекләр. Күренә ки, бу фотога, һичшиксез, бай тормышлы чын башкорт гаиләсе һәм өлешчә аның хуҗалыгы да төшерелгән. Әйтәсе дә түгел, бик колоритный фото!.. Тагын шунысы кызык, рәсемдәге озын таза башкортны минем атакай мәрхүм таныды: «Бу яңа Көрмәнкәйдән Мостафа агай!» — диде. (Яңа Көрмәнкәй — Эткол очындагы кечкенә генә авыл. Арада бер сай чокыр гына иде. Хәзер бу авыл юк. Ә Дим аръягындагысы Иске Көрмәнкәй дип йөртелә.)

Мостафа агай шикелле бай башкортлар якын-тирә авылларның һәркайсында диярлек булган ул заманда, кайберләрен мин дә әле күреп белә идем. Әйтик, Акколадан Гани агайны — Дәүләкән базарына тәпән-тәпән бал төяп китерә торган иде. Нәкъ теге фотодагы шикелле аның да шәптән киенгән малае базар саен атасына ияреп килә иде. Атасы бал сатканда, малай, арба башында ак калач ашап яки көнбагыш ярып, аякларын селкеп

утыра иде. Тик күпмегә сузылгандыр малайның бу бәхетле чаклары?!

Инде укучыда табигый рәвештә икенче бер сорау туарга мөмкин: хуш, ә бу күп милләтле Дәүләкәндә татар-башкорт мөнәсәбәтләре ничек иде?

Әйе, ул мөнәсәбәтләр турында мин үзем дә еш кына уйланам һәм, билгеле, ачык сорауга туры җавап та бирергә кирәктер. Хәзер менә Дәүләкәндәге тормышыбызны искә төшереп әйтәсем килә: мөнәсәбәтләр, һичшиксез, якын, тату, әйбәт иде. Безнең, мәсәлән, башкортлардан дуслашып йөрешкән, хәтта туганлашкан кешеләребез дә бар иде. Минем инәйнең бертуган сеңлесе Кәримә тутакайның Өммегөлсем исемле дәү кызын Шәрип авылының Котлыяр мулла улы Миңнемөхәммәткә туйлап кияүгә бирделәр. Башкорт йоласы буенча, Миңнемөхәммәт җизни бер ел чамасы кияүләп йөрде, бары шуннан соң гына Өммегөлсем апабызны Ташлыкүлдән Шәрипкә килен итеп төшерде. (Бу ике авыл арасы бер илле чакрым булыр.) Инде Дәүләкәннең үзендә татарга өйләнү яки башкортка чыгу гадәти бер күренеш иде.

Әлбәттә, бу икесе — ике халык. Татары — татар, башкорты — башкорт, моны яшерү дә, моңардан качу да юк иде. Һәркайсының үз халкы үзенә туган анасы кебек, һәркайсы шул халыкның исемен мулла кушкан исем шикелле йөртә иде. Ихтимал, бик сирәк очракларда гына аерым кеше, ниндидер фани исәпләрдән чыгып, «исемен» үзгәрткәндер, ләкин миңа андый хәлне Дәүләкәннең үзендә ишетергә туры килмәде. (Бердәнбер фәүкылгадә[1] вакыйга — ул да булса Миһранның чукынуы булды. Бу хакта югарыда язган идек инде.)

Билгеле ки, татар белән башкортны якын иткән сәбәпләр күп иде: дин бер, тел бер диярлек, тарихи язмышларда да уртаклык зур. Һәр ике халык Бөек Октябрь революциясенә чаклы хокуксыз булган, патша самодержавиесе тарафыннан каты изелгән... Бөек Тукай, патшаның үзенә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп:

Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? —
Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук! —

дигән һич тә икеләнмичә! Халык шагыйре әнә шундый була ул!

Ә башкортларның ике йөз ел дәвамында (XVII—XVIII гасырларда) «ак патша»га каршы өзлексез баш күтәрү-

[1] *Фәүкылгадә* — гадәттән тыш.— *Ә.Е.*

ләре әнә шул хокук, тигезлек, гаделлек өчен кан кою түгел идемени?! Бу баш күтәрүләрнең бик күбесенә татарлар да катнашкан. Димәк, уртак язмыш ике халыкка да бер-берсенә якын торырга, терәк-таяныч булырга кушкан.

Кечкенә Дәүләкәндә дә без әнә шул борыннан килгән язмышлар бәйләнешен тоеп яшәдек дияр идем мин. Хәтта кайбер очракларда читләшүгә охшаш нәрсә булуга да карамастан... Ни дисәң дә татар Дәүләкән җиренә читтән килгән, димәк, аңа «килмешәк» дип карарга да була, ул моны үзе дә сизә һәм вакыт-вакыт башкорт авызыннан да ишеткәли иде. Әмма татар — колонизатор түгел, аны башкорт җиренә патша хөкүмәте күчереп утыртмаган. Күрдегез инде, ул бу якларга бәләкәй арба тартып, җәяүләп килгән — авыр нужадан һәм золымнан котылу өчен аның башка юлы да булмаган. Тарих үзе аны шулай югалмаска, бетмәскә өйрәткән. Аннары килүчеләр барысы да сәүдәгәр булып киткән икән дип уйлау да хата булыр иде. Юк, килүчеләрнең күпчелеге хезмәт иясе — тимерче, кием тегүче, пима басучы, приказчик, извозчик, укытучы һәм тегермәннәрдә эшләүчеләр иде. Кыскасы, татар-башкорт арасы тормышның үзендә бик күп җепләр белән бәйләнгән таза, нык мөнәсәбәтләрдән гыйбарәт иде.

Мин үскәндә, Дәүләкән имамы Искәндәр ахун — башкорт, ә мөәзине Нәбиулла абзый татар иде. Мәчет каршында урам аша гына иркен ихата эчендә ике йорт — берсе гади бүрәнәдән, икенчесе — зуррагы, такта белән тышлап, сарыга буялган. Болар мәдрәсә — Искәндәр ахун мәдрәсәсе дияләр иде. Кечерәгендә иптидаи (башлангыч), ә зуррагында рөшди (урта) сыйныфлар укый иде. Рөшдидә укучыларның күбесе Дим буе башкорт авылларыннан килгән яшьләр — укулары да, торулары да шул сары мәдрәсәдә иде. (Бу мәдрәсә хәлләре турында мин кайчандыр «Коръән Хафиз» исемле хикәямдә язган да идем.)

Менә без дә, ягъни минем яшьтәге татар һәм башкорт малайлары, башта бер-ике кыш ахун мәдрәсәсендә, аннары инде гел совет мәктәбендә бергә укыдык. Укулар, билгеле, татар телендә иде. Чөнки ул заманда бөтен дәреслекләр һәм әдәбият китаплары бары татар телендә генә чыга иде. Шулай ук укытучыларның барсы да татарлар иде. (Хәер, дин сабагын соңыннан безгә мәчеттә Әхмәдия мәхзүм укытты.) Гомумән, уку-укыту эшләре Дәүләкәндә күптән, сәүдә эшләре җанланып киткәч тә, башланган булырга тиеш. Революциягә чаклы ук анда кызлар мәктәбе дә булган. Махсус салынган йорты Этколның иске зираты кырында иде. (Бу зират, Эткол зурайгач, авыл уртасында торып калды.) Кызлар мәктәбе

өчен дә укытучыларны читтән чакырганнар. Шулай ук анда Искәндәр ахунның үз кызы Гайшә апа да укыткан. Гайшә апа бик сылу, чибәр кыз иде, соңыннан, егерменче елларның башында, Таһиров дигән бер башкорт юристы килеп, өйләнеп, аны Уфага алып китте. Кияүне баш мәхкәмәдә эшләүче зур кеше дип сөйләделәр белгән кешеләр.

Дәүләкәндә шулай ук үзенә аерым татар китапханәсе дә бар иде. Заманына күрә шактый бай китапханә булгандыр, ахрысы, чөнки мин, мәсәлән, ул чактагы бик күп татар китапларын шуннан ташып укыдым. Укырга яратучы өлкәннәр дә, малайлар һәм кызлар да шул китапханәгә йөриләр иде. Аннары сәүдәгәр өйләрендә, бигрәк тә приказчикларда, элегрәк чыккан газета-журналлар да саклана иде әле. «Ялт-йолт», «Ак юл», «Сөембикә», «Аң» һәм «Шура» журналларын мин башлап Дәүләкәннең үзендә күрдем, кайберләрен сорап алып укыштыргаладым да. Янә тагын әби, бабай булган өйләрдә шулай ук «Тутыйнамә», «Бакырган», «Бәдәвам», «Бүз егет», «Каһарман катыйл» кебек укыла-укыла тузып беткән борынгы китаплар да табыла иде. Бик ялварып кына шуларны миңа кулга төшерергә һәм аңлый алганнарын укып карарга да туры килде. Инде ачлык елы үтеп, тормышлар бераз рәткә кергәч, Уфадан, Казаннан һәм Мәскәүдән татар телендәге совет газета-журналлары да килә башлады. Болары безнең өчен, әйтәсе дә түгел, бик яңа, бик кызыклы иде, без аларны кулдан-кулга йөртеп укый торган идек. Минем үземә Уфада чыккан «Белем» журналы һәм Мәскәүдән килгән «Кечкенә иптәшләр» бик ошаган иде.

Әйе, ул чакларда ана телендә уку күңел ихтыяҗына әйләнгән, гадәткә кергән бер эш иде. Телне безгә нык өйрәткәннәр, уку, язу, сөйләү саф үз телебездә, шуңа күрә китапка хөрмәт тә зур иде. Һәм бу тел — татар теле — башкорт яшьләре өчен дә бердәнбер укый-яза торган тел иде. Сары мәдрәсәдә ятып укыган башкорт шәкертләре шушы телдә китапча югары ыслуп белән, сүзләрнең дә иң матурларын гына сайлап, кәгазь читенә буяулы каләм белән чәчәкләр ясап, хәтта каләм тоткан бармакларын да төшереп, танышасы килгән кызларына хатлар язалар иде.

Аннары ул чакта укучы малайлар һәм кызлар арасында «ядкарь дәфтәре» тоту дигән нәрсә дә бар иде. Шул дәфтәрне бер-берсенә биреп, ядкарь яздыралар иде. Минем дә булган андый дәфтәрем. Искереп бетсә дә, ул

дәфтәр 1921 елдан бирле һаман әле миндә сакланып яткан. Бергә укыган күп кенә малайлар һәм кызлар шуның битләренә үзләренең ядкарьләрен язганнар: күбесе миңа «иптәшем» дигән, «шәригем» дигән, ләкин арада «Әмирхан әфәндегә» дип куйганнары да бар. (Унике яшьлек малайга!) Димәк, иске гадәтләр онытылып бетмәгән әле ук чакта.

Шул дәфтәрдәге ядкарьләр арасыннан берсен генә монда китерәсем килә. Кыска гына ул һәм бик матур кул белән язылган:

«*Тәзкирәм*[1].
Нәрсә языйм синең альбумыңа?
Матур язарга белмимен,
Сезнең бәхетле булуыңызны
Ихлас күңел илә телимен.

Сезнең кыйммәтле альбумыңызны былчыратканым өчен гафу үтенәм.

Апаңыз: Г.Ишаева. $19\frac{27}{1}21$".

Моны язучы — әлеге үзе дә кызлар мәктәбендә укыткан Гайшә апа. Билгеле, мин дәфтәремне аңа бирмәгән идем, ә үзем белән бергә укучы энесе Исмәгыйльгә биреп торган идем. (Исмәгыйль миңа ядкарь итеп Тукайның «Танса» шигырен күчереп язган.) Күрәсең, шул чакта күзенә чалынган дәфтәргә Гайшә апа да үзенең тәзкирәсен язып куйган. Чын башкорт кызының саф татарча язуы берәүне дә гаҗәпләндермәсен. Чөнки бу ул заман өчен табигый күренеш, чөнки элек-электән үк башкортның муллалары, мөәзиннәре дә, соңрак мөгаллим-мөгаллимәләре дә — төрле өяз һәм шәһәрләрдәге татар мәдрәсәләрен яки мәктәпләрен бетереп чыккан кешеләр. Хакыйкатьне яшерүдән мәгънә юк, тик моны дөрес аңларга кирәк. Мәсәлән, борын авылда күршедән ут алып чыгу гадәте булган. Утны соскы белән алып чыккан, учагына яккан, өен җылыткан — күршесенә рәхмәтен әйтергә дә онытмаган. Аң-белем бирүне дә мин шул ут биреп торуга охшатыр идем. Татар халкының учагында мәгърифәт уты иң авыр заманнарда да сүнеп бетмәгән, калын көл астында да әкрен генә көйрәп яткан ул, ә тора-бара, Россиядә азатлык хәрәкәте көчәйгәч, яңадан кабынып, ялкынланып киткән. Менә шул утны ул ихтыяҗы төшеп килгән кардәш халыкларга да биргән. Ә башкорт халкына аеруча, чөнки ул терәлеп торган күрше, аңардан инде кызганып тору булмаган. Хәзер менә башкорт халкы-

[1] *Тәзкирәм* — истәлегем.— *Ә.Е.*

ның үзендә аң-белем, культура, сәнгать утлары дөрләп яна. Бу — Ленин милли сәясәтенең иң гүзәл, иң куанычлы бер нәтиҗәсе. Моңа татар халкы да ихлас күңелдән куана — ничек кенә булмасын, аның да бит башкорт культурасына һәм сәнгатенә керткән зур өлеше бар. Әйдә, моннан соң да аралашып яшәгән бу ике кардәш халыкның дуслыгы отыры ныгый барсын, икесенең дә белем, культура учаклары якты, тигез янсын — чөнки дуслыкның төп нигезләреннән берсе һәм иң мөһиме — тигезлек! Һәр эштә, һәр җәһәттән!

Әйе, Дәүләкән күп кенә милләтләрне үзенә җыйган шәһәр сыманрак зур бер авыл иде. Ләкин минем үземә бу милләтләр арасында нинди дә булса зур, җитди каршылыклар яшәп килүен күрергә туры килмәде. Чөнки мин үскәндә инде революция булган, Совет власте урнашкан, милли тигезсезлекләр бетерелгән иде. Дәүләкәндә дә яңа заман, яңа тормыш башланды. Әмма бу яңа заманның нэп дигән кыска гына бер чоры булып алды. Әйтерсең иске тормыш бермәлгә кире әйләнеп кайтты. Сугышлар бетеп, ачлык елы да үтеп киткәч, кыска гына вакыт эчендә Дәүләкәнгә төрле яктан әүвәлгечә иген күпләп керә башлады. Тегермәннәр эшләргә тотынды, базарлар җанланып китте, кибетләр-магазиннар ачылды, элекке сәүдәгәрләр генә түгел, һич уйламаган кешеләр дә җиң сызганып сату итәргә кереште, кыскасы, иске тормышның күп кенә якларын шушы чорда тагын бер тапкыр күреп калырга туры килде. Минем әле үсмер чагым, яңа җитлегеп килгән чагым иде, шуңа да карамастан бу хикмәтле вакыт минем хәтердә шактый нык утырып калды. Әмма шундый кинәт җанланып киткән «иркен» тормыш озакка бармас, тиз бетәр кебек иде,— нигә, ни өчен? — әйтә алмыйм, бәлки, Ленин бик иртә, бик вакытсыз үлеп киткәнгә күрәдер, чөнки бу нэп дигән нәрсәне ул кирәк тапкан, ул керткән дип сөйлиләр иде. Һәрхәлдә, дөньяның тиздән башка якка үзгәрәчәген мин акылым белән түгел, ничектер йөрәгем белән сизә идем кебек... Шуның нәтиҗәсендә булса кирәк, миндә бик иртә уйлану, борчылу, эзләнү дә туа башлады. Шул ук вакытта күңелнең бу борчылу-ашкынулары, ә кайчагында газаплы кичерешләре яшь өстәлә барган саен отыры көчәя, тирәнәя дә бара иде. Кемгә генә таныш түгел яшьлекнең андый кичерешләре?! Минем өлешемә исә алар күбрәк тә төште. Менә ни өчен мин нэпның иң кызган чагында, уналты яшемнән үк Дәүләкәнне калдырып чыгып та киттем. Ләкин боларның барсы турында да миңа, насыйп булса, бу китапның соңгы өлешендә язарга туры киләчәк.

Хәзер исә бу «Дәүләкән» өлешен менә нәрсә белән бетерәсем килә. 1981 елның җәендә мин соңгы тапкыр Иске Көрмәнкәй авылында булдым. Хәтерләсәгез, Көрмәнкәйдә торучы Хәмит дустымның һәм аның бичәсе Сәгыйдәнең кыска гына вакыт эчендә үлеп китүләрен, ләкин, кызганычка каршы, аларның каберләренә бара алмавымны башта ук язган идем инде. Бу юлы Дәүләкәнгә кайтуым да бары бер теләк — шул дусларымның каберләрен зыярәт кылу өчен генә иде.

Безне, ягъни мине һәм Уфадан бер-ике көнгә генә кайткан минем бала чактан ук якын кешем Маһирәне, «Салават» колхозының машинасы Көрмәнкәйдән килеп алды. (Машинаны райбашкарма комитеты председателе Равилов иптәш чакырткан булган.) Алырга килүчеләр дә колхозның баш агрономы белән партоешма секретаре иде. Озак юанмыйча утырдык та киттек. Башта туп-туры Хәмит өенә барып туктадык. Менә кайткан саен күпме сыйланып, күпме сөйләшеп утырган иске генә өй... Әмма хәзер монда торучы юк икән инде, ул ташландык-буш, аны тиздән сүтәргә тиешләр. Шулай ук Сәгыйдәнең безгә ашлар пешергән, балыклар кыздырган читән алачыгы да юк — анысын бөтенләй сүтеп ташлаганнар. Шулай итеп, хуҗалары белән бергә аларның гомер иткән җылы почмаклары да киткән яки китәргә тора бу фани дөньядан!..

Аның каравы, Хәмитнең кече улы шушында ук, капканың уң ягында гына зур таза йорт салдырып ята. Урам башын өлгерткән дә инде, тик эчке башы гына салынып бетмәгән әле... Егетне атасы кебек бик тырыш, уңган диделәр безгә, ләкин үзен күрә алмадык, эштә булып калды. Ә хатынын күрдек һәм миңа бераз гаҗәп тә тоелды: ул әле түгәрәк йөзеннән балалык чырае да китеп бетмәгән бик яшь кенә, бик сөйкемле башкорт кызы иде, ләкин инде ике бала анасы, берсе кулында — Алсу исемле икән. Аталарыннан калган нигездә әнә шулай яңа, яшь тормыш таза үсентедәй күтәрелеп килә. Әйе, бу да бик табигый хәл, бик табигый күренеш!

Аннары каберлеккә киттек. Яшь кенә килен дә баласын күтәреп безгә иярде. Хәмит өе авылның иң читендә иде, аны узгач та сөзәк кенә Көрмәнкәй тавы башлана. Кечкенә каберлек менә шул тауның итәгеннән бераз өстәрәк, калку урында, авыл очыннан бер ике йөз метрда гына булыр... Барып җитү белән үзебезгә кирәк каберләрне күрдек. Икесе дә янәшә генә, Хәмитнеке аз гына өстәрәк, икесенә дә гади генә ак таш куелган, тар гына рәшәткә тотылган... Ташларына уелган сүзләрне укыдым: Хәмит 1976 елның ноябрендә, ә Сәгыйдә 1977 елның

мартында вафат булганнар... Аралары бик якын шул, бары өч кенә ай... Ашыккан Сәгыйдә Хәмите янына... Әмма уңайлы урында яталар — югарыда. Моннан гомер иткән өйләре — ишегаллары әнә генә, Дим дә яныннан гына уза, печән өстендә икәүләп йөргән болыннары, Сәгыйдәнең карагат, бөрлегән җыйган әрәмәлекләре, Хәмитнең балык тоткан күлләре, хәтта аның әнә туып-үскән Дәүләкәне дә — барысы да ап-ачык күренеп тора. Ерак китмәгәнсез икән сез үзегезне чорнаган дөньядан — гүя авылдашларыгызга, балаларыгызга, менә бу кечкенә оныкларыгызга тыныч кына карап ятасыз!.. Эчемнән генә дога укыгандай әйтәсем килде: сез тир түгеп шушы җирне сугарган бик гади, бик самими кешеләр идегез — иң элек сезгә төшсен бу җирдә яшәүчеләрнең рәхмәте дә! Хушыгыз, дусларым, хушыгыз!

Ике кабер янында һәркайсыбыз эчтән генә уйлап бераз басып торганнан соң, без әкрен генә кузгалдык. Калкулыктан төшеп, «Жигули»га утыргач, егетләр безне Ярыштауга алып киттеләр. Вакыт тыгызрак тыгызын, ләкин мин каршы килмәдем. Мондый форсаттан файдаланмыйча ярамый иде, әлбәттә. Кайткан саен каршы алган, киткән саен озатып калган тавым бит ул минем!

Ярышның Дим буена озын сәкедәй карап торган беренче катына безне машина үзе алып менде. Хәзер без аның каплап куйган казандай иң биек икенче каты янында басып торабыз. Бусы инде Ярыштауның үзе!.. Егетләр миңа әйтәләр: «Әйдә, агай, түбәсенә дә меник»,— диләр. «Менәргә... Ничек итеп?» «Туп-туры җәяүләп кенә!» — диләр егетләрем. Мин ирексездән көлеп башымны чайкыйм: «Ай-һай, миннән булыр микән, егетләр?!» «Булыр, булыр, курыкмагыз, үзебез җитәкләп мендерербез!» — дип кыстыйлар һаман мине... «Биеклеге күпме соң?» «Итәгеннән алып өч йөз илле метрлар чамасы, яртысын почти мендек инде»,— диләр... Эчемнән генә уйлыйм: «Алай күп тә калмаган икән, ләкин мин бит Матбугат йортының дүртенче катына да туктамыйча менеп җитә алмыйм. Күпме булыр ул, унбиш-егерме метр, ә бу йөз илле метрдан да ким булмас. Минем өчен бик күп шул. Җитмәсә, Бишбүләктә ике көн кунак булып кайтып килгән чак... Йөрәк күтәрә алыр микән? Әмма менә алганда кызык та булыр иде... Ярышка мин унике-унөч яшьләремдә бер менгән идем, хәзер миңа җитмеш өченче яшь... йөрәктә стенокардия... Тәвәккәлләргәме-юкмы?» Һәм мин тәвәккәлләргә булдым. Әнә миннән өч яшькә олырак Маһирә карчык та менәбез дип тора... Киттек менеп... Ашыкмаска тырышам, аякларны җиргә

нык терәп, салмак кына атлыйм. Бер генә тапкыр туктап тын алдым, егетләргә кулымны да биреп тормадым... Ниһаять, менеп җиттек... Йөрәккә колак салам: юк, кысуы да, авыртуы да сизелми... Бик гаҗәп иде бу минем өчен... Хикмәт нәрсәдә?.. Хәер, тиз сиздем мин моның серен: һава, һава, һавада бөтен хикмәт!.. Шундый саф, шундый коры, шундый җиңел мондагы тау, дала, кылганлы сәхрә һавасы!.. Киерелеп, бавырларга үтәрлек итеп сулыйм, юк, туеп булырлык түгел — мондый һава имгәнгән йөрәкне дә йөз ел яшәтер!..

Тау башыннан ачылган ерак, күксел, чиксез киңлекләргә туйганчы бер карарга өлгермәдек, тагы да гаҗәбрәк икенче бер күренешнең шаһиты булдык. Тау түбәсенә, аның да текәрәк ягыннан, таякка таянган бер карчыкның, тар чалбар кигән унике-унөч яшьлек кыз балага тотынып, менеп җиткәнен күреп алдык. Кайдан, нинди карчык бу?.. Мин янына барып сорашмакчы булдым, әмма ул дөм сукыр һәм чукрак булып чыкты. Кыз баладан: «Әбиең ничә яшьтә?» — дип сорадым, кыз, сиксән җиде яшендә, диде. Бик аптырап: «Шушы яшендә ничек итеп һәм ни өчен менә ул?» — дип сорагач, кыз әбисенең шушындагы кабергә Коръән укыр өчен менүен аңлатты. Әйе, минем малай чактан ук исемдә калган ялгыз кабер һаман монда тора икән, тик ул инде җир белән тигезләнеп беткән, урта бер җире уелган да, ләкин кемдер аны, кыска гына казыклар кагып, тимерчыбык белән генә булса да уратып куйган... Карчыкның бу кабергә беренче генә менүе түгел күрәсең, ул кыз ярдәменнән башка туптуры кабер янына барды да, иң элек аның өстенә вак тәңкәләр ташлады, аннары чирәмгә аякларын сузып утырып, кулларын тезләренә куеп, авыз эченнән генә Коръән укый башлады. Без барыбыз да тынып калдык. Ләкин карчыкның Коръән укыган җирендә казык шикелле басып торуыбыз килешми иде кебек, томаналыгыбызны сизгәндәй, нининдер бер уңайсызлану да кичерә идек шикелле, һәм шуңа күрә без, карчык изге гамәлен үзе генә үтәсен инде дип, шыпырт кына түбән төшеп киттек.

Ләкин төшеп машинага утыргач та, минем ике нәрсәгә эчем поша башлады: беренчедән, изге ният белән азапланып тауга менгән карчыкка бераз гына булса да сәдака бирмичә китүемә үкендем, ничек бу исемә килмәгән дип, эчемнән генә үземне тиргәп тә алдым. Дөрес, сәдака бирүем яшьләргә сәер дә тоелыр иде (язучы бирә бит), әмма барыбер кирәк булган — күңелне сафландыру өчен кирәк булган ул... Борыннан килгән бер йола — аны үтәүдән кемгә ни зарар?! Ришвәт (взятка) бирү түгел ич!..

Икенчедән, карчыкның кем булуын ачык кына белмичә киту дә кызганыч иде. Үзе чукрак, үзе сукыр карчык миңа ничектер бер хикмәт иясе булып тоелган иде... Янымдагы егетләрдән сорап карадым, ләкин алар да бик аз белә икән: Дүртөйледә, картаеп пенсиягә чыккан улында тора, җитәкләп менгән кыз оныгының баласы, ә карчык, чын булса, китап укый-укый сукырайган, диделәр. Шуннан артыгын мин белә алмадым. Кызганыч!.. Уйламаганда гына хикмәтле кешеләр очрап куя, ләкин без һәрвакыт, әлеге каһәр суккан ашыгу аркасында, аларны күрмичә узабыз да китәбез. Шулай да егетләремә әйтүне кирәк таптым: сез ул карчыкны яхшырак белергә тырышыгыз әле... Кем каберенә йөри ул, кемне зыярәт кыла?.. Бер батыр кабере дип минем дә малай чакта ук ишеткәнем бар иде. Билгесез гади бер кешене генә Ярыш төбәсенә мендереп күммәсләр. Бәлки, картлардан тагы да белүче бардыр... Ә ул каберне рәтләп, баш очына таш та куйдырсагыз, бик күркәм бер эш эшләгән булыр идегез, дидем.

Егетләрем минем белән килешкәндәй булдылар.

Әмма шулай да мин бүгенге сәфәремнән ифрат та канәгатьмен. Иң элек күптән күңелемдә йөргән теләгемне үти алдым — Хәмит белән Сәгыйдәнең каберләрендә булдым, изге догасыз гына булса да, үземчә аларны зыярәт кылдым. Аннары менә алтмыш елдан соң икенче мәртәбә Ярыштау башына мендем, дөньяны күрдем, дөньяның бик борыннан килә торган, тик без генә оныткан серләрен сизгәндәй булдым. Бер көн өчен бу һич тә аз түгел иде. Чын канәгатьләнү кичергән мондый көннәр безнең гомердә еш булып тормый ул!..

Кайтышлый, Дүртөйле очында, Димнән якында гына нефть чыгаручы ике качалканың ашыкмыйча гына бер җайга селкенеп торуларын күрдем. Монда да тапканнар икән... «Димкәем, сиңа да чират җиттемени?!» — дип уздым мин бу качалкалар яныннан... Ә алар, «тагын да кайтырсың әле» дигән төсле, һаман шулай гамьсез-салмак кына башларын селкеп калдылар.

## СӘХИФӘЛӘР

...Үткәнгә кайтуны дәвам итәбез... Язманың бу өлешенә «Сәхифәләр» дип кыска һәм гади генә исем куясым килде. Чөнки кеше гомеренең һәр көне — бер сәхифә. Билгеле, дөньяда озак яши торгач алар бик күп җыелган — менә шуларны мин күздән кичермәкче булам. Аларның бик күбесе бер-берсен кабатлыйлар (безнең көннәре-

без шикелле үк), арада үзем өчен генә кадерлеләре бар, шулай ук ачып карыйсы килмәгәннәре дә юк түгел. Әмма бөтенесендә дә мин белгән кешеләр, мин күргән тормыш, мин кичергән заман. Минем бурыч исә шулардан үзем кирәк дип тапканны сайлап алу һәм сөйләп бирү — менә шул шактый четерекле эшкә мин тәвәккәлләп керешмәкче булам. Кабатлап әйтәм, бу «сәхифәләр» бары минеке — минем күргән һәм кичергәннәрем!

...Искә төшерик: бу китапның «Каргалы» өлешендә язылганча, минем атам 1910 елның көзендә Каргалыдан Дәүләкәнгә (искечә Этколга) күчеп килгән. Мин бу вакытта бишектән дә әле төшеп җитмәгән яшь ярымлык сабый гына булганмын. Күз күрсә, колак ишетсә дә, миндә әле хәтер дигән нәрсә юк, мин әле һичнәрсә белмим — мин бары ашый беләм, йоклый беләм, көлә беләм, җылый беләм. Әмма ничек итеп көләм яки җылыйм — бусы да миңа билгесез... Кыскасы, дөнья миннән еракта,бик еракта әле, җиде диңгез артында!

Кеше бала чагында үзенең картлыгын күз алдына китерә алмаган шикелле, картайгач, ул бала чагын да күз алдына ачык кына китерә алмый икән. Ә инде сабый чакны әйтеп торасы да юк — сабый чактагы хәлләрне без бары соңыннан әти-әниләребездән яки якын туганнарыбыздан ишетеп кенә белә алабыз. Хуш, нәрсәләр ишетеп белдем соң мин Дәүләкән[1] белән бәйләнгән сабый чакларым турында?

...Иң элек шуны әйтергә кирәк: безнекеләр башта Дәүләкәннең үзенә түгел, ә аңа терәлеп үк торган Яңа Көрмәнкәйгә килеп төшкәннәр һәм шунда яшәүче Муллый карт дигән бер башкортның өенә вакытлыча кереп торганнар. Бер генә урамлы бу кечкенә авыл Дим аръягындагы Иске Көрмәнкәйдән күчеп утырган булса кирәк, шуңа күрә аның исеме дә Яңа Көрмәнкәй дип аталган. Дәүләкәннең югары очы белән бу авыл арасында, мин үскәндә, бер сай чокыр гына иде. Хәзерге вакытта Яңа Көрмәнкәй юк, беткән, аны күптән инде Дәүләкән «йоткан».

Шул рәвешчә, без башта күпмедер вакыт Муллый карт өендә торганбыз. Муллый карт ул минем бабакайның электән үк йөрешкән дус кешесе икән. Бай башкорт, күп җир биләгән, ишле мал асраган, шуның өстенә Дәүлә-

[1] Хәзерге Дәүләкәннең ул заманда Эткол дигән авыл җирендә үсеп киткәнен күргән идек. Ләкин укучыны саташтырмас өчен мин моннан соң Дәүләкән исемен генә кулланачакмын.— *Ә.Е.*

кәннең үзендә аның ике катлы тагын бер йорты да булган. Нәкъ базар күзендәге шушы асты таш, өсте агач зур гына йортын Муллый карт минем атакайга арендага биреп торган. Атакай бит Дәүләкәнгә, онытмаган булсагыз, сәүдә итү максаты белән килгән, аңа тизрәк эш башларга кирәк булган, ә кулында сумасы зур булмаган (әйтүенә караганда, бер өч йөз сум чамасы гына), шулай да ул, тәвәккәлләп, Муллый карт йортында «чәйни» (чәйханә) ачып җибәргән. «Аллага тапшырып эшне башлауда Муллый бабаем бик ярдәм итте»,— дип яза ул үзе дә.

Шулай итеп, Каргалыдан килгән яңа «сәүдәгәр» үзенә бөтенләй таныш булмаган бер эшкә тотына. Ярый, тәвәккәл — таш йоткан, диләр, ә без карап карыйк, нәрсә икән ул атай ачкан «чәйни»? (Бөтен җирдә чәйханә, ә Дәүләкәндә ни өчендер «чәйни»! Ахрысы, русның «Чайная»сыннан шулай үзгәреп киткәндер инде.) Ул, ягъни мәсәлән, безнең «чәйни», гади генә бер ашап-эчеп чыгу урыны булган. Анда зур чуен чүлмәкләрдә турап салган куе итле, кулдан гына кискән эре токмачлы өреле аш пешкән, чиләк сыешлы җиз самоварларда чәй өчен өзлексез су кайнап торган. Ә чәйнең үзен фарфор чәйнекләрдә пешереп биргәннәр. Бу эшләрне бер аш пешерүче белән бер ташып торучы (половой) башкарган. Эш кызып киткәндә, атакай үзе дә булышкан, ләкин ул күбрәк базардан кухняга азык ташыган, ә инәй гел генә савытсаба юып, сөртеп торган. «Чәйни»дә бернинди хәмер заты сатылмаган һәм тәмәке тартып утыручы да булмаган.

Эшнең иң кызу, тыгыз чагы, гадәттә, базар көненә туры килгән. Бу көнне «чәйни»гә базарчы агайлар кереп тулган. Ашау, эчү арзан булган, мәсәлән, ике тиен түләп, чәйне теләсәң нихәтле эчәргә яраган. Бер җамаяк куе аш та ун тиен генә торган шикелле — сөйләүләре буенча шулайрак хәтеремдә калган. (Гомумән, ул елларда азык әйберсе арзан йөргән, мәсәлән, тере сарык ике сум илле тиен — өч сум торган, диләр иде.) Шуңа күрә дә агайлар чәйне күп эчәргә яратканнар. Кыш көне булса, кайры туннарын да салып тормыйча, тик бүрекләрен генә салып, шабыр тиргә батып, «агып киткәнче» чәйне эчәләр дә эчәләр икән. Ашаганнары ак калач яки юкә бауга тезгән йомшак клиндер, тик шикәр генә күп түгел — чәйне ун чәшке эчсә дә, шикәрне бер генә кисәк биргәннәр. Хәер, акчаларын җәлләмәгәннәр, базардан үзләре белән йөзем, хөрмә, хәлвә кебек тәмле-тәмлене дә алып кергәннәр.

Базарсыз көннәрдә исә «чәйни»гә йөрүчеләр әллә ни күп булмаган. Төш вакытында яки кичен ялгыз приказ-

чиклар, извозчиклар һәм ломовойлар, мәдрәсәдә ятып укучы хәллерәк шәкертләр кереп, ашап-эчеп чыга торган булганнар. Аннары безнең «чәйни»гә ни сәбәптер Дәүләкән саилчеләре[1] дә ияләшкәннәр. Зур базарлы сәүдә җире саилчеләрне һәрвакытта үзенә тарткан — берәүләре гариплеге аркасында бүтән эшкә ярамаган, икенчеләре исә хәер сорашуны үзләренә кәсеп итеп тә алганнар. Менә шулай һәр көнне өй борынча урам йөреп, озын киндер капчыкларын сынык-санак белән тутырып, безнең «чәйни» янына кайталар икән дә, баскыч төбенә утырып, барлык җыйганнарын бушатып, сортировать итәргә тотыналар икән. Ап-ак оннан пешерелгән иң тәмле, йомшакларын гына үзләренә калдырып, башка каты-котыларын минем инәйгә: «Мә, абыстай, сыерыңа ашатырсың!» — дип бирәләр икән. Аннары «чәйни»гә кереп, әйбәтләп чәй эчәләр дә кайдадыр үзләренең куна торган җирләренә кайтып китәләр икән. Минем инәй дә аларны ярым көлеп, ярым сагынып дигәндәй, вакыт-вакыт исенә төшергәли иде.

Менә шундый саилчеләрнең берсе бөтен авыр һәм хәтәр елларны (ачлык елын да) исән-сау үткәреп, мин малай чакта да безнең Дәүләкәндә йөри иде әле. Тәбәнәк кенә буйлы, түгәрәк кенә битле, сакал-мыексыз — ничә яшьтә икәнен бер Ходай үзе генә белгәндер. Өстендә итәкләрен этләр өзгәләгән көрән төстәге кыска гына постау чикмән, аның астында кат-кат ямау салынган бик киң алача ыштан, аягында керле тула оек өстеннән киндерәсен чуашларча балтырына чаклы уратып бәйләгән, тузып «мыегы да чыккан» чабаталар, иңендә озын киндер капчык, кулында шактый саллы таяк... Чын исемен белгән кеше юк, ләкин ул үзен: «Мин — Курапаткин!» — дип йөртә иде, ягъни япон сугышы вакытында даны чыккан патша генералы, янәсе! Генералга охшар өчен ул ике колагы да өзек бүрегенең түбәсенә ап-ак куян койрыгы утыртып, чикмәненә түгәрәкләп кискән ак калай кисәкләре тагып йөри иде. Һәр йортның ишегалдына кергәч, «Курапаткин», бала-чага алдында ниндидер кеше аңламас кыска гына такмак әйтеп, бер генә урында әйләнгәләп, тыпыр-тыпыр биеп тә ала торган иде. Аны милләте белән чуаш диләр иде. Бәлки, дөрес тә булгандыр, чөнки ул сәдаканы татарлар бирсә, ашыкмыйча гына дога кылып, руслар бирсә, бер-ике кат тиз генә чукынып, ишегалдыннан чыгып китә иде. Кыскасы, кешеләргә һич зарары тимәгән, Алланың бер дивана бәндәсе

[1] *Саилче* — теләнче.— *Ә.Е.*

иде — башын кайчан, кайда салгандыр инде бу «мәшһүр» Дәүләкән Курапаткины?!

Муллый карт йортының ике катлы булуын әйткән идем бугай. «Чәйни» — аскы катында, ә өске катында фатирчылар торган. Дөресрәге, өске катның такталар белән генә бүленгән берничә вак бүлмәсендә айлап-еллап ялгызак кешеләр яшәгән. Мәсәлән, безнең Каргалы кешесе Ибәтулла учитель, Солтанмораттан (Галимҗан Ибраһимов авылыннан) килгән Мөхәммәтша тегүче, тагын икеме-өчме ялгыз приказчик шунда торганнар. Учитель үзенең бүлмәсендә башкорт шәкертләрен русча укыткан, ә тегүче «Зингер» машинасында текер-текер чалбар, камзул, җилән тегеп утырган. Бүлмә өчен күпмедер акчаны безнекеләргә түләгәннәр, ашау-эчүләре дә бездән булган. Русчалап әйткәндә, аларны нахлебниклар дияргә дә ярый. Барысы да буйдак яшьләр булганга күрәдер инде, алар кызык яшәгәннәр, гел генә төрле мәзәк, уен-көлке уйлап чыгарганнар — шулай исләренә төшереп сөйли торганнар иде минем атакай белән инәй дә...

Мин үзем, билгеле, бу «чәйни» заманын бөтенләй диярлек хәтерләмим, бик кечкенә булганмын әле — әйтик, ике белән биш арасында гына... Аннары без «чәйни»нең үзендә түгел, ә күршедәге икенче бер йортта торганбыз. Шуның өстенә, бу йортка күчеп күпмедер торгач, мин өченче яшемдә кинәт кенә... аяксыз калганмын. Ягъни әйбәт кенә йөреп яткан җиремнән тотканмын да аякка баса алмас булганмын. Нинди чир, нинди зәхмәт аркасында — моны миңа атам-анам да бервакытта да әйтеп бирә алмадылар. Авырту-сызлану да булмаган шикелле. Һәрхәлдә, урын өстендә үрсәләнеп ятмаганмын, киресенчә әле, мүкәйләп булса да, йөрергә тырышканмын. Алар, әлбәттә, бик курыкканнар, тугыз баладан соң унынчысы да гарип калса — Алла үзе генә саклый күрсен!.. Мине аякка бастыру өчен врачларга күрсәтү (ул чагында ук Дәүләкәндә земский шифаханә булган), төрлечә дәвалап карау, им-томнар куллану, нindидер бер зур ишанга илтеп өшкертү — берсе дә калмаган. Озакка сузылган бу тырышу, ә мин һаман идәндә шуышып кына йөрим икән... Әмма шулай да инәйнең күз яшьләре, ялварып сораулары, ниһаять, Алла бабайга барып җиткән булса кирәк, көннәрдән бер көнне, кинәт аяксыз калган шикелле, кинәт кенә аягыма да басканмын! Ул болай булган: кемнеңдер киңәше буенча, зур түгәрәк тазда ниндидер шифалы үлән-чәчәкләрне кайнар су белән пешекләп, мине шуның пар-суына утырткannar. Башымны гына ачык калдырып, өстемә калын юрган ябкан-

нар. Һәм иң гаҗәбе — атакай белән инәй, мине шул хәлдә калдырып, үзләре мунчага киткәннәр. «Без кайтканчы утыр, балам» дигәннәрдер инде. Ә мин кайтканнарын көтеп тормаганмын, үрмәләп таздан чыкканмын да, урындыкка тотынып, әкрен генә аягыма басканмын! Кайтып кергәч, атакай белән инәйнең күзләре шар булган — бу нинди могҗиза!.. Тиз генә мине күтәреп алганнар, киендергәннәр, яңадан аякка бастырганнар. Һәм менә шул басудан мин йөреп тә киткәнмен.

Бала чагымда булып узган бу хәвефле хәлемне мин бары сөйләүләре буенча гына беләм, ләкин — ни гаҗәп! — урындыкка тотынып басып торуымны үзем дә әзрәк кенә хәтерлим... Инде шактый ук үскәч, мин колын шикелле нечкә, бик йөгерек аяклы бер малайга әйләндем. Бик ярата идем чабарга, узышырга... Дәүләкән малайларыннан берәүне дә уздырмый идем, тик кайчагында Арыслангәрәй агай малае Таһир гына мине узгалый торган иде.

«Чәйни»дә чакта да мин, әйтүләренә караганда, бөтиле түбәтәй кигән, бик җиңел, бик тере бер малай булганмын (бигрәк тә аягыма басканнан соң). Бер генә минут та бер урында тик кенә утыра белмәгәнмен, каядыр китәм дә барам, чыгам да югалам — кайчагында «чәйни»дә утыручылар күмәкләшеп мине эзләргә чыгалар икән. Еш кына әлеге саилчеләрнең берсенә ияреп китеп, өйдән өйгә «хәер сорашып» та йөргәнмен. Бала җитәкләгән саилчегә сәдаканы мулрак биргәннәр... Мине таныган кеше очраса, ул шунда ук «чәйни»гә барып, инәйгә: «Хәдичә апа, улыгыз бер саилчегә ияреп йөри бит, шуны беләсезме?» — дип әйтә икән. Инәй, бичара, бот чабып ах-вах иткән, ә атакай тиз генә артымнан барып, мине күтәреп алып кайткан. Ә миңа нәрсә, миңа кызык кына саилче капчыгына тотынып йөрү!..

Соңыннан, күп еллар узгач, атакай нindидер бер уфтану белән миңа: «Улым, син малай чагыңа бер дә охшамагансың»,— дип әйтә торган иде. Гаҗәп түгел, бишектәге — бишкә төрләнә, дигәннәр, һәм мин моны үзем дә тоя идем. Һәрхәлдә, бик үзгәрдем мин — бала чактагы җитезлек, гамьсезлек күптән инде онытылды. Бик басынкы, бик сабыр (һәм чыдам), бик сак картларга әверелдек без барыбыз да...

Әйткәнемчә, «чәйни»дәге тормышыбызны мин ишетеп кенә беләм — ул хакта атакай белән инәй әлек еш кына исләренә төшереп һәм күбрәк көлеп сөйли торганнар иде. Гүя алар өчен дә ул «чәйни» дигән нәрсә очраклы һәм кызыклы әкәмәт бер урын булып кына исләрендә калган... (Атакай аны беренче герман сугышы башлан-

гач ташлаган.) Ә йорты үз урынында һаман да тора әле. Искергән-тузганы да артык сизелми, яхшы карыйлар, ахрысы. Хәзер инде ниндидер идарәме, конторамы урнашкан... Кайткан чакларымда мин һәрвакыт аның яныннан узам. Бик истәлекле йорт — миңа кадерле булырга тиештер инде ул. Төрле уйлар, хисләр уятырга... Ләкин, ни хикмәттер мин аңа карап сагыну яки якын итүгә охшаган бернинди дә тойгы кичермим. Чит-ят бер бина кебек ул минем өчен. Хыялым белән монда торган чагыбызга кайтырга тырышсам да, безнең базарчылар белән тулы бик гади генә «чәйни»ебезне нишләптер күз алдына китерә алмыйм. Бик күп еллар узган шул инде... Гомер катламы өстәлә барган саен, үткәннәрнең һәммәсен дә искә төшерү дә һәм сагыну да мөмкин түгелдер, күрәсең.

Әйтергә кирәк, «чәйни» тоту атакай өчен дә очраклы гына бер кәсеп булган икән. Шуннан соң ул бер урында гына утырып, мәсәлән, кибет ачып, сату итмәде. Аның сәүдәсе гел йөрү белән бәйләнгән иде. Күптән түгел, Срур тутакай миңа: «Атаң, мәрхүм, сәяхәт итәргә ярата иде бит»,— диде. Һәм, чынлап та, йөрергә бик һәвәс иде ул. Малай чагыннан ук бу һәвәслек аңа йоккан булырга тиеш. «Каргалы» өлешендә мин аның башта бабасы Әхтәм картка ияреп, аннары әтисе белән бергәләп, башкортлар арасында тире-яры, йон-ябага җыеп йөрүләрен язган идем инде.

Егет булып өйләнгәч тә ул йөреп алыш-биреш итүдән туктамаган, тирә-яктагы базарларны һәм ярминкәләрнең берсен дә диярлек калдырмаган. Шул чакларын исенә төшереп сөйли башласа, мин бик гаҗәпләнеп тыңлый торган идем. Чөнки бик күп еллар узуга карамастан, ул кайсы ярминкә артыннан кайсы ярминкә килүен, һәркайсының аен, айның кай числосында указ укылуын (ярминкә ачылыр алдыннан, гадәттә, указ укылган) төп-төгәл белә иде. Мәсәлән, январьның искечә 25 ендә Уфа ярминкәсе ачылган, аның артыннан 15 мартта Эстәрле ярминкәсе башланган, аннан — Бәләбәй ярминкәсе, аннан — иң соңгысы — Бөгелмә ярминкәсе булган икән. Тагы да гаҗәбе — атакай шул ярминкәләргә (мәсәлән, Бөгелмәгә) барган чакта узарга туры килгән бөтен авылларның исемен белә иде. Алай гына түгел, кайсы авылдан соң кайсы авылга җитүләрен, кем исемле агайга кереп ат ашатуларын яки кунып чыгуларын бәйнә-бәйнә сөйли торган иде. Искиткеч хәтер иде үзендә!

Әнә шул бик яшьтән башланган йөрү һәвәслеген ул картайганчы диярлек ташламады. Миңа караганда ул

дөньяны күбрәк гизде, күбрәк күрде. Кыскасы, «чәйни»не ташлагач та, минем атай, коммивояжер шикелле, күн саквояжын күтәреп һәм уңышлы алыш-биреш өмет итеп, якын-тирә шәһәрләргә юл тота башлады.

Ул чагында безнең үз йортыбыз юк иде әле, шул сәбәпле без фатирдан фатирга күчеп йөргәнбез. Болай йөрүебез 1918 елга чаклы дәвам итә. Шуңа хәтле, ягъни дүрт ел эчендә, без өч тапкыр фатир алыштырдык. 1918 елның җәендә атакай, ниһаять, чибәр генә йорт сатып ала. Истән чыгармыйк, «чәйни»не ташлап киткән елны герман сугышы башлана, ә без йортлы булганда инде Бөек революция дә булып өлгерә. Кыска, әмма тыгыз заман! Минем биш яшьтән тугыз яшькә чаклы вакытым. Хәтерем инде ачылган һәм күп кенә нәрсәне күрергә дә өлгергән. Әмма күпмесе шуның күңелдә сакланган? — моны әле сынап карыйсы бар.

«Чәйни» йортыннан без Арыслангәрәй тыкрыгындагы бер йортка күчкәнбез. Бу — зур урамнан Комач буена төшә торган бик кыска гына бер тыкрык иде. Аның бер ягында Арыслангәрәй башкортның каралты һәм абзарлары, икенче ягында ниндидер бер рус кешесенең амбар-куралары сузылып киткән иде. Ягъни тыкрыкта яр башына җиткәнче бернинди йорт-мазар юк иде. Бары тик тыкрык беткән җирдә яр башыннан Комачка карап ике генә йорт тора иде. Шуларның берсе, Арыслангәрәй койрыгындагысы — тимерче Миңнегали агай йорты, икенчесе — рус койрыгындагысы — без күчкән йорт иде. Йортлар кеше койрыгында гына торсалар да, алар каршысында ачылган манзара гаҗәп тә матур, шагыйранә иде! Хәер, мин хәзер менә шулай дим, ә ул чагында манзараның да, матурлыкның да нәрсә икәнен, әлбәттә, белмәгәнмен. Ләкин шулай да күз алдына китерик.

...Түбәндә — Комач (башкортча — Комас). Бу — Димнең шактый озын һәм киң генә култыгы. (Элекке Этколның шушы култык буенда утырганын мин әйткән идем инде.) Комачның теге ягында кечерәк кенә тугай, тугайны үткәч, Димнең үзенә барып чыгасың. Дим аръягында куе әрәмәлек башлана, аны ерып үтсәң, тагын Димгә килеп чыгасың... тукта, нигә болай, Дим әллә икәүме? — дип гаҗәпләнергә мөмкин. Юк, ул берәү генә, ләкин хикмәт шунда: еractan туры гына агып килгән Дим Дәүләкәнгә җитәрәк озын-озын өч борылыш ясый. Борылышларны ерымнар тоташтыра. Һәр ике борылыш арасында йә кечкенә тугайлык, йә куе әрәмәлек. Менә шулар барысы да — Димнең борылышлары, ерымнары,

әрәмәлекләре, алардан да ары Көрмәнкәй тавына хәтле җәелеп киткән бик киң тугай, тугайдагы камышлы күлләр — кыскасы, минем әлеге манзара дигәнем безнең яр башындагы йорттан ап-ачык күренеп тора да инде. Гаҗәеп бер күреп тә бетермәслек киңлек ачыла каршыңда! Тагы да ераккарак — Димнең үренә таба карасаң, бу яшел, бөдрә, тип-тигез киңлек, чиге булмагандай, якты томан эченә китеп югала.

Яр кырыена салынган һәрбер йортныкы шикелле безнең йортның да аскы һәм өске каты бар иде. Аскы каты ярга кертеп таштан салынган, өске каты бүрәнәдән. Без менә шунда — өске катта тордык. Аста кемнәр торганын ачык кына хәтерләмим. Безнең белән янәшә, өйнең икенче яртысында, герман сугышы башлангач, каяндыр Литва якларыннан күчерелгән бер немец гаиләсе тора иде. Мин аларны да бик аз беләм, бары минем чамадагы бер кызлары гына истә калган. Ул минем телне, мин аның телен белмим, ә шулай да бергә уйный торган идек. Кызык, песи балалары кебек телсез дә ничектер аңлаша алганбыз.

Без бу йортта озак тормадык. Шуңа күрә сөйләрлек истәлегем бик аз. Әмма бернәрсәне бик ачык хәтерлим: безнең фатирның һавага чыгып торган иркен генә балконы бар иде. Җәйнең җылы иртәсендә яки кичкырын безнекеләр шул балконда еш кына чәй эчеп утырырга яраталар иде. Әтрафтагы манзараның матурлыгын әйтәсе түгел, сез моны беләсез инде, ләкин биек балконда чәй эчеп утыруның тагын бер хозурлыгы шунда иде ки, һәр көнне кояш баер алдыннан, Комачта бакалар хоры башлана иде. Комач — акмый торган су, шунлыктан анда бакалар бихисап иде. Менә шулар, аеруча тын җылы кичләрдә, көтүләре белән су читенә җыелып, тотыналар төрлесе төрлечә «сайрарга»! Бөтен су буе өзлексез яңгырап тора. Һәм әйтергә кирәк, төрле тавыштагы бу бакалар хорының үзенә күрә бер тәртибе бар, моңы-яме бар. Тыңлый торгач аңа күнегеп була, кайчагында исә күңелдә үзенә бер сагыш та кузгата иде ул!

...Кичке су өстенең тагын бер сере хәтердә нык калган. Шулай ук кояш баеган чакта гына аргы Димнән «бум... бум» дигән төслерәк өзеп-өзеп кычкырган калын бер тавыш ишетелә торган иде. Аны ишетүчеләр шунда ук: «Әнә су үгезе кычкыра!» — дип әйтәләр иде. Чынлап та, тавыш шундый калын, шундый көчле ки, андый тавыш бары үгез шикелле зур бер җанвардан гына чыгарга тиеш иде. Һәм мин үсеп җиткәнче диярлек безнең Димдә дүрт аяклы су үгезе булуына ышанып

йөрдем... Мин генә түгел, бик күп малайлар моңа ышаналар иде. Ләкин — ни гаҗәп! — үгезнең үзен күрүче генә юк. Бервакытта да берәүнең дә: «Күрдем мин аны, малай!» — дип шаккатырып сөйләгәнен ишетергә туры килмәде. Әллә инде ул дәһшәтле үгез бер дә судан чыкмыйча ятамы?! Алай дисәң, көчле-калын тавышы аның шундый еректан ничек ишетелә соң?

...Бары тик шактый вакытлар узгач кына, дәү абыйлардан чын дөресен ишетергә туры килде: бернинди су үгезе безнең Димдә юк икән. Аның каравы ниндидер бер кечкенә кош бар, имеш. Менә шул хәтәр исемле өтек кенә кош, кичке тынлыкта ялгызы гына йөзеп йөргән чагында, башын суга тыгып «бум-бум...» дигән төслерәк калын тавыш чыгара икән. Вәт сиңа су үгезе! Хәзер бармы ул, белмим, ләкин кайткан чакларымда аның мәһабәт тавышын ишеткәнем юк.

Яр башындагы ике йортның берсе тимерче Миңнегали агай йорты дигән идем. Аның йорты да түбәннән караганда ике «катлы» иде. Тик түбән каты яр асты ягыннан өйне күтәреп торган бер подвал сыман гына нәрсә иде. Шуның өстендәге йорт, үзе калай белән япкан булса да, шактый кечкенә иде... Янә тар гына ишегаллларында такта алачыклары бар иде — шуннан көне буе диярлек зур чүкеч белән кечкенә чүкечнең алмашлап тимер чүкегәне ишетелеп тора иде.

Миңнегали агай безнең мин белгән иң беренче якын күршебез... Гаиләсе аның ишле иде, шул чакта ук инде дүрт улы, өч кызы бар иде. Ике улы — Габдулла абзый белән Муллагали абзый — җитеп килгән егетләр, алардан кечерәк Зөфәр дә миннән алты яшькә олы үсмер малай иде. Ә миннән күпмегәдер яшьрәге — Әхтәм, ләкин мин аның бала чагын белмим диярлек. Кызлары — Маһирә, Рәхимә, Рәхилә, тагын соңрак Сания исемлесе дә булды. Болай санап чыгуымның бер хикмәте бар: шушы тимерче гаиләсе белән без озак еллар буена бик якындус яшәдек. Соңыннан терәлеп торган күршеләр булмасак та, бу якынлык бервакытта да бетмәде, һәрвакыт аралашып, йөрешеп тордык.

Миңнегали агай үзе — кара сакаллы, таза, базык кына кеше — Дәүләкәндә хөрмәт казанган бер авторитет иясе иде. Аны белмәгән һәм аңа эше-йомышы төшмәгән кеше юк иде диярлек. Тимерчелек исә аңа нәселдән күчкән, гомере буена ул алачыгыннан чыкмады, кулыннан чүкечен төшермәде. Ләкин шуңа карамастан Миңнегали агай диндар бер кеше дә иде. Билгеле, ул шәригатьнең файдалырак якларын күбрәк исендә тоткан булырга тиеш:

үз гомерендә авызына бернинди эчемлек алмаган, тәмәкене өенә дә кертмәгән (һәм балаларын да бу нәрсәләрдән катгый рәвештә тыйган), ризыкның кадерен белгән — валчыгын да исраф итмәгән... Биш вакыт намазга йөрмәсә дә, атнага бер килә торган җомга намазын бер дә калдырмый иде. Өстенә кара җилән, башына шактый ук кыршылган кырпы бүрек киеп, урам уртасыннан мәчеткә таба кызу-кызу атлап баручыны кем дисәң, ул Миңнегали агай була торган иде.

Шуның белән бергә, бу диндар тимерче һич тә кара томана кеше түгел иде. Ул үткен акыллы, гаделлек яклы, сүзгә оста, бәхәсләшергә дә яратучы тынгысыз бер адәм булган. Аш мәҗлесләрендә карт хәзрәтне еш кына төрле сораулар биреп аптыраткан, бәхәсләшеп тә китә торган булган — үзенчә ислам шәригатен һаман ярлылар файдасына борырга тырыша икән. Шулай сөйлиләр иде аның турында. Эш хәтта ки шуңа барып җиткән — безнең хәзрәт аның белән бер мәҗлестә утырудан баш тарта башлаган.

Билгеле, Миңнегали агай үз балаларына да бик таләпчән булган, әмма бервакытта да аларның иркен бумаган. (Мәсәлән, берсен дә көчләп мәчеткә кумаган.) Карт алар өчен авторитет иде, берсүзсез аңа буйсыналар иде. Уллары эшкә ярый башлагач та, аталары белән бергә алачыкта тимер суктылар. Кызлары барысы да укыдылар,- бер-берсен карадылар, үстерештеләр. (Сигез бала бит!)

Кыяфәтләре белән дә алар бер-берсенә бик охшаганнар иде, һәммәсе дә төскә чибәр, төз буйлы, кара бөдрә чәчлеләр... Бәлки, көнчелектәндер инде, кайчагында аларны «Кара Миңнегали малайлары» диеп тә йөртәләр иде. Аталарына берсүзсез буйсынып торсалар да, алар шактый хөр үстеләр. Иң өлкәне Габдулла абзый 1917—1918 елларда ук сәхнәдә уйный башлады, соңыннан аны Уфа театрына да чакырган булганнар. Миңа калса, ул чын артист булырга тиешле кеше иде, ләкин нишләптер Дәүләкәннән ычкына алмады... Кечерәкләреннән Зөфәр дә берзаман сәхнә һәвәскәре булып китте — шәп декламатор һәм оста гына гармунчы да иде ул. Маһирә исә бик матур җырлый иде. Ике киленнәре — Галия апа белән Зөләйха апа да — Дәүләкән сәхнәсендә күп уйнадылар. Һәм болар барысы да бер гаиләдән — Миңнегали карт өеннән!

Аннары килеп, Зөфәр Дәүләкәннең иң беренче комсомолы иде. Әйтүенә караганда, ачлык елдан соң ике егет — ул һәм тегермәндә эшләүче Әфтәх — татарлардан беренче булып комсомолга кергәннәр. (Әфтәх турында

алда сүз булачак әле.) Алардан соң инде егетләр генә түгел, кызлар да комсомолга керә башлыйлар.

Миңнегали агайның Габдулладан кала икенче улы Муллагали — кечкенәләре аны «бәләкәй абый» дип йөртәләр иде. Үтә тыйнак, йомшак, әдәпле бер егет иде ул... Үтә тыйнаклар күзгә бик ташланмыйлар бит, шуңадыр мин аның егет чагын бик аз беләм. Әмма шушы егет, бердән, Дәүләкәннең иң чибәр кызы Зөләйха апаны качырып ала, икенчедән, Ватан сугышы вакытында, ягъни иң авыр елларда, Аюхан авылында колхоз председателе булып тора. Ул елларның газабын хәзер дә сөйләп бетерә алмый Муллагали карт!

Миңнегали агайның миннән яшьрәк тагын бер кызы һәм бер улы турында әйтәсем килә: болар Рәхилә белән Әхтәм... Дәүләкәннән иртә киткәнгә күрә мин аларның бала чагын, ничек үсүләрен аз хәтерлим. Рәхиләне туташ булып җиткәч белә башладым һәм, яшерәсем килми, ул мине үзенә каратып та өлгергән иде. Рәхилә араларында иң матуры иде — күзләре сөрмәле, озын керфекле, кашлары нечкә, ә коңгырт чәчләре күпереп, дулкынланып тора иде. Бәлки, шушы матурлыгы аркасындадыр, ул шактый ук тәкәббер дә иде. Һәрхәлдә, миңа игътибарын юнәлдермәде. Нишлисең, кызлар мәсьәләсендә минем бәхетем шулайрак булды инде: мин игътибар иткәннәр миңа карамадылар, мине җәлеп итмәгәннәр минем белән кызыксындылар. Ярый, хәерле булсын, бу мәсьәләне хәзергә калдырып торыйк. Миңнегали картның барлык сәләтле, зиһенле, уңган балалары арасыннан бары шушы Рәхиләсе бик югары күтәрелде. Калганнары ни сәбәптер Дәүләкән масштабыннан чыга алмадылар. Ә менә Рәхилә партия эшенә кереп китә. Башта ул Уфаның партия мәктәбен тәмамлый һәм Башкортстан өлкә комитетында эшли. Күпмедер эшләгәннән соң, аны Мәскәүдәге Югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Бу мәктәпне тәмамлагач, ул Казахстанга билгеләнә. Монда инде Дәүләкән кызының чын партия җитәкчесе булып үсүе һәм күтәрелүе башлана: Казахстан Үзәк Комитетында бүлек мөдире урынбасары, Көнбатыш Казахстан өлкә комитеты секретаре, Көньяк Казахстан крае башкарма комитетының председатель урынбасары, Чемкент өлкә комитеты секретаре — кыскасы, егерме ел буена диярлек ул әнә шундый зур һәм җаваплы урыннарда эшли.

Сугыштан соң, илленче ел урталарында, мин Рәхиләне Уфада очраттым, аннары Дәүләкәндә дә бер үк вакытта булдык. Әйе, бу инде үз-үзенә нык ышанган, үзен кирәгенчә гади, әмма бәйсез тота белгән чибәр, тулы гына

бер ханым иде. Уфада бер мәҗлестә дә булдык. Дәүләкәнгә кайткач, Дим буйлап көймә белән Көрмәнкәйгә дә бардык, ләкин яшьтән үк күрше булып үскән Рәхилә белән минем арада кешеләрчә гади, җылы мөнәсәбәт туа алмады. Ниндидер бер сынаумы, әллә сагаюмы, яшерен күзәтүче шикелле, безне рәсмирәк булырга, дистанция сакларга мәҗбүр итә иде. (Мин моны аеруча үземә карата сиздем).

Әмма, ни кызганыч, Рәхилә барлык туганнары арасында иң гомерсезе дә булды (илле биш яшендә үлеп китте). Апасы Мәһирә әйтә, эштә янып бетте ул, ди. Хәбибрахман да миңа шулайрак әйтте: йөрәге һәм баш мие бик тузган иде, диде. Рәхилә үләреннән берничә ел элек кенә Хәбибрахман санаториенда ял иткән. Алар бик дуслашып киткәннәр, Рәхилә Хәбибрахманны врач итеп тә, кеше итеп тә бик яраткан булса кирәк. Хәзер сөйләшкәндә Мәһирә дә моны раслый, Хәбибрахман аңа бик кулай кеше иде, ди.

Гаҗәп хәл: тулы бәхет берәүгә дә насыйп түгел, күрәсең. Рәхилә Дәүләкәндә чакта ук әле Солтанов дигән район прокурорына кияүгә чыккан булган. Ләкин сугыштан соң алар аерылышканнар. Рәхилә башка инде иргә чыкмаган, ялгызы ике бала үстергән... Барысы да бар лабаса — зур урын, дәрәҗә, материаль бөтенлек, тик менә бәхет чамалы да гомер генә кыска... Эх, бу тормыш!

Рәхиләдән кечеләре — Әхтәм. Ифрат тыйнак, юаш, тырыш, бу сөйкемле-сабыр егет бөтен гомерен Дәүләкәндәге кирпеч заводында бухгалтер булып эшләп уздырды. Шул кирпеч заводыннан пенсиягә дә чыкты. Аның Уфа белән Бәләбәйдән башка җирне күргәне дә булмады шикелле.

Дәүләкәнгә кайтып йөри башлагач, мин Әхтәмнең бер кабилиятен (дөресрәге, талантын) күреп исем китте. Ул художник булыр өчен туган икән лабаса! Иң элек аның кулы агач эшенә гаять оста икән. Менә дигән резчик ул. Төрле-төрле нечкә-нәфис сырлар, бизәкләр салып, бик пөхтә итеп, тәмам җиренә җиткереп эшләгән буфетын яки шкафын мебель магазинына илт тә куй — шунда ук бәреп алачаклар. Бусы — бер. Икенчедән, ул рәссам, ягъни буяу белән картиналар да яза. Стенага элгән кайбер эшләре миңа ошаган иде, ләкин мин аларга бәя биреп тормыйм. Ихтимал, профессиональ күзлектән караганда, аның картиналары гади бер һәвәскәр эше генә булып күренер. Ләкин бит Әхтәм, бернинди махсус белем алмыйча, беркемнән дә өйрәнмичә, бары Ходай бирмеш күзе һәм кулы белән эшләгән ич барсын да!.. Әгәр укытканда, әгәр өйрәткәндә чын рәссам чыкмас идемени?!

Минем хәтта, соң булса да, нидер эшлисем, ниндидер чара да күрәсем килеп киткән иде. Әмма бик йорт җанлы, гаилә җанлы, аздан да канәгать Әхтәмдә мин дәрт тә, теләк тә сизмәдем. «Нишлисең инде, соң бит, Әмирхан абый!» — диде ул миңа, сүлпән генә уфтанып. Әйе, талант өстенә характер да кирәк шул! Хәтта бик зур талантларга да!.. Хәлбуки кайчагында таланты чамалы гына кеше дә, характеры булса, шактый ерак китә ала.

Булмаса, яр башындагы өебезгә кайтыйк әле — минем бәләкәй чагыма. Күршебез Миңнегали агайның ишле балалары арасыннан миңа иң якын торганнары Зөфәр белән Мәһирә иде. Дөрес, алар икесе дә миннән олырак — Зөфәр алты яшькә, Мәһирә ике яшькә. Ләкин шуңа карамастан мин аларга бик ияләштем, алар янында үстем, егет чагым алар белән бергә үтте һәм икесе дә минем бертугандай якын кешеләрем булып калдылар. Шушы көнгә кадәр!.. Моның төп бер сәбәбе менә нидән гыйбарәт: минем атакай сәүдә эшләре белән читкә киткән чакларда, инәй күршедән төн кунарга Зөфәр белән Мәһирәне чакыра торган иде (билгеле, әти-әнисеннән сорап). Бу инде беренче герман сугышы башланып, дөньяның тынычлыгы китеп торган вакыт, ә без ике малай бик кечкенәбез әле, билгеле, инәй ялгызы гына кунарга курыккан. Унике яшьлек малай белән сигез яшьлек кызчык — бу бит үзенә күрә бер терәк, өйдә, һич югы, җан иясе арту дигән сүз. Аларның безгә куна керүен бигрәк тә мин көтеп ала идем, чөнки алар кергәч, өебез бөтенләй җанланып китә, бергә утырып чәй эчү дә күңеллерәк була, аннары минем өчен иң тансыгы — алар белән бергә, бер урында ятып йоклау иде. Алар бит мине гел генә урталарына алып яталар иде... Әнә шулай бала чактан ук туа безнең арада якынлык!

Ләкин еллар уза, без дә туктап тормыйча һаман үсәбез — алар алданрак, мин алар артыннан. Шулай үсә торгач, берзаман Зөфәр — егет, Мәһирә туташ булган, мин дә малайлыктан чыгып, егет булып киләм, имеш! Һәм шушы чорга кергәч, безнең арадагы яшь аермасы ничектер сизелми дә башлады, һәрхәлдә, без күпмедер дәрәҗәдә тиңләштек. Шуны да әйтергә кирәк, мин яшемә караганда күп кенә яктан шактый иртә өлгердем. Егет чакта дусларымның күбесе яшькә миннән олыраклар иде.

1925 ел белән 1930 еллар арасы — минем һәр җәйне Казаннан Дәүләкәнгә кайтып йөргән чагым. Менә шушы вакытта без Зөфәр белән егетләр буларак бик дуслашып киттек. Кем әйтмешли, без һаман бергә, һаман бергә! Бу биш-алты ел вакыт Дәүләкән яшьләренең иң оешкан, иң

актив чагы иде. Җомга көн саен диярлек көймәләргә утырышып, Дим өстен җыр-гармун тавышлары белән яңгыратып йөрүләр, уникешәр атка төялеп, азыклар алып, арбага казаннар салып, Ачлыкүл буена сәхрәгә чыгулар, әзерләгән концерт-спектакльләребез белән татар һәм башкорт авылларына «гастрольгә» барулар — болар барысы да әнә шул биш-алты ел вакыт эчендә булып алды. Зөфәр дә, Маһирә дә бу эшләргә иң якыннан катнашучы, җан өрүче, беренче башлап йөрүчеләрдән иде. Гомумән, ул чакта Дәүләкәндә яшьләр күп иде әле, китеп, таралып бетәргә өлгермәгәннәр иде. Әмма һәркемнең шул күп яшьләрдән аеруча якыны, күңелгә ошаганы, үзенә тартып торганы була. Зөфәр минем өчен әнә шундый иң якын, сирәк дусларның берсе иде. Ул яше белән дә, акыл белән дә күпләрдән өстен иде, ахрысы, шуңадыр мин химая эзләгәндәй гел аңа тартыла идем. (Ә химаяче миңа бик кирәк була башлаган иде инде.) Шуның белән бергә Зөфәр ачык, шат күңелле, туры сүзле һәм өстәвенә көяз бер егет тә иде. Көне буе атасы янында тимер чүкегәннән соң, ул бик әйбәтләп юынып, кара чалбар, ап-ак күлмәк киеп, кулына дирижер таягыдай нечкә генә чыбык тотып, кичкырын йөрергә чыга торган иде. Һәм без дә, читтән кайткан берничә егет, шулай ук киенеп-көязләнеп, кичке йөрүгә чыга идек. Бергә очрашып, исәнләшеп, көлешеп алганнан соң, урам уртасыннан «Күрәсезме безне!» дигәндәй, ашыкмыйча эре генә атлап китә идек. Иң элек вокзалга барып, берәр пассажир поездын үткәреп җибәрәбез — бу тамашага русы, татары шактый яшьләр җыела торган иде. Без яшь чакта поездларның килеп-китүе кызыклы гына бер тамаша иде. Иң элек күрше разъездан поезд чыкканын белдереп, кызыл фуражкалы дежурный вокзал ишеге янында асылынып торган җиз чаңны дәртле генә яңгыратып кага. Шуннан соң вокзал тирәсендә хәрәкәт көчәя, билет кассасы янында кысыш-сытылыш башлана. Бер унбиш-егерме минут үтүгә, семафор ягыннан күкрәген киереп килгән гайрәтле кара паровоз күренә — ул һәрвакытта поездны беренче юлга кызу гына китереп туктата. Перронда ыгы-зыгы башлана, берәүләр төшә, берәүләр менә, күп кенә пассажирлар, калай чәйнекләрен шалтыратып, кипәтүккә йөгерәләр. Йомшак урынлы вагоннарның ачык тәрәзәләреннән тузган чәчле чибәр ханымнар, мыекларын тәкә мөгезедәй бөтереп җибәргән ирләр тыштагы тамашага көлеп кенә карап торалар.

Скорый поезд, гадәттә, озак тормый иде... Бер биш минуттан дежурный чыгып чаңны ике тапкыр сугып

ала, шуның артыннан ук сакаллы кондуктор сыбызгысын чырылдатып җибәрә, һәм очтагы паровоз калын гына итеп кычкырта да, азрак гайрәтләнеп пошкырганнан соң, әкрен генә кузгалып китә. Вагоннар шома гына тәгәри, ачык тәрәзәләрдәге адәм башлары отыры кызурак уза башлыйлар. Состав, ниһаять, узып китә, тик әнә иң арттагы вагоннан сары флагын сузган проводник кына бераз әле күренеп бара...

...Поезд китә, ничектер хыялны кузгатып, ияртеп китә, аңардан соң ямансурак та булып кала. Халык тарала, перрон бик тиз бушый, һәм без дә вокзал урамыннан ашыкмыйча гына Димгә таба атлыйбыз. Яр башына җиткәч туктыйбыз да кичке шәфәкънең алсу нурына манылып тын гына агып яткан Дим өстенә, аның Көрмәнкәй тавына чаклы җәйрәп яткан, инде аргы читләренә эңгер караңгылыгы иңә башлаган тип-тигез тугаена, андагы куе әрәмәлекләр, таллыклар уртасыннан тонык кына елтырап күренгән ерымнарга, күлләргә сүзсез генә карап торабыз. Һәр кичне диярлек без бу үтә таныш манзарага яр башыннан менә шулай карап тормыйча китмибез. Иллә мәгәр туйганыбыз юк һәм беркайчан туймабыз да шикелле... Комач ягыннан бакалар җыры ишетелә башлый, каяндыр Дим үреннән су үгезенең кичке тынлыкта «бум, бум!» дип кычкырган калын тавышы ишетелеп куя... Тагын ашыкмыйча гына урам буйлап китәбез. Вакыт соң инде, ә көн һаман да сүнеп бетмичә тора, ләкин урам әкренләп кенә тына. Йөреп аргач, безнең капка төбендәге эскәмиягә килеп утырабыз. Сүз күп, сүз бетәрлек түгел, ниләр генә сөйләшми идек без, кайчагында таралыша алмыйча, беренче әтәчләргә чаклы да утыра идек. Бу безнең зур хыяллар, зур өметләр белән янып яшәгән чагыбыз иде.

Ә еллар уза, нинди кадерле еллар уза, тик без аңа игътибар гына итмәгән булабыз. Шул арада заман безнең язмышларны үзенчәрәк, без көтмәгәнчәрәк хәл дә итеп куя һәм тормыш юлларыбызны да төрле якка аерып җибәрә. Бик озакка аера ул безне. Зөфәр, татар җанлы егетебез, көтмәгәндә генә бер чибәр рус кызына өйләнә, Дәүләкәннән китә, Башкортстанның төрле районнарында почта начальнигы булып эшли, соңгы гомерен Бәләбәйдә яшәп уздыра. Мин аны бер утыз биш ел чамасы күрмичә тордым. Алтмышынчы-җитмешенче елларда, Дәүләкәнгә кайтышлый, бары аны күрер өчен генә ике тапкыр Бәләбәйдә тукталдым. Без икебез дә бик үзгәргән идек, әмма бала чактан ук күңелләргә сеңеп калган якынлыкны бер дә югалтмаганбыз икән. Алтмыш

яшемне бәйрәм иткәндә, мин, телеграмма биреп, аны Дәүләкәнгә чакырдым. Килде мәрхүм, куандырды, бергәләп үзебез укыган мәктәпкә бардык (ул чагында татар мәктәбе эшли иде әле), малай чакта чана шуган тауны да барып карадык, боз өстенә дә төшеп йөрдек. Бу сөйләшеп йөрүләр вакытында Зөфәр миңа күп кенә нәрсәләрне искә төшерергә ярдәм дә итте.

Әйе, еллар уза, дусларны, туганнарны алып китә тора!.. Картларыбыз күптән инде бу дөньяда юк: Габдулла абый да, Рәхилә дә, Зөфәр дә юк, мин дә берүзем генә калдым. Шулай да исәннәребез арасында бәйләнешләр өзелмичә, һаман да дәвам итә. Балалыктан картлыкка килеп җиткән бу бәйләнешләргә инде җитмеш ел тулып узды.

...Сүз нәрсәдән башланып киткән иде?.. Беренче күршебез тимерче Миңнегали агайдан... Ул заманнарда «күрше» дигән нәрсәнең әһәмияте гаять зур булган икән. Дуслык-якынлыклар да күршеләр булудан башланган, онытылмаганы-сагындырганы да шул ук күршеләр. Чөнки иске мәгънәдәге күршелек, ягъни якыннан аралашып, хәл-әхвәл сорашып, йомышка йөрешеп, кирәк чакта ярдәмләшеп яшәүче күршеләр хәзерге заманда, бигрәк тә шәһәр шартларында, бетеп бара диярлек. Халык унар катлы, йөзәр квартиралы йортларга кереп тулды, бер җиргә тупланды, үзара якынайды да кебек, әмма шул ук вакытта бер ишектән кереп, бер баскычтан менеп йөрүчеләр дә бер-берсен юньләп белмиләр... Күршелек нәрсә ул хәзер? — очрашканда исәнләшеп узу да бик сирәк кенә йомыш төшеп керү (мәсәлән, телефонга) — бары шул гына!

Бер елдан соң без яр башындагы балконлы йорттан ни өчендер икенче йортка күчкәнбез. (Ахрысы, хәвефсезрәк урын эзләптер, чөнки яр башындагы йортка берике тапкыр караклар керә язганнар иде.) Бусы инде Дәүләкәннең төп урамында, түбән очка табарак шактый чибәр зур гына йорт иде. Миңа алты-җиде яшьләр чамасы, хәтер-зиһен ачыла барган чак, шулай да бу йорт турында исемдә калганнар күп түгел. Иң элек шуны хәтерлим: аның ишегалды бик бәләкәй иде, иркенләп йөгереп-чабып уйнарлык түгел иде. Аннары аның коймалары да бик биек иде, биек койма артында бер генә катлы таш тегермән эшли иде (аны Зайцев тегермәне диләр иде), шуннан көн саен диярлек кешеләр шаулаган, атлар пошкырган тавышлар ишетелеп тора иде.

Яңа урында яңа күршеләр — әкренләп алар белән дә танышырга туры килде. Уң ягыбыздагы кечерәк кенә йортта Зариф исемле бер тегүче абзый тора иде — мин

менә шуларга кергәли идем. Чөнки тегүченең минем чамадагы Гариф исемле малае бар иде, керүем, билгеле, шуның белән уйнар өчен булгандыр инде. Тик, ни гаҗәп, безнең икәү бергә уйнап йөрүебез юньләп хәтердә калмаган, ә менә кергән саен бер үк тамашаны күрүем бик нык истә сакланган. Бу шактый кызыклы тамаша иде: Зариф абзый — каны качкан ак чырайлы, кара мыеклы, үтә арык кеше — гел генә йә бөкрәеп аяк машинасында текер-текер нидер тегә, йә идәндә бер аягын чәнчеп тезләнгән килеш зур кайчысы белән кием кисә. Буш чагын белмим, сөйләшкәнен, күтәрелеп караганын да хәтерләмим — эше күп булгандыр, ахрысы. Ләкин ул бик авыру иде бугай, муены неп-нечкә, калак сөякләре беленеп тора иде. Ә хатыны, киресенчә, тулы-таза иде, бите дә тулы-түгәрәк иде, зур соры күзле, сөйкемле хатын иде, ләкин өйдә берни дә эшләми иде шикелле. Ничә кермә, бу абыстай идәндәге ак киез өстенә юан аякларын сузып утырган, янына улы Гарифны да шулай әйбәтләп утырткан булыр. Урталарында зур калай тәлинкә белән Әстерхан чикләвеге, сары күрәгә, кара йөзем. Абыстай менә шул эре чикләвекне бөкләп салган тастымал өстендә ике кадаклы гернең чокыры белән бәреп вата да, төшен чүпләп, күрәгә һәм йөзем белән кушып, кыстый-кыстый малаена ашата... Көн саен диярлек болай сыйланып утыруны минем берәүдә дә күргәнем юк иде әле. Чикләвек белән җимеш безгә дә бик сирәк кенә эләгә торган иде. Күрәсең, Зариф абзый акчаны яхшы төшергәндер инде. Әмма моның ахыры ни булып бетте — ансын алдарак күрербез.

Бездән бер йорт аша зур урамны аркылы кисеп тыкрыктай тар гына урам үтә. Бер башы аның базар мәйданына, икенче башы Дим ярына барып чыга. Дәүләкән урамнарына кайчан исем бирелеп, чаттагы йортларга кайчан тар калай сукканнардыр, әмма бу урам мин малай чакта ук Тукай урамы дип атала иде. Менә шушы Тукай урамының Димгә табарак очындагы бер йортка мин еш кына барып йөри идем. Коймадан эчкәрәк бүрәнәдән алты почмаклы итеп салынган кечкенә өч тәрәзәле тәбәнәк кенә йорт, урамнан такта түбәсе дә ике морҗасы гына күренеп тора, ләкин, әнә шундый авылча гади генә булуына карамастан, бу йортның капка-коймалары, каралты-куралары бик таза эшләнгән иде. Амбары тимер белән япкан, ат-сыер абзарлары тоташтан такта түбәле, мунчасы да бәләкәй генә өй кебек ак мунча иде.

Бу — итче Гали абзый йорты. Тук йорт, һәрвакыт итле бәлеш исе килеп торган йорт. Гали абзыйның ми-

нем белән бер яшьтәге Мәхмүт исемле һәм энем белән бер чамадагы Миңнеәхмәт исемле ике улы бар иде. Шулай ук нәфис ак чырайлы, нечкә-зифа сынлы, буй җитеп килгән Гайникамал исемле кызы да бар иде.

Гали абзый белән минем атакай күптән таныш һәм әшнә дә булганнардыр, ахрысы, чөнки берзаман без алар белән якыннан аралашып, йөрешеп яшәдек. Аңа инде күп еллар узды, мөнәсәбәтләр дә бик күптән өзелде, әмма ләкин мин барыбер бу күптән таралып, югалып беткән гаиләне бервакытта да онытып бетерә алмадым. Тирән кереп калган алар минем күңелгә...

...Мәхмүт белән без бик дуслашып киткән идек. Кече малай чактан алып үсмер егет булганчыга кадәр гел бергә йөрдек, бер-беребезгә бик ияләштек, үсмер чакта гына була торган самими күңел якынлыгы безне бәйләгән иде, шуңа күрә безнең серләребез дә гел бергә, уртак булды. Малай буларак мин беренче мәртәбә Мәхмүт белән сугыштым. Икебез дә җирдә аунадык, икебез дә гарьлегебездән җыладык — әнә шулай сугышудан башланган дуслык кайчагында бик көчәеп китә икән ул!..

Мәхмүт буйга миннән кайтышрак, бик аз гына шадрасы да бар, ләкин күзләре зур, керфекләре озын иде. Сөйкемле, матур малай иде. Уналты яшебездә без икәү янәшә утырып, иң беренче мәртәбә фоторәсемгә төштек. Ике ахирәт дус, әмма һич тә бер-беребезгә охшамаганбыз. Мәхмүтнең йөзендә уй бар, ниндидер сагыш та бар кебек, ә минем чырайда бернәрсә дә юк — тырпаеп торган зур колаклар да тар гына күзләр... Бик кадерле бу фоторәсем минем өчен!

Мәхмүт, чынлап та, яшьтән үк уйчан-моңлы малай булып үсте. Ниндидер бер тирән яткан хәсрәт, язмышыннан канәгатьсезлек, бетми-үтми торган төшенкелек аңа гүя тумыштан ук бирелгән иде. Еш кына ул кайгылы җырлар җырлый иде. Ашыкмыйча, әкрен генә моңлы итеп җырлый иде:

Әнкәй мине тапкачтын да
Ак биләүгә биләгән,
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхете булсын димәгән...

Бу зарлы-моңлы җырның сәбәбе дә билгеле иде — алар бик иртә әниләрен югалттылар... Әниләре Мәгълифә җиңги бик юка, бик арык хатын иде. Бөтен хәлсез кыяфәтеннән аның күптән инде авыру икәнлеге күренеп тора иде. Ахырда балаларын бик иртә ятим калдырып, чахоткадан үлеп тә китте. Бу вакытта Мәхмүткә ун яшьләр

булгандыр — адәм баласының зур хәсрәтне иң авыр кичерә торган чагы. Күпне аңлый, күпне тоя, әмма акылы, әмма бәгыре бер дә ныгып җитмәгән әле.

Ә аталары Гали абзый — үгездәй таза, кызыл чырайлы кеше — балаларына һәрвакытта каты бәгырьле, каты куллы булды. Дөрес, ул аларны ашау-эчү, кием-салым җәһәтеннән бервакытта да кысмады — мул ашатты, әйбәт киендерде. (Итчеләр, гомумән, таза ашап яшиләр иде.) Әмма инде үз ихтыярына буйсындыруга килгәндә, аның сүзе-хөкеме һәрвакытта бик коры-каты булды. Балалары каршы әйтү түгел, аңа күтәрелеп карарга да куркалар иде. Өстәл әйләнәсенә җыйнаулашып ашарга утыргач, табында беркем бернәрсә сөйләми, авыз шапылдатудан башка тавыш та юк, инде малайларның берәрсе ни өчендер шыңшый башласа, аталары аңа күзенең агы белән бер генә карап куя — малай, җаны табанына киткәндәй, шунда ук тып-тын була. Шулай сөйли торган иде Мәхмүт атасы турында.

Гали абзый, җәмәгатен җирләгәч, озак та тормыйча үз авылыннан Мәликә исемле яшь, чибәр, таза хатын алып кайтты. Балалар өчен ятимлеккә үгилек тә өстәлде. Мәликә апаның ул балаларга мөнәсәбәте, бәлки, начар да булмагандыр, карагандыр да, әмма сынык күңелле балалар өчен ул инде барыбер үги ана иде. Мәхмүттәге төшенкелек, моңаюның да бер сәбәбе атасының бик яшь, чибәр хатынга өйләнүе булды түгелме икән?! Күзе ачылган ир бала мондый хәлне бик авыр кичерә торгандыр, ахрысы.

1918 елның кара көзендә, ягъни гражданнар сугышы иң көчәйгән бер чакта, без ике гаилә вакытлыча Уфага күчеп тордык. Күрәсең, безнең атайлар зур калада җан саклавы җиңелрәк, хәвефсезрәк булыр дип уйлаганнардыр инде. 1919 елны кызыллар Уфаны алгач та, без кире Дәүләкәнгә, үз йортыбызга кайттык. Ә Гали абзый ни өчендер ашыкмады, калып торды. Ачлык елны да уздырып, дөньялар рәтләнгәч, ялгышмасам, 1923 елны гына ул үзенең йортына кайтып керде. Бу вакытта инде Гайникамал апа буй җиткән зифа кыз иде. Аның Уфада яратып йөргән егете дә булган икән, озак та үтми, шушы Сәхип исемле егет Гайникамал артыннан Дәүләкәнгә дә килеп чыкты. Шул чакта мин аны күргән дә идем. Түгәрәк йөзле, зур күксел күзле, кечкенә колаклы, үзенә күрә чибәр генә егет иде ул... Ләкин Гали абзый ни өчендер бу егетнең исемен дә ишетергә теләми, өенә дә аяк бастырмый. Гайникамал апаны да очрашудан катгый рәвештә тыя. Ахрысы, шактый күпне күреп өлгергән иркә, көяз егетне мужик табигатьле итче абзыйның күңе-

ле кабул итә алмагандыр инде. Хәтеремдә, кышкы салкын көннәр, Сәхип егет айлы зәңгәрсу кичләрдә Дәүләкән урамында Гайникамал апаны сагалап, шыгыр-шыгыр атлап йөри — максаты аның кызны ничек тә качырып алып китү булган икән. Кемнеңдер ярдәме белән алар шулай да кайдадыр аулакта очрашалар, сөйләшәләр, качу турында сүз дә куешалар. Ләкин егет бер ахмаклык эшли: ат яллап, кызны качырып алып киткән төнне ул бер уңайдан Гали абзыйның капкасын да дегеткә буяп китә. Бу инде бик зур хурлык, тискәре атаны гына түгел, сөйгән кызын да ил-күз алдында мәсхәрә итү — моны ул, Сәхип, ахмак булмаса, әлбәттә, белергә тиеш иде. Гали абзый, кызның качканын сизгәч тә, иртә таңнан атын җигеп, артларыннан куа чыга. Ләкин, тегеләрнең бәхетеннән диеп әйтик инде, ул ялгыш юлдан китә һәм таба алмыйча караңгы төшкәндә генә кире борылып кайта. Әгәр ул артларыннан җитә алса иде, кала егетен «әһ» тә димичә күсәк белән сугып үтергән булыр иде. Көч-гайрәтне Ходай аңа биргән инде, ә ачу-ярсуы, билгеле, ташып чыккан булырга тиеш. Кайткач, шушы дәү-таза кеше капкасына буялган дегетне җылый-җылый кырган, имеш,— күргән кешеләр шулай сөйләгәннәр. Бәгырь дигәнең берәүдә дә таш түгел...

Кыска гына гомерле нэп вакытында Гали абзый Дәүләкән базарында әүвәлгечә ит белән сату итте. Аның йонлач бәкәлле, озын кара яллы йомры гына туры аты бар иде, шуны җигеп ул авыллар арасына чыгып китә иде дә, тимер ходлы арбасына бер-ике сарык салып, йә булмаса тәртәсенә берәр печкән үгез яки тана бәйләп алып кайта иде. Базар мәйданында ит рәте Кәримовлар бакчасы буенда иде. Гали абзыйның да шул рәттә, такта кыек астында, өстәле белән юан бүкәне тора иде. Алып кайткан терлеген суеп, шунда чыгара, күбрәк үзе сата, ләкин еш кына Мәхмүтне дә сатуга куя иде. Әйтергә кирәк, Мәхмүт бу эшкә, ягъни түшкәне белеп чабарга һәм дөрес үлчәргә шактый ук өйрәнеп өлгергән иде.

Ләкин, мәгълүм булганча, ирекле сәүдә озакка бармады. Егерменче елның урталарыннан инде сәүдәгәр малайлары таралыша да башлады. Язмышыннан аеруча канәгатьсез дустым Мәхмүт тә башын алып кая да булса чыгып китү турында еш кына хыяллана торган иде. Әмма аңа атасының каты кулыннан ычкынуы җиңел түгел иде. Мин менә атам-анамның ризалыгы белән җиңел генә киттем дә бардым, ә ул киндер алъяпкычын бәйләгән килеш ит рәтендә торып калган иде әле... Ләкин озакка бармаган аның да бу күңелсез һәм өметсез эшкә бәйләнеп

торуы — ничектер кыюлыгы җитеп, бөтенесен ташлап, ниһаять, ул да атасы йортыннан чыгып киткән. Мин икенче җәйне Казаннан кайткан чакта, Мәхмүт Дәүләкәндә юк иде инде.

...Тагын берничә тынгысыз ел үтә, сәүдә эшләре әкренләп сүнә, аннары бөтенләй бетерелә, шуннан соң Гали абзый үзе дә, яшь хатынын һәм аңардан туган ике кызын алып, яңадан Уфага күчә. Шулай итеп, Дәүләкәндә янә бер гаилә гомер иткән нигезеннән аерыла. Кайткан чакларымда мин һәрдаим Гали абзый йорты яныннан әкрен генә каранып узам. Ләкин кайчандыр, моннан бик күп еллар элек миңа бик таныш йортның танырлык бер җире дә калмаган — бөтенесе башка, йорт үзе дә, капка-коймасы да, торган кешесе дә... Кем ул? — белмәдем, сорашып та тормадым.

Мәхмүт белән без үсмер чакта никадәр дус-сердәш булып йөрсәк тә, Дәүләкәннән икебез ике якка чыгып китү белән безнең бәйләнешләр өзелде дә куйды. Очрашу да, хат язышу да булмады. Бары 1938 елны Оренбурга, якын туганнарыма кунакка баргач, мин Мәхмүтне шушы шәһәрдә очраткан идем. Кайда, кем булып эшләгәнен хәзер онытканмын инде, ләкин без берничә тапкыр күрештек, бергә ашап-эчеп тә утырдык, үткәннәрне сагынып искә дә төшердек. Бу безнең соңгы очрашуыбыз булды. Шуннан... юлларыбыз бөтенләйгә аерылды. Әмма мин аны гомерем буе диярлек онытып бетермәдем, күңелнең ниндидер бер яшерен почмагында ул һаман да яшәде, хәтта, сирәк кенә булса да төшләремә дә кергәли иде. Ихтимал, ул да мине онытып бетермәгәндер — күргән төшләрем аның да мине исенә төшергән чакларына туры килгәндер?!

Мәхмүтнең хәрби хезмәт кешесе булып киткәнен ишеткәнем бар иде, шулай ук сугыштан соң Кишинев шәһәрендә төпләнеп калуын да ишеткән идем. Шунда гаиләсе белән утыз елдан артык яшәгән ул, әмма бер генә тапкыр да Уфага яки Дәүләкән тирәсенә кайтмаган. Гаҗәп, Дәүләкәнне ташлап китүчеләр ни сәбәптер туган-үскән җирләренә кайтырга яратмыйлар. Җәбер-рәнҗүдән башка сагыныр нәрсәләре булмаганга күрәме?.. Югыйсә без бит барыбыз да Дәүләкәнне бик ярата идек.

Мәхмүт моннан бер-ике ел элек кенә вафат булган. Уфага баргач, Гайникамал апа миңа аның соңгы рәсемен күрсәтте. Билдән генә зур итеп төшерелгән бу фоторәсемдә Мәхмүтнең йөзе-кыяфәте бик ачык чыккан. Хәрби киемдә, яланбаш, күкрәгендә орден-медаль колодкалары, погоннарына караганда подполковник икән.

Ләкин Мәхмүтне тануы читен, җитмештән узган карт ул, йөзе-бите бик үзгәргән, тик менә чыгыбрак торган зур күзләре генә мин белгән Мәхмүтнеке. Һәм иң гаҗәбе — бу күзләрдә үсмер ятим чагындагы моңсу уйчанлык һаман да сакланган икән... Сугышларны үтсә дә, подполковник булса да, сакланган... Менә шулай очраштык без... Йә, нәрсә дип дәшим, дустым, мин сиңа?!

Гайникамал апага мине 1982 елның җәендә Маһирә алып барды. Бер үк шәһәрдә, хәтта бер үк урамда күптән торсалар да, алар да яңарак табышканнар. Ә мин күрмәгәнгә күпме булыр? Гайникамал апа 1924 елның кышында Сәхипкә ияреп киткән иде. Ә хәзер Җир шарында 1982 ел — күпме җилләр исеп, күпме сулар аккан шуннан соң! Нәкъ илле сигез ел икән — менә нинди ул очрашулар арасы!.. Ләкин мин Гайникамал апаны күрү белән таныдым. Җитмеш алты яшьлек карчык булса да, ул аз үзгәргән. Аннары әнисе Мәгълифә җиңгигә бик охшаган икән. Әнисенеке кебек озынча ак йөз, туры гына борын, нечкәрәк иреннәр — һәм җыерчык та басмаган үзен.

...Илле сигез елдан соң очрашкан кешеләр ни кичерә? Әлбәттә, гаҗәпләнү, сәерсенү, ышанып бетмичә һәм сүзне дә нидән башларга белмичә тору... Хәер, бу хәл озакка бармады, күпме генә еллар узмасын, без бик борыннан якын кешеләр — тиз кайттык без шул борынгы якын чакларыбызга. Билгеле, Гайникамал апа башта үз хәле турында сөйләде. Аның Сәхибе күптән үлгән икән инде, атасы Гали абзый да үлгән, энесе Миңнеәхмәт тә Мәхмүткә чаклы ук үлгән булган. Кыскасы, берүзе генә калган, бер малай үстергән, анысы күптән өйләнгән, үзләренә башка торалар икән. Үзе генә шушында, озынча тар бүлмәдә, ялгызы гына яшәп ята, күпмедер пенсиясе бар, ара-тирә эшләштергәли дә икән (урамда лотошница булып, диде). Без килүгә үзенчә әзерләнгән, берничә төрле камыр ашлары пешергән, сухой виносын да өстәлгә чыгарып куйды. Сүзен бүлә-бүлә кыстый безне...

Әмма ул сөйләгәннәрдән минем өчен иң гыйбрәтлесе — Гали абзый турындагысы иде. Баштарак әйтергә оныткамын — Гали абзый эчә торган кеше иде бит... Малай чактан ук әле мин аның эчүдән гел кып-кызыл булып йөргәнен, еш кына безнең ишегалдына кызмача килеп кергәнен һәм кәефле-дорфа гына: «Кайда син, Каргалы төмәне?» — дип, атакайга кычкырганын хәтерлим. Дөрес, ул заманда татарлар бал эчәләр иде, койган баллары мичкәсе белән җылы мич башында кымырҗып, әкрен генә шаулап утыра торган иде. Бал янында табак

тулы пешкән ит, кыскасы, таза эчкәннәр, таза ашаганнар — бигрәк тә итчеләр. Ләкин Гали абзый, мәрхүм, эчүен соңгы гомеренә чаклы ташламаган. Базар капкасы төбендә утырып, көнбагыш сатып тапкан тиеннәрен дә аракыга тотып бетергән. Яшь хатыны Мәликә апа аны күптән ташлаган булган. Ялгыз тилмереп йөрергә калган ятим карт ахырда кызы Гайникамалга барып сыенган. Әнә шундый ачы язмыш! Ләкин язмышы ачы булса да, һәм гомере буена эчсә дә, Гали абзый туксан ике яшенә җитеп, сукыраеп, Гайникамал апа кулында вафат булган... Әйе, Ишле авылыннан чыккан бу татар абзыена Ходай тазалык белән куәтне биргән дә икән — исеңакылың китәр!

Белмим, атакай бер урында озак торырга яратмаганга күрәме, әллә бүтән берәр сәбәптәнме, без тагын фатирыбызны алыштырдык. Соңгы өч-дүрт ел эчендә бу инде өченче йорт. Җитмәсә, бусы да аерым йорт, ягъни бары үзебез өчен генә... Хәзергә кадәр аңлый алганым юк, мондый буш торган йортлар Дәүләкәндә ничек табылды икән? Хуҗалары кайда, кемнәр алар? Вакытында сораша да белмәгәнмен... Ләкин, фараз кылуымча, Дәүләкәндәге буш йортлар, тәгаен, якын-тирә хуторларда торучыларныкы булгандыр, шулар, мөгаен, арендага бирә торган булганнардыр. Дәүләкән кебек җирдә табыш китерә торган йорт биләү начар эшмени ул?!

Шулай итеп, без яңадан Комач буена күчтек, ләкин яр башына түгел, ә яр астына. Монда, су буена сөзәк кенә төшкән тигезрәк җирдә, бер урам бар иде, аны Набережная дип йөртәләр дә иде — безнең йорт менә шул урамның беткән җирендә, бездән соң бүтән йорт юк, чөнки тигез җир бетеп, текә яр башлана.

Бу йорт та, әйтергә кирәк, әйбәт-төзек кенә иде. Калай белән япкан, такта белән тышланган, күк төскә буялган — аны шулай «күк йорт» дип атыйлар да иде. Урамга чыга торган кунаклар ишеге дә бар, ишегалдына караган верандасы да бар. Һәм безнең өчен иң күңеллесе — ишегалды белән янәшә зур гына бакчасы да бар... Дөрес, анда җимеш агачлары үсми, анда койма буйлап карт тирәкләр генә үсеп утыра, ә арткы коймасы су читенә тиеп үк тора. Безгә уйнар өчен бик әйбәт «площадка»! (Хәзергечә әйтсәк!)

«Күк йортта» без бары бер җәй дә бер кыш кына тордык. Атакай үзенең сәүдә эшләре белән һаман читкә чыгып йөрде, безнең янга «иптәшкә» әүвәлгечә Зөфәр белән Маһирә куна киләләр иде, ә көндезләрен әлеге бак-

чада бергә уйнарга Мәхмүт белән Миңнеәхмәт килеп җитәләр иде. Кыска гына вакыт торганга күрәдер инде, минем бу йорт белән бәйләнгән истәлекләрем бик аз, булган кадәресе дә онытылып беткән диярлек. Бик яшь идек шул әле, зур дөнья, зур вакыйгалар бездән читтә иде әле. Хәлбуки бу инде унҗиденче елның җәе иде, дөньяның бик кайный башлаган чагы, өченче ел инде бөтендөнья сугышы бара, Дәүләкән турысыннан көн саен диярлек атлар, туплар, солдатлар төягән кызыл эшелоннар тукылдап үтеп тора, тик боларны аңлабрак күрү өчен безнең тагын азрак үсә төшүебез кирәк булган.

Әмма шулай да бу йортның «истәлеге» буларак бер вакыйга минем бала күңелемдә бик нык уелып калды. Әйтергә кирәк, хәзергә кадәр ачык сакланган бик сирәк хатирәләремнең берсе ул... Беләсез инде, җиде-сигез яшьлек малайлар өйләре тирәсендә генә уйнап йөрү белән чикләнмиләр, кызык эзләп алар ераккарак — авыл читенә, кырга-яланга, тау-чокыр буйларына китеп йөри башлыйлар. Менә без дә, өч малай, беркөнне тоттык та тимер юлга киттек. Куркырга ашыкмагыз, без үзебез дә үткәнсүткән поездларга якын бармыйбыз, аның тавышыннан, җиленнән үк әле качабыз. Аннары безнең теләк тә юл буенда йөрү түгел, ә юлны аша үтеп, кырга чыгу иде. Анда, элеватор артындагы кырда, руслар күп итеп көнбагыш үстергән — менә шунда таба инде безнең юлыбыз да... Читтәге такыр сукмактан Яңа Көрмәнкәйгә таба күпмедер атлагач, без тимер юлга күтәрелеп, каршы якка чыктык. Шунда ук алдыбызда, бик ерак та түгел, сапсары түгәрәк башларын иеп, яшел-зифа урмандай үсеп утырган көнбагыш кырлары ачылды. Без тимер юлдан йөгерешеп төштек тә киттек шунда таба! Барырга, тиягә ярамый дип яки каравылчысы-мазар булыр дип уйлый белдекме икән? Юктыр, ахрысы, ничектер куркып та, икеләнеп тә тормыйча көнбагышлар арасына барып та кердек. Эчкә узмыйча гына читтәге көнбагыш башларын кабаланып өзәргә дә тотындык. Бөгелеп төшкән бик зурларына безнең көчебез җитмәде. Шулай да нечкәрәк сабаклы кечерәкләрен боргалый-боргалый өзеп алдык. Инде нишләргә? Беребез хәйләсен тапты — күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырды да көнбагышларын изүе эченә салды. Без дә шулай эшләдек. Хәзер тиз генә моннан сызарга кирәк иде. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, көнбагыш сабаклары арасыннан чыгуга, безгә таба якынлашып килгән бер марҗа түтәен күреп алдык. Янында бездән олырак малае да бар... Бу хәлдән бер мәлгә каушап калдык, хәтта туктарга мәҗбүр булдык, аннары,

сүз куешкандай бердән кубып, табаннарны ялтырата-ялтырата түбән таба элдерттек. Марҗа түти безнең арттан йөгермәде, малаен да куа җибәрмәде, бары боерык биргәндәй татарчалап кычкырды гына:

— Туктагыз!

Һәм мин туктадым, ә иптәшләрем — юк, борылып та карамыйча чаптылар гына... Марҗа түти кулын изәп кенә мине янына чакырды:

— Малайка, кил әле монда, кил!

Мин бик каушап, курка-курка гына аңа якынлаштым.

— Курыкма! — диде ул миңа, малае кизәнмәкче иде — аны да тыйды, суктырмады. Түти гәүдәгә зур иде, тулы-таза иде, мөлаем да кебек иде.

— Күлмәк эчендә нәрсә, чыгар әле! — диде.

Мин изүдән өч баш көнбагыш чыгардым.

— Ват вит, бәләкәй генә башың белән урлашырга да тотынгансың,— диде ул, гүя ачусыз гына.

Мин дәшмәдем, колакларыма хәтле кызардым, җылап җибәрергә авызым да җәелә башлады, ләкин ничектер тыелып калдым. Марҗа түти әллә кызганып, әллә нидер уйланып, беравык минем өстемә карап торды — мин ул чакта чебештәй бик арык, нечкә генә бер малай идем.

— Кем малае син? — дип сорады ул.

Мин көчкә генә:

— Хәдичә апаныкы,— дидем.

— Кайда торасыз?

— Күк йортта.

— Кайда ул «күк йорт»ыгыз?

— Комач буенда.

Марҗа түти аз гына дәшми торганнан соң миңа:

— Итәгеңне тот әле,— диде.

Мин аңламадым, ул тагын кабатлады:

— Итәгеңне күтәр диләр сиңа!

«Нигә икән?» дип аптырап, мин кыюсыз гына ике куллап күлмәк итәгемне күтәрдем, ә марҗа түти әлеге өч баш көнбагышны минем тотып торган итәгемә салды. «Биреп җибәрә, ахрысы» дигән уй килде миңа шунда ук, һәм мин берьюлы җиңеләеп киткәндәй булдым. Ләкин мөлаем түти тыныч кына:

— Инде өегезгә барабыз, әйдә атла! — диде.

...Өчәүләшеп авылга таба кузгалып киттек. Барган җиремнән «Озатып куймакчы була микәнни, мин бит болай да кайта беләм» дип уйлыйм, тик бу турыда түтинең үзенә әйтергә кыюлыгым гына җитми, билгеле... Ә

ул мине туры гына «озатасы» урында, ни өчендер шактый урау ясап, Дәүләкәннең төп урамына алып чыкты. Озын урамның иң очыннан төшеп, безгә таба атлыйбыз — уртадан, көнбагыш тулы итәгемне күтәреп, мин барам, ике ягымда ике сакчыдай таза марҗа түти белән аның дәү генә малае бара... Очраган кешеләр, «Бу ни тамаша?» дигәндәй, безгә карап калалар. Кайберләренең йөзендә «малайны эләктергәннәр икән» дигән төслерәк әче генә елмаю да чагыла һәм бу хәл мине оялту гына түгел, чынлап торып борчый да башлый.

Ахырда безнең «күк йорт»ка килеп җиттек. Парадный ишектән барып кердек, туп-туры өйгә дә уздык. Керсәк, залда өч-дүрт хатын чәй эчеп утыра. (Атакай өйдә юк чакта, инәй күрше хатыннарын шулай чәйгә дәшәргә ярата иде.) Ләкин кунаклар өстенә килеп керү марҗа түтине бер дә борчымады, ахрысы, ул каты итеп, кычкыра биреп сорады:

— Хәзәйкә, сезнең малаегызмы бу?

Инәй аның соравын ишетмәгән дә шикелле тәмам коелып миңа текәлде:

— Балам, сиңа ни булды?

Билгеле, минем сүз әйтерлек тәкатем калмаган иде, аның каравы марҗа түти шунда ук:

— Без аны көнбагыш урлаган җирендә тоттык! — диде.

— Булмас ла!

— Әнә бит итәгендә көнбагышлары!..

Инәй, бичара, бер сүз әйтә алмады, йөзе сытылып, агарып киткәндәй булды, авыру күзләренә мөлдерәп яшьләре дә килде. Мин көнбагышларымны төшереп җибәрдем дә аның итәгенә барып капландым. Һәм тыелгысыз үксүдән, бизгәк тоткандай, бөтен тәнем белән калтырана да башладым. Түрдә ашау-эчүләрен бүлеп, аптырап утырган хатыннар да, ахры, түзмәделәр:

— Бала гына бит әле ул, көнбагыш башы өчен генә шулай рисвай итәргә ярыймыни? — диештеләр.

Марҗа түти бармагын туп-туры миңа төртеп, тагы да катырак итеп:

— Менә, менә, бала чактан ук тыярга кирәк аны урлашудан,— диде.— Үскәч соң була ул... Шуның өчен китердем дә мин аны сезгә... Сабак булсын дидем! Ә көнбагыш безгә җәл түгел, пажалыста, ашасын!

Шулай диде дә, малаен ияртеп, каты басып чыгып та китте. Көнбагыш башлары идәндә сибелеп калды. Инәй, бераз исен җыйгач, аларны юынтык су чиләгенә чыгарып ташлады.

Әнә шундый сабак алдым мин сигез яшемдә! Гомер

буена онытылмаслык сабак! Һәм... файдалы сабак! Моның өчен маржа түтигә рәхмәт тә әйтергә ярый торгандыр. Әмма ул чакта инәйне бик кызганган идем. Ни сәбәптер ул минем «урлашып» тотылуымны бик авыр кичерде. Кунаклары киткәч тә, сүздән калып, боегып йөрде. Мине дә үгетләп-нитеп тормады, бары аркамнан сыйпады да йомшак кына: «Әйдә, балам, ачыккансыңдыр»,— дип ашарга утыртты. Күрәсең, кунаклар алдында «рисвай булуым» да җиткән дигәндер инде. Һәм үзенең йөрәге дә бигрәк шуның өчен сызлангандыр — шулай уйладым мин соңыннан бу «истәлекле» көнне исемә төшергән чакларда.

«Күк йорт»ка бәйле тагын нәрсә күңелемдә саклана? Әллә ни кызыклысы юк шикелле, булганнары да бала-чага уеннары гына, ә уеннар турында соңрак сүз булыр әле. Әмма шулай да бер мөһим вакыйганы искә төшермичә үтү ярамас. Без моңарчы сыер белән кош-корттан башка нәрсә асрамый идек. Бәлки, кирәге дә булмагандыр, ә бәлки, хәлебез җитмәгәндер — мин ул кадәресен белмим. Ә менә шушы йортта торганда, атакай тотты да бик шәп бер ат сатып алды. (Димәк, бу вакытта инде аның хәленнән килгән.) Ат — зәһәр, тимеркүк яшь айгыр. Гәүдәгә биек кенә, буйга да озын гына, ялы белән койрыгы да куе-озын, колаклары уйнаклап, күзләре янып тора. Әйе, әйтәсе дә түгел, сылу хайван! Җигеп йөрер өчен махсус өйрәтелгән юртак икән ул үзе. Бер дилбегә кагу белән нечкә-озын аякларын эре-эре ташлап, ләкин һич тә сикереп чабуга күчмичә, җилдәй очып кына бара икән. Ниндидер боярның затлы нәселдән бик кадерле юртагы булган, диделәр аны.

Энем белән без икәү, Тимеркүктән күзләребезне алмасак та, кыюланып янына барырга курка идек әле. Кушмыйлар да, белмәссең хайванның холкын, диләр. Ә дәртле айгыр гел башын чайкап, пошкырып, алгы тоягы белән җирне тырнап кына тора. Аны күбрәк аранда гына тоталар. Атакай өйдә чакта үзе карый, киткән чакларында инәй карый торган иде. Айгыр аранда торып, бик тынычсызлана башласа, ишегалдына чыгарып, берәр баганага таза бау белән бәйләп куялар. Әйткәнемчә, безнең ихата Комач читенә терәлеп үк тора, язгы ташу вакытында су ишегалдына да үтеп керә иде. Бәйләп куйган айгыр да, якындагы су исен сизепме, әллә аръяктагы яшел болынны күрепме, баскан җирендә һич тыныч кына тора алмый, өзлексез әйләнә-тулгана, чигенә-тартыла, йә булмаса, башын күтәреп, танавын киереп һаваны иснәргә тотына, шул чагында еш кына бөтен су буен яңгыратып кешнәп тә җибәрә. Кыскасы, хөрлек, иркенлек таләп итә иде ул!

Атакай хайваннарга карата йомшак күңелле иде, сөяргә, сыйпарга, дәшәргә ярата иде. Күк айгырның да хәлен аңлап булса кирәк, беркөнне ул аны ишегалды белән янәшә бакчага, йөгәнен салдырып, кертеп җибәрде. Айгыр, читлектән ычкынган коштай, бакчаны бер итеп, артын уйната-уйната, әллә ничә кат чабып әйләнде, аннары, күңеле хушлангандай, ашыкмыйча җирне иснәп кенә йөрде, бер җирдә ятып, аякларын күтәреп, аунап та алды, торгач, бөтен тәне белән калтырана-калтырана селкенде, шуннан соң нидер сизенгәндәй бакча түренә барып, койма өстеннән аргы якка карап тора башлады. Ә анда, ерак тугайда, елкы көтүе йөри иде. Безнең айгыр шуларны күрде, күрү генә түгел, ничектер исләрен тойды бугай, башын күтәргән килеш колакларын кайчыдай торгызып, уттай күзләрен тасрайтып карап торды-торды да, кинәт койма аша суга сикереп, аргы якка йөзеп чыгып та китте... Без «ах!» итеп кенә калдык. Ярый әле атакай ишегалдында йөри иде, бу хәлне күргәч бик хафаланып: «Өер айгырлары белән сугышып, харап кына булмаса ярар иде!» — диде дә, тиз генә йөгән эләктереп, күрше коймәсендә аргы якка ашыкты. Ул каршы ярга барып туктаганда, Тимеркүк әллә кайчан бияләр көтүенә барып та җиткән, андагы өер айгырлары белән чинашып, тешләшеп сугыша да башлаган. Яхшы әле, якында гына печән чабучы башкорт агайлары бу тамашаны күреп алганнар. Бары шулар ярдәме белән генә атакай күк айгырны бияләр көтүеннән көчкә аерып алып кайтты. Йә, шыр тиле түгел диген син аны. Җитмәсә әле, яудан кайткан батыр сыман эре генә басып тора, тешләнгән, яраланган җире дә күренми үзенең. Атакай әйтә: «Аңа чыдыйлармы соң, вак айгырларны шунда ук куып бетергән»,— ди... Ләкин шулай да бу вакыйгадан соң инде Тимеркүкне тезгенсез бушлай гына бакчага җибәрү бетте.

Атакайның соңгы елларда эше әйбәт барган булырга тиеш — югыйсә мондый шәп ат безнең йортка кайчан керер иде әле... Бу вакыт 1917 елның буталчык хәвефле җәе булса да, ул үзенең сәүдә эшләре белән йөрүдән туктап тормады.

Ләкин шуңа да карамастан аны чын «купич» дип танымыйлар иде әле, чөнки ул йортсыз кеше, ул һаман да «фатир күчеп» йөрергә мәҗбүр... Ә йортсыз «купич» булырга мөмкинме? — Әлбәттә, юк. Мондагы эре сәүдәгәрләр генә түгел, вак сатучылар да — йортлы-җирле кешеләр. Хәтта әнә тимерче Миңнегали карт яки тегүче Солтан абзый кебек хәллерәк һөнәрчеләр дә үз йортлары белән торалар. Йорты барның абруе бар — ул ышанычлы

кеше. Җиккән атың нихәтле генә шәп булмасын, әгәр синең үз нигезең, үз йортың юк икән, син әле төпле, ныклы хуҗа түгелсең.

Билгеле инде, безнең атакайның да бөтен хыялы йорт алу, йортлы булу иде. Шуның өчен йөри, шуның өчен тырыша һәм шуңа омтыла да иде. Ләкин ни сәбәптер ул бу эшне һаман суза да суза. Акчасы җитмиме, йорты очрамыймы — сәбәп нәрсәдә?

Кыскасы, без 1917 елның тынгысыз җәен дә, явымлы пычрак көзен дә шул «күк йорт»та уздырдык. Кышка да кердек... Мин икенче ел инде мәчет каршындагы мәдрәсәгә укырга йөрим. Монда ул чакта парта дигән нәрсә юк иде әле, тәбәнәк өстәлләр артында астыбызга җәйгән киезләргә тезләнеп утыра идек. Хәлфәбез читтән килгән коръәнхафиз — бик усал кансыз бер кеше иде. Янында утырган шәригеңә дәшү түгел, борылып карарга да ярамый — шунда ук хәлфәнең өчтән үргән талчыбыгы сызгырып өстеңә төшә. Күп кенә малайлар дәрестән юеш балакларын ләштердәтеп өйләренә кайталар иде. (Бу хәлфә турында мин күп еллардан соң «Коръәнхафиз» дигән хикәя дә яздым.)

Безнең башлар әнә шулай кыйнала-кыйнала укып азапланган бер заманда, ерак пайтәхеттә[1] тагын бер инкыйлаб булган дип ишеттек. Бусын Үктәбер инкыйлабы, диделәр. Аның хәбәре безнең Дәүләкәнгә соңрак килеп җитте. Бик алама вакыт иде, кар-яңгыр, сыргак, салкын, Дәүләкән урамнары тездән пычрак, шуңа күрә патша төшерелгән чактагы кебек урамнарга чыгып, нәмаеш ясап йөрүләр дә булмады. Әмма шушы кечкенә җиребездә дә тыныч түгел, шомлы-киеренке, кешеләр, тыннарын кысып, гүя зур тайфун килеп җиткәнен көтеп торалар. Безнең атакай да йөрүеннән туктады, өйдә генә ята. Хәер, ул гынамы соң — сәүдәләр сүнде, базарлар сүрелде, күпләр өчен тик ятудан яки мал-туарын караудан башка эш тә калмады.

Ләкин озакка бармады бу хәл, бу көтеп яту. 1918 елга керү белән вакыйгалар, бөтен җирдәге шикелле, бездә дә бик тиз куерып, кискенләшеп китте. Нәкъ ел башында Уфадан килгән кораллы отряд ярдәме белән Дәүләкәндә дә, ниһаять, Совет власте урнаштырылды. Әмма яңа власть озак яши алмады — Дәүләкәнне чехлар басып алдылар. Шуңа ялганып, аклар-кызыллар сугышы башланып китте. Тагын халыкка шик-шөбһә, талаш-тартыш, курку-өркү килде. Бу зур сугыш Дәүләкәнне дә, билгеле, читләтеп узмаячак иде.

---

[1] *Пайтәхет* — башкала.— *Ә.Е.*

...Дөньяның нәкъ шушындый кызган, буталган бер чагында безнең атакай тотты да йорт сатып алу хәстәренә керește. Хәзер дә гаҗәпләнәм, нәрсә мәҗбүр итте икән аны болай ашыгырга?.. Ахрысы, ул чактагы буталчык шартларда берәүләргә артык мөлкәттән тизрәк котылырга, ә икенчеләргә кулындагы акчасын ничек тә мөлкәткә әйләндерергә кирәк булгандыр. Әнә шундый ситуация, хәзергечә әйтсәк.

Ничек кенә булмасын, атакай чарасына керешә, йорт сатучыны таба һәм сөйләшүләр башлана. Йортның хуҗасы — хуторда яшәүче бер рус бае. Сөйләшүләр авыр бара, хуҗа сайлана, юри суза, чөнки йортны сатып алырга теләүче бүтәннәр дә табыла. Шуның өстенә тагын икенче бер кыенлык та килеп чыга. Хикмәт шунда, йорт үзе русныкы булса да, утырган җире, гадәттәгечә, башкортныкы. Аның да ризалыгын алырга кирәк. Җир хуҗасы Сәлимҗан агай үз таләбен китереп куя: ердең бөтәһен дә бирмәем, яртыһын үземә калдырам, ди... Шулай итеп, берьюлы ике хуҗа белән сөйләшүләр алып барырга туры килә.

Бәлки, тырышып йөрүләр нәтиҗәсез дә беткән булыр иде, ярый әле бу эштә безнең атакайга әлеге тимерче Миңнегали карт бик нык булыша. Ул акыллы, абруйлы һәм сүзгә оста кеше иде. Атакай аны, күк айгырга утыртып, берничә мәртәбә хуторга алып бара. Ахырда ул өч якны да килештерә: атакай йортны ала, килешенгән хакын түли, ә җиргә килгәндә, аны Сәлимҗан агай белән бүлешергә риза була. Бары шуның аркасында гына йорт безнеке булып кала, чөнки башка сатып алырга теләүчеләр йорт ихатасын бүлешергә риза булмыйлар... Зур эш әнә шулай төгәлләнә. Хәере белән булсын, диләр, утырып дога кылалар, соңрак хәзрәтне чакырып Коръән дә укыталар.

Мактанудан булмасын, йорт үзе дә, утырган җире дә бик әйбәт. Күрү белән яраттык без аны. Төп урамның уртарак бер төшендә, мәчет-мәдрәсәгә дә якын, базардан да ерак түгел, каршыда гына тимер юлга чыга торган кыскарак тагын бер урам башлана (исеме — Холодный переулок). Йортыбыз калай белән япкан, ике катлы: түбәнге каты җиргә кертеп — таштан, ә өске каты бүрәнәдән салынган. Урамга өч тәрәзәсе карый, парадный дигән ишеге дә бар. Капка-коймасы кызылга буялган, шуңа күрә аны «кызыл йорт» дип тә йөрткәннәр.

Ихатабыз, бик киң булмаса да, ишегалды түренә таба шактый озын иде. Әлеге килешү буенча, аны нәкъ уртасыннан бүлеп киртә тоттылар: уң ягы безгә, сул ягы

Сәлимҗан агайга. Безнең якта йортыбыздан башка тагын тәгәрмәч чыгырлы кое торып калды. Ә Сәлимҗан агай өлешенә кайбер caралтылар белән бергә матур гына бакча да эләкте. Без бигрәк тә бакчаны кызгандык. Сәлимҗан агай үзенең «пәриле» очындагы өен соңыннан шул бакча урынына күчереп куйды.

Ихатаны бүлүнең исә көтелмәгәнрәк бер кыенлыгы да чыкты. Ишегалды түреннән тотыла башлаган киртә урам капканың нәкъ уртасына туры килде. Бер яртысы безнең якка, икенче яртысы Сәлимҗан агай ягына ачыла торган булып калды. Шул сәбәпле киртәне капкага китереп җиткермичә туктаттылар һәм вакытлыча бер капкадан йөреп торырга булдылар. Соңыннан ике хуҗа да үзләренә аерым капка эшләтергә тиеш иде. Ләкин айлар узды, еллар узды, сугышлар да үтеп китте, ачлык елын да уздырып җибәрдек, әмма яңа капка тәки эшләнмичә калды. Шулай итеп безнекеләр Дәүләкәннән киткәнчегә кадәр ике күрше бер капкадан йөрделәр. Безгә килүчеләр киртәнең уң ягына, күршегә килүчеләр сул ягына узалар иде.

Яңа йортка — инде үзебезнең йортка — без 1918 елның июнь башында күчендек. Үзебезнеке! — бу кодрәтле сүз безнең малай җаныбызны да биләп алырга өлгергән иде.

Без, әлбәттә, бик шат идек. Тизрәк күчәргә атлыгып кына тора идек. Беренче мәртәбә атакайга ияреп баргач, без энем белән икәү йортның бөтен җирен — эчен-тышын һәм ишегалдын карап чыктык. Түбәнге ярым подвалында кайчандыр пекарня булган икән. Ишектән керүгә нәкъ каршыда тәбәнәк-киң авызлы галәмәт зур мич, стена буенда ак тактадан таза эшләнгән лар-әрҗәләр, мич кырыенда сөяп куйган озын саплы көрәк һәм пумалалар... Почмакларында он кунган пәрәвезләр һәм... бөтен җиреннән күпергән камыр исе килеп тора кебек... Монда ак калач белән йомшак клиндерләр пешергән булырга тиешләр. Ак калачның нәрсә икәнен без дә әзрәк беләбез... Бәлки әле, бу әкәмәт мичтә безнең үзебезгә дә ак калачны пешерергә туры килер... дип уйладым мин бала хыялым белән.

Пекарняны тиз генә карап чыктык та ашыгып югары катка мендек. Монда инде иртәгәдән дә калмыйча без үзебез тора башлаячакбыз. Менә зур гына өй алды, сулда такта ишек — анда чолан булса кирәк, уңда урам (парадный) ишегенә төшә торган, сарыга буяган баскыч... Әйбәт!.. Ярый, зур таза ишектән өйгә үк кердек. Каршыда коридор, сулда кухняга уза торган аралык, ә уңда

ике якка ачылмалы ак ишек. Без иң элек әнә шул шәһәрчә шәп ишекне сак кына ачып, түр якка (залга) кыяр-кыймас кына атладык. Һәм керү белән авызыбызны ачып, бер мәлгә аптырап калдык: монда моңарчы без күрмәгән кайбер җиһазлар да бар иде. Мәсәлән, каршы стенада идәннән алып түшәмгә чаклы сузылган зур көзге. Без, ике яланаяк малай, гүя каршы яктан килеп кергәндәй шул көзге эчендә янәшә басып торабыз, әкәмәт!.. Монда шулай ук бик матур сары шкаф белән стена буена тезелешкән биек артлы урындыклар да бар иде. Боларның барысын да атакай йорт белән бергә сатып алган икән.

Без, ике малай, әнә шулай яңа йортыбыз белән танышып чыктык. Билгеле инде, бөтен ихатасын әйләндек, бер почмагын да калдырмадык. Ихата әле уртадан бүленмәгән иде, шуңа күрә ул безгә бик иркен-зур булып күренде... Әйткәнемчә, без яңа йортка июнь башында күчендек. Иң элек, йола кушканча, инәй йортыбызның түренә070бербөтен икмәк белән бер чирек сөт китереп куйды. Монда да тормышыбыз мул, тук булсын өчен иде бу... Аннары күк айгырда әйберләребезне ташыдык. Дәүләкәндә безнең якын туганнарыбыз Зәкия тутакай белән Хәсән җизни торалар иде — күченгәндә шулар иртәдән кичкә кадәр безгә булыштылар. Көн яктысында ашап-эчкәннән соң, туганнар да киткәч, без беренче мәртәбә яңа урында, догаларыбызны укып, йокларга яттык. Ләкин, бик арыган булуыбызга карамастан, беребез дә тиз генә йокыга китә алмадык. Әллә шатлыктан, әллә татлы хыялдан... Атакай белән инәй шыпырт кына һаман нидер сөйләшеп яттылар. Миңа да бит инде тугыз яшь, хыяллана башлаган чагым. Хәер, йоклый алмыйчаниләр уйлап ятканымны белмим, бәлки, тизрәк үсү, матур булу, матур киенү турында уйланганмындыр... Әйе, бу төнне хыяллар йокыдан татлырак иде.

Күпмедер вакыт без яңа йортыбызга урнашу, җайлашу, ияләшү чорын кичердек. Әмма бу бик кыска бер ара булып калды. Баштарак әйткәнемчә, 1918 елның җәе аклар-кызыллар сугышының көчәйгән чагы иде, шуңа күрә безнең Дәүләкәндә дә вакыйгалар бик тиз үзгәрә башлады.

Әнә шулай ниләр булыр икән дип көтеп йөргән арада, мин әле ике ягыбыздагы күршеләр белән дә әзрәк кенә танышырга өлгердем. Уң ягыбызда рус ихатасы иде. Калай түбәле кечерәк кенә йорт, бер сарайдан башка бүтән каралтысы да юк, ләкин зур гына ишегалларында төрле яшелчәләр утыртылган түтәлләре күп иде. Тик, ни га-

җәптер, бу йорт кайчан гына карама гел буш тора, анда уйнап йөргән бала-чага да, хуҗага охшаган ир-ат та күренми, бары түтәлләр арасында бер марҗа түти генә иелеп эшләп йөри торган иде. Соңыннан белдек — бу йортның хуҗасы Дәүләкәннең иң беренче революционерлары бертуган Иван белән Николай Кириченколар икән. Бәлки, вакыт бик киеренке-куркыныч булганга күрә, алар өйләрендә юньләп тормаганнардыр да... Николай атлысы бит 1918 елның башында Дәүләкәндә оештырылган Совет властеның беренче председателе булган кеше — димәк, ул чакта аның бу тирәдә ни өчен күренмәве хәзер менә аңлашылса кирәк. Аннары инде соңрак безнең белән Кириченколар арасына Сәлимҗан агай килеп утырды.

Әмма мине иң кызыктырганы — сул як күршебез Борһан абзый йорты иде. Борһан абзыйның кем булуын хәтерлисездер — ул Дәүләкәннең зур бер купецы иде. Йорты урамга буй салынган, шактый тәбәнәк, тәрәзәләре дә кечкенә, шуңадыр, ахры, тыштан әллә ни зур да, матур да түгел иде. Ләкин аның каравы ишегаллары бик иркен, күп җире яшел чирәм, сарай-амбарлары да бүрәнәдән салынган. Менә шул зур ишегалдында бик пөхтә киенгән бер көтү вак бала-чага шаулап, уйнап йөриләр. Мин аларны бик кызыксынып койма ярыгыннан күзәтәм. Алар бер дә диярлек урамга чыкмыйлар һәм үзләренә дә беркемне дә кертмиләр бугай — капкаларының аркылы агачы һәрвакытта шылдырып куелган була. Шуңа күрә миңа койма буйлап ярык эзләп йөрергә туры килә дә. Оятрак булса да әйтим инде, ишегалдын тутырып, уйнап йөрүче бу шат балалар арасыннан бер кыз башта минем күземне, аннары күңелемне үзенә тартып өлгергән иде. Ул араларында зуррагы, нечкә-нәфис буйлы, озын кара толымлы иде. Хәер, барысы да чибәрләр, барысы да матур киенгәннәр, араларында тездән генә бәрхет чалбар кигән ике малай да бар, ләкин барыбер минем күзем әлеге шул кара толымлы кызда гына... Бу кыз сезгә таныш булырга тиеш — ул Һаҗәр, Борһан абзыйның уртанчы кызы, арада иң чибәре һәм минем беренче мәхәббәтем... Соңыннан, миңа аларның барысы белән дә танышырга да, якыннан аралашырга да туры килде. Әмма Һаҗәргә гашыйк булуым койма ярыгыннан карап йөргән чакта ук башланган иде инде!..

Ләкин, әйткәнемчә, хәлләр бик тиз үзгәрде. Июнь ахырлары булды микән, көннәрдән бер көнне Дәүләкәнгә сугышмыйча-атышмыйча гына чехлар керделәр. Бу инде Дәүләкәнне басып алган беренче кораллы гаскәр иде. Алар, кергән көннәреннән алып чыгып киткәнчегә кадәр,

станциядә запас юлга куелган үзләренең эшелоннарында тордылар. Солдатлары авыл арасына чыгып, таралып та йөрмәделәр. Халык та аларга чит-ят бер кавемгә караган шикелле карый иде. Шулай да мин аларның бик көяз киенгән офицерларын әзрәк хәтерлим әле. Безгә каршы чаттагы чибәр генә йортта бер рус гаиләсе тора иде, анда берничә сылу гына ханым да күренә иде — чех офицерлары ара-тирә менә шулар янына килеп, граммофон уйнатып, танцевать итеп китәләр иде. Шул чакта мин аларны күргәләдем.

Бу вакытның тагын бер вакыйгасы истә калган. Дәүләкән станциясендә чехлар безнең Шәриф җизни Сүнчәләйне кулга алалар. Шәриф Сүнчәләй — Уфадагы революция вакыйгаларына актив катнашкан кеше, большевиклар тарафдары, чехлар кулына эләкмәс өчен Уфадан вакытлыча киткән дә булган. Ләкин Дәүләкәндәге чехлар да, нидер сизепме, белепме, бу бик интеллигент кыяфәтле кешене камап, тикшерә башлыйлар. Әлбәттә, җизни өчен зур куркыныч туа. Озак та үтми, Уфадан Срур тутакай да килеп җитә. Аларны күрештерәләр.

Минем күз алдымда шундый бер күренеш саклана: урам уртасыннан рессорлы шәп пролеткага җигелгән үзе эре сөякле, үзе бик сылу, бәкәлләрен кысып ак чүпрәк ураган чем-кара айгыр атлап кына китеп бара. Пролеткага җизни белән Срур тутакай янәшә утырганнар. Җизнинең иңендә кара накидка, башында киң читле эшләпә, Срур тутакайның башында да бик матур, бик килешле җиңел эшләпә — Дәүләкәннеке түгел икәнлекләре әллә кайдан күренеп тора. Кучерда — чех солдаты, ә пролетканың ике ягында — атка атланган ике сакчы. Ни өчен кулга алынган кешене болай шәп ат җиккән пролеткага утыртып йөртәләр икән, дип бик гаҗәпләнгән идем, тик соңыннан гына зурлардан ишетеп белдем: безнең җизни үткән ел Учредительный Собраниегә сайланган булган, ул депутат кеше, шуңа күрә аңа менә шундый аерым игътибар, аерым бер мөнәсәбәт икән! Һәм шул Собраниенең депутаты булганы өчен аны бик озак тотмыйча азат та итәләр.

Чехлар үзләре дә, Дәүләкәндә озак «кунаклап» ятмыйча, килеп кергәндәге шикелле сугышсыз-нисез генә чыгып та киттеләр. Эшелоннары белән, ахрысы, төнлә кузгалып киткәннәрдер — без малай-шалай сизмичә дә калдык. Шуннан соң артларыннан ук диярлек Бәләбәй ягыннан Дәүләкәнгә җәяүләп тә, атка атланып та, тупларын һәм обозларын ияртеп, икенче бер зур гына отряд килеп керде. Болар инде кызыллар иде. Алдан уйнап килүче оркестрлары булмаса да, сафларга тезелеп, кы-

зыл байракларын күтәреп, бөтенесе бер тавыштан җырлап, чын гаскәрләрчә төп урам буйлап уздылар. Бөтен халык урамга сибелеп чыкты. Болар инде чехлар түгел, болар инде үзебезнең шанлы Кызыл Гаскәр! Аларны шунда ук йорт саен төркем-төркем фатирларга урнаштырдылар. Безнең ишегалды да атлар белән тулды, күрше Борһан абзыйның да гел бикта торган капкасы ачылды,— кыскасы, тазарак, баерак йортларның барысына да кереп тулдылар. Дәүләкән бердән җанланып китте. Кая карама, кызыл йолдызлы, мылтыклы солдат, араларында кылыч аскан, наган такканнары да бар — боларын кызыл командир яки комиссар дип атыйлар икән. (Искечә әфисәр дип әйтү юк, тыелган, имеш.) Дәүләкәннең кызылларны әле беренче генә күрүе, шуңадыр инде бөтен яшь-җилкенчәк, бала-чага гел алар тирәсендә. Аннары бу отрядта татар, башкорт егетләре дә күп иде. Алары безнең бик тыйнак, бик әдәпле кызларыбызга да ошаган булса кирәк, чөнки соңыннан кайбер «мәхәббәт маҗаралары» да мәгълүм булды.

Шулай да, кызыллар кергәч, Дәүләкәндә нинди үзгәрешләр булганын менә хәзер мин язарга кыенсынам. Җитди нәрсәләрне күрергә, белергә артык яшь булып калганмын. Минем өчен барысы да искечә кебек иде — уйнап йөрүдән башканы белмәгән малайга! Хәзергә әле безнең Дәүләкәндә тыныч кына, андый-мондый куркыныч вакыйгалар да ишетелми, ләкин шулай да нидер көтү, борчылып, шомланыбрак тору сизелә иде. Зурларның сөйләнүенә караганда, Дәүләкәнне бер генә сугыш та читләтеп узмаячак, агы да, кызылы да тимер юл өстендәге бу зур, бай авыл өчен аяк терәп сугышачак, имеш! Һәм, чынлап та, күпмедер вакыт үтүгә, аклар Уфаны алганнар, Дәүләкәнгә якынлашып киләләр дигән хәбәр дә таралды. Инде чат саен кешеләр авызында бер генә сүз — Дәүләкән өчен каты сугыш булачак, кызылларның чигенергә һич тә исәпләре юк!.. Чын сугышны күрмәгән халыкның беришe моңа әллә ни исе дә китмәгән шикелле, әмма йорт башы өлкән агайлар шактый ук куркуга да төшкәннәр иде. Ничек кенә булмасын, якынлашып килгән сугыш берәүне дә тынычлыкта калдырмады, кайберәүләрне исә котылу чарасын күрүгә дә мәҗбүр итте. Атлы-тунлы кешеләрдән бала-чагасын төяп читтәгерәк авылларга китүчеләр дә күренә башлады. Безнең атакай белән итче Гали абзый да, үзара сөйләшеп, сугыш узганчы Дәүләкәннән читкәрәк китеп торырга булдылар.

Мин үзем бу курка-курка көтелгән сугышның кайчан килеп җиткәнен дә белмим, якында туп, мылтык

тавышлары ишетелгәнен дә хәтерләмим, ләкин көннәрдән бер көнне иртән-иртүк атакай безне тәмле йокыбыздан кабаланып торгызды да, җигелеп куйган күк айгырга утыртып, каядыр алып чыгып та китте. Йортыбызны саклап торыр өчен Зәкия тутакай белән Хәсән җизни килгәннәр икән — шулар безгә хәерле юл теләп, озатып калдылар.

Яңа Шәрип турысында Дим күперен чыккач, без Гали абзыйны куып җиттек. Ул да хатыны белән балаларын читән тарантаска төягән, үзе кучерга утырып, ашыкмыйча, безне көтә-көтә бара икән. Очрашкач, аз гына сөйләшеп алдылар да, дилбегәләрен кагып, кызу гына юрттырып та киттеләр. Атлар шәп иде. Шулай итеп, сугыштан качып барабыз. Юлыбыз Имай Карамалысына... Бу — Дәүләкәннән егерме-егерме биш чакрым чамасы ераклыкта бер татар авылы. Тимер юлдан шактый читтә булгач, аңа сугыш кагылмыйча узарга тиеш, янәсе. Һәм, чынлап та, без анда чакта сугышның җиле дә кагылмады бу авылга.

Дөресен генә әйткәндә, без Имай Карамалысында күп тә тормадык. Искә төшерерлек нәрсә бик аз: тып-тын авыл, ерак түгел нечкә генә манаралы агач мәчет, урамы киң, яшел чирәм, шул чирәмдә башларын сыртларына салып утырган каз бәбкәләре, тагын нәрсә?.. Без төшкән хуҗаның малаена ияреп, кечкенә инеш буена баруыбыз, шуннан ак каурыйлар җыеп кайтуыбыз — мондагы малайлар шул каурыйларны ничектер очыртып уйныйлар икән — менә хәтердә бераз сакланып калганы шулар гына. Хуҗабыз кем иде дә, малаеның исеме ничек иде — күптән инде онытылган. Атна-ун көн үтүгә, Дәүләкәннән сугыш узып киткәнен ишеткәч тә, без кире кайтырга да чыктык. Юлыбыз Дим буйларына таба булгач, атларыбыз җилдерә генә — хәзер инде озын үрләр менәсе юк. Бер җирдә без әле төлке дә күрдек. Атакай: «Әнә төлке, төлке!» — дип, чыбыркысы белән алга төртеп күрсәтте, аннары: «Әлелүү!» — дип бер кычкырып та җибәрде. Без энем белән очардай калкынып, ялт-йолт карана торгач, озын койрыклы, кара колаклы сап-сары җәнлекнең юл аша шым гына үтеп киткәнен күреп калдык. Ул заманда юлга чыксаң, берәр төрле җәнлек очрамыйча калмый торган иде.

Кайтсак, Дәүләкән тынган, кызыллар киткән, йортыбыз исән-сау! Монда хәзер аклар булырга тиеш. Ләкин кайда алар, бармы алар — һич белерлек түгел. Дәүләкән бик тын да, бик буш та кебек, өйләрдә дә солдатлар юк. Кайткан мәлгә әнә шундый бер сәер вакытка туры кил-

дек. Сугыш артыннан кыска гына тынлык булып ала түгелме соң?!

Миңа, тугыз яшьлек малайга, Дәүләкән аша узган каты чын сугышның берсен дә күрергә туры килмәде. Сугыш якынлашкан саен, атакай безне кая да булса читкә алып китә иде. Шул сәбәпле мин күргәннәрдән бигрәк ишеткәннәрне язарга мәҗбүрмен. Ә күрү белән ишетү арасында, үзегез беләсез, аерма бик зур.

Хәзер менә шул чактагы вакыйгалар турында сөйләүчеләрдән ишетсәм яки газета битләрендә басылган истәлекләрне укысам, исем китә — безнең Дәүләкән дә күп хәлләрне башыннан кичергән икән. Иң элек ул 1918—1919 еллар дәвамында берничә мәртәбә кулдан-кулга күчә: башта чехлар, аннан кызыллар, аннан аклар, тагын кызыллар, тагын аклар... Дәүләкән өчен сугышта отыры катырак була барган. Аклар, мәсәлән, тупларын урам уртасына куеп, һөҗүм итеп килүче кызылларга атканнар. Кара-каршы атышу нәтиҗәсендә Дәүләкән кешеләре арасыннан яраланучылар, хәтта үлүчеләр дә булган (Каһарман карт өенә тигән снарядтан безнең шәриктәш Хөсәен җиңгәсенең бер аягы өзелгән иде. Соңыннан бу чибәр хатын агач аякта йөрде).

Дәүләкәнне сугышып алган һәр як үз властен, үз законын урнаштыра. Каршы якның кешеләрен эзләү, аулау, тоту башлана. Бигрәк тә аклар кансыз кыланганнар. Әле чех фетнәчеләре Дәүләкәнне калдырып чыгар алдыннан унсигез кызыл гвардеецны атып китәләр. (Район газетасы, «Знамя», 1 май, 1960 ел.) Колчак гаскәре килгәч тә шул ук хәл — тоталар, аталар, кызыллар яклы берәүне дә аяп тормыйлар. Җирле большевикларның да бер өлеше шушы канлы сугышлар вакытында дошман кулына эләгеп һәлак була. Аларның кабере вокзал янындагы кечкенә бакчада — Дәүләкәнгә килгән һәр кеше кереп, күреп, туфракларына баш иеп чыга ала.

Билгеле инде, Дәүләкән халкының күпмедер өлеше үзе дә «ак»ка, «кызыл»га бүленә. Яшьләр арасыннан кызылларга ирекле язылучылар булган шикелле, акларга язылучылар да табыла. Рус байларыннан Самсонов һәм Антемонов малайлары акларда офицер булып йөриләр. Ә татарлардан Муллаҗан дигән бер талчукчы абзый үзенең Носрулла исемле улын көчли-көчли акларга биреп җибәрә. Шуның өстенә Дәүләкәннең күп кенә яшьләрен аклар мобилизовать итеп тә алалар. Болар арасына хезмәт иясе һәм ярлы-ябагай балалары да эләгеп китә. Җамалетдин бабайның Вәлетдине, тимерче Миңнегали картның Муллагалие, Сафа купец ялчысы Кәфи картның

Хәйретдине әнә шундыйлардан. Ләкин Муллагали абзый белән Хәйретдин абзый чигенә башлаган аклардан качып, кире кайталар. Әмма бик күпләр шул китүдән гаип тә булалар[1]. Кыскасы, безнең Дәүләкәндә вакыйгаларның төрлесе — гыйбрәтлесе дә, аянычлысы да аз булмаган ул бик катлаулы, бик киеренке хәтәр елларда...

Имай Карамалысыннан кайткач, без яңа йортыбызда тагын үзебез генә тора башладык. Безнең бит әле үз йортыбызда юньләп тора да алганыбыз юк. Ә йортка ияләшәсе, йортның кадерен белеп кенә торасыбыз килә... Инде җәй дә үтеп бара. Тиздән көз, аннары кыш, ләкин алда нәрсә булачагы билгесез. Каядыр бездән еракта сугыш дәвам итә — яңадан безгә әйләнеп килерме ул, юкмы?.. Кешеләрнең уе-кайгысы әнә шуңа юнәлгән.

Шушы вакыт эчендә без зур гына казалы да булдык. Атакай һаман да күк айгыр өчен куркып тора иде. Айгыр — шәп, күрә калсалар, һичшиксез, алып китәрләр дип, ул аны абзарда гына бикләп тора иде. Юньләп беркая җигеп тә чыкмый иде. Үзебездә торучы кызыллар, билгеле, айгырны күрделәр, өстенә сокланып та карадылар, әмма тимәделәр. Шулай да арадан берсе әйткән, ярый әле, абзый, атың икәү түгел, дигән... Аклар вакытында да атакай аны бик сакларга тырышты, ләкин барыбер саклап кала алмады. Көннәрдән бер көнне ул, күк айгырны җигеп, Әлшәй базарына барып кайтыр өчен чыгып китә. Ләкин Дәүләкәннән ерак та китәргә өлгерми, аңа акларның ниндидер бер отряды очрый. Каршыларына нечкә аякларын эре-эре ташлап, җиңел генә «очып» килгән айгырны күрү белән, солдатлар, мылтыкларын югары күтәреп, атакайны туктаталар. Бу асыл сөякне карап торасы да юк дигәндәй, шунда ук тугарырга да кушалар. Атакай тугарырга ашыкмый, нидер аңлатмакчы була, ләкин отряд башлыгы аңа җикеренеп: «Без бер сүзне ике тапкыр кабатларга яратмыйбыз, тиз бул, гражданин!» — дип кенә кычкыра. Шуннан соң атакай, чак җыламыйча, күк айгырны тугара, башыннан, ял астыннан сыйпап-сыйпап сөя, ә тегеләр шунда ук айгырны иярләп тә алалар. Буш тәртәләр янында аптырап басып торган атакайны кызганыпмы, әллә кирәге булмаганга күрәме, алар шулай да айгыр урынына сырты чиләнгән, бик өшән, бик арык бер атларын калдырып китәләр. Атакай менә шул мәхлукны тарантасына җигеп, атлатып кына өйгә кайтып керә.

Күк айгыр өчен без барыбыз да бик кайгырыштык. Гүя кеше шикелле үк бик кадерле җан иясен югалттык,

[1] *Гаип булу* — юкка чыгу.— *Ә.Е.*

йортыбызның ничектер берьюлы яме китте һәм, билгеле инде, талап алып китүчеләргә гаять ачуыбыз да килде. Күк айгыр кебек асыл сөякне безгә инде бүтән күрергә туры килмәячәк иде — без моны алдан ук белеп тордык. Аяк урынына тояк дигәндәй, атакай әлеге арык карт алашаны карарга, ашатырга, җәрәхәтен дәваларга тотынды. Һәм озакламый ул безгә бик кирәк тә булды.

Әйткәнебезчә, көз кергән иде инде, тагын сугыш якынлашып килә дигән сүзләр ишетелә башлады. Кызыллар Бәләбәй тирәсендә генә, имеш, ә Бәләбәй белән Дәүләкән арасы, күп булса, алтмыш-җитмеш чакрым чамасы булыр. Кайчан килеп җитәрләр? Бәлки, бик тиз... Ләкин аклар Дәүләкәнне бирергә җыенмыйлар, каты торачаклар, яңа көчләрен монда тарттыралар, дип сөйлиләр. Чынлап та, Дәүләкәндә кинәт солдатлар бик күбәйде, станциягә килгән ачык вагоннардан туплар да бушаттылар, аннары «нимеч ягында» лазарет ачып, шунда яралы солдатларны ташый башладылар. Күренә ки, нык хәзерләнәләр, бу тирәләрдә каты сугышлар булуы бик ихтимал икән.

Кыскасы, урман янгыны шикелле дөрләп безгә тагын сугыш килә, һәм безнекеләрнең башына тагын «нишләргә?» дигән кайгы төшә. Хәер, мондый курку һәм борчылу күпләрнең башына төшкән булса кирәк. Баерак кешеләр, сугыш килеп җиткәнне көтеп тормыйча, Дәүләкәннән киткәли дә башладылар. Безнең күрше Борһан абзый да, ишле бала-чагасын төяп, Уфага китеп барды. Аңа хәтле Шәймәрдән абзыйның да китүен әйткәннәр иде. Ә безнең атакай һаман икеләнә иде әле — йортны ташлап китү дә жәл, әмма җан дигән нәрсә дә газиз. Бигрәк тә ул безнең өчен борчыла иде шикелле... Мондый чакта төрле шомлы хәбәрләр күп тарала, кешеләр юри бер-берсен куркытудан гүя ләззәт табалар... Әмма иң куркытканы, билгеле, сугыш үзе иде. Иң элек атышкырылышлардан башны сакларга кирәк иде.

Ә көннәр уза — таң ата да кич була. Борчылып һәм өметләнеп көткән кызылларыбыз ни сәбәптер һаман әле килеп җитә алганнары юк. Сугыш кайда бара, Бәләбәйдәме, Әлшәйдәме — анысын да юньләп белгән кеше юк. Дәүләкән урамнарында хәзергә тынлык һәм тынычлык. Без әле мәктәпкә дә йөрибез, сабактан кайткач, шакырдап каткан ат юлында шар да сугабыз. Көннәр аяз тора, ләкин иртә-кичләрен бик суык була башлады, тиздән инде Дим өсте дә туңар. Бәлки, сугыш безгә тимичә читләтеп узып та китәр...

Һәм менә шундый тыныч көннәрнең салкын бер ирт-

әсендә, инәй безне хәвефле-әкрен тавыш белән генә: «Торыгыз, балалар!» — дип, тәмле йокыбыздан уятты. Үзләре күптән торганнар булса кирәк, ашаганнар-эчкәннәр, киенгәннәр, зур-зур төеннәрне дә бәйләп куйганнар, Хәсән җизни белән Зәкия тутакай да килгәннәр икән... Йокыдан айнып җитмәсәк тә, өйдәге бу күренештән, бигрәк тә зурларның җитди-киеренке кыяфәтләреннән аңлап алдык: димәк, китәбез!.. Димәк, сугыш килеп җиткән яки килеп җитәргә тора. Хәер, монысын безгә әйтеп тә тормадылар, тиз генә юынып, чәйгә утырырга куштылар. Әзерләп куйган ризыкны кабалана төшеп ашаганнан соң, безне, ягъни энем белән икебезне, таза гына итеп киендерделәр. Шул арада төеннәрне, кәрзиннәрне дә арбага чыгардылар. Аннары барыбыз да утырып, озын гына бер дога кылдык. (Минем инде бер-ике ятлаган догам да бар иде.) Шуннан соң кузгалдык, олылар соңгы теләкләрен әйттеләр, аннары барыбыз да җыйнаулашып өйдән чыктык. Ишек төбенә тарттырып куйган җигүле атка башта инәй белән безне әйбәтләп утырттылар, аннары атакай дилбегәне кулына алып, итәкләрен җыеп, иске бишмәт салган кучерга менеп утырды. Хәсән җизни капканы ачты, һәм без, атлатып кына, канау күперен дөбердәтеп йортыбыздан чыгып киттек. Дүрт ай эчендә икенче тапкыр! Юньләп торырга өлгермәгән йортыбызны шул ук җизни белән Зәкия тутакай саклап калдылар.

Бу чакларда атакайның гел аралашып, киңәшеп йөргән кешесе әлеге шул итче Гали абзый иде. (Һәрьяктан бер чамадагы кешеләр.) Күрәсең, алар бу юлы да бергә китәргә алдан ук сөйләшеп куйганнар — Дәүләкәнне чыгуга, Гали абзыйның туры аты безне куып та җитте. Тимер хутлы ящик арбасына төеннәрен салган, яшь хатыны белән өч баласын утырткан, үзе исә кучер башына менеп урнашкан. Атакай аңа алга чыгарга кушты, чөнки аты да безнең өшән алашадан шәбрәк, аннары Гали абзый юлны да яхшырак белә икән. Шулай итеп, ике атта туңгак юлдан дыңгыр-дыңгыр кояш чыгышына таба карап киттек. Ә сәфәребез бу юлы Уфаның үзенә үк икән. Ләкин ни өчен Уфага? Чөнки Уфа — зур кала, әллә ни ерак та түгел, ә зур калада сугышны хәвефсезрәк үткәреп җибәрергә дә була торгандыр... Аннары Уфада безнең якын туганнарыбыз тора бит, димәк, барып керер, сыеныр кешеләребез бар дигән сүз... Ниһаять, сугышлар үтеп киткәч (әйтик, кызыллар Уфаны алгач), безгә яңадан Дәүләкәнгә кайтуы да ансат булачак. Шулай уйлаган булырга тиеш минем атам.

Дәүләкән белән Уфа арасын туксан чакрым, диләр. Көзге салкын, шәрә, эчпошыргыч бу озын юлны ничек үтүебез бер дә ачык кына хәтердә калмаган. Көн өстендә генә барып җитә алмадык, билгеле. Шулай да бернәрсәне ачык хәтерлим: инде караңгы иңгәч, зур, калын урманга кердек. Тып-тын урман эченнән күпмедер баргач, бер бик тирән чокырга җиттек. Атларны туктаттылар. Бу чокыр юлның иң хәтәр җире икән. Шушы чокырда еш кына юлчыларны тотып талыйлар икән. Җыен карак һәм качаклар шушында, имеш. Атакай белән Гали абзый үзара шыпырт кына нидер сөйләштеләр дә арбаларга сузып бәйләгән озын күсәкләрне чишеп алдылар. (Гали абзый аю сыманрак иелә төшкән калын җилкәле эре, таза кеше — берүзе биш кешегә каршы торырлык.) Шуннан соң атларның тезгененнән тотып, тыя-тыя гына, бөтен ягын куе агачлык каплаган тирән чокырга төштеләр. Төптә тонык кына челтерәп аккан сай чишмәнең чуерташлары өстеннән шыбырдап уздылар да, инде тәҗегә тотынып, атларга булыша-булыша каршы якка мендeләр. Тирә-юньдә шылт иткән тавыш та юк, сискәндереп селкенгән ботак та юк, юлга чыккан карачкы да күренмәде — кыскасы, бик хәтәр булып тоелган бу тирән чокырны без, мең шөкер, әнә шулай исән-имин генә үтеп китә алдык. Бераздан инде урман сирәгәя башлап, ахырда ачык кырга да килеп чыктык. Кыр өсте шактый яктырак булса да, куе зәңгәр төн бихисап йолдызлары белән дөньяны каплап алган иде. Тагын күпмедер киткәч, без бер зур гына авылга барып кердек. Авыл бөтенләй үк тынып бетмәгән иде әле, этләр өргәне дә ишетелгәли, сирәк кенә тәрәзәләрдә утлар да күренә... Һәм безнең атайлар шушы авылда кунып чыгар өчен атларын кемнеңдер капкасына борып туктаттылар.

Хәзер менә уйлыйм — ул авыл Келәш булмады микән? Чөнки, Уфага җитәрәк, юл өстендә башка бер зур татар авылы барлыгын белмим һәм ишеткәнем дә юк. Утырган җире дә тигез ялан түгел иде бугай, әйләнә-тирәсендә калкулыклар, сай чокырлар бар кебек иде. Каян беләсең, бәлки, без чынлап та мәшһүр шагыйрьләр авылында кунып чыкканбыздыр. Хәер, мәшһүр шагыйрьләрнең берсе ул чакта тумаган да булган әле.

Икенче көнне караңгыдан ук торып, чәйләр эчеп, юлга чыктык. Уфа инде якын, егерме-егерме биш чакрым чамасы гына, диләр. Хәл алып өлгергән атлар җиңел юрттыралар. Күзләребез гел алда — еракта, Уфаның ачылганын тизрәк күрәсебез килә, ләкин офыкны, үч иткәндәй, авыр-салынкы ала-кола болытлар каплап алган. Аннары

берзаман юлыбыз калын урман эченә кереп китә, ике яклап сузылган куе-таза агачлар арасыннан берни күрмичә озак кына барабыз. Шулай да төш вакыты җитәрәк, без ахырда Уфа каршысына килеп чыктык. Менә ул биек тау башындагы зур кала!

Чынлап та биекме соң Уфа таулары?.. Әлбәттә, биек! Миңа, тугыз яшьлек малайга, моның кебек үзе зур, үзе биек тауны моңарчы әле күрергә туры да килгәне юк... Әнә бит аның өстендәге ак таш биналар, чиркәү гөмбәзләре, мәчет манаралары әллә кайлардан ук күренеп тора. Ә тауның битләренә, чокыр-чакырларына сырышкан агач йортлар, кош ояларыдай, әнә ничек вак кына булып күренәләр.

Ләкин каршыбызда ачылган бу күренеш каланың тау башындагы чите генә иде әле. Чын кала үзе кайдадыр эчтәрәк булырга тиеш. Без аны, чын каланы дим, Агыйдел күперен чыгып, тавына күтәрелә башлагач кына күрдек. Йомры чуерташ түшәлгән һәм сөзәк кенә югары күтәрелгән бер озын урам буйлап дыңгыр-дыңгыр әкрен генә менгән чакта гел уңга-сулга каранып бардык. Монда да йортларның күбесе агачтан, әмма матур-бай йортлар, ике катлылары да шактый, өчәр катлы таш йортлар да очрады. Бер зур бакча яныннан да уздык, бакча эчендәге галәмәт зур чиркәүне күреп, аңа да исебез китте... Бара торгач, ахырда ике катлы агач йорт каршында туктадык — монда безнең Шәриф җизниләр тора икән. Без менә шуларга килеп төштек, ә Гали абзый үзенең белгән кешеләренә китте.

Шәриф җизниләргә безнең әле беренче килүебез. Алар инде чын шәһәр кешеләре — үзләре дә, тормышлары да шәһәрчә. Безне яхшы каршы алдылар. Фатирлары шушы чибәр генә йортның икенче катында. Иркен генә зал, берничә бүлмә, зур гына балконнары да бар — аңа залдан пыялалы ишек чыга. Монда җизни, Срур тутакай, аларның бер яшьлек балалары һәм янә җизнинең әнисе — куе кара кашлы, озын-чандыр гына карчык — Һаҗәр әби белән Сәгыйть абзыйның (Сәгыйть Сүнчәләйнең) миннән кечерәк Таһир исемле улы да тора иде. Һаҗәр әби нәкъ җизни төсле икән. (Дөресрәге, әлбәттә, җизни әнисенә бик охшаган.) Карчыкның кыяфәте генә түгел, тавышы да, сөйләшүе дә улларын бик нык хәтерләтә иде. Сәгыйть абзый бу вакытта кайда булгандыр, белмим, ләкин без аны монда күрмәдек. Улы Таһир авыру бала — йөзе күксел, үзе үтә ябык иде. Әмма акыллы, әдәпле бала булгандыр инде, бер дә ятсынып тормыйча безгә якынлашты, самими бер гадилек белән бөтен булган нәрсәләрен күрсәтергә

тотынды. Авыру сәбәпле мәктәпкә йөрмәсә дә, ул инде укый да, яза да белә, рәсем дә ясый белә, өстәвенә мине шашка дигән уенга да өйрәтте. Алгарак күчеп әйтәсем килә: зур үкенечкә каршы, Таһир гомерсез булды, унике-унөч яшенә җиткәндә ул үлеп тә китте. Әтисе Сәгыйть абзый аның үлемен бик авыр кичергән булырга тиеш. Егерменче елларның уртасында улы хатирәсенә «Әбү Таһир» имзасы белән ул башкорт телендә берничә кечкенә китап та бастырып чыгарды. Шулай ук ул соңыннан Әминә Милюшевадан туган кызына да «Таһирә» дип исем куштырган иде. Әмма, ни үкенеч, аның бу кызы да гомерсез булды, бик авыр шартларда үсеп, туташ булып җиткәч кенә дөньядан китеп барды[1].

...Шушында торган чакта миңа тагын бер шагыйрьнең улы белән танышырга туры килде. Бу Мәҗит Гафури малае Әнвәр иде. Минем чамада булыр, шактый тере, сүзгә дә юмарт малай иде. Ул чагында Гафурилар шул ук урамда, җизниләргә каршырак бер катлы сары йортта торалар иде. Әнвәр белән ничек танышып китүемне ачык кына хәтерләмим, өйләрендә булмадым, бәлки, Әнвәр үзе Таһир янына кергәндер дә шунда танышып киткәнбездер. Ничек кенә булмасын, мин, Әнвәргә ияреп, Уфа тавының якын-тирәдәге чокыр-чакыр буйларында бераз йөреп килгән идем. Ләкин безнең бу танышлык озакка бармады, җизниләрдән икенче фатирга күчеп киткәч өзелде һәм яңадан инде беркайчан да ялганып китмәде.

...Кунак булып яту күңелле, әмма торыр өчен үз куышың булырга тиеш. Шуңа күрә тиздән, туганнар ярдәме белән фатир табып, шунда күчеп киттек. Күченеп барган урамыбыз җизниләрдән шактый еракта, Спасская дип атала иде. (Хәзер Новая Мостовая урамы.) Аулак кына, тыныч кына, яшеллеккә дә бай гына бер урам. Уфаның башка урамнары белән чагыштырганда артык озын да түгел һәм, урамыбызга аеруча бер ямь биреп, аның бер башында ак чиркәү, икенче башында ак мәчет күренеп тора иде. Ләкин чиркәү үзе — Большая Казанскаяда, ә мөфти мәчете — Тукай урамында — безнең урам исә ике очы белән нәкъ әнә шул ике гайбадәтханә каршысына барып чыга иде. (Большая Казанская ул хәзерге Октябрьская революция урамы, тик анда мин әйткән мәһабәт ак чиркәү генә юк хәзер.)

---

[1] *Әминә Милюшева* — актриса, егерменче елларның ахырында безнең театрда да уйнап китте. С.Сүнчәләй аклангач, Әминә ханым аның Соловкидан язган хатларын миңа җибәргән иде. Бу хатлар хәзер Риза Ишморат кулында. Әминә Милюшева — Кировабад шәһәрендә вафат.— *Ә.Е.*

Без күчкән йорт та чиркәүгә якын гына иде. Такта белән тышлаган күк йорт, асты таш, өске катының зур гына балконлы чардагы да бар. Бай-таза тормышлы кешенең йорты булгандыр, ахрысы — ишегалдындагы бүрәнәдән салган, калай белән япкан каретнигы да, ак мунчасы да шуны әйтеп тора сыман. Бу күк йорт хәзер дә әле исән-сау, Уфага кайткан саен мин аның янынан карап узмыйча китмим. Кайчандыр ачык, якты, матур гына йортны, кызганыч, бозганнар. Урамга караган тәрәзәләрнең берсен ишеккә әйләндереп, гади такталардан ямьсез генә болдыр ясап куйганнар.

Йортның хуҗасы ул заманда Уфа морзасы Сәлимгәрәй Җантурин булган икән, ләкин мин моны бары соңгы елларда гына, күп сораша торгач, белә алдым. (Егерменче елларның башында йорт аның кызы Сара исемендә булган.) Җантурин үзе җәмәгать хадиме һәм Дума члены — татар дөньясында билгеле кеше. Сәйфи ага Кудашның әйтүенә караганда, «Галия» мәдрәсәсен салдыруда һәм асрап тотуда күп көч куйган кешеләрнең берсе. Шулай ук ул китап бастыру эше белән дә шөгыльләнгән. Аның «Лөгать» исеме белән басып чыгарган гарәпчә-татарча сүзлеге минем кул очымда саклана — кулланыр өчен бик уңай төзелгән китап.

Җантурин җир-су биләүче алпавыт булса да (имениеләре Килем авылында иде), революциядән соң эмиграциягә чыгып китмәгән. Егерменче елларның башында Казанга килеп, Дәүләт банкысында гади хезмәткәр булып эшләгән... Әмма гомере фаҗигале рәвештә өзелә: көзге караңгы төннәрнең берсендә каяндыр кайтып килешли су тулы казылмалы чокырга төшеп һәлак була. Әнә шулай... Тәкъдир димичә, ни дисең?!

Бездә әле үзебезнең энциклопедиябез булмагач, тарихыбыздагы азмы-күпме билгеле шәхесләр әкренләп онытыла һәм югала бара. Сәлимгәрәй Җантурин турындагы ишеткән-белгәннәремне шуның өчен кыскача гына язарга да булдым.

...Яхшы хәтерлим, без килеп кергәндә, бу йорт буш иде. Барлык бүлмәләрендә җиһазлары тора, ә хуҗалары юк. Димәк, яңарак чыгып киткәннәр булырга тиеш — билгеле, сугыш аркасындадыр инде. Хәзер уйлыйм, бәлки әле хуҗалар үзләре үк йортларын бөтен җиһазлары белән безнекеләргә вакытлыча тапшырганнардыр — югыйсә башкача без бу яхшы йортка ничек килеп керер идек?! (Әлбәттә, минем атамны яхшы белгән берәр кешенең тәкъдиме аркасында гына булгандыр инде мондый ышаныч казану.)

Кыскасы, унсигезенче елның хәвефле кара көзендә кемнеңдер ашыгыч калдырып киткән йортында без әнә шулай хуҗа сыман тора башладык. Йорт иркен, бүлмәләр зур, җиһазлар шәп — барсы да затлы таза агачтан. Монда чибәр туташлар да торган булырга тиеш — зур көзгеле кием шкафларында алардан ниндидер вак-төяк киемсалым, төрле чүпрәк-чапрак, ефәк тасмалар, нәфис челтәрләр, матур-матур тартмалар, кечкенә ислемай шешәләре дә торып калган иде. Ниндидер ят, әмма матур бер тормышның ватыклары булып күренә иде безгә бу аз гына хуш ис аңкыткан нәфис вак әйберләр.

Билгеле, мондый йортны үзебез генә биләп, барсын да саклап тору читен булгандыр инде, озакламый ике янәшә зуррак бүлмәгә итче Гали абзый да бала-чагалары белән килеп керде. (Ә без зур зал белән кечерәк бер бүлмәдә калдык.) Шулай итеп, ике семья бергә килгән иде, бергә тора да башладык.

Ләкин бу йортның тагын бер күз-колак булып торучысы бар иде. Ул — дворник Хәйретдин абзый. Кара сакаллы, караңгы чырайлы, авызыннан сүзе чыкмас бер кеше, әмма йорт-җирне гүя үзенекедәй бик уяу саклый, капкадан чит кешене түгел, ят этне дә кертми, һәр көнне иртә таңнан ишегалдын, урам якны кыштыр-кыштыр себереп, җыештырып кына тора, хәтта безнең кебек вак малайларга да ихатада иркенләп уйнарга ирек бирми иде. Аны хуҗаларына бик бирелгән, бик тугрылыклы кеше, тизрәк шуларның әйләнеп кайтуын гына көтеп тора, дип әйтәләр иде. Мөгаен, ул ниндидер Нигъмәтҗан, итче Гали кебек билгесез вак сатучыларның Дәүләкән шикелле базарлы саладан килеп, Уфаның атаклы кешеләре йортына хуҗа сыман кереп утыруларын бер дә яратмагандыр — моны аның бөтен кырыс-караңгы кыяфәтеннән ничектер сизеп тә була иде.

Бу абзыйның тәбәнәк, тулы гына хатыны (исеме онытылган) һәм Маһинур исемле бик чибәр җиткән кызы да бар иде. Алар таштан салынган аскы катның ишегалдына караган башында торалар иде. Сугышлар беткәч тә, йорт дәүләт кулына күчкәч тә, Хәйретдин абзый шул подвалыннан чыкмаган — гүя ул һаман хуҗасын көткән! Соңыннан шуны ишетеп мин дә бик гаҗәпләнгән идем.

...Ә без чардаклы күк йортта тыныч кына торып ятабыз. Кышка да кердек: урамнарны, йорт түбәләрен апак, йомшак кар каплады (ул чакларда Уфа карлары бик чиста була торган иде). Ләкин безне урамга чыгармыйлар, хәвефле вакыт, диләр. Чыксак та, капка төбеннән ерак китмибез, шәһәр белән таныш түгелбез, урамнарын

белмибез, китсәк, адашырбыз дип тә куркабыз... Минем бит әле мәктәпкә дә йөри торган чагым. Укуны бер дә калдырасым килмәгән иде. Җизниләрдән күчмәс борын мине Сабир хәзрәт мәдрәсәсенә илтеп тә биргәннәр иде, ләкин бирегә күчкәч, ара бик ерагайды (бөтен шәһәр аша барырга кирәк), өстәвенә суыклар да башланды, шулай итеп, укырга йөрүдән туктарга туры килде. Хәзергә исә без «дөньяны» күбрәк тәрәзәдән генә күзәтәбез. Сугышның әле килеп җиткәне юк. Шомланыбрак булса да, без аны бик кызыксынып көтәбез, чын сугышны якыннанрак күреп, һич югы, тавышын ишетеп каласыбыз килә, тик зурлар гына бик хәвефләнеп, көн дә догаларын укып, аның бәла-казасыз тизрәк үтеп китүен теләп торалар.

Һәм менә яңа (1919) елның нәкъ беренче көнендә Уфага кызыллар кергәнен ишеттек. Бәй, кай арада, ничек болай ансат кына? Без бит бернинди атыш тавышлары да, «ура» тавышлары да ишетмәдек. Баксаң, алар кичә үк кергәннәр икән. Аклар сугышмыйча гына сыздылар микәнни?! Зурларның тыеп маташуларына карамастан, тизрәк киенешеп урамга чыктык. Ә урам буш, урам тыптын, бернинди «кызыл» солдат та күренми... Тик бераздан гына кайдадыр шәһәр үзәгендә тынлы оркестрның дәртле генә уйнаган тавышын ишеттек тә Большая Казанская буйлап шул якка таба бер төркем атлы солдатларның тупыр-тупыр чаптырып узганнарын күреп калдык. Әһә, әнә кайда икән ул тамаша!.. Әгәр без әз генә зуррак булсак, атакайлардан куркып тормасак, ике дә уйламыйча, тизрәк шул тарафка чапкан булыр идек... Юк, бер дә әйбәт түгел икән мондый «кызык» чакларда бәләкәй булып калуы... Күпме нәрсәне күрмәдек һәм белмәдек без.

Уфада кызыллар... Бу зур вакыйга булырга тиеш. Аны без дә әзрәк сизәбез. Кышның үзәге, каты суыклар башлануга карамастан, урамнарда кешеләр бик күбәйде. Бик ашыгып, бик эшлекле кыяфәттә йөриләр... Аклар вакытында каядыр югалып торган безнең Шәриф җизни дә өенә кайткан. Ләкин Срур тутакайның әйтүенә караганда, аны без түгел, үзләре дә юньләп күрә алмыйлар икән. Эшләре гаять күп, көне буе митингларда йөреп, төннәрен редакцияләрдә уздыралар, ди. Ә безнең өчен тормыш һаман искечә кебек, безнең тирәдә хәзергә бернинди дә үзгәреш юк.

Ләкин шулай да бер вакыйга минем хәтердә саклана, чөнки ул вакыйга нәкъ менә без торган йортта булды. Кызыллар кереп, күпмедер вакыт узгач, дворник Хәйретдин абзыйның әлеге чибәр кызын — Маһинур апаны бер

гаскәригә кияүгә бирделәр. Кияү тиешле абый түгәрәк ак битле, зур соры күзле, көләч, сөйкемле генә бер егет иде. Кызылларда гади солдат белән командирны аеруы ансат түгел, бу егет тә гади солдат кынамы, әллә берәр командир-мазар идеме, ачык кына белмәдек. Әмма туена, аскан коралларына һәм тотыш-кыланышларына карaганда, шактый зур кешеләр җыелган иде. Тагын истә шунсы калган: егетне бик шәп итекче, диделәр. Командирларга иң әгълә итекләрне ул гына тегә, имеш. Ләкин шуның өчен генә бирегә зур кешеләр җыелмагандыр инде. Егет үзе бәләкәйләрдән түгелдер, ахрысы...

Ә туен безнең буш торган зур залда үткәрделәр. Ашауэчү дә вакытына күрә ярыйсы гына иде шикелле — кияү үзе тапкан, үзе китергән, дип әйттеләр. Минем инәй туй ашларын әзерләшкән иде шул чакта. Бу чын мәгънәсендә хәрбиләр туе иде. Зал тулы гаскәриләр, һәммәсе дә бер чамадагы какча ирләр, араларында берничә генә хатынкыз, ләкин алары да хәрби киемнән. Тик Маһинур апа үзе дә, булышырга килгән бер-ике ахирәте генә бу тоташ сорылар арасында ак күгәрченнәрдәй аерылып тора иде. Әмма шундый бер генә төрле кунаклар җыелуга карамастан, мәҗлес бик җанлы узды. Күрәсең, мондый туй мәҗлесен бик сагынганнардыр инде, саратский гармунны өзелгәнче уйнатып, тәмам биһуш булганчы җырладылар, биеделәр, ара-тирә ялкынлы нотыклар да әйттеләр. Тик шунысы гаҗәп: кыз ягыннан бу мәҗлестә хуҗа тиешле кеше юк иде. Кызның атасы Хәйретдин абзый туйның башында да, ахырында да бөтенләй күзгә дә күренмәде. Чакырып карасалар да, менмәгән, кулын гына селтәгән, имеш! Нигә мондый тискәрелек, сәбәп нәрсәдә?.. Ул, янәсе, башта никах укытуны таләп иткән булган, ә кияү буласы егет, хәзер аның кирәге юк, бик теләсәгез, миннән башка гына укытырсыз, дип әйткән, имеш. Бәлки, бүтән сәбәпләр дә булгандыр, ләкин туй әнә шулай кызның атасыннан башка гына дәвам итте. Хәер, аңа карап кына мәҗлес бер дә сүрелеп, тукталып тормады. Шул ук хәрбиләрдән постау френч кигән кара мыеклы берәү, ике якның да ага тиешле кешеседәй, озын өстәлнең түр башында аягүрә торып, мәҗлесне бик матур алып барды. Дәрәҗәсе белән дә өстенрәк булгандыр инде, чөнки ул боера, ул куша, котлау сүзләрен дә күбрәк ул әйтә иде. Аның кушуы буенча кызның әнисен дә чакырып керттеләр — ак батист яулыгын йөзен яшерә төшеп бәйләгән йомры-тулы гына абыстайны иң түргә уздырып, кунаклар берәм-берәм каршысына чыгып, бик түбәнчелек белән аңа ниндидер җылы мактау сүзләре

әйттеләр. Абыстай, яулык чите белән яшьләрен сөрткәләп, аларны тыңлагач, әкрен генә рәхмәтен әйтеп, шунда ук кире чыгып та китте. Югалыбрак калган кыяфәтенә карaганда ул шатланырга да, кайгырырга да белмәгән бер хәлдә иде шикелле...

Без туйның бары тышкы, шау-шулы ягын гына күрдек, эчендәге хәлләрне, туйга кадәр һәм туйдан соңниләр булганын белми дә калдык. Бер төркем хәрбиләр бер кич шаулап утырдылар да таралдылар, ә икенче көнне егет Мәһинур апаны каядыр алып та китте. Һич көтмәгәндә, уйламаганда!.. Сугыш вакыты бит әле, җитмәсә!.. (Хәер, сугыш дип тормаганнар, җае чыкса өйләнешә биргәннәр.) Ләкин шулай да соңыннан, күп еллар узгач инде, төш шикелле генә булып калган бу сәер туйны искә төшергән чакларда мине, нигәдер борчып, һаман бернәрсә уйландыра иде: кем булды соң ул егет, кая алып китте икән чибәр кызны, өйләнешүенең ахыры ни булып бетте икән?..

Әлбәттә, егет командирларга итек тегүче гади солдат кына булмагандыр инде. Булса, бәлки, элек итекче булгандыр, әмма хәзер ул ниндидер зур гына хәрби урын биләп торучы булырга тиеш иде. Моны аның үз-үзенә нык ышанган тәвәккәл кыяфәте дә, хөр сөйләшүе, иркен хәрәкәтләре дә, хәтта өстендәге кием-каешлары да күрсәтеп тора иде. Кунакларының да бит күбесе командирлар да комиссарлар иде, димәк, ул үзе дә шулар дәрәҗәсендәге кеше булгандыр инде.

Аннары Мәһинур туташ, ай-һай, гади солдатка гына чыгар идеме икән? Ул бит ни җитте генә кыз түгел иде. Күзгә бәрелеп торган бер сылу, матур иде. Шәһәрдә үскән, һичшиксез, мәктәп күргән, ниндидер матур гадәтләрне дә отып алган — үзен бик мөлаем тота да белә, каушамый-кызармыйча сөйләшә дә белә. Туйда да бит аңа һәммәсе, бөгелә биреп, «туташ» кына дип дәштеләр. Юк, Мәһинур туташ кемгә чыгуын бик яхшы белеп чыккан булырга тиеш.

Кызыллар ул чагында Уфаны кулларында озак тота алмадылар, ташлап чыгарга мәҗбүр булдылар. Шәһәрдә тагын аклар... Дөрес, озакка түгел, берничә айдан кызыллар аларны яңадан сөреп чыгардылар. Бу юлы инде бөтенләйгә!.. Мәһинур апа кияве белән Уфага кире кайттылармы, юкмы — белмим. Һәрхәлдә, безнең тирәдә күренмәделәр.

Ә монда Хәйретдин абзый юаш-сабыр карчыгы белән икәү генә үзенең шул ярым подвалында торып ята. Киндер алъяпкычын бәйләгән, себеркесе-көрәге кулында, һәр көн караңгыдан торып, кыштыр-кыштыр урам себерә,

ишегалларын көри. Гүя дөньяда яшәүнең мәгънәсен дә ул бары шул ялгызак эшеннән генә таба иде.

Аклар Уфаны соңгы тапкыр, ялгышмасам, мартның урталарында алдылар. Кояшлы көннәр иде, челтәрләнеп, уалып карлар эри, түбәләрдән шабырдап тамчылар коела. Менә шундый көннәрнең берсендә, иртән торсак, кызыллар чигенгән, шәһәргә аклар кереп тулган. Бу юлы да чын сугышны күрмәдек, төнлә шәһәрнең төрле җирендә булгалап алган атыш тавышларын да язгы тирән рәхәт йокы аркасында ишетми калганбыз. Шулай да бу атышларның бер корбанын безгә күрергә туры килде. Урамга чыксак, бездән ерак та түгел, урам уртасында карга йөзтүбән капланып бер кеше ята. Барып карадык. Өстендә бер кат эчке күлмәк тә зәңгәр галифе, итекләрен салдырып алганнар, ак чолгаулары гына торып калган. Яланбаш, куе бөдрә чәчләре кан белән укмашып каткан. Башына атканнар... Мин күз генә салдым да тизрәк кире чаптым. Кем булгандыр инде ул, ләкин гади солдат кына булмаска тиеш. Кызылларның шәһәрдән китеп өлгермәгән берәр зуррак кешесе булмады микән?..

Әнә шулай, кешене ансат кына үтереп ташлаганнар. Мине бу куркытты — үтерүнең җиңел, гади генә булуы куркытты. Менә сиңа чын сугыш!.. Ә безнең бит гел шуны күрәсебез килә иде моңарчы, әмма ак карда канга батып, күлмәкчән генә яткан матур кеше мәете кинәт мине айнытып җибәргәндәй итте. Чынлап та, сугышның бөтен эше кеше үтерү ләбаса! Ходаем, ничек итеп соң мондый ерткычлык белән килешмәк кирәк?! Беренче мәртәбә әнә шундый тетрәнү кичердем мин ул көнне...

Кызыллар китеп, күпмедер вакыт узгач, безнең буш яткан зур залга бер татар офицеры кереп урнашты. Озын буйлы, киң җилкәле, мәһабәт бер кеше иде ул. Өсте-башы өр-яңадан, аягында йомшак хром итекләр, иңендә көмеш погоннар... Аны Сәлимгәрәй морза Җантурин улы, диделәр.

Безнең әфисәрләр турында яхшы сүз ишеткәнебез юк иде. Шуңа күрәдер инде бу татар әфисәре бездә ирексездән курку катыш зур кызыксыну уятты. Ниндирәк кеше ул — усалмы, явызмы, әллә андый түгелме? Инәй көн дә аңа поднос белән чәй кертә. Шул чакта без энем белән инәйгә ияреп барабыз да, залга кермичә, ишек төбендә торып калабыз. Безне анда кертмиләр, ишек ачылган чакта гына без мәһабәт-көяз әфисәрне күреп калабыз. Гомумән, аңа беркем дә кереп йөрми, хәтта үзе кебек әфисәрләр дә аның янына килми иде бугай — ничектер хәтердә калмаган. Ә без, ике малай, һаман ишек

төбендә чуалабыз, кайчагында кыюланып йозак тишегеннән дә карыйбыз. Һәм гаҗәпләнәбез: ни өчен бу әфисәр абый, кулларын артка куеп, залның бер башыннан икенче башына гел йөреп кенә тора. Ничә карама шулай — авыр уе бар төсле башын иеп, йомшак хром итекләре белән тавышсыз гына басып йөри дә йөри... Бәлки, шуңа күрә аның янына керергә дә ярамагандыр... Ул үзе дә бит бик сирәк кенә чыгып китә торган иде. Инәйгә ул абыстай дип дәшкән, чәй керткән саен рәхмәтен әйтеп калган, ләкин без бер генә тапкыр да аның берәү белән дә сөйләшкәнен ишетмәдек.

Бездә күпме торганын һәм кайчан чыгып киткәнен дә хәзер инде әйтә алмыйм. Кызыллар тәмам якынлашкач кына киткәндер, мөгаен, ләкин без белми дә калдык. Әйтерсең ай күрде, кояш алды бу бик сәер әфисәр абыйны!..

...Инде җәйгә дә кердек. Урамдагы юкәләр, чокыр буендагы карт тирәкләр ямь-яшел яфракта. Алма бакчалары бер атна буена, ак күбеккә күмелгәндәй, чак кына бал исе аңкытып, күпереп утырдылар. Койма буйлары, канау читләре яшь үләнгә күмелде, юлдагы таш араларыннан да төртеп чыкты — ул чакта безнең урамда асфальт дигән нәрсә юк иде. Без инде көне буе тышта, урамда, чокыр буйларында йөрибез, кайчагында, чит малайлардан куркып тормыйча, Спасский урамының аргы башына, Мөфти мәчете каршысына ук барып чыгабыз. Мәчет үзе иркен ихата эчендә, ә урам буйлап аның яшел калай түбәле озын таш коймасы сузылган. Бик матур шактый киң урам, нәкъ уртасыннан тар гына бакчалар тезелеп киткән. Менә шуларның берсеннән икенчесенә әйләнмәле капкаларын үтеп бара торгач, Агыйделнең текә яры өстендәге үзенең чокыр-чакырлары, борылмалы юллары, биек агачлары һәм куе куаклары белән гаҗәп кызыклы, күңелле, ямьле икенче бер зур гына бакчага барып керәсең... Бу бакчаны ул чакта Случевский бакчасы дип йөртәләр иде, ә аңа илтә торган киң урамны шул заманда ук инде Тукай урамы дип атыйлар иде. (Хәтеремдә шулай саклана.) Аннары безнең үзебездән ерак та түгел тагын бер бакча булган әле — без җәйгә чыккач кына аны «таптык». Бу — хәзерге Луначарский бакчасы... Карт бакча булса кирәк, ул чагында ук инде агачлары юан, биек, очлары бер-берсенә тоташып, бөтен җирне күләгәләп тора иде. Аның бер коймасы безнең урамга да карый, без шуның тактасы каерылган җиреннән кереп йөри идек. Кышны сукыр тычкан шикелле йорт тирәсеннән ерак китмичә үткәргәнгә күрә, безнең хәзер җәйге хөрлектән файдаланып күбрәк йөрисебез дә, күбрәк

күрәсебез дә килә иде. Мәсәлән, «синтральный» урамны! Әле Дәүләкәндә чакта ук минем: «Уфа диләр, Уфа диләр — Уфаны күрсәң иде, «Синтральный» урамында подручка йөрсәң иде!» — дип җырлаганны да ишеткәнем бар иде. Баксаң, ул «Синтральный» бездән ерак та түгел икән. Большой Казанский буйлап берничә чат киткәч тә, нәкъ уртасына барып чыгасың. Нәрсә күрдек без анда? Зур-зур таш йортлар күрдек, урам уртасыннан шак та шок чаптырып узган извозчикларны күрдек, аннары бик әкәмәт киенгән хатын-кызларны һәм көмеш погонлы бик көяз әфисәрләрне күрдек. Мәгәр безнең эше малай-шалай бөтенләй юк диярлек — күрәсең, иртәрәк әле безгә «синтральный» урамнарда йөрергә.

Әнә шулай зур кала белән чынлап таныша башлагач кына, тагын «шомлы» хәбәр таралды: кызыллар, имеш, Уфага якынлашып киләләр! Бик яман киләләр, ди, Дәүләкәнне алганнар, инде Чишмәгә җиткәннәр, имеш!.. Бу юлы да акларның гомере кыска булып чыкты, март урталарында кергәннәр иде, ә хәзер июнь башлары — димәк, өч ай да торырга өлгермәгәннәр. Сугышның якынлашуын бик тиз сизә дә башладык. Шәһәрдә ыгы-зыгы көчәйде, солдатлар күбәйде, кичләрен урамнарга чыгып йөрүләр бетте (катгый рәвештә тыелган дип әйттеләр), ә бер ике-өч көннән кайдадыр еракта тонык кына күк күкрәгәндәй туп тавышлары да ишетелә башлады. Ул да булмый, калага яралы солдатларны да ташый башладылар. Большой Казанскийдагы өч катлы зур гына таш йортка аяклары, куллары, башлары ак марля белән чорналган, күбесенең каннары да саркып торган яралыларны арбалардан бушатканнарын мин үзем дә күреп тордым.

Кызыллар Уфага бик тиз килеп җиттеләр. Июньнең беренче атнасы булды микән — бик матур кояшлы озын көннәр иде, җылы, җилсез, йомшак төннәр, шәһәр бакчаларында сандугачлар да чут-чут сайрый иде әле — менә шул чакта Агыйдел ягыннан туп тавышлары гына түгел, кабаланып такылдаган пулемет тавышлары да ишетелә башлады. Димәк, сугыш якын, сугыш каядыр Агыйдел буенда гына!.. Көндез үк Срур тутакай, Һаҗәр әби, кечкенә Равилне күтәреп, авыру Таһирны җитәкләп, безгә килделәр. (Җизни үзе юк, аклар кергәч, каядыр яшеренгән.) Алар зират тавына якын гына торалар, түбәндә Агыйдел күпере, кызыллар шуннан киләләр, шәһәргә дә шуннан торып аталар — бик куркыныч икән анда. Ә без шәһәр эчендә, еракта, аннары без торган йортның бик таза подвалы бар — билгеле, монда хәвефсезрәк... Кичкә таба мендәр, юрганнар күтәреп барыбыз да шунда төштек.

Шәһәр өстенә ату көчәйде, кайдадыр гөрселди, ухылдый, «шап» иттереп тә куя — без «ләхәүлә»не укып, тыңлап кына ятабыз. Төн буе дәвам итте бу мәхшәр!.. Безнең тирәгә снаряд төшеп шартлаганын сизмәдек, әмма шәһәрне тетрәткән бер көчле шартлау котыбызны алды алуын... Нәрсә булды, нидер ишелеп төштеме, әллә күккә очтымы? — аптырадык, тик соңыннан гына акларның Агыйдел күперен шартлатканын белдек.

Без, ваклар, атышларның кайчан туктаганын белми дә калдык — төеннәр өстендә йоклап киткәнбез. Иртән торсак, дөнья тынган, кояш күтәрелгән, зурлар күптән аяк өстендә, мәш килеп нидер эшләп йөриләр... Аклар чыгып киткәнме, кызыллар кергәнме — белүче юк. Зал якка табын әзерләгәннәр, һәммәсе бергә чәй эчәргә җыеналар. Сугыш әз генә тындымы, кеше үзенең гадәттәге эшенә тотына икән. Мин моны соңыннан, Ватан сугышы вакытында күреп тә гаҗәпләнгән идем. Әйтик, немецлар берәр станция тирәсен бик каты бомбага тотып китәләр, йортлар җимерелә, яралanучылар, үлүчеләр дә була, ә тере-исән калганнар аз гына исләрен җыйгач та үзләренең көндәлек эшләренә тотыналар — мичен яга, ашын пешерә, керен юа, дуңгызын, тавыкларын карый... Әнә шулай кеше дигәнең, үлем-һәлакәт дип тормый — һаман да яшәвен белә!

Мәгълүм булганча, Уфаны легендар Чапай дивизиясе азат итә, шәһәргә дә беренче булып Чапай дивизиясе керә. Ләкин кайсы числода, кай вакытта? Мин моны бары хәзер генә язма чыганакларга (мәсәлән, Уфа тарихы дигән китапка) карап ачыкладым: Чапай дивизиясе Уфага 1919 елның 9 июнендә, кичке сәгать сигездә кергән! Ә без моны бары икенче көнне генә белдек — икенче көнне инде шәһәр терелгән, халык урамнарга сибелгән, йортларга кызыл флаглар эленгән иде. Бу инде якты, кояшлы чын бәйрәм көне иде!

Уфаны aклардан азат итү әнә шулай шактый тиз тәгәлләнде, сугыш каядыр Урал эченә таба китте. Без дә, ниһаять, тынычландык дияргә дә ярый. Хәзер инде сугыш якынлашкан саен, башны саклар өчен анда-монда китеп йөрергә туры килмәс, Алла боерса! Кызыллар ягында бөтенләйгә торып калдык булса кирәк — шулай сизә күңел! Бик әйбәт, хәзер тотарга да Дәүләкәнебезгә кайтып китәргә!..

Ләкин без тиз генә кайтып китә алмадык. Сәбәбе — атыбыз юк, безнең яктан атта килүчеләр дә юк, ә поезд белән кайтырга тимер юл күпере ватык... Шулай итеп, җәйне ирексездән Уфада үткәрергә туры килде. Торуы-

быз һаман шул ук күк йортта, тик без аның икенче катыннан югарыдагы иркен чардагына күчтек. Бу чардакта, безнең шикелле үк, башын саклар өчен Бөредән килгән Мостафа исемле кеше бала-чагалары белән тора иде — менә шулар Уфа тирәсендә сугыш беткәч тә, үзләренең шәһәрләренә кайтып киттеләр. Шулай ук икенче катның янәшә ике бүлмәсендә торучы Гали абзый да гаиләсе белән башка фатирга чыгып китте. Зур йорт берьюлы бушап калды. Түбәндә, подвалда, дворник Хәйретдин абзый, югарыдагы чардакта без, ә менә уртадагы бушап калган зал белән бүлмәләргә кемнәр кергәндер — һич кенә дә хәтерли алмыйм. Тик бер генә нәрсәне беләм: бу йортта энем белән миннән башка бүтән бала-чага калмады.

Ә уйнарга малайлар кирәк. Җәйнең иң матур айлары, көннәр дилбегәдәй озын, вакытны кая куеп бетерерлек түгел. Күрше тирәдә дә безгә тиң татар малайлары күренми — нишләргә, кайдан табарга?!

Кайчагында, ара ерак булса да, Таһирны күрергә дип җизниләргә баргалый идек. Безне монда бик әйбәт каршы алалар, бигрәк тә Таһир янына килүебез өчен куаналар, чөнки ул, бичара, авыру бала, урамга чыгып йөрерлек хәле юк, гел диярлек өйдә генә утыра. Җизнинең әнисе Һаҗәр әби дә бәрхеттәй йомшак тавышы белән: «Менә, Таһирымның дуслары килгән, рәхмәт төшкерләре, әйдә узыгыз, уз, сүэклеләрем!» — дип каршы ала иде.

Таһирның уенчыклары да, китаплары да күп. Без аларның иркен балконнарына чыгып, шуның чиста идәнендә рәсемле китаплар актарабыз, шашка да уйнап алабыз, эре шакмаклардан биек йортлар да өябез. Таһир бик юмарт малай иде, теләсә нәрсәсен үзе үк безгә көчләп бирергә тырыша иде. Билгеле, аның безне бер дә җибәрәсе килми, ә без, таза малайлар, безне урам тарта, урамга чыгып, Идел тавының чокыр буйларында йөрисебез килә. Таһирның хәтерен саклап һәм Һаҗәр әбидән дә уңайсызланып, түзә алган кадәр утыргач, без шулай да кузгалабыз. Нигә болай бик тиз дип гаҗәпләнәләр Һаҗәр әби дә, Срур тутакай да, ләкин барыбер безне чәй эчермичә җибәрмиләр. Ә Таһир боек, бер сүз дә әйтми, гүя үз хәлен аңлый, без чыгып киткәндә, әбисенә тотынып, ишек төбендә басып кала. Бәлки, соңыннан әкрен генә җылый да торгандыр... Менә хәзер искә төшкәндә үкенү хисе бәгырьне сыкратып куя: ник без, ике юньсез, Таһир мәрхүмне шулай нәүмиз калдырып киттек икән?!

Уфада электән үк торучы Каргалы халкы күп, шулар арасында безгә бик якын туганнар да бар. Аларның берсе — Мортаза җизниләр, икенчесе — Ибраһим абзый-

лар. Дәүләкәннән килгәч, без һәркайсында кунакта булган идек, ләкин кышкы айларда барып йөрергә туры килмәгән иде. Ә хәзер, җәйгә чыккач, һәм сугыш куркынычы да үтеп киткәч, без, ике малай, аларны да искә төшердек.

Мортаза җизниләр Иске Уфада торалар, җитеп килгән ике кызлары бар (Рәкыя апа белән Суфия), тик малайлары гына юк. Шулай да без, ара ерак булуга карамастан, берме, икеме тапкыр аларга да бардык. Әйтергә кирәк, безнең халык бала җанлы, төче тел белән сөеп (безнеңчә сүэп) каршы ала, янәшә утыртып сыйлый, сораша, мактый, ә озатканда үгет-нәсихәтен дә әйтеп кала. Әле ялгыз гына җибәрмиләр дә — кечерәге Суфия апа безне җитәкләп дигәндәй өебезгә чаклы китереп тә куя иде.

Икенче якын кардәшебез Ибраһим абзыйлар бездән ерак та тормыйлар иде. Әнә безнең урамның аргы очында Мөфти мәчете күренеп торамы — менә шул гөмбәзле мәчетнең артындагы Бельская дигән урамда аларның йортлары. Бу йортка инде без бик теләп барабыз, чөнки анда берьюлы өч малай — Хәбибулла, Идиятулла һәм Хәсән. Янә ике кызлары да бар: иң олысы — Мәхмүзә тутакай, иң кечесе — Рәисә. (Төпчек кызлары бик чибәр иде, соңыннан Казанга килгәч, профессор Хәмит Мөштәринең җәмәгате булды.) Өч малайның миңа тиңрәге Идиятулла — бөтен уеныбыз, йөрүебез аның белән иде. Урамнары Уфа тавының нәкъ кашыннан уза. Тау биек, текә, чокырлы-чакырлы, ак ташлар чыгып тора, тар сукмакларда кәҗәләр йөри, түбәндә Агыйдел ялтырап ята. Иделнең аръягы — кара яр, тар аланлык, шуны үткәч тә куе урман башлана; уңда челтәрле тимер күпер, сулда тәбәнәк кенә агач күпер — шуны чыккач та, калын урманны кисеп, еракка-еракка озын юл китә. Без әнә шул көмештәй Агыйдел суында коеныр өчен текә, ташлы сукмаклардан көненә ничә төшеп, ничә генә менми идек — кош йөрәге кебек булган ул чакта безнең йөрәкләр.

Уфа урамнарында кызыл йолдызлы, корал аскан хәрбиләр бик күбәйде, гомумән, шәһәр бик җанланды, хәрәкәт, шау-шу көчәйде, әмма кайда ниләр эшләнә — анысыннан без хәбәрсез. Без зурлар дөньясыннан читтә, без үзебезнең кечкенә дөньябызда яшибез. Ләкин шулай да бер бик мөһим вакыйганы мин үз күзләрем белән күрдем. Әлеге аклар ваттырып киткән тимер юл күперен Уфа эшчеләре ничектер тиз арада гына яңадан торгызганнар иде. Агыйдел ярында менә шул күперне ачуга багышланган тантана булды. Халык күп җыелган иде. Без, малайлар да, шунда чабышып бардык. Күпернең бер

башы белән яр читенә җимерелеп төшкән челтәр торыгын (пролетын) калын бүрәнәләрдән киң-таза бура итеп өелгән терәк өстенә күтәртеп куйганнар. Юлны ялгаганнар. Хәзер шуны сынап карау булырга тиеш.

Уфа станциясе ягыннан, ком-таш төягән берничә ачык платформаны артыннан этәреп, кара паровоз килде. Күпер алдында бераз гына туктап торды. Аннары, зәһәр генә кычкырткannан соң, платформаларын этәреп, бик әкрен генә күпергә керә башлады. Халык тын да алмыйча карап тора — нишләр, бүрәнәләрдән өелгән терәк күтәрерме, исән генә үтә алырмы? Ә паровоз һаман әкрен генә керә-керә, ниһаять, күпернең хәтәр җирен үтеп китте. Каты итеп гудок бирә-бирә, аргы якка кызу гына барып та чыкты. Бу якта тынлы оркестр дәртле генә марш уйнап җибәрде, халык кулларын болгый-болгый кат-кат «Ура!» кычкырды... Бик кызыклы, бик күңелле булып калды бу тамаша безнең өчен дә... Әмма кызыклы гына түгел, гаять әһәмиятле дә булган ул тамаша. Менә шуны күрергә туры килде безгә!

Әнә шундый вакыйгаларга бай кызыклы җәйне үткәреп, без, көз кергәч тә, үзебезнең Дәүләкәнебезгә кайтып киттек. Алып кайтучылар очраклы юлаучылар иде. Агыйдел аша агач күпердән дөбердәп чыкканнан соң, биек тау башындагы зур калага һаман борылып карый-карый бардык. Бик әкрен һәм бик озак ераклаштык без аңардан... Аерылышу һәрвакытта ямансу!.. Без аның төз, озын урамнарына, биек таш яки матур агач йортларынаияләшкән идек, үзебезне инде чын шәһәр малайлары итеп тә тоя башлаган идек — кайткач, бәләкәй генә Дәүләкәнебезгә тиз генә күнегә дә алмабыз кебек иде... Хуш инде, хуш, биектәге ак кала! Син безне онытсаң да, без сине онытмабыз беркайчан да!

Һәм әйтергә кирәк, Уфа, чынлап та, минем исемнән бервакытта да чыкмады. Мин аңа һәрвакытта бик теләп, сагынып кайтам. Егет чагымда да һәм менә картайгач та... Асылда бит Уфа ул минем туган калам. Уфага якын җирләрдә мин туып үскәнмен. Иң якын туганнарым да Уфада яшиләр. Мин үзем дә Уфага кайтып яшәү турында күп уйландым. Иң элек аның коры тау һавасы миңа килешә, авыру йөрәккә сулавы җиңелрәк анда. Соңгы елларда мин моны аеруча ныграк сизә башладым... Һәм, гомумән, Уфа — таза шәһәр, яшеллек тә күбрәк, чистарак та ул.

Бик табигый рәвештә укучыда «Нигә алайса Казанга киттегез, нигә Уфада гына торып калмадыгыз?» дигән сорау туарга мөмкин.

Моның бер сәбәбе шунда ки, мин кече яшьтән диярлек татар әдәбиятын укып үстем. Казан ул минем өчен кәгъбә сыманрак бер җир иде. Әдәбиятка керәсе килгән һәркем шунда барырга тиеш кебек иде. Аннары Казан — элек-электән үк үзенең уку йортлары белән танылган шәһәр. Анда белемнең, һөнәрнең төрлесен алырга була. Бу уку йортларының төрле милләт яшьләренә кайчандыр бикле ишекләре революциядән соң, ниһаять, киң итеп ачылды. Егерменче еллар белән утызынчы еллар арасында бер Башкортстаннан гына күпме яшьләр шәһәри Казанга укыр өчен агылып килмәде! Менә шул агымга ияреп мин дә киттем. Минем дә төп максатым, билгеле, уку иде. Хәер, дөресен генә әйткәндә, Казан һәрбер белем эстәп килүчене кочагын җәеп каршы алмады. Берәүләр максатларына тиз ирештеләр, икенче берәүләргә ирешүләре шактый авыр булды. (Ул чакларда социаль чыгыш дигән нәрсә еш кына кешенең язмышын билгели иде.) Әмма ничек кенә булмасын, мин дә шушы бик теләп, бик хыялланып килгән каламның шактый ук комлы туфрагына, азаплана торгач, тамыр җибәрә алдым. Әкренләп булса да үстем, әчерәк булса да, җимешләр дә биргәләдем... Мин инде карт агач, ә карт агачны, үзегез беләсез, күчереп утыртырга ярамый — бөтенләй корып китүе бар.

Шулай да яшерә алмыйм, Уфа мине тарта. Ничектер менә яшьтән үк мәхәббәтем төшкән бу калага. Бигрәк тә Уфаның иске үзәге, шул үзәккә килә торган төз урамнары, шул урамнардагы капка-коймалы, алма бакчалы җыйнак кына матур йортлары әле дә булса исемнән чыкмыйлар. Бигрәк тә мин күп йөргән Тукай урамы, «Госмания» мәдрәсәсе тирәләре, текә яр өстендәге «Случевская» (хәзерге Крупская) бакчасы ничектер аеруча җанга якын урыннар булып хәтердә сакланалар. Әгәр кодрәтемнән килсә, мин шушы «Госмания» мәдрәсәсе белән Аксаков йорты урнашкан мөешне бер дә кул тидермичә саклаткан булыр идем. Иске Уфаның үзенә күрә бер кабатланмас почмагы, шунда кайчандыр Аксаков яшәгән, шунда ук безнең шәкертләр дә укып йөргәннәр... Кызганычка каршы, мин «Галия» мәдрәсәсе урнашкан тирәләрне яхшы белмим (без аннан ерак тордык), хәлбуки Уфаның демократик яшьләре шунда тупланган, халыкка кирәк чын мәгърифәт тә шуннан таралган булырга тиеш.

Уфа соңгы бер утыз ел эчендә искиткеч үзгәрде, галәмәт үсте, зурайды. Иң күп өлеше бер яки ике катлы агач йортлардан гыйбарәт иске кала сүтелеп бетте дияргә ярый. (Һәрхәлдә, бик аз өлеше генә калган булса кирәк.) Хәзерге Уфа ул тоташы белән диярлек зур-зур

биек йортлардан торган таш кала. Озынлыгы аның, чын булса, йөз километрга җитә, диләр. Шуңадыр инде Уфада метро төзү чарасына да керештеләр.

Уфада торучылар Уфаны бик яраталар. Билгеле, аларга хәзерге Уфа ошый, хәзерге Уфа кадерле, шуңа күрә минем «искесен» сагынуымны, ихтимал, аңлап та бетермәсләр. Әмма хатирәләр бит үзләре искермиләр — хатирәләр шуның белән кадерле дә.

...Менә без яңадан үзебезнең Дәүләкәндә!.. Йортыбыз исән-сау торган, кызыл сыерыбыз да исән-сау, күршеләр дә сау-сәламәт, Дәүләкәннең үзенә дә берни дә булмаган. Диме, тугае, күлләре дә әүвәлгечә җәйрәп ята — шәп иттек без өебезгә кайтып.

Хәзер инде сугыш Дәүләкәннән ерак китте, яңадан әйләнеп килмәскә тиеш. Кызыллар акларны Себер буйлап куалар, дип сөйлиләр. Бусы бик әйбәт. Ләкин шулай да вакыт хәвефле, талау-үтерүләр дә ишетелгәли (авыллар арасында ниндидер кораллы бандитлар йөри, имеш), яшәү шартлары да авыр, ачлык, бөлгенлек, һәртөрле чир-зәхмәт хөкем сөрә. Дөньяны бет басты, аны бетерергә һич әмәл юк, тифның котырган чагы. Менә без дә Уфадан кайтып, күпмедер торырга өлгермәдек, өй эчебез белән тифтан егылдык. Башта инәй, аннары мин, аннары энем өч-дүрт атна ут эчендә яттык. Инәй мескен тифны бик авыр үткәргән, саташкан чакларында урын өстеннән торып-торып китә икән. Атакай берүзе безне көне-төне карады, өсләребезне алыштырды, урыннарыбызны җыештырды. Тифның эчендә кайнаса да, аның үзенә берни дә булмады, ни гаҗәп!.. Ә без өрәкләр шикелле агарып, нечкәреп, тәмам хәлдән таеп аякка бастык. Бик әкренләп кенә рәткә кердек. Тифтан соң адәм баласында ашыйсы килү бик көчәя икән. Нәфес анысын тели, монысын тели, ләкин кайдан табарга?.. Кибетләр ябык, алу-сату юк, атнага бер килә торган базар да бик ярлы, агайлар азык-төлекне качып-посып итәк астыннан гына саталар. Сыерыбызның да сөтне киметкән чагы. Шәптән түгел эшләр. Шулай да мин ул чактагы тормышыбызны бик үк начар димәс идем. Һәрхәлдә, ризыктан аерылмадык. Миңа калса, безнең атакай ул чакларда да тик ятмагандыр, якын-тирә авылларда аның танышлары күп иде, анысын алып, монысын биреп дигәндәй, кирәк нәрсәне тапкандыр, ахрысы. Аннары Ташлыкүлдән Кашшаф җизни дә бәрәңгесен, онын китергәли иде, алар ягы азык-төлеккә һәрвакытта мул булып торды, үзләре дә бик ярдәмчел туганнарыбыз иде.

Тагын безне борчыган бер мөһим мәсьәлә — ул да булса уку мәсьәләсе иде. Күргәнсездер инде, бу аклар-кызыллар сугышы аркасында безнең укуның бер дә рәтеюне булмады. Бер генә кышны мин тоташ укып үткәрдем. Икенче кышым бер өзелеп, бер ялганып ничек җитте шулай үтеп китте. Уфага баргач, тагын шул сугышлар аркасында өйдә генә утырырга туры килде. Гаеп атайларда да булды шикелле. Сабир хәзрәт мәдрәсәсенә илтеп биргәч, мине сабакка йөрүдән туктатмаска иде. Имеш, минем әле укырга вакытым узмаган. Ә уку елын югалтуы жәл, мин моны чамалый идем инде.

Ахырда менә, шактый соңга калып булса да, без энем белән икәү Дәүләкән мәдрәсәсенә йөри башладык. Энемнең киндер букча тагып беренче баруы, ә бит аңа да инде сигез яшь!.. Укулар һаман да әле мәчет каршындагы иске мәдрәсәдә бара. Иркен генә ихата эчендә ике йорт: берсе, зуррагы, такта белән тышлап сарыга буялган, икенчесе, кечерәге, гади авыл ызбасы кебек кенә. Икесен дә Искәндәр ахун мәдрәсәсе дип йөртәләр. Зурысында рөшдиләр (урта сыйныфлар), кечесендә иптидаи (башлангыч) сыйныфлар укыйлар. Без менә шул кечесенә йөрибез.

Әйтергә кирәк, ул кышны (бу 1919—1920 уку елы) ике мәдрәсә дә шәкертләр белән тулы иде. Бигрәк тә сары мәдрәсәгә Дим буе авылларыннан буй җиткән башкорт егетләре килеп тулган иде. Аларның күбесе кайчандыр монда укып, сугышлар вакытында бер-ике кыш аерылып торучылардыр, ахрысы, ләкин араларында солдатка алынмас өчен килеп кергәннәре дә бар дип сөйлиләр иде. Болар барсы да диярлек кайры ак тун, ак ката, кама читле хәтфә бүрек кигән, муеннарына ак шарф ураган шактый мут һәм көяз шәкертләр. (Күренеп тора, хәлле кеше малайлары.) Аларның яту-тору, ашау-эчүләре дә мәдрәсәнең үзендә үк — көндезләрен Ахун хәзрәттән дәрес алалар, ә кичләрен... кичләрен, белмим, нишләгәннәрдер. Без, бәләкәйләр, сары мәдрәсә тирәсенә барып йөрми идек, чөнки андагы мыеклы шәкертләр безне гел генә: «Каениш, нихәл?» «Каениш, апаңа миннән сәлам әйт!» — дип үртиләр иде. Кайчагында кичләрен сары мәдрәсәдән курай уйнаган, җырлаган тавышлар да ишетелә иде. (Бусын тыңламыйча түзеп булмый, бусы күңелләрне әллә нишләтә!) Әйтәләр иде: мондый кичләрдә шәкертләр Шәйморат бичәсеннән койган бал китереп эчәләр, мич авызына чүгәләп кенә фифруз да тартып җибәрәләр, дип... Булыр да, алар бит инде, кем әйтмешли, үгезне мөгезеннән тотып егарлык егетләр иде.

Ул кышны әле дин сабагы белән дөньяви дәресләрне

укыту бергә алып барыла иде. Бер үк хәлфәдән без әфтиякне дә, башлангыч шәригать кагыйдәләрен дә һәм тел, хисап, җәгъръәфияне дә укый идек. Шулай ук безнең кечкенә мәдрәсәдә дә якын-тирә авыллардан килеп укып ятучы малайлар да бар иде. Шулардан ике малай — Тазлар Дәүләкәненнән (бу — зур Дәүләкәннең Дим түбәнендә аерылыбрак торган бер өлеше генә, ни өчендер аңа әнә шундый «матур» исем кушканнар). Аталары бик иске кеше булгангадыр, ахрысы, аның таләбе буенча хәлфә абзый малайларны кадимчә укытып маташты. Месеннәрдән бик көләләр иде, кемдер ике малайның да бишмәт аркасына акбур белән «таз» дип язып та куйган иде.

Еш кына без, Дәүләкән малайлары да, култык астына мендәр кыстырып, үзебезнең мәдрәсәгә куна килә идек. Анда кызык, анда уен-көлке, мендәр сугышы, урлашып ашау — тик шулай да зур мич артында йоклап ятучы кизү бабай бар, бабайның матчага кыстырган озын чыбыгы да бар, әгәр артык онытылып китсәк, бабай мич артыннан кашына-кашына чыга да, бер сүз әйтмәстән, зәһәр тал чыбыгы белән чыжлатып безне тәртипкә утырта иде.

Әмма иң кызыгы һәм куркынычы — идәндәге киезгә тезелешеп яткач сөйләнә торган әкиятләр! Ниләр генә сөйләнми иде! Җен, пәри, албасты, абзар иясе, мәчет өрәге, кабердән чыгып, очып йөргән ут шары, яшь кыз кыяфәтенә кергән юха елан — берсе дә калмый иде. Монда, билгеле, иске китаплардан отып алган падишалар, шаһзадәләр, хан кызлары турында да күп сөйләнә, ләкин малайларның үзләре уйлап чыгарган уйдырмалары да җитәрлек. Һич тузга язмаган булса да, ант итә-итә безне ышандыралар, һәм без ышанабыз, без куркудан юрган астында калтырана башлыйбыз, йоклап китә алмыйча азапланып бетәбез... Инде төнлә тышка чыгасың килсә — бәла!..

Әнә шулай үтеп китте безнең малай чакның, авыруларга, бөлгенлеккә карамастан, тагын бер кызыклы, ваемсыз кышы. Иске мәдрәсәдә ята-тора дин белән фәнне бергә укып йөрүебез дә шул кышта тәмам булды. Икенче кышны инде без Мөфәххар картның Марҗа базары каршындагы озын-карсак йортында бары «сәвитчә» фәннәр генә укыдык. Шулай итеп, безне диннән аердылар, ләкин бөтенләй үк түгел. Егерме икенче елның көзеннән башлап дин сабагын укытуны мәчеттә оештырдылар. Без әле Коръәннәребезне күтәреп, кичләрен мәчеткә дә йөрдек. Намаз бүлмәсенең йомшак киезенә тезләнеп, зур түгәрәк ясап утырган килеш карт хәзрәтнең

үзеннән һәм аның чатан мәхзүменнән сабаклар алдык. Ләкин бу укып йөрүнең бер дә ата-анасы булмады. Ник дисәң, малайлар бик усалланды, хәзрәт килгәнче мәчет эчендә тузан куптарып сугышалар, бер-берсенең каталарын, итекләрен яшерәләр. Азгынлык хәтта шуңа барып җитте ки, тыныч кына укып утырганда малайларның берәрсе күршесенең салып куйган бүреген алып, түгәрәк уртасына «шап» иттереп ыргыта. Мескен хәзрәт куркуыннан сискәнеп, агарынып китә, ә малайлар берни булмагандай башларын түбән иеп, китапларына төртелеп утыра бирәләр. Ник берсе тынын чыгарсын, ичмасам! Хәзрәт «Кем бүрке, кем ташлады?» дип сорап та тормый, чөнки барыбер беркем дә бер сүз әйтмәячәк. Һәм бүрек дәрес беткәнче түгәрәк уртасында ятачак.

Билгеле, мондый сансызлык, йөгәнсезлек дин сабакларының дәрәҗәсе төшүдән, дин укып йөрүнең кирәкмәгән бер эшкә әйләнүеннән, бары атайлар мәҗбүр иткәнгә күрә генә йөреп маташудан килә иде. Шул ук вакытта малайлар барсы да көндез совет мәктәбенә йөриләр, анда фән дәресләре үтәләр, ә фән ул диннең капма-каршысы, фән Алланы да, динне дә инкарь итә. Дин ул иске дөнья калдыгы, изүче сыйныфларга хезмәт иткән, хәзер исә эшче-крестьянга яңа тормыш корыр өчен белем кирәк, фән кирәк... Әйтәсе дә түгел, бу үзе бик гади, үзе аңлаешлы өйрәтүләр малайлар күңеленә көннән-көн ныграк сеңә бара иде. Аннары 1923—1924 елларда Дәүләкәндә комсомол хәрәкәте дә көчәеп китте. Татар һәм башкорт яшьләреннән дә комсомолга керүчеләр була башлады. (Ә комсомолга керүче ул инде иң элек Алла белән мулладан йөз чөерә.) Бер үк вакытта мәктәпләрдә пионерлар хәрәкәте дигән өр-яңа бернәрсә дә барлыкка килде. Барабан, быргы, кызыл галстук, кыска ыштан — болар барсы да бик кызыклы, бик мавыктыргыч иде. Кая монда дин сабагы?! Оят ул хакта уйларга да!.. Атай йодрыгы да инде куркытмый. Кыскасы, ике кыш малайларны көчләп азаплаганнан соң, мәчеткә йөреп уку үзеннән-үзе диярлек тукталды, бетте.

Инде иске мәдрәсәдән аерылган чагыбызга — егерменче елның язына кайтыйк. Миңа шушы язда унбер яшь тулды. Балалыктан чыгып барам, ләкин яшүсмер түгел әле (дип уйлыйм). Һа, баксаң, миңа Дәүләкәннән чыгып китәргә бары биш кенә ел калган икән ләбаса! Үз юлымны табарга, үз көнемне күрергә!.. Ә бит минем бернәрсә көтмәгән, уйламаган иң ваемсыз чагым әле... Нинди тиз өлгерә икән адәм баласы! Ә шулай да бу калган биш ел турында күпме язасым бар. Сугыштан соңгы

кырык елыма караганда да күбрәк һәм минем үзем өчен әһәмиятлерәк тә диясем килә.

...Без бик күп уйный идек. Хәер, бөтен җирдә дә бала-чага күп уйный, ләкин Дәүләкәндә аеруча, чөнки мондагы малайларга уеннан башка эш тә юк. Күбесенең аталары йә сәүдәгәр, йә хезмәткәр, йә һөнәрче — берсендә дә крестьян эше белән бәйләнгән хуҗалык юк, ишле малтуар да юк, шул сәбәпле аларның малайлары вакытларын урам таптап та уйнап уздыра. (Безнең тирәдә крестьян эше белән шөгыльләнүчеләр Арыслангәрәй агай да Гатаулла карт, тагын мөәзин абзый — менә аларның улларына җәйге эш өсләрендә уйнап йөрергә туры килми иде. Кешене эшкә өйрәткән иң шәп «мәктәп» тә — крестьян хуҗалыгы.) Һәм без, эшсез малайлар, шактый күп идек. Урамга чыктык исә, өч-дүрт йорттан унлап малай җыелабыз. Нишләргә, кая барырга, нәрсә уйнарга?..

Уеннар, уеннар... Нинди генә уеннар уйнамый идек без!.. Алар күп, һәр вакытның үз уены, мәсәлән, җир туңгач, шар сугу башлана. Каты тамырдан ясалган йомры шар, кулларда карама яки имән кәшәкә, малайлар, егетләр урамның буеннан буена кара-каршы торып, шомарып беткән шарны урамның бер очыннан икенче очына таба куалар. Бу уенга, кызыгып китеп, хәтта бичәле ирләр дә чыгып кушыла иде.

Кышын кар утыргач, билгеле, күбрәк чана шуу — Арыслангәрәй тыкрыгының яры биек, текә, без шуннан буран уйнатып шуабыз. Түбәндә тип-тигез, ап-ак Комач өсте — безнең чаналар карны ерып, әллә кая хәтле китәләр. Монда да без узыша-узыша шуабыз.

Кар китеп, җирләр кипкәч, йөгертмә туп, чокыр туп уйнау... Шәп уеннар, бигрәк тә йөгертмә туп — күпме чослык, өлгерлек, тизлек кирәк бу уенда! (Хәзер уйныйлар микән бу уенны? Шәһәр эчендә күргәнем юк, аңа иркен мәйдан кирәк, без, мәсәлән, кырга чыгып уйный идек.)

Бөтен уеннарны да санап чыгу кирәк микән? Һәр җирдә дә алар булгандыр дип уйлыйм. Мәсәлән, кузна уенын кайда гына белмиләр иде! Тик бер генә нәрсәне искә төшерәсем килә: кузнаның бит әле бәрә торганы була. Бездә аны нәлти, диләр. Ул авыр булырга тиеш. Ә авыр итәр өчен без башта зуррак кузнаның төбен үткен пәке очы белән кыра-кыра тишәбез дә шуннан соң чүмеч белән утлы күмер өстендә эретелгән кургашны чүпрәккә урап тоткан кузна эченә ипләп кенә коябыз. Менә шул кургашын тутырылган авыр-саллы кузна бәрә торган

нәлти була да инде. Аны ун адымнан бик туры ыргытсаң, парлап тезелгән кузналарны кырып кына саласың!

Бик оста уйнаучылар була торган иде. Кайчагында бөтен кузна бер кулга кереп бетә — откан малай ыштан бөрмәсенә кыстырган күлмәгенең эченә тутырып кайтып китә. Кузна бит ул акча бәрабәренә йөри диярлек. Оттырып бетергәч, син аны берәүдән дә бушка ала алмыйсың. Сатып яки әйбергә алмаштырып кына алып була иде. Шуңа күрә кузнаны бервакытта да ташламыйлар, киндер капчыкка яки зуррак тартмага тутырып, киләсе язга чаклы чормада саклыйлар.

Әмма ике уен турында сөйләмичә булмас, ахрысы. Чөнки малайлар уенында да заманның үзгәрүе чагыла. Аларның берсе бездә генә очрый торган иске уен иде, икенчесе — читтән кайткан яңа уен. Иске уенның тәгаен исеме инде онытылган, ләкин ул җәя белән укка бәйләнгән иде. Җәйгә чыктык исә без үзебезгә җәя белән ук ясый торган идек. Дим тугаенда таллыклар күп, юанрак талдан җәя бөгәбез, туп-туры, нечкәсеннән ук ясыйбыз. Каеннан да бөгә идек, ләкин тал яхшырак бөгелә, сынмый, нечкә, әмма таза сүс бау белән бөгеп бәйләгәч, кыл шикелле тартылып тора, атар өчен дә каты була. Ук өчен нечкә талны каерысыннан әрчибез, киптерәбез, турылыйбыз, аннары бер очындагы йомшак үзәгенә башак утыртабыз һәм барып кадалганда эчкә кереп китмәсен өчен укның башак утыртылган җирен нечкә тимерчыбык белән бик каты урап куябыз... Ук башагы ике төрле була — без башак һәм балта башак. Без башак тишеп керә, ә балта башак кисеп төшерә. Без башакка калын энә дә ярый, ә менә балта башакны махсус ясарга кирәк. Моның өчен без дага кадагын поезд үткәндә рельс өстенә куеп таптатабыз, аннары бик әйбәт иттереп тигезлибез һәм үткерлибез. Исеменнән күренгәнчә, ул чынлап та балта йөзенә охшап тора.

Хуш, ә уен үзе нидән гыйбарәт?.. Әйтик, дүрт-биш малай бергә җыелабыз, иңдә — җәя, кулда — берничә ук. Шуннан элеватор артындагы кырга чыгып китәбез. Барып җиткәч, бер-беребездән читтәрәк торып тезелешәбез дә берәр укны һәммәбез бергә һавага атып җибәрәбез. Һәм карап торабыз: кемнең угы биегрәк оча?.. Шул арада уклар төрлесе төрле җиргә төшеп кадалалар. Иң биек менгәне, билгеле, аз гына соңга калып төшә. Менә шул укның хуҗасы инде ату хокукын ала, ягъни үзенең угы төшеп кадалган җирдән торып, башкаларның утырып торган укларына төзәп ата башлый. Тидерсә — ук аныкы, тидермәсә — хуҗасына кала.

Бу уен берничә мәртәбәләр кабатлана. Берәүләр укларыннан язалар, икенчеләр ук башагы җыеп алалар. (Сынган ук кирәкми, аны ташлыйлар.) Монда малайларның ике төрле сәләте сынала: беренчедән, укны һавага мөмкин кадәр биегрәк ату өчен көч кирәк, икенчедән, төшеп кадалган укларга тидерер өчен бик үткен күз кирәк. Шәп, кызыклы уен!.. Миңа калса, бу уен бик борыннан сакланып килгән булырга тиеш. Хәзер юк инде ул, күптән онытылган.

Ниһаять, Дәүләкәнгә... футбол килде. Егерме дүртенче елның җәендә булды бу шаккатыргыч вакыйга!.. Моңарчы һич күргән, ишеткән нәрсәбез түгел иде. Кемдер каяндыр (билгеле, зур шәһәрдән) күреп кайткан булырга тиеш. Башта рус малайлары күннән теккән зур тупны тибеп уйный башладылар. Без авыз ачып карап торабыз, аңларга тырышабыз. Ике төркемгә бүленеп, каракаршы торып уйныйлар, үзенә күрә ниндидер тәртипкагыйдәләре дә бар, ахрысы...

Әйтергә кирәк, ул елның кышында элекке гимназия бинасында безне, бишенче сыйныфтан башлап, рус балалары белән бергә укыттылар. Рус малайлары һәм кызлары белән класста гына түгел, уйнаганда, йөргәндә дә әкренләп аралаша башладык. Кыскасы, туп тибү белән безнең бик кызыксынганны күреп, алар, ниһаять, безне дә уенга катнашырга чакырдылар. Без инде сикерә-сикерә риза! Арадан берсе — бу уенны бик белгәне — безгә төшендерде: ике команда булырга тиеш, без менә үзебезгә команда төзедек, сез дә үзегезгә аерым команда төзегез. Унбер кешедән артык ярамый. Яшь ягыннан да бер чамарак булсын — бик кечкенәләрне яки бик зурларны алмаска. Аңладыгызмы?.. Арадан бер толковый иптәшегезне капитан итеп сайлагыз.

...Кызу кулдан тотындык без команда төзергә... Теләүче күп, талаш-ызгыш китте, чак сугышып та китмәдек, ләкин Таһирдан барыбыз да курка идек. Менә ул күкрәккә төртә-төртә исемнәрне әйтеп чыкты һәм үзе үк капитан да булды. Унбер бәхетлеләр арасына мин дә эләктем.

Икенче көнне рус малайларына әйттек, безнең команда әзер, уйнарга да була, дидек. Теге барсын да белүче малай (ялгышмасам, аның фамилиясе Маслов иде бугай) бездән сорый: командагызның исеме бармы, булмаса кушарга кирәк, ди. Нинди исем? Безнеке менә «Искра» дип атала, сез дә табыгыз!.. Алай икән диештек без, йә, нинди исем кушабыз? Арадан берәвебез кабаланып әйтте: «Ә безнеке «Очкын» булсын»,— диде. Рус

малае сорый: «Нәрсә ул учкун?» Аңлаттык. Юк, ярамый, ди, безнекен алгансыз, ди... Таба алмыйча аптырап беттек, уебыз һаман ут, ялкын, төтен кебек бер үк төрле исемнәр тирәсендә әйләнә дә әйләнә. Ахырда бер зирәкнең башына һич уйламаган исем килде. Әйдәгез, «Байрак» кушабыз!.. Без шунда ук моны эләктереп алдык: «Шәп! «Кызыл байрак» булсын!» Мактана биреп рус малаена да әйттек, ләкин күпне белүче егет безгә, исем кыска булырга тиеш, диде: или кызыл, или байрак!.. Шулай итеп, без «Байрак» кына булып калдык.

Хәзер инде кайда уйнау мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде. Гимназия күршесендә ак чиркәү, аны узгач тигез чирәмлек — барыбыз да шунда киттек. Баш булып йөрүче малай җитәкчелегендә без зур гына мәйданның чикләрен билгеләдек, аның ике як башына ташлар өйгәләп «капка» ясадык. Аннары җитәкчебез үзе мәйданның нәкъ уртасын билгеләде — уен шуннан башланырга тиеш икән. Уенның төп максаты — каршы якның капкасына туп кертү. Һәр команда шуңа омтыла — үз капкасын саклый, каршы якка һөҗүм итә. Уенны дөрес алып бару өчен судья булырга тиеш икән әле — ул сыбызгы кычкыртып башлата, ул туктата, кагыйдәне бозган өчен штраф та «түләтә» (ягъни каршы якка тупны типтерә).

Хуш, егетнең сөйләгәннәрен аңлаган шикелле булдык, инде тизрәк уйнап карыйсыбыз килә. Ләкин көтелмәгән бер хәл килеп чыкты: футбол уйнар өчен өстә җиңсез күлмәк, кыска ыштан, аякта ботинкалар булырга тиеш, имеш!.. Билгеле, андый махсус кием безнең беребездә дә юк иде (сабый чакта төпсез ыштан кигән бар, әмма балаксыз ыштанны күргәнебез дә юк әле). Нишләргә? Шуннан уйлаштык та әйттек: юкны таба алмыйбыз, күлмәкләрне салып ташлыйбыз, ыштан балакларын сызганабыз, и... яланаяк уйныйбыз, дидек. Урыс малайлары, ни әйтергә белмәгәндәй, безгә бераз карап тордылар да: «Чурт с вами, уйнагыз!» — диделәр... Һәм менә ике көннән соң микән, «Искра» белән «Байрак» арасында чын уен башланды. Өйрәтүчебез үзе үк судья да булды. Башта ике капитан шобага тотышты, «Искра»ныкы өскә чыкты — уенны алар башлаячак. Без урта сызыктан арткарак чигендек, «судья» өреп тутырган зур тупны җиргә куйды, сыбызгысын кычкыртты һәм уен башланып та китте... Һәм бер минут та үтмәгәндер, рус малайлары тупны безнең капкага илтеп тә керттеләр. Капкада торучы теге... ничек әле, аты коргыры? — Голкипер Гыйззәтулла селкенергә дә өлгермичә авызын ачып кына калды. Яңадан без инде уртадан башладык.

Уен бик тиз кызып китте, судьяның сыбызгысын ишеткән дә, тыңлаган да юк, тупны кем эләктерсә, шул алга таба куа да куа, калганнар барсы да аның артыннан өерелешеп чабалар гына... «Пас» дигән нәрсәне белүче дә юк, киресенчә, безнең малайлар тупны күбрәк үзенә генә эләктерергә тырыша, чөнки аның да куасы, аның да капкага тибәсе килә.

Безнекеләр арасында бик шәп йөгерүчеләр бар иде, мәсәлән, Таһир белән Шакир, мин дә ул чакларда бик шәп йөгерә идем. Менә шуның аркасында без дә «Искра» капкасына берничә туп керттек. Ләкин уен барыбер «Искра» җиңүе белән бетте. Һәм ул шулай бетәргә дә тиеш иде, чөнки рус малайларының беренче уйнаулары гына түгел, аннары барысының да аякларында ботинка... Ботинкага каршы яланаяк уйнап кара әле син! Ул көнне без барыбыз да диярлек көчкә-көчкә генә басып, аксый-туксый кайттык... Соңрак инде без дә остара башладык, акыллырак уйный башладык. Ә ботинкага каршы чабаталар киеп алдык. Үзе җиңел, үзе ипле, ботинкадан куркып тору да юк, тик бер генә кимчелеге бар — тупка катырак типсәң, аяк чабатадан бүселеп килә дә чыга, хәерсез!.. Ләкин аңа каршы да әмәлен таптык — киндерәне бәйләгәндә чабата башына да кидереп ала торган булдык. Кыскасы, эшләп туздыра алмаган чабаталарны менә шул чакта туздырып бетердек.

...Дәүләкәннең яшел чирәмендә мин ике генә җәй футбол дигән бу гаҗәеп мавыктыргыч уенны уйнап кала алдым. Казанга киткәч, билгеле, туп тибеп йөрүләр бик тиз онытылды, яшь кенә башка шунда ук бүтән уй, бүтән кайгылар кереп тулды. Дөресен генә әйткәндә, без барыбыз да уен яшеннән тиз чыктык. Бер-ике ел үтүгә, минем яшьтәшләрнең күбесе укырга китте, калганнары эшкә керде — алар өчен дә башка чор — тормышка керү чоры башланды. Ә без уйнаган уеннарны безнең арттан килүче малайлар дәвам иттерергә тиешләр иде. Тик мин белмим, нинди уеннарны алар сайладылар икән?.. Уеннар да бит искерә, үзгәрә, онытыла... Шартлары да үзгәрә — әйтик, без үскәндәге иркенлекләр юк инде алар... Әмма уен ул бетә торган нәрсә түгел, уен ул — мәңгелек!.. Мәхәббәт кебек, җыр кебек, тормышның үзе кебек... Уйнаучылар да килә тора, үтә тора, китә тора бу дөньяда!

Зур су буе бала-чага өчен һәрвакытта куркыныч. Дим дә әнә шундый елгалардан — зур су, тирән су. Бигрәк тә немецлар елганы нәкъ Дәүләкән турысында буып, биш катлы таш тегермән салгач, Димнең өске ягы бик тирән-

әеп, киңәеп киткән, түбән ягы исә тау шарлавыгы сыман котырып ага торган булып калган. Ә без, Эткол малайлары, барыбыз да елганың өске ягында торабыз. Монда кечкенәләр өчен генә түгел, зурлар өчен дә су керер урын табуы читен — елганың яры стена шикелле тирәнгә төшә дә китә. Йөзә белмәсәң, син дә керү белән таш шикелле төпкә китәсең. (Әти-әниләр, Дим ул бала-чаганы үзенә тартып ала дип, юкка гына безне куркытмыйлар иде.) Ләкин шуңа да карамастан без көнозын диярлек су буеннан кайтып керми идек. Яшерә алмыйм: бу башбаштаклыгыбыз белән без инәй бичараны күп саргайттык. Тугыз баладан соң күргән «ике бөртек» өчен ул, билгеле инде, кан калтырап тора иде. Еш кына яр башына килеп, кулын маңгаена куеп, зәгыйфь күзләре белән түбәндә чапырдаучы балаларга карап тора, судан менеп килүчеләрдән «күрмәдегезме минекеләрне?» дип сорап та карый һәм күп вакытта бернәрсә белә алмыйча борчылып, сызланып кайтып та китә. Әлбәттә, инәйнең борчылуы бик урынлы булган — мин, мәсәлән, өч тапкыр Дим төбенә чак-чак кына китмичә калдым. Ләкин уйлый белү дә юк, инәйнең хәленә керү дә юк, урамга чыктык исә, малайларга иярәбез дә китәбез. Баштарак, әле кечерәк чагыбызда, өйдән ерак китмичә, Арыслангәрәй тыкрыгыннан гына төшеп, Комач суында җыен бала-чага быкырдаша торган идек. Монда тирән түгел, хәтәр чоңгыллар да юк, әмма төбе бик алама — тубыктан батарлык мәте генә... Баскан саен богыр-богыр итеп өскә эре күбекләр калка. Аз гына чапырдауга су тәмам болгана, дегеттәй карала, коенып чыкканда борын төпләренә «кара мыек»лар утыра... Әйтергә кирәк, Комачның төбе буеннан буена әнә шундый мамыктай калын мәтеле, зурраклар аның бер төшендә дә су керми торганнар иде. Нигә ул алай дисәгез, мин моның сәбәбен соңрак аңладым: Комач буена утырган бөтен йортларның мал абзарлары, бәрәңге бакчалары суга карый, менә шунлыктан бөтен абзар сулары, тирес-туфраклар Комачка агып төшә дә. Ничәмә еллар буена ул шулай килгән һәм шулай Комачны пычратып та бетергән. Кыскасы, Димдә су күп, ә коеныр урын аз иде. (Безнең Казандагы шикелле.)

Үсә төшкәч без дә, билгеле, Комачта быкырдауны ташладык. Әйбәт урын эзләп ераккарак китә башладык. Иң әйбәт урыннарның берсе — ул каршы яктагы Комач белән Димне тоташтырган ерым иде. Озын гына бу ерымның Димгә барып чыккан җире шактый ук тирән, суы да чиста, әмма яры сөзәк, төбе такыр комлык — рәхәтләнеп коена торган урын иде. Ләкин анда барыр өчен иң элек

көймә белән аргы якка чыгарга кирәк. Ә көймә сирәк кешедә генә, чылбырын казыкка урап, бикләп куелган, безнең ише малай-шалайга сорасаң да бирмиләр. (Күрше Борһан абзый үзенең буяулы яхшы көймәсен улларына да алып китәргә рөхсәт бирми иде.) Шулай да берәрсенең батып яткан ташландык «тагарагын» суыннан бушатып, такта белән ишә-ишә аргы якка чыгып китә торган идек. Аннары инде тугай буйлап, күлмәкләрне өстән сала-сала, ерым тамагына чабабыз. Һәм, барып җиткү белән, ыштаннарны төшереп кенә җибәрәбез дә, чаптыр-чоптыр суга кереп тә китәбез. Монда тәмам күгәреп беткәнче коена торган идек.

Безнең су керергә йөри торган янә берничә урыныбыз бар иде. Шуларның берсе һәм иң кызыктырганы — Димнең буадан түбән җире иде. Әмма буа асты су керер өчен бик хәтәр урын — без энем белән икәү беренче баруыбызда ук шунда харап була да яздык. Бик яшь идек шул әле — энемә тугыз, миңа унбер яшьләр чамасы булгандыр — зуррак малайларга ияреп, алар ни эшләсә, шуны эшләп йөри торган чагыбыз. Ә алар буа астында да су керүдән курыкмыйлар иде.

...Искә төшергәч, хәзер дә әллә нишләп китәм!.. Шактый биек буа өстеннән шарламадай ишелеп төшкән су котырып-дулап, яман шаулап ага. Монда суга керү түгел, янына бару да куркыныч. Әгәр, әйтик, таза ат керә калса, бу котырган агым аны да мәтәлдереп алып китәчәк. Ләкин берничә йөз адым түбәнрәк төшкәч, елганың читләрендә агым беркадәр әкренәя — менә шул төшләрдә инде кыю малайлар батыраеп суга керәләр. Монда комлык, вак ташлык, су бик чиста, хәтта бераз салкынрак та кебек. Тик шулай да бик сак булырга кирәк — эчтәрәк агым ифрат көчле, эләксәң, йомычка урынына ала да китә.

Хәер, кем аны уйлап тора?! Барсы да керәләр, без дә керәбез!.. Йөзәбез, чумабыз, уйныйбыз, һәм... эчкәрәк керүдән дә сакланабыз. Ләкин барыбер саклану җитмәгән, күрәсең, менә бервакытны каты агым энемне эләктереп, бөтерә-бөтерә алып та китте. Аны тотыйм дип кенә үрелгән идем, мин дә йомычкадай актым да киттем. Эш харап!.. Алдан бата-калка энем бара, аның артыннан мин... Ләкин таш шикелле төпкә китмибез әле, чөнки көчле агым үзе безне күтәреп, уйнатып кына илтә дә илтә. Тик кайчанга хәтле? Ычкынып чыгуны уйлаган да юк... Ә алда, ерак та түгел, Дим күпере. Яр буеннан кемнәрдер, безгә нидер кычкыра-кычкыра, шул күпергә таба йөгерәләр. Әллә аларны ишетеп, әллә үзем белеп, мин дә энемә кычкырдым: баганага ябыш, күпер баганасына!..

Башта ул күпергә җитеп, баганаларның берсенә ябышты, аннары мин килеп җитеп, икенчесенә тотындым. Бу минуттагы хәлебезне мин аңлата алмыйм, тик шуны гына беләм — без җыларлык та, сүз әйтерлек тә хәлдә түгел идек... Шул арада яр буйлап йөгерешкән кешеләр, күпергә кереп, безне кул сузып кына баганалардан тартып алдылар. Әнә шулай коткардылар безне. Ләкин моңа бер дә гаҗәпләнмәгез. Башкорт агайларының баганалар өстенә аркылы-торкылы чыбык-чабык салып, күп итеп салам түшәп салган күперләре әнә шулай бик тәбәнәк була, тар гына була, бер башыннан җигүле ат керсә, икенче ярдагысы күтәп тора — гомерем буена оныта алмадым мин шул ястык кебек йомшак Дим күперләрен!

Без инәйгә бу хәлне сөйләмәдек, билгеле. Гомумән, андый куркыныч хәлләрне һәрвакытта яшерә торган идек, чөнки без үзебезнең «ике генә бөртек» булуыбызны аңлый идек инде. Әмма ләкин кемдер соңыннан инәйгә безнең икәүләп агып китүебезне җиткергән. Күрәсең, инәйнең курку-тетрәнүе артык көчле булгандыр инде, безгә сүз әйтергә, безне тиргәргә аның тәкате җитмәде, бары өстебезгә карап җылады гына ул...

Белмим, калган батуларым турында сөйләп тору кирәк микән? Мәсәлән, яңа гына туңган, әле сыгылыбрак та торган боз өстендә кызык өчен юри чабып йөргәндә уелып төшеп китүемне (ярый, малайлар озын колга сузып, тартып алдылар) яки Димнең иң киң җиреннән, күлмәкыштаннарны башка урап, йөзеп чыкканда хәлдән таеп чак-чак кына батмыйча калуымны — юк, кирәкмәстер, ахрысы... Зур су буенда торгач, аның ише хәлләр була инде ул.

Әмма, мәгълүм ки, һәрбер азапның тора-бара бер рәхәте яки яхшы нәтиҗәсе дә булып куя. Менә без дә, инәйне җылата-җылата булса да, бата-калка маташа торгач, ниһаять, бик шәп йөзәргә өйрәндек. Хәзер безгә диңгез тубыктан — Димнең бер төшеннән дә куркып тору юк. Бигрәк тә энем Илдархан бик шәп, бик матур йөзә иде. Ул төз буйлы, киң күкрәкле малай иде, Димнең иң тирән җиреннән дә чумып мәте ала торган иде. Аңа кушаматны да малайлар «Күкен» дип бирделәр. Бу — балык исеме. Кечкенә үзе, әмма бик тере-җитез балык. Хәзерге заман кибетләрендә сатыла торган килька дигән мәшһүр балыкны белмәгән кеше юктыр инде — Димдәге күкен дә төсе, кыяфәте, зурлыгы белән нәкъ менә шул гаять популяр килька төсле үк иде. Ихтимал, алар бер үк токымнандыр да әле — исемнәре үк туры килеп тора бит!

Ничек кенә булмасын, без, чынлап та, суда күкен шикелле җиңел генә йөзәргә дә, чумарга да өйрәнеп беткән идек. Кайларга гына бармый идек тә кайларда гына коенмый идек. Җәйләр эссе, көннәр озын, суга шул хәтле ияләштек ки, мин хәтта бервакытны су өстеннән атлап кына китүемне дә хәтерлим. Ышанмыйсыз, күләсез?.. Ә мин ышандым, чын-чынлап ышандым! Хәлбуки, тип-тигез су өстеннән җиңел генә атлап китүем ул, билгеле инде, бары төштә генә булган, әмма шулкадәр ачык, шулкадәр чын төш булган ки, мин аны ирексездән өнем итеп кабул иткәнмен, өнемдә йөрдем дип шуңа сөенә-сөенә ышанганмын да. Малай чакның төшләре дә әнә нинди була икән ул!

Хәер, ни гаҗәп, агымсу белән бәйләнгән төшләр хәзергә кадәр миңа һаман кергәли торалар. Төшемдә йә берәр елга ярларыннан чыгып ташый башлый, йә шәһәр урамнарыннан котырып-шаулап су ага, йә чиксез киң дәрья уртасыннан капланып китәргә торган кечкенә көймәдә барам, имеш — барсы да әнә шундый хәтәр куркыныч төшләр... Әйткәнемчә, шушы яшемә хәтле кабатлана торган төшләр!.. Ләкин кайдан бу төшләр, ни өчен алар озак еллар дәвамында һаман кергәли торудан туктамыйлар?.. Бу сәер хәлнең серен мин бераз сизенсәм дә, ачык кына белми идем. Тик 1979 елны «Юматау» санаториендә бер врачның йокы һәм төшләр турында сөйләгән лекциясен тыңлагач кына, эшнең сере, ниһаять, ачылган кебек булды. Баксаң, кешенең кайчан да булса үтә көчле тирән кичергән берәр вакыйгасы гомерлеккә җуелмаслык булып баш миендә «язылып» кала икән. Һәм шушы язылып калган вакыйга, гәрчә онытылып бетә язса да, төрле вариантларда аның төшенә дә кергәли тора икән. Димәк, минем дә төшләремә кергән куркыныч су ташулары әлеге шул малай чакта берничә мәртәбә Димдә бата язуымның нәтиҗәсе икән ул!.. Булыр, врач сүзенә ышанмый мөмкин түгел.

Бер тирәдәрәк торучы бер тиңрәк малайлар без шактый идек. Күршедә генә — Борһан абзыйның Зәкәриясе белән Яхъясы, алар янәшәсендә — Арыслангәрәй агайның Таһиры. Каршыда гына — Габдрахман, аның күршесендә — Мөхәммәтгали белән Муллагали, ә алар күршесендә — Габделбарый белән Гомәр, тагын Гыйззәтулла, инде безнең яклап, аз гына түбәнрәк — Хәкимҗан белән Шакир... Күрәсез, якын күрше-тирәдә генә күпме малай! Инде шуларга энем белән мине дә кушарга кирәк. Һәм без, шушы малайлар, урамга чыктык исә, гел бергә —

көтүебез белән бергә йөрибез, бергә уйныйбыз. Әмма бертөсле генә малайлар түгел идек — һәр җәһәттән без бик нык аерыла торган идек. Дәүләкән халкы бик чуар булган шикелле, без дә бик төрле-төрле идек. Безне саф авыл малайлары да дип булмый, шулай ук чын шәһәр малайлары рәтенә дә кермибез. Безнең беришеләребез ярлылыкта, бөлгенлектә яшәсә, икенчеләребез тук-таза тормышта яши идек. Шулай ук безнең арада атасыз яки инәсез калган ятимнәр дә бар иде. Менә ни өчен без тәрбия җәһәтеннән һәм характерларыбыз белән бер-берездән бик нык аерыла идек. Мәсәлән, Зәкәрия белән Яхъя көн саен малайлар көтүенә ияреп, бөтен уеннарга да катнашып йөрмиләр иде. Чөнки аталары каты тота. Хәтерлисездер, аларны кечерәк чакларында ишегалларыннан да чыгармыйлар иде. Сафиулла абзыйның Габделбарые да сирәк катнаша — ул әдәпле һәм тыйнак, малайларның кайвакытта артык башбаштакланып китүләрен яратмый иде, ахрысы, андый чакта ничек тә читтә торырга тырыша иде.

Иң хөр-йөгәнсез малайлар Таһир, Габдрахман, Гыйззәтулла, Шакир иде. Алар төркеменә, билгеле, мин әнем белән үземне дә кертәм. Без эшсез малайлар идек, безнең бөтен «гамәлебез» урам таптау, бертуктаусыз уйнау, каядыр китеп югалу һәм ачыккач кына, өйгә кайтып керү иде. (Дөрес, мин, кулыма кызыклырак китап эләксә, урам уеннарын онытып та тора идем.) Малайлар һәр заманда да шул бер үк малайлар инде — мәнсезлек тә, шуклык та, ызгыш та, рәнҗеш тә җитәрлек булган. Ярыган белән ярамаганны еш кына аерып та тормаганбыз. Шулай ук әхлак-әдәп ягыннан да, әйткәнемчә, бертөсле генә булмаганбыз. Менә Габдрахманны гына алыйк — акыллы, сүзгә тапкыр малай, әмма бик хәйләкәр һәм мәкерле!.. Ул бүтәннәрне берәр ямьсез эшкә котырта, ә үзе гел читтә торып кала. Нәтиҗәдә ул яхшы, ә теге начар. Шулай оятка кала торганнар иде аның коткысына бирелгән малайлар... Миңа Габдрахман белән күп йөрергә туры килде, аның әнә шул әшәке гадәте, әче теле, мыскыллап көлүе еш кына ачуымны китерсә дә; ни сәбәптер мин аны ярата идем. Бәлки, бүтәннәрдән аерылып торганга күрәдер?! Әче теле өчен без аны «черки» дип йөртә идек. Үзенчә сәләтле малай иде ул!..

Габдрахман тик берәүдән көлүдән тыела, берәүне котыртудан саклана — бу Таһир иде. Арыслангәрәй агайның Таһиры турында мин язган идем инде. Бик кыю, көчле һәм... гарьчел малай! Кагылсаң — тукмый да ташлый. Без барыбыз да аңардан курка идек.

Ә менә Шакир, киресенчә, бик тиз коткыга бирелеп китә, шунда ук алдын-артын уйламыйча эшли дә ташлый. Аңа тик кызык кына булсын! Шуның белән бергә ул да бик кыю, гайрәтле һәм сугышырга да бик чос малай иде. Үзеннән шактый олыраклар белән дә ул бәрелешүдән һич куркып тормый — яшь үгез шикелле башын иеп, акны-караны күрмичә ташлана. Бу җәһәттән Шакир белән Таһирны бертигезләр дияргә дә ярый, шуңадыр, ахрысы, алар беркайчан да бер-берсенә кагылмадылар. Әгәр аларга сугышырга туры килсә, икесенең берсе беткән булыр иде дип уйлыйм мин әле хәзер дә.

Шакир көләргә дә, көлдерергә дә ярата торган бик шук малай иде. Ниндидер балаларча беркатлылык һәм эчкерсез самимилек бар иде аңарда. Кайчагында җитди күренергә тырышса да, сүзе-кыланышы барыбер көлке килеп чыга иде. Һич онытасым юк кечкенә бер вакыйганы.

1926 елның җәй башында без Фәтхелислам белән икәү беренче мәртәбә Казаннан Дәүләкәнебезгә кайттык. Фәтхелислам — студент, ә мин — китап кибетендә курьер булып эшләүче. (Дәүләкәндә курьерның нәрсә икәнен дә белмиләр.) Казан хәтле Казаннан кайткач, безнең дәрәҗә зур һәм игътибар да безгә зур. Ул чакларда инде без барыбыз да малайлыктан чыкканбыз, берәүләребез егет булып җиткән, икенчеләребез менә-менә булырга тора.

Икенчеме, өченчеме көнне үк без әнә шул бергә уйнап үскән күрше дусларыбыз белән имәнлеккә барырга булдык. Имәнлек тау ягында, тимер юл аша чыгып барырга кирәк... Киттек, тимер юлга җиттек, шул чагында каяндыр каршыбызга Шакир килеп чыкты. Без әле аның белән күрешмәгән идек. Менә ул ашыкмыйча гына яныбызга килде дә үзенчә җитди-әдәпле генә итеп башта Фәтхелисламга дәште:

— Исәнмесез, Фәтхелислам туташ!

Без егылып китә яздык: «Туташ, ха-ха-ха!..» Белеп дәшәме, әллә белмичәме бу чукынган?! Әлбәттә, белептер, әмма ник бер уңайсызлану әсәре яки көлү галәмәте чыксын ки аның йөзенә! Гүя бик дөрес һәм бик урынлы дәшкән ул Казаннардан кайткан студент егеткә! Зурлаган, янәсе!.. Әнә шулай эчләребезне катырган иде, мәрхүм!.. Мәрхүм дим, чөнки шул ук елның көзендә, без киткәч инде, Шакирны Смолин дигән бер малай мәктәп коридорында атып үтергән. Егет ниндидер зур урында эшләүче кешенең улы, имеш, атасының револьверын ке-

сәсенә тыгып, мәктәп кичәсенә килгән булган. Араларында низаг нәрсәдән чыккандыр — Хода белсен! Җинаятьне тикшереп тору да, үтерүчене хөкем итү дә булмаган — шау-шусыз гына үткән дә киткән. Шакир кечерәк кенә таш кибет тотучы Зариф абзыйның улы иде, ләкин атасы аның үзеннән алдарак үлгән иде бугай... Бергә үскән тиңдәшләрне югалтулар әнә шулай бик иртә башланды.

Инде яңадан малай чакка чигенсәк, шуны әйтергә кирәктер: безнең бер дә урамнан кермичә көнозын биләмдә югалып йөрүебез атакай белән инәйне бик борчый, хәвефләндерә иде. Билгеле, алар безнең берәр бәлагә таруыбыз өчен генә түгел, эшсезлектән, күп йөрүдән азыптузып китүебез өчен дә куркалар иде. (Аларча әйткәндә, безне төрле «эт-коштан» бик саклыйсылары килә иде.) Әмма нихәтле генә борчылсалар да, вакыт-вакыт берәр гаебебез өчен ачулары бик килсә дә, безгә сукмыйлар иде. Инәйне инде әйткән дә юк, хәтта атакай да кул күтәрми иде. Тик бер генә тапкыр, мин көн буена каядыр югалып торып, кичкырын гына кайтып кергәч, ул, ниһаять, түзмәде — бик җилле генә минем яңакка салып җибәрде. Шуннан башка аның миңа бүтән чирткәне дә булмады. Ләкин алар икесе дә безне бик каты үгетли торганнар иде. Каршыларына утыртып, әйбәтләп аңлатырга тырышып, яхшы сүзләр белән ялвару катыш, шелтә катыш, инәй исә җылыйҗылый да без ике юньсезне үгетлиләр иде. Һәм бу кечкенә намусыбызга тия торган үгетләүләр миңа, мәсәлән, бик авыр тәэсир итә иде. Еш кына мин эчемнән, ник кыйнамыйлар — кыйнасыннар гына иде, ичмасам, дип үрсәләнеп тели дә торган идем... Кул җәзасы бит авырттырса да, ничектер, тиз онытыла, ә менә сүзнең тәэсире, юк, тиз генә онытылмый икән ул... Белмим, ата-ана нәсыйхәте ул чагында безне күпме генә төзәткәндер, әмма соңыннан, еллар узгач, искә төшергән чакларда, вөҗдан авазы шикелле, җанны борчый, үкендерә һәм уйландыра. Әйе, без, кызганычка каршы, ата-ана борчылуын еш кына бик соңга калып аңлый башлыйбыз.

Ләкин шулай да бичараларны борчый-борчый безнең күп йөрүебез файдага да булгандыр, ахрысы... Без бозылмадык та, азмадык та (димәк, үгетләүләр бушка китмәгән), әмма инде бөтен Дәүләкән әтрафын айкап йөрүдән дә туктап тормадык. Иртә яздан башлап кара көзгә чаклы!

...Менә берзаман Дим кузгала, Дим ярларыннан чыгып ташый башлый. Мәһабәт күренеш! Бер-ике көн тоташтан боз китә, боз өстендә печән чүмәләсе, тирес өеме,

берәрсенең кара мунчасы китә. Су арта-җәелә торгач, каршыдагы Көрмәнкәй тавына барып җитә. Тугайдагы әрәмәлекләрнең нечкә очлары гына күренеп тора. Җәенкышын тар ярларында бормаланып тын гына аккан елгабыз ташу вакытында әнә шундый мәһабәт көчле бер дәрьяга әйләнә!

Водокачка янындагы кояшка караган яр башы саркып кибә башлагач та, без шунда кузна уйнарга тотына идек. Бу — язгы уеннарның беренчесе, шуңа инде тиздән бүтәннәре дә ялганып китәчәк... Водокачка яры үзе дә минем өчен бик истәлекле урын — малай чакта гына түгел, үсеп егет булгач та, миңа бу урынны күп таптарга туры килде. Иң элек мин шуны хәтерлим әле — революциягә чаклы монда каталашка дигән алама гына бер ызба да тора иде. Дәүләкән «төрмәсе» — сукбайларны, хәерчеләрне, вак каракларны шунда китереп япканнар. Революциядән соң каталашканы туздырып ташладылар. Аннары мондагы яр башы Дим буйларына, аның киң тугайларына карап торыр өчен бердәнбер диярлек иркен-ачык урын да иде. Без инде ак күлмәк, кара чалбар киеп, билне зинар яки тар каеш белән буып йөрүче көяз егетләр булгач, башта вокзалга барып, берәр пассажир поездын озатып җибәргәннән соң, ашыкмыйча гына шушы водокачка ярына килеп, каршыбызда ачылган, еракларга җәелеп киткән тын, якты, гүзәл манзарага сүзсез генә күпмедер вакыт карап тора идек. Мин бу гадәтебезгә хәзер дә гаҗәпләнәм: көн дә диярлек шушы урынга килеп, яр башыннан карап тору безне ничек туйдырып бетермәде икән?.. Күрәсең, туйдырырлык булмаган Димкәй буйлары; күрәсең, үзенә тартып, бәйләп торган бу сихри манзара! Хәер, без моны шул чакта ук инде аңлый да идек, белә дә идек — аерылып китәчәгебезне, әмма мәңге оныта алмаячагыбызны белә идек.

Шулай ук җомга көннәрен егетләр-кызлар Дим өстендә гармун тартып, җырлашып йөрер өчен дә көймәләргә төялеп шушы ярдан кузгалып китә идек һәм әллә кайлардан әйләнеп, тәмам арып, әйтеп биргесез шатлык-канәгатьләнү кичереп, яңадан шушы ук яр читенә көлешә-көлешә кайтып төшә идек. Кайда калды ул чаклар? Кая китеп, таралып, югалып бетте ул егетләр белән кызлар?.. Кайткан вакытларымда япа-ялгыз водокачка ярына барып, Дим өсләренә тик кенә карап торам — сүз катар, искә төшерер өчен янымда көймәдә йөрүчеләрдән берәү дә юк, берәү дә калмаган...

Тукта, сүз малай чак турында иде бит әле... Язгы ташу турында иде.

Назланып, сазлар чиртеп,
Уйный-җырлый яз килә.
Яз килә!
Ямьләр ягыннан илгә
Аккош, каз килә.

. . . . . . . . . . . . . . . .

Кызганыч, Димгә аккошлар килми иде. Ә кыр казлары бик биектән каңгылдашып уза торганнар иде. Безнең тугай күлләренә кыр үрдәкләре килә, сазлыклырак түмгәкле урыннарга тәкәрлекләр килә — ефәк «мөгезле», нечкә тәпиле бик нәфис кош. Күп иде алар — килүче кошлар!.. Һавада, җирдә, суда — тик күрә бел дә ишетә бел!

Ә яз артыннан шул тынгысыз кошлар белән бергә безнең өчен дә бик озын җәй киләчәк. Безгә дә күпме «очарга», суларга чумарга, ялан-кырлар таптарга туры киләчәк... Ул заманда спорт-физкультура дигән нәрсәне белгән юк. Әмма шушы яшькә хәтле җитүне мин барсыннан элек әнә шул малай чакта кошлар шикелле өзлексез хәрәкәттә булудан күрәм. Һәм нинди һавада бит әле?! Эльбрус түбәсендә яткан кардан да чистарак — исе юк, төсе юк, белми идек без һаваның нәрсә икәнен дә! Саф тирес исен яратыбрак исни идек, чөнки аны тоеп-белеп була иде.

Аннары без җәй буена күпме поливитамин ашый торган идек. Җир ачылганнан алып беренче кар төшкәнчегә кадәр. Иң элек ташу китеп, тугайлар кибә төшкәч тә, каршыдагы болынга чыгып, букча тутырып, төче юа җыябыз. Юа яшь, йомшак, әчесе юк, без аны болай да ашыйбыз, кайткач ипи белән дә, куаска турап та ашыйбыз. Юадан соң кузгалак чәйнәргә тотынабыз. Әчкелтем, сусыл-тәмле. Кызганыч, ул чагында безнең инәйләр ашын пешерә белмәгәннәр (әллә теләмәгәннәр). Кузгалак артыннан бер-бер артлы төрле үләннәр китә, исемнәре инде онытылып та бетә язган, ләкин без аларның ашарга яраганын ярамаганыннан бик әйбәт аера белә идек. Ул арада какы, балтырган өлгерә. Имәнлеккә менеп, шуларны кочак-кочак җыеп кайтабыз. Ул да булмый, тугайдагы әрәмәлектә карлыган (карагат) һәм бөрлегән дә өлгереп җитә. Аз гына алданрак җир җиләге дә өлгерә. Кайсына барырга, кайсын җыярга? Әлбәттә, башта җиләккә, чөнки җиләк вакыты иртәрәк үтеп китә. Ә карлыган белән бөрлегәнгә соң түгел, куак төбе саен ишелеп ята, аларны ашый-ашый да авызлар камашып бетә иде. Тагын бер бик шәп витамин — бу әлморын (башкортча), ягъни гөлҗимеш! Ул көзгә таба гына өлгереп җитә, бик озак

кызара, ә беренче кыраулар өтеп алганнан соң балланып та китә. Хикмәтле җимеш! Без, Дим өсте туңгач, шуа-шуа аргы якка чыгып, гөлҗимешне куагыннан өзеп ашый идек. Җыеп бетергесез күп була торган иде. Кадерен белмәгәнбез. Җыеп киптермәгәнбез, әмма гомерлеккә җитәрлек итеп ашап калганбыз.

Шушы өч нәрсә — саф һава, өзлексез хәрәкәт һәм табигать җимешләре безне үстерде, саклады, чыныктырды. Мин моны сабый чактан исән калып, хәзер дә әле сау-сәламәт яшәүчеләргә карата әйтәм. Әмма моның өчен безгә сабый чакта «сират күпере»н кичәргә, ягъни һәртөрле йогышлы авырулардан котылып калырга кирәк булган. Хәер, соңрак та безне сагалаган төрле хәтәрләр аз булмады, әмма иң куркыныч-әшәкесе безнең ныгып өлгермәгән малай чагыбызга туры килде.

Менә 1921 елга да кердек. Елның башы — таза кыш. Ап-ак кар, юлдан чыксаң — тездән батарлык, чиллә вакытында гадәттәге каты суыклар да булды, февраль-март бураннары да котырып узды, кыскасы, елның килеше бер дә хәвефләндерерлек түгел иде ләбаса... Шулайрак саклана минем хәтердә егерме беренче елның кышы.

Көтеп алган яз да кичекмичә килеп җитте. Вакытында кары да эреде, бозы да китте, ташуы да булып узды, елан-кырлар да яшәрде. Табигатьтә бернинди тайпылыш юк, һәммәсе үз нәүбәтендә елдагыча килеп тора. Шулай хәтерлим... Халык чәчүгә төште, маллар көтүгә чыкты. Тик шушы вакытта беренче яңгырлар булып узды микән? Мөгаен, булгандыр, булмыйча калмагандыр... Чәчү өстендә бит еш кына суытып та җибәрә, салкын яңгыры да килеп җитә, хәтта кайчагында ап-ак кар да җирне каплап китә. Бу язын андый карны хәтерләмим, әмма салкыны белән беренче яңгырлары булып узгандыр — һәр иртә язда булмыйча калмый ул.

Ләкин шулай да халыкта елның килешеннән хәвефләнү кайчанрак башланды икән?.. Әйтүе бик читен, чөнки хәвефләнү алай тиз генә һәм кинәт кенә килми ул... Халык сабыр, халык көтә белә... Соңгы чәчүләр дә бетте, май да үтеп китте, җәйгә дә кердек. Беренче иртә яңгырлардан соң айга якын вакыт узды. Май аяз булды диярлек, июнь дә аяз тора, әгәр шуннан июль дә аязга китсә?.. Халык көтә, сораша, чуашлар нәрсә әйтә, төрле елларны исенә төшерә — бу инде чынлап борчыла башлау иде. Эткол урамының әле бер очында, әле икенче очында бала-чага, яшь-җилкенчәкләр куыша-куыша су сибешәләр, узып баручы мөхтәрәм абзыйларның да өстенә берәр чиләк

суны тондыралар — ачуланган кеше юк, тик яңгыр гына килсен!.. Ә кайбер авылларда халык, хәзрәтләре белән бергә, тәкбир әйтә-әйтә кырга чыгып, ятимнәргә карга боткасы пешереп, ничәдер рәкәгать намаз укып, Ходайдан яңгыр сораганнар, имеш... Шуннан соң Ходайның хикмәте, ботканы ашап бетерүгә, кинәт гарасат купкандай, күкрәп-яшенләп яңгыр килгән дә, ди, бөтен дөньяны иңләп, ишеп-ишеп яварга да тотынган, ди... Хәзрәтләр читек-кәвешләрен салып, ыштан балакларын сызганып, чапаннарын башларына каплап, манма су булып кайтканнар, ди... Әнә шулай ышанып сөйлиләр, сөйлиләр дә, аннары тыналар. Чөнки андый яңгырның якын-тирәдә генә түгел, бөтен өяздә дә булмавы иртәме-соңмы ачыклана торган иде.

Ниһаять, июльгә дә кердек, яртысына да җиттек... Җәй уртасы, чиллә башланды, күк йөзе әллә нинди кургашын төсендә, атналар буе анда бияләй хәтле генә дә болыт әсәре күренгәне юк. Кояш иртәнге сәгатьтән башлап кыздырырга тотына, көнозын аяусыз яндыра, көйдерә, ә кичен җирнең канын эчкәндәй кызарып-бүртенеп, ялкау гына тагын аязга бата. Димәк, иртәгә дә шушындый ук мәрхәмәтсез көн булачак.

Хәзер инде быелгы җәйнең тоташтан корыга китүе һәркемгә ачык иде. Бик хәтәр, бик шомлы!.. Бу инде ачлык килә, ачлык якынлаша дигән сүз. Аның галәмәтләре дә күз алдында: айларга сузылган корылыктан җир кара чуен шикелле яргаланып катты. Үләннәр күптән саргайды, кипте, корды — көтү йөргән җирләр тузанга әйләнде диярлек... Ач сыерлар көтүдән күзләре тонып, өйдәге азмы-күпме ризыкка йөгерә-йөгерә кайталар. Сарыкларның авызлары кара туфрак — алар җир кимерәләр. Әмма иң хәтәр-хәвефлесе — чәчкән игеннәрнең тәмам харап булуы иде. Берсе дә юк — көзге арыш та, язгы бодай да, арпа белән тары да. Сипкән орлыкны да алып булмас, диләр агайлар. Мин бик яхшы хәтерлим: бодай, мәсәлән, сирәк кенә чыгып, кашык буе үсәр-үсмәс катып калган иде. Җитмәсә, аның һәрбер ач башагын саранча сырып алган... Бу хәшәрәт шул җәйдә генә, каяндыр болыты белән килеп, кырларны тоташ баскан иде. Үзе эре, үзе соры, үзе һичнидән курыкмый — узып барышлый чыбыркы белән суксаң, башак белән бергә сынып төшә, әмма очып китәргә уйламый да... Аннары шушы кипкән, беткән басуларны да чүп үләне басып киткән иде. Дәүләкән тирәсендәге күп кенә басуларны аерып та булмый — әллә чәчелгән җир, әллә кысыр яткан кыр?! Тик немецларның гына кырларын танып була,

чәчелгән кадәресе болай чиста гына, ләкин барыбер сирәк, ач башаклы... Кыскасы, ипекәй булмаячак, ачлык һәр йортның капкасы төбенә килгән иде инде.

Бәхетсезлек җитәкләшеп йөри дигән сүз бар. Бу бигрәк тә быелгы шикелле афәтле елларга туры килә дә икән. Авылларда әледән-әле зур янгыннар чыгып торуы шуның бер мисалы. Ут ялап кына алды — якынына барырлык та булмады, дип сөйлиләр. Һәм гаҗәп тә түгел. Җитмәсә, менә шушы коточкыч эссе корылыкка ияреп, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаять куркыныч бер үләт — ваба (холера) чире безнең Дәүләкәнгә каяндыр килеп керде. Ярый әле артык озакка бармады, шулай да күп кенә йортларга кереп чыгарга өлгерде. Безнең әбекәйне алып китте, күршебез Сәлимҗан агайны, Габдрахманнар әтисе Хәсән абзыйны алып китте. Көн дә мәчет ихатасында җеназа укыйлар, көн дә салмак кына чиркәү сугалар... Әмма гаҗәбе шул — бу үләт ни сәбәптер гел олыларны, карт-корыларны чүпләде, ә менә безнең ише малайларга тимәде диярлек, һәрхәлдә, мин белгәннәрдән берәү дә китмәде.

Әнә шулай үтте яки үтеп тә бара инде бу һич онытылмас фаҗигале җәй! Тарихта үзенең кара урынын алган, халык хәтерендә гомерлеккә сакланып калган «егерме беренче ел ачлыгы»ның башы иде инде бу! Ләкин ачлык үзе ни дәрәҗәдә көчле, каты булачак — ул кадәресен берәү дә белми иде әле... Ел нинди генә булмасын, җәй бит әле, яланнардан нидер табып була, азмы-күпме бәрәңгесе, яшелчәсе бар, сыерлар чәйлек, аш пешерерлек кенә булса да, сөт бирә, тавыклар күкәй салгалый, әле чынлап ачыккан кеше дә юк... Мин моны үзебезнең хәлдән дә беләм. Дөрес, безнең бер таяк та чәчкән, утырткан нәрсәбез юк, ләкин без дүрт кенә тамак, сыерыбыз бар, тавык, үрдәкләребез бар. Билгеле, атакай да тик ятмый. Хосусый сәүдә тыелган булса да, базарлар элеккечә һаман булып тора, анда кулдан гына нидер саталар, алалар... Атакай күбрәк менә шунда анысын алып, монысын сатып дигәндәй, хәрәкәт итә... Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр бит...

Быелгы урып-җыю әллә булды, әллә юк — аны күрми дә калдык. Элекке еллардагы шикелле арбаларга төялеп уракка китүләр, ындыр табакларына фурман тутырып көлтә ташулар бөтенләй булмады да... «Игеннәр» урак белән дә, машина белән дә урып алырлык түгел иде. Аны күп урында кул белән йолкып кына алдылар. Бары немец утарларында гына косилка тавышы ишетелгәләде — анда ашлык чалгыга әләгерлек булган, дип сөйләделәр. Аларның кыр-

лары бушагач та, кайбер хатын-кызлар капчык алып, шунда башак җыярга йөри башладылар. Башак җыю беренче мәртәбә, бәлки, шул елны башлангандыр да, чөнки элек мондый эшне ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Бу җәйнең һич көтелмәгән тагын бер хикмәте — ул да булса шушындый корылыкта алабута котырып үсте. Бернәрсә юк, бөтенесе янды-көйде, хәтта читән буендагы кычыткannар да, ә ул, хөрмәтле алабута, бөтен ташландык кырларда урман-урман булып утыра! Гүя табигатьнең адәмнәргә күрсәткән соңгы шәфкате иде бу... Һәм адәмнәр аңа шунда ук игътибар иттеләр, тизрәк җыеп алдылар, орлыгын уып киптерделәр, җилгәрделәр... Элек халык мәкале «Алтын-көмеш — таш булмас, алабута — аш булмас» дип әйтә торган иде. Хәзер исә шул ук халык моны нәкъ киресенә әйләндерде дә куйды: «Алтын-көмеш — таш, имеш, алабута — аш, имеш!..» Әйе, шушы кара-яшькелт әче бөртек ул елны бик күпләр өчен бердәнбер ризык булды.

Чын ачлык әле килеп җитмәгән иде, ул тик көннән-көн якынлаша, аңардан котылып булмаячак — инде нишләргә?.. Ничек итеп алдагы елның икмәгенә чаклы җан асрарга?.. Башак җыеп, алабута киптереп кенә торып булачакмы?.. Бигрәк тә бала-чагасы ишле семьяларның хәле бик мөшкел. Нинди котылу чарасы бар?.. Ярый, нидер чәчкән кешеләр бик аз гына булса да бөртек җыеп алдылар, бәрәңге утырткannарның күпме-азмы бәрәңгесе булыр, аяклы малы барлар, көннәр суыткач, малларын суярлар... Ләкин бит Дәүләкәндә берни чәчмәгән, утыртмаган, бер кәҗәсе дә булмаган кешеләр дә аз түгел.

Шундыйларның берсе — тимерче Миңнегали карт. Дөрес, аны фәкыйрьләрдән санап булмый, эше күп, алачыгында чүкеч тавышы тынып тормый, димәк, яшәрлек килере бар. Әле күптән түгел, яр башындагы йортын сатып, безнең каршыдагы урамда яңа йорт та торгызып керде. Ялгышмасам, сыерлары да бар иде шикелле. Ләкин картның гаиләсе зур, бала-чагасы күп иде. Өчесе әле бик яшьләр — ачлык алар өчен аеруча куркыныч булачак... Хәзер инде тимерчелек эше көннән-көн бетә бара, акча юньләп керми, бернинди запаслары юк, билгеле. Миңнегали карт нидер уйларга тиеш иде. Аның зур улы Зөфәр белән зуррак кызы Маһирә җәй ахырыннан ук немец басуларына башак җыярга йөри башладылар. Ләкин бу инде, бичарадан ни чара дигәндәй, бушка әлсерәп йөрү генә иде. (Ач башактан нәрсә чыксын, Ходаем!)

Без элек тә алар белән якын күрше идек, хәзер дә күршеләр дип әйтерлек, һәрвакыт бергә аралашып яшә-

дек. Ике гаиләнең дә йорт башлары бер-берсен хөрмәт итәләр һәм еш кына үзара киңәшләшә дә торганнар иде. Һәм шушы бик хәвефле чакта, Миңнегали карт, тәмам аптырауга төшеп, үзе безнең атакай янына килде:

— Нишлибез, Нигъмәтҗан, эшләр харап бит! — диде ул, чал йөгергән кара сакалын учлап.

— Әйе, эшләр шәптән түгел, Миңнегали абзый,— диде атакай да, авыр көрсенеп.— Ни күрергә язгандыр инде?!

— Күрәчәгебез — ачык. Тик шуңардан ничек котылырга, ә, күрше?! Шуны әйтсәң иде син миңа!

Алар, безнең бакча рәшәткәсе буена чүгәләп, әнә шулай сөйләшеп киттеләр. Мондый чакта күпме генә уйлама-сөйләшмә, дөрес бер карарга килүе бик читен булырга тиеш. Чынлап та, юкны кайдан табарга? Шулай да атакай, сөйләшә торгач, ахырда Миңнегали картка әйтте: әйдә, булмаса, Себергә таба барып карыйк, анда әле туклык, азмы-күпме азык алып кайтырбыз, диде.

Билгеле, минем атакай — күп йөргән кеше, Себер ягын да яхшы белә, аңа ерак юлга чыгып китү әллә ни хәтәр эш түгел. Әмма Миңнегали картның үз гомерендә Дәүләкәннән беркая да аяк атлап чыкканы юк, хәтта туксан чакрымдагы Уфаны да барып күргәне юк, шул сәбәпле аның өчен Себер хәтле Себергә чыгып китү бик зур тәвәккәллек сорый торган гадәттән тыш бер вакыйга булырга тиеш иде. Ул, әлбәттә, шунда ук ризалык белдермәде, тирән уйга төште, торып-торып авыр сулады, кайтып, карчыгы, балалары белән киңәшеп карарга булды. Ләкин барыбер күпмедер вакыттан соң, башка чарасы калмагач, ниһаять, тәвәккәлләде карт!

Әйбәт кенә җыендылар, бар кадәренчә ризыкларын алдылар, азыкка дигән кадерле акчаларын ерак яшерделәр, шуның өстенә капчыкларына иске-москы киемнәр дә салдылар. Шулай итеп, ике күрше шәрә көзнең салкын бер көнендә, узгынчы товар поездына эләгеп, Себер тарафларына китеп тә бардылар. Ул чакларда йөрүләр әнә шулай иде: кайчан, ничек, нәрсә туры килсә, шуңа утыралар да китәләр. Юлда ни була, исән-сау барып җитәрләрме, бәлаказасыз гына кайтып керерләрме — моны алдан белүче юк. Өйдә калучылар, күпме вакыт үтмәсен, сабыр гына көтәргә тиешләр. Без инде моңа өйрәнгәнбез. Ләкин Миңнегали карт семьясы ут эчендә иде бугай... Гомерендә Әлшәй[1] базарына да чыкмаган кеше әллә кайдагы Себергә

---

[1] *Әлшәй* — Дәүләкәннән унсигез чакрымдагы базарлы авыл. Станциясе Раевка дип атала. Район үзәге. Элек Әлшәй базары дүшәмбе, ә Дәүләкән базары сишәмбе көн була торган иде.— *Ә.Е.*

китеп «югалсын» әле!.. Шулай да алар икеме-өчме атна йөреп, Петропавловскига хәтле җитеп, шуннан исән-сау Дәүләкәнгә әйләнеп кайттылар. Юл азабын күп күргәннәр, әмма барулары бушка китмәгән — үзләре белән күтәрә алган кадәр ит һәм карындыкка тутырган куй мае алып кайтканнар иде. Әйтәсе дә түгел, атайларның шундый кадерле ризык белән исән-имин кайтып керүләре ике гаилә өчен дә зур бәйрәм булды. Бигрәк тә Миңнегали карт өендә корбан гаетендә дә мондый бәйрәм булмагандыр, шәт! Киң сәке түрендә көрәк сакаллы карт үзе, ике яклап тезелешкән җидеме-сигезме уллары һәм кызлары, каршысында карчыгы Сабира җиңги, ә табын уртасында зур шава[1] белән хуш исләр тараткан симез итле, кара чумарлы шундый тәмле тансык аш! — йә, моның ише сыйны кайчан күрерләр иде әле алар?! «Нигъмәтҗан абзыйга рәхмәт инде — тәки йөртеп кайтарды бит картны!..» Ә карт Себернең туклыгына, ит-маеның күплегенә шулкадәр хәйран калган — балаларына сөйләп кенә дә бетерә алмый икән. Һәм бу ерактагы туклык аны харап та итә язды. Ул, баксаң, Себергә семьясын алып китү нияте белән кайткан икән. Билгеле, семьяда бу турыда сүз күп була. Себернең итенмаен авыз иткән һәм аталарының мактап сөйләвен ишеткән балалар моңа бик шатланып риза, хет бүген үк чыгып китәргә әзер торалар. Әмма картның зуррак уллары алай ашыгып ризалыкларын белдермиләр. Бигрәк тә карчыгы борчыла, икеләнә, аңа яңарак кына тора башлаган өе жәл,— итәк тулы балалары белән җылы оядан бер дә чыгып китәсе килми. Карт үзе дә чамалый, аңа Себердәме яки кире монда кайтыпмы, яңадан йорт-җир торгызуы җиңел булмаячак. Шуларның барсын да исәпләп, карт, ниһаять, соңгы сүзен әйтә: йортын хәзергә сатмаячак, уллары Муллагали белән Зөфәр монда калачак, алар инде үзләре дә тимерчелектә бик әйбәт эшлиләр, иншалла, ат дагалап булса да, тамакларына таба алырлар. Ә менә бу бер табын бәләкәйләрне коткарырга кирәк. Шуңа күрә ул хәзергә әле карчыгы белән шушы балаларын гына алып китәчәк. Анда, әйтик, шул ук Петропавловскида аның һөнәре белән тамаклары ач булмаячак. Калганы исә Алла кулындагы эш. Бу афәтле елны исән-имин үткәреп җибәрә алсалар, йә үзләре кайтырлар, йә барсы да яңа урында тупланып, шунда калырлар.

Әнә шулай мәсьәләне хәл иткәннән соң, алар ашыкпошык җыенып, балаларны ни бары белән җылы киендереп, төеннәрен һәм капчыкларын күтәреп, ноябрьнең

[1] *Шава* — зур агач табак.

җепшек кар явып торган болганчык бер иртәсендә Дәүләкән вокзалына чыгалар. Күрше-тирәдән озата төшүчеләр дә байтак кына — тимерче картның бөтен оясы белән диярлек ерак сәфәргә күтәренеп чыгуы үзенә күрә бер вакыйга!.. Ул чакта поездларның кайчан киләсе билгеле түгел (расписание дигән нәрсә дә юк иде шикелле), нинди поездга ничек эләгеп китәсен берәү дә белми, шуңа күрә көнозын сагаларга кирәк. Озата төшүчеләр саубуллашып һәм бәхилләшеп берәм-берәм китеп бетәләр. Болар сабыр гына көтәләр, көн уза, кич җитә, вокзал эче төенле-капчыклы халык белән шыгрым тулы — энә төшәр урын да юк. Арыган-талчыккан балаларын йоклатып чыгар өчен кире өйләренә кайталар. Икенче көнне дә, өченче көнне дә шул ук хәл кабатлана — ничә тапкыр чыгып, ничә тапкыр кайтырга мәҗбүр булалар. Ахырда карт күрә: әйе, китеп булырлык түгел икән, соңгарак калган икән шул!.. Халык купкан, халык ачлыктан кача! Шушы бәләкәй генә Дәүләкән станциясенә дә тирә-як авыллардан ничәмә йөз халык килеп тыгылган. Кайсылары — Себергә, кайсылары — Ташкент ягына (болары күпчелек). Ә юлларда — мәхшәр!.. Сирәк кенә узгалый торган пассажир поездлары тамбурларына хәтле тулып килә, шуңа карамастан халык ташлана, андагы талаш-тартыш, җылау-чинау — якын барырлык та түгел! Күпләр товар поездына эләгеп, аның да вагон түбәләренә менеп, ә кайбер ялгыз-кыюлар ике вагон арасына да утырып китәләр. Менә шушы мәхшәрне берничә көн рәттән күзәткәч, Миңнегали карт, ниһаять, кулын селти: юк, булмый, Ходай җылы оябыздан аермасын, ди дә, бала-чагасын ияртеп, вокзалдан бөтенләй кайта да китә.

Бәлки, бу хәерлегә дә булгандыр. Юллар бик начар, бик куркыныч. Коточкыч тыгызлык, пычрак-шакшы, тифның беткәне юк. Кешеләр вокзал идәннәрендә, вагоннарда үләләр. Талау, урлау, бер-берсен югалтулар булып кына тора. Әле шушы кечкенә Дәүләкән станциясендә дә вак караклар башы-күзе тонган халыкның әйберләрен күз алларында урлап китәләр. Бездән түбән яр астында торучы Сөбханкул исемле бер кара малай көн саен диярлек вокзалдан караңгы төшкәндә генә берәр капчык яки кәрзин күтәреп кайта торган иде. Урлаганын яшереп тә тормый, киресенчә, мактанып сөйли генә... Әнә шулай Дәүләкән вокзалында күпме тәүлекләр аунап ятып-ятып та, поездларга эләгә алмыйча, әйберләрен урлатып, кире өйләренә яки авылларына кайтып китүчеләр дә аз булмады. Миңнегали карт, ичмасам, андый казага дучар булмыйча гына бу «һиҗрәт»тән торып калды.

Без хәзер «егерме беренче ел ачлыгы» дип сөйлибез һәм язабыз. Әйе, бу дөрес, ачлыкны егерме беренче ел китерде, әмма чын ачлык үзе егерме икенче елның кышына һәм язына туры килде. Бөтен нәрсәне яндырган-көйдергән коры җәйнең ахыры ачлы-туклы булса да, ничектер үтте, ә менә кышка кергәч, ачлыкның шәрә сөяк куллары халыкны чынлап торып бугазыннан буып алды дияргә ярый. Хәер, ачлыкны күрмәгән яки күрсә дә, җиңел үткәргән кешеләр дә, билгеле, булды. Болар элекке елның икмәген ашап бетермәгәннәр (мәсәлән, безнең күрше Арыслангәрәй агай кебекләр), шулай ук хәле җитеп алдан запас хәстәрләгәннәр... (Ул көзне азык юклыктан мал бик күп суелды. Шул чакта һәркем ничек тә булса күбрәк ит алып калырга тырышты. Безнең атакай да бер чибәр генә тана түшкәсе алып куйган иде.) Әмма иң кирәге, иң заруры, иң кадерлесе шулай да икмәк икән!.. Икмәк белән генә кеше тук, икмәк кенә кешене ач үлемнән саклап кала икән! Ә икмәк юк, ашарга түгел, иснәп карарга да юк... Әгәр кайдадыр, кемдер кулында бодай яки арыш булса, ул инде дөньяның иң бай кешесе... һәм андый байлар да бар иде бугай, чөнки бер пот арыш онына ачтан интегүченең таза келәтен яки ярты ызбасын сатып алучылар да булды. Аннары Дәүләкән базарына да чыккалый иде он дигән нәрсә, ләкин дә инде ул онны кесәсе тулы алтыны булган кеше генә алса ала алгандыр. Кыскасы, икмәк юк. Шуңа күрә икмәксез елны «ачлык елы» диләр дә.

Ул елны икмәк урынына йөри торган бердәнбер ризык, әйткәнемчә, алабута булды. Алабутаны бөтен халык ашады. Без дә аны кыш буе ашадык. Әмма ләкин алабутаның бары үзеннән генә пешерелгән кап-кара «икмәк» ашар өчен бик әче, бик тәмсез һәм туклыклыгы да юк дәрәҗәсендә аз. Өстәвенә үзәкне көйдерә, саруны кайната, эчне дә бозып бетерә. Аңа ни дә булса, мәсәлән, бәрәңге яки тары оны кушарга кирәк — шул чакта гына аны икмәк итеп ашап була. Тик кайдан алырга бәрәңге белән тарыны?

Безгә алабутаның үзен дә, аңа кушарлык тары онын да Ташлыкүлдән Кашшаф җизни китерә торган иде. Ташлыкүл бөтен тирә-якта бердәнбер тугырак авыл булгандыр, ахрысы, ә Кашшаф җизни бик ярдәмчел бер кеше иде, мәрхүм!.. Кыскасы, без алабута ашарга мәҗбүр булсак та, хәтәр кышны ачыкмыйча гына уздырып җибәрдек.

Ачлыктан тормыш сүнә, кешеләр сүнә. Мин бик яхшы хәтерлим, мәсәлән, малайлар арасында бергә уйнаулар бетте. Җәй көннәрендә элеккечә көтүебез белән тугай-

ларга чыгып, сулар кереп йөрсәк тә, көзен инде, бигрәк тә кышка кергәч, җыелышып шар сугулар, шаулап чана шуулар тынды, тукталды. Якын-тирәдәге дусларым юньләп урамга да чыкмый башладылар. Аларның инде кайберләрен ачлык әкрен генә буа да башлаган иде. Тугырак яшәүчеләр дә өйләреннән чыкмыйлар — куркалармы, ачларны күрәселәре килмиме — аңламассың...

Мин үзем урам аша каршыда гына торган Габдрахманнарга ара-тирә кергәли идем. Алар ишле семья, әниләре Бибикамал апа белән җиде җан, ә этиләре Хәсән абзый холера вакытында үлеп киткән иде. Хәсән абзый — вак сәүдәгәр, кайчандыр җиләк-җимеш белән сату иткән, ишле булсалар да әйбәт, тук торганнар. Хәзер, йорт башы үлеп киткәч, алар бик тиз бөлгенлеккә төштеләр һәм бик иртә ачыга да башладылар. Зур уллары, бик көязләнеп йөрергә яратучы Ибраһим абый, ул чагында кайда булгандыр — хәтерләмим. Аңардан кечерәк Таифә апа китапханәдә эшли иде. Калганнары ике кыз, ике малай — ваклар, тик Габдрахман гына минем чамада. Менә шул ваклар барысы да ачтан шешенделәр. Эчләре күпкән, битләре өртелгән, әллә нинди ямьсез күксел төскә кергәннәр. Әкрен генә кыймылдыйлар, үзара әкрен генә сөйләшәләр, күбрәк ятып кына торалар. Ләкин арада иң ачыкканы Габдрахман булды шикелле, чөнки ул, уникe яшьлек малай, элек тә ашарга комсыз иде, йөргәндә дә гел ни дә булса чәйни иде, аннары бөтен нәрсәне, мәсәлән, төрле үләннәрне тәмләп карарга ярата — яраса, ашый, ярамаса, төкереп ташлый иде. Ә хәзер көннәр буе ач, тәрәзә каршына баскан, урамга тик карап тора. Ул шешенү генә түгел, әллә ничек картлар сыман булып киткән, авыз тирәсе җыерчыкланган, битенә бала төкләре бәреп чыккан иде. Мин җиң эченә яшереп кенә аңа чуенда пешкән берәр бәрәңге яки он кушылган алабута икмәге керткәләдем. Ул шуны, мине озатырга чыккан булып, өй алдында гына ашый иде. «Әни биргән генә миңа җитми шул» дип һаман зарлана иде... Шулай да Бибикамал апа балалары ачлыкны ничектер кичерделәр, берсе дә үлмәде, барысы да исән калды.

...Себергә ычкына алмыйча калган Миңнегали карт семьясы да ачлыктан бик интекте. Якын торгач, Зөфәрне күргәли идем, беткән егет, сөяккә генә калган, йөзе дә күм-күк — бала төге басып бетергән. Аңа бит инде унҗиде яшь, туярлык ашар өчен берүзенә генә күпме кирәк! Ничек әле чыдый диген!.. Ә кечеләре Санияләр, Әхтәмнәр?.. Хәер, ни хәлдә ятканнарын әйтә дә алмыйм — яннарына керергә уңайсызлана идем. Миңнегали карт

үзе дә бик бетеренде, әмма чүкечен кулыннан төшермәде. Алачыкларыннан тимер чүкегән тавыш гел ишетелеп тора иде. Ул бит татарлардан бердәнбер тимерче — ачлык вакытында да аңа эш бетеп тормаган, күрәсең... Һәм шушы аларны ач үлемнән коткарды да булса кирәк.

Әйткәнемчә, ачлыкның иң рәхимсез чагы егерме икенче елның кышына һәм яз айларына туры килде. Дәүләкән урамнарында өйдән өйгә кереп, хәер сорашып йөрүчеләр бик күбәйде. Болар барысы да диярлек тирә-як авыллардан килгән ачлар. Һәм иң гаҗәбе — нәкъ менә авылларда ачлык отыры каты булды. Ә Дәүләкән — тимер юл буенда, бөтен әтрафның ашлыгы бирегә агылып килә иде, байлары да күп иде заманында, ат аунаган җирдә төк кала дигәннәр — менә шушы өмет ул бичараларны куып китергән дә булса кирәк. Әмма ләкин Дәүләкән үзе ач, үзе бер кабым сыныкка тилмереп утыра, инде азыклырак кешеләр бар икән, аларның капкалары көнетөне биктә. Һәм шул капкаларга сугылып, көчкә генә сөйрәлеп йөргән хәер эстәүчеләр ахырда урамда ук егылып үлә торганнар иде. Әгәр дә берәрсенең ишегалдында егылып үлә калса, аның гәүдәсен дә урамга чыгарып ташлыйлар иде. Моны гаеп итүче дә юк иде шикелле, чөнки урамда яткан үлекләрне махсус тәгаенләнгән кешеләр җыеп алып, каядыр илтеп күмәләр иде.

Бу ачлыкның бөтен хикмәтләрен сөйләп бетерерлек түгел. Мин әле бер Дәүләкән хәлләре турында, аның да үзем күргән һәм истә калганнарын гына сөйлим. Ә бит коточкыч ачлык бөтен Рәсәйне Уралга чаклы «биләп» алган иде. Мондый зур территориядәге ачлык төрле җирдә төрлечәрәк булгандыр, билгеле, әмма иң авыр-катысы Идел (Волга) белән Урал арасына туры килгән иде бугай... Һәм шушы регион эчендә дә төрлечәрәк үткәндер инде ул фаҗига... Безнең Дәүләкәнгә килгәндә исә, әйтергә кирәк, аның үзендә дә һәм әйләнә-тирәсендә дә ачлык бик көчле булды. Бик күп халык читкә качты, йортында калганнар исә ачтан кипте, корды, бик күбесе бер сыныкка тилмереп үлде дә... Адәм баласы ниләр генә ашамады ул кышны!.. Урамнарда этләр, мәчеләр калмады, хәтта балалар югалу турында да сүзләр чыккалады. Монысына никтер ышанасы килмәде, ахрысы, күңел кабул итмәгәндер, аннары каяндыр, читтән, ерактан килгән сүзләр иде алар... Әмма Дәүләкәннең үзендә булган икенче бер нәрсәне мин һич тә оныта алмыйм — бик нык уелып, утырып калды ул минем хәтердә!.. Бу — самосуд дигән нәрсә. Мин моны үз күзем белән күрдем. Ул елны, билгеле инде, урлаулар күбәйде, кеше келәтенә төшү, абзар-

дан сарыгын яки кәҗәсен урлап сую, ә базар көннәрендә агайларның йөкләреннән берәр нәрсәсен чәлдереп киту гадәти бер эшкә әйләнде. Менә шуның өчен урлаучыга бер генә хөкем — самосуд! Эләккән каракны милициягә биреп тору юк, базар халкы тоталар да гөр килеп вата башлыйлар. (Милиция ул чакта бик аз булды микән — нишләптер күренми дә иде.) Бу бик кансыз кыйнау, ерткычларча кыйнау... Ничек башлана ул?.. Әкрен генә чайкалган базар мәйданында менә берзаман, кинәт көчле өермә купкандай, халык шау-гөр килеп бөтерелә башлый. Кемнедер тотканнар!.. Барсы да шунда таба йөгерә, урлаганын күрсә-күрмәсә дә, «карак»ка ташлана, кулына ни эләксә, шуның белән ватарга тотына. Эләккән кеше уртада орчыктай бөтерелә, әйләнә-тулгана, башын-битен сакларга тырыша, баштарак: «Ай-ай, нишлисез, агайлар? Туктагызчы, агайлар!» — дип кычкырып та карый, аннары бераздан тавышы өзелә-тына, бары дөп тә дөп суккан тавышлар гына ишетелеп тора.

Бервакытны минем алдымда Иске Көрмәнкәйнең Хәйдәр исемле егетен шулай эләктереп алып тукмый башладылар. Ул озын, таза егет иде, кемнәрнедер селтәп тә ыргытты, ләкин базар уртасында котырган халыктан ычкынып буламы соң?! Урлаганмы, нәрсә урлаган — күргән-белгән кеше юк, ә тукмаучылар инде этләр өере шикелле Хәйдәрне урап та алдылар. Менә, мәсәлән, чабата-чыпталар сатып торучы Яшел Ибрай дигән кеше, тавыш купканны ишетү белән, чанасыннан озын күсәк суырып алды да, изге бер эшкә ашыккандай, тизрәк шунда таба чапты. Ул инде шул күсәге белән «карак»ка бер-ике тапкыр тондырмыйча әйләнеп килмәячәк.

Мондый кыйналудан бик сирәк кеше исән кала, күп вакытта үлек гәүдәсен ташлыйлар да китәләр. Җавап бирүче юк, җавап бирүчене табып та булмый, чөнки бу самосуд — бөтен базар аңа катнашкан. Ләкин Хәйдәр ниндидер могҗиза аркасында исән калган иде. Соңыннан әле ул Көрмәнкәйдән безнең спектакльләргә дә килеп йөрде. Ярата иде егет «уен» карарга. Ә менә Дәүләкәннең үз егете Нәгыйм белән «эшне» тиз бетерделәр. Аны, бичараны, базар мәйданына якын гына бер йортның ишегалдыннан котырган халык дөмбәсли-дөмбәсли алып чыкты. Имеш, шул ишегалдында урлап суелган кәҗәнең тиресе табылган... Нәгыйм утлы табада биегәндәй зыр-зыр бөтерелә, үзе ачы тавыш белән: «Юк, минем гаебем юк, агайлар!» — дип үкерә... Шул чакта кемдер артыннан йөгереп килде дә моның башына таза күсәк белән берне кундырды да... Егетнең өстенә әйтерсең бер чиләк канны

коеп җибәрделәр — бөтен алды-арты буйлап шыбырдап акты да китте. «Аһ!» дип кенә өлгерде Нәгыйм һәм шунда ук башын учлап җиргә дә чүкте.

Баштарак мондый самосуд күренешләре мине әллә ничек миңгерәүләтте, өнсез итте, гүя ирексезләп-көчләп үзенә бәйләде. Әмма бер-ике «тамаша»дан соң мин инде бу ерткычлыкны күрә дә, күтәрә дә алмый башладым. Базар эчендә берәр шиклерәк тавыш-гауга куба башлау белән үк, ак-караны күрмичә, тизрәк үзебезгә таба чаба торган идем... Тәмам авыруга сабыштыра язды ул «самосуд» дигән нәрсә мине... Еш кына бизгәк тоткандай калтырануымны тыя алмыйча азаплана идем.

Ә хәзер адәм баласының ерткычлыгына алай ук исем китми. Ерткычлыкның җир йөзендә бер генә көн дә бетеп торганы юк. Менә алтмыш ел буена мин аны күреп, күрмәсәм — ишетеп киләм. Әмма ләкин дә кешенең үзе кебек кешегә, бигрәк тә химаясыз җан ияләренә күрсәткән ерткычлыгына мин бервакытта да ияләшә алмадым, алмыйм һәм алмаячакмын!.. Табигатем башка минем...

Хуш, тагын ниләр минем хәтердә саклана? Алтмыш елдан соң искә төшерүләре бик читен, бик күбесе, әлбәттә, онытылган. Бары тирән эз калдырганы гына сакланган. Һәм әнә шундый тирән, әмма яхшы эз калдырган тагын бер вакыйганы беләм мин. Ул да булса Совет дәүләтенең ачларга ярдәме! Әгәр дә бу ярдәм килеп җитмәсә, ачлыкның корбаннары, һичшиксез, тагы да күбрәк булачак иде.

Иң элек шуны әйтергә кирәк, бик авыр-фаҗигале ел булуга карамастан, мәктәпләрдә укулар бетеп тормады — ач балаларның килә алган кадәресен ач укытучылар һаман әкрен генә укыта бирделәр. Егерме беренче елның көзендә безне тагын икенче урынга — русларның элеккеге «городское начальное училище» дигән асты таш, өсте агач зур бинасына күчерделәр. Укуларыбыз хәзер иркен, якты классларда бара, укытучыларыбыз да берәү генә түгел — төрле фәннәрдән берничә. Хәзер инде бик куанып, рәхәтләнеп укыйсы иде дә бит, тик менә каһәр суккан ачлык... Белмим, укуларны без язга чаклы суза алган булыр идек микән, әмма — мең шөкер! — кыш уртасыннан безне мәктәптә бер тапкыр ашату башланды. Кайдан килде бу изге ярдәм? Дәүләкәндә 1918 елда ук оештырылган потребкооперация җәмгыяте бар иде. Менә шул кооперациянең зур таш магазинында ниндидер «Ар» дигән оешма исеменнән ачларга азык бирә башладылар. Кемнәргә нинди азык һәм күпме биргәннәрен хәзер инде әйтә алмыйм, ләкин мәктәп балалары өчен шуның кухнясында пешерелгән ап-ак икмәк, дөге бот-

касы һәм бик тәмле какао биреп җибәрәләр иде. Көн саен берәр укытучыбыз өч-дүрт малайны ияртеп әлеге таш магазинга бара иде дә безгә дигән икмәкне чиста капчыкка, ә ботка белән какаоны капкачлы савытларга салып, чана белән тартып алып кайта иде. Шуннан соң түземсезлек белән көтеп алган шул гаять тансык ризыкларны безгә бик тигез генә итеп бүлеп бирәләр. Безнең хәзер букчаларыбызда кашык-савытларыбыз бар — менә шуңа салдырып алабыз да бер бөртеген дә әрәм итмичә ашап, ялап куябыз.

Бу көненә бер ашау... Бәлки, ул ашау безнең кече телебезгә дә йогар-йокмас кына булгандыр, әмма шушы ашау аркасында бик күпләр ач үлемнән котылып калды...

Ике елдан соң Ленин вафат булгач, балалар теленә ничектер үзеннән-үзе «Ленин бабай» дигән сүз кереп китте. «Ленин бабай»га багышлап шул чакта күпме шигырь язылмады, күпме җыр чыгарылмады! Ачлык фаҗигасе әле онытылып бетмәгән иде, аны кичергән балалар да һаман әле шул ук балалар иде. Миңа калса, «Ленин бабай» дип бик якын, үз итеп дәшүдә әнә шул балаларның да бөек юлбашчыга эчкерсез тирән рәхмәтләре, һичшиксез, ишетелә иде.

Егерме беренче ел ачлыгы табигый буларак безнең әдәбиятта да чагылмыйча калмады. Әмма аның иң фаҗигале, иң ачык-шәрә күренешләре Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» исемле әсәрендә тасвир ителгән иде. Әнә шул артык «натуральный», артык берьяклы булуы өчен ул әсәр үз вакытында каты гына тәнкыйтькә дә юлыкты.

Егерме беренче елның рәхимсез корылыгыннан соң килгән егерме икенче елның җәе гаҗәпләнеп бетмәслек һәм сокланып туймаслык булды. Менә алтмыш елдан артык инде мин аның кебек җәйнең булганын белмим, хәтерләмим... Күпмедер охшаганы булгандыр, бәлки, әмма теге җәй шикелле күңелдә сакланып калганы юк, булмады... Ихтимал, бик зарыгып көтеп алганга күрә ул безгә шулай гадәттән тыш ямьле, ягымлы, бәрәкәтле булып күренгәндер дә... Юк, аның өчен генә түгел!

...Ничегрәк килде соң егерме икенче елның җәе?.. Язлар җитеп, кошлар килгәч һәм җир яшәргәч, майның урталарыннан ук көннәр ничектер озакка утырды. Көндезләрен җилсез, аяз, ә төннәрен җылы яңгыр явып үтә. Бу һәр көнне диярлек шулай кабатлана — кичтән күк читендә болытлар кабара, төнлә ашыкмыйча гына килеп, шифалы яңгырын сеңдереп кенә коеп китә, ә иртән күк

йөзе офыктан офыккача чалт аяз, дөнья тагын ялт иткән! Кояш тигез генә кыздыра, курай селкенерлек тә җил юк, ә җир рәхәткә талгандай тирләп, парланып ята. Агачлар, үләннәр, чәчкән-утырткан нәрсәләр барсы да парниктагы шикелле күзгә күренеп үсә-күтәрелә... Әнә шундый җәй килде ул елны тәмам арыккан, интеккән табигатькә һәм бөтен җан ияләренә!

Безнең ишегалды электән үк тап-такыр җир иде, менә шул такырны да бәбкә үләне басып китте. Моңарчы шәрә яткан яки сирәк кенә кылган үскәләгән тау түбәләрен дә тездән куе үлән каплады. Былтыр чәчелеп тә чыкмый калган урыннарда арыш һәм бодай күкрәп үсте. Безнең якта үзеннән-үзе әнә шулай үсеп киткән арышны — «ту арыш», бодайны — «ту бодай» диләр. (Яңадан туган мәгънәсендә булса кирәк.)

Ачлыктан кипкән, бетеренгән халыкның авызы, ниһаять, табигать биргән беренче ризыкларга тиде. Башта, тугайлар ачылгач та, төче юа, кузгалак бик күп булды, шунда ук койма-читән буйларын яшь кычыткан каплап алды, аннары озак та тормый якын урманнарда какы, балтырган өлгерде. Болар барысы да ризык иде. Инде табигатьнең шушы һәм тагын күп кенә нигъмәтләренә ялганып, кеше үзе чәчкән-утырткан азыклар да бер-бер артлы әкренләп өлгерә башлады. Кыскасы, халык ачлыктан чыкты, ачтан үлү куркынычы бетте.

Әмма бу гаять матур килгән бәрәкәтле җәйдә дә өсбашлары тетелеп беткән ач хәерчеләр, керләнеп, бетләп беткән арык ятим балалар (беспризорниклар) бик күп иде әле. Хәерчеләргә оя кирәк, эш кирәк, шуларны тапканнан соң гына алар Дәүләкән урамнарында күренми башладылар. Тик хәер сорашуны кәсеп итеп алганнары гына һаман йөриләр иде әле, ләкин тора-бара андыйлары да бик аз калды. Ә ятим балаларга килгәндә, аларның вакларын власть органнары җыеп алдылар, зурраклары исә, Дәүләкәнне ташлап, Уфа яки Самара якларына китеп бардылар бугай. Дәүләкәннең Габдулла исемле бер малае да шуларга ияреп киткән дип ишеттек. Бу Габдулланың гыйбрәтле тарихы бар, җае чыкса, бәлки, сөйләрмен дә әле.

Гаҗәп, миңа да Дәүләкәннән китәргә өч кенә ел калган икән инде. Ә нәрсә ул өч ел? — күз ачып йомганчы үтә дә китә. Без хәзер ун-унбиш елның үтеп киткәнен дә сизмичә калабыз, шушы еллар дәвамында күргәннәребез дә бик сыек, сөйлим дисәң, рәтләп сөйләр нәрсә дә юк. Ә менә Дәүләкәндә торасы калган өч елым шактый ук озын да һәм күргән-кичергәннәргә бик бай да булган икән. Бу бит, дусларым, җитмештән җитмеш өчкә җиту

түгел, ә унөчтән уналтыга җитү — бу бит бөтенләй башка!.. Малайлыктан чыгу, балигъ булу — менә нәрсә ул минем өч елым... Һәм моның нинди үткен-тирән кичерешләр белән бәйләнгәнен, шәт, үзегез дә бик яхшы беләторгансыздыр...

Тик ничегрәк дәвам итим икән күргән-кичергәннәрне?.. Кыска вакыт, озын яшьлек — нәрсәдән башларга?..

...Менә ачлыктан соң килгән гаҗәеп җәйне сөйләдем мин... Шушы җәйдән илдә туклык башланды. Ләкин зарыгып көткән туклыкны табигать кенә түгел, тормыштагы көтелмәгән зур үзгәреш тә китерде: бу үзгәреш нэп дигән яңа бернәрсә иде — без менә шуның гаять хикмәтле чорына кердек. Нэпның нәрсә икәнен, кем аны зарури табып, гамәлгә керткәнен барыбыз да тарихтан беләбез, шуңа күрә мин аның илебез тормышында нинди зур роль уйнаганын монда язып тормыйм. Минем бары Дәүләкәндәге нэп турында гына сөйлисем килә — үз күзем белән күргәнне, үзем белгәнне генә.

Мәгълүм булганча, нэп хосусый сәүдәгә киң юл ачты. Патент ал да сату итә башла — полный рөхсәт!.. Бер ел үттеме икән, Дәүләкәндәге моңарчы ябык торган кибет-магазиннар ачылып бетте диярлек. (Кай арада һәм кайдан товары табылган?) Бу коммерция шаукымы бик күпләрне һәм бик тиз үзенә тартып алды. Элекке «купич»-ларны әйткән дә юк, сәүдә алар өчен хәләл кәсеп, бу көнне алар, билгеле инде, көтеп кенә торганнар. Шулай ук элекке приказчикларның да күбесе җиң сызганып сату итәргә керешә. Мәсәлән, биш приказчик, бер сәүдәгәр «Алга» ширкәте төзеп, Басыйр купецның ике катлы магазинында эш башлап җибәрделәр. Тиз арада «Алга», чынлап та, бик алга китте, Дәүләкәндәге иң эре сәүдә фирмасына әйләнде. Элекке сәүдәгәр һәм приказчиклар гына түгел, моңарчы сәүдәнең нәрсә икәнен дә белмәгән кайбер кешеләр дә, хәтта үсмер малайлар да, «җиңел табыш»ка кызыгып, вак-төяк белән аяк өсте генә булса да сату итәргә тотындылар.

Гомумән, алу-сату, алыш-биреш эшләре бик җәелде, көчәйде, базарлар бик җанланды, авылдан һәртөрле азык-төлек күпләп керә башлады, чәйханәләр һәм сыраханәләр ачылды, пекарниләр күпереп торган ап-ак калач, булочниклар (мәсәлән, Эрлих дигән немец булочные) төрле тәмле нәрсәләр пешереп чыгарырга керешә. Шул ук немецлар сыр, май, колбасалар эшләп чыгара башладылар. Шәйморат башкорт бал коеп сатарга тотынды, ә кымызны инде әйткән дә юк — һәр көнне Көрмәнкәйдән, Акколайдан, Шәриптән китереп кенә торалар.

...Каяндыр кытайлар килеп чыкты. Беришеләре, бигрәк тә кеп-кечкенә сабый аяклы хатыннары, төрле төстәге махсус кәгазьләрдән чәчәкләр һәм башка бик матур әкәмәт нәрсәләр ясап саттылар, беришеләре исә ачык прилавкаларда тимер аршиннарын уйната-уйната ситса һәм ефәк белән сату иттеләр, ә тагын берничәсе базар чатындагы йортта ниндидер бер исерткеч ясап сатарга тотындылар. Баштарак аларның бу әллә нинди сихер белән ясалган эчемлекләренә халык ябырылган иде дә, соңга таба күпмедер кеше шул зәхмәттән үлә язып калгач, аңардан бик тиз бизделәр. Ахырда Дәүләкән властьлары ул кабакны бөтенләй ябып та куйдылар... Шунсы тагын кызык, әлеге кызыл мал белән сату иткән баерак кытайлар Дәүләкәннең чибәр-чибәр генә марҗа кызларын үзләре белән дә алып киттеләр.

Әйе, дөнья бик тиз үзгәрде, гүя иске тормыш көтмәгәндә борылып кайтты. Магазиннар, кибетләр, такта лареклар көн буе ачык, хәтта кичләрен лампалар яндырып та сату итәләр. Җаның ни тели — шул бар, тик акчаң гына булсын!..

Мин Дәүләкәннең 1924—1925 еллардагы көзге базарларын бик яхшы хәтерлим. Бу чакларда базар үзенең иске мәйданына гына сыймый иде инде — ул ак чиркәүдән дә арырак башланып, Дәүләкән чокырына хәтле барып җитә иде. Чиркәүдән ары ачык урында мал базары — анда атлар, сыерлар арасында авыл агайлары, маклерлар, чегәннәр, анда коелган юеш печән исе, буы чыгып торган яңа тизәк исе, чыпчыклар чыр-чуы... Мал базарыннан соң чиркәү урамы буйлап үзәккә таба Бурангол, Кыдырач башкортлары, Бәләбәй ягы чуашлары китергән утын йөкләре тезелеп киткән. Боларга ялганып, ләкин аркылы мәчет урамына да борылып, Дим тугаенең печән йөкләре тезелеп тора. Шуннан соң без төп базар мәйданына керәбез. Монда инде азык-төлек... Чиркәү урамының дәвамы буларак сузылган Кәримовлар бакчасы буенда ит рәтләре. Дәүләкәннең үз итчеләре дә, авыл агайлары да ит-майларын шушында саталар. Әле дә исемә төшкәндә гаҗәпләнәм, сугым вакытында базарга ит заты шулхәтле күп керә иде, сарык түшкәләрен, мәсәлән, утын әрдәнәсе шикелле өеп куялар иде. Чана саен йә сыер түшкәсе, йә тана түшкәсе ята торган иде. Сугым вакыты узганчы кереп торачак әле бу симез түшкәләр!

Мәйданның каршы ягында — он-ярма рәте. Монда онның төрлесен — арышныкын, бодайныкын, карасын, агын — өчаякка аскан соскылы бизмәннәрдә саталар.

Монда шулай ук зур тәпәннәрдән бал сатучылар, җирдән генә чабата-чыпта, тимер-томыр, табак-савыт сатып утыручылар — кыскасы, бу базарның иң тыгыз җире. Кулдан иске кием, вак-төяк чүп-чар, куян тиресе сатучылар да һәм кесә караклары да шушында кайнаша.

Бу тыгыз җирне узгач, таш кибетләр башлана. Алар берничә рәт, күбесе татарларныкы, шулай ук русларныкы да бар. Кибетләрнең ишекләре киңенчә ачык — монда инде зур сәүдә, җитди сәүдә бара. Ләкин шуны әйтергә кирәк, аерым кибетләрнең (мәсәлән, «Алга»ларның) сәүдәсе ничаклы гына зур булмасын, әмма элекке замандагы шикелле приказчиклар тоту юк иде. Һәрбер хуҗа бары тик үзе генә яки компаньоны белән генә сату итә, ә базар көннәрендә исә хатынын һәм малаен эшкә җигә. Чөнки ул бик тиз белеп алды: Совет шартларында кеше көченнән файдалану бик хәтәр эш икән. Шуңа күрә нэп сәүдәгәре кырыкка ярылса да, кибетенә кеше ялла637мады. Хәер, ул үзе дә искиткеч өлгер — алучы алдында теле телгә йокмый, кулларына күз иярми торган иде.

...Кибетләр рәтен үтеп, вокзал урамын да аша чыккач, янә бер зур базар башлана. Бу — Марҗа базары (марҗалар саталар икән дип уйлый күрмәгез тагын!). Исеме бик күптәнге, чөнки шушы шактый зур мәйданда элек-электән үк рус, хохол, немец хатыннары бричкалардан һәртөрле яшелчә һәм дуңгыз балалары сата торганнар иде[1]. Монда ниләр генә юк, хәтта Дәүләкәннең эссе туфрагында үскән вак кавын белән юка кабыклы карбыз да була иде. Татар һәм башкорт үзе үстерергә иренгән бөтен яшелчәне (бәрәңгедән башкасын) шушыннан ташый торган иде.

Марҗа базарын ерып узганнан соң, Дәүләкән чокырына барып чыгасың, Чиркәү аръягыннан ук башланган шау-шулы, әкәмәт кызыклы чуп-чуар озын базар менә шунда инде тәгәлләнә иде. Безгә дә кайтыр якка борылырга вакыт.

Чокыр буендагы кыска урамны үтеп, Эткол (русча — Итколовская) урамына чыгабыз. Бу инде Дәүләкәннең төп урамы — иң озын урам. Мондагы күп кенә йортлар базар көнне базарчылар кертәләр. Үзенә күрә бер кәсепкә әйләнде бу... Безнең күршедә генә берничә йорт «базарчылар» белән тула торган иде. Агайлар шунда атларын

[1] 1978 елны Уфадан Оренбург аша Сакмар буена барып чыккач, мин Куандык базарында бер кызыклы тамаша күрдем: дуңгыз балаларын авылдан «Жигули» машинасының багажнигына төяп китер-гәннәр — кычкырта-кычкырта шуннан гына сатып җибәрәләр.— *Ә.Е.*

тугарып калдыралар, базарда йөреп эшләрен бетергәч, кайтып, кибет күчтәнәче белән тирләп-пешеп чәй эчәләр. Ул көнне ике самовар алмаш-тилмәш кайнап кына тора. Моның өчен хуҗа һәр базарчыдан ничә тиендер акча алып кала. Төшеме әйбәт булгандыр, ахрысы... Әнә безнең каршыдагы Бибикамал апа да үзенең бик кечкенә ишегалдын базарчылар белән тутыра иде. Асылда, базарчылар кертү Бибикамал апа кебек тол хатыннар эше иде дә. Озын сүзнең кыскасы, һәр сишәмбедә булып уза торган Дәүләкән базары әнә шулай бик зур да, бик җанлы да һәм карап йөрер өчен бик кызыклы да була иде.

...Ярый, болары мәсьәләнең бер ягы, ваграк ягы... Без әле нэпның тагы да зуррак һәм мөһимрәк нәтиҗәсен күрдек: Дәүләкәнгә бөтен әтрафтан әүвәлгечә иген агылып керә башлады. Ә бу инде ил байлыгы — бөтен нәрсәдән дә кадерлерәк! Ул инде элекке шикелле вагоннарга төялеп, Россиянең үзәк шәһәрләренә озатыла. Икмәк Дәүләкәннең борынгы даны иде, менә шул даны кайтты аңарга. Шул ук вакытта аның моңарчы тик торган мәшһүр тегермәннәре дә хутка китте. Аларның «Якир», «Труд», «Гардер» тегермәннәре кебек бик зурлары дәүләт кулында иде. Вагракларын хосусый кулларга да бирделәр шикелле. Мәсәлән, Үтәмишевләрнең биш катлы тегермәннәре ачлык елның кышында утырып янганнан соң, шуңардан ничектер зарарланмыйча калган бер өлешендә алар яңадан ашлык тарттыра башладылар... Көзен-кышын өзлексез иген кереп торуның тагын бер кызыклы галәмәте — ул да булса ачлык елында кырылып бетә язган күгәрченнәрнең кинәт бихисап үрчеп китүендә иде. Ашлык бушаткан җирләргә алар кара болыттай төшеп утыралар, һавага күтәрелә башласалар, канат тавышларыннан колак тонып китә иде.

Дәүләт тегермәннәренең башына «хуҗа» итеп Гыйният дигән кеше куелды. Ул Дәүләкәннең бер извозчик улы булган, ләкин без аны элегрәк күреп белми идек, революциягә чаклы ул гел читтә йөргән. Извозчик Хәбибулла абзыйның Сафый исемле янә бер улы һәм Галимә исемле җиткән кызы да бар иде. Боларын әзрәк хәтерлим: Сафый (Сафиулла) абый чибәр генә гармунда уйный иде, ә сеңелесе Галимә спектакльләр куюда катнашып йөрде.

Гыйният хакында, үзе кайтып күренү белән бер үк вакытта диярлек, төрле сүзләр дә чыкты: ул, имеш, ниндидер яшерен партиядә торган, партия өчен акча кирәк булгач, банкларны басуда катнашкан, үзе, имеш, патша жандармнарыннан гел качып йөргән. Булыр да! Бәлки,

шуның өчен аны Дәүләкән тегермәннәренә җитәкче итеп куйганнардыр да. Әмма ләкин бу «җитәкче» иң элек үзе өчен гаять өлгер чын хуҗа булып чыкты. Бер-ике ел да үтмәгәндер, Гыйният абзый Дәүләкәннең иң шәп урынында, ягъни әлеге без барып йөри торган водокачка янындагы ачык мәйданда, калай белән япкан, такта белән тышлаган, биш-алты тәрәзәсе Дим буйларына карап торган бик шәп йорт салдырып җибәрде, зур-иркен ишегалдына шулай ук калай белән яптырып ак мунча, конюшни, сарай, тагын нindидер каралтылар салдырды, бөтен ихатасын такта койма белән әйләндереп, таза-чибәр капка бастырып куйды. Шуларның барысын да, ягъни йортыннан алып капка-коймасына кадәр, лимон төсендәге сарыга буятты. Моның кебек йорт Дәүләкән купецларының да бик күбесендә юк иде. Үзе ул кара айгыр җиккән, йомшак күн утыргычлы, рессорлы тарантаска утырып кына йөри башлады. Һәм озак та үтмәде, халык аңа «Кинәт бай» дигән исемне дә такты. Бу кушамат бик тиз таралды, абзыйның исем-фамилиясен дә оныттылар, телдә бары «Кинәт бай» гына калды.

Хәзер, ярты гасырдан соң, мин тегермәннәр «хуҗасын» гаепләргә дә, хөкем итәргә дә җыенмыйм. Асылда, мин аны белмим, күргәләвем дә бик аз, тик шуны гына әйтә алам — ул заманда Гыйният абзый кебек кинәт баеп китүчеләр аз булмады. Бу хәлләр барсы да әлеге шул нәп дигән хикмәтле нәрсәнең җимешләре иде.

Шулай да минем, малай башым белән, Гыйният абзыйга бер этлегем тиде. Эш шунда, Мәрвәр утарыннан килеп, Дәүләкән мәктәбендә бер кыш укыган Гобәйдулла дустым Кинәт бай турында бәет чыгарды. (Хәтерләсәгез, Гобәйдулланың «һөҗү» белән мавыкканын «Дәүләкән» өлешендә сөйләгән идем инде.) Менә монда да шәкертнең кулы тик тормаган, Кинәт байны үзенчә фаш итеп тоткан да бәет язган. Миңа килеп, сер итеп кенә укып күрсәтте. Бәет, ахрысы, икебезгә дә кызык тоелгандыр, һәм без аны үрчетергә булдык. Ике кулдан куш дәфтәр битенә берничә нөсхә итеп күчердек. Шуннан соң апрель аеның җылы, караңгы бер кичендә (бу 1924 елның язы иде) шул күчермәләрне бер-ике урам чатына, мәчет коймасына, Гыйният абзыйның үз капкасына да ябыштырып куйдык. Бу эшнең үзебез өчен бик хәтәр икәнен, ахрысы, сизгәнбездер, чөнки бүтән беркемгә дә әйтмәдек, сөйләмәдек, эчебездән тындык.

...Икенче көнне бәетне күргәннәр, укыганнар, хәбәре дә таралып өлгергән. Безнең үзебезгә дә «Кинәт байларга бәет чыгарганнар!» дигән «яңалык» бик тиз килеп җит-

те. Ул гына түгел, Кинәт байның ялчысы, сабан туйларында көрәшүче озын-таза Нури абзый әйткән, янәсе: «Кем язганын белсәм, ботыннан тотып җиргә бәрәм!» — дигән, имеш. Без моны да ишеттек. Ләкин серебез ачылмады, белүче булмады, куркыныч узды, бәет үзе дә тиздән онытылды. (Бала-чага эше дип карадылар булса кирәк.) Ә Гыйният абзаңа нәрсә? — утырган урыны биек, йөрткән аты шәп — сыңар төге дә селкенмәгәндер, билгеле... Тик минем күңелдә генә ниндидер ямьсез бер юшкын утырып калды. Күрәсең, яшерен эшне яшьтән үк яратмаганмындыр инде.

Кинәт байның соңгы язмышы турында бер хәбәрем дә юк. Дәүләкәндә озак төпләнеп кала алмаган булса кирәк — мин Казаннан кайтып йөргән чакларда, ягъни егерменче елларның азакларында, Гыйният абзый үзе юк, ә шәп таза йорты тора иде. Анда кайбер туганнары һәм әлеге ялчысы Нури агай яшиләр иде. Нури йортны караучы да, саклаучы да иде бугай.

Шушы әйберне язарга җыенгач, Гыйният абзый турында сорашып карадым — белүче булмады. Тик кемнәндер «Гыйният ачтан үлгән» дигән гаҗәп сүзне ишеткәнмен һәм шуны блокнотыма язып та куйганмын. Кайда, кайчан, нишләп? — бу сорауларга җавап юк, күрәсең, сөйләүче үзе дә белмәгәндер. Билгеле, минем моңа һич тә ышанасым килмәде — кайчандыр Дәүләкән тегермәннәрен кулында тотканга күрә генә түгел, ә бигрәк тә аның революциягә чаклы ук инде утны-суны кичкән кеше булуын белгәнгә күрә дә ышанасым килмәде. Хәер, безнең заманда кемнәр белән ниләр генә булып бетмәде. Алла сакласын, бака чакмасын, им дә тапмассың, дип әйтә торганнар иде без малай чакта. Уйнап әйтелсә дә, уйлап әйтелгән!..

Тагын нәрсә әйтәсе калды Дәүләкәндәге нэп турында? Әйе, бу вакытта тагын дин көчәйде дип тә әйтергә була. Тиз арада мәчетләр җанланды, җомга намазына йөрүчеләр күбәйде, елына ике килә торган Гает бәйрәме дә бик күтәренке үтә башлады. (Гражданнар сугышы вакытында һәм ачлык елында бу эшләр тәмам сүрелгән иде.) Сәүдәгәр халкы, авылның хәлле кешеләре, гомумән, динне тотарга яраталар — бу электән үк билгеле. Ләкин фәкыйрь-фөкарәләрдән һәм хезмәтчеләр белән һөнәрчеләрдән дә мәчет юлын таптаучылар аз түгел иде (һәрхәлдә, җомга намазын калдырмыйлар иде). Бу туклыкка һәм иминлеккә ирешүнең бер галәмәте булмады микән?.. Ачлык вакытында бит югыйсә мәчетләр бөтенләй бушап калган иде. (Мәсәлән, хәзерге вакытта да халыкның күп-

медер өлеше дин тота яки дин кушканны эшләргә тырыша — бу бит инде хәерчелектән, бөлгенлектән, нужадан түгел, һәрхәлдә.) Нэп елларында исә халыкның иң зур күпчелеге иске заман тәрбиясен алып калган кешеләр иде әле. Шулай булгач, диннең вакытлыча көчәеп китүе дә шактый табигый бер күренеш иде.

Дин йогынтысыннан әле без яшүсмерләр дә азат түгел идек. Бигрәк тә аның бәйрәмнәреннән... Елына ике килә торган Гает бәйрәме, мәсәлән, минем хәтердә малай чакның кызыклы һәм нигәдер сагышлы бер истәлеге булып хәзер дә әле саклана. Көтеп ала идек бит, әзерләнгән була идек, җылый-җылый яңа кием сорый идек... Бәйрәм көне килеп җиткәч, бик иртә генә торып, зурлар кушканча «тәһарәтләнү», кичтән әзерләп куйган чиста яки яңа киемнәрне киеп алу, аннары атакайга ияреп гает намазына, ә мәчеттән чыккач, зиратка бару — болар барысы да ничектер күңелне сафландырган, мәгәр шулай да мәҗбүри булган гамәлләр иде. Инде менә шулардан соң, коймаклап бәйрәм чәен дә эчкәч, без үз иркебездә, без бәйрәм белән дә үзебезчә хозурланабыз. Тизрәк урамга чыгабыз, очрашабыз, җыелышабыз, мактаныша да башлыйбыз. Баеракларның өстендә бәйрәмгә дип тегелгән яңа тужурка-чалбар, фәкыйрь яки ятимнең өстендә кичтән әнисе юып киптергән чиста күлмәк-ыштан. Баераклары кесәләренә чикләвек, кәнфит тутырып чыккан — алар ландрин суыралар, фәкыйрьнең дә ыштаннарына ябыштырган кесәләре буш түгел — алар исләре дә китмичә генә чырт-чырт көнбагыш яралар... Әмма нәкъ менә бәйрәмнәрдә адәм балалары арасындагы тигезсезлек үзен аеруча әрнеттереп сиздерә дә түгелме соң? Тик шулай да безнең малайлар, аңлапмы-аңламыйчамы, һәрхәлдә, изге бәйрәм хакына бу тигезсезлеккә әллә ни игътибар итмәскә, үзара дуслык-татулыкны берничек тә бозмаска тырышалар иде. Бөтен кешеләргә килгән бәйрәм ич бу!.. Тукай абыйлары да шуңа сөенгән ләбаса! Ә ул инде тигезсезлекнең нинди ачы нәрсә икәнен бик яхшы татыган, белгән шагыйрь.

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкатдәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген,
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген!

Әмма ләкин дөньяны бер генә көнгә ямьләндергән изге бәйрәмнәр безнең өчен бик тиз үтеп китте. Һәм «тигезсезлекләр» дә, әйтергә кирәк, тиз арада бөтенләй үзгәрде — ничек итеп, кая таба — анысын соңрак күрербез.

Ә бер-ике елдан инде совет бәйрәмнәре өстенлек ала башлады. Аларның иң зурлары, билгеле булганча, Октябрь белән Май бәйрәмнәре иде. Аларны аеруча дәртләнеп һәм шатланып бәйрәм итүчеләрнең күпчелеге дә, билгеле, яшьләр иде. Шулай ук Дәүләкәндә революция вакыйгаларына катнашучыларның да читкә китмәгәннәре исән-саулар — алар оештыручылар, алар беренче сафта!.. Ләкин Октябрьнең еллыгы көзнең иң шыксыз, пычрак чагына туры килгәнлектән, бәйрәм итү башлыча мәктәпләрдә, клубларда үткәрелә иде. Ә менә Беренче май бәйрәме язның аяз, матур көненә туры килсә, бик күңелле, тантаналы уза торган иде. Үзенә күрә демонстрация дә, митинг та булып ала, төрле уеннар да оештырыла, кыска гына вокзал урамы да әкрен генә гулять итеп йөрүче, киенешкән яшьләр белән тула иде.

Шундый бәйрәмнәрнең берсе белән бәйләнгән кызык кына бер вакыйга әле дә булса исемдә: нәкъ Беренче май көнне безнең Дәүләкән белән Яңа Шәрип арасындагы тигез кырга энә карагына охшаганрак кушканатлы кечкенә генә яшел аэроплан төшеп утырды. Ишеткәнебез бар, әмма җиргә төшкәнен моңарчы һич тә күргәнебез юк иде. Шунда ук бала-чага, яшь-җилкенчәк барыбыз да кырга чаптык. Тыныбыз бетә язып барып җиттек, чорнап алдык, карап торабыз бу әкәмәт аэропланга! Әнә ул нинди икән! Янында зур күзлекле, озын колаклы күн бүрек кигән очучысы да басып тора. Һәм көлемсерәп кенә җыелган халыкка аңлата: «Мин осоавиахимнан килдем, ди, сезгә шушы очкычны махсус күрсәтер өчен, ди, инде утырып карарга теләүче булса, мин аны очыртып та килә алам»,— ди.

Димәк, утырып очарга да була?! Бусы инде гаҗәпхәйран! Моңарчы бит әле Дәүләкәндә һичкемнең аэропланга утырып караганы юк иде. Кем генә башлап утырыр икән?.. Ләкин ни өчендер утырырга ашкынып торучы юк. Күрәсең, берәүнең дә җирдән аерылырга йөрәге җитми. Ә очучы кыстый: «Курыкмагыз, килегез, машинам бик әйбәт, исән-сау шушында китереп төшерәм»,— ди... Башкалар бер-берсенә карашып, икеләнеп торган арада,бер кәҗә сакаллы агай алгарак ерып чыкты да: «Кая, булмаһа үзем осып караем әле»,— диде. Ул аты белән килеп туктаган бер йөк ташучы икән. Бүреген батырыбрак киде дә, чыбыркысын тоткан килеш, очучы ярдәме белән аэропланга менеп тә утырды. Шунда ук очучы үзе дә менеп урнашты. Бераздан аэропланның алдындагы агач калаклары зырлап әйләнергә тотынды, аннары үзе кузгалып кыр өстеннән сикергәләп китте...

китте дә, отыры кызурак чабып, ахырда җирдән дә аерылды. Халык, артыннан йөгереп, шаулап, бүрекләр чөеп, агайны озатып калдылар.

Аэроплан башта Дим тугайлары өстеннән Әлшәй ягына таба китте, Акколайларны узгач, Түлән буена борылды, шул чакта бераз күздән дә югалып торды, аннары тимер юл буйлап Дәүләкәнгә таба кайтты һәм яңадан нәкъ шушы урынга исән-имин төшеп тә утырды. Бөтен очуына бер унбиш-егерме минут вакыт киткәндер... Аэроплан туктауга, агайны күтәреп алып җиргә бастырдылар. Ул шунда ук геройга әйләнде. Бала-чага, артыннан калмыйча, көтүләре белән ияреп йөри башлады... «Йә, агай, ничек булды, ниләр күрдең? — дип сораучыларга ул, исе китмәгәндәй, гади генә: «Әйбәт булды, дөньяны күрдем, тик менә колак кына тонды»,— дип җавап бирә иде. Ә малайларның, кабаланып: «Адәм ничек күренә, атлар, сыерлар?..» — дип кызыксынуларына каршы ул, көлемсерәп: «Аттың дүрт аягы ла күренә, ә мона сусканың аяктары бөтенләй күренмәй»,— дип җавап биргән иде... Шулай итеп, Дәүләкән тарихында аэропланга беренче мәртәбә утырган кеше йөк ташучы бер башкорт агае булып чыкты. Тик кызганыч, исеме генә елъязмаларга кереп калмады.

Инде үз хәлебез турында да сөйләргә вакыттыр... Әлбәттә, истә калган кадәресен арттырмыйча һәм киметмичә. Билгеле, безнең атабыз да нэп башлану белән сәүдә эшенә кереште. Әйткәнемчә, сәүдә аның өчен хәләл кәсеп иде. Әмма электән үк килгән бер гадәте (яки комарлыгы) бар — ул һәрвакыт йөрү белән бәйләнгән сәүдәне ярата иде. Шуңа күрә кибет ачмады, бернинди ширкәткә кушылмады, ә искечә ялгыз башы йөреп сату итәргә тотынды. Башта ул Самар юлын таптады. Авыл халкында кием-салымга кытлык бик зур иде, өс-баш күптән искергән-тузып беткән, яңаны тектерергә һәркемнең дә кулыннан килми, бик күпләр үзенә кирәкне талчуктан эзли торган иде. Талчуктан киенү бик гадәти бер эшкә әйләнгән иде ул чакта. Безнең атакай да, менә шуны исендә тотып булса кирәк, Самар талчугыннан берничә капчык кием-салым тутырып кайта иде дә шуларны Дәүләкән базарында һәм якын-тирә базарларда кулдан сатып йөри иде. Әйбәт сәүдә димәс идем, вак эш, дәрәҗәсе дә түбән, әмма нишләсен башка чарасы булмагач?! Картның мондый «сәүдәгә» тотынырга мәҗбүр булуының төп сәбәбен мин бары соңрак кына аңладым.

Самар талчугына атакай мине дә берничә тапкыр ияр-

теп алып барды. Минем эшем аның үзен дә, алган әйберләрен дә сагалап йөрү — мин бу «мөһим» эшкә ярыйм, миңа инде ундүрт яшь.

Самар — зур шәһәр, мин белгән Уфадан да, һичшиксез, зуррак... Зур-зур таш йортлар да монда күбрәк. Станциясе дә ифрат зур — үтеп чыга алмаслык юлларда тезелеп торган кызыл эшелоннарның да исәбе-хисабы юк.

Беренче мәртәбә барып төшкәч тә, мине бик гаҗәпләндергән нәрсә — вокзал мәйданындагы извозчикларның төрле яктан атакайга «князь» дип дәшүләре булды. Валлаһи менә, әле берсе, әле икенчесе: «Князь, әйдә кил, утыр, утыр!» — дип чакырып кына торалар. Башта мин моны мыскыл итү дип аңладым, бик гарьләндем һәм сакаллы русларга чынлап торып ачуым да килде. Тик соңыннан гына белдем: татарга «князь» дип дәшү көлү дә, мыскыл итү дә түгел икән, бу бик күптән руска кереп калган бер гадәт икән ләбаса!

Ә Самар талчугы — галәмәт!.. Вокзалдан ерак та түгел зур мәйдан, еллар буенча чүмәләдәй өелгән кырмыска оясы кебек өзлексез мыжгып-кайнап тора. Шулай ук ул өзлексез бөтерелеп, чайкалып, гүләп тә тора. Монда әйтерсең бөтен Рәсәйнең сатучысы һәм алучысы, сукбай һәм зимагуры, карагы һәм жулигы җыелган — ерып йөрерлек тә, читенә барып чыгарлык та түгел!.. Искиткеч уяулык кирәк монда, югыйсә күз ачып йомганчы акчаңнан да, әйбереңнән дә колак кагарсың!

Самар ул Себергә һәм Урта Азиягә китә торган иң озын юллар өстендә тора. Шуңа күрә монда кырык яктан килеп тыгылган кырык милләт халкы бутала. Монда сатылмаган нәрсә юк — аларны белеп тә бетерерлек, санап та чыгарлык түгел. Без кием-салым карыйбыз, безгә кием-салым кирәк. Һәм бу «товар» да мең төрле. Өр-яңасы да, тузып беткәне дә — кайсын телисең, рәхим итә күр!.. Берәрсенең кулындагы ошаганрак әйберне карый башлау белән нindидер шикле кешеләр безне чорнап та алалар. Һәркайсы үзенең сәләмәсен күзебезгә төртә башлый:

— Яле, агай-эне, алып җиффәр булмаса, гомерең буе рәхмәт укырсың! Балаларыңа да әтеп калдырырсың...

— Абзый, мөселман кеше икәнсең, баскан урынымда җир йотсын, минекеннән дә юнерәген тапмассың!

— Әй, мажик, ач капчыгыңны, бушлай ташлыйм. Каян килеп кая китмәгән безнеке!..

Ә безнең кайгы ничек кенә булса да кесә белән капчыкны саклау — шуңа күрә тизрәк бу тыгыз чолганыштан ычкыну ягын карыйбыз. Чынлап та, бу кырмыскалар

шикелле мыжгып торган халык арасында иң читене — кирәк әйберне карап алу иде. Шуңа күрә без, талчук уртасында бераз буталганнан соң, этешә-төртешә читенә чыга идек тә, капчыкларыбызга утырып, үткән-сүткәнне күзәтә идек. Берәр ышанычлырак кешенең кулында юньлерәк әйбер күренсә, атакай шуны чакырып ала да иплэп кенә әйберсен карый һәм сатулаша башлый... Әйбер бик төрле булган шикелле, сатучысы да бик төрле — кайбере белән бик тиз килешәләр, ә кайбер үҗәте белән килешә алмыйча җаны чыга. «Насыйбы безнеке булыр!» — ди минем карт, гүя үзен юатып.

Без җыйган кием-салымнарның берсе дә яңа түгел, барсы да киелгән, ләкин бөтен-таза, «рәхәтләнеп» иләрлек әле... Мин үзем дә ул елларны кеше иңеннән төшкәнне киеп йөрдем. Хәтеремдә Самар талчугыннан алган бәрхет якалы, зәңгәр тужуркам — зуррак иде ул миңа, шулай да яратып кидем үзен.

Талчукта эшебез беткәч, күрше мәйдандагы тимер ишекле таш кибетләр рәтендә дә йөрдек. Кибетләрнең эчендә генә түгел, тышында да товарлар өелеп ята. Бик кызу сәүдә бара — монда да алучыны буш җибәрмәскә тырышалар, хәтта арттан кычкырып калалар. Җиләк-җимеш бик күп — үзбәкләр, төрекмәннәр китереп тутырганнар. Шулардан күчтәнәчкә өрек, күрәгә, кишмиш алып киттек.

Ул елларда зур калага читтән килгән кешенең «фатир керә» торган берәр яхшы танышы була иде. Безнең дә Садовый урамда шундый таныш мишәрләребез бар иде. Каланың таш урамнарын таптый-таптый тәмам алҗыгач, шуларга куна керә торган идек. Иркенләп туйганчы бер ашау-эчүебез дә шунда үтә иде. Аннары инде башны тизрәк мендәргә куясы килә. Зурлар чыдам, зурларның һаман сүзе бетми, ә мин әкрен генә торып чоланга чыгам да әзер урынга авып, шунда ук «мәрткә» дә китәм. Их, бу Самар, Самар, кем генә сиңа чыдар?! Вакыт-вакыт каяндыр гармун тавышы ишетелеп киткәндәй була, ләкин мин аны төшемдә ишетәм дип кенә беләм. Ә баксаң, хуҗаның бер малае кичләрен капка төбендә әкрен генә гармун тартып утыра икән. Һәм шушы малай үскәч бик оста гармунчы булып китә. Сез дә аны беләсез — ул Гали Җәмлиханов!.. Менә кемне мин гүя төшемдә ишетеп ятканмын...

Икенче көнне бик иртә генә, капчык-төеннәребезне күтәреп, вокзалга төшеп китәбез. Монда үзенә бер дөнья!.. Мәхшәр дияргә дә була. Вокзал алды мәйданында кем генә йөрми-буталмый — килүче, китүче, актык киемен

сатучы, сәләмә малай-шалай (беспризорниклар), бетле хәерчеләр, шикле хатын-кызлар, нидер сагалап йөрүче ирләр, чегәннәр — мин инде Самарның бирегә килеп тулган извозчикларын, ломовойларын, рәт-рәт тезелеп утырган азык-төлек сатучы марҗаларын әйтеп тә тормыйм. Унҗиденче-унсигезенче елларда ук урыныннан купкан халык, адашкан сарык көтүедәй, һаман әле бутала да тулгана. Кая бара, ни өчен бара, нәрсә эзли — Хода белсен! Бик биек тә бик озын вокзал бинасына керсәң, анда да энә төшәр урын юк. Бөтен идәне сандык, кәрзин, әрҗә, капчык, төеннәр белән түшәлгән. Ашау-эчу, йоклап яту, хәтта үлеп яту да шул ук таш идәндә. (Бер рус картының шунда үлгәнен үз күзем белән күрдем.) Монда нинди генә исләр аңкымый, әмма иң көчлесе — карбулка исе. Хәзер инде тиф та, холера да юк кебек, ләкин карбулканы һаман да жәлләмиләр, күрәсең...

Менә шунда ике аяк сыярлык урын табып, капчык-төеннәр өстендә утырырга кирәк. Берең утыра, берең поезд сагалый. Белешмә бюролары ул чакта булгандырмы, һич әйтә алмыйм, ләкин бөтен «белешмәне» үзең кебек аптырап йөрүчедән беләсең яки перронга чыгып, килеп туктаган поездларның кая таба китүләрен сорашасың... Белмичә утырсаң, Уфа урынына Ырынбурга киттең бардың — монда поездларның беришесе Уфа — Чиләбегә, икенчеләре Ташкент ягына китәләр. Кассаларга якын барырлык түгел, анда сытылып үләргә мөмкин. Күбрәк проводниклар белән сөйләшеп утыру ягын карыйсың — сөйләшә белсәң, утырып була торган иде.

Элегрәкме, шул еллардамы вокзалларга җыелган халыкны, чүпне көрәгән шикелле, төяп алып китүче «Максимка» дигән поезд йөри башлаган иде. (Аны, Максим Горький геройларын истә тотып, шулай атаганнар, имеш!) Дүртенче класслы соры вагоннар, аларда ике кат тоташ сәндерәләр... Менә шул сәндерәләргә халык бәрелә-сугыла, ызгыша-тартыша кереп тула. Урын алганнар — ирләр, хатыннар — рәттән тезелешеп яталар. Монда оялу да юк, гаеп итү дә юк. Тик иң түбәнге сәндерәләр генә тоташ түгел, утырып барырлык, тәрәзә янында кечкенә өстәле дә бар — юньлерәк, чистарак кешеләр шунда эләгергә, утырып кына булса да, шунда кайтырга тырышалар иде.

Безгә дә күбрәк менә шул «Максимка»га эләгеп китәргә туры килә иде. Самар белән Дәүләкән арасы әллә ни ерак та түгел, хәзерге скорый җиде-сигез сәгатьтә үтә торгандыр, ләкин безнең «скорыебыз» тәүлектән артык та өстерәлә торган иде. Рәхәт поезд иде ул, бер җан иясе булмаган разъездларда да сәгатьләп тора, кешеләр

вагоннардан төшеп, яшел чирәмгә йөзтүбән капланып, йоклап та меңәләр иде. Әмма барыбер кузгала ул! Башта кычкырта, халыкны җыя, аннары ахылдый-ухылдый китеп бара.

Бу «Максимка»да, Самарның үзендәге шикелле үк, иң беренче кайгы — әйберләрне саклау иде. Ничә барып, ничә кайттык, әмма арсак та, ачыксак та, йокламасак та, бәла-казага юлыкмыйча бөтен «товарыбыз» белән исән-имин Дәүләкәнебезгә, ниһаять, кайтып төшә идек. (Бу язганнар 1922—1923 елларга карый, бер-ике елдан соң поездлар күбәйде, йөрүләре шактый ансатлашты, вагоннарның да төрле төскә буялганнары чыкты — «мягкий» дигән зәңгәр-сарысына бай нэпманнар гына утырып йөри иде. Ләкин безгә андый «йомшагына» бервакытта да утырырга туры килмәде.)

Сәүдәләр кыза. Кибетләр гөрләтеп сату итә. Каяндыр товары да чыга, товары да килеп тора. Яңа сәүдәгәрләрнең эшләре шәп бара — моны аларның кыяфәтләреннән, өсбашларыннан да күреп була иде. Кайберләре яхшы атлар да җигә башладылар.

Әмма мин атакайның «сәүдәсен», әйткәнемчә, яратмый идем. Хурлана да идем. Малайлар алдында Самар кебек зур каланы күрүем белән мактанасым да килми иде — беләләр ич безнең нәрсә өчен анда барып йөргәнне. Дөрес, аларның берсе дә ул чакта сату эшенә начар карамый иде, мин дә шулай ук начар карамый идем. Аннары кемнәр генә сатуга тотынмады законный нэп заманында?! Җитезрәк малайлар үзләре дә базар көннәрендә кое суы сатып булса да, акча төшерергә тырышалар иде.

Миңа исә атайның бары «товары» гына ошамый иде. Ярый әле шул товарын базарда сатып йөрергә мине мәҗбүр итмәде. Әгәр мәҗбүр итә калса, мин җирдә стаканлап тәмәке сатып утырырга риза булыр идем, әмма кеше искесен селкеп йөрергә, юк, Алла сакласын, бервакытта да!

Ни өчен соң минем атай, Дәүләкәндә шактый абруйлы бер кеше булуына карамастан, сатуның шундый вактүбәнен сайлады икән? Бер сәбәп итеп мин аның йөрергә яратуын әйткән идем. Ләкин чын сәбәп, төп сәбәп аңарда гына булмаска тиеш. Дөресен генә әйткәндә, кием-салым күтәреп йөрүдән әллә ни зур файда да күрми иде. Баштарак бу «товар» шәп кенә үтсә дә, соңга таба инде отыры авыр китә башлады — кайбер нәрсәләрен айлар буена сата алмыйча йөдәп бетә иде. Чөнки халык бөтенәйде, искегә исе китми, яңаны алырга яки тектерергә дә хәленнән килә башлады.

Сизәм: атакайның кәефе дә әйбәт түгел, әледән-әле уфтана да көрсенә, еш кына үзалдына моңланып та ала. Аның өчен мин дә борчылам — минем дә борчылыр вакытларым җитте дияргә ярый... Ә көннәрдән бер көнне мин һич көтелмәгән бер күңелсез хәлгә тап булдым. Базар көн иде бу, мәктәптән кайтып керсәм, өебезнең кухня ягында, сәкедә атакай иңбашларын селкетеп, тавышсыз гына җылап утыра!.. Инәй аның янына баскан, сабыр гына юатып тора иде, ахрысы... Мин бу хәлне күрү белән аптырап, өнсез калып, бусагада шып туктадым. Шулай да инәй сизеп алды, борылып миңа кулы белән генә чыгып китәргә ишарә ясады. Мин күләгә шикелле артка чигенеп кенә чыгып киттем... Әйтергә кирәк, мин бала җылавын да авыр күтәрә идем, әмма олы кешенең, җитмәсә, атай кешенең җылавы мине тәмам кисте, хәлсез итте, гүя бөтен эчемне актарып чыгара язды. Үземә урын таба алмыйча, әллә кызганудан, әллә гарьләнүдән үксиүкси тизрәк абзарга кереп яшерендем. Тик шунда гына беренче тетрәнүдән көч-хәлгә айныгач, мин ниндидер бер гаҗизлеккә төшеп: «Ни булган аңа, ни өчен ул сакаллы башы белән сәкедә җылап утыра, нинди бәхетсезлеккә тарган?!» — дип ачынып уйландым. Озак тынычлана алмадым, абзарда бик озак яшеренеп тордым... Аннары курка-курка гына өйгә керсәм, атакай юк, чыгып киткән, инәй үзе генә иде. Ул да бик боек, нидер ямап утыра... Бераз икеләнеп торганнан соң, мин шулай да әкрен генә сорадым:

— Ни булды соң, инәй?

— Атаң бер пәлтәсен урлаткан,— диде инәй.

— Шул гынамы? — дидем мин, бик гаҗәпләнеп.

— И бала, белмисең шул син атаңның хәлләрен! — диде инәй, авыр-тирән сулап.— Бер пәлтә югалту да зур каза аның өчен.

Менә шуннан соң гына мин аның «талчукчы» булып йөрүенең төп сәбәбен аңлагандай булдым. Ул, баксаң, купецлар теле белән әйткәндә, сумасыз сәүдәгәр икән ләбаса! Чистарак, абруйлырак сәүдәгә тотынырга аның инде хәленнән дә килми икән... Һәм бу дөрес иде, чынлап та ул шулай иде — тагы да соңрак миңа мәгълүм булды: атакай революция алдыннан сәүдә итеп тапкан бөтен сумасын шушы асты таш, өсте агач әйбәт йортка тыгып бетергән, имеш! Ә сумасыз сәүдәгәр — канатсыз кош кебек, йөгереп караса да, очып китә алмый икән ул. Аннары минем атакай бу нэп дигән яңа шартларга тиз генә җайлаша да алмады шикелле — ниндидер серен, хикмәтен аңлап җиткермәде бугай ул аның... Хәзер аеруча

таләп ителгән өлгерлек, үткенлек, әрсезлек, хәйләкәрлек тә, ахрысы, җитеп бетмәгәндер! Совет шартларындагы «нэпман» дип йөртелгән яңа купецлар нәкъ менә шул сыйфатлары белән аерылып та торалар иде... Кыскасы, мактанырлык түгел иде атакайның эшләре, һәм мин моны малай башым белән дә сизә идем, үземчә уйлана да, борчыла да идем.

...Әмма чынлап торып уйланыр һәм борчылыр вакытлар мине соңрак көткән икән әле... Тормышның тиз үзгәрүенә исең китәр! Яңарак кына коточкыч ачлык кичергән идек, инде шуның артыннан ук дип әйтерлек туклыкка да ирештек. Моны нэп нәтиҗәсе, диделәр. Һәм бу чынлап та шулай иде. Ләкин — гаҗәп хәл — нэп үзе файдалы бернәрсә булып чыкса да, аңа караш һәм мөнәсәбәт бер дә әйбәт түгел икән шул!.. Моны миңа шактый иртә чамаларга туры килде. Чөнки нәкъ менә нэп тудырган яңа сәүдәгәрләргә («нэпманнарга») караш гаять начарланды. Иске буржуйларга караганда да начаррак иде дип әйтәсем килә... Ачлыктан соң Дәүләкәндә комсомол хәрәкәте көчәйде, ә бер-ике елдан инде комсомолга кергән егетләрне һәм кызларны дистәләп санарга мөмкин иде. Алар барсы да сатучы белән кулакны, әлбәттә, сыйнфый дошман итеп саныйлар иде. Ләкин мөнәсәбәтләре төрлечә — берәүләре йомшаграк, икенчеләре рәхимсез катылар. Моны инде мин үземә карата булган мөнәсәбәттән дә ачык сизә идем, тик бу хакта соңрак, җае чыккач сөйләргә туры килер, ахрысы... Хикмәт шунда ки, нэпка тулаем һәм нэп тудырган «элементлар»га начар караш ул бер Дәүләкәндә генә түгел, бөтен илдә хөкем сөрә иде. Мин ул чакта газета-журналларны укый идем инде, кайберләрен үзем дә яздыра идем. Менә шул газета яки журналның кайсын гына ачып карама, син анда нэпман белән кулакны яманлаган, каһәрләгән, фаш иткән яки алардан бик әче көлгән юлларга очрап кына торасың — укып кына өлгер!.. Хәтта үзе дә нэп аркасында дөньяга килгән хосусый «Бабич» журналы да (аны өч кешелек «ширкәт» чыгарырга тотынган иде) беренче саныннан ук нэпманнарны хурлаудан, мыскыллап көлүдән башлады. Ләкин бу кызыклы гына көлке журналның гомере нэпманныкы шикелле үк бик кыска булды — бары өч саны гына чыгып калды шикелле... Әмма ташка баскан сүзнең тәэсире бик көчле бит ул!.. Минем әле күп нәрсәне белмәгән, аңламаган тынгысыз башыма сәүдә ул бер дә хәләл кәсеп түгел икән, сәүдә урлау-талау шикеллерәк бер гаепле эш икән, сәүдәгәр үзе дә начар, зарарлы бер кеше икән ул дигән уй

шактый тиз керә дә башлады. Һәм аеруча хәтәре — нэпманнар белән кулаклар яңа җәмгыятьтә булырга тиеш тә түгел икән әле. Ә мин бит шундыйрак кешенең баласы. Ничегрәк кабул итәргә тиеш мин боларның барысын да?.. Китап сүзенә, газета-журнал сүзенә бик нык ышана торган чагым. Аларда язылганнар белән бер дә икеләнмичә килешергә әзермен, аларга ияреп, бөтен сатучыларны начар, кирәксез кешеләр дип санарга әзермен, әмма дә ләкин үз атамны түгел, атам миңа кадерле дә, кызганыч та, аннары мин аны һич тә начар кеше дип саный да алмыйм. Киресенчә, бик әйбәт кеше ул минем атам. Бүтәннәрдән сорасагыз да шулай диячәкләр. Күптән бернәрсәне сизеп киләм: барлык туганнар, күршеләр, якын таныш-белешләр бер дә риясыз аныяраталар иде. Аннары ул үзенчә гадел дә иде, алдашудан, хәрәмләшүдән, кеше хакына керүдән саклана иде, чөнки гөнаһлы булудан бик курка иде. Ә сату итүенә килгәндә, аның бит бүтән һөнәре юк, сәүдә күптәнге кәсебе (хәзер аңа илле яшь), революция буласын алдан белмәгән, хәлбуки яшәргә кирәк, безне асрарга кирәк, йә, нишләсен ул?! Яңадан крәстиян эшенә кайтырга монда аның җире дә, аты да юк, яше дә узып бара инде, шулай булгач, ирексездән мәҗбүр ул тузанлы базар мәйданнарын таптарга... Әмма күпмегә сузылыр икән соң бу каһәргә юлыккан сәүдә эше? Нәрсә көтә безне? Ничек яшәргә? Мин нишләргә тиеш?.. Ышанасызмы, унөч-ундүрт яшьлек малай башы өчен кинәт кенә туган мондый шикләнү, икеләнү, аптырау белән тулы уйларга җавап табуы бер дә җиңел түгел иде, абзыкайлар!

1924 елның январенда Ленин вафат булды. Шул чакта мин Уфада, җизниләрдә идем. (Каникул көннәрендә килгәнмендер, ахрысы.) Бу вакытта җизниләр Диния нәзарәтенең зур ихатасындагы бер агач йортта торалар иде. Яхшы хәтерлим: бик салкын кышкы көннең кичендә җизни белән Срур тутакай киногa киттеләр. Җылы өйдә Рокыя тутакай белән без бер көтү бала-чагалар гына калдык. Күпмедер вакыттан соң, һич көтмәгәндә, әллә нинди гайре табигый-сәер бер кыяфәттә (әллә бик курыккан, әллә берәр нәрсәсен югалткан — тәгаен генә әйтә дә алмыйм) Срур тутакай ялгыз үзе генә кайтып керде. Без аның хәвефле-сәер кыяфәтенә дә, ялгыз гына кайтуына да шунда ук игътибар иттек, җизнигә берәр нәрсә булмады микән дип шомлана да калдык, ләкин үзебез башлап сорашырга җөрьәт итә алмыйча тордык. Срур тутакай бу чакларда бик чибәр яшь хатын булу өстенә, бөтен йортка байбикә шикелле баш хуҗа да иде.

Бары өстен чишенеп, залдагы зур өстәл янына бик арыган кешедәй утырып, күпмедер вакыт хәл алганнан соң гына үзе башлап безгә әйтте:

— Балалар, Ленин үлгән!

Моның тәэсирен мин хәзер ачык кына әйтә алмыйм, алдашырмын дип куркам. Ләйлә белән Равил кебек кечкенәләргә, бәлки, әллә ни тәэсир дә итмәгәндер (алар алты-җиде яшьтә), Рауза белән Әнвәр кем турында сүз барганын, һичшиксез, аңлаганнардыр, мин исә, арада иң өлкәне, бу көтелмәгән хәбәрне, билгеле, хәйран калып тыңлаганмындыр. Әмма шуны әйтергә кирәк: Ленин исеме безнеңише зурракларга гына түгел, кечерәкләргә дә бик таныш иде, әлбәттә. Бу исем күптән инде халык теленнән бер дә төшми иде. Иллә мәгәр аның үлеме халык язмышы, ил язмышы, бөтен дөнья язмышы өчен нәрсә икәнен, нинди нәтиҗәләргә китерәсен без әле аңлаудан бик ерак идек. Бу гаять зур югалту — без менә шуны гына аңлый-тоя алганбыздыр ул минутларда!

Тукта, ә җизни кайда соң?

Срур тутакай безгә кинотеатрда булган хәлне кыскача гына сөйләп бирде: кино башланып, халык мавыгып кына карап утырганда, кинәт картина өзелә һәм залда ут кабына... Гадәттәге өзелү дип кенә аңлый тамашачы моны, артык исе китми, тик кайбер түземсез яшьләр генә аяк дөбердәтеп сызгырырга тотына. Ләкин шул чакта экран алдына хәрби киемдәге бер ир уртасы кеше чыга да халыкка тынычланырга ишарә ясап, кулын күтәрә. Халык тынычлана.

— Картинаны без туктатырга куштык! — ди бу, үзе дә ак җәймәдәй агарынган кеше һәм, гаҗәпләнә калган тамашачыларны тагы да сыныйсы килгәндәй бераз көттереп, ахырда әкрен-салмак кына, әмма һәр сүзен бик ачык иттереп әйтә: — Иптәшләр, өлкә партия комитетына Мәскәүдән ашыгыч телеграмма килде: бүген, 21 январьда, Горкида... Владимир Ильич Ленин вафат...

Залда гаҗәеп бер тирән тынлык урнаша — әйтерсең кешеләр бер мәлгә сулау, селкенү, сүз әйтә алу сәләтен югалтып җибәрәләр. Тик күпмедер секундлардан соң гына төрле урыннан сабырсызланып кузгалган, авыр сулаган, тәкатьсез үксегән тавышлар ишетелә башлый. Экран алдындагы кеше тагын кулын күтәрә:

— Гражданнар, тәртип саклагыз, тынычлык саклагыз! Кино бүген туктатыла... Өйләрегезгә тараласыз... Безнең белдерүләрне иртәгә газеталардан укырсыз. Ә монда булган коммунистларның барысына да шәһәр комитетына җыелырга!

Халык кузгала, картинаны карап бетерү турында беркем тарафыннан бер генә сүз дә булмый,барсы да аяк астына карап кына, этешми-төртешми ишекләрдән салкын, караңгы төнгә чыга башлый. Ә җизни Срур тутакайны капка төбенә хәтле китерә дә үзе ашыга-ашыга шәһәр комитетына китеп бара.

...Тагын ниләр ишеткәнне һәм ниләр уйлаганны искә төшерәсе килә дә бит, әмма бик күп еллар узган шул инде... Һәрхәлдә, бер уй күңелгә килмичә калмагандыр: Ленин урынына кем булыр икән?.. Бу бик табигый, чөнки борын-борыннан ук баш кеше, җитәкче кеше үлеп китсә, халык зурысыннан алып кечкенәсенә хәтле иң элек әнә шуны уйлаган: кем генә булыр икән? Һәм күп өметләрен ул шуның белән бәйләгән. Дөньяда озак яши торгач, без дә моның дөреслегенә кат-кат ышандык.

Янә бернәрсә хәтергә эләгеп калган. Җизни икенче көнне соң гына бик арып, йончып кайтты. Ашарга утыргач, безнең алда Срур тутакайга кайда булуларын, ни эшләгәннәрен сөйләде. Алар, бер төркем татар коммунистлары, төнне газета редакциясендә уздырганнар. Ленин вафатына багышлап чыгарылачак газетаны, шунда эшләүчеләр белән бергәләп, ашыгыч рәвештә әзерләгәннәр. Кайсы утырып мәкалә язган, кайберләре үзенең истәлеген язарга керешкән, башкалары алар язганны укыгантөзәткән — кыскасы, һәммәсенә дә эш җиткән. Тик шигырь юк икән, ә шигырьсез газетаны чыгарып булмый, ярамый, мөмкин түгел... Шунда ук тиз генә шигырь язуны Гариф Гомәр дигән шагыйрьгә йөкләгәннәр. Аны аулак җиргә утыртканнар, янына бармаска, дәшмәскә кушканнар... Әмма ләкин Гариф абый яза алмыйча бик азапланып беткән, имеш. Үзен кулга алалмый икән шагыйрь — берничә юл гына яза да сыгылып төшеп җылый башлый икән... Шагыйрьне юата алмыйча йөдәп беттек, ди җизни...

Нишләп соң бу кечкенә эпизод минем хәтердә сакланып калган әле?.. Бәлки, шул чакларда үзем дә язу турында хыяллана һәм аз-маз гына сызгалый да башлаганга күрәдер? Бүтәнчә ничек аңлатыйм? Шагыйрьнең җаны тетрәнүдән шигырь яза алмыйча газаплануы миңа да тәэсир итмичә калмагандыр, ахрысы...

Тарихтан беләбез: Ленинны Горкидан китергәннән соң, Мәскәүнең Кызыл мәйданында җирләү (вакытлы мавзолейга кую) 27 январьда булды. Мин инде Дәүләкәнгә кайткан идем. Көннәр гаять суык, очкан кош та катып җиргә төшәрлек. Дәүләкән тын, урамнары буш, капка төпләрендә малайлар да күренми. Кешеләр үзләре дә,

авыр уйлары да, кара кайгылары да моңсу-боек өйләренә әйтерсең кереп бикләнгән. Тоташ туңган тәрәзәләре генә агарып калган сукыр күзләрдәй дөньяга күрмичә карыйлар. Эңгер-меңгер вакыты якынлашып килгәндә тын, куе һаваны калтыратып тегермәннәрнең гудоклары кычкырта башлады. Аларга станциядәге паровоз гудоклары кушылды. Үкси-үкси үкергән бу гудок тавышлары кинәт сискәндереп җибәрде, бәгырьләрне телгәләп узды һәм гүя үлемгә көчле-килешмәс нәфрәт булып яңгырады. Шушы тавышлардан гына белдек без дөньяның инде бөтенләйгә Лениннан аерылганын...

Матәм көннәре үтеп китте, мәктәпкә дә йөри башладык. Әмма Ленин үлеме аңда һәм күңелләрдә яши иде әле... Моны нәрсәдән сизеп була?.. Әйткәнемчә, Ленин исемен ишетмәгән-белмәгән кеше элек тә юк иде. Инде үзе үлгәч, аның исеме тагы да киңрәк таралып, кадерлерәк булып китте. Бу җәһәттән аның язмышы бүтәннәрнекеннән бик нык аерылды: мәсәлән, башкаларның исемнәре, үзләре исән чакта никадәр популяр булуга карамастан, үлгәннән соң шактый тиз онытыла башласа, Ленинныкы, киресенчә, бөек шагыйрьләрнеке шикелле, һаман күтәрелә-зурая барды. Бу исем бигрәк тә яшьләр һәм балалар күңеленә бик нык керә башлады. Күпме бала-чага аның турында шигырь язмады — әгәр шул чактагы балалар матбугатын актарып карасагыз, моны үзегез дә күрерсез. Билгеле, матбугатта чыкканы меңнән бере генә ул, ә чыкмаганы бихисап булырга тиеш. Һәрбер мәктәптә «Ленин почмагы» оештырылды, балалар үзләре аны үз куллары белән тырышып бизәделәр. Шул матур «почмак»ларда беренче мәртәбә стена газетасы да күренә башлады. Ә газета инде, билгеле, рәсемсез булмый, шигырьсез булмый. Ничектер үзеннән-үзе рәсем ясаучылар да, шигырь язучылар да табылды. (Малайлар-кызлар арасында бу эшкә азмы-күпме сәләте булганнар һәрвакытта табыла икән ул, тик рухландыра торган сәбәбе генә чыксын!) Менә безнең мәктәптә дә Мөхәммәтгали шигырь язган, Фәтхелислам язган, алардан күрмәле мин дә яздым. Бу бит минем язу теләге белән исерә башлаган чагым — ничек инде мин Ленинга багышлап шигырь язмыйча кала алыйм ди?! Булмый ул!.. Һичшиксез, күңелемдә нидер тугандыр инде, нидер әйтәсем килгәндер, тик, бәлки, кыюлыгым җитмичә торгандыр, ә менә иптәшләремнең язганын белгәч, дәртләнеп, тоттым да тәвәккәлләдем. Әмма тырышып-тырышып язуымнан нәрсә килеп чыкканын хәзер инде әйтә алмыйм, шигырь сакланмаган, сүзләре дә истә калмаган, хәтта исеме дә оны-

тылган. (Тик һәр юлы ундүрт-унбиш иҗектән торганын хәтерлим, чөнки иҗекләрне бармак белән саный-саный язган идем.) Бу шигырь минем беренче тәҗрибәм диярлек. Ләкин язу эшен шигырьдән башлавымны мин моңарчы бер дә әйткәнем юк иде шикелле, чөнки, бердән, шигырьләрне бик аз яздым, икенчедән, үземдә шигырьгә сәләт юклыгын бик тиз сиздем. Шулай да минем Ленинга багышлап шигырь язуыма, шәт, ышанырсыз — бу очракта алдашып маташу бик зур түбәнлек булыр иде. Аннары шул чакларда мин берничә шигыремне (ихтимал, Ленинга багышланганын да) Мәскәүгә «Кечкенә иптәшләр»гә җибәреп караган идем. Әгәр журналның 1924—1925 елларда чыккан саннарын актарып карасагыз, иң соңгы битенең астында Әмирхан иптәш Яникәефкә: «Әйтер фикерегез булса да, шигырьләрегез чизәгыйфь» дигән мәгънәдәрәк җавап басылганын күрерсез. Моның өчен журналның редакторы Муса Җәлилгә, бәлки, үпкәләгәнмендер дә, әмма зәгыйфь шигырьләр язудан тизрәк туктарга ул, һичшиксез, ярдәм дә иткәндер дип беләм. Соңыннан Муса белән очрашкан чакларда бу хакта бер-вакытта да сүз булмады — ул инде журналында басылмаган «шагыйрьләр» арасында минем дә булуымны күптән оныткан, ә мин моны шаярып кына булса да аның исенә төшерүдән, билгеле, тыела торган идем. Шагыйрь алдында шагыйрь була алмыйча калуың белән мактану... Юк, килешми, егетләр!..

...Ә нэп гөрли. Сәүдәләр шәп бара. Базарларга азыктөлек ишелеп керә. Тормыш беркадәр тигезләнде кебек — элеккедәй череп баючылар да, кара-җәяү калучылар да күренми диярлек. Халык тулаем канәгать сыман. Ләкин озаккамы бу?.. Ленин вафатыннан соң киләчәк турында уйлану һәрбер кешенең күңелендә туган булырга тиеш. Әлбәттә, һәркем үз хәленнән, үз теләкләреннән чыгып уйлана... Хәер, артык борчылырга урын да юк шикелле... Үзгәрешләр көтелми, дөнья үз эзеннән искечә һаман тәгәрәр кебек... Газета битләрендә дә, җыелышларда да гел «Ленин юлы, Ленин байрагы, Ленин тәгълиматы» дип, өзлексез кабатлап кына торалар. Ә «Ленин үлде, әмма эше яши!» дигән сүзләр бөтен җирдә язып куелган иде. Ләкин Ленин юлын кем, ничегрәк дәвам иттерәчәк — бу хакта фикерләр бер үк түгел кебек — шулайрак сизелә иде. Дәү абзыйлар: «Ленин кимәнең койрыгын болайрак тоткан иде, ә икенче берәү, бәлки, тегеләйрәк тотар»,— диләр, үзара сак кына сөйләшкән чакларында...

Мин безнең Дәүләкәндә комсомолларның артуын, көчәюен әйткән идем бугай. Шулай ук нэп тудырган

яңа байларга, сатучыларга, баерга тырышкан авыл агайларына, гомумән, искене хәтерләткән, искегә тарткан бөтен нәрсәгә нәфрәт-ачуның да көчәюен әйтеп узган идем. Һәм бу нәфрәт, бу ачу отыры көчәя бара иде. Һәм ул нәфрәт-ачу сүздә генә түгел, гамәлдә дә үзен сиздерә башлады. Иң элек әле «финотделлар» хосусый сәүдәгәрләргә елдан-ел зуррак налоглар салып, аларны ничек тә кысарга, чикләргә керештеләр. Шулай ук авылларда таза тормышлы агайларны һәм кулакларны кысрыклау да башланды булса кирәк. Җыеп кына әйткәндә, сүз хәзер күбрәк сыйныфларны бетерү, илдә социализм төзү турында бара. Димәк, бу нэп дигән нәрсәнең гомере озакка бармаячак — моны нэпның иң кызган чагында да ничектер сизәргә мөмкин иде.

Миңа инде унбиш яшь! Минем инде үз уйларым, үз кайгыларым бар. Мин дә бит шушы заман эчендә үсеп килүче бер адәм баласы! Заманның җилләре, эсселәре, салкыннары миңа да кагыла, авырттырып кагыла... Бер елдан мин Дәүләкәнемнән чыгып китәргә тиешмен... Ә күргән-кичергәннәрем һаман да күп әле — шуларны сөйләр өчен миңа унбиш яшьлек халәтемә кайтырга кирәк. Бу һич тә ансат түгел. Нәрсәдән генә башларга соң?!

Ахрысы, мәхәббәт белән әдәбияттан башлау дөресрәк булыр. Ник дигәндә, адәм баласының уянуы һәм күзе ачылуы мәхәббәт белән китаптан башлана. Һәрхәлдә, алар икесе дә кешене балалыктан чыгара һәм хыял, өмет дөньясына алып керә. Беренче татлы газап белән беренче куанычлар да шулардан башланса кирәк.

Мәхәббәттән котылу юк. Табигать адәм баласын барлык җан ияләре шикелле үк ике җенес итеп яраткан икән, димәк, мәхәббәт орлыгы аңа инде ана карынында чакта ук салынган да булган. (Хәзергечә әйтсәк, башта ук программалаштырылган.) Тик берәүдә бу тылсымлы орлык иртәрәк шыта, икенчедә — соңрак, берәүдә көчлерәк шытып чыга, икенчедә — зәгыйфьрәк, аерма бары шунда гына.

Миндә исә, ни хикмәттер, шактый иртә кыймылдый башлады ул хәерсез орлык!.. Югарыда мин күрше кызына койма ярыгыннан «гашыйк» булуымны язган идем инде. Бу хәлгә без-мәҗнүн унсигезенче елның җәй башында дучар булдык.

...Көн дә диярлек кешегә сиздерүдән курыккандай мыштым гына койма буенда йөрим. Сакланып кына әле бер ярыктан, әле икенче ярыктан «аны» эзлим. Хәер,

болай качып-посып күзәтмәгән чакта да инде ул минем күз алдымнан китмәс булды — гел менә гади генә ситса күлмәге, нечкә-нәфис сыны белән, башын әз генә ия төшеп каршымда басып тора кебек. Ниндидер сәер бер хәл сизә башладым мин үземдә — гүя каяндыр күкрәгемә кереп оялаган ап-ак кына йомшак кош шикелле, ул да минем эчемдә яши — ятсам да, торсам да, без гел бергә, имеш! Әнә шундый серле бер малайга әйләндем әле мин, бик кадерле табышым бар минем, шуны ят күзләрдән ничек тә сакларга тырышам, тик менә ул ап-ак «кошчыгым»ның исемен генә белмим әле мин...

Хуш, абзыкаем, нәрсә бу? «Гашыйк» булу түгелме соң?.. Шулайрак шикелле... Иллә мәгәр мин моны «мәхәббәт» дип әйтә алмас идем, чөнки мин әле мәхәббәтнең нәрсә икәнен белмим, мәхәббәт турында әле уйлый да белмим — мәхәббәт ул зурлар эше, ә мин нечкә сыйраклы арык кына бер малай... Миңа бит күрше кызыннан берни дә кирәкми, минем аны бары ешрак күрәсем генә килә. Ләкин койма ярыгыннан түгел, якын барып, якыннан күрәсем килә. Ул да мине күрсен иде... Ничек карар иде икән?.. Бу куркыныч, бу мине хәтта калтыранып куярга мәҗбүр итә, әмма барыбер аңа бик күренәсем килә. Тик менә Борһан купецның капкасы безгә дә кайчан гына ачылыр икән?!

Әйткәнемчә, минем бу хәлгә юлыгуым унсигезенче елның хәтәр җәенә туры килде. Ул җәйдә ниләр булганын мин башта ук язып узган идем инде. Кыскасы, аклар-кызыллар сугышы бара, Дәүләкәнгә сугыш әле бер яктан, әле икенче яктан килеп җитә, кешеләрдә баш кайгысы да мал кайгысы... Шул чакта сугыштан куркып без дә китеп бардык, Борһан абзый да балаларын төяп, Уфага китеп барды, мин дә «кошчыгым»ны күпмедер вакытка күздән югалттым. Әмма күкрәгемнән очырмадым! Моның шулай икәнлегенә мин яңадан Дәүләкәнгә кайткач ышандым: уянды минем ап-ак кошым күкрәгемдә!.. Беренче көннән үк мин аның уянганын сиздем, тизрәк аны күрергә ашыктым... (Бу вакытта алар да Дәүләкәнгә кайтканнар иде инде.) Елдан артык югалтып тордым мин аны — ничегрәк, ниндирәк икән ул хәзер?.. Без бит бер яшькә үстек, үзгәреш бардыр, буйга гына түгел, башка яктан да әзрәк үскәнбездер... Минем, мәсәлән, хәзер койма ярыгыннан карап торасым килми (оялам болай күзәтүдән), минем өйләренә кереп күрәсем килә, дәшәсем һәм сөйләшәсем килә.

Аларга беренче керүемне ачык кына хәтерләмим. Һәрхәлдә, Уфага киткәнче үк булгандыр дип беләм, чөнки

кызыллар беренче тапкыр Дәүләкәнне алгач, бөтен йортларга рәттән атлар, солдатлар куйдылар. Борһан абзыйның капкасы да, ниһаять, төбенә хәтле шыңгырдап ачылды. Билгеле инде, атлар, солдатлар бар җирдә һәрвакыт малайлар кайнаша. Без менә шул чакта Борһан абзый ихатасына да курыкмыйча кереп йөрдек. Әлбәттә, мин «аны» да күргәнмендер инде, ләкин ничек итеп — якыннанмы, ерактанмы — ул кадәресе исемдә калмаган. Һәм бу гаҗәп тә түгел, чөнки без, малайлар, үзебез белән йөрибез, без иптәшләр алдында кыз күзләүдән бик куркабыз. Тик бер нәрсәне яхшы хәтерлим — аның Һаҗәр исемле икәнен шул чакта ук ничектер белгән идем.

...Егерменче елларга да кердек. Сугышлар бетәргә өлгермәде, коточкыч ачлыгы килеп җитте. Ләкин, шуңа да карамастан, мин күрше кызын онытмыйм, мин аның барлыгын тоеп яшим... Бәлки, ул бу авыр чакта миннән ерагаеп, томан эченә китебрәк торгандыр — ачлык бит ул бөтен нәрсәне кешедән ераклаштыра. Хәтта бергә уйнап йөргән малайлар белән дә очрашулар бу вакытта бөтенләй бетә язган иде. Әмма адәм баласы, әгәр исән калса, үзенең өмет-хыялларын әллә нинди һәлакәтләр аша да түкми-чәчми алып чыга икән... Барысы да терелә, барысы да яктыга үрелә. Ә мәхәббәт хисе барысыннан да элегрәк уяна, элегрәк әйләнеп кайта.

Мин дә, билгеле, шул ук хәлне кичердем, ләкин башкачарак итеп кичердем. Чөнки мин тагын берничә яшькә үстем. Хәзер инде минем Һаҗәргә гыйшкым тагы да көчәя, тирәнәя төшү белән бергә, ничектер аңлырак, мәгънәлерәк тә була башлады. Баштагы шикелле аның мине үзенә ни өчен тартуын аңламыйча миңгерәүләнеп йөрү урынына, мин хәзер үземдәге аңа булган хисләрнең нәрсә икәнен, кайдан килгәнен шактый ук дөрес чамалый идем. Бик яшерен рәвештә генә, курка-курка гына үземә: «Бу — мәхәббәт!» — дип әйтә дә ала идем.

Аннары мин бу яшьтә әдәбиятны күп укый идем. (Җитмәсә, үзем дә әдип булу турында хыяллана башлаган идем.) Ә матур әдәбият ул мәхәббәткә сусауны бик көчәйтә, ашыктырып берәр кызга гашыйк та иттереп куя. Сынаганыгыз бардыр, шәт?! Соңыннан, еллар узгач, мин үземнең Һаҗәргә булган мәхәббәтемне күбрәк шул роман, хикәяләр аркасында тумадымы икән дип тә уйлаштыргалый идем. Һәрхәлдә, күңелдә яралганны көчәйтеп җибәрүдә, һичшиксез, йогынтысы булгандыр аның... Икенче яктан, күрше кызы белән мавыгуым минем «әдип» булырга хыяллануымны да, һичшиксез, көчәйткәндер. Кемнең генә яраткан кызына гадәттән тыш шәп

кеше булып күренәсе килми?! Хәер, мин моны тәгаен шулай булды дип әйтә алмыйм, ул хакта, бәлки, уйлый да белмәгәнмендер әле, ләкин шулай да миндәге ярату хисләре күңелдә әкренләп шигърият тойгыларын да уяткандыр дип әйтергә була. Хәзерге заман шагыйрьләре шигърият белән мәхәббәтне бер итеп күрәләр, ягъни шигърият ул мәхәббәт, диләр турыдан-туры... Тик мәхәббәтне хатын-кыз белән генә чикләнмичә, аны җиргә, илгә, кешегә дә күчерәләр. Шагыйрьләр өчен ул, ихтимал, шулайдыр да, ләкин мин үзем, пәри башка, җен башка дигәндәй, алар икесе ике нәрсә, ягъни хатын-кызга мәхәббәт кешенең үзе белән бергә туа, ә дөньяга мәхәббәтне (яки нәфрәтне) яши торгач кына татый башлыйсың дип уйлый идем. Берсе — табигатьтән, икенчесе — аңнан.

Ярый, фәлсәфә күпкә китте, җитеп торыр. Онытмыйк, мин гашыйк, мин мәхәббәт утында янам! Хуш, ә каршы як, Һаҗәр туташ үзе ничек соң, ничегрәк карый ул миңа, өмет, ышаныч бармы аның тарафыннан?.. Иң беренче вакытларда без әле балалар гына идек, нидер уйлау, нидер белергә теләү дә юк, минем бары аны күрәсем һәм аңа күренәсем генә килә, әмма ләкин аның бертөрле дә карашын сизмим — гүя ул мине белми дә, күрми дә иде. Һәм моңа гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки мин урам таптаучы яланаяклы малайларның берсе, үзем арык-котсыз, өстемдә дә ситса күлмәк, ычкырлы ыштан, ә ул башка — өеннән беркая да чыкмаган, малай-шалайлар белән беркайчан да аралашмаган, үзе чибәр, үзе пөхтә, шактый һавалы купец кызы — билгеле инде, карамый, күрми ул!..

...Үтә берничә ел. Без инде бала түгел, үсмерләр... Күңел дә сизгеррәк, зиһен дә үткенрәк... Һаҗәр тагын да матурлана төште, күкрәкләре дә тула башлады. Миңа да бераз ит кунды, битем дә алсулана төште, өс-башым да рәтләнде — Самар талчугыннан кайткан бәрхет якалы тужуркадан, чалбардан, ботинкадан йөрим. Ләкин, шуңа да карамастан, Һаҗәр миңа карамый, мине күрми. Мәхмүткә карый, Таһирга карый, ә миңа күз дә салмый. Әйтерсең мин юк, мин яшәмим аның өчен!.. Ниһаять, әрнеп-сыкрап аңладым: Һаҗәр юри, аңлы рәвештә миңа күз салырга, мине белергә теләми икән... Әмма ни өчен соң, ни өчен, кемнән ул хәтле ким мин?! Аңгыра-ахмак түгелмен ләбаса, азып-тузып та йөрмим, кешедән ояла да беләм, җан иясен кызгана да беләм. Энеләре, сеңелләре белән дә арам әйбәт кенә, көн саен очрашабыз, сөйләшәбез, бергә уйныйбыз — нигә соң бары аның та-

рафыннан гына мондый... тәкәббер салкынлык?! Һәм минем кечкенә башыма бу зур газап иде.

...Тик берара гына мин аның игътибарын үземә җәлеп итә алдым. Ул китап укырга ярата иде (күп кызларга караганда да). Еш кына мин аның ачык тәрәзә төбендә, алга күчергән чәч толымын бер сүтә, бер үрә-үрә, итәгендәге китабын укып утырганын күрә торган идем. Моңа мин һәм сөенәм, һәм өметләнәм, чөнки бу хәл мине ничек тә аңа якынайтырга тиеш иде. Үзем мин китапханәгә дә йөрим, кешеләрдән дә алып укыйм. Сүз нәрсәдән, ничек башланып китктәндер инде, ләкин озак та үтми, мин Һаҗәргә китап ташый башладым. Әлбәттә, бик теләп һәм рәхәтләнеп... Мин аның янында булам, мин аңа дәшәм, кулына китап бирәм яки алып китәм... Минем бер дә тиз генә китәсем килми, минем озаграк сөйләшәсем килә (укылган китап турында күпме сөйләшеп булыр иде!), ләкин, кызганычка каршы, миндәге теләк Һаҗәрдә юк. Нишләтәсең, юк кына бит!.. Юри сорашсам да, аның өзеп кенә «ошады» яки «ошамады» диюеннән башканы ишетмим. Сизәм инде, сизәм, тизрәк китүемне көтә. Гаҗәп, еремәсә ереми икән эчендәге зәңгәр боз!

Бу хәтле салкынлыкның сәбәбен мин ул чагында, әйткәнемчә, аңлаудан гаҗиз идем. Шулай да соңрак бер хакыйкатьне ачкандай булдым: аңа минем яратуым бер дә ошамый икән ләбаса, шуңа ачуы килә, шуның өчен гел сырты белән тора икән ул!.. Гәрчә мин яратуымны телдән бервакытта да әйтмәсәм дә, ул аны, һичшиксез, белә иде. Үземә карап та һәм бүтәннәрдән ишетеп тә, чөнки минем Һаҗәргә «гыйшык тотып» йөрүем, кызганычка каршы, фаш ителгән иде инде. Беләсезме, мәхәббәт газабын үз эчеңдә генә асрап булмый, аны иртәме-соңмы кемгә дә булса ачасың, шуның белән, янәсе, үзеңә җиңеллек табасың. Менә мин дә Мәхмүт дустыма, җәйге айлы кичләрнең берендә, икәүдән-икәү генә йөргән чакта, бик дулкынланып-кичереп, үземнең серемне ачкан идем. Мәхмүт — моңлы бала, хәсрәтле җырлар ярата, үзе дә күршеләрендәге Гыйззәтдин абзыйның кызы Мәрьямгә гашыйк. (Гаҗәп, малайларның «мәхәббәтләре» гел күрше кызларыннан башлана.) Ул да миңа үз хәлен сөйләгән иде, шулай итеп, уртак хәсрәтләребез булу аркасында без бик дуслашып та киткән идек. Әмма ләкин минем сөйләгәннәрем, гәрчә Мәхмүт беркемгә дә әйткәнем юк, дип антлар итсә дә, Дәүләкән малайлары һәм кызлары арасына таралып та өлгерде. (Ахрысы, тагын берәрсенә «чишкәнмендер» инде.) Мине артымда да, алдымда да үртәү китте, хәтта коймабызга «Әмир+Һаҗәр» дип язып

та куйдылар. Ә бит безнең коймалар терәлеп үк тора. Һаҗәр анда нәрсә язылганын белмичә калмый, әлбәттә. Менә шуннан соң минем хәлне күз алдыгызга китереп карагыз инде. Аклану мөмкин түгел, иң яхшысы — күзенә күренмәскә!.. Ходаем, мин бит моңарчы да кагылган гашыйк, йә, нигә кирәк булды тагын аның нәфрәтен кузгатырга? Ярата алмаган кеше кызгана да алмый ул... Моның шулай икәнен миңа бер татырга туры килгән иде бит инде. Әмма гашыйклар күбәләк кебек бер көйдергән утка яңадан да барып керәләр.

...Моннан бер ел чамасы элек булган иде ул вакыйга... Көз ахыры иде, көннәр шактый суытты, тугай өстенә ак бәс кунды, ниһаять, менә Дим култыгы Комач өсте дә күксел боз белән тигез генә капланды. Ә кар юк, кар әле төшмәгән иде. Ике-өч көн узуга, Комач бозы безнең ише малайларны күтәрерлек ныгып та өлгерде. Әнә шундый көннәрнең берсендә өч кыз Арыслангәрәй тыкрыгыннан су буена төштеләр. Болар безнең каршыдагы Таифә апа һәм Гайшә апа белән Һаҗәр иде. Мин аларны яр башында очраттым һәм нишләптер үзем дә аларга ияреп төштем. Мөгаен, Таифә апа дәшкәндер, ул хәйләкәр кыз иде, минем хәлне дә белә иде, хәер, дәшмәсә дә, Һаҗәрне күргәч, иярмичә булдыра алмадым инде. Төштек шулай, мин шунда ук боз өстенә кереп киттем — ул тәмам ныгыган, зурларны да күтәрерлек иде. Кызлар да әзрәк таптанып тордылар да сакланып кына бозга бастылар. Шуа-шуа гына киттек. Мин, кыюлык күрсәтергә теләп, алдан йөгереп барып шуып та китәм, ә алар кулларын җәеп, аумаска тырышып, вак-вак кына шуышып киләләр. Шулай бара торгач, шактый киң Комачның аръягына да чыгып җиттек. Кызарышкан идек, куанышкан идек, миңа да бик күңелле иде. Ни сәбәптәндер бу вакытта боз өстендә беркем дә юк, тик бераз ерактарак бер рус малае үзе ясаган «тимераяк»та шуып маташа иде. Малай буйга да миннән зур, яшькә дә олы булырга тиеш иде. Без бераз тын алгач, кире үзебезнең якка чыга башладык. Шул чагында теге малай, кулындагы таягын күтәреп, туп-туры минем өскә җилләнеп килмәсенме?! Күрәм, усал ният белән килә бу, ә минем кулымда берни дә юк. Шуннан мин тоттым да ярга таба чаба башладым. Барып җитсәм, каты җиргә басам, кулыма ташмы, таякмы да ала алам. Малай чакта мин бик шәп йөгерә идем, берәүне дә уздырмый идем, бәлки, хәзер дә аны җиткермәгән булыр идем (ул бит агачтан ясаган «тимераяк»та иде), ләкин, бәхетсезлеккә каршы, ярга җиткәндә генә нәрсәгәдер сөртенеп, йөзтүбән барып та төштем. Малай килеп тә җитте, кулындагы таягы белән минем тубыкка китереп тә сукты. Ми-

нем сыным катты, хәтта тавышым да чыкмас булды — тубыкның никадәр авырта торган җир икәнен белсәгез иде!.. Ә кызлар алдында хурлыгы ни тора?! «Гашыйк егет» пычрак ярда аунап ятсын әле! Мин кызулык белән сикереп тормакчы булган идем, ләкин, аякның яман авыртуына түзә алмыйча, яңадан бөгелеп төштем. Шул арада кызларым килеп җиттеләр. Таифә апа юри генә кызганган-дай: «Йә, егет, сиңа ни булды?» — дип сорады, ә Гайшә апа белән Һаҗәр, туктап та тормыйча, көлә-көлә үтеп киттеләр. Йә, шәфкатьсезлек түгелме бу? Күсәктәй малайның куып җитеп, таяк белән тубыкка сугуын күрделәр ич, күрделәр!.. Бәлки, минем куян шикелле качуымнан көлә торганнардыр?.. Чын малай эшемени ул качу?! Бигрәк тә кызлар алдында! Әлбәттә, канга батканчы сугышырга кирәк булган, тагы да катырак кыйналырга, ичмасам, бу кадәр хурлыгы булмас иде.

Әнә шундый тән һәм җан ярасы алган идем мин ул чакта. Әмма адәм баласы әрсез, тиз оныта барысын да, яра да әкренләп төзәлә, тик җөе генә торып кала. Боз өстендәге вакыйгадан соң бер-ике ел үтеп тә китте. Без тагын шактый гына үстек. Миңа инде уналтынчы яшь, егет булып барам. Ә Һаҗәр чын туташ булып җитте. Аның миннән ике яшькә олырак булуын да белдем. Өлгергән туташка мәхәббәт тә аеруча көчәя икән… Дөрес, безнең ара әүвәлгечә ерак, әүвәлгечә салкын, ләкин хәзер без бер-беребезгә карата әдәп саклыйбыз, очрашканда исәнләшәбез, сирәк кенә сөйләшүдән дә качмыйбыз. Һаҗәр мине яратмавын электәге шикелле ачык күрсәтми һәм ачыктан-ачык кырын да тормый. Боларны ул ничектер эчкәрәк яшерде. Шулай да мин чын хәлне күреп торам, Һаҗәрдә өметем юк диярлек, әмма аның турында хыялланырга яратам. Гашыйкның бер үҗәтлеге бар — ул чигенә белми. Гашыйк ул — шыр тиле!

Соң, кай тирәдәрәк йөри минем хыялларым? Хәер, башта менә нәрсәне әйтергә кирәктер, ахрысы: мин инде язу-сызу белән чынлабрак мавыга башладым. Почмакка куйган кечкенә өстәлем бар, өстәлдә бәләкәй генә өем китапларым тора, каршыдагы стенага уку китабыннан копировка аша күчереп алган Тукай белән Лермонтов рәсемен дә ябыштырып куйдым. (Лермонтовны яхшы белгәнгә күрә түгел, ә күчереп алыр өчен ансат булганга күрә.) Көн дә шул өстәлемдә күпмедер утырган булам, аны-моны сызгалыйм, шигырь нишләптер чыкмый, ә хикәя-мазар язарга «мәүзугъ»[1] таба алмыйм. Әллә пьеса

---

[1] *Мәүзугъ* — тема.— *Ә.Е.*

язып караргамы?.. Театр куярга җыенсак, пьеса таба алмыйча йөдибез. Шәп булыр иде, барып чыкса!.. Көннәрдән бер көнне Дәүләкән коймаларында шәмәхә кара белән язылган афишалар: «Бәлдәй клубында фәлән-фәләневнең биш пәрдәлек әсәре куелачак!..» Ха, моңа хәтта Һаҗәрнең дә исе китәр иде. Тик менә нәрсә хакында язырга?.. Үзебезнең тирәдән бернәрсә дә табылмый бит әле... Әллә, булмаса, Англиядәге эшчеләр хәрәкәте турында язып караргамы?.. Тәк, тәк, газеталарда да күп язалар андагы эшчеләрнең революцион көрәше турында... Валлаһи дип әйтәм, мин шундый пьеса язарга тотынган да идем. Газеталардан инглиз исемнәрен чүпләп алдым, шуларны «катнашучылар» итеп тезеп чыктым һәм яңа биттән аларны «уйната» да башладым... Ярый әле тиз айныдым мин бу эштән... Юк, егетләр, язучы буласы килгән кешенең бала чакта да ахмак булырга хакы юк!..

...Тагын өстәп шуны да әйтәсем килә: мин әүвәлгечә һаман китап укырга ярата идем. Күбрәк иске әдәбиятны, чөнки яңасы бик аз табыла иде әле... Ул чактагы минем хыялларыма иске әдәбиятның турыдан-туры йогынтысы булгандыр, ахрысы... Мәсәлән, мин өметсез мәхәббәттән чахоткага сабышканмын, имеш. Мин үлем түшәгендә, көннәрем дә санаулы гына калган... Ә күршебездә Һаҗәрнең туен гөрләтеп үткәрәләр икән. Аны кызыл симез чырайлы бер таза егеткә бирәләр, имеш. Мин менә шул туйны — ишегалларыннан ишетелеп торган җыр-музыка тавышларын, егетләр-кызларның шатланып көлүләрен ишетеп ятам... Бик авыр, имеш, минем хәлем... Ул да булмый, берзаман кыңгыраулы пар атларда Һаҗәрне егет йортына алып китәләр. Шул чагында мин актык көчемне җыеп урынымнан торам да, ачык тәрәзәгә сөялеп, соңгы мәртәбә скрипкада бик моңлы бер көй уйныйм, имеш!..

Очтылар «моңнар» фәзага җырлашып кызлар белән.
Мин торып калдым, торып калдым күңел сызлау белән!..[1]

Әнә шундый төче, сентименталь, мәгънәсез хыял... Әлбәттә, каяндыр кергән инде ул миңа...

Егерме бишенче елны Казанга киткәч тә, мин Һаҗәр турында уйланудан туктамадым. Казан минем дәрәҗәмне аның алдында күтәрергә тиеш иде. Дөрес, килгән елны ук миңа уку насыйп булмады, китап магазинында курьер булып кына эшләргә туры килде. Аның каравы «Безнең юл»да минем «Озын көй тыңлаганда» дигән беренче зәгыйфь кенә әйберем басылып чыкты... Әйбер зәгыйфь

---

[1] Шәехзадә Бабичтан.— *Ә.Е.*

булса да, журнал үзе бик авторитетлы иде — шул заманның бөтен мәшһүр язучылары аның битләрендә басыла иде. Менә мин дә шулар арасына кысылдым.

Егерме алтынчы елның җәендә мин яңа чалбар, яңа ботинкалар киеп, «Безнең юл»ны да үзем белән алып, Дәүләкәнгә ялга кайттым. Бу вакытта шактый гына чибәрләнеп тә киткән идем, коңгырт чәчләрем дә ак маңгаема алкаланып төшеп тора иде. Дәүләкәндә калган иптәш малайларым да, таныш кызларым да миңа, билгеле, шунда ук игътибар иттеләр, кызыксынып, сокланыбрак карадылар. Как же, Казаннан кайткан егет!.. Ә Казан ул елларда Дәүләкәннән бик еракта иде.

Кайткан көнне үк мин Борһан абзыйларга да кердем, һәммәсе белән дә күрештем, һәммәсе дә мине шаулап каршы алдылар. Һаҗәр дә миңа игътибар итмичә калмады — күреште, төбәлебрәк карады, хәтта сөйкемле генә елмайды да...

...Ул чакларны искә төшерсәм, бәгырьне үкенү хисе телеп уза: Ходаем, нигә дим, мин, шулхәтле җебегән булдым икән?! Үземне иркен, бәйсез тотасы урында, тагын элеккегечә кызара, тотлыга башлыйм. Гүя мин, чәч җибәреп кайтсам да, һаман әле малайлыктан чыгып җитмәгәнмен, ачу китергеч хәл! Тагын иң хәтәре: Һаҗәр алдында каушау ничектер гадәткә керә язды, соңыннан башка кызлар алдында да мин еш кына югалып кала торган булдым. Ә туташым яңадан салкын калыбына керде, горур-өстен ул, хәтта Казан журналында минем исемем белән басылган «Озын көй...» дә аңа тәэсир итмәде бугай... Һәрхәлдә, укыды да, бер сүз әйтмичә, кире кайтарып бирде. Әмма шунысына шөкер итәм, аның тирәсендә күп чуалмаска минем шулай да көчем җитте. Бик тиз бергә үскән, сагындырган дусларым арасына кереп киттем. Безнең бергә иңләгән Димкәебез бар, аның киң тугайлары бар, тугайларында камышлы күлләре бар — җаның теләгән кадәр чап, чум, уйна, ауна!.. Миңа, Казанның салкын кышын ике-өч көнгә бер генә ягылган һәм юньләп яктыртылмаган да ташландык йортында үткәргән, тәмам суырылып, агарып кайткан япь-яшь егеткә тагын ни кирәк?! Ул йорт турында, җае чыкса, сүз булыр әле, ә хәзергә әйтәсе килгәнем шул — минем үпкәләрем элек тә бик үк сәламәт түгел иде, язын үземне начар тоя башлап, Әбүбәкер абзыйга[1] күренгәч, ул миңа туп-туры әйтте: «Энекәш, йөрмә монда, Дәүләкәнеңә кайт, саф һавада йөр,

---

[1] *Доктор Әбүбәкер Терегулов* — соңыннан профессор. Безнең Каргалыдан чыккан кеше.— *Ә.Е.*

кояшта кызын, күбрәк сөт-май аша, хәлеңнән килсә, кымыз эч!» — диде. Димәк, мин әле сәламәтлегем турында да уйларга тиешмен икән. Әбүбәкер абзый киңәшләрен тоту Дәүләкән шартларында бик җиңел иде... ул елларда. Барысы бар, барысы җитәрлек, һава да, ризык та саф, пакь, шифалы. Сөт-май үзебезнеке, яшь сарык ите көн дә базарга чыгып тора, ике көннең берендә Акколайдагы дус башкортыбыз бер чирек кымыз да калдырып китә.

Аннары минем белән бер вакытта Казаннан Фәтхелислам белән Хәбибрахман да кайтканнар иде. Уфадан кайтучылар да бар иде. Дәүләкәннең үз яшьләре дә күп, бик активлашып барган чаклары. Клубка җыелу, спектакльләр кую, кичке уеннарга чыгу, Дим өстен яңгыратып көймәләрдә йөрү — болар гадәткә кергән күңел ачулар, ләкин мин алар хакында хәзергә сөйләп тормыйм, чөнки бу күңел ачуларның берсенә дә Һаҗәр йөрми-катнашмый иде. (Бәлки, атасы тыйгандыр, ә бәлки, үзе теләмәгәндер.) Шул сәбәпле минем өчен иң якты хатирәләр белән бәйләнгән күмәк уеннарда аның урыны буш, бары тик күңелне әкрен генә сызландырып, кайдадыр эчтә генә ул саклана иде.

Көзен яңадан Казанга баргач, мин, ниһаять, укырга керә алдым. Уку ул минем киләчәгем — башка бүтән юл юк миңа. Язучы булыр өчен дә уку зарури. Аңлырак яшьләрнең барысы да хәзер укырга омтыла — Себердән, Уралдан, Донбасстан һәм тагын бик күп яклардан татар яшьләре агылып килә башладылар. Казан урамнары йөзләренә азрак аптырау да, кызыксыну да, куану да чыккан бик чуар киемле шул яшьләр белән тулды. Бездән күрмәле дигәндәй, бу көзне бер унлап Дәүләкән яшьләре дә Казанга килделәр. Кайсылары татрабфакка, кайсылары педтехникумга урнаштылар. Урнаша алмаганнары кире кайтып киттеләр. Торып калганнары барысы да диярлек электән үк бергә укыган, бергә йөргән таныш егетләр һәм кызлар иде. Бары казакъ Усман дигәне генә ят егет, яшькә дә олы, үзен бик өстен тотарга да яратучы иде. Кәкрерәк нечкә борынының ике ягында батып торган соры-салкын күзләре дә аның кешегә гел сынап, шикләнеп карыйлар төсле иде. Ул совпартшколага укырга керде. Калганнарыбыз исә якын авылдашлар сыйфатында еш кына очрашып, хәбәрләр уртаклашып, өйдән килгән күчтәнәчләребез белән дә сыйлашып тора идек.

...Инде студентлар буларак без барыбыз да кышкы каникул вакытында тагын Дәүләкәнебезгә кайттык. Ике атна чамасы вакытны концертлар куеп, кунакларга йөрешеп бик күңелле генә уздырып җибәрдек. Менә шушы

вакытта минем өчен фәүкылгадә бер вакыйга булды — гомеремдә беренче мәртәбә Һаҗәр белән киногa бардым. Бу «бәхеткә» мин күршебез Таифә апа аркасында ирештем. Билгеле, минем үтенүем буенча, ул башта Һаҗәрне үзләренә кич утырырга чакырган, аннары ничектер җайлап-көйләп кенә киногa барырга күндергән. Шулай итеп, без өчәүләшеп иске заманнан ук эшләп килгән «томанный»га киттек. Билетлар алып, залга кергәч, Һаҗәр уртага утырудан да баш тартмады. Картина, әлбәттә, хәтердә калмаган. Янымда гына «ул»! Маңгай күзе экранда булса да, күңел күзе бары тик аңарда гына!.. Билгеле, мин аның җиңенә кагылырга да җөрьәт итә алмадым. Шулай ук бернинди сөйләшү дә булмады. Бәлки, Таифә апаның янәшә генә утыруы да телне бәйләгәндер, хәер, бик игътибар белән кино караган кызга нәрсә генә әйтә аласың?!

Карап бетердек, салкын төнгә чыктык, шыгыр-шыгыр атлап өйләргә ашыктык... Өйләребез бер төштә, кайтып җиткәч, урам уртасында туктадык. Хуш, шуннан соң?.. Шуннан соң кызларга хәерле йокы теләргә генә калды. Ләкин хәерле йокы теләр алдыннан мин шулай да Һаҗәрдән сорадым:

— Һаҗәр, сезгә хат язарга ярыймы?

Ул әз генә көттереп һәм юри генә көлемсерәгән булып:

— Языгыз! — диде.

Шуннан соң инде кызларым үзләренә кереп киттеләр, ә мин капкабызга таба атладым. Өйгә керәсе килми иде, бераз рәшәткәгә сөялеп тордым. Дәүләкән йоклый, тынлык һәм бушлык... Минем күңелдә дә шулайрак... Нәрсә генә бирде миңа бу көтеп, теләп алган киногa бару?.. Бер генә өмет чаткысы да кабызмады шикелле ул миндә... Гүя урыннарыбыз ялгыш кына янәшә туры килгән — ул үзенә, мин үземә!.. Ул рәхәтләнеп кино карый, ә мин, тиле, чыкмаган кояшка җылынып утырам. Минем чакыруымны кабул итеп килсә дә, аңа һаман иске эчпошыргыч «уенны» дәвам иттерергә кирәк: янәсе, мин ялынучы, ул ялындыручы!.. Хат язарга рөхсәт иткән булуы да, белеп торам, шул ук уен!.. Инде вакыт түгел микән бу мәгънәсез «уенны» туктатырга?! Миңа бит тиздән унсигез тула. Дөньяда кызлар беткәнмени — бигрәк тә укучы яшьләр белән тулы Казанда!.. Нигә әле вакытны заяга уздырырга?

...Тын, салкын төндә ялгыз рәшәткәгә сөялеп, мин әнә шундыйрак әче-әрнүле, ләкин ничектер җиңеллек тә китергән айну кичергәндәй булдым. Һәрхәлдә, Һаҗәргә өмет баглауның бикәрлеген аңладым бугай... Әйе, оны-

тырга вакыт, онытырга!.. Башканы эзләргә, башканы табарга — тик күңелдә бушлык кына туа күрмәсен!.. Шулай, кәбәм, балалыктан чыктык, егет булырга вакыт!.. Иртәгә — сәфәр... Әмма җәйләр җитәр дә тагын шушы сары йорт күршесенә кайтырга туры килер... Хәтәр, бик хәтәр «мәхәббәт»нең күршедә генә булуы... Яңармас микән яңадан бөтенесе дә йөрәктә, Ходаем?!

Егерме җиденче елның җәендә, укуларны бетергәч, без-яшьләр тагын үзебезнең Дәүләкәнебезгә кайттык. Бу инде июнь ахырлары булгандыр. Гадәттәгечә, якын күршеләребез Бибикамал апаларга һәм Борһан абзыйларга кереп, күрешеп чыктым. Һаҗәрне күрмәдем — Хәйретдин җизниләргә киткән иде, диделәр... Бер атна чамасы вакыт узды, ә минем аны һаман күреп сөйләшә алганым юк әле. Сылтаусыз керергә кыенсынам, ул бит инде егерме яшьлек туташ, әдәп кагыйдәсен сакламыйча булмый... Әлбәттә, без очрашмыйча калмабыз, күрешербез, сөйләшербез дә, тик менә ничегрәк каршы алыр ул мине, ничегрәк үзен тотар икән — нигәдер тагын бер сынап карыйсым килә туташымны!..

...Ә матур иртәләрнең берсендә, булачак очрашу турында әнә шулай хыялланып яткан чакта, каршыбыздагы Габдрахман кереп, сөенче әйткәндәй авызын ерып, миңа хәбәр салды:

— Беләсеңме, синең Һаҗәреңне бер егет алып киткән бит, әй!

Мин ирексездән сискәндем, ләкин:

— Юкны лыгырдама! — дидем, ничектер уйламастан гына.

— Ышанмасаң, әнә энеләреннән сора!

— Койма аша гына торабыз, алып китсәләр, кыңгырау тавышларын мин дә ишетер идем,— дигән булам, акылга сыймас бу хәбәрне уенга борырга теләп. Ә Габдрахман, күзләрен хәйләкәр генә кысып, отыры мине үртәгәндәй:

— Атлар җиктереп торырга вакытлары булмаган шул,— ди.— Кечкенә төенчеген алган да шыпырт кына чыгып сызган... Һаҗәрең!

Юк, әллә нәрсә бу, шайтан алгыры!.. Габдрахманны беләм мин, кеше үртәргә, ялган сөйләргә аңа гына куш! Әмма... Әмма бу юлы ялганламый кебек, явыз!

— Ни сөйлисең син... черки? — дим мин, кашларымны җимереп.

— Белгәнемне сөйлим... Ялганласам, баскан урынымда җир йотсын!

Мин сикереп тора яздым, ләкин тыелып калдым. Ни-

һаять, ышандым һәм... тындым. Дөньяда булмый торган эшмени ул?!

Габдрахманның әйткәннәре дөрес булып чыкты: Һаҗәр кичә көпә-көндез, әтисенә дә, үги әнисенә дә әйтмичә генә, бер егеткә ияреп киткән дә барган. Станциядә Хәйретдин җизнәсе аларны озатып та калган, имеш.

Бу эшнең ничек булганын төпченеп сорашу минем өчен бик уңайсыз иде. (Ничек тә сер сынатмаска кирәк иде миңа.) Шулай да әкренләп кайбер нәрсәләрне белдем: ияртеп китүчесе Ыслактан килеп чыккан Низам исемле бер егет, имеш. Борһан абзый күршесе Арыслангәрәй агайларда күпмедер вакыт кымыз да эчеп торган... Һаҗәр белән танышып китүе шул чакта булгандыр, ахрысы.

Хуш, ярый, исемнәре Низам да булсын ди, ә ниндирәк кеше икән соң ул егет?.. Белгәнрәк кешеләрнең әйтүләренә караганда, ул, имеш, гади авыл гыйбаты гына түгел, утырган, чарланган һәм күпмедер укыган да егет, янәсе; җитмәсә, Ыслакның беренче комсомолларыннан ди, ниндидер әйбәт кенә урында эшли дә икән... (Ыслак — волость үзәге иде.) Боларның күпмесе дөрестер, әмма шомарган егет булса кирәк, Һаҗәр кебек һавалы кызны үзенә карата белгән... Ләкин һавалы кызмы соң Һаҗәр? Беренче очраган егеткә тагыл да кит, имеш,— кайда монда кызлар горурлыгы?! Хәер, белмим, аптырап кына әйтүем, гайбәтенә керәсем килми... Җаны теләгән — җылан ите ашаган, диләр, хәерле булсын!.. Мәгәр нишләргә инде миңа, утырып бер җыларга, што ли? Юк, булмый, ярамый... Яшерә алмыйм, өметләрнең болай кинәт кенә өзелүе күңелләрне бәк әчеттерде әчеттерүен (сигез ел буена саклап килгән өметләр иде бит), әмма ант итеп әйтә алам: артык гамь-хәсрәт чикмәдем мин... Күрәсең, көтеп алган хәсрәт булгандыр...

Гаҗәп, Дәүләкәннең үзендә Һаҗәр кебек чибәр кызга кеше табылмаган. Югыйсә йорт саен диярлек мыек чыгарган егетләр бар... Бәлки, Һаҗәрнең «купич» кызы булуы аларны куркыбрак торырга мәҗбүр иткәндер. Мәсьәләнең бу ягына хәзер бик игътибар итә башладылар. Ә Ыслак егете әнә бер дә куркып тормаган... Беләм мин ул Ыслакны! Әлшәйдән ары, Корсак буенда утырган (Корсак — кечкенә елга исеме.) бишме-алтымы мәчетле бик зур мишәр авылы. Базарында да, җыенында да булганым бар. Мәгълүм ки, зур авылның халкы, гадәттә, бик чуар була. Андый авылларда исемле байлар, мулла-мунтагайлар, фанатик картлар белән беррәттән ата дәһриләр дә, җете коммунистлар да, чая комсомоллар да күп табыла. Низам

иптәш тә әнә шундыйларның берсе булса кирәк. Югыйсә Дәүләкәнгә килеп, «купич» кызын сорамыйча гына алып китәргә батырчылыгы җитмәс иде.

Шулай итеп, Дәүләкәнебездә бер кыз кимеде. Ләкин моңа әллә ни зур әһәмият бирмәделәр шикелле, азрак тел кайрадылар да тындылар... Бездә яшьләр болай да җитәрлек, җәйнең матур чаклары, йөрүләр, күңел ачулар көн саен диярлек булып тора... Мин дә шулар арасында, шул ваемсыз хәят эчендә, бер уеннан, бер тамашадан калмыйм, әмма шулай да кара-калын толымлы «күрше кызы» минем күңелемдә тынып бетмәгән, ләкин әкрен генә ераклаша барган җыр шикелле һаман саклана иде әле.

...Тиз узды шау-шулы көннәр, җәй дә үтте, китәр вакытлар да җитте. Тавыш-тынсыз гына аккан Дим белән хушлаштым, тып-тын айлы төн белән хушлаштым, инде яңадан терелмәс хыялым белән дә хушлаштым...

Казанга кайткач, минем башка бүтән гамьнәр төште. Хәлләр тиз үзгәреп тора бу заманда... Миңа укуны калдырып, Донбасс якларына китеп барырга туры килде (сәбәбен — соңыннан). Шуннан соң шактый еллар узды, күп нәрсәләр баштан кичте, ә Һаҗәр әкренләп һаман ераклашты... ераклашты, әмма бөтенләй үк онытылып бетмәде — кечкенә бер төер сыман күңелнең ниндидер яшерен бер җирендә сакланып ята бирде. Хәбәрем юк, кайда икәнен дә белмим, тик әллә нидә бер искә генә төшергәлим. Ләкин шулай да каяндыр, кемнәндер колакка кайбер хәбәрләр килеп керде: Һаҗәрләр күптән Кырымда торалар, ире — Низам иптәш — шундагы органнарда эшли икән. Димәк, тормышлары яхшы көйләнгән булырга тиеш.

1972 елны, ягъни кырык биш елдан соң, мин Һаҗәрне күрдем. Бу вакытта алар Ессентукида торалар иде — мин моны белә идем. Өч тапкыр Кисловодскида булдым. Икенче баруымда Һаҗәрнең Казанда торучы җизнәсе Хәйретдин абзыйдан Низам Вәлиуллинның адресын алып киттем. Ләкин Кисловодскига соңгы баруымда гына, кайтып китәр алдыннан, мин аларны шул адрес белән эзләп таптым. Акка буяган бер катлы, өч тәрәзәле таш йортның капкасыннан барып кердем. Керүгә үк — җыйнак кына җимеш бакчасы, шул бакчага чыккан өй баскычы һәм шул баскычта... Һаҗәр үзе... Мин аны күрүгә таныдым. Ихтимал, белеп килгәнгә күрәдер, ләкин шулай да алтмыш биш яшьлек карчыкның Һаҗәр икәнлеген танып булырлык иде. Буе-сыны да, йөзе белән кечерәк күзләре дә аның кыз чагын яхшы ук хәтерләтә иде...

Мин аңа: «Һаҗәр!» — дип дәштем һәм: «Таныйсызмы?» — дип сорадым. Ул миңа аптырабрак, сүзсез генә берављык карап торды, бәлки, кем икәнлегемне әзрәк чамалагандыр да, ләкин катгый рәвештә: «Юк, танымыйм»,— диде... Мин исемемне әйттем. Шуннан соң ул чынлап гаҗәпләнде, ирексездән әкрен генә: «Ходаем!» дип тә куйды, ничектер каушый да төште, йөзенә бераз гына куанычлы елмаю да чыкты: «Сез,— диде,— ничек болай,— диде,— кайдан?.. Әйдә узыгыз!..» диде һәм шунда ук артына борылып, өй эченә: «Низам, чык әле, безгә... менә кем килде!» — дип кычкырды, әмма ни өчендер исемемне әйтмәде.

Өйдән искерәк күлмәк, таушалган чалбардан гына, буйга миннән кайтышрак һәм юанрак кеше чыкты. Бу инде миңа бик күптән таныш Ыслак «егете» Низам үзе иде, әмма менә болай якыннан каршымда күрүем гомеремдә беренче тапкыр гына! Ул да мине гомерендә беренче тапкыр гына күрә, ләкин минем кем булуым турында бөтенләй хәбәрсез иде бугай... Һаҗәр дә безне нигәдер таныштырмады. Шуңа күрә минем үземә кем булуымны, кайдан килүемне, Һаҗәр ханымны бала чактан ук белүемне әйтеп бирергә туры килде. Ул моны бик хуплап каршы алды һәм бик әйбәтләп минем белән күреште.

...Өйгә кердек, утырыштык. Өйдә тагын бер яшь хатын бар иде — бу Һаҗәрнең Ленинградтан кайткан кызы икән. Аның кулында япон балаларына охшаган ике яшьлек чамасы бик сөйкемле кара гына кызы да бар иде... Утырышкач, алар минем кайчан килүемне, кайда ял итүемне, тагын күпме торасымны сораштылар. Шуннан соң Һаҗәр торып ук китте (күп булса, бер биш минут утыргандыр), без Низам белән икәү генә калдык.

Мин бөтен «тарихны» белгәнгә күрә, аңа, билгеле, бик кызыксынып карыйм, ләкин аның егет чагын бер дә күз алдыма китерә алмыйм. Ул бик үзгәргән булырга тиеш. Хәзерге кыяфәте исә шәптән түгел — бик тузган, таушалган кешенекенә охшаган. (Ахрысы, эчкәндер дә... Бу хакта ишеткәнем дә бар иде.) Битен-муенын җыерчык басып бетергән, чәчләре күптән сирәгәеп, агарып беткән, куе кашлары чуалып, асылынып төшкән. Әмма тузган кыяфәтле булуына карамастан, ул шактый тере, җегәрле күренә иде. Аннары сүзгә бик юмарт икән. Беренче генә күрешүебез бит, ләкин шулай да мине якташы итепме, әллә моннан кырык биш ел элек Һаҗәрнең «күршесе» булганга күрәме, үзләренең бөтен тарихларын миңа сөйләде дә чыкты.

Әйе, алар сугышка чаклы Кырымда торганнар. Ул, Низам Вәлиуллин, комсомолдан алып пенсиягә чыкканчы гел органнарда эшләгән. (Ләкин шуларның кайсында эшләгәндер — үзе әйтмәде, ә мин сорамадым.) Сугыш башлангач, Һаҗәрне ике баласы белән тиз генә туган авылы Ыслакка илтеп куйган. Шунда ук кире Кырымга кайткан һәм мондагы партизаннар отрядының командиры булып, немецларга каршы сугышкан. Немецларның теңкәсенә бик нык тигән булса кирәк, алар аның башы өчен ун мең марка акча да вәгъдә иткәннәр. Шулай да фашистлар кулына эләкмәгән. Кырымны азат иткәч, яңадан үз эшенә кайткан, Кырым татарларын күчерүдә актив катнашкан, ләкин соңыннан үзе дә бу җирләрдә торып кала алмаган... (Кырым хәлләре турында сөйләгәндә Низам иптәш: «Гаммасын да (ягъни, һәммәсен дә) кирәк имәс иде»,— диде. Аның теле шулай кырымчарак иде.) Шуннан соң Башкортстанга кайткан, ләкин анда озак төпләнеп тора алмаган, яңадан бу тарафларга күчерүне сораган. Шулай итеп, начальство боерыгы белән Ессентукига килеп урнашкан. Аңа шушы аерым йортны биргәннәр... Тагын күпмедер органнарда эшләп, ахырда пенсиягә чыккан. Хәзерге вакытта бакча карап, чәчәкләр үстереп, карчыгы белән тыныч кына яшәп ята... Хезмәте, әлбәттә, җиңел булмаган, ләкин тормышы әйбәт тәэмин ителгән булса кирәк. Һәрхәлдә, «күршем» Һаҗәргә, таш койма эчендә утыргандай, газап һәм нужа кичерергә туры килмәгән — шулай аңладым мин... Һәм эчемнән генә уйлап куйдым: әгәр язмыш аны минем белән бәйләгән булса, «Лаеш шулпасы»н аңа шактый үк эчәргә туры килгән булыр иде.

Хуҗа сөйләгән арада, Һаҗәр чәй өлгертте, табын әзерләде. Ул һаман үз эшләре белән йөренеп торды. Гүя әдәп өчен генә килеп утыра да бер-ике минуттан тагын торып китә... Хозяйка кешенең эше бетәмени, дидем мин баштарак, аннары ирексездән бу аның элеккечә читләшеп маташуы түгелме икән, дип тә уйлап куйдым. Бәлки, ялгыша да торганмындыр, ләкин сүзгә бер дә катнашмавы миндәге каядыр сакланып яткан шикне уятырга җитә калды... Инде чынлап та читләшүе булса, бу... бу бик гаҗәп, әлбәттә. Ул борынгы Һаҗәр түгел, мин борынгы Әмир түгел — без шулкадәр ераклашканбыз ки, яшьлектә булган хәлләргә инде ышануы да читен. Ләкин бит без бер туфракта күршеләр булып үстек — моны онытырга, моның белән исәпләшмәскә мөмкин микәнни?! Хәер, кеше күңелен кара урман диләр, аның караңгы почмакларында ниләр генә ятмый торгандыр!

Чәйгә утырышкач, Һаҗәрнең теле шулай да бераз ачылды. Ул, сирәк кенә булса да, Уфага кайткалый икән (Дәүләкәнгә кайтканым юк, диде), минем турыда да братларыннан әзрәк ишеткәләгән. Мәсәлән, минем язучы булып китүемне белә икән. «Сез бит яшьтән үк язгалый идегез шикелле»,— диде ул миңа. Әнә шулай уйламастан гына минем яшьлеккә кагылып алды. Ләкин тизрәк башка сүзгә күчте. Гаиләм, балаларым турында бераз сорашты. Сүз ахырында мин яңадан әдәбиятка күчеп, сез кыз чагыгызда укырга ярата идегез, мин сезгә китап ташый идем, дидем. Ул көлемсерәп кенә: «Онытмагансыз икән әле»,— дип куйды. «Ә хәзер ничек?» «Вакыт булганда хәзер дә укырга тырышам»,— диде. Билгеле, русча гына укый икән, татар китапларыннан күптән аерылган... Кайткач, берәр китабымны сезгә җибәрермен, дидем мин аңа. Ул моңа каршы ризалыгын белдергәндәй башын кагып: «Рәхмәт»,— дип куйды.

...Чәйдән соң мин кузгалдым, алар мине озата чыктылар. Әзрәк бакчаларын да күреп китәсем килде. Роза чәчәкләре монда күп иде. Һәм бик эреләр, бик матурлар иде алар... Минем сокланганны күреп, Низам иптәш: «Әллә бер-ике төбен биреп җибәримме?» — диде. «Белмим шул,— дидем мин,— кайтып җиткәнче корымаслар микән?..» «Тамырларын юеш чүпрәккә төреп тотсагыз, берни булмый»,— диде Низам һәм тиз генә ике төп розаны казып та алды, юеш чүпрәккә әйбәтләп төреп тә бирде... «Рәхмәт, сезнең истәлек булыр»,— дидем мин аларга... Чыгып киткәндә баш иеп Һаҗәрнең кулын кыстым, ә Низам мине вокзалга кадәр озата барырга булды. Юл өстендә винолар сата торган бер подвал очрады, мин юлдашымны шунда кереп чыгарга чакырдым, ул берсүзсез риза булды. Кыскасы, Низам иптәш белән безнең «борчак пеште». Ике көннән инде мин Казанга да кайтып китәргә тиеш идем.

...Әнә шулай узды минем кырык биш елдан соң Һаҗәрнең үзен дә, ире Низамны да беренче һәм соңгы мәртәбә күрүем... Үземне бер сынап карау булды бу... Шөкер, «уңышлы» үтте — барысы да күптән сүнгән, беткән икән инде...

Казанга кайткач, озакка сузмыйча, мин Һаҗәр исеменә татар һәм рус телендә ике китабымны җибәрдем, әмма Һаҗәрнең үзеннән: «Алдым, рәхмәт»,— дигән хәбәр килмәде... Саклап алып кайткан розаларым да, үземчә яхшылап утыртуыма карамастан, тамырлана алмадылар. Язга чыккач та корыдылар.

...Еллар узып, дөньяны да таный башлагач, мин ирексездән уйлап куя идем: Һаҗәр теге чакта Ыслак егетенә

ияреп китеп дөрес эшләгән бит!.. Аңа бит инде башка юл юк, калмаган. Егермегә җитеп килгән кыз үзенең киләчәге турында ничек уйламасын да борчылмасын ди?! Атасы Борһан абзыйның сәүдә эшләре бүген булмаса иртәгә сүтелергә, бетәргә тора. Алда нинди язмыш көтә — билгесез. Мондый хәлләрдә купец кызларының аңлырак, җитезрәкләре ышанычлы кешеләргә сыеналар икән, моңа бер дә гаҗәпләнергә туры килми. Булды андый эшләр... Безнең әдәбиятта да бу нәрсә үзенең чагылышын тапты.

Әгәр дә Һаҗәр үзенең Низамын яраткан да булса (әлбәттә, бөтенләй яратмыйча кушылмагандыр инде), димәк, ул аңа тагылып китеп бик дөрес эшләгән — ир канаты астына кергән, гаилә корган, тормышын тәэмин иткән. Билгеле, аңа шул гына кирәк тә булгандыр...

Инде бер генә минутка фараз кылыйк: Һаҗәр, минем яратуыма ышанып, шул чакта миңа чыгарга риза булды ди. Ә мин аны тизрәк үземә алдым ди... Моның ахыры ни булыр иде икән?.. Менә шуны уйлыйм... уйлыйм да ихтыярсыздан калтыранып куям. Бик зур бәхетсезлеккә дучар булыр идек шикелле... Иң элек, мин аңардан яшьрәк, укып маташкан чагым, хатын асрарлык урыным да, рәтем дә юк. Аннары, иң хәвефлесе — мин үзем дә чыгыш ягыннан Һаҗәрнең ише диярлек, ә ул чактагы шартларда бу инде җанны бик борчый торган мәсьәлә иде. Менә шундый хәлләрдә мәхәббәт хакына өйләнеп кара инде!

Ярый, илдә чыпчык үлми, дигәннәр, без дә, нужа ләмкәсен иңебезгә киеп, дөньябызны ничек тә сөйрәгән булыр идек әле... Әмма эш бары тырыша-тырмаша яшәп маташуда гынамыни?.. Бергә тора алу өчен ипи-су белән бер үк дәрәҗәдә мәхәббәт тә кирәк түгелме соң?.. Чын бәхет бары шунда гына ич!.. Инде уйлап карагыз, ниндидер сәбәпләр аркасында минем белән кушылырга мәҗбүр кыздан элек булмаган мәхәббәтне хәзер көтеп булачакмы?.. Әлбәттә, юк яки... бик тә шикле... Асылда ул болай булачак: мин аны яратачакмын, ә ул мине ярата алмыйча интегәчәк. Йә, моңардан да зур бәхетсезлек булырга мөмкинме?! Бу бит гомерлек газап, гомерең буена сызланып-сызып яшәү дигән сүз!.. Мин үзем моның нәрсә икәнен яхшы беләм, һәм Һаҗәрнең дә мондый хәлгә дучар булмавына ирексездән сөенәм. Әйе, күпме сабырлыклар кирәк яратмыйча яши алыр өчен!..

Ә миңа исә күк томаннар артында торып калган ерактагы, бик ерактагы әнә шул бәхетсез мәхәббәтем нигәдер бик кадерле. Бәлки, ул таш астыннан чыккан яшь үлән шикелле саф мәхәббәтем мине гел генә хыял дөньясына

китеп яшәргә, шуннан үземә ләззәт, юаныч табарга өйрәткәндер; бәлки, ул мине Дим буйлары өстендәге айлы кичләрнең тирән тынлыгын ишетергә өйрәткәндер; бәлки, ул мине җирдәге һәм судагы барча җан ияләренә миһербанлы булырга өйрәткәндер... Мәхәббәтнең кодрәте чиксез — аның хәтта караңгы чырае алдында да сәҗдәгә егылырга ярый!

Миңа тагын чигенергә туры килә. Казанга китәр алдыннан Дәүләкәндә үткәргән соңгы елым турында язмыйча үтү мөмкин түгел — шактый күп вакыйгаларны эченә ала ул соңгы елым... Минем «сәхифәләрем» берберсенә ялганып барырга тиеш.

Иң әлек, үз хәлебез турында. Атайның эшләрен шәптән димәс идем. Йөри, чаба, ансын ала, монсын сата, ләкин бер дә күтәрелеп китә алмый. Самарга йөрүен дә ташлады, чөнки иске кием-салым үтми башлады. Кытлык бетте, кеше хәзер яңасын кияргә тырыша... Ә атай еш кына сума юк дип зарлана. Димәк, зуррак сәүдәгә аның инде үз көче генә җитми. Берәр кеше белән кушылып, уртак эш башларга да уйлана иде шикелле...

1924 елның җәендә Эстәрлетамактан Муса Хәбиров дигән кеше яшь хатыны белән Дәүләкәнгә килде. Алар безгә фатир керделәр һәм өебезнең зал ягында тора башладылар. Без инде йортны сатып алган көннән диярлек зал якка фатир кертә башлаган идек. (Билгеле, акчасы килсен өчен.) Семьябыз бәләкәй булгач, өйнең эчке башы да безгә җитә иде. Фатирчылар китеп, зал як күпмедер вакыт бушап торганда, без үзебез дә иркенләп бер торып кала идек.

Әйткәнемчә, Муса абзый Хәбиров, кара айгыр җиккән яхшы тарантаска яшь хатынын утыртып, безгә килеп керде. Аның шул кара айгыры белән яхшы тарантасыннан башка бүтән бернәрсәсе юк та иде. Кием-салымнары, ястык-мендәрләре исәпкә керми, ә калганы, мәсәлән, өй җиһазлары — барысы да бездән иде.

Муса абзый Эстәрле мулласының улы икән. Яхшы ук укымышлы булырга тиеш. Әрмәнгә охшаган зур күзле, озын борынлы кара кеше, тик буй-сын гына әрмәннеке түгел — юанрак та, аяклары да кәкрерәк... Ә менә яшь хатыны Зәйнәп апа иреннән калкурак, бик зифа да һәм бик чибәр дә иде, чем-кара чәч, сызылып киткән кара каш, тулы гына шома битенең ике ягы да чокыраеп тора һәм шушы нәни чокырчыклар аны аеруча ягымлы-мөлаем итеп күрсәтә иде. Шуның өстенә ул гаҗәеп шат табигатьле, көләргә дә, сөйләргә дә яратучан

алчак бер хатын да иде. (Иренең нәкъ киресе.) Мандолинада чибәр генә уйный иде.

Ул Троицк кызы икән. Алдынгы сәүдәгәр гаиләсендә үскән булса кирәк. Кыз чагын исенә төшереп сөйләгәне хәтеремдә. «Без, кышкы салкын кичләрдә,— дип сөйләгән иде ул,— бөтен гаиләбез белән җылы залдагы зур түгәрәк өстәл тирәсенә җыелып, яшел абажурлы асылмалы лампа яктысында һәркайсыбыз нәрсә дә булса укып утыра идек. Әтием, гадәттә, «Вакыт» яки «Шура»ны укый торган иде, энеләрем «Ак юл»ны карый, ә мин «Аң» белән «Сөембикә»не укырга ярата идем. Безгә шуларның барысы да килә иде. Әтием бик һәвәс иде укырга. Әнә шулай үткәрә идек без кышкы озын кичләрне...»

Һәм шушы татар әдәбиятын укып үскән, татарча бик матур сөйли белгән, музыкага да сәләте булган туташны Муса абзый Троицкига барып, никахлап алган, Эстәрлегә әтисе йортына килен итеп алып кайткан, аннары, озак та тормыйча, ни өчендер Эстәрледән Дәүләкәнгә китергән. Безгә фатирга килеп керүләре кем аркасында булгандыр инде, ләкин мин үсмер малай башым белән моны үзем яхшыга юрадым. Зәйнәп апа кебек чибәр, ачык, мөлаем, мәдәниятле яшь кенә хатынның ниндидер бер якты, матур эзе күңелләрдә калырга тиеш иде. Ул еш кына, безнең якка чыгып, инәй белән сөйләшеп утырырга ярата иде. Шул чакта мин аңа, барлыгымны да сиздермәскә тырышкандай, читтән генә карап утыра идем. Ә ул Троицк каласы, аның кызлары, егетләре, андагы сагынуларын аңлатасы килгәндәй, башын кырын сала биреп, мандолинада уйнап җибәрә иде. (Ихтимал, шушы ишетүләр нәтиҗәсендәдер инде, минем күңелдә Троицк каласына гомерлек бер мәхәббәт тә уянып калган иде. Әмма кайчандыр татар халкының шактый гына күренекле мәдәни бер учагы булган даладагы бу каланың үзендә, кызганычка каршы, миңа булырга туры килмәде. Бары Куандыкка барышлый вагон тәрәзәсеннән генә карап узарга туры килде.)

...Кышка кергәч, озын төннәрнең берсендә, Зәйнәп апа бездә беренче бәбиен тапты. Берничә көн без аны күрми тордык, тик бала тавышын гына ишеткәли идек. Өчме-дүртме көн узгач, бәбиен күтәреп, безнең якка да чыкты. Апабыз бер дә үзгәрмәгән диярлек, шундый ук шат, мөлаем, сүзчән, тик беркадәр агара гына төшкән иде. Инәй аларга, бәбине котлап, ит бәлеше пешереп кертте һәм чиккән башлы озын бер сөлге дә бирде.

Хуш, Муса абзыйга да эш кирәк бит әле, гаиләсен асрарга кирәк. Ләкин Дәүләкән кебек кечкенә җирдә

эш табулары бик читен иде. Озак та тормый ул үзенең кара айгырын тарантасы-ние белән сатып җибәрде. Шуннан соң минем атакай белән әйбәтләп сөйләшә, мәслихәтләшә торгач, алар үзара килешеп, «Аллага тапшырып», яңа «эш» башлап җибәрергә булдылар. Күзгә табан базар мәйданында такта кибет (ларек) ачып, бакалея әйберләре белән сату итәргә тотындылар. Товарлары — чәй-шикәр, өрек-йөзем, кәнфит-ландрин, прәнник-клиндер, тагын шуның кебек азык нәрсәләре иде. (Аларны оптом сатучылардан алалар иде бугай.) Алмашлап сату итәләр — ярты көн Муса абый кибеттә торса, калган ярты көнне атакай торып уздыра. Ике арада, әлбәттә, тулы ышаныч, һәр көннең сатуын махсус кенәгәгә теркәп баралар. Ай тулгач, йомгак ясыйлар да файдага чыккан акчаның күпмесендер тигез итеп бүлешәләр... Ләкин сатулары шәп бара дип әйтмәс идем. Базарда аларныкы шикелле лареклар аз түгел иде, аннары бакалея белән сату итүче зур-зур кибетләр дә бар — халык та, күбрәк шуларга кереп, ашыкмыйча сатулашып алырга ярата (ә ларектан ашыккан кеше генә ярты кадак, чирек кадак нәрсә эләктереп китә). Кыскасы, безнекеләр бәләкәй генә такта куыш эчендә таптанып, салкын кышны ничек җитте алай үткәзеп җибәрделәр дә, язга чыккач, сәүдәне бетерергә, кибетне ябарга булдылар. Бу сәүдә аларга көткән нәтиҗәне бирмәде, шуның өстенә шактый зур налог та китереп салдылар. Аеруча Муса абзый «эшне» тизрәк очлап бетерүне ашыктырды — аның инде сәүдәне генә түгел, Дәүләкәнне дә ташлап китәсе килә иде. Калдык-постык товарларын сатып бетерделәр, налогларын кертеп түләделәр, шулай итеп, кечкенә генә бер «ширкәт» нәпның башыннан ук диярлек яшәүдән туктады. Бу «ширкәттән» минем атакай тагы да зәгыйфьләнебрәк чыкты шикелле, чөнки шуннан соң инде ул патент алып сату итүдән туктады. Ә Муса абзый җәйгә чыккач та, хатыны белән баласын алып, Ташкент тарафларына китте дә барды. Әнә шулай белгән яки үзенә эш эзләгән татарларның Урта Азиягә китүләре 1925 елдан ук башланды дияргә ярый. Ачлык елында халыкның ул якка агылуы бер булып узган иде инде, хәзер исә яңа «Һиҗрәт»нең башлануын күтәргә була — эшләр шуңа таба бара иде бугай.

Инде миңа да киләчәгем турында уйланырга вакыт иде. Унбишем тулды бит... Бәлки, иртәрәктер дә?.. Юк, бер дә иртә түгел, нәкъ менә уйланыр чак. Дөрес, күп нәрсәне белү дә, аңлау да юк әле, әмма сизенү бик көчле. Нәрсә көтә безнең ишеләрне алда? — Заман үзе мәҗбүр

итә япь-яшь кенә башларны шул хакта уйланырга... Бу нэп дигән нәрсә бик гөрләп башланса да һәм озакка сузылыр кебек тоелса да, ике-өч елдан ук инде аның кыска гомерле булачагын чамаларга мөмкин иде.

Хәер, нэп озак яшәсә дә, атамның сәүдәсе шәп барса да, мин инде бу сату эшенә үзем теләп кереп китә алмас идем. Дөньяны әкренләп таный башлавым ул эштән тыйган булыр иде. Сез беләсез, мин бик иртә татар китапларын укый башладым. Ә китапларның берсе дә сәүдәне мактамый, сәүдәгәрне яхшы итеп күрсәтми. Киресенчә, китапта язганнарга ышансаң, руханилар белән сәүдәгәр-байлардан да гүя начаррак кеше юк. Ә мин китапка, әлбәттә, ышана идем. Аннары бит әле мин үзем дә язучы булырга курка-курка гына хыялланып маташам. Кая инде ул монда сәүдәгәрлек турында уйлау!.. Әгәр дә мәгәр хыялым вөҗүткә[1] ашса, мин бит бөтенләй башка дөнья кешесе булачакмын!.. Киләчәктә, боерган булса! (Ләкин бу киләчәк минем өчен шактый ук ерак булып чыкты — бер егерме-егерме биш елдан соң гына мин, ниһаять, әдәбиятка үтеп керә алдым.) Ә хәзерге вакытта исә мин мәктәпнең эчендә дә, тышында да бик активлашып киттем. Җәмәгать эшләренә дә зур дәрт кузгалды миндә... Укыйм, язган да булам, Мәскәү һәм Казанда чыккан газета-журналларны да алдырам. (Атакай моның өчен акчасын кызганмады.)

Әле җитмәсә, Гомәр Вафиннан мандолинада уйнарга да өйрәнеп маташам. Үзе ул бик шәп уйный иде, ләкин миннән булмады — музыка сәләтеннән бөтенләй мәхрүм икәнмен... Әмма, аның каравы, миңа «дивар гәзитәсе» чыгару бик ошап китте. Бу әле бик яңа нәрсә иде, өйрәнелмәгән-күнегелмәгән, шулай да мин аңа җиң сызганып тотындым. Бер-икесен хәтта берүзем диярлек язып чыгардым. Дөресрәге, материал барысы да минеке, ә зур каты кәгазьгә күчереп язу башканың эше. Минем кулым (почеркым) бик әшәке, ә менә күршебездәге Гарифның кулы ташка баскандай бик ачык, бик пөхтә яза иде. Сез Гарифны онытмадыгыз микән?.. Аның турында башта ук сүз булган иде инде. Ул тегүче Зариф абзый малае, әнисе аны киез җәйгән идәнгә утыртып, йөзем һәм чикләвек төше белән сыйлый торган иде — хәтерлисезме? Зариф абзый чахоткадан үлеп киткәч, алар фәкыйрьлеккә төшеп, бик бетеренделәр. Тол хатын улы Гариф белән безнең якын күршебез Сылубикә җиңгигә (аның ире Сәлимҗан агай да холера вакытында үлеп киткән иде)

[1] *Вөҗүткә* — чынга.— *Ә.Е.*

өйдәшкә кереп, шундагы озын сәкенең чаршау белән генә бүлгән бер башында торып яталар. Хәлләре бик авыр, әнисе төрле кешеләргә көнлекле эшкә йөреп ашарлык ризык китерә, ә Гариф, әтисенең авыруын алып калган үсмер малай, күбрәк өйдә ятып кына тора. Үтә ябык, нечкә муены эчкә киткән, иңбашлары төртеп чыккан, күзләрендә нур сүнгән... Әмма дәрт бар, кызыксыну бар, еш кына мине тәрәзәдән чакырып, бүген мәктәптә ниләр булды, нәрсәләр укыдыгыз? — дип сораша. (Ул үзе инде укуга йөрүдән туктаган иде.) Мин аны гәзитә язышырга чакыра кергәч, аңа да бик куанып риза булды. Тиз генә өстенә иске сырмасын киде, бүреген киде, ә менә аягына төпләгән, бер кунычы көйгән пимадан башка нәрсәсе юк икән. Ә тышта апрель ае, бөтен җир су, лачкылдаган баткак... Шуңа күрә Гарифны әйбәт кенә аркама атландырып, үзебезгә күтәреп алып кайтырга туры килде. Ләкин болай аркада китереп, аңардан гәзитәне яздыру ике генә мәртәбә булды — бердән, авыру иптәшне артык борчыйсы килми иде, икенчедән, минем өчен инәй дә бик борчыла иде. (Чахотканың йогышлы икәнен кем генә белми!) Үзебезнең мәктәптә дә, Гариф шикелле үк булмаса да, матур гына язучылар табылды. Хәер, озакка бармады бу эш, укулар бетү белән тукталды, малайлар бөтенесен онытып, җәйге хөрлеккә атылдылар.

Инде гәзитә шаукымыннан бераз айныгач, мин театр уйнау, кичәләрдә катнашу белән берзаман бик мавыгып киттем. Дөресен генә әйткәндә, театрны мин үземне белә башлаганнан бирле яратам. Театр һәрвакытта миңа гаять кызыклы, күңелле, шау-шулы, үзенә бер мәзәк дөнья булып күренә иде. Һәм бик тарта иде бу дөнья мине үзенә!.. Анда катнашып йөргән, сәхнәсенә чыгып уйный алган абыйларга, апаларга бик кызыга идем, хәтта көнләшеп тә карый идем. Тизрәк үсәсе дә шулар арасына кереп китәсе килә иде. Бәлки, шуңадыр, мин ундүртунбиш яшемнән үк үземнән зур егетләр һәм кызлар арасына кереп йөри дә башладым.

Дәүләкәннең театр белән бәйләнгән тарихы да шактый кызыклы, шуңа күрә минем аңа махсус тукталып китәсем килә.

Чын булса, беренче спектакль Дәүләкәндә приказчиклар тарафыннан 1911 елда ук куелган, имеш!.. Моңа ышанырга була. Без беләбез, бу — татар дөньясының бик нык тәрәккый иткән еллары... 1905 елның җил-давылыннан уянган татар халкы үзенең тәрәккыятендә йөз елда уза алмаганны күп булса ун-унбиш ел эчендә узды. Шуның нәтиҗәсендә безнең халык бөек Октябрь рево-

люциясенә дә аңлы, алдынгы бер халык булып килеп керде һәм революция көрәшенә, аның җиңүенә үзеннән зур өлеш кертте.

Димәк, бу гомуми үсеш-күтәрелештән безнең кечкенә Дәүләкән дә читтә торып калмаган. Театр уйнау исә ул елларда Казан, Оренбург, Уфа кебек мәдәни үзәкләрдә генә түгел, татарлар яшәгән Себер, Урта Азия һәм үзебезнең өяз шәһәрләрендә дә була башлаган иде. Гаҗәп тиз таралды бу сәнгать безнең татар дөньясында!.. Вак шәһәрләрдә моны башлап җибәрүчеләрнең күбрәк приказчиклар булуы да аңлашылса кирәк, чөнки нәкъ шулар арасыннан яңалыкны күреп, күтәреп алучы кыю яшьләр чыкканнар да инде. Андыйлар Дәүләкәндә дә булган. Кайберләрен мин дә әле беләм: болар Хисами, Кәрим, Мәгыйҗан, Габдрәхим абзыйлар... Соңрак аларга ярлы гаиләдән чыккан яки байларда асрау булып эшләгән кызлар да кушылган. Шуларның икесе — Галия апа белән Фатиха апа — хәзер дә исәннәр әле.

Мин үзем аларның уеннарын 1920 елдан күрә башладым. Миңа әле ун-унбер яшь кенә, театр карарга да, кемгә дә булса, мөгаен, Зәкия тутакайга ияреп кенә барганмындыр. (Ул шундый тамашаларны карарга бик ярата иде.) Нәкъ шул елның кышында «Галиябану» безгә дә килеп җитте. Мин менә шуны Бәлдәй клубының сәхнәсендә беренче мәртәбә күрдем. Соңыннан Казан сәхнәсендә иң шәп артистлар башкаруында бу спектакльне кат-кат карасам да, әлеге кечкенә сәхнәдә унлы лампа яктысында күргән беренче «Галиябану»ым бервакытта да күз алдымнан китмәде, күңелемнән чыкмады. Мин аны ниндидер бер тамаша итеп кенә карамадым, Галиябану булып Суфия апа, Хәлил булып Мәгыйҗан абый уйнаганын да белмәдем. Мин аны чын бер вакыйга дип кабул иттем, шуңа беткәнче ышанып, чын күз яшьләрем белән җылап утырдым. Менә ул чәчәкле яулык ябынган, чиккән алъяпкыч бәйләгән, тула оек өстеннән кара галушлар кигән, үзе җиңел, үзе сөйкемле, үзе бик оялчан, вакыт-вакыт хәтәр сизгән коштай дерелдәп куйган, тавышын да калтыратыбрак сөйләгән минем беренче Галиябануым, менә ул кара кәләпүшен кырынрак салып кигән, кара камзулы өстеннән яшел билбау буган, култык астына кечкенә иске гармун кыстырган, тыйнак, әдәпле, саф күңелле, гади авыл егете минем беренче Хәлилем! Авыл тынгач кына аның тәрәзәгә килүе, иске гармунын әкрен генә тартып, тыелып кына җырлавы, ә Галиябануның тәрәзә яңагына ышыклана төшеп, оялыпкуркып кына җырлап җавап бирүләре — болар һәм бөтен

уен искиткеч яңа, таң калдырырлык, бәгырьләрне өзәрлек иде. Аларның берсе Искәндәр хәзрәт ишегалдында торучы тол хатынның кызы Суфия апа, ә икенчесенең кайдадыр конторщик булып эшләүче Мәгыйҗан абый икәнен белгәч, минем күңелемдә бу кешеләргә гомерлек бер мәхәббәт уянып калды. Шунысы тагын кызыклы: Галиябану белән Хәлилнең саф, көчле мәхәббәте аларның үзләренә дә күчкән икән — шушы спектакльдән соң алар озак та тормыйча матур гына туйлап, өйләнештеләр дә. Тик алар сәхнәдән никтер тиз киттеләр, бәлки, моңа өйләнешүләре сәбәп булгандыр, ләкин барыбер Суфия апа белән Мәгыйҗан абыйлар күпләр хәтерендә Дәүләкәннең сагынып искә алырлык беренче артистлары булып калдылар. Хәзер инде аларны белүчеләр юк диярлек — мин дә тагын берничә кеше генә...

...Хикмәтле ерак елларның тагын бер кечкенә кызыклы эпизоды истә саклана: шул ук артистлар сәхнәдә «Мөгаллим» дигән әсәрне уйнап күрсәтергә тиешләр. Тамашага килгән бала-чага арасыннан алар үзләренә бәләкәйрәк малай эзлиләр: бу малай спектакльдә бик кечкенә бер роль «уйнарга» тиеш икән. Менә шушы уен өчен минем энем Илдарханны сайлыйлар да, сәхнәгә алып менеп, аңа нәрсә эшләргә кирәклеген өйрәтәләр: «Син, үскәнем, менә шушында юри генә йоклап яткан булырсың, ә менә бу абыең кычкырып фәлән сүзне әйткәч, уянып, үкереп җыларга тотынырсың... «Аңладыңмы?» «Аңладым!» «Үкереп җылый беләсеңме?» «Беләм!» «Менә бик әйбәт!» (Әйтергә кирәк, минем энекәш өйдә җылый башласа да яшь үгез шикелле үкерә иде.) Шулай итеп, энемне сәкегә яткызалар, өстенә юрган да каплыйлар. Пәрдә ачыла, уен башлана. Уен бара, малайның уянып җылар вакыты да җитә, ләкин ул никтер уянмый, артистлар аның тирәсендә тыз-быз киләләр, бер үк сүзне отыры кычкырыбрак әйтеп тә карыйлар, ә малайның гамендә дә юк — ул, баксаң, юри генә түгел, ә чынлап торып йоклап киткән икән! Изрәп, төшләр күрә-күрә йоклый малай!.. Шулай да аңа карап уен тукталып калмый, дәвам итә, ахырына да барып җитә. Пәрдә төшкәч, энекәшне көчкә төрткәләп уяталар. Менә шул чакта инде ул үкерә-үкерә җылап та җибәрә! Ниһаять, «роле» исенә төшә малайның!..

Ярый, һәвәскәрләр уйнаганда ни булмас, аңа берәүнең дә исе китми, тик рәхәтләнеп бер көләләр генә.

Билгеле, театр уены ул яшьләр эше. Алар яраталар, алар дәртләнеп йөриләр. Әмма озакка түгел, монда буыннар тиз алышына. Өч-дүрт, күп булса биш ел уйнаган-

нан соң «искеләр» сәхнәдән китә башлыйлар — йә өйләнәләр, йә кияүгә чыгалар һәм тормыш арбасына җигеләләр. Алар урынына яңалар җитешә, яңалар килә. Әйтик, егерменче елларда без әле клуб ишеге төбен таптаучы, зур артистларга шаккатып йөрүче малайлар гына булсак, 1924—1925 елларда инде үзебез дә сәхнәгә менеп, каушый-каушый гына уйный башладык. Бу вакытта Мәгыйҗан, Габдрәхим, Габдулла абый һәм Галия, Фатиха, Суфия апа кебек «корифейлар» берәм-берәм китеп беткәннәр иде. Ләкин безнең буын турында сүз башланганчы, минем Дәүләкәнгә ара-тирә килеп чыккан чын (профессионал) артистлар турында да әзрәк сөйләп узасым килә. Бу кызыклы һәм гыйбрәтле. Мәсәлән, минем чын артистларга гаҗәпләнүем дә, соклануым да, хәтта аларны кызгануым да шушы чакларда туып, күңелемдә сакланып калды булса кирәк.

...Хәтеремдә көзге Дәүләкән ярминкәсе. Нэп кергәч беренче ярминкә әле бу, шулай да бөтен тирә-яктан татары, башкорты, русы, чуашы килеп тулган, базар мәйданы ярларыннан чыккан дәрьядай әкрен генә гүләп, чайкалып тора. Читтән килгән сәүдәгәрләр дә күп, җиңел кулдан гына корып ташлаган такта кибетләр дә күп, ә ярминкәгә кергән малның, азыкның, товарның хисабы юк! Хәтта сәнгате дә читтә торып калмаган — базар мәйданының бер кырыена сәләмә брезенттан түгәрәк балаган да корылган. Монда цирк артистлары үзләренең уеннарын күрсәтәчәкләр икән. Ләкин балаган тирәсендә хәзергә шаулашкан бала-чагадан башка халык юк диярлек. Халыкның башы-күзе тонган, алар базар айкыйлар, базарда бөтен эшләре... Балаганның тышында биек кенә сәндерәсе бар, менә шунда өч артист чыгып басканнар. Берсе — кып-кызыл чукмар борынлы, самавыр җиздәй җирән чәчле клоун, икенчесе — күлмәге-ыштаны тоташ, тыгыз, җиңсез нәрсә кигән таза гына ир — герләр чөеп уйнаучы, өченчесе — битен-күзен бик нык акшарлаган, өстенә кендектән түбәнрәк кып-кыска кызыл күлмәк кигән, озын шәрә аяклы бер марҗа. Алар халыкны чакыралар, клоун нидер кычкыра, кулындагы кыңгыравын һаман селкетә, җирән чәчен дә еш кына «аягүрә» бастыра. Гер күтәрүче кулларын баш өстенә куеп, йомры мускулларын уйнатып күрсәтә. Ә кыска итәкле марҗа кулындагы шөлдерен селкә-селкә ниндидер такмак әйтеп маташа. Әмма халык авызын ачып, бераз гына карап тора да тагын үз юлы белән китеп бара. Нигәдер ашыкмый халык балаган эченә керергә... Шуннан соң әлеге марҗа сәндерәдән төшеп, бер йөз метр чамасы ба-

зар эченә кереп китә дә, озын-шәрә аякларын югары күтәргән килеш, куллары өстендә генә кире балаганы янына кайта. Аның артыннан ябырылып, чинап бала-чага, егетләр-кызлар, ак чикмәнле яшьрәк башкортлар ияреп киләләр. Вәт тамаша!.. Ә хатынның бите тузан эченнән бара, бөтен буяуларын юып кара тир ага — ул инде яшь тә түгел, муенын-күкрәкләрен вак кына җыерчык басып бетергән. Әнә шулай әллә ничаклы халык ияртеп, көчкә-хәлгә балаган янына килеп җитә ул, әмма ләкин аның шәрә ботларын күрер өчен генә ияргән халык билет алырга да, балаган эченә керергә дә ашыкмый, ә күбесе тамаша беткәндәй шунда ук китеп тә бара. Әлбәттә, балаган — бик кызыклы урын, барыбер ул бала-чага, яшь-җилкенчәкләр белән тула, андагы кызык-мәзәк уеннарны исе китеп карап утыра, тик шулай да халыкны үзләренең тамашаларына шундый азап белән тартырга тырышкан бу тузган-таушалган, инде олаеп та барган ярлы балаган артистлары миңа нигәдер бик кызганыч булып тоелган иде шул чакта.

1924 елның җәендә Оренбурдан Дәүләкәнгә бер төркем артистлар килде. Алар биш кеше иде — Ильяс Кудашев-Ашказарский, Сабир Гаспринский, Хәлил Наилский, Безруков (исеме онытылган) һәм хатын-кыздан Мәрфуга Кудашева-Ашказарская. Дәүләкән туфрагында моның кебек тә данлы һәм яңгыравыклы фамилияләрнең булганы юк иде әле. Җитәкчеләре Кудашев-Ашказарскийны элек тә ишеткәнебез бар иде (театр тарихында бик мәгълүм кеше), әмма бу Гаспринский, Наилскийлар... нинди йолдызлардыр — беренче генә ишетүебез... Аларның килүе Дәүләкән өчен, әлбәттә, зур вакыйга иде, тик аңлашылып кына бетми — безнең кечкенә Дәүләкәнебезне алар белеп килделәрме икән, әллә белмичә очраклы гына килеп чыктылармы икән?.. Хәер, ишетеп-белептер, чөнки Кудашев-Ашказарскийның үзен дә шушы Бәләбәй өязеннән чыккан кеше диләр бит... Аннары безнең Дәүләкән караңгы бер почмак та түгел, шуның өстенә кымызга килеп йөргән татар зыялылары аша аны күп җирдә беләләр дә... Ләкин шулай да зур корабка зур диңгез кирәк диләрме?.. Күтәрә алырмы икән кечкенә Дәүләкән моның кебек шөһрәт ияләрен?!

Гадәттә, гастрольгә килгән артистларга бездә спектакль куеп китү ул елларда бик ансат иде. Рөхсәт-мазар алу да юк шикелле, Бәлдәй клубы күп вакытта буш тора, караучы хатын, үзебезнекеләрдән берәрсе кушты исә, ача да кертә — рәхим генә итегез! Бары тик җирле һәвәскәрләр белән сөйләшеп, килешергә генә кирәк,

чөнки алардан башка читтән килүчеләрнең бер генә спектакльләре дә узмый торган иде.

...Белмим инде, нәрсә сәбәп булгандыр — Дәүләкән үзе ошамаганмы, клубын яратмаганмы, әллә һәвәскәрләр белән килешә алмаганмы (хәер, нинди килешү — алар бит катнашкан өчен бервакытта да акча сорамыйлар), әмма, ни генә булмасын, Ильяс абзыебыз ике-өч көннән, Мәрфуга апайны алып, бездән китте дә барды. Мәшһүр фамилияләре генә калды хәтерләрдә язылып!.. Әйттем ләбаса, бәләкәй безнең Дәүләкән алар өчен, бәләкәй — базарсыз көннәрдә йокымсырап тын гына торган бер авыл кебек кенә бит ул! (Зур каладан килгән кешеләр өчен бигрәк тә!)

Ләкин калган өчесе китәргә ашыкмадылар. Гаспринский җитәкчелегендә һәвәскәрләр катнашы белән бер-ике спектакль дә куйдылар. Гаспринский үзе уйнамады да бугай — ни хикмәттер, бу спектакльләрнең берсе дә хәтердә сакланып калмаган. Тамашачы да күп түгел иде шикелле. Һәрхәлдә, аншлаг булмады. Моңа, бәлки, җәйге озын көннәр сәбәп булгандыр, эш өсте, халык арып кайта, иртә ята, иртә тора, кыскасы, сезоны ул түгел.

Ул чакларда сбор җыяр өчен бер-ике көн алдан кибетләргә кереп, билетларны сәүдәгәр абзыйларга да тәкъдим итеп йөриләр иде. Яшьрәк нэпманнар баш тартмый, ала, әмма картраклары буш бирсәң дә алмыйлар. Кирәкми аларга театр, алар мәчеткә йөрүчеләр, башка дөнья кешеләре! Ә сбор дигәнең бик кирәк артистка, бөтен өмете аның бары шул сборда! Ярый ла һәвәскәрнең ашарына бар, торыр җире бар, ә читтән килгәннәргә сбор булмаса, ничек яшәргә?

Сабир агай Гаспринский да, бер-ике атна чамасы торганнан соң, чыкмады монда рәт дигәндәй, ялгызы гына китте дә барды. Инде биштән бары икәү — Наилский белән Безруков кына торып калдылар. Шулай итеп, башта исемнәре белән безне шаккатырырлык булып килеп төшкән труппа Дәүләкәндә кыска гына вакыт эчендә таралды да бетте.

Бу сөзелеп калган икесе турында сүз башлаганчы Гаспринскийның үзе турында әйтеп бетерик. Сабир Гаспринский — Ашказарскийның бертуган энесе, театр дөньясында шулай ук азмы-күпме билгеле кеше. (Утызынчы елларның башларында ул Татар академия театрында баш администратор да булып эшләде.) Безгә килеп чыккан чагында Сабир абый ачык соры төстәге җәйге костюм һәм ак панама кигән, йөреше белән дә чын шәһәр интеллигентын хәтерләткән, утыз-утыз бишләр тирәсендәге бер

ыспай-чибәр генә ир иде. Сырлы таягын селкә биреп, Дәүләкәннең кибетләре арасыннан узганда һәркемнең дикъкатен үзенә җәлеп итә торган иде. Бәлки, әнә шулай берәүгә дә охшамаган килеш-килбәте белән ул Басыйр абзыйның гимназистка кызы Газизә апаны үзенә карата да алгандыр. Карату гына түгел, алар арасында кыска, әмма кайнар гына роман да булып алды бугай... Һәрхәлдә, безнең яшьләр аларның айлы кичләрдә икәүдән-икәү генә аулак урамнарда йөрүләрен дә, ә кайчагында көпә-көндез җитәкләшеп Дәүләкән тавына менеп китүләрен дә күрмичә калмадылар. Инде гайбәтләре дә чыга башлаган иде, ләкин, әйткәнемчә, Сабир абый озакламый, роман җепләрен ансат кына өзеп, ак панамасын болгый-болгый бездән китеп тә барды... Кичерегез, бу хакта мин ничектер уйнап кына язам, бәлки болай ярамый да торгандыр, бәлки алар арасында чын тойгы да булгандыр, Хода белсен!.. Әмма иртә өзелгән роман — ташлап калдырган чәчәк төсле ул — кызганыч та, кадерсез дә!

Инде Наилский белән Безруковка килсәк, боларның эшләре харап иде. Китә дә алмыйлар, торырга рәтләре дә юк — әнә шундый авыр хәлдә калдылар ул бичаралар! Монда тагын шуны да әйтергә кирәк, Хәлил Наилский — малайлыктан чыгып бетмәгән япь-яшь, ваемсыз бер егет — үзе белән бергә яшь кенә хатынын да ияртеп килгән иде. Сәрби исемле, Оренбурның зур гына бай кызы икән — Хәлил менә шуны эти-әнисеннән качырып алган да киткән... Кызганыч иде бу кыз бала — үзе бик яшь, бик юаш, бик йомшак, аның бала йөзендә «Ни булды миңа?» дигән тирән бер гаҗизлек һәрвакыт чагылып тора иде. Җитмәсә әле үзе йөкле дә икән. Хәзер инде менә безнең тук Дәүләкәндә алар икәүләп ач утыралар.

Кызганып булса кирәк, аларны теге чалгыга киселеп үлгән Кәрим абзыйның хатыны Миңкамал апа үзенең кухнясына керткән иде. Стена буенда тар гына тимер карават, икесенә бер мендәр, өсләренә Наилскийның бөрмәле кайры тунын ябынып яталар — бу тунны да аңа кемдер биргән булырга тиеш. Тышта инде шыксыз салкын көз.

Әмма ничек яшәргә?.. Артистның башка бер төрле кәсебе дә, эше дә, килере дә юк. Һәм иң гаҗәбе — үз хәлен аңлау да, кайгыру да юк иде шикелле бу зур гына авызлы озын-чандыр егеттә. Базар арасында йөри, сүзгә җор, мәзәк сөйләргә ярата, шуның өчен генә аны кайбер таныш-белешләре чәйханәгә дә алып кергәлиләр. Ә кухняда аның акчамы, ризыкмы табып кайтканын көтеп,

корсаклы хатыны утыра. Ул, бичара, шулкадәр юаш иде, балыктай өнсез иде, миңа, мәсәлән, аның Хәлилгә бер генә тапкыр да үпкәләп, ачуланып әйткәнен ишетергә туры килмәде. Артистлар тирәсендә гел генә чуалырга яратканга күрә мин Наилскийга да шактый ук ияләшеп киткән идем һәм аңа ияреп еш кына әлегә торып яткан өйләренә дә бара торган идем. Ләкин барган саен диярлек мине Сәрби апаның әнә шундый мескенлеге ирексездән сыкрата иде, нәрсә бу — көчле яратуданмы, әллә, киресенчә, көчсезлектәнме? — дип уйланырга да мәҗбүр итә иде. Әйе, чынлап кызгана идем мин аны, буш кул белән бармаска тырыша идем, йә кибеттән алып, йә инәйдән сорап, аңа ни дә булса китерә идем. «Рәхмәт!» — ди иде ул миңа әкрен генә, ләкин күтәрелеп карарга ояла иде.

Шулай да Хәлил Наилский үз хәлләрен җиңел генә яхшыртыр өчен бер талпынып карады. Театр сенсация ярата бит... Менә бу егет тә Дәүләкәнне шаккатырыр өчен әлеге Гаспринский белән Газизә апа арасында булып алган кечкенә роман турында өч пәрдәле пьеса язып ташлады. Пьесаның әдәби ягы, әлбәттә, ташка үлчим генә булгандыр инде, әмма эчтәлеге белән ул бик йөгәнсез, шапшак бер әйбер иде. Газизә апаның үзен дә, әтисе Басыйр абзыйны да, шулай ук төп «герой» Сабир Гаспринскийны да теләгәнчә хур итеп, мыскыл итеп, төрлечә буяп бетергән иде. Басыйр абзый олы яшьтәге сәүдәгәр кеше булгач, «автор» аны, дегеткә буясаң да ярый дигәндәй, кызганып та, тыелып та тормаган.

Ул чакларда берәр әйберне сәхнәгә куяр өчен бернинди рөхсәт-мазар кирәкмәгәндер, ахрысы... Шуңа күрә җирле һәвәскәрләр язып ташлаган әйберләр дә ансат кына уйнала торган иде. «Артистлар» җыелышып укыйлар да, «ярый, булган бу» дип, шунда ук рольләрен дә бүлешәләр.

Наилский да үз әйберсен куюю хәстәренә җиң сызганып кереште. Бу вакытта элегрәк елларны уйнаган өлкән һәвәскәрләр театрдан читләшкәннәр иде инде. Алар урынына безнең кебек «яшь буын» (күбрәк үсмер малайлар) килгән иде. Хәлил абзый менә шуларны бик кызыксындырды, уйнаучыларны сайлап алды һәм ашык-пошык репетицияләр үткәрергә дә тотынды. Үзе ул Сабир Гаспринскийны уйнаячак иде. «Һа! — ди иде ул репетиция вакытында, кулларын күтәреп.— Дәүләкәннең төшенә дә кермәгән шаккатыргыч бер тамаша булачак бу!..»

Хәлил миңа да роль тәкъдим итте — Газизә туташның энесе булып уйнарга. Спектакльгә катнашу безнең өчен зур дәрәҗә, без аны көтеп кенә торабыз, шуңа күрә мин башта ике дә уйламыйча риза булдым. Ләкин икен-

че көнне үк инде мине нидер борчый башлады, нигәдер менә бер дә күңелем ятмый бу «шаккатыргыч тамашага», һәм үзалдыма бераз шулай уйланып, борчылып йөрдем дә, ахырда кыюланып, рольдән баш тарттым. Наилский моның өчен мине каты гына сүгеп ташлады, ләкин эш тукталып калмады — рольне шунда ук эләктереп алучы да табылды. Әмма соңыннан, бигрәк тә спектакльне карагач, мин уеннан баш тартуым өчен бик сөендем.

Уйналачак спектакль турында инде сүз халык арасына таралып өлгергән иде. «Автор» моның өчен бик тырышты, дүрт-биш көн алдан ук «Дәүләкән купецы тормышыннан алып язылган көчле сатира» дип, афишалар да чыгарды. Кем хакында, нәрсә хакында икәнлеге билгеле булгач, спектакль көнне Бәлдәй клубына халык, бигрәк тә яшьләр белән бала-чага килеп тулды. Ниһаять, пәрдә ачылды, спектакль уйналды. Бала-чага, билгеле, шау-гөр килеп утырды. Зурлар исә, никадәр генә талымсыз булмасыннар, ниндидер бер ярамаган, килешмәгән ямьсез тамашаны күзәткәндәй уңайсызланып, кызарып утырырга мәҗбүр булдылар. Ярый, «купич»ның үзеннән көлсен дә ди, бу инде гадәткә кергән нәрсә, әмма аның яшь гимназистка кызын болай ачыктан-ачык мәсхәрә итү нигә кирәк булды икән? — Менә нәрсә һәркемнең күңелен тырный иде шикелле. Без ул чакта пасквиль дигән нәрсәне белми идек әле, ләкин шуның иң алама үрнәген үзебезнең сәхнәдә күрдек. Хәтта спектакльгә катнашучы безнең һәвәскәрләр дә моны соңыннан сизмичә калмадылар.

Бер уйлаганда, Наилский үзе дә кызганыч иде. Аның шушындый түбәнлеккә төшүе, әйткәнемчә, каты нужадан иде. (Нужа печән ашата, дигәннәр.) Ләкин зур өметләр белән шаулатып куйган халтурасы бертөрле дә җиңеллек китермәде. Шул ук бөлгенлек, эшсезлек, аптыраганлык — барысы да искечә калды. Нишләргә? — Дәүләкән шартларында артист булып кына яшәү һич тә мөмкин түгел. Шуны соңрак булса да аңлап, ул ахырда безнең кинотеатрга эшкә урнашты. Эше — ишек төбендә билет тикшерү һәм билетсыз үткән малайларны сөреп чыгару — моны вышибало диләр бугай... Бик мәзәк кеше иде Хәлил Наилский, төскә дә чибәр иде, артистлык сәләте дә аңарда, һичшиксез, бар иде, әмма артык ваемсыз, пошымсыз, җиңел генә уйлаучан — шуның аркасында ул бездә адашып калып, үзен дә, япь-яшь хатынын да күпме җәфаланырга, күпме түбәнлекләр кичерергә мәҗбүр итте.

1926 елның җәендә мин беренче мәртәбә Казаннан

Дәүләкәнгә кайткан чагымда, алар үзләренең Оренбурларына кайтып киткәннәр иде инде. Бик дөрес эшләгәннәр. Бәлки әле, Сәрби апаның эти-әниләре дә аларны гафу итеп, үзләренә кабул иткәннәрдер. Кечкенә сабыен күтәреп кайткан газиз бала бит... кагып буламы соң?! Юньсез кияүгә дә сәүдәгәр бабасы янында берәр эш табылгандыр, шәт! Соңыннан миңа Наилский фамилиясе белән тарихка кереп калган артистны ишетергә туры килмәде.

Дәүләкәнгә Ашказарскийлар белән бергә килеп, адашып калган артистларның бишенчесе Безруков дигән бер мишәр иде. Самар егете булса кирәк, «труппа»га ничек эләккәндер — ул кадәресе безгә намәгълүм (китапча әйтсәк). Әмма араларында иң мескене һәм иң җәфа чиккәне шул бичара иде. Өстендә керләнеп беткән, төсен югалткан кыек якалы күлмәк, таушалган иске пинҗәк белән иске чалбар — шулардан башка бер әйберсе, хәтта башына кияр нәрсәсе дә юк иде. Ләкин ул абруен сакларга тырышучы инсафлы егет иде, шуңа күрә әрсезләнеп, соранып, берәүгә дә тагылып йөрмәде. Аның кайда торганын, ничек яшәгәнен дә белүче булмады. Әнә шулай күпмедер вакыт Дәүләкәндә бер тиенгә тилмереп, ачлы-туклы каңгырап йөрде дә үзеннән-үзе ничектер гаип тә булды. Ул чакларда товар поездларына эләгеп, төрле якка китеп була иде — без инде аны үзенең Самарасына киткәндер дип юрадык.

Болар — нэп вакытының сәнгать «корбаннары». Җиңел генә шөһрәт казанырга уйлап, бәхетсезлеккә дучар булучылар ул елларда очраштыргалыйлар иде әле.

Дәүләкәнгә ялгыз гына килеп чыккан артистлар да булгалады. Бер җәйне Мохтар Мутин килеп, безнең һәвәскәрләрне аякка бастырып, утлы табада биетеп, шаккатырып, бер генә спектакль уйнап китте. Бу инде чын артист иде, күренеп кенә узды, әмма тавышы озакка сузылды... Аннары Уфадан Мансуровский дигән өлкән генә бер абзый килеп чыккалый иде. Ул да ярлы артист. Чабулары салынып төшкән зәңгәр пинҗәгенең җиң очларын ак җеп белән типчегән булса кирәк, шәмәхә кара белән җыйнак кына буяп куйган. Шулай да үзе керле ак якасына кара бантик тагып йөри иде. Ул җырчы иде, озын башкорт көйләрен матур гына җырлый иде. Шуңа күрә аны базар көннәрендә баерак башкортлар үзләре белән чәйгә алып кереп, әйбәт кенә сыйлап, сәке түрендә җырлатып утырталар иде. Уфаның борынгы кешеләре бу Мансуровский дигән җырчы-артистны хәзер дә әле, бәлки, хәтерли торганнардыр.

Дәүләкәнгә килеп чыккан тагын бер кеше турында әйтмичә уза алмыйм. Ерак Ленинградтан килгән иде, күрше Арыслангәрәй агайларда күпмедер вакыт кымыз эчеп ятты. Гаҗәп сәер бер кеше иде ул... Үзе татар, ләкин исем-фамилиясен әллә белмәдек, әллә белеп оныттык — хәзер инде әйтүе дә читен. Һичшиксез, сәнгать дөньясыннан, тик театрданмы яки эстрададанмы — ул кадәресен дә ачык кына белә алмадык. Кечерәк кенә буйлы, бөтенләй сакал-мыексыз, йөреше һәм кыланышлары белән шактый ук хатыншага охшаган иде.

Кичкә таба капка төбенә чыгып утырса, без аның янына бара торган идек. Ул бер дә тартынып тормыйча безгә төрле мәзәкләр сөйли торган иде. Мәсәлән, Петроградта, имеш, бервакытны иң кечкенә аякларга ярыш үткәрелгән. Шул ярышта аның аяклары, имеш, иң кечкенә булып табылган һәм беренче зур призны алган... Хет ышан, хет ышанма!.. Ә аяклары чынлап та үсмер кызларныкыдай кеп-кечкенә — безгә, мактана биреп, сузып күрсәткән дә иде.

Бер җылы кичне без, берничә егет, аның белән көймәдә йөрергә төштек. Үзе ул бик матур җырлый да икән. Дим өстендә рәхәтләнеп җырлап барды. Шул чакта мин аңардан беренче тапкыр «Алма-Ата» көен ишеттем. Күңелнең нигәдер үзеннән-үзе нечкәрергә торган чагы иде. Шуңадыр, ахры, аның бу яңа җыры миңа бик нык тәэсир иткән иде. Дим өсте көзгедәй тип-тигез, кучкылзәңгәр, талларның күләгәләре яткан, мин суны чапылдатмаска тырышып, әкрен генә ишәм, җыр мине еракка-еракка алып китә. Әмма кая илтә ул мине — мин белмим, белмим... Миңа бик ямансу, хәсрәтем әче-татлы, ирексездән күземә яшьләрем килә... Мондый хәл җыр тыңлаганда минем белән хәзер дә булгалый әле. Шул сәбәпле җырларның сүзләрен мин бервакытта да отып кала алмыйм.

...Кечкенә аяклы, матур җырлаучы бу сәер кеше Дәүләкәннән китәр алдыннан, Наилский белән сөйләшеп, безгә бер спектакль дә куеп күрсәтергә булды. Куйган нәрсәсе Чеховның «Аю» дигән ике генә кешелек комедиясе иде. Үзе ул шундагы Елена Ивановна исемле, күптән түгел ире үлгән тол хатынны уйнады. Аюдай тупас помещик ролендә Наилский иде. Яше һәм кыяфәте белән бигүк туры килмәсә дә, аны грим һәм кием ярдәмендә помещикка охшаттылар. Әмма инде Ленинград артисты әлеге ире өчен хәсрәт чигүче, ләкин ахырда «аю» кочагына эләккән Елена Ивановнаны искиткеч оста башкарды. Буе, сыны, чәче-бите, хәрәкәте, кыланышы,

тавышы — бөтенесе коеп куйган чын табигый хатын-кызныкы иде. «Бесподобно!» — дияр идем мин әгәр дә русча язсам... Белмәгәннәр аны ир кеше дип тә уйламадылар, ә белгәннәр шаккатып утырдылар.

Заманында безнең кечкенә Дәүләкәндә әнә шундый күз күрмәгән тутый кош сыман гаҗәеп кешеләр дә булып, үзләре турында тиз генә онытылмас истәлекләр калдырып киткәлиләр иде. Әмма Дәүләкән аша узучылар белән якыннан очрашуның минем өчен иң истәлеклесе егерме бишенче елның җәендә булган иде. Моны сөйләмичә үтү ярамас, чөнки Дәүләкән белән генә чикләнеп калмады ул очрашу... Ничектер беркөнне ялгызым гына вокзалга таба киттем. Барып җитсәм, вокзал тирәсе буш, кеше юк, тик перрон рәшәткәсе буенда шәһәрчә киенгән ике ир белән ике ханым басып торалар. Җирдә чемоданнары — күрәсең, яңарак кына поездан төшеп калганнар. Яннарыннан ашыкмыйча гына колак салып уздым: үзара кызу гына татарча сөйләшәләр... Бу мине бик кызыксындырды — күренеп тора, ни җитте генә кешеләргә охшамаганнар. Май чүлмәге тышыннан билгеле ди — һичшиксез, алар, кыяфәтләреннән күренгәнчә, чын шәһәр зыялылары. Ирләрнең берсе — озын буйлы, эре, мәһабәт кеше; кулында — калын, сырлы таяк, зур башында — салам эшләпә. Икенчесе — урта буйлы, җыйнак-ыспай, өс-башы да бик пөхтә. Хатыннарның исә берсе ак чырайлы, нәфис, юка гына гәүдәле, икенчесе яшьрәк тә, тулырак та һәм бик алчак та күренә. Кулларында — нечкә саплы зонтиклар... Шунда ук уйлап алдым — болар, һичшиксез, кымызга килүчеләр, ләкин ни өчен монда кая барырга белмәгәндәй, үзләре генә басып торалар? Туктар урыннары юкмы әллә?.. Кире борылып, яннарыннан тагын узган чакта, мин уңайсызланыбрак булса да сорамыйча түзмәдем:

— Абыйлар, сезгә әллә фатир кирәкме?

Ханымнарның әлеге яшьрәге һәм җитезрәге бик ачык тавыш белән:

— Кирәк иде шул, энекәш! — диде.— Син мондагы фатир төшерүчеләрне беләсеңме әллә?

Мин аптырап калдым — кемне әйтергә? «Базар» төшерүчеләр күп бездә, ләкин боларны анда илтеп булмый, билгеле... Теге мәһабәт дәү абый да калын тавышы белән сорап куйды:

— Может, сезнең бу салагызда алама гына булса да мосафирханә бардыр?..

— Юк шул, мосафирханә юк! — дидем мин уйланып, һәм, абыйларның йөзендә «булмады бу малайдан!» дигән

төслерәк бер чырай күргәч, тиз генә әйттем үзләренә: — Ә мин сезне үзебезгә алып кайтам!

— Үзегезгә?.. Сез фатир кертәсезмени?

— Кертәбез.

— Без бит берничә көнгә генә...

— Барыбер.

Алар ышанып бетмәгән шикеллерәк бераз миңа карап тордылар. Мин бит инде малай түгел, уналты яшьлек... егет дияргә дә ярый — ышанырга тиешләр иде. Шулай да ак чырайлы юка ханым йомшак кына итеп миннән сорады:

— Әти-әниең риза булырмы соң, туганым?

— Булырлар, безнең залыбыз хәзер буш тора, урын җитәрлек.

«Зал» дигәнне ишеткәч тә, аларның йөзләре ачылган кебек булды: барырга ярый, димәк!

— Йортыгыз еракмы соң? — диде яшь ханым, җәһәт кенә.

— Юк, әллә ни ерак түгел.

— Бик хуп! — диде калын тавышлы абый.— Киттек алайса... Әйдә, шәкерт, алдан атла!

Чемоданнарын җирдән алдылар, һәм мин ияртеп алып киттем бу шактый мәзәк, чибәр, сөйкемле кешеләрне!.. Безгә тимер юл буйлап бераз барасы да аннары «Холодный переулок» дигән кыска бер урамга керәсе. Урамның аргы очында безнең йорт инде күренеп үк тора... Үзем атлыйм, үзем әзрәк кенә борчылам да: берьюлы дүрт кеше ияртеп кайтып, мин инәйне уңайсыз хәлдә калдырмам микән, алай-болай ризасызлыгын белдермәс микән? Ничек тә аңа алданрак әйтәсе иде бит... Сылтавын табып, артымнан килүчеләргә: «Әнә безнең йортыбыз, мин парадный ишекне барып ачыйм әле»,— дидем дә тиз генә алдан йөгердем. Өйгә килеп керү белән инәйгә кабаланып әйттем:

— Инәй, мин вокзалдан дүрт кунак алып кайттым, бик әйбәт кешеләр, син инде ачык кына каршы ал!

Инәй тәмам каушап калды:

— Ай Аллам! Ни сөйлисең? Нинди кунаклар, әйтмисөйләми...

— Шулай туры килде инде... Уфадан, берничә көнгә генә... Тик син, зинһар, ризасызлык белдермә!

— Нишләп белдерим, үзләре риза булсалар...

— Риза, риза! — дидем дә мин, тизрәк төшеп, парадный ишеген ачтым.

Кунакларым килеп җиткәннәр иде инде. Керделәр, каушабрак торган инәй белән бик ачык исәнләштеләр: «Ка-

бул итсәгез, абыстай, менә без улыгызга ияреп килдек»,— диделәр. Инәй дә: «Рәхим итегез, яратсагыз — торырсыз, урын җитәрлек»,— диде аларга. Мин, зал ишеген ачып, кунакларны эчкәре уздырдым. Керделәр, әйберләрен куйдылар, карандылар, ошаттылар булса кирәк — ничектер җиңел сулап, иркенәеп киткән шикелле булдылар.

Ак чырайлы апа миннән: «Исемең ничек, туганым?» — дип сорады. Әйткәч, «Әдипләр исеме икән»,— дип тә куйды.

— Атаң кем? — диде дәү абзый.

— Нигъмәтҗан.

— Фамилиясе?

— Еникеев.

— Еникеев?.. Каргалы морзасы?

— Шулай шикелле,— дидем мин кызарып һәм, кайдан белә икән, дип бик гаҗәпләндем.

Апалар инәйнең исемен сорадылар, мин әйткәч, икесе дә аның янына чыгып: «Хәдичә апа!» — дия-дия бик ягымлы-ачык итеп сөйләшергә дә тотындылар. Инәйнең самовары куелган иде инде. Залга табын әзерләнде. Инәй сөтен, маен, ак күмәчен тәлинкә тутырып кертте. Кунаклар бик мәмнүн[1] булып чәйгә утырдылар.

Хуш, кемнәр булып чыкты соң бу мин ияртеп кайткан Өфе кунаклары?.. Моны үзләреннән туп-туры сорап булмый иде, килешмәячәк иде, шуңа күрә аларның үзара сөйләшүләреннән генә белергә мөмкин иде. Ирләрнең берсенә Нури, икенчесенә Шакир дип дәшәләр. Апаларының өлкәнрәгенә Нәгыймә, яшьрәген Мәһирә диләр икән. Кыскасы, бер-ике көннән генә, ниһаять, мәгълүм булды: кунакларымның бер пары Нури Сакаев белән Нәгыймә Таҗдарова, икенче пары Шакир Шамильский белән Мәһирә Мирвәлиева иде. Татарның дан тоткан артистлары — мин инде аларны ишетеп белә дә идем.

...Килүләре исә чынлап та кымызга икән. Бездән Көрмәнкәйгә китәргә тиешләр. Ләкин, Дәүләкән кебек кечкенә шәһәрне хәтерләткән җайлы гына бер урында тукталырга туры килгәч, алар үзара сөйләшеп монда бер спектакль уйнап китәргә булдылар. Ул елларда сезон бетереп, эштән бушаган артистларның җай чыкканда сбор өчен спектакль уйнап китүләре гадәти бер эш иде. Менә Нури абый белән Шакир абый да каядыр барып, кемнәр беләндер сөйләшеп, тимер юл буендагы элекке зур рус мәктәбенең сәхнәсен бер кичкә алып торырга килешеп

[1] *Мәмнүн* — шат-канәгать.— *Ә.Е.*

кайттылар. Хәзерләнүгә бер дүрт-биш көн вакыт киткәндер. Мин дә аларга әзрәк булыштым — ак кәгазьгә шәмәхә кара белән язган афишаларын урам чатларына ябыштырып чыктым. Шуның өстенә әле алар мине спектакль көнне сәхнә будкасына суфлер итеп тә утырттылар... Уйнаган әйберләре «Ташландык бала» исемле өч пәрдәле драма белән «Чалбарлы туташ» дигән бер пәрдәлек комедия иде. Бу соңгысы халыкның игътибарын бик җәлеп итте бугай, чөнки чалбар кигән туташны берәүнең дә күрү түгел, ишеткәне дә юк иде. Шуңа күрә тамашачы шактый күп килгән иде, хәтта бик сирәк күренә торган кайбер мөхтәрәм кешеләр дә бар иде. Мәсәлән, нэп вакытында гына Дәүләкәнгә күчеп килгән һәм сату итәргә керешкән Стәрлетамак мулласы Мөбарәкша Хәнәфи дә остабикәсе белән әнә иң беренче рәткә килеп утырган! (Бу кайчандыр шактый мәгълүм, искечә әйтсәк, тәрәккый пәрвәр мулла иде. Аның эчүчелек һәм тәмәке тарту кебек зарарлы гадәтләргә каршы язган кечкенә китабы да заманында басылып чыккан иде. Бу мулла хакында Шәехзадә Бабич болай дип язган иде:

Мөбарәкшаһдыр Хәнәфи, төп-түгәрәк, оп-озын.
Аклы-коңгырт, күкле-саргылт, чоп-чуар һәм кып-кызыл!

Күрәсең, бик чуар кеше булган ул.)

Спектакльне яхшы артистлар уйнагач, билгеле, бик уңышлы узгандыр инде — мин суфлер чокырында утырып, барысын да ачык кына күрә дә алмадым. Әйтергә кирәк, минем суфлерлыгым артистларны вакыт-вакыт читен хәлгә дә куйгалады шикелле, чөнки сәхнәдә барган уенга мин авызымны ачып, аларга сүз бирергә дә онытып җибәрә идем. Шул чакта артистларның берәрсе будка алдыннан: «Сүз, сүз!» — дип пышылдап узгач кына айнып китә идем. Хәер, сүз бирсәм дә, бирмәсәм дә, алар барыбер үз эшләрен эшли бирделәр. Соңыннан мине шелтәләп тә тормадылар, күрәсең; моныңише генә нәрсәгә игътибар итмәскә күптән өйрәнгәннәр инде. (Ә бәлки, «егетнең» күңелен төшермик дигәннәрдер.)

Әнә шулай үтеп китте ул бердәнбер чын спектакль. Икенче көнне үк алар, пар ат яллап, бездән Көрмәнкәйгә китеп тә бардылар. Бездә бары алты гына көн тордылар, әмма бу алты көн минем өчен онытылмас бер бәйрәм булып калды. Алар янына залга керергә никадәр уңайсызлансам да, барыбер кермичә түзә алмый идем. Гаҗәеп бер хөрлек, табигыйлек, гадилек һәм өзлексез уенкөлке иде алар арасында... Шуның өстенә Маһирә апа бик матур җырлый да иде... Менә шулар кебек булсаң

иде дә шулар кебек торсаң иде! — дип хыяллана идем мин ниндидер бер сагышлы-татлы уфтану белән. Үзләре дә сизмәстән алар әнә шулай әсир иттеләр дә киттеләр минем өмет-теләкләрем яңа гына әле уяна башлаган япь-яшь җанымны!

Шулай да язмышка рәхмәт әйтергә тиешмендер, ахрысы... 1925 елның августында Казанга килгәч, күпмедер вакыттан соң, мин аларның да Казанда булуларын белдем. Дүртесе дә Уфа театрыннан Казан театрына күчкәннәр икән. Ул чакта татар театры хәзерге ТЮЗ бинасында (Островский урамында) иде. Минем әле аларның берсен дә күргәнем юк, эзләп барырга кыенсынам да, ләкин күрәсем дә бик килә — ачык кына аңлап җитмәсәм дә, моның минем өчен ниндидер бер әһәмияте булырга тиеш кебек иде. (Һичюгы, таныйрлар микән дип кызыксынуым булгандыр.)

Ниһаять, сезон ачылып, спектакльләрнең берсенә баргач, мин театр бинасында Нәгыймә апа Таҗдарованы очраттым. Дәштем, билгеле — ул мине шунда ук таныды, ачык йөз белән исәнләште һәм, бераз гаҗәпләнеп, минем шулкадәр ерактан Казанга ничек, ни өчен килүемне сорашты. Антракт вакытында сөйләшү кыска гына булса да, бу очрашу мине бик куандырды һәм ничектер тынычландырды. Нәгыймә апа әле Нури абый белән шушы ук театр йортының бер бүлмәсендә торуларын да әйтергә өлгерде. Шакир абый белән Маһирә апа икенче җирдә торалар икән.

...Әкренләп мин калганнарын да күрдем. Күбрәк сәхнәдә уйнаганнарын күрә идем, ләкин ара-тирә театр эчендә дә очрата идем. Мин укырга дип килгән яшь кенә егет, ә алар дәү кешеләр, исемле һәм эшлекле кешеләр — үземә ниндидер аерым игътибарны көтмим, әлбәттә, әмма очраганда Дәүләкән малаен танып, бездә биш-алты көн генә булса да торып китүләрен исләренә төшереп, ачык йөз күрсәтсәләр, миңа шул бик җиткән иде. Һәм әйтәсем килә: шушы тану, шушы үз итүләре алар тарафыннан гомерләренең ахырына кадәр диярлек бетмәде.

Еллар узып, үзем дә инде яшь ягыннан шактый олыгайгач, мин бу дүрт артистның икесе, ягъни Нәгыймә апа Таҗдарова һәм Шакир Шамильский белән ярыйсы гына якынаеп та киткән идем. Ни өчен икесе белән генә дигәндә, моның ачык сәбәбе шул: алар Казанга килеп күпмедер торгач та Шамильскийларның яшь балалары фаҗигале рәвештә үлеп китә. Ана өчен шушы аеруча зур хәсрәттән соң, Маһирә апа Мирвәлиева сәхнәне ташлап, Казан университетының медицина факультетына

укырга керә һәм биш елдан инде ул врач та булып чыга. Сәхнәне никадәр генә яратмасын, күпме генә ияләшмәсен, әмма авыруларга, вакытсыз үлемнәргә каршы көрәшү аның җан таләбенә әйләнә. Ватан сугышында ул башыннан ахырына чаклы врач буларак фронтларда йөреп уздырды.

Нури Сакаев исә 1927 елның февраль ахырында кинәт кенә үлеп китте. Мин аның җеназасын (күмү мәрасимен) яхшы хәтерлим. Ул елларда шагыйрь, әдип яки артистның үлеме зур бер кайгылы вакыйга булып санала иде. Газеталар да аңа күп урын бирәләр иде. Озатырга халык та күп җыела торган иде. Моның шулай икәненә ышаныр өчен Фатих Әмирхан белән Һади Такташның үлемен искә төшерү дә җитә.

Нури Сакаевны да бик зурлап озаттылар. Иң элек, аның вафатына багышлап, Салих Сәйдәшев үзенең мәшһүр «Сакай маршы»н язды. Бәгырьләргә үтәрлек бу гаҗәеп көчле-моңлы матәм маршы Сакаевны озаткан чакта беренче мәртәбә уйналды да... Нури абзыйның гәүдәсен театр бинасыннан алып чыгып, ачык машина өстенә урнаштырдылар (машина ул чакта бик сирәк нәрсә иде). Табутның баш очына мәрхүмнең юан таягы белән кара эшләпәсен, ә аяк очына киеп йөргән ботинкаларын куйдылар. Артистны соңгы юлына аның тере чакларында кигән, токкан әйберләре дә озата бардылар. Бу моңарчы күрелмәгән бер яңалык иде.

Тагын бер онытылмаслык эпизод: күмү мәрасиме, Татарстан урамына җиткәч, «Шәрекъ клубы» алдында туктады. Халык тынып калды. Кәрим ага Тинчурин машина өстенә басып, татар театрының беренче үз йорты булган сәхнәсендә Нури Сакаев та күп мәртәбәләр уйнаган шушы тар гына гади кирпеч бинага мәрхүмнең соңгы сәламен тапшырды... Әнә шулай тантаналы, җылы, күркәм, матур итеп озаттылар ул чакта татар сәхнәсенең олы артистын!

Нәгыймә Таҗдарова белән Шакир Шамильский Нури Сакаевтан соң бер егерме ел чамасы озаграк яшәделәр. Дөрес, алар да дөньядан бик вакытсыз иртә киттеләр, әмма шулай да татар сәхнәсен үзләренең онытылмас гүзәл эшләре белән бизәп, театр сәнгатебездә тирән эз калдырып китәргә өлгерделәр.

Миңа аларның икесе турында да язарга туры килде. Сугыштан соң башта ВТО тапшыруы буенча Таҗдарова турында язарга керештем... Нәгыймә апа авыру иде инде. Мин аның театр ишегалдында Сәйдәш торган кызыл йортның икенче катындагы кечкенә бүлмәсенә барып, кара-

ваты янына утырып, үзе һәм эше турында сөйләгәннәрен тыңладым. Шулай ук язып килгәннәремне дә, янына утырып, үзенә укыдым. Әмма басылып чыкканын күрү аңа насыйп булмады (Нәгыймә апа озак авырудан соң 1947 елның мартында вафат булды). «Н.Таҗдарова» дигән кечкенә китап бары 1957 елда гына дөньяга чыкты. Шулай да бу китап безнең әдәбиятта артист иҗатын тикшерүгә багышланган беренче тәҗрибә, беренче әсәр дә иде.

Шакир Шамильский Нәгыймә ападан ике ел чамасы алданрак — 1945 елның маенда вафат булды. Хатыны Маһирә апа да фронттан кайтып җитмәгән иде әле. Шакир абый бөтен сугышны ялгызы гына бик авыр шартларда яшәп үткәргән. Рәхимсез сугышның корбаны дияргә дә була аны... Мәрхүмне җирләгән көн бик нык истә калган, чөнки бу 8 нче май көне иде. Ни хикмәттер, шул ук кичне йокларга яткач, таң алдыннан Шакир абый бик ачык булып минем төшемә дә керде. (Соңыннан мин бу төшне язып та куйган идем.) Һәм шул чакта безнең урам як тәрәзәсен кемдер бик каты каккан тавышка уянып киттем. Төшем өзелде... Янабызмы әллә дип сикереп торсам, тәрәзәгә күрше хатыны капланган, ике куллап кага-кага безгә кычкыра: «Нишләп ятасыз, торыгыз, сугыш беткән, ишетәсезме, сугыш беткән, җаныкайларым!»

Әйе, Бөек Җиңү хәбәрен китергән 9 нчы май таңы иде бу. Халыкның шатлыгы чиктән ашкан, урамнарга һәм мәйданнарга ташып чыккан көн иде бу... Бу көнне шатлыктан да, хәсрәттән дә җылаучылар аз булмады. Тик шуны мәрхүм Шамильский гына күрергә өлгермичә бер көн алдан китеп барды.

Шакир Шамильский минем иң яраткан, иң хөрмәт иткән кешем һәм артистым иде. Һич тә икеләнмичә, мин аны бөек артист дип әйтә алам. Билгеле инде, аның турында да мин язмыйча кала алмадым. Вафаты уңае белән «Совет әдәбияты» журналында язып чыктым, соңрак тагын тулырак һәм киңрәк тә итеп яздым. 1965 елны аның турында бер кечкенә истәлекләр китабы да җыеп чыгардым.

Шулай итеп, малай чакта уйламастан гына үзебезгә ияртеп кайткан артистлар белән миңа соңыннан да әнә шундый якын һәм дәвамлы бәйләнештә булырга туры килде. Кызык икән ул язмыш дигән нәрсә! Еш кына һич көтелмәгән нәтиҗәләргә дә китереп чыгара икән. Һәм уйлыйм ки, бу олы затларның минем киләчәгемә дә уңай йогынтылары булмыйча калмагандыр, әлбәттә.

1925 ел, гомумән, бик истәлекле ел булды минем өчен... Нәкъ шушы елда миңа туган-үскән оядан да аерылырга туры килде. Безнең тормышыбызга да шактый үзгәрешләр кертте ул нәүбәттәге бер ел.

...Атай хәленә килгәндә, аны нэпның беренче банкроты дияргә була. Югарыда язып узганымча, Муса Хәбиров белән бергәләп бер кыш сәүдә итеп маташканнан соң, безнең карт инде патентлар алып сату итүдән туктады. Аның инде кечкенә ларек ачарлык та рәте беткән булып чыкты. Муса китте дә котылды, ә без үзебезнең мактаулы Дәүләкәнебездә яшәргә тиеш идек. Атакай Дәүләкәнне никтер бик ярата иде һәм кая да булса күчеп китү турында уйлап та карамый иде. Ләкин бит торырга кирәк, семьяны асрарга кирәк, безне дә аякка бастырырга кирәк. Атакай күптән инде крәстиян эшеннән аерылган, игәр җире дә, җигәр аты да юк, бар мөлкәте — йортыбыз да бер сыерыбыз гына... Бүтән һөнәре юк, яше дә илледән узган. Билгеле, ул базар тирәсендә алыш-биреш итеп кенә яши ала. Йә, шуннан соң нишләргә, нинди юлын-чарасын табарга? Нэп заманындагы базарларда үз кулы белән нидер ясап, аягөсте генә яки җиргә утырып кына сату итүчеләр дә күп була торган иде. Кибет тотмагач, аларны чын нэпманнардан санамыйлар, ә вак-төяк белән табыш итүчеләр генә дип карыйлар. Берәү чабата үреп сата, икенчесе чаганнан кашыклар ясап сата, кемдер тагын үзе иләгән куян тиреләрен күтәреп йөри. Азмыни шуның ише ипи-тозлык акча табучы һөнәрмәндләр?! Менә безнең атакай да үзенә шундый бер эш тапты — ул тимер чыбыктан кием элгечләр, таба һәм утюг аслары үреп сатарга кереште. Шуларны ясар өчен кирәк булган кискеч, бөккеч, «карга борыны» кебек коралларны да каяндыр тапты, ә материалның үзен, ягъни тимер чыбыкның төрлесен, Златоуст, Мияс якларына барып, шуннан табып алып кайта иде. Авыр йөк иде бу аның өчен, әмма бүтән чарасы юк — башыңа төшкәч, башмакчы буласың, дигәннәр тормышны татыган агайлар... Белмим, бу «кәсеп»нең табышы күпме генә булгандыр инде, ләкин, һәрхәлдә, акмаса да тамгандыр — акчаның бик бәрәкәтле чагы иде. Шуның өстенә, без йортыбызның урам башына һәрвакытта фатирчы кертә идек — бу да үзенә күрә бер терәк... Менә шулайрак яши торган булдык без нэпның нәкъ «чәчәк аткан» чагында.

Шул ук егерме бишенче елның язында миңа уналты яшь тулды. Шул ук елны мин җиденче сыйныфны да тәмамладым. (Сугышлар аркасында өзелеп тормасам, бәлки, иртәрәк тә бетергән булыр идем.) Уналты яшь,

үзегез беләсез, адәм баласының балигъ булу вакыты, шушы яшендә кеше малайлыктан аерыла, егет булып җитешү чорына керә. Акыл, зиһен, хыял, рух — барысы да бик тиз үсә, көчәя, тирәнәя башлый. Әзләнү килә, тынгысызлык килә, хәтта борчылу да... Мин, иң элек, менә шушы тынгысызлык белән борчылуны үземдә сизә башладым. Билгеле, моның миңа гына кагылган аерым сәбәпләре бар иде. Һаҗәргә булган өметсез мәхәббәтне әйтеп тормыйм, чөнки мин (гәрчә мәхәббәт газабы кешенең җанын бик җәрәхәтләсә дә) аңа күпмедер дәрәҗәдә ияләшкән идем инде. Иң борчыган, иң уйландырган нәрсә — ул киләчәк мәсьәләсе иде. Тиздән зур үзгәрешләр башланыр кебек, ни булыр, нәрсә көтә безне алда? — борчылмыйча мөмкин түгел! Миңа да нидер эшләргә, каядыр китәргә, мөгаен, кирәктер, әмма кая китәргә, нәрсә эшләргә — бу кадәресе әле суга сәнәк белән язылган. Кечкенә Дәүләкән шартларында моңа җавап табуы да читен иде, аннары миңа әзрәк кенә үсә төшәргә дә кирәк булгандыр, ахрысы.

...Һәм шушы нәрсәне ничектер сизепме, әллә аң дәрәҗәм өстенрәк булганга күрәме, мин үземнән яшькә олыраклар арасына керергә омтыла башладым. Үз тиңнәрем белән Димнең төрле җиренә барып су керүләрне яки чабата киеп футбол тибүләрне исәпләмәгәндә, минем инде якыннан аралашкан дусларым үземнән өч-дүрт яшькә олы, җиткән егетләр иде. Алар арасыннан иң беренче итеп, мин, әлбәттә, Зөфәрне күрсәтер идем. Чөнки кече яшьтән үк дәвам итеп килгән якынлыкның торабара егетләр арасында гына була торган дуслыкка әйләнүе бик табигый иде. Әмма мине аңа тарткан тагын бер тирәнрәк яткан сәбәп тә бар иде. Зөфәр бит ул егерме өченче елдан ук безнең беренче комсомол-яшьләрне үз артыннан ияртүче, күп эшләрне башлап йөрүче, өстәвенә әйбәт кенә гармунчы да, шәп кенә декламатор да иде — билгеле инде, аның кебек үткен-булган егеткә һәркем тартыла, һәркем ярарга, ышанычын казанырга тырыша. Минем өчен исә кешегә ышану икеләтә зарур иде. (Бергә уйнап-көлеп йөргән иптәшләр арасында да иртәме-соңмы мөнәсәбәтләр үзгәрәчәген, бервакытны моның миңа да кагылачагын мин ничектер сизә дә башлаган идем.) Әмма мин Зөфәрнең мине читкә какмаячагына ышандым. Икейөзле түгел иде ул, атасы кебек туры сүзле иде — андый кеше хатаң булса туп-туры үзеңә әйтер, иллә мәгәр хаиннарча артыңнан китереп сукмас... Еллар узды, нинди генә вакытларны кичермәдек, ләкин ике арадагы дуслык, бер-беребезгә ышану какшамады, бозылмады, ис-

кечә кала бирде. Тик безгә иртә аерылырга һәм озак еллар очрашмыйча торырга туры килде. Бары олыгаеп беткәч кенә без, ниһаять, яңадан очраша алдык. Ул инде күптәннән Бәләбәйдә яши иде — менә мин аны күрер өчен генә ике тапкыр шушы шәһәрдә булып киттем һәм 1969 елны үземнең туган көнемә Дәүләкәнгә дә чакырып алдым.

...Зөфәр миннән дә битәр Хәбибрахман белән ныграк дус иде, чөнки яшь ягыннан тиңрәк булып, иртәрәк берберсен белгәннәр, бергә йөри башлаганнар. Хәзер инде алар икесе дә бу фани дөньядан киттеләр, әмма хәтердән һәм күңелдән киткәннәре юк. Ак күлмәк, кара чалбар киеп йөргән егет чакларыбызның тере образлары булып, икесе дә бөтен кыяфәтләре белән минем күз алдымда сакланалар. Соңгы елларда безнең җырчыларыбыз каяндыр «Җомга» көен табып чыгардылар. Бу бит Зөфәрнең Димдә йөргәндә кечкенә гармунында өздереп уйнаган көе, безнең аңа кушылып, дәртләнеп-шашып җырлаган көебез ләбаса! Моннан нәкъ алтмыш еллар чамасы элек!

Эчемнән генә әллә җырлыйм, әллә җылыйм:

Гармуныңны тартып уйна үрләргә менгәндә дә,
Онытасым юк үлгәндә дә, гүрләргә кергәндә дә...

Юк, булмый, җитәр!..

Казанга китәсе елны мин тагын үземнән дүрт яшькә олы бер егет белән шактый ук якынайдым. Бу — Фәтхелислам Хәкимов иде. Әнисе — Латыйфа җиңги, энесе — Миңнеислам. Болар турында мин «Дәүләкән» өлешендә беркадәр язып узган идем. Аталары грузчик Мансур агай 1918 елны ук тифтан үлеп киткән. Тол хатын, ике малай бик авыр хәлдә калганнар, кеше өендә генә үтә фәкыйрьлектә яшәгәннәр. Егерме беренче елның ачлыгында алар, бәлки, беткән дә булырлар иде, ләкин, бәхетләреннән, аларны Гатаулла карт ач үлемнән коткарып кала. Карт аларга хәленнән килгән кадәре ризык та һәм ишегалды түрендәге өеннән җылы почмак та бирә. Тук елларга ирешкәнче, алар азмы-күпме картка хезмәт күрсәтеп, шунда тыныч кына яшәделәр. (Ләкин батрак булып түгел, чөнки Гатаулла бабайның үзенең җиткән өч улы бар иде.) Ике малай икесе дә мәктәпкә укырга йөрделәр. Мин үземә тиң Миңнеислам белән нигәдер артык дуслашып китә алмадым, ә менә агасы Фәтхелислам белән без, киресенчә, ару гына дуслашып киттек. Моның ике сәбәбе булды: мин Фәтхелисламнан белмәгән дәресләремне өйрәнә идем, икенчедән, Фәтхелислам да минем кебек әдәбият уку

белән бик мавыга торган иде. Ул миннән бер сыйныфка югарырак укый иде һәм, әйтергә кирәк, бик сәләтле шәкерт иде. Бигрәк тә — математикадан, ә бу минем иң авыр дәресем,— менә мин аның янына шушы авыр дәресне өйрәнергә бара идем.

Әйткәнемчә, алар ишегалды түрендәге озын гына йортның бер янтык мөешендә, димме, торалар иде. Ишеге дә аның туп-туры ачык һавага чыга иде. Кем өчен, нәрсә өчен эшләнгән булгандыр инде бу мөеш (яки бүлмә), әмма ул шулкадәр бәләкәй иде ки, ишегеннән кергәч тә бусагада ук тукталып калырга туры килә иде. Чөнки эчкәрәк үтәргә урын юк — каршыда гына мич авызы, уңда, ике стена арасында, кыска гына сәке, шушы ике нәрсә белән «торак мәйданы» тулган да беткән. Ашау-эчү, яту-тору иске киез җәйгән сәкедә, ә үзләренә җитәрлек кенә савыт-сабалары мич кашагасы белән бердәнбер тәрәзә төбендә. Бүтән әйбер заты юк, хәер, мич белән сәке арасында бер бүкән тора икән әле — бу Фәтхелисламның пима (Казанча, киез итек) төпләгәндә астына иске бишмәт салып утыра торган урыны. Күрше-тирә керткән пималарны әйбәт кенә төпләргә ул азмы-күпме килере өчен үзлегеннән өйрәнгән иде. Туры безе, кәкре безе, зур калып энәсе, әйбәтләп сумалалаган сүс җепләре бар — дәрестән кайткач, бүкәненә утырып, берәр пиманы ике тезе белән кысып, телен дә авыз читенәрәк чыгара төшеп, эшкә тотына иде.

Фәтхелислам, өс тә юка, эш тә кала дип булса кирәк, кыш көне бер дә чыгып йөрми иде, шуңа күрә мин үзем дәфтәрләремне күтәреп аңа килә идем. Үткән дәресне кабатлыйсы бар, укытучы биреп җибәргән мәсьәләләрне чыгарасы бар — менә миңа шуларны эшләүдә Фәтхелислам дусның ярдәме кирәк. Мин каршысына, сәке кырына утырып, әнә шул «чыкмыйча» мине азаплаган мәсьәлә белән аны таныштырам. Ул әйтергә ашыкмый, эшеннән дә аерылмый, тик: «Үзең уйладыңмы? Тагын уйлап карале»,— ди миңа... Мин тагын каш җыерып уйлаган булам, ләкин барыбер «очын» таба алмыйм, тик шуннан соң гына ул ничек эшләргә кирәген әйтеп бирә. Кайчагында аның бер сүз әйтүе җитә — мин, шунда ук эләктереп алып, мәсьәләне ахырына чаклы эшләп тә чыгам... «Син, Әмир, ялкау,— ди торган иде ул миңа.— Әнә тырышкач булдырасың бит!» — ди иде. Мин аның яныннан, билгеле, куана-куана кайтып китә идем.

Биредә аеруча шуны әйтергә кирәк: Фәтхелислам бик сабыр, тыйнак һәм гаҗәп әдәпле егет иде. Гаҗәбе шунда ки: яшьтән үк атасыз калу, авыр нужа, фәкыйрьлек, ач-

лык бүтән берәүне, бәлки, бозып та бетергән булыр иде, әмма әнә шуларның барысын да бик нык татыган Фәтхелисламда бозылуның бер генә төрле дә билгесе юк, киресенчә, әдәп-инсаф ягыннан ул иң әйбәт шартларда яшәп, иң яхшы тәрбия алганнарга да үрнәк булырлык иде. Кайдан, нәрсәдән бу?.. Бәлки, нәсел-нәсәбеннәндер, бәлки, Гатаулла бабай, Габдрахман абзыйларның да аңа уңай йогынтысы булгандыр, ә бәлки, авыр нужа аркасында урам малайлары белән күп аралашып йөрмәү дә аны бозылудан саклагандыр?! Ләкин шулай да әхлак дигән нәрсә, минемчә, күбрәк нәселдән килә. Энесе Миңнеисламда да бит бу җәһәттән агасына охшаган.

Укулар бетеп, җәйгә чыккач, без буш вакытларыбызда күбрәк безнең өйдә китап укырга ярата идек. Кояшлы көнне өй артындагы бакчада, явымлы көн булса, зур залда икәү генә китапны алмашлап кычкырып укый торган идек. Гадәттә, мин ялгыз үзем генә укырга ярата идем, ләкин хәзер, дәресләрне бергә хәзерләп өйрәнгәнгә күрәме, кулыма яхшырак китап керсә, Фәтхелисламны да бергәләп укырга чакырмыйча калмый идем. Ул китап укуның тәмен белә, миңа кадәр үк күп кенә дини китапларны һәм дини әкиятләрне укып та өлгергән. Элек бит андый китаплар кулдан-кулга йөреп, бик укыла торган булган. Ләкин хәзер инде безнең иң яратып укыганыбыз — матур әдәбият, аның да иң яңалары... Шундый китап кулга эләксә, без инде аңардан аерыла алмыйбыз, хәтта инәйнең каймак туглап биргән катыгын ашаган чакта да!

...Һич онытасым юк Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр»ен икәү алмашлап укып чыгуыбызны! Сары кәгазь тышлы, соры кәгазьгә басылган, әдипнең креслога утырып төшкән рәсеме дә урнаштырылган бу Коръәннән дә калынрак роман безне тәмам йотты, әсир итте, без аңардан аерыла алмас булдык, тиз генә бетмәвен, уку рәхәтенең бер дә өзелмичә дәвам итүен теләдек. Моңарчы да мин үзем генә яки икәү бергә укыган матур китаплар аз булмады, әмма «Безнең көннәр» кебек бу хәтле дә безгә ошаганы, безне беткәнче биләп алганы булды микән? Моның сәбәбен без ул чакта, бәлки, аңлап та бетермәгәнбездер, ләкин шулай да романның бер ягын сизмичә һәм тоймыйча калмадык: роман үзенең эчтәлеге, ягъни чоры, вакыйгасы, кешеләре белән безнең өчен гаять яңа һәм кызыклы иде. Менә ни өчен аның күп кенә каһарманнары да — Даут Урманов, Хәбиб Мансуров («Сруҗе»), Сәхип шәкерт, Гөлбикә, Баязит карый, морза кызы Рауза, Даутның сөйгәне Нәфисәләр — барысын да

атап чыгу мөмкин түгел — хәзергә чаклы онытылмыйча хәтердә сакланып килделәр. Мондый хәл сирәк була. Ихтимал, шуңа күрәдер, мин бу романның әдип тарафыннан утызынчы елларның башларында төзәтелгән вариантын шушы көнгә кадәр укырга җөрьәт итә алганым юк, ничектер менә беренче басмасыннан алган тирән тәэсоратны югалтырмын дип куркам. Бәлки, мин ялгыша да торганмындыр, төзәтелгән варианты, бәлки, яхшырактыр да, ләкин нигәдер шуңа ышанып бетә алмыйм. Чөнки ул елларда «төзәтелгән» кайбер әсәрләрнең беренче вариантларына караганда шактый йомшак булып чыгуларын күрергә туры килде. Гомумән, конъюнктурага ияреп әсәр төзәтү ул, минемчә, сәнгать эше түгел.

Безнең эшебез китап укып утыру белән генә чикләнми иде, әлбәттә. Күп вакытыбыз уенга, йөрүгә, җәмәгать эшләренә дә китә иде. Фәтхелислам егерме яшендә муенына хәтта кызыл галстук та бәйләде — мәктәптә яңа оешкан пионерлар отрядына аны вожатый итеп куйдылар. Ә мин күбрәк клуб тирәсендә йөрим, анда үткәрелгән кичәләргә, спектакльләргә катнашырга атлыгып торам. Бу җәйдә безнең яшьләр бик активлашкан иде, ләкин мин аларның һәркайсы турында язып тора алмыйм — бик озынга китәчәк. Шулай ук бик кызыклы, бик күңелле көннәребез турында да сөйләп бетерү мөмкин түгел... Әмма ике кешенең язмышы белән бәйләнгән бер вакыйганы шулай да сөйләү кирәктер дип уйлыйм.

...Җәйнең бик ямьле вакытында, печәнгә төшәр алдыннан, без дүрт егет, ике кыз спектакль күрсәтеп йөрер өчен волостебыздагы авылларга чыгып киттек. Җитәкчебез Әфтах исемле, волкомолда эшләүче егет иде. Зөфәрнең бик якын дусты, бер елгылар, бер үк вакытта комсомолга да кергәннәр, җитмәсә, икесе дә оста гына гармунчылар. Ләкин Әфтах характеры белән Зөфәрдән нык кына аерыла да иде. Зөфәр кайнар, тынгысыз, ә бу, киресенчә, сабыр-тыныч, кешеләргә мөгамәләсе дә тигез, һәм шуның белән ул безне үзенә тарта да иде... Менә шулай аның җитәкчелегендә авылдан авылга йөрибез. Ул чакта клуб дигән нәрсә юк, ябылган мәчетләр дә юк әле, тамашабызны гел диярлек мәктәпләрдә күрсәтәбез. Йөри торгач, ахырда без Өршәк буендагы Мерәс дигән башкорт авылына килеп җиттек. Бу безнең юлыбыздагы соңгы авыл иде. Мерәсләр бер-берсенә якын гына торган ике авыл — без шуларның зуррагында тукталдык.

Авылда җыен көне иде — күчебез белән җыенда йөрдек. Монда күргән ярышларны, уеннарны язып тормыйм — болар билгеле нәрсәләр. (Көрәшне, ат чабы-

шын кем күрмәгән?!) Минем икенче бер нәрсәне язасым килә: халык арасында җыен кызыкларын карап йөргәндә, безгә киез эшләпә, ак күлмәк, кызыл ыштан, оек-чабата кигән бер таза-чибәр егет иярде. Кулларын артка куйган, як-ягына каранган була, ә үзе бездән бер адым да калмый — эчебездән генә шикләнә биреп, бу куе-кара кашлы егеткә ни кирәк икән? — дип уйлыйбыз. Ахырда йөри торгач, бер туктап торган арада үзе үк башлап Әфтахтан сорады:

— Агай, сез Дәүләкәннәнме?

— Әйе, Дәүләкәннән,— диде Әфтах.

— Әртистләрме?

Әфтах егеткә сынаулы бер күз ташлады да көлемсерәп кенә:

— Ийе, монда без артистлар, менә бүген сезгә уйнап та күрсәтәбез әле,— диде.

— Бик әйбәт, көнен белеп килгәнсез,— диде егет тә елмаеп, аннары аз гына дәшми торып, тагын сорады: — Ә сез, агай, үзегез кайда эшләйсез?

— Минме?.. Мин элек тегермәндә эшләдем, ә хәзер волкомолда эшлим.

— Вәт! — диде егет, эзләгәнен тапкандай кинәт яктырып.— Сез кәрәк тә инде миңа!

Хуш, ни өчен әле бу егеткә һич көтмәгәндә Әфтах шулкадәр кирәк булып чыкты?.. Баксаң, аның бик зур бер теләге бар икән: укырга һәм укырга! Юк, ул грамотный егет, үз авылында башлангыч мәктәпне күптән бетергән инде, ләкин хәзер аның кая да булса читкә китеп, зур җирдә укыйсы килә икән... Менә шуңа ничекирешергә?.. Волкомол ярдәм итмәс микән?..

— Итәр, ник итмәсен!.. Теләгең бик әйбәт, егет кеше, но читкә киткәнче тагын монда бер-ике кыш укырга кирәк булыр,— диде Әфтах аңа.

Ләкин егет моның белән килешеп бетмәде, яшем узып бара, быелдан яки киләсе елдан да калмаска кирәк, диде. Кыскасы, алар арасында әнә шундый бик мөһим сөйләшү булып алды.

Әйе, авыл яшьләрендә уку дәрте бик нык кузгалган чак, хәтта менә иң читтәге башкорт авылында да уянган икән инде ул дәрт!

Җыен бетәр-бетмәс, егет безне үзенең өенә дә кыстый башлады. Без, бераз кыенсынсак та, барырга риза булдык — җыеннан кунак алып кайту ул күптәнге йола, аны кире кагу килешмәячәк иде. Егетнең атасы юк, инәсе белән икәү генә торалар икән — шулай диде ул безгә.

...Җил капкасы, читән абзарыннан башка бүтән бер

каралтысы да булмаган, салам түбәле бәләкәй генә ярлы өй, әмма шушы ярлы өйдә егетнең инәсе — озын чандыр гына җиңги — безне бик тәмле бәйрәм коймагы белән сыйлады. Сары майда гына йөзгән юка гына әче коймак ашап туймаслык иде. Җыеннан ачыгып та кергәч, без аны, иркен сәкегә аякларны бөкләп утырып, сөтле чәйне эчә-эчә, әйбәтләп бөктек кенә!.. Шәп төште бер таба коймак!

Ләкин соңрак безнең башыбызга бер кайгы да төште: бу авылда спектакль куярлык урын юк икән. Иске генә мәктәпләрен яртылаш сүтеп, яңадан сипли башлаганнармы шунда — кыскасы, аңа кереп, тамаша күрсәтеп булырлык түгел, диделәр безгә. Бик аптырауда калган идек, шуннан соң хуҗа егетебез безне түбән Мерәскә алып китте. Ике авыл арасы бик якын иде, җәяүләп кенә барып та җиттек. Кечкенә генә, бөтен генә, күңелле генә бер авыл икән бу Яңа Мерәс... Һәм шушы авылда заманның кая таба барганын чамалый белгән бер бай башкорт үзенең келәт белән абзар арасындагы арбалар, чаналар тора торган ачык лапасын безгә биреп торырга риза булды. Кердек, карадык, лапасның түшәме юк, кыегы гына бар, аркылы киртәгә кибәр өчен яшь каен себеркеләре эленгән. Хуҗа сбруйларын келәткә күчерде, арбалар үз урынында калды. Без лапасның бер башын дәррәү генә әрҗә, мичкә кебек нәрсәләрдән бушатып, җир идәнен себереп, чаршау корып җибәрдек. Тамашачылар өчен бер-ике эскәмия дә табылды, калганнарына әнә арба-чана, йә аягөсте генә карарлар... Елына бер килгән тамаша бит бу, тик менә бик караңгыга калмасак иде. Чөнки ут юк, ут булмаячак, хуҗа лапаска лампа асуны каты рәвештә тыйды. Дөрес тыйды, әлбәттә... Көннең дә иң озын чагы, сәгать уннарда гына сыек караңгылык иңде, бары шул чакта гына ике авылның утызлап яшь-җилкенчәкләре лапаска, ниһаять, кереп тулдылар. Без инде күптән әзер идек, көтә-көтә арып та беткән идек. Әфтах яшьләргә комсомол исеменнән кыска гына нотык сөйләде, шуннан без чаршауны шылдырып, уйный башладык. Кызганычка каршы, нәрсә уйнавыбыз ачык кына хәтердә калмаган — ялгышмасам, «Яшьләр алдатмыйлар» дигән ике пәрдәлек кенә комедия иде бугай. Хәер, ни генә уйнамыйк, лапас астына йолдызлардан гына иңгән төнге яктылыкта тамашачылар йөзләребезне ачык күрмәсәләр дә, сүзләребезне бик ихлас тыңладылар. Ул заманда читтәге авылларда «тиятер» дигән нәрсә бик тансык иде, яшьләр бик мавыгып карыйлар һәм тәртипне дә һич тә бозмыйлар иде. Тамаша беткәч тә әле, алар таралырга ашыкмыйча, урамда безне көтеп тордылар.

Без эшне бетереп, җыенып, хуҗага рәхмәт әйтеп чыкканда, таң сызылып килә, җир өстенә тын-соры яктылык әкрен генә җәелә башлаган иде инде. Яңадан иске авылыбызга кайтырга булдык, әлеге юлдаш егетебез үзенә чакырып тора — кызлар өйдә, ә без печәнлектә йоклар-быз, ди. Киттек. Безгә ияргән егетләрнең берсе: «Давай, чабыннан кайтаек әле»,— диде. Чынлап та, нигә тузанлы юлдан атларга?.. Авылны чыккач та болынга төшә торган арба эзе белән Өршәккә таба борылдык. Болында яшь үлән тездән дә югары, иртәнге бал чыгы төшкән, чәчәкләргә инде бал кортлары да килеп җиткән... Куе үләндә юеш эзләр калдырып атлыйбыз. Тынлык, алсу-тирән тынлык, тик әнә әрәмәлектә кошлар гына уянып, балалары белән нидер черелдәшәләр... Әфтах гармунын күкрәгенә күтәрә биреп, тартып җибәрде. Тирән таң тынлыгында яңгыраган гармун тавышы гаҗәеп икән ул! Бәгырьнең кай җиренә генә үтеп керми дә нинди генә хисләр уятмый икән ул!.. Хәтта егетләрдән гармунга кушылып җырларга җөрьәт итүче дә булмады — һәммәсе дә әсәрләнгән, йотылган, онытылган, гүя аларга шушы гармун тавышыннан башка берни дә кирәкми!.. Һәм Әфтах та, шуны сизгәндәй, аеруча бер дәртләнү, кабыну белән, әйтерсең соңгы мәртәбә, бөтен күңелен-җанын салып уйнады... Күпме уйнады, нинди көйләр уйнады — мин әйтә алмыйм, әмма аның шул уйнавы минем хәтеремдә, минем колагымда гомерлеккә торып калды.

Сүз ике язмыш турында дидем. Инде менә шуның берсе: шул ук җәйнең сентябрь башында Әфтах Уфа рабфагына укырга китәргә тиеш. Китәсе көнне ул кечкенә чемоданына кирәк- яракларын, китап-дәфтәрләрен салып, эшен бетереп куя да урам аша гына торган Гомәр исемле егеткә әллә йомышы төшеп, әллә күрешеп чыгар өчен генә керә... Гомәрне мин дә яхшы белә идем. Ул ире үлгән Хәят исемле укытучының улы иде, зур кара күзле, кара чәчле, тыгыз-җыйнак бәдәнле егет, мандолинада бик оста уйнаучы — мине дә уйнарга өйрәтеп маташкан иде дә, тик бер хикмәт тә чыкмады. Гомәрнең Әминә исемле миннән берничә яшькә генә кечерәк, күп малайларны үзенә караткан бик чибәр сеңлесе дә бар иде. Алар Дәүләкәнгә ачлык елыннан соң кайсыдыр шәһәрдән (Уфадан булса кирәк) күчеп килделәр. Ахрысы, шунлыктан Гомәр дә, Әминә дә бик пөхтә киенеп йөрүләре һәм үзләрен ничектер һавалырак тота белүләре белән безнең Дәүләкән яшьләреннән аерылыбрак, өстенрәк торалар да иде. Шулай ук шәһәр йогынтысыдыр инде, Гомәрнең һичберәүдә булмаган ау мылтыгы да бар иде.

...Әфтах менә шуларга керә, өйдә Гомәр ялгыз үзе генә була, һәм... бераздан Гомәр кулында әлеге ау мылтыгы атылып китә. Тугыз ядрә Әфтахның йөрәге аша үтә — кайберләрен соңрак аның аркасыннан ярып та алалар. Әфтах берничә минуттан җан да бирә... Әнә шундый фаҗигале, мәгънәсез үлем!..

Игътибар иткәнсездер, мин, мылтык Гомәр кулында атыла, дидем, ягъни ул Әфтахны үтерү максаты белән юри төзәп атмаган. Соңыннан суд та аңа мондый гаепне тага алмаган. Һәм Гомәрнең юри үтерү максаты белән атуына ышануы да бик читен, чөнки моның өчен аңарда Әфтахка карата ниндидер зур дошманлык, үч алу теләге булырга тиеш. Ләкин мондый дошманлыкны берәү дә белми, берәү дә сизмәгән — хәтта Әфтахның иң якын дуслары да. Кыскасы, мылтык Гомәр кулында ялгыш атылган (әлбәттә, саксызлык аркасында дип уйларга кирәк) — тикшерү вакытында Гомәр бары тик әнә шулай аңлаткан... Әйткәнемчә, алар өйдә икәү генә булганнар, әмма ничек булганын сөйләүчесе бер генә!

Дәүләкәннең беренче комсомолын бик зурлап җирләгәннәр. Бөтен яшьләр, бөтен мәктәп укучылары озата барган, митинг булган, бәхилләшү сүзләре әйткәннәр. Зөфәр әйтә: Әфтахны күмгән чактагы шикелле минем гомеремдә алай җылаганым булмады, ди.

Мин бу вакытта Казанда идем инде. Бу фаҗигале вакыйганы үз күзем белән күрмәдем. Тик күп еллардан соң моның барысын да миңа Зөфәр сөйләде. Ул иң элек кан эчендә яткан Әфтах янына барып җиткән, мылтык атылудан башка һәммәсен ул күргән, ул белгән — менә мин дә Әфтах һәлакәтен нәкъ аңардан ишеткәнемчә язып чыктым.

Хәзер икенче бер язмышны да искә төшерик. Әлеге Мерәс җыенында очрап, безгә ияреп йөргән, Әфтахка укыйсы килүе турында борчылып сөйләгән киез эшләпәле, оек-чабаталы башкорт егетен шул ук елның көзендә Казан урамында очраттык. Ул солдат киемендә иде. Баксаң, аны армиягә алган булганнар һәм хезмәт итүе дә, бәхетеннән диик, Казанга туры килгән. Егеттә уку дәрте чынлап та бик көчле булган икән. Армиядән бушагач та ул башта рабфакка керә, аны бетергәч, Казан университетында укый, аны да бетергәч, аспирантурада кала — шулай итеп, сәләте һәм тырышлыгы аркасында бу мәһабәт, таза башкортым үсә-үсә фән докторы дигән дәрәҗәгә дә ирешә. Махсус белеме буенча геолог ул, Татарстанда нефть ятмалары табуда күп эшләгән галим. Озак еллар Казанда торган иде, хәзер Уфага күчкән дип ишеттем... Мин

һаман аның исемен әйтмичә килдем. Инде ярый да торгандыр: ул — Билал Юсупов. Нефть чыгаручылар аны яхшы белергә тиеш.

...Ике язмыш! Алар нәкъ бертөсле булырга тиеш иде кебек. Ләкин берәүгә язды, берәүгә язмады! Язмыш үзенә күрә бер табышмак ул!..

— Укырга, укырга, укырга! — дигән Ленин бабай. Һәм бу ялкынлы өндәү татар, башкорт яшьләренең дә колагына кергән иде. Егерме бишенче еллардан башлап, бигрәк тә татар яшьләре арасыннан, читкә укырга китүчеләр күбәйде. Озакламый бу үзенә күрә бер хәрәкәт рәвешен алды. Авыл егетләре һәм кызлары Бәләбәй, Уфа, хәтта Казан белән Мәскәүгә таба да юл сала башладылар.

Миндә дә шул ук теләк, шул ук кайгы... Әмма бу кайгы бары укыйсы килү белән генә чикләнмәгән иде. Әйткәнемчә, яшьтән үк әдәбият уку, соңгы вакытта газета-журналларны карап бару һәм үземнән олырак яшьләр белән аралашу нәтиҗәсендә минем күңел күзем шактый ук ачылган иде. Мин инде сизәм: дөнья үзгәрәчәк. Миңа үз юлымны табарга кирәк һәм соңга калмыйча!.. Әгәр Дәүләкәндә торып калсам, мин югалырмын, мин беркем дә була алмам — менә шундый бер эчке сизенү минем җанымны гел борчый да тора. Тыштан гамьсез йөрсәм дә, уйнасам-көлсәм дә, мин тыныч түгел, мин һаман уйланам... Билгеле, гел киту турында, каядыр китәргә кирәк, тик Дәүләкәндә генә калмаска!.. Әлбәттә, минем өчен иң якыны, иң уңае Уфа иде. Анда җизниләр тора, җизни зур урында эшли (Шәриф Сүнчәләй Башкортстан гыйльми мәркәзенең рәисе иде) — аларга барып сыенырга, алар ярдәме белән берәр җиргә укырга да кереп булыр иде... Һәм шушы өмет белән җәй уртасында ниндидер сылтау табып, Уфага барып та кайттым. Ләкин баргач күрдем (хәер, электән дә беләидем), алар Рокыя тутакайның өч ятим баласын укыталар, Каргалыдан Зөләйха да килергә тиеш икән, шулар өстенә мин дә килсәм, бу бик күпкә китәчәк, килешмәячәк — мин менә шуны аңладым. Әлбәттә, теләгемне әйткән булсам, алар тарафыннан, бәлки, бертөрле ярдәм дә булыр иде, ләкин әйтеп, белдереп тормадым инде... Мин әле аларга әйтмичә генә үземә эш тә эзләп карадым, бер-ике учреждениенең коридорына да кереп чыктым, әмма юкка гына вакыт әрәм итеп, каңгырап йөрү иде бу... Әйләндем-тулгандым да тизрәк Дәүләкәнемә кайтып киттем.

...Һәм кайтсам, минем алдымда һич көтелмәгән икенче бер юл ачылырга тора, имеш!.. Эш шунда ки, мин

Казаннан Татарстан гәзитәсен алдыра идем. (Җае чыккач шуны да әйтим: ул заманда татар газета-журналларына, кайда гына алар чыксалар да, һичберничди тоткарсыз язылып була иде.) Билгеле инде, Казанның үзеннән килгән газетаны мин башыннан ахырына чаклы бик җентекләп карап чыга идем. Бу юлы да Уфадан кайтуыма килеп торган газеталарны дикъкать белән күзәтеп чыктым. Шул чакта берсенең соңгы битендә басылган игъланга күзем төште. Укыйм, яхшырак төшенер өчен икенче тапкыр да укыйм — хуш, нәрсә бу?.. Казанда рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыймарәтчелек мастерскойлары бар икән. Игъланда менә шушы мастерскойларга укырга керү шартлары басылган. Ягъни мәсәлән, бу мастерскойлар имтихан биреп кергән яшьләрне йә рәссам, йә һәйкәлтараш, йә гыймарәтче итеп чыгарачак икән. Татар яшьләрен махсус менә шунда укырга чакыралар! (Ул мастерскойлар русча Архумас дип атала иде.)

Бу игълан мине бердән канатландырып җибәрде, бөтен уем бары шуңа тупланды: рәссамның кем икәнен мин беләм, һәйкәлтарашын бик үк белеп бетермәсәм дә, чамаладым — һәйкәл ясаучы булырга тиеш, ә гыймарәтчелекне лөгатьтән[1] карарга туры килде, анысы — архитектура, имеш, ягъни матур биналар салдыручы. Нинди шәп, нинди гүзәл һәм мактаулы һөнәр иясе булырга мөмкин икән ләбаса! Шартларына караганда, анда керер өчен минем белем җитәргә дә тиеш кебек.

Кыскасы, бу игълан мине тәмам хыялыйга сабыштырды, мин инде башка бернәрсә турында да уйлый алмый башладым. Ятсам да, торсам да минем уемда бары Казан, бары шундагы мастерскойлар, бары шуларда укып һәйкәлтарашмы, гыймарәтчеме булу хыялы! (Рәссам булырга күзем җитми, чөнки рәсемне бик начар ясый идем.) Ә күңелгә бер кереп утырган уйдан котылу мөмкин түгел — димәк, китәргә, һичнигә карамыйча китәргә, китәргә!

Әмма минем юлымда гаять зур киртә бар: атам-анамның ризалыгын алырга тиешмен. Бу ансат булмаячак, ялгызым гына Казанга чыгып китү өчен ризалык алу — юк, бу бик авыр булачак... Ләкин мин тәвәккәлләргә тиеш, вакыт аз, сузарга ярамый, ашыгырга, ашыгырга кирәк! Берничә көн бәрелеп-сугылып йөрдем дә ахырда туп-туры әйттем үзләренә: Казанда менә шундый уку йорты бар, ул менә шундый кешеләр укытып чыгара, мин менә

---

[1] *Лөгать* — сүзлек.— *Ә.Е.*

шунда китәргә булдым, дидем. Билгеле, алар минем «һәйкәлтарашларымны» тамчы да аңламадылар. Инәй шунда ук ике кулын селтәп: «Ни сөйлисең, балам, куй, җүләрләнә күрмә, беркая да җибәрмим!» — диде һәм яшьләрен тыя алмыйча җылый ук башлады. Атакай исә ашыгып каршы төшмәде, ул шактый ук уйга калды. Әлбәттә, ул укуның кирәклеген белә, укуга каршы да түгел, әмма Казан хәтле җиргә барып кергән мәктәбем нәрсә ул, нәрсәгә укыталар анда, рәтле кеше чыгачакмы аннан — менә нинди уйлар аны борчый иде булса кирәк. Бу хакта сүз күп булды, көн дә диярлек миңа үзем дә юньләп белмәгәнне аларга тотлыга-тотлыга аңлатырга, төшендерергә, еш кына кызып китәргә, җылап та алырга туры килде. (Духтырлыкка яки агрономлыкка укыйм дисәм, билгеле, бик тиз аңларлар иде.) Ләкин иң төп авырлык бу түгел иде, иң төп авырлык минем «ике бөртек»нең берсе булуымда иде. Ничек итеп шундый газиз балаңны җаныңнан аерып, әллә кайдагы зур калага җибәрмәк кирәк, китәр дә югалыр, эзен дә таба алмассың, Ходай үзе саклый күрсен!.. Бигрәк тә инәйнең бөтен курыкканы, гел әйтеп торганы әнә шул иде. Ә менә атакайны минем еракка китүем ул хәтле куркытмый иде, чөнки ул үзе күп йөргән, күп җирләрне күргән кеше. Тик яшең бәләкәйрәк, улым, ди ул миңа, берәр ел сабыр иткәндә яхшырак булмасмы, ди. Ләкин инде мин сүз-киңәш тыңлаудан узган идем. Һичнигә карамыйча, китүне өзлексез таләп итүем, өзгәләнүем, бәргәләнүем ахырда аларның каршылыгын сындырды. Ниһаять, атакай соңгы сүзен әйтте: «Ярый, улым, бар, бәхетеңне сынап кара!» — диде. Тик шулай да бер шарт белән: мин үземә ышанычлы бер юлдаш табарга тиешмен. Аңлыйм инде, аңлыйм шартларын — куркалар, бичаралар, ялгызымны гына чыгарып җибәрергә!..

Минем шатлыгым, әлбәттә, эчемә сыймый иде, мин инде Казанны күрмәс борын ук бәхетле идем. Ә юлдаш (иптәш) мәсьәләсенә килгәндә атайлар бик дөрес әйтәләр — юлдашсыз ярыймы соң?! Юл ерак, Казан — күрмәгән шәһәр булганга күрә генә түгел, ә яшь чакта без, гомумән, иптәшсез бер көн тора да, беркая бара да алмый идек. (Хәзер генә ул ялгызлыкка өйрәндек.) Кыскасы, иптәш кирәк. Тик менә кемгә әйтергә, кемне күндереп булыр икән?.. Барлык дусларымны берәм-берәм күздән кичерәм — бу зур эштә бит дус малайның үз теләге генә җитми, бигрәк тә ата-анасы риза булырмы — менә хикмәт нәрсәдә!.. Мәсьәләнең иң элек шушы ягын уйлап, мин башта Сафиулла абзый малае Габделбарыйга әйтеп ка-

рарга булдым. Сафый абзый ул балаларына белем бирүне бик хуп күргән кеше, кызы Рәкыя апаны да революциягә хәтле үк рус гимназиясенә биргән иде, малайларын да иске мәдрәсәгә йөртмичә бары совет мәктәбендә генә укытты. Барый үзе дә безнең арада иң тырышып укучы иде, киләчәктә дә ул барыбер кая да булса укырга китәчәк.

...Мин аңа, үземчә бик мавыктыргыч итеп, газетадагы игълан турында сөйләдем. Беләсеңме, Казан бит ул, дидем, теләсәң рәссам, теләсәң һәйкәлтараш яки гыйммарәтче (архитектор) булырга мөмкин, дидем. Түп-түгәрәк битле, кап-кара Барыем мине елмаеп кына тыңлады. Елмаюдан кысылып бетә язган күзләренә карап, аның әллә чынлап, әллә юри генә тыңлавын белеп тә булмый иде. Мин сөйләп беткәч, ышанмагандай сорап куйды:

— Ә сине җибәрәләрме соң?

— Шту син! — дидем мин, гаҗәпләнгән булып.— Берсүзсез җибәрәләр. Шуңа күрә сине чакырам да.

— Ярый, мин дә әткәйләргә әйтеп карармын,— диде Барыем, ничектер сүлпән генә.

Әнә шулай балаларча гына сөйләшеп алу булды безнең арада. Барый ни өчендер Казан турында да, мин мактаган уку турында да сорашып тормады, шуңадыр инде миндә аңа ышаныч та туа алмады. Һәм икенче көнне үк инде ул миңа: «Юк, малай, булмый, әткәйләр якын да килмиләр»,— диде.

— Сөйли белмәгәнсеңдер, ышандыра белмәгәнсеңдер,— дидем мин аңа, кинәт ачуым килеп.

— Ә нәрсәгә ышандырып торырга,— диде Барый, бер дә исе китмичә генә.— Тугызны бетергәч, мин, беләсеңме, духтырлыкка укырга китәм... Бәлки әле, шул ук Казанга!..

«Алай икән!» — дидем мин эчемнән генә һәм бер хакыйкатьне ничектер аңлагандай булдым: рәссам яки һәйкәлтараш булыр өчен генә уку берәүне дә артык кызыксындырмый да, тартмый да, күрәсең!.. Дәүләкән малайларына болар чынлап та бик ерак, бик ят нәрсәләр... Духтырлыкка яки агрономлыкка уку — бу икенче мәсьәлә, бу инде бик дәрәҗәле дә һәм бик кирәкле дә.

Әмма... кемне дә булса табасы иде бит, шайтан алгыры! Бик мөһим ич бу минем өчен — табылмаса, минекеләр дә йә сүрелә башларлар... Тик кемгә барып төртелергә, кемне генә котыртып карарга?! Габдрахманнымы? — Юк, ярамый, кирәкми, үзе теләсә дә — чөнки ышанычлы иптәш түгел... Таһирны да котыртып булмаячак, үзенең шушындагы туфрагына бик нык тамыр җибәргән малай, кышларын атасына ияреп бүре сугарга йөри,

җәйләрен тирә-як җыеннарны калдырмыйча кола айгырларын чабышка йөртә, аннары кунак ярата, туй ярата, аулак өйләрне ярата. Менә шунда ул, бәлки, үзеннән берәр «һәйкәл» ясап та калдырыр... Дөрес, минем Мәхмүт дустым бар, ул минем белән Казанга түгел, җир читенә китәр иде, әмма ләкин атасының каты кулларыннан ычкына алмаячак. Итче Галинең нинди кеше икәнен мин сезгә сөйләгән идем инде.

Әнә шулай кемгә тукталырга белмичә, күңелдән эзләп, сайланып йөри торгач, мин кайгымны Фәтхелисламга әйтеп карарга булдым. (Сез беләсез, соңгы вакытларда без аның белән шактый якынаеп киткән идек.) Әлбәттә, аны кузгатып булыр дигән өмет белән түгел, чөнки Фәтхелисламның шушы яшенә җитеп, Дәүләкәннән беркая да аяк атлап чыкканы юк. (Аргы яктагы Көрмәнкәйдә дә булганы бар микән әле?) Икенчедән, фәкыйрьлекләре бик көчле, Казанга хәтле чыгып китәргә кайда аның акчасы да, кайда кием-салымы?! Аннары бит ул монда инәсен карарга, энесенә дә ярдәм итәргә тиеш. Дөрес, укырга бик сәләтле егет, күрше-тирәгә пима төпли-төпли булса да Дәүләкәннең тугыз еллыгын бетерер инде, иллә мәгәр читкә китеп укулар аңа, ай-һай, насыйп булыр микән?!

Шулай да мин аңа бер керүемдә аптыраганнан гына Казанга китү мәсьәләсен әйттем, иптәш юклыктан зарландым, менә синең белән киткәндә нинди шәп булыр иде, дип тә өстәдем. Ул моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, бары: «Кая, миңа да китереп күрсәт әле шул игъланыңны!» — диде.

Шул ук көнне мин аңа газетаны китереп тә күрсәттем. Бик җентекләп укыды да тагын бер сүз әйтмичә кире үземә бирде. «Йә, ничек соң?» — дидем мин, сабырсызланып. «Әйбәт, ләкин синең өчен түгел»,— диде ул. «Нишләп?» «Рәссам булыр өчен зур кабилият[1] кирәк!»

Аңардан моны ишеткәч, мин кинәт аптырап калдым.

— Туктале, Фәтхелислам! — дидем, ашыгып.— Анда бит әнә гыймарәтче булырга да укыталар... Кем ул гыймарәтче?

— Ну... зур йортлар, матур биналар салдыручы... Русча әйтсәк, архитектор.

— Әһә, үзең дә беләсең икән!.. Нигә әнә шуңа укымаска?.. Мин, мәсәлән, шул бүлегенә керергә дип барам да.

— Иң әйбәте шунысы инде аның,— диде Фәтхелислам, ниһаять, уйланып кына.— Мине дә бик кызыксындыра анысы... архитекторлыкка уку!..

[1] *Кабилият* — сәләт.— *Ә.Е.*

Миңа җитә калды аның бу сүзләре... Бернинди өметем булмаса да, мин аны бик нык кыстый башладым. Төрлечә — мавыктырып та, мактап та, хәтта ялварып та... Ләкин ул сүзен әйтергә ашыкмады — отказ да юк, ризалык та юк, бары «уйлармын» дип кенә куйды. (Гүя миннән котылыр өчен генә!)

Әлбәттә, аңа тәвәккәлләве бик читен — мин моны күреп торам. Ләкин бит миңа да көтүе ансат түгел, август аена кердек, китәргә булганда, ашыгырга кирәк, хәзерләнергә!.. Мин инде бүтән егетләргә әйтеп тә тормадым, көн дә ут капкандай тотам да Фәтхелислам янына йөгерәм... Булса, аның белән бергә, булмаса — үзем генә! Һәм менә ахырда Фәтхелислам тыныч кына минем белән Казанга... барырга риза булуын белдерде. «Йа Алла!» дидем мин, бер җиңел сулап. Җилкәмнән әйтерсең Ярыш тавы төште!..

Хәер, Фәтхелисламның бу кыю адымын мин бары үземә генә кайтарып калдырсам, өстемә артык зур җаваплылык алу булмасмы икән?.. Аның бит үз акылы бар, ул үзе барысын да уйлаган, исәпләгән булырга тиеш. Әмма шулай да кыю адымның сәбәпчесе мин булдым, мин аны урыныннан кузгаттым... Аның киләчәк язмышында моның шактый зур әһәмияте булачак әле — сез дә бер күрерсез!

Ярый, бусы булды, инде тизрәк юлга әзерләнергә кирәк. Үзем ашыгам, Фәтхелисламны да сакланып кына ашыктырам. Бездә дә моңаебрак булса да әзерлек бара. Атакай бер җиңел генә ак кәрзингә бик һәм йозак куеп бирде. Инәй шул кәрзингә юып киптергән, сырлы бәләк белән тәгәрәткән күлмәк-ыштаннарымны, бер-ике өске күлмәгемне, тастымал, оекбаш, кулъяулык кебек әйберләремне әйбәтләп салып куйды. (Кышкы киемнәрне, әгәр Казанда калырга туры килсә, соңыннан посылка итеп җибәрергә булдылар.) Китәр көн җиткәч, инәй юлга күп кенә итеп ит кыздырды, бер тавык та пешерде, бер бөтен икмәк, май, күкәй кебек азыкларны да кичтән әзерләп, шуларның барысын да аерым бер кечерәк бөрмәле капчыкка тутырды. Атакай кулыма ун сум акча бирде. Бу, әлбәттә, аз, бик аз, ләкин мине, артыңнан тагын җибәрербез, дип юаттылар. Акча белән бергә атакай Казан доктcorrectоры Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегулов исеменә язган хатын да миңа тоттырды... Казан халкына бик билгеле, соңыннан профессор булып танылган Әбүбәкер абзый Терегулов безнең Каргалыдан чыккан кеше, атакай аны яхшы белә икән — белү генә түгел, кайчандыр аңа ниндидер ярдәме дә тигән... Без менә шушы хат белән Әбүбә-

кер абзыйларга барып керергә тиешбез. Бүтән безнең барып төртелер урыныбыз да, кешебез дә Казанда юк.

...Тәгаен китәсе көнебезне минем дус-ишләргә артык белдерәсем килмәде. Шаулап озатырлар, ә кире әйләнеп кайтырга туры килсә? — Юк, кирәкми, белми калулары яхшырак. Әмма күрше Борһан абзыйларга кереп чыгудан тыела алмадым. Бигрәк тә Һаҗәр өчен... Соңгы тапкыр күрәсем, күрешәсем һәм нәрсә әйтеп калыр икән дип беләсем килде. Кичкырын гына кердем. Зәкәрия, Яхъя, Хава, Хәким — алар бик ишле бит... Барысы да шаулашып, мине сырып алдылар. Барысы белән дә саубуллаштым, ләкин алар арасында Һаҗәр юк иде. Ул өй эченнән — ачык тәрәзәдән безнең тамашага карап тора иде. Беләм, чыкмаячак һәм яныма килмәячәк. Мин үзем ачык тәрәзәгә бардым, «Иртәгә мин китәм инде»,— дидем, кулымны суздым. Ул да кулын бирде, ул да: «Хушыгыз!» — диде һәм шуның белән саубуллашу бетте. Мин чыгып киттем... Йөрәктән суырып кына ташлыйсы иде дә бит, булмый гына лабаса, Ходаем!.. Ярый, зур сәфәргә чыгар алдыннан күңелне болай төшермик әле — миңа язган бәхетләр дә, бәлки, табылыр әле, табылыр...

...Менә китәсе көнебезнең кояшлы иртәсе — бу августның әллә җидесе, әллә сигезе иде. Иртә генә тордык, иртә генә чәйне дә эчтек. Барыбыз да уйчан, инәй, бичара, боек, әйтер сүзләр дә беткән кебек. Тик энем Илдархан гына гамьсез, бернинди күңелсезләнү юк, хәтта китүемә үзенчә куана да иде бугай. Әйтерсең агасының Казан хәтле Казанга китүе малайлар алдында аның да дәрәҗәсен күтәрәчәк! Минем өйдә утырасым килми, тиз генә Фәтхелисламга барып килдем — хәзерләнеп ята, станциягә бер вакытта чыгарга булдык... Соңгы тапкыр ишегалдын әйләндем, соңгы тапкыр коебызның салкын суын эчеп карадым...

Без өйдән күтәренеп чыкканда, каршы яктан Фәтхелислам да үзе ясаган тоткалы әрҗәсен күтәреп һәм инәсе белән энесен ияртеп, безгә таба киләләр иде. Бергә кушылып, ишле бер төркем булып Холодный тыкрыгы буйлап тимер юлга таба атладык. Безнең бит юлыбыз башта поезд белән Уфага, аннан инде пароход белән Казанның үзенә, боерган булса!

Вокзалга кайбер иптәшләр дә озата чыкканнар иде, алар үзләренең көлү-шаяртулары белән безнең хәлне бераз җиңеләйттеләр. Югыйсә аерылышу минутлары күңелсез-авыр, ничектер киеренке-ясалма була башлый... Инәйләрнең йөзләрендә хәсрәт, күзләрендә яшь, әйтер сүзләре әллә беткән, әллә төер булып утырган, ә без, ки-

түчеләр, аларның хәлен җиңеләйтер өчен берни дә эшли алмыйбыз. Таптанып торабыз, як-якка каранабыз, берәрсенең юк кына сүзеннән дә, тай кешнәгәндәй, кинәт кенә көлгән булабыз. Ярый әле болай интегеп тору озакка бармады. Әнә элеватор ягыннан килеп чыккан поездның кара паровозы күренде. Атакай безгә билетларны алып, китереп биргән иде инде. Пассажир поезды монда икеөч минут кына тора. Килеп туктавына без барысы белән дә ашык-пошык саубуллаштык, инәйләр тавышсыз гына җылаша башладылар... Әйберләрне тиз генә эләктереп, вагоныбызга йөгердек. Юри ашыкмый торган проводник билетларны караганчы да без кереп урнашканчы поездыбыз инде кузгалды да... Бәй, киттек тәмени?! Тизрәк ачык тәрәзәдән сузылсак, әнә вокзал бинасы да, кызыл фуражкалы станция начальнигы да, бер җирдә өелешеп, селкенмичә безгә карап торучы якыннарыбыз да әкрен генә артка йөзгәндәй ераклаша баралар. Без аларга кул болгыйбыз, ә инәйләр күзләренә җәелгән яшьләре аша безне, бәлки, күрми дә торганнардыр... Поезд кызулый... станциянең озын, сары пакгаузларын узабыз, менә биш катлы «Труд» тегермәнен дә үттек, тимер юлга якын йортларның түбәләрен соңгы тапкыр күреп калдык. Озакламый поездыбыз казылма чокырга керде һәм Дәүләкәнебез күздән дә югалды... Без киттек, бер минут саен ераклашабыз. Ләкин бу минутларда ниләр уйлап, нилэр кичерүебезне мин аңлата алмыйм. Гомумән, җитди уйлар килде микән безнең таркау башларга?! Үзара сөйләшмибез, ачык тәрәзәдән яшел кырларга тик кенә карап барабыз. Әмма ләкин, уйлый белмәсәк тә, ниндидер бер әчке сизенү кичерә идек шикелле... Күңелнең бу сизенүе ике капма-каршы тойгыдан, ягъни бүгенге аерылышу кайгысыннан һәм, ниһаять, китә алу куанычыннан туган иде булса кирәк. Шуңадыр инде безгә бер үк вакытта ямансу да һәм ничектер җиңел дә кебек иде.

...Поездыбыз такылдап, селкенеп бара да бара. Дәүләкән каршындагы ялгыз, мәһабәт Ярыш тавы да бездән әкренләп ераклаша, тик киң тугайлар уртасыннан борғаланып аккан Дим генә бездән калышмый — аның юлы да биек Уфа тауларына чаклы... Разъезд саен туктыйтуктый барган поезд безне Уфага бер өч сәгатьтән генә илтеп җиткерәчәк... Һәм менә кузгалып китүебезгә күпме генә вакыт үткәндер инде, безгә беренче юл газабын да татырга туры килде. Әйтсәм, кеше ышанмас, һич уйламаган-көтмәгәндә нәрсәдәндер кинәт Фәтхелисламның бизгәге кузгалды. Аның бизгәге барын белә идем, ләкин авырып ятканын күргәнем юк иде, шактый ук

әшәке бер нәрсә икән ул!.. Фәтхелислам, бичара, дер-дер калтырый, теше-тешкә тими, үзе көлдәй кум-күк булды. Өстәге сәндерәгә менеп, капчыгын баш астына салып, бөгәрләнеп ятты... Йә, кирәк бит, үч иткәндәй, юлга чыккач кына!.. Мин, билгеле, бик борчылдым, нишләргә дә белмим, Уфадан кире борылмаса ярар иде дип курка да башладым. Чишмәгә җиткәч, вокзалдан аңа бер кружка кайнар су китереп бирдем. Ул шуны ике учына алып, тешләренә тидерә-тидерә, йотымлап кына эчте. Рәхмәт әйтеп, кружканы кире бирде. Бераздан калтырануы басылгандай булды һәм йокыга киткәндәй тынып калды.

Сәгать өчләр тирәсендә Уфага килеп җиттек. Вагоннан төштек, зур бина аша вокзал мәйданына чыктык. Каршыбызда Уфаның галәмәт биек тавы басып тора — менә шул тауга менәргә кирәк. Ул елларда шәһәргә менәр өчен извозчиклардан башка бер төрле дә транспорт юк иде. Акчаң булса, извозчикка утырасың, булмаса — җәяүләп кенә менеп китәсең. Ләкин хәзер извозчикка утыру — безнең өчен һич тә көтелмәгән расход. Нишләргә икән дип башымны кашыйм мин, ә Фәтхелислам әйтә, давай җәяү генә меник, ди. Менә алырсыңмы соң?.. Менәм, ди. Ярый, мин әйтәм, киттек алайса! Безнең бит, ни дисәң дә яшь чак, көчле чак, безнең кебекләр, гомумән, извозчикка утырмыйлар. Әнә барысы да кырмыскалар шикелле әкрен генә тауга үрмәлиләр... Без дә әйберләребезне ипләп кенә тоттык та җәяүлеләр сукмагыннан ашыкмыйча гына күтәрелә башладык.

...Дәүләкәндә чакта еш кына:

Уфа таулары биек,
Йөри арыслан-киек.
Су сипмәгән гөлләр кебек,
Йөрибез яныл-көеп,—

дип җырлый торган идек. Менә безгә дә августның бүгенге яман эссе көнендә шушы тауның җәфасын шактый ук татырга туры килде. Чынлап та биек икән шул, каһәр!..

Менеп җитеп аз гына хәл алгач, тагын кузгалып киттек. Бер борылыштан соң центральный (хәзерге Ленин) урамының очына барып кердек. Уфаны бөтен аркылысына кисеп узган шушы иң озын, иң туры, иң шәп урам буйлап без аның икенче очына чаклы барырга тиешбез. Аннан инде җизниләр торган Садовый урамына да ерак калмый. Шундагы 3 нче номерлы бер катлы зур гына таш йортка безнең юлыбыз... Бу йортны тарихи бер йорт дияргә дә була. Җизниләр торган елларда, ләкин төрле вакыттарак анда Сәгыйть Сүнчәләй дә, газета редакторы Муса Юсупов та, тел галиме Вәли агай Хангильдин дә

торып киткәннәр. Мәҗит агай Гафури да еш кына килә торган булган. Зур гына бакчалы, верандалы, сигезметугызмы бүлмәле иркен-тоташ бер йорт иде заманында (хәзер дә әле саклана ул йорт, ләкин аны вак кына квартираларга бүлеп бетергәннәр). Соңыннан минем үземә дә күп булырга туры килде бу йортта.

Бүген исә әлсерәп барып җиткәч, башта үзем генә керергә булдым. Ничектер капчыклар, кәрзиннәр күтәреп, капыл гына икәү барып керүне яхшысынмадым. Йорт иркен булса да, торучылары да аз түгел, аннары монда бөтенесенә Срур тутакай хуҗа, ә ул хөрлеккә, бәйсезлеккә өйрәнгән горур хатын — ничек кабул итәр бит әле безне? Мине күргәч тә, ул:

— Бәй, кайдан килеп чыктың әле син болай? — дип, гаҗәпләнүен яшермичә каршы алды. (Күптән түгел миңа бер килеп китәргә туры килгән иде бит инде.) Мин аңа Дәүләкәннән Казанга барырга дип бер иптәшем белән юлга чыгуыбызны, ләкин иптәшемнең поездга утыргач кына кинәт авырып китүен аңлатырга тырыштым.

— Нинди авыру ул тагын? — дип сорады Срур тутакай, җәһәт кенә.

— Бизгәге кузгалды.

— Бизгәк кенәме? Эч авыруы була күрмәсен! Шушындый эсседә. Ә кайда соң ул иптәшең?

— Капка төбендә калды әле,— дидем мин, уңайсызланып кына.

«Йөрисез шунда, җәфалар!» — дигәндәй, тамак кырып куйды Срур тутакай, аннары миңа, коры гына:

— Алып килгәч инде, урамда калдырмыйлар, туганым! — диде.— Бар, чакыр, урын табарбыз!..

Әлбәттә, башта ук мин бу йортта безне кабул итәчәкләрен белеп килгән идем, ләкин бит безнең ише «саладан килүчеләр»дә, гадәттә, тыйнаклык дигән нәрсә кирәгеннән артыграк була... Ярый, бигайбә, тизрәк чыктым да әйберләрне күтәреп, Фәтхелисламны ияртеп кердем. Безне зур кухня янәшәсендәге кечкенә, караңгырак бер бүлмәгә урнаштырдылар... Монда салкынчарак та иде. Тыштагы кызудан соң безгә бер мәлгә рәхәт тә булып китте. Ләкин бераздан Фәтхелисламны тагын калтырата башлады. Бүлмәдә җыештырып куйган тимер карават тора иде — мин Фәтхелисламга чишенеп шунда ятарга куштым. Ул, ботинкаларын гына салып, юка одеял астына кереп ятты. Мин өстенә кыска сырмасын да капладым.

Бу йортта ике изге җан бар — берсе аның Рокыя тутакай (атакайның бертуган сеңлесе, ә Срур тутакайның апасы була), икенчесе — җизнинең әнисе Һаҗәр

әби. Рокыя тутакай шушы йортның бөтен йөген тартучы, бик кече күңелле, миһербанлы хатын — ул шунда ук Фәтхелисламга сөт тә кайнатып кертте, өстенә тагын бер чиста одеял да бирде. Һаҗәр әби исә ниндидер дарулар, үләннәр китерде, үзенең бәрхеттәй йомшак тавышы белән ашыкмыйча гына егетнең хәлен сорашты, аннары тәҗрибәле карчык буларак үзенчә дәвалый да башлады. Фәтхелисламның хәле күпмедер вакыттан соң чынлап та җиңеләйде, дер-дер калтырануы бетте-басылды, температурасы да төште булса кирәк. Дөрес, иптәшем шактый ук йомшап, хәлсезләнеп калды, ләкин яңадан бу зәхмәте кузгалмаса, безгә иртәгәдән ничек тә чыгып китәргә кирәк.

Кичкырын, җизни дә эштән кайткач, мин алар янына чыктым. Верандага караган иркен бүлмәдә чәй табыны әзерләнгән иде. Ике якка киң итеп ачылган зур ишектән куе бакчаның төрле үлән, чәчәк, алма исләре белән бергә кызуы инде сүрелгән, кичке талгын һава да кереп тора. Әйбәт вакыт, күңелле вакыт. Әмма кайчан булган иде соң бу?.. Күптән, бик күптән шул инде... Чәй янында җизни белән Срур тутакай миннән ни өчен болай кинәт кенә Казанга барырга теләвемне сораштылар. Мин аларга теләгемне булдыра алган кадәр аңлаттым һәм яхшырак аңласыннар өчен теге газета игъланын да эчке кесәмнән чыгарып күрсәттем. Алар игъланны укыдылар, бераз уйланып тордылар, ләкин «юкка, туганым, кузгалгансың» дип әйтмәделәр. Мин әзрәк сизәм инде — аларны миннән рәссам яки һәйкалтараш чыгармы икән соң дигән шик борчый иде бугай. Әмма җизни дә, Срур тутакай да минем укырга омтылуымны, һичшиксез, хуплыйлар иде. Әгәр мин шушы теләп барган җиремә керә алсам, бу да бик әйбәт, бу да бик күркәм эш булачак, инде моның кебек махсус мәктәпкә керүе читен икән, Казанда уку йортлары бетмәгән, шуларның берәрсенә керергә тырыш, диделәр алар миңа сак кына. Иптәшем турында да сораштылар һәм ахырдан икебезгә дә максатларыбызга ирешүне теләделәр. Яхшы сүз — җан азыгы! Минем рух-дәрт бердән күтәрелеп киткән иде бу тын, җылы кичне туганнар белән бер табында утырганда.

...Икенче көнне без бик иртә генә торып, кухняда гына Рокыя тутакай әзерләгән чәйне эчеп, чыгып китәргә җыена башладык. Һаҗәр әбинең Фәтхелисламны кичтән дәвалап яткыруы бик шифалы булып чыкты — егетем иртән торганда яшь тәкә шикелле сау-сәламәт иде инде.

Без зур йорттагы халыкны тәмле йокыларыннан уятмыйча гына кузгалырга булган идек тә, ләкин барыбер белеп, Һаҗәр әби дә, ефәк халатын киеп кенә Срур тута-

кай да безне озатырга чыктылар. Рокыя тутакай кулыбызга зур гына төргәк — ниндидер ашамлыклар тоттырды. Срур тутакай миңа, «туганым» дия-дия, гадәтенчә, үзенең акыллы киңәшләрен бирде, аннары барысы да бергә хәерле юл теләп, ишек төбеннән озатып калдылар. Шулай итеп, без ике шәкерт, кәрзин-капчыкларыбызны күтәреп, бөтен шәһәр аша җәяүләп кенә пристаньга төшеп киттек.

Ниһаять, менә алдыбызда, түбәндә, безнең ак юлыбыз — Агыйдел! Гүя көтеп ята ул безне... Ирексездән тукталып, бер генә минут сихерләнгәндәй карап тордык та яңадан капыл гына кузгалып, түбән төшеп киттек. Аякларыбыз йөгертә генә безне ак юлыбызга таба!..

Ул заманда Уфа пристане бик кечкенә иде. Су өстендә пароходка охшаган бер корылма (ягъни дебаркадер) тора, ә яр өстендә бер төрле дә бина-мазар юк. Тик агым үрендә, бераз читтәрәк ниндидер озын лабазлар, алар каршында, өсте ачык баржалар гына күренә.

Китәргә дип төшкән халыкның күбесе яр буенда аунап яткан бүрәнәләр өстендә утыра... Мин дә Фәтхелисламны әйберләре белән шул бүрәнәләрнең берсенә утыртып калдырдым да, үзем халык арасында йөрештереп, пароходның кайчан китәсен, билетларның кайда сатыласын сораштым. Белгән агайлар, Казан пароходы монда, тик каядыр өстәрәк йөк төятә, диделәр. Билет сатыла торган урынны да тиз таптым — ул су өстендәге пароходка охшаган әлеге корылмада икән.

Менә шундый мөһим эшләр артыннан өтәләнеп йөри торгач һәм көтә торгач, безне алып китәсе ике катлы апак чибәр пароход салмак кына килеп, нәрсәләрнедер шыгырдатып, безне дә әкрен генә селкетеп, пристань корылмасына, ниһаять, терәлде. Касса да ачылды. Кысылыпсытылып дигәндәй, мин иң арзанлы дүртенче класска ике билет алдым. Фәтхелислам бөтен әйберләрне күтәреп минем янга төшкән иде инде. Тагын күпмедер зарыгып көткәннән соң, халыкны пароходка кертә башладылар. Халык дәррәү кузгалды. Ә без ашыкмыйча җайлабрак керергә тырыштык. Кергәч әле кая таба барырга белмичә, юл өстендә тукталып калдык. Беренче тапкыр утырабыз бит! Кемдер безгә ачуланып: «Әнә сулга, койрыкка!» — дип кычкырды. Һәм без караңгы тар аралыктан кемнәргәдер бәрелә-төртелә сулга таба киттек. Иң койрыкта икән без барасы класс!.. Берничә генә рәт аслы-өсле сәндерәләре дә бар икән, ләкин инде аларны алдан керүчеләр алып бетергәннәр иде. Капчыклы агайларның ни өчен ашыгуларын бары шунда гына аңладык. Ярый, хәерле булсын дидек тә хәзергә стена буена, идәнгә урнаштык.

Төш вакытларында пароходыбыз, ниһаять, эшен бетереп, башта ике тапкыр, аннары өч тапкыр өзеп-өзеп каты гына кычкыртканнан соң, бушап калган пристаньнан аерылып әкрен генә кузгалып китте. Мин тизрәк «койрык»ның иң арттагы ачык җиренә чыктым. Пароход аз гына үргәрәк менеп, киң генә дуга ясап борылды да елга уртасыннан түбәнгә таба юл алды. Киттек без, киттек! Хәерле сәгатьтә!.. Гаҗәеп рәхәт икән пароходта барулары — селкетми, сикертми, гүя аккоштай йөзеп кенә бара. Тик ике ягындагы зур тәгәрмәчләрнең агач калаклары суны салмак кына шапылдата, койрыгы артыннан бик озын булып киң эзе ярылып кала, ә як-якка тыгыз атластай йомры дулкыннары бер-бер артлы куышып ярларга таба китәләр... Болар барысы да минем өчен бик яңа, барысын да беренче күрүем. Әле Агыйделнең ярларына, әле Уфаның тауларына карыйм — кош оясыдай тауның нәкъ түбәсенә урнашкан яки озын чокыр араларына сылашкан йортлар әкрен генә артта кала бара, шәһәр кырыеннан ук тауларны каплап куе урман сузыла, урман эченнән манаралап эшләнгән ниндидер матур биналар сирәк кенә күренеп кала — хуш инде, җанга якын гүзәл калам!.. Ул заманда Агыйдел буйлап йөз километрга сузылган, көне-төне төтен дә ялкын бөркеп торган, иске Уфаның үзеннән дә зуррак дәвамы юк иде әле... Бөтен әтрафта шәһәрне чорнап алган, кеше таптамаган-бозмаган куе урманнар да сөрелмәгән-казылмаган чиксез киң болынлыклар иде.

Шушы манзарага карап бара-бара күпмедер хушлангач, мин юлдашым Фәтхелислам янына борылып кердем. (Ул бизгәгеннән куркып, кояшка чыгудан саклана иде.) Төш вакытлары узган иде инде, бик ачыктырган да иде — без идәнгә табын корып, ашап-эчеп алырга булдык. Газета җәйдек, стенага сөялеп, аякларны сузып утырдык, капчыктан ризыкларны чыгардык. Иң элек минем зур тавыкны ботарладык. Азык-төлегебез җитәрлек иде, кыздырган итебез дә бар, агач тустаган белән атланмай, бик күп йомырка (Фәтхелислам үзе генә дә ике дистә пешертеп алган), чәй, шикәр, ипи-күмәч — барысы да бар. Тавыкның калганын икенче көнне хәтта Агыйдел балыкларына да ташладык (кыздырылмаганга күрә исләнә башлаган иде)... Пароходның тагын бер рәхәт ягы — аның җиз борынлы зур бакларында өзлексез кайнаган су (кипәтүк) булып тора икән. Менә без дә кайнар кипәтүкне кружкаларыбызга агызып, бөртекле чәйне салып, әйбәтләп кенә чәй дә эчтек.

Хәзер бездә бер генә кайгы — ул да булса урын табу

мәсьәләсе. Пароход Казанга дүрт тәүлектән дә ким бармый, диделәр. Ләкин бу кадәр озын юлны гел идәндә аунап бару бер дә кызык түгел бит әле. Нишләргә? Әкренләп карана-сораша торгач, бернәрсә ачыкланды — монда баручыларның бик күбесе үзебезнең татар агайэнесе булып, алар шушы Агыйдел буендагы пристаньнарда төшеп тә бетәргә тиешләр икән. Болай булгач, сәндерәләр дә әкренләп бушарга тиештер инде. Тик безгә шуны бик «уяу» сакларга гына кирәк. (Соңрак белдек, Казанга хәтле баручылар әнә югарыда икән алар. Янә берише гади халык өченче класста.)

Беренче төнне стена буенда, башны башка терәп дигәндәй, утырып кына үткәрдек. Болай йоклар-йокламас баруның файдасы да тиде. Таң вакытларында пароходыбыз кайсыдыр пристаньга җитеп туктагач, Фәтхелислам балалы хатыннан бушаган бер сәндерәне эләктереп алырга өлгерде. Ә көн урталарында Бөрегә җитеп, шактый халык монда төшкәннән соң, миңа да бер өстәге сәндерә бушады. Хәзер инде түшәмгә карап, җырлыйҗырлый барырга да була. Юлыбыз озын, тагын өч тәүлек барасыбыз бар. Пароходның бөтен эче белән диярлек танышып чыктык, бары уртадагы ухылдап барган машиналар чокырына гына төшмәдек. Бер тапкыр югары катка да менгән идек тә, тик безне аннан бик тиз борып төшерделәр. Аз гына күреп калсак та, андагы чисталыкка, матурлыкка, яктылыкка, иркенлеккә исебез китте. Баручылары да бөтенләй башка шул — асылдан киенгән тутый коштай ханымнар, карлыгачтай нәфис туташлар, кыргычлап чистартылган көр алашадай тук ирләр... «Менә кайда икән ул бәхетле кешеләр!» — дип уйладык без... Хәер, чын бәхетнең нәрсә икәнен аңлаудан без әле бик ерак идек. Бәхетсезлекнең нәрсә икәнен беләбез, бу — ятимлек белән гариплек. Шулай уйлау безгә ничектер бала чактан ук кереп калган иде. Ә бәхет дигәнен безнең әле татып караганыбыз юк. Бу очракта исә кеше пароходның югары катында бара алса, матур киенсә, тәмле ашаса, үзе дә чибәр булса — шул инде безгә бәхетнең иң югары ноктасы булып тоелган. Хәлбуки соңыннан миңа Казан — Уфа арасын бик күп мәртәбәләр ак пароходның беренче класс каюталарында үтәргә туры килде, әмма моны мин бервакытта да чын бәхеттән саный алмадым. Бәхет ул минем өчен һаман җавапсыз табышмак булып кала бирде.

...Кайчагында югарыдан пианинода бик матур татарча уйнаганнары ишетелә. Мин шул тавышка якынрак барам. Бик өзә бәгырьне бу музыка, ихтимал, шул чакта

бәхет дигән бик кадерле, бик тансык нәрсә миңа якынайган шикелле дә булгандыр, әмма, музыка тынгач, тагын бушлык кайта, тагын шөбһә кайта, бәхетем гүя миннән ерагая.

Без күбрәк пароходның койрыгында барабыз — анда җылы, ышык. Фәтхелисламның бизгәге тәмам басылды шикелле, яңадан инде ул бүтән калтыранып ятмады. Бетүе шул була күрсен!..

Көне буе Агыйдел буйлап бардык. Бер дә үзеннән аерыласы килми. Бик яшел, бик якты, бик ягымлы ул... Бик бормаланып ага ул, бик тар урыннары бар, үрелсәң — озынрак колга да җитәр кебек кара ярына. «Сандугач богазы» дигән шундый бер бик тар урынны үттек. Ике ягында да биек куе тирәкләр... Таң вакытларында мондагы сандугачлар сайравыннан пароходта баручылар йокыларыннан уяналар икән... Гаҗәеп елга, күпме җырларга кермәгән дә, кемнәр генә аңа мәдхия язмаган!.. Мәктәптән үк күңелгә сеңгән шагыйрь сүзләре ирексездән телгә килә:

Идел буйларында киң болында
Җылкыларым утлый чабында,
Оҗмахларың торсын бер ягында,
Шул болында йөргән чагында.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ак пароходның зур тәгәрмәчләре тонык кына шаулап суны ишә дә ишә, без кара ярлар, яшел болыннар буйлап барабыз да барабыз... Икенче төнебезне шәрә сәндерәләрдә иркенләп сузылып ятып үткәрдек. Йокы монда гаҗәп тәмле икән, чөнки гаҗәеп саф, җиләсрәк су һавасы безне гүя йомшак кына сыйпап йоклата иде... Иртән торсак, манзара шактый үзгәргән — без Камага кергәнбез икән инде. Бу башкарак икән шул!.. Мәһабәт, көчле, киң елга. Ярлары да ерактарак, таулары да текәбиек, аның суы да кызгылт — күргән кешеләр, Агыйделнекеннән нык аерыла, диделәр. Әмма бу елганың үз тылсымы бар — ул күңелләрдә ниндидер бер зурлык, иркенлек хисе уята. Елга уртасында озын-озын комлы утраулар очрый, без хәтта утрау читләрендә озын-нечкә сыңар аякларына гына басып, йокымсырап торган соры торналарны да күреп уздык. Бозылмаган табигать, өркетелмәгән кошлар күпме гасырлардан бирле шулай сакланып килә, ахрысы... Гомумән, бу елгалар безнең җаныбызга һәм аңыбызга җырлар белән, әкиятләр белән, ниһаять, әдәбият белән кергән, шуңадыр, бәлки, беренче күрүдән үк шушы елгалар буенда бит инде безнең баба-

ларыбыз яшәгән, шушы бит инде безнең төп ватаныбыз дигән уймы, тойгымы күңелләрдә ничектер уянмыйча калмады.

Кама өсте җанлырак та иде. Әледән-әле безнекеннән дә зуррак ак пароходлар очрый, галәмәт зур баржаларны сөйрәгән җәенке-карсак пароходлар да очрый, буе берничә йөз метрга сузылган, өстенә кечкенә ак бура утыртып куелган салларны да узып китәбез. Пристаньнар да бу елгада күбрәк, икеме-өчме зур гына каланы да уздык. Пароход озаграк туктап торганда, без дә ярга чыгабыз. Монда чын базар, азык-төлектән җаның ни тели — барысы да бар. Күз кыза, әмма акча кызганыч. Шулай да бер урында ике стакан карлыган алдык, икенче тукталганда яңа пешкән күмәч белән кайнаган сөт алып кереп ашадык.

...Ниһаять, дүртенче тәүлекнең иртәсендә зур Иделгә кердек. Бу инде олы Идел, баш елга, тарихи елга! Ниләр генә күрмәгәндер ул үз гомерендә! Менә без барып җитәсе Казан да аның ярларында. Шушы үзе генә дә Казанны үстерә, аңа дан өсти кебек... Идел Камадан нык кына аерыла икән. Киңлеге белән, бәлки, бер чамадыр, әмма бөтен күренеше, әтрафы белән ничектер олы сыман, яктырак та, иркенрәк тә сыман. Аның суы да Каманыкыдай кызгылт-болганчык түгел, ә эретелгән кургашын төслерәк аксыл-коңгырт. Ярлары да төрлерәк, яшел хәтфә белән капланган зур йомры таулар бар, текә генә киселеп төшкән ак балчыклы ярлар бар. Бездән уң кулда исә күлләре, таллыклары белән җәйрәп яткан киң тугайлык, ә тугайлыкның аргы чиге буйлап тоташ куе урман сузылып бара.

...Күпмедер вакыттан соң пароходның югары катында хәрәкәт, шау-шу көчәйде... Казан күренә, диделәр. Без тизрәк пароходның алгы башындагы тар гына палубага уздык. Бөтен күзебез, дикъкатебез алда, елганың түрендә. Шулай җигелеп карый торгач, еракта, сыек рәшә аша зур каланың биек ак биналары, чиркәү гөмбәзләре күренә башлады. Менә шуңа, шул сихри-мәһабәт манзарага, әкрен-әкрен шактый озак якынлашабыз. Кала Иделдән күпмедер читтә булса кирәк — ике арада киң генә тугай барлыгы сизелә... Якынлаша барган саен Казан да ачыклана бара — чиркәүләр бик күп икән, алтын гөмбәзләре елык-елык нурда уйныйлар. Әнә, әнә калкулык өстендәге шул чиркәү гөмбәзләре уртасыннан кыртләчләнеп күтәрелгән нечкә-озын бер манара күренде. Без аны шунда ук таныдык: Сөембикә манарасы!.. Йөрәкләр аша гүя ниндидер бер дулкын йөгерде — ул сабырсыз-

ланып ешрак тибә башлады. Күзләргә дә нидәндер җылы томан пәрдәсе җәелгәндәй булды. Шунда ук Мәҗит Гафуриның шигъри юллары күңелгә килде (без аны мәктәптә хор белән җырлый торган идек):

Һәр бинадан биек улып күкләрә чыкмыш башың,
Мин беләм белдермәсәң дә: агадыр канлы яшең.

Әйе, Сөембикә манарасын беренче мәртәбә менә шулай ачык күрү безнең өчен, һичшиксез, дулкынландыргыч вакыйга иде — без әйтерсең ерак тарих түренә, халкыбызның үткән язмышына күз салгандай булдык.

Кала зур, кала мәһабәт иде. Читләрендә озын-озын завод торбалары да күренә — болар инде калага ниндидер бер көч-куәт биреп торалар кебек иде. Без, зур өметләр белән килүче ике шәкерт, Татарстан Социал Шуралар Җөмһүриятенең башкаласына якынлашабыз...

Пароходыбыз килә-килә, ахырда Усиягә җитеп, яр буендагы дебаркадерларның берсенә әкрен генә терәлеп туктады. Басманы сузгач, озын юлдан арган, талчыккан халык ашыкмыйча гына агылып чыга башлады. Без дә, бушап калган капчыкларыбызны иңебезгә элеп, шул агымга иярдек. Ярга чыктык һәм менә, ниһаять, Казан туфрагына аяк бастык.

# ТАШ КАЛАДА

Казан каласы — таш кала,
Күп калага баш кала.

*Борынгы җырдан*

Шулай итеп без, ике Дәүләкән егете, яңа гына пароходтан төшеп, Казан туфрагында басып торабыз. Ашыкмыйча гына тирә-ягыбызга каранабыз, кая табарак китәргә кирәклеген чамаларга тырышабыз... Һәм, әйтергә кирәк, татар каласына аяк басуыбызны без инде беренче күзебезгә ташланган күренешләрдән, кешеләрдән, хәтта бу җирнең һавасыннан ук тойган шикелле дә булдык. Килеп төшкән җиребез «Усия» дип атала икән — бик җанлы урын, халык күп, бик чуар, нинди генә милләт кешесе юктыр монда, ә шулай да татар агай-энесен ерактан ук танып була. Кырмыскалар шикелле барысы да хәрәкәттә — килүчеләр, китүчеләр һәм нидер эшләп йөрүчеләр белән яр башы мыжгып тора. Әнә аркаларына «ияр» кигән, кыска-киң балаклы крушниклар аллы-артлы тезелешеп пароходтан тюклар, капчыклар, әрҗәләр

чыгаралар. Яр өстендә билен кызыл билбау белән буган төптәй таза ломовойлар крушниклар чыгарып өйгән йөкләрне сәкедәй арбаларына төйиләр. (Атларының сыртлары да ястык кебек — ятып йокларлык.) Ярдан бераз читтәрәк тезелешеп киткән лареклар, ишекләре киңенчә ачык чәйханәләр, озын лапас астында азык-төлек сатып утыручы хатын-кызлар — монда ниләр генә сатылмый да нинди генә исләр аңкымый... Ул заманда су юлы Казанны күп шәһәрләр белән бәйли торган бердәнбер юл булган һәм Казан халкы ак пароходка утырып, Нижнийга менәргә, Әстерханга төшәргә, Кама-Агыйдел буйларына кайтырга бик яраткан. Хәзер дә ярата ул бу өч елга буйлап сузылган күк юлны, әмма елга буйлары үзләре соңгы елларда бик нык үзгәрде. Безнең Усиябез дә күптән инде су астында калды һәм «Усия» дигән сүз үзе дә тәмам онытылды диярлек.

Пароходтан төшеп, тирә-юньне әнә шулай бераз күзәткәч һәм Усиягә генә хас су исе белән тозлы балык исен дә күпмедер сулагач, без калага таба юл тотарга булдык. Ул чакларда Усиядән шәһәргә, Бишбалта аша, трамвай йөри иде. Минем бу трамвай дигән нәрсәне Самарда күргәнем бар иде инде, ләкин утырганымны бер дә хәтерләмимм... Казан үзе моннан шактый ерак булгач, без, Аллага тапшырып дигәндәй, шул вагонга утырырга булдык. Халыкка ияреп, тукталышына бардык та сары трамвайларның берсенә эләгеп тә киттек. Сәер дә, кызык та икән... Вагон шалтырап һәм селкетеп кызу гына алып бара, йөртүчесе идәндәге бер йомры тимергә басып, тышындагы кыңгыравын да «чың-чың» суктырып ала, ә без, акыллы этләр сыманрак, вагонның тар, ачык тәрәзәләреннән әле уңга, әле сулга каранып барабыз. Нindирәк кала, нинди урам, нинди йортлар монда — гүя шуларны белеп, отып калырга тырышабыз... Минем куен кесәсендә Казан докторы Әбүбәкер абзый Терегулов исеменә атакай язып биргән хат — без менә шул абзыйны эзләп табарга тиешбез.

Трамвайдан кайда төшүебез, кайсы урамнар буйлап эзләп йөрүебез, билгеле, күптән онытылган, ләкин артык озак җәфаланмыйча гына без үзебезгә кирәк йортны эзләп таптык. Бу шәһәрнең нәкъ үзәгендә, Проломный белән Телеграфный урамнары чатындагы, Казан халкына бик билгеле һәм бик матур йорт иде. Менә шуның өченче катында Әбүбәкер абзыйлар торырга тиеш. (Бу йортны кайчандыр «ТУМ» дип тә йөртәләр иде, чөнки аның беренче катында ул чагында ук инде «ТУМ» дигән зур универсаль магазин урнашкан иде.)

Фәтхелисламны әйберләр белән түбәндә калдырып, мин тәвәккәлләп һәм бераз гына каушабрак, карана-карана югары күтәрелдем. Менә биек, таза, кызгылт-көрән ишек, аңа «Доктор А.Г.Терегулов» дип язылган кечкенә генә эмаль такта кагылган. Ишек яңагындагы ак төймәгә сакланып кына бастым. Аз гына көттереп, миңа ишекне юка гына, пөхтә генә бер татар хатыны ачты... (Хадимәләре икән.) Мин кереп, Әбүбәкер абзыйга килүемне әйткәч, ул каршыдагы зал ишеген ачып, кемгәдер дәште. Залдан марҗаларча киенгән бик төз буйлы, озын-мәһабәт бер ханым чыкты. «Сезгә кем кирәк?» — дип сорады ул миннән ирләрчә калынрак, әмма ягымлы күкрәк тавышы белән... Мин Дәүләкәннән килүемне әйтеп, кесәмнән хатны чыгарып, аңа суздым. Ул хатны алып, адресын укып карады да миңа: «Аз гына көтеп торыгыз»,— дип, залга кереп китте. Бу мәһабәт озын ханымның Әбүбәкер абзый җәмәгате Әминә апа икәнлеген мин шунда ук аңлап алдым. Ул ят бер малайның килеп керүенә ризасызлык сиздермәде, шулай ук якты чырай да күрсәтмәде — ничектер бик гади генә мине каршы алды.

Бераздан Әминә апа белән бергә, кулына ачык хатны тотып, Әбүбәкер абзый үзе дә чыкты. Урта буйлы, тулырак тыгыз гәүдәле, карарак йөзле, куе җыйнак кына мыеклы, чал куна башлаган чәчен дә кыска гына (русча әйтсәк, подъежик) калдырып алдырган, кырыклар чамасындагы бер кеше иде ул. Безнең өчен зур кеше — татар докторы. Каргалы өлешендә язганымча, ул да шул авылдан чыккан морзалар нәселеннән, атакай аны яхшы белгән. Әбүбәкер абзый үзе дә минем атайны хәтерләргә тиеш иде. Һәм, чынлап та, ул иң элек миннән:

— Нигъмәтҗан абзый малаемы? — дип сорады.

— Ийе,— дидем мин.

— Укырга дип килдеңме?

— Ийе, бер иптәшем белән.

— Та-аак... Ә кая кермәкче буласыз?

Мин буталыбрак булса да әлеге рәссамчылык-һәйкәлтараш мастерскойларын атадым. Әбүбәкер абзый бераз гына дәшми торды да русчалап:

— Ну что же! — дип куйды, аннары Әминә апага карап: — Атасы Нигъмәтҗан абзый бездән шәкертләрне вакытлыча кабул итүне сораган... Керсеннәр булмаса,— диде дә, үзе шунда ук борылып, эчкәре кереп тә китте.

Инде Әминә апа миннән сораша башлады:

— Исемең ничек?

— Әмирхан.

Ул гаҗәпләнде:

— Әмирхан?! Сездә дә бармыни бу исем?
— Бар, ник булмасын...
— Алай икән... Ә иптәшең кем?
— Фәтхелислам.
— Кайда соң ул?
— Түбәндә... Әйберләр янында.
Шуннан соң Әминә апа миңа сынабрак карап торды да ничектер өздереп кенә:
— Ярый, туганым, вакытлыча кереп торырсыз... Укырга урнашканчы...— диде, аннан ишек ачкан асрау хатынга борылып әйтте: — Эчке бүлмәгә керт үзләрен!..
Шулай итеп, Әбүбәкер абзыйлар безне кабул иттеләр. Мин тиз генә төшеп, Фәтхелисламны әйберләре белән алып мендем. Асрау хатын безне кухня аша бер кечкенә бүлмәгә кертте.
— Шушында торып торырсыз, ятарыгызга урын-җир бирербез,— диде.
Без әйберләребезне идәнгә куйдык, үзебез урындыкларга утырдык. Бу инде безнең урнашуыбыз иде. Ләкин шулай да без әле үзебезне кул-аякларыбыз бәйләнгәндәй читен бер хәлдә хис итә идек. Шәп йортка, мөхтәрәм дәү кешеләргә килдек тә мәшәкать ясадык — ярыймы, килешәме бу?.. Икебез дә шулай уйлый идек бугай, һәм шәкертләрчә кулыбызны тезләребезгә салып, селкенмичә дә тик кенә утырабыз. Хәтта сөйләшергә дә кыймыйбыз... Беренче минутлар әнә шулай үтте. Аннары мин карана башладым: вакытлы торагыбыз — бер генә тәрәзәле җыйнак кына бүлмә, кечкенә өстәле, ике урындыгы, комод кебек нәрсәсе дә бар. Стена буенда пөхтә итеп җыештырган тар гына тимер карават тора — бу әлеге асрау хатын бүлмәседер, ахрысы... Торып, тәрәзәдән тышка да карадым. «Безнең» йорт күрше йортлардан биегрәк икән, аларның кызыл түбәләре бер-берсенә тоташып киткән, тик биекләкләре генә бер түгел... Шулай да шәһәр кызыклы — күпме халык аслы-өсле салынган читлекләрдә торалар. Без дә берзаман «читлектә» торучы кала кешесенә әйләнербез микән? Ләкин күңел нигәдер әле моңа ышанып бетми иде.
Шулай каранып, яңа урынга әзрәк ияләшкәч тә, без чыгып китәргә булдык. Әлбәттә, бүген үк күз төбәп килгән мәктәбебезне эзләп табарга кирәк — бу һич кичектермәс беренче эшебез... Ләкин кузгалырга өлгермәдек, асрау хатын безне кухняга чакырды.
— Әйдәгез, тамак ялгап алыгыз! — диде ул безгә.
Без икеләнебрәк калдык — монда ашап-эчеп алуны бер дә уйламаган идек. Кыюсыз гына рәхмәтебезне әйттек, ә асрау хатын авыз да ачырмый:

— Әйдәгез, әйдә, бүген ашаганыгыз юктыр бит әле. Кыстатып торырга, язмаганны!..

Шулай дигәч, чыктык инде, ак клеенка япкан зур гына өстәл янына утырдык. Кухня иркен, бик чиста, бөтен җире тәртиптә, монда чебеннең заты да юк иде. Өстәлдә ак самовар, бизәкле чынаяклар, сөт, шикәр, май, тәлинкә тулы ап-ак күмәч. Асрау хатын үзе безгә чәйне ясап, сөтен салып бирде. Бик ачыккан булсак та, без әдәп саклап, кабаланмыйча гына ашарга тырыштык. Ак май да, күмәч тә бик тәмле иде. Беренче Казан ризыклары!

Ул да булмый, безнең яныбызга саф татарча киң җиңле озын күлмәк кигән, башына ак батист яулык бәйләгән, кулына дисбе тоткан, бик пөхтә, бик мөлаем, йомры гына бер карчык килеп керде. Бу — Әбүбәкер абзыйның анасы икән. (Бәлки әле, Каргалыча «анакай» дип дәшә дә торгандыр.)

Без олы кешегә хөрмәт йөзеннән тормакчы да булган идек, ләкин карчык, кулы белән генә ишарә ясап, утырырга кушты. «Ризыгыгыз бүленмәсен»,— диде ул безгә... Аннары бер читкә үзе дә утырып һәм көтә төшеп, бездән җайлап кына исемнәребезне, ничек килеп җитүебезне, әти-әниләребезне, кая укырга кермәкче булуыбызны сораша башлады. Мөлаем карчыкның тавышыннан һәм күз карашыннан ук безне чын-чынлап кызгануын, кайгыртуын, химая итәсе килүен сизеп була иде. Һәм, әйтергә кирәк, бу йортта тору дәвамында Ходай бирмеш һәр көн безне ашатып-эчертеп, хәлләребезне белешеп, озатып һәм каршы алып торучы шушы ике изге җан — хадимә хатын белән Әбүбәкер абзыйның әнисе карчык булды. Төп хуҗалар Әминә апа белән Әбүбәкер абзыйны без бик сирәк күрә идек.

Чәйдән соң без үзебезгә кирәк әлеге мәктәп-мастерскойны тизрәк эзләп табарга булдык. Кулыбызда адресы бар, аннары хуҗалар да бераз өйрәтеп чыгардылар: шушы аркылы урам белән тауга менәсез, анда Чернышевский урамы булыр, менә шуның белән уңга борылып, бер квартал барырсыз, университетка җитәрәк, сулга борылып, әзрәк түбән төшәрсез, башта бер бакчаны, аннан икенче — «Бакыр бабай» бакчасын үтәрсез дә нәкъ сезгә кирәк урам өстенә барып чыгарсыз, диделәр... Шактый ук буталчык иде бу безнең өчен, ләкин юнәлешне бер белеп алгач, тел үзе дә илтеп җиткерер әле дип уйладык без, чыгып китешли...

Шул рәвешчә, тау менеп, уңга һәм сулга борылып, ике бакчаны да үтеп, без, ниһаять, үзебезгә кирәк урам

өстенә килеп чыктык. Ләкин башта «Бакыр бабай» һәйкәле янында тукталмыйча китә алмадык. Әкрен генә әйләнеп, башны каерып, авызны да ача төшеп, бу безгә әле юньләп билгеле дә булмаган озын чәчле кешенең һәйкәлен игътибар белән тамаша кылып чыктык. Әйе, зур, мәһабәт, бик шәп һәйкәл, чынлап та, бакырдан икән үзе, тик «бабай»ның утырып торган күтәрмәсе генә шома кара таштан. Казан халкы аңа «Бакыр бабай» дип бик дөрес исем биргән икән[1].

...Ярый, мәшһүр «бабайны» да күрдек, мәмнүн булдык, инде бакча алдыннан гына узган урамның кайсы очына таба китәргә? Узып баручы бер чибәр туташтан сорарга туры килде. «Әнә уңга таба барыгыз»,— диде туташ, нәфис кулын селкеп... Киттек, карана-карана барабыз, ләкин никтер һаман җитә алмыйбыз. Бу элек Грузинская дип йөртелгән, хәзер исә Карл Маркс исеменә күчерелгән, Казанның иң озын һәм иң төзек урамы иде. Барысы да диярлек таштан салынган, әмма бер-берсенә охшамаган зур, таза, бай йортларга карый-карый бара торгач, без менә ахырда Дәүләкәннән үк уйлап килгән, тик әле күреп кенә өлгермәгән бинабыз алдына килеп чыктык. Шушымы соң?.. Шушы икән шул!.. Әмма бу хәтле үк мәһабәт, матур булыр дип һич тә көтмәгән идек. Мондый бинаны «мастерской» дип атарга мөмкинмени?! Бу бит иң шәп уку йорты булырга тиеш ләбаса!.. Хәер, ул чынлап та, рәссамнар укытып чыгарыр өчен гасыр башында ук махсус салынган бина икән — без моны озак та тормыйча белдек, әлбәттә.

Урам капкасыннан да тазарак, ләкин бик пөхтә итеп, матурлап эшләнгән авыр имән ишегеннән эчкәре кердек. Аз гына узып, берничә мәрмәр баскычтан күтәрелгәч, безгә тагын шундый ук таза-нәфис бер ишекне ачарга туры килде һәм безнең нәкъ каршыбызда түргә таба сузылган киң генә коридор ачылды. Бер ягында тезелеп киткән бүлмә ишекләре, икенче ягында исә төрле төстәге пыялалардан зур-зур тәрәзәләр иде. Әмма безне тәмам хәйран иткәне, яшел-зәңгәр пыялалы тәрәзәләрдән дә бигрәк, коридорның ике як мөешендә басып торган ике арыслан сыны булды. (Хәзерге вакытта бу мөешләрнең берсендә В.И.Ленин, икенчесендә М.Горький сыны басып тора.) Ак таштан эшләнгән икесе дә бертөсле үк арысланнар туп-туры ишеккә карап гүя сакта торалар. Моның әллә берәр төрле мәгънәсе дә бар микән? Ягъни син, кеше,

---

[1] Бу рус шагыйре Г.Державинга куелган һәйкәл иде. Хәзер аның бакчасы урынында Опера театры.— *Ә.Е.*

кая килеп кергәнеңне белеп кер һәм лаек булсаң гына аяк атлап үтәргә җөрьәт ит! Һәм без моны, акыл белән уйлаудан элегрәк, күңелләребез белән тоеп өлгердек. Юк, чынлап та без гади бер уку йортына гына килеп кермәдек бугай... Инде тагын бер хикмәтле нәрсәне күргәч, безгә бу тойгы аеруча көчәйде. Коридорның түренә таба, нәкъ уртада, сәке сыман агач күтәрмә өстендә йөзтүбән капланып, галәмәт бер адәм сыны ята иде. Без әкрен генә шуңа якынлаштык: кем бу, нәрсә бу?.. Адәм гәүдәгә гади кешедән ике-өч мәртәбә зуррак, аңардагы көч-куәт тә чамасыз булса кирәк — кулы, аркасы, ботындагы мускуллар эре-йомры ташлардай буын-буын калкып торалар... Мөгаен, борынгы әкияттән алынган берәр пәһлевандыр дип уйладык. Әмма аның коточкыч бер киеренкелек белән аягын җиргә терәп, бармакларын куе чәчләренә батырып, йөзтүбән ятуында әллә ярсу-ачудан, әллә көчсез-гаҗизлектән шундый бер дәһшәтле газап сизелеп тора иде ки, аңа карап ирексездән тетрәнмичә һәм сихерләнмичә калу мөмкин түгел иде. Яныннан китә алмыйча хәйран булып торганда, без бу пәһлеванның кем икәнлеген ачык кына белмәсәк тә, аның кеше хыялы белән тудырылган сәнгать әсәре булуын шулай да аңладык. Әнә нәрсә икән ул «Һәйкәлтараш!»... Шушында өйрәтәләр икән бу гаҗәеп сәнгатькә!.. Без, ике Дәүләкән малае, моңа, һичшиксез, балаларча сөендек һәм шул ук вакытта ирексез туган шик-шөбһәдән ныграк каушый да төштек. Насыйп булыр микән керүләре? Әмма чигенү юк, чигенергә һич тә ярамый. Тәвәккәл — таш йоткан, диләр... Пәһлеван яныннан кире борылып, туры кәнсәләрия бүлмәсенә киттек — ул тышкы ишектән кергәч тә уң кулда иде... хуш, инде кем башлап ача бу кәнсәләрия ишеген?! Фәтхелислам миңа төртә — мин өйдән чыкканнан бирле алдан йөрүче... Ачтым — кердек, алдан ук язып куйган гариза белән документларыбызны кемгәдер бирдек. Хәзер инде ул кешенең кем икәнен дә, бездән нәрсәләр сорашканын да хәтерли алмыйм. Килеп, белешеп торырга кушты бугай... Шуның белән эш бетте, һәм без нindидер бер җиңеллек хис итеп, артык юанмыйча, шәһәр гизәргә чыгып киттек.

Без килгән чактагы Казан ул кадимге Казан иде әле, ягъни анда бернинди үзгәреш юк, бернинди яңа салынган бина-мазар да юк, әйтик, 1915 елны ул нинди булган булса, ун елдан соң да шундый ук иске шәһәр иде. Дөрес, күптән түгел үтеп киткән сугыш еллары, революция вакыйгалары, ачлык-бөлгенлек вакыты шәһәрнең урам һәм

йортларында үзенең ниндидер эзләрен калдырган. Безгә, яңа килүчеләргә дә, моны күрү әллә ни читен түгел иде. Мәсәлән, урам тротуарлары күп җирдә ватык, чокыр-чакырлы, күп кенә йортларның шкатурлары купкан яки керләнеп беткән, фанер белән каплаган тәрәзәләр дә күренгәли, хәтта кайбер йортлардан лазарет исе дә килә иде... Шулай да Казан безгә бик ошады. Мин яхшы гына белгән Уфадан ул зуррак та, җанлырак та, зур-зур таш биналар да күбрәк, трамвайлар да йөри, аннары әнә калкулык өстендәге таш диварлар белән әйләндерелгән, эче эреле-ваклы чиркәүләр белән тулган һәм шулар арасыннан ялгыз гына күккә сузылган нечкә-нәфис манаралы мәһабәт ак Кремле дә аның борынгы кала булуын күрсәтеп тора. Гомумән, чиркәүләр бик күп, мәчетләр дә аз түгел икән — унсигез дип ишеткәнем хәтердә калган.

Менә шул көннәрдән соң алтмыш ел гомер узды да китте. Бу вакыт эчендә Казан берничә мәртәбә зурайды һәм искиткеч үзгәрде. Ләкин шулай да калабыз үзенең борынгы йөзен югалтып бетермәде. Шуның белән кадерле дә бит ул безгә һәм заманнар узу белән аның кадере тагы да артачак кына...

Ә алтмыш ел элек безгә иң әүвәл шәһәрнең үзәген күрергә туры килде, чөнки йөри торган юлыбыз хәзерге Бауманнан Карл Маркс урамына чаклы иде. Урамнарның да күбесе иске исемнәрен саклыйлар иде әле. Бауман урамы ул чакта Большая Проломная, янәшәсендәге Профсоюзная — Малая Проломная, Куйбышев урамы — Рыбнорядская, Бутлеров урамы Старо-Горшечная дип йөртелә иде. Әзрәк ияләшә төшкәч, татар ягына — Печән базарына да, Кабан күле буена да баргалый башладык. Нэп дигән «хөрлек»нең бу иң көчәйгән, иң котырган чагы иде. Проломныйдагы искедән калган бөтен магазиннар ачык, Гостиный дворның (Татарстан музее урнашкан йортның) бик күп бүлекләре сату итеп ята, хәзерге Кольцо дигәнебез ул чакта вак кына кибетләр белән шыгрым тулы иде... Инде Печән базарына барсаң, анда сату-алу эшләре «Кисекбаш» заманындагы шикелле гөрләп тора. Тимер ишекле таш кибетләр барысы да ачык, товарлары урамга ук чыгарылган — өлгер хуҗалары урамнан узучыларны әллә кайдан ук чакырып-дәшеп кенә торалар. Мәскәүский (хәзерге Киров) урамындагы бакча урынында толчок иде. Шунда бер читтәрәк зур чуеннарда аш пешереп сатучылар — моны «бирәннәр» (обжора) рәте дип атыйлар иде. Тирә-юньдәге йортларда чәйханәләр, сыраханәләр — аларда кызарган, бүртенгән агай-эне шау-гөр килеп утыра. «Болгар», «Амур», «Сарай»

номерларында татар рестораннары, татар музыкантлары, татар җырчылары (дөресрәге, шансонеткалары) — монда инде кичләрен нэпманнарның кәттәләре типтерәләр булса кирәк... Урамнарда даңгыр-доңгыр узган ломовойлар, тротуар буйларында сала агайларының ат-арбалары — кыскасы, нэп тудырган чын базар, чын сәүдә оясы! Ихтимал, Тукайлар, Камаллар заманында да ул шулайрак булгандыр, бары тик «Көфер почмагы» гына юкка чыккан булырга тиеш.

...Мәчетләрнең дә барысы да эшлиләр иде шикелле. Манаралардан иртә-кич азан тавышлары ишетелә, бүрек, җилән кигән агайлар ашыга-ашыга намазга баралар... Минем әле шул замандагы рамазан ае да хәтеремдә. Кичкырын икенде-ахшам вакытында мәчет аллары муенналарына сай тартма асып, кәләвә, как-төш, чәкчәк, балда катырган мәк сатучы малайлар белән шыгрым тулы була торган иде. Мәчеттән чыгучы агай-энене бу малайлар яшел-зәңгәр тавышлар белән: «Кәләвә! Кәләвә!», «Кактөш! Как-төш!» — дип кычкыра-кычкыра каршы алалар. Һәр мөселман ни дә булса алмыйча китми — күрәсең, изге айның бер йоласы булгандыр инде бу. Тагын бер нәрсә мине бик гаҗәпләндергән иде — хәер сорап утыручы гарип-горабаның күплеге... Бәлки, мәчет алларында гына барысы бергә җыелып утырганга күрәдер... Алай дисәң, урамнарда да төрле гарипләр — зур башлы кәрләләр, бөкреләр, сукырлар еш кына очрап торалар. Ә кәкре аяклыларны әйткән дә юк — болары аеруча хатын-кызлар арасында еш очрый... Моңа минем бик исем киткән иде, чөнки бездә, мәсәлән, Уфада, кәкре аяклы кызны күрмәссең... Бичара Казан кызларына мондый бәхетсезлек кайдан, нәрсәдән килә икән дип уйланганым да бар иде. Ишетүемә караганда, Казан халкының эчә торган суында нниндидер матдә җитешми икән. Шунлыктан рахитик балалар күп, шулар кәкре аяклы булып үсәләр, имеш. Белгечләр бу хакта ни әйтә торгандыр, ләкин татар ягында торучылар суны чынлап та күбрәк Кабаннан эчкәннәр. Ә Кабан акмый яткан ябык күл, хәзерге шикелле үк кортлы, шакшы булмаса да, барыбер шунда кер дә чайкаганнар, су да кергәннәр, завод-фабрика һәм урам сулары да агып төшкән. Шулай да эчкәннәр, чөнки Кабан ул элек-электән үк Казан халкының бердәнбер төп су чыганагы булып килгән.

...Күл һәм Болак дигән сусыз тирән чокыр, билгеле булганча, Казанны нәкъ уртасыннан икегә бүлеп узган. Без килгән чакларда каланың югары һәм түбән ягы дип йөртелгән бу ике өлеше бер-берсеннән шактый нык аеры-

ла иде. Татарлар тыгызланып утырган түбән якта яшеллек бик аз, зур бакчалар юк, күп җире сазлык, урамнарда һәрвакыт тузан... Иске бистә белән Яңа бистә арасындагы зур сазлыктан таралган үзе әче, үзе яман сасы ис җәйнең бөркү көннәрендә Болакка хәтле үк килеп җитә иде.

Иске Казан, иске заман... Монда диннең көчле булуын әдәбияттан да укып белә идек. Әнә бит бер катлы, ике катлы агач йортларны да кыйблага каратыр өчен урамга кырынрак итеп салып куйганнар — бу безнең өчен яңалык иде. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәсе килә: Казанда элек мәшһүр байлар күп кенә булса да, алардан калган зур, матур йортлар бик сирәк күренә иде. Тукай урамындагы Шамил йорты белән аркылы урамдагы Апанаевлар йортын исәпләмәгәндә, Казанның татар ягы архитектурага бик ярлы булган икән. Байлык җитмәгәнгәме, әллә вакытмы?..

Татар ягында йөргәндә тагын бер нәрсә күзгә ташланмыйча калмады. Монда саф мөселман агай хатынын артыннан ияртеп йөри икән... Кызык! Хәер, безнең Дәүләкәндә дә Әхмәтвәли исемле Казаннан килеп чыккан бер абзый хатыныннан гел бер-ике адым алдарак йөри иде. Үзе ул кечерәк буйлы, вак-вак кына атлап, кызу гына тыраклый, ә хатыны озын-таза, аякларын салмак кына эре-эре итеп сала. Кешеләр күреп алсалар:

— Әнә Әхмәтвәли агай дөясен җитәкләп килә! — дип көлә торганнар иде... Әмма Казан урамнарында Әхмәтвәли ишеләр шактый ук икән әле.

Ләкин барыбер чал Казан — иске Казан түгел иде инде. Яңа заман галәмәтләрен дә таш каланың һәр җирендә ачык күрергә мөмкин иде. Иң элек бик табигый рәвештә без моны уку йортлары тирәсендә күрдек. Безнең ише ерактан, мәсәлән, Уралдан, Оренбурдан, Әстерханнан, Донбасстан, Себердән һәм мишәр якларыннан укырга дип килгән татар егетләре, татар кызлары кая гына барсаң да очрап кына торалар. Алар бик төрле, бик чуар — өстеннән әле шинелен дә салмаган «картлары» һәм өеннән беренче мәртәбә генә чыгып киткән бик яшьләре дә бар. Күпчелеге авылдан — боларны кыяфәтләреннән үк танып була. Ләкин төрле шәһәрләрдән килүчеләр дә аз түгел. Һәммәсе дә зур өметләр белән килгән — беренче мәртәбә бит аларга барлык уку йортларының ишекләре киңенчә ачык!.. Кер, укы, белем гранитын кимер!.. (Бу сүз ул чакта бик модада иде.) Бәлки, барысы да кереп бетә алмас — шуңа күрә аларның йөзендә шатлык белән бергә каушау да чагыла... Тик, ни сәбәптер, алар арасында Казанның үз яшьләре сирәк күренә — моңа да нәп гаепле булмады микән?!

Урамнарда йөргәндә без һәр очраган вывесканы укымыйча үтмибез. Әлбәттә, барысы да ике телдә — русча һәм татарча. Ләкин татарчасы хәзергегә караганда башкачарак, мәсәлән, дәүләт биналарына куелган такта яки калайга «Татарстан Автономияле Социалистик Шуралар Җөмһүрияте» дип язылган... Бу — яңа, бу — горурлык уята, «Татарстан... Шуралар Җөмһүрияте» — димәк, безнең үз дәүләтебез!..

Халык комиссариатларының да кайберләре бүтәнчәрәк атала иде: финансныкы — малия, юстициянеке — гаделия халык комиссариаты дип язылган була иде. Хәтта университетка да «дарелфөнүн» дип язылган иде ул чакта. Инде татар ягындагы кибетләр арасында йөрсәң, монда әллә кайдан ук татарча гына язылган зур-зур вывескалар күзеңә ташлана: фәлән ширкәт тә төгән ширкәт!.. Ләкин арада бик хөртиләре дә очрый — болары вак сатучы яки һөнәрченеке булырга тиеш. Мәсәлән, шундый хөрти вывесканың берсе әле дә хәтеремдә: Тукай урамындагы бер капкада «Галуш җамыйм» дип язылган калай кисәге эленеп тора иде.

Тагын нәрсә?.. Урамнарда — йөк ташучы ломовойлар, чатларда — резин ходлы извозчиклар... Ат-арба заманы. Акчаң булса, утыр да кит — үзләре үк чакырып торалар. Ә кичләрен бу извозчиклар, спектакль бетүгә, театр алдына килеп тулалар. Тамашадан чыккан бай нәпманнарны утыртып, бер-бер артлы, таш урамнарны шакылдата-шакылдата, җилдертеп алып та китәләр. Акча бик кадерле иде ул чакта. Миңа, мәсәлән, бервакытта да извозчикка утырырга туры килмәде. Хәер, бер генә мәртәбә, егерме сигезенче елны микән, кышын, Бишбалтада торучы Хәсән Туфанга Шәйхи Маннур һәм тагын кем беләндер извозчикка утырып барганымны хәтерлим... Аның каравы, безнең «люмпеннар» өчен ул елларда «барабыз»лар бар иде. Чана юлы төшкәч, алар Дөбъяз тирәсеннән киләләр иде бугай. Үрәчәле чанага алашасын җиккән чикмәнле агай ун-унбиш тиенгә сине теләсәң кая илтә дә ташлый торган иде.

Ярый, сүзгә мавыгып, әзрәк читкә дә чыктым. Безнең бит әле яңа гына килгән чагыбыз, кала белән бары тыштан гына танышып йөрибез. Эчендә аның ниләр бар — хәзергә билгесез. Әгәр калырга язган булса, «эче» дә әкренләп ачылыр.

...Килүебезгә берничә көн үтеп китте. Документлар бирелгән, имтиханнар башлануын көтәбез, ә хәзергә урам таптаудан башка эшебез юк. Әбүбәкер абзыйлардан иртән

чыгып китәбез, кич кенә кайтып керәбез. Хуҗаларга артык мәшәкать ясамас өчен көндез кайтмаска тырышабыз. Кесәбездә юлдан калган күпмедер акчабыз бар, арзанлы ашханәләрнең берәрсенә кереп, тамак та ялгап чыгабыз. Кольцодагы хәзерге «Чулпан» рестораны ул чакта әнә шундый ашханәләрнең берсе иде. «Нарпит» дип атыйлар иде аны... Бу «нарпит»та ун тиенгә бер тәлинкә аш алсаң, шуны дүрт-биш телем икмәк белән әйбәт кенә сеңдереп чыгасың. Икмәк түләүсез иде шикелле, өстәлләрдә өелеп ята иде — теләсәң күпме аша!

Ләкин, «фатир»га соң гына кайтсак та, безне көн дә диярлек аш белән көтеп алалар иде. Асрау хатын безнең соңлап кайтуыбызга әз генә үпкәсен белдереп, шунда ук ашын да, ите белән бәрәңгесен дә җылытып бирә. Без, ашап кайттык, тамагыбыз тук, рәхмәт, дия башлагач, ул чын шелтә белән: «Нигә, акчагыз әтәч булып кычкырамыни?» — дип әйтә торган иде. Әбүбәкер абзыйның әнисе миһербанлы мөлаем карчык та, гаҗәпләнүен яшермичә: «Ник читтә ашап йөрисез, килешми ич ул, кунак бит сез безгә!» — ди иде. Шуннан соң инде без, ике сантый, алдыбызга китереп куйган сыйларны кызарынып, сүзсез генә ашарга утырабыз.

Аларның безне шулай кайгыртулары, көтеп алулары, хәлебезне дә сорашып торулары безгә, әлбәттә, бик ошый иде. Чит-ерак җирдән килгән безнең ише кеше, ничек дим, беркадәр ятим кеше, шуңа күрә ул һәрвакытта җылы сүз, яхшы мөгамәләгә мохтаҗ... Ләкин дә бит ике таза малай урын биләп ятабыз!.. Көн дә кайтып-китеп, мәшәкать ясап йөрибез. Шушы нәрсә безне һаман борчый, шушы нәрсә җаныбызга тынычлык бирми иде...

Әбүбәкер абзый ул елларны Казандагы бармак белән генә санарлык татар докторларының иң танылганы иде. Бөтен татар ягы аңа йөри иде дисәм дә хата булмас... Иртәрәк кайткан чагыбызда, аңа килгән авыруларның каршыдагы залда көтеп утыруларын күрә торган идек. Әбүбәкер абзыйның зур гына кабинеты ишектән кергәч тә сул кулда — авыруларны ул көн дә диярлек шунда кабул итә иде. Болай үзендә кабул итү ул электән үк килгән законлы бер эш, шуңа күрә һәрбер врачның тышкы ишегендә исем-фамилиясе язылган кечкенә генә бакыр яки эмаль такта була торган иде. (Андый такта Әбүбәкер абзыйның ишегендә дә бар иде.) Кабул итү, әлбәттә, түләү белән — аны гонорар дип кенә әйтәләр иде... минем үземә дә соңыннан әнә шул зур кабинетта Әбүбәкер абзыйга бер-ике тапкыр күренергә туры килде — билгеле, түләүсез генә, чөнки мин аңа үз кеше...

Авырулар кабул итмәгәндә дә алардан кеше өзелми иде диярлек — кичләрен еш кына зур залда үзләре кебек интеллигент кешеләр җыелышып утыралар. Алар арасында медицина әһелләре генә түгел, художниклар, артистлар да була икән... Бик җанлы мәҗлес, өзлексез сөйләшү, көлешүләр — шулар арасыннан мәһабәт-төз буйлы Әминә апаның көр тавышы ап-ачык ишетелә... Менә шундый вакытта кайчак без звонок биреп кайтып керәбез һәм җилкәләребезне җыерып, мыштым гына кухня аша үз бүлмәбезгә үтеп китәбез. Дөрес, кунаклар безне күрмиләр, ләкин шулай да уңайсыз. Мондый чакта кайтмый тору яхшырак та бит, әмма нишлисең, бүтән чараң булмагач?! Җитмәсә әле, мәрхәмәтле асрау хатын кунакка әзерләгән сыйлардан безгә дә өлеш куя. Менә шулай, кәбәм!..

...Тагын бер мәртәбә кабатлап әйтәм, бу йортта ике атнадан артыграк торып, без хуҗалар тарафыннан бернинди ризасызлык сизмәдек. Кайчанрак күчәрсез икән дип, читләтеп кенә булса да бездән теш елтыратып сораучы булмады. Бер караганда, төп хуҗаларның боздә эшләре юк шикелле тоелса да, безгә булган игътибарның, әлбәттә, Әминә апа ризалыгы һәм боерыгы белән эшләнгәнен аңлавы читен түгел иде. Мондый гаиләдә башкача була да алмый торгандыр инде ул... Әмма ләкин бу изгелекне нәрсә белән кайтарырга?.. Әгәр аларга берәр төрле эш эшләргә, әйтик, су китерергә, утын ярып кертергә кирәк булса, без «әһ» тә димичә рәхәтләнеп эшләгән булыр идек. Ләкин аларда безгә яраклы бер төрле дә эш юк иде.

...Хәер... бер эш шулай да табылды. Әбүбәкер абзыйның салпы колаклы, аклы-сарылы бер чуар ау эте бар иде. (Без аны икенче көнне генә күрдек, чөнки аның урыны ишек төбендә түгел, каядыр түрдә иде бугай...) Менә шушы акыллы эт, кемнәр икәнебезне белгәч, безгә бик тиз ияләште. Кайтып керүебезгә, чабып яныбызга килә, бүлмәгә дә, «әйдәгез, әйдә» дигәндәй, алдан үзе кереп китә, куанычыннан нишләргә белмичә бөгелә-сыгыла, бертуктаусыз әле миңа, әле Фәтхелисламга сырпалана... Аннары бераз тынычлангач, башын теземә сала да туп-туры күзләремә карап тора башлый. Адәм баласыныкыдай күзләре аның нидер сорый, нидер көтә. Ах, әйтә дә алса иде ул!.. Ахырда без сиздек, аның, мөгаен, йөрергә чыгасы килә торгандыр... Асрау аша Әминә ападан алып чыгарга рөхсәт итүен сорадык. Әминә апа үзе безгә, пажалысты, алып чыга күрегез, Әбүбәкер абзагызның аны йөртергә бер дә вакыты юк, диде. Шуннан соң

без, Фәтхелислам белән икәү, һәр көнне диярлек чуар этебезне алып чыгып, Болак буйларында күңеле тәмам хушланганчы йөртә торган булдык. Каешыннан ычкындырмый идек ычкындыруын, әмма аның өчен бу чыгулар барыбер гаять зур хөрлек иде. Хәлдән тайганчы безне сөйрәп чаба иде, бөтен җирне исни-тырный иде, һәр очраган баганаsuccessfully «тамгалап» китә иде... Бу иреккә чыгуларны ул озак оныта алмагандыр, безне бик юксынгандыр, бәлки әле боегып, җылап та йөргәндер.

Сүз җаеннан әйтмичә үтә алмыйм, этләрне мин үзем бик яратам. Алар үзләре дә миңа һәрвакытта шәфкатьле булдылар. Чылбырдагы усал эт янына барганым бар — карады, иснәде, тимәде. Эт гаять сизгер ул, акыллы ул, инсафлырак та ул. Начар белән яхшы кешене әллә кайдан ук сизеп тора. Начарга якын да бармый, ә яхшыга үзе үк килә. Мәкерле алдау гына аны харап итәргә мөмкин... Яхшылыкка каршы ул бервакытта да начарлык эшләмәс. Адәм баласыннан «этлек»не күп күрдем, әмма этләрдән — юк. Хәзер дә әле мин очраган бер эткә, ышанычлы дуска дәшкәндәй, «Нихәл син!» дип дәшмичә узмыйм.

Әйткәнемчә, без Әбүбәкер абзыйларда ике атнадан артыграк, укырга керү мәсьәләсе хәл ителгәнче тордык. Кайчан, кая китүебезне түбәнрәк язармын, ә хәзер исә бер үкенечемне әйтеп үтәсем килә: күргәнегезчә, безгә шундый яхшылык эшләгән һәм күпмедер дәрәҗәдә миңа нәселдәш булган шушы бик әйбәт, бик хөрмәтле гаилә белән мин ни өчендер соңыннан элемтәмне югалттым. Дөрес, моның минем үз хәлем белән бәйләнгән җитди сәбәпләре булды. Хәлбуки сугыштан соң авыр еллар узып, тормышлар да бер эзгә төшкәч, үзем дә инде олаеп, язучы да булып киткәч, өзелгән элемтәне яңартырга бик мөмкин иде. Әбүбәкер абзыйның үзен дә, Әминә апаны да якыннанрак белергә, алар күреп уздырган заман, тормыш һәм кешеләр турында сорашырга бик кирәк иде. Зур кызганычка каршы, «кирәклеген» белеп йөргән хәлдә, мин аны да эшли алмадым. Әллә урынсыз тыйнаклык, әллә ваемсызлык, әллә тормышның ваклыклары — нәрсәдер мине чабуымнан тоткандай тыйды да торды.

Ә бит мин килгән елларны авыр чакларда аларга баргалый идем. Мәрхәмәтле карчык белән асрау мине үз итеп каршы алалар, хәлемне сорашалар, кухняда гына ашарга да утырталар. Инде Әминә апа өйдә булып, түр бүлмәләрдән чыкса, аз гына сөйләшүдән дә хәлемне аңлап, берәр сум акча да биреп җибәрә иде.

...Ике-өч тапкыр Әбүбәкер абзыйга да күрендем.

Үпкәләрем таза түгел иде ул чакта. Язга чыгу белән кәефнең начарлануын сизеп, беренче мәртәбә аңа баргач, ул мине әйбәтләп карады-тыңлады да: «Сиңа саф һава, таза ашау, кымыз эчү кирәк, монда тузан йотып йөрмә, тизрәк өеңә — Дәүләкәнеңә кайтып кит!» — диде, һәм бу бик дөрес киңәш иде.

Икенче мәртәбә белешмә алу өчен аңа күренергә туры килде. (Нинди белешмә һәм ни өчен — бу хакта вакыты җиткәч.) Ә өченче мәртәбә күренүемнең сәбәбе болай булды: мин ат казылыгы ашап агуландым. Төн буе күз дә йома алмыйча газапланып чыктым, укшудан бөтен эчем актарылды, берни дә калмады. Иртән көч-хәлгә торып Хәбибрахман янына киттем — аның медфакның дүртенче курсында укыган чагы иде. Ул мине ияртеп, хәзерге Вишневский клиникасына алып китте. Алар курсы шул көнне анда практика үтә икән. Хәбибрахман курс җитәкчесе врач-ассистенттан мине каравын үтенде. Ассистент бик рәхәтләнеп риза булды һәм бөтен группа алдында мине чишендереп өстәлгә салды. Әзрәк сорашканнан һәм үзе караганнан соң, студентларның да барысына карарга кушты. Ну, шул чактагы хәлемне белсәгез иде!.. Студент кызлар җылы-йомшак куллары белән минем бушап калган эчемне әле уңнан, әле сулдан басып-басып карыйлар, җитди генә нидер әйткән булалар, үзара сөйләшкән булалар. Шунда берәрсе шырык-шырык көлеп тә куя. Ә мин, ыштан изүен тотып, сикереп торырдай булып ятам.

Карау-сорашулар беткәч, врач-ассистент нәтиҗә ясап, үзенең диагнозын куйды:

— Картина ачык. Авыруның сәбәбе — аппендицит. Приступ шуңардан... Егетнең сукыр эчәген кисәргә кирәк!..— Һәм миңа, озакка сузмыйча, берәр атнадан операциягә керергә кушты.

Киенеп урамга чыккач та, мин тиз генә тынычлана алмадым. Бу операция дигән нәрсә мине чынлап торып хафага салды. Кисү-яруны моңарчы бик сирәк ишетергә туры килә иде, һәм бик сирәкләр генә исән калалар да иде шикелле... Белмим, бәлки, болай курку-шикләнү урынсыздыр да, ләкин нишләмәк кирәк, хәвефле уйлар күңелгә килә дә тора. Соңрак миңа Хәбибрахман да сукыр эчәкне кистерүнең бик җиңел операция булуын аңлатырга тырышты. Юатырга оста иде ул, аның сүзләреннән соң беразтынычланган кебек тә булам, тәвәккәллек тә кайткан шикелле була, ләкин озакка түгел — тагын төрле шикшөбһә күңелне әкрен генә кимерә башлый. Нишләргә инде? Күзне йомып, ятаргамы әллә?.. Әмма аяк тартмый гына бит... Инде бер атна вакыт та узып китте, врач биргән

срок та килеп җитте. Ә мин үземне, үч иткәндәй, бик әйбәт хис итәм, ашау-эчү дә элеккечә шәп бара, бер генә җирем дә авыртмый — йә, шушы хәлдә бар да пычак астына ят, имеш!.. Туктале, дидем, «асылынсаң асыл алмагачның асылына» дигәннәр, тоттым да Әбүбәкер абзыйга киттем. Кабул итте. Әйбәтләп карады һәм әйтте:

— Пока операциягә керми тор,— диде.— Әгәр приступ яңадан кабатланса, килерсең, карарбыз!..

Менә шул. Әйтерсең авыр ташны өстемнән алды Әбүбәкер абзый. Рәхмәт кенә аз аңа! Шулай да баштарак яңа приступны көтебрәк йөрдем, ләкин ул килмәде, һәм мин бик тиз тынычландым — сукыр эчәкнең барын да оныттым. Шуннан соң менә, әйткәнем булмасын, алты дистәгә якын гомер узып китте, бер генә тапкыр да приступка охшаган нәрсә кабатланмады. Һәм моннан соң да... Хәер, моннан соң ни буласын юрамый тору яхшырак.

Инде югарыда әйткән миндәге үкенү хисе ул Әбүбәкер абзыйның яхшылыгын онытудан гына туган нәрсә түгел, әлбәттә. (Хәлбуки бу да зур үкенеч.) Сәбәп тирәндәрәк ята: хикмәт шунда ки, Әбүбәкер абзый да, Әминә апа да — тарихи шәхесләр. Татар халкының чын зыялылары, киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм кешеләр. 1885 елны Уфада туган Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегулов 1911 елны Казан университетының медицина факультетын бетереп чыга. Совет вакытында Германиягә барып белемен арттыра, докторлык диссертациясен яклый. Татарлардан беренче атаклы доктор һәм медицина профессоры. Сугышка чаклы һәм сугыштан соң да Татарстан Верховный Советына депутат булып сайланган иде... Күрәсез, игътибарга бик лаек кеше.

...Ахрысы, шуңа күрәдер дә язучы Габдрахман Әпсәләмов үзенең мәшһүр «Ак чәчәкләр» романындагы карт доктор Әбүзәрнең прототибы итеп Әбүбәкер абзый Терегуловны алган булган — һәрхәлдә, шулай дип сөйләделәр. Ләкин әсәрдәге образ белән тормыштагы прототип күп очракта төгәл туры килеп бетми — аерма һәрвакытта була һәм шактый зур да була. Менә бу очракта да аерма, минемчә, зур иде. Озак еллар дәвамында миңа да бит Әбүбәкер абзыйны күрергә, күзәтергә, сөйләшкәләргә дә туры килде. Һәм мин аны үз бәясен яхшы белгән, һавалырак, әмма ачык йөзле, бөтен торышы-тотышы белән чын бер интеллигент кеше дип таный идем. Йөргәндә дә ул бик пөхтә киенеп, эшләпәсен яки бүреген яшьләрчә кырынрак салып йөри торган иде. Эт ияртеп ауга йөрүче, китап җыючы, сәнгать әһелләре белән утырырга ярату-

чы,— кыскасы, тормыштан тәм табучы иде ул, миңа калса. Һәрхәлдә, кешеләргә мораль укып, акыл сатып йөрүче резонер түгел иде.

Миндә иске бер фоторәсемнең Срур тутакай күчертеп биргән копиясе саклана. 1911—1912 елларда булса кирәк, Дим буена кымызга килгән бер төркем татар зыялылары авыл кырыендагы яшел чирәмдә фотога төшкәннәр. (Авылы Кара Якуп түгел микән?) Рәсемдә Мәҗит Гафури, хатыны Зөһрә ханым белән, Сәгыйть Сүнчәләй, тагын кем булулары ачылып бетмәгән берничә кеше — һәм шулар арасында Әбүбәкер абзый белән Әминә апа да бар... Әнә шундый бәйләнешләр...

Моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Әминә апа бит ул Ибраһим Терегуловның өлкән кызы. Ә Ибраһим Терегулов — культура тарихыбызда мәгълүм кеше — мәгърифәтче, педагог, җәмәгать эшлеклесе... Күп еллар Учительский школада эшләгән, рус классикларын татар телендә бастыра башлаган, «Шәрекъ клубы»н оештыручыларның берсе һәм беренче рәисе дә булып торган. Җәмәгате Бибигайшә ханым да мәдәни эшләрдән читтә тормаган — русчадан татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән. (Аның хакында «Азат хатын» журналының 1984 ел, 10 нчы санын карагыз.) Димәк, бу гаилә үз заманының мәдәни хәрәкәтендә якыннан катнашып, барлык алдынгы кешеләре белән аралашып яшәгән. Әдипләрне, шагыйрьләрне, артистларны да алар яхшы белгәннәр. Билгеле инде, җитеп килгән кызлары да бу даирәдән читтә тормаган. Әминә апа, мәсәлән, 1905—1906 елларда ук йорт спектакльләрендә катнаша башлый. Моны мин Шәриф җизни Сүнчәләйдән ишеткән идем — ул да бит шул елларны Учительский школада укый һәм демократик яшьләр хәрәкәтенә якыннан катнаша. Шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең Әминә апага мөкиббән гашыйк булуы турында да ишеткәнем бар. Чын булса, шагыйрьнең «Сызла, күңелем!» шигыре турыдан-туры Әминә апага атап язылган.

Сызла, сызла, сызла, күңлем!
Сызла бер туктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

Сызла, сызлап син мәхәббәт
Ялкынын гөлләр яса,
Мәңге хәсрәт һәм кара төн
Елларын көннәр яса!..

...Кызыклы заман, таң вакыты (шагыйрь әйткәнчә), әмма татар йокламый — татарның уянган чагы. Әбүбәкер

абзый белән Әминә апа да нәкъ шул заман яшьләре — йөргәннәр, күргәннәр, эчендә кайнаганнар. Бигрәк тә Әминә апаның хәтерендә һәм күңелендә күп нәрсәләр сакланган булырга тиеш иде. Ләкин ни кызганыч — барысы да үзләре белән китте. Хәзер инде үкенүдән мәгънә юк — мин үз гаебемне өстемә алдым... Әмма... мондый үкенү бер миндә генә микән?.. Без бит озак вакытлар тарихыбызның иң кызыклы, иң гыйбрәтле дәверенә игътибарсыз булып кала бирдек. Һәм шул вакыт эчендә ул дәвернең Әминә апа кебек җанлы шаһитлары аз киттемени бу дөньядан? Юк, үкенүчеләр дә аз булмаска тиеш.

Без кабул итү имтиханнарын көтеп йөрибез. Башка эшебез юк, көн дә Карл Маркстагы чибәр йортка барабыз. (Хезмәткә йөргән шикелле.) Барган саен анда үзебез кебек читтән килгәннәрне очратабыз. Барысы да егетләр, кызлардан ни өчендер берәү дә юк. Аларга иртәрәктер шул, өлгереп җитмәгәннәр күрәсең әле... Егетләрнең һәммәсе дә диярлек төрле шәһәрләрдән — Оренбурдан, Әстерханнан, Самарадан — ә менә Стәрлетамактан берьюлы өч егет килгәннәр. Болар инде безнең якташлар, алар белән бик тиз дуслашып киттек... Мортаза Абдуллин дигәне белән минем дуслык даими төс алып, мәрхүмнең үлгән көненә кадәр дәвам итте. Аның хакында сүз булачак әле...

...Йөри торгач, имтиханнар көне дә килеп җитте. Читтән килгән, гариза биргәннәрнең барысын да үткәргәннәр. Беренче имтиханга керүебезнең тәгаен числосын күптән онытканмын, һәрхәлдә, августның егермеләре тирәсендә булды шикелле... Шулай ук нәрсәләрдән имтихан бирүебез дә истә калмаган, әмма берсе, иң куркытканы, хәтердә әле булса саклана. Бу — рәсем буенча иде, ягъни рәсем ясап күрсәтергә тиеш идек без... Ә миндә рәсем ясауга бер дә сәләт юк, булса да бик зәгыйфь... Бала чакта кеше башы белән песи башын (болар бер-берсенә бик охшаганнар) алама гына сызгалап маташуны исәпләмәгәндә, мин рәсем ясау белән юньләп шөгыльләнмәдем дә һәм чынлап мавыкмадым да... Ләкин шунда ук сездә: «Алайса, ни пычагыма монда килеп кердең?» — дигән сорау үзеннән-үзе туа торгандыр бит инде. Нәрсә дип әйтим?.. Махсус уку йорты булгач, рәсем ясарга да өйрәтерләр дип ышанганмындыр, ахрысы. Әмма мине барысыннан элек уку йортының исеме, дәрәҗәсе, сәнгать белән бәйләнгән булуы тартып китерде бирегә... Аннары, кирә алсам, архитекторлыкка укырмын дип тә уйлаган идем. Тик менә архитекторның да рәсем ясый алырга тиешле-

ген белми идем. Хәзер инде чигенеп булмый, егетләр!.. Ни булса шул, тәвәккәлләргә туры килә.

...Иркен генә бүлмә, төрлечәрәк куелган мольбертлар, биек кенә өстәл сыман нәрсәдә гипстан эшләнгән адәм башы. Безгә берәр табак каты-калын кәгазь, йомшак кара карандашлар бирделәр. Кәгазьне кнопкалар белән мольбертка беркетергә куштылар. Ярый, монысын да эшләдек... Инде хәзер әнә шул Ходай орган адәм башын ак кәгазьгә төшерергә тиешбез. Егетләр кыю гына эшкә дә керештеләр. Ә мин торам әле, күршеләремә караштырам: ничегрәк сызалар? Шуннан мин дә бик сак кына сыза башладым... Иллә мәгәр шәп төшми, дөрес төшми сызыкларым!.. Бозам да тагын сызам... Ярый әле, безнең эшләгәнне карап йөрүче рәссам бик рәхимле кеше булып чыкты. Бер-ике мәртәбә яныма килеп, карап, менә болайрак кирәк дип, минем эшне үз кулы белән төзәткәләп тә китте. Башкаларга да әнә шулай күрсәткәләде ул. Күрәсең, зәгыйфьләр бер мин генә түгел. Бу исә минем хәлне бераз гына җиңеләйткән кебек тә булды.

Кыскасы, без барыбыз да — кайсыбыз алданрак, кайсыбыз соңрак — бу адәм башын тирләп-пешеп булса да төшереп бетердек. Безгә әле ошап та китте бу азаплану — яхшымы-начармы,— ак кәгазьдә үзебез ясаган сурәт калды. Рәссам булырга теләүнең сере дә, бәлки, шул сурәт ясау белән сихерләнүдәдер?!

Имтиханнар бетте, хәзер инде нәтиҗәне көтәргә кирәк иде. Минем үтә алуыма өметем аз, ә менә Фәтхелислам, һичшиксез, үтәчәк. Бөтен имтиханнарны да шәп бирде, хәтта рәсем буенча да... Сәләте дә зуррак, хәзерлеге дә көчлерәк иде шул аның!

Күпмедер борчылып, көтеп йөргәннән соң, ниһаять, укырга алынучыларның исемлеге чыкты. Барыбыз да шуңа ябырылдык. Иң беренче исем — Мортаза Абдуллин. Гаҗәп түгел, ул рәссам булачак егет. Бераз түбәнрәк минем фамилия дә тора, шайтан алгыры! Бу мин, әлбәттә, чөнки бүтән «Еникеев» юк керүчеләр арасында... Йа Ходa!.. Мин алынганмын, мин укыячакмын, мин — студент, мәтәлеп китим!.. Их-ма!.. Ну, конечно, Фәтхелислам да бар, Фәтхелислам да алынган, ләкин ул тыныч, ул алынасын алдан ук белеп торды... Әмма бу безнең икебез өчен дә бик зур бәйрәм!.. Әле бит бер ай элек кенә Дәүләкәннең тузанлы урамын таптап йөргәндә, Казан нинди ерак иде бездән, ә бирегә килеп, рәссамнар мәктәбенә укырга керә алу тагы да ераграк иде — инде менә тәвәккәлләгәч шөйлә генә булды да куйды, мин сиңа әйтим!

Болай ансат кына үтүебезнең сәбәбе нәрсәдә дип уйласак, моны татар яшьләренә укырга керү шартларының җиңеләйтелгән булуы дип аңларга да ярый торгандыр. Чынлап та, яңарак кына автономия алган милли республиканың һәр тармактан кадрлар җитештерү өчен уку йортларының ишекләрен киңенчә ачып куюы бик табигый иде. Нәкъ шушы елларда инде татар яшьләренең төрле яктан Казанга агылып килүе дә башланды.

Менә без дә, ике Дәүләкән егете, махсус уку йортының — рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыймарәт мастерскойларының (Архумасның) студентлары булдык. Безнең язмышыбызда моның нинди әһәмияткә ия булуын аңлап бетердек микән әле без шул чакта, әллә ул хакта уйлап та тормадык микән?.. Юк, уйлаганбыздыр, һичшиксез, уйлаганбыздыр — бу бит безнең киләчәгебез, ә киләчәк турында уйламыйча торып буламыни?! Ләкин безне шунда ук башка уйлар, башка мәшәкатьләр биләп алган иде инде. Без тизрәк Әбүбәкер абзыйлардан китәргә һәм башка студентлар белән бергә кайдадыр тора башларга тиеш идек. Ул елларда Казанда студентлар өчен торак йортлар аз иде. Күп кенә хәллерәк студентлар хосусый йортларда бүлмә яки почмак алып торалар иде. Архумасның торагы бармы-юкмы икәнен без әле белми дә идек. Ләкин имтиханнар бетеп, кабул ителгән студентлар үзләренә торыр урын сорый башлагач, безнең барыбызны да кемгәдер ияртеп, бер йортка җибәрделәр. Бу ике катлы, ал төскә буялган кирпеч йорт хәзерге Ирек мәйданы артында, Касаткин белән Бассейнный урамнары чатында иде. (Соңгы елларда гына, КПСС өлкә комитетының икенче бинасы салынгач, андагы йортларны рәте белән сүттеләр.) Нindидер байдан калган чибәр генә йортның икенче катына барып кердек. Бишме-алтымы тәрәзәсе урамга караган, шар тәгәрәтерлек шыр ялангач бер зур зал иде бу... Менә шушында урнашыгыз, диде ияртеп килүче безгә. Без күп түгел идек, уникеләп кенә кеше, барыбызга да урын җитәрлек иде.

Шул ук көнне без, Фәтхелислам белән икәү, берничә атна буена безгә җылы урын биргән Әбүбәкер абзыйлардан, һәммәсенә дә рәхмәтебезне әйтеп, шушы шәрә залга күчеп тә килдек. Берәм-берәм башка егетләр дә, капчык-кәрзиннәрен күтәреп, килеп җиттеләр. Ләкин безгә уку йортыннан берниндиурын-җир нәрсәсе бирмәделәр. Караватта юк, матрас та, одеял да юк,— үзегез табыгыз, диделәр. Әйтергә кирәк, безнең Архумас укучыларын тәэмин итү ягыннан вообще бик хәерче булып чыкты. Без моны бик тиз татый башладык... Ә хәзер исә һәркем

үзенә яту урыны әмәлләргә кереште. Ул чакта Бассейнный урамында кечкенә базар бар иде. (Аны яһүд базары дип тә йөртәләр иде шикелле.) Шунда ук тагын бер ташландык бакча да бар иде. Безнең егетләр, менә шул базардан төнлә белән бер-ике буш әрҗә күтәреп яки бакча рәшәткәсен каерып алып кайтып, үзләренә тапчан кебек нәрсә әмәлләделәр. Фәтхелислам белән без дә каяндыр зур гына бер ишек күтәреп кайттык. Ике кузла ясап, шуның өстенә ишекне салдык... Менә икебезгә бер «карават» та булды. Таррак инде, ләкин җылырак булыр, дидек. Соңрак шул ук базардан ике капчык «табып», аларны сүтеп, яңадан икесен бер итеп һәм шуңа әйбәт кенә печән-салам тутырып, матраслы да булдык. Шулай итеп, һәркем үзе белгәнчә һәм тапканча әкренләп үзенә ятар урын әзерләде. Тик Самар егете Гата Юсупов кына әрҗә урлап, тапчан ясап тормады, каяндыр тапкан озын капчыкка салам тутырды да, шуны стена буена сузып салып, өстенә менеп ятты. Бердән, иркен, икенчедән, ишелеп төшү куркынычы юк, диде ул... Гаҗәп ваемсыз егет иде бу Самар мишәре... Ә менә икенче бер иптәшебез байларча дип әйтерлек урнашты. Бу Оренбурдан килгән Рәхмәтуллин фамилияле, барыбыздан да яшькә шактый олы бер абзый иде. Ул инде хатынлы да, балачагалы да кеше икән, ләкин, шуңа да карамастан, аның укып, рәссам буласы килгән. Күрәсең, үзендә ниндидер оеткы барлыгын сизгәндер инде. Өеннән дә ул нык хәзерләнеп чыккан — кием-салым да бик бөтен, өстәвенә мамык мендәре белән кызыл тышлы сырган юрганы да бар иде. Каяндыр тимер караватта табып китерде. Урынның да әйбәтен сайлап алды. Кыскасы, төпле урнашты бу абзый!..

Әмма без үзебезгә ничек кирәк шулай урын хәстәрләсәк тә, зур залыбызның җитешмәгән җирләре бик күп иде әле. Бер урындык заты юк, бөтенебезгә бер өстәл юк, су алып керергә чиләгебез юк — кыскасы, юктан башка берни дә юк! Бигрәк тә нык борчыганы — залыбызны яктырту белән җылыту мәсьәләсе иде. Көннәр бит һаман кыскара, әкренләп суыкларга таба бара. Заманында нәрсә белән яктыртылгандыр инде бу зал, Хода белсен, хәзер исә түшәм уртасындагы калкытып эшләнгән түгәрәк эченнән таза тимер ыргак кына тырпаеп тора. (Хуҗалар вакытында аңа зур якты лампа эленгән булгандыр, мөгаен.) Димәк, гади генә булса да, «керәчин» лампасы табарга кирәк. Залның бер почмагында зур голанка миченең биек аркасы чыгып тора. Авызы баскычка чыга торган алгы бүлмәдә... Рәхмәтул-

лин абзый, мичне җентекләп карагач, бу, егетләр, безгә ярый торган мич түгел, диде. Моны җылытыр өчен көн дә ярты йөк утын кирәк булачак, имеш... Хуш, ә нишләргә соң?.. Зал уртасына бәләкәй генә бер мич салмыйча булмас, ахрысы, диде Рәхмәтуллин абзый, бераз башын кашып торгач. Ә материалын кайдан табарга: кирпеч, балчык, комын?.. Әмма, чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, дип белмичә әйтмәгәннәр икән. Эзләнә-йөри торгач, барысы да табылды ахырда... (Кирпечне, мәсәлән, Архумасның үзеннән табып китердек.)

Мичне Рәхмәтуллин абзый үзе салырга булды. Калагын да, чүкечен дә каяндыр тапкан... Киндер алъяпкычын бәйләде, җиңен сызганды һәм эшкә дә тотынды. Без аңа измә ясап, кирпеч биреп тордык, ә ул зал уртасына бәләкәй мичне җыйнак кына иттереп, ике көндә салып та куйды. Өстенә карап кына торырлык. «Болай ук кирәкмәс иде!» — дигән була хәйләкәр абзый үзе дә.

Хәзер безнең мичне теге зур мичкә илтеп тоташтыру өчен калай трубалар табу мәсьәләсе алдыбызга килеп басты. Искергәннәр ярамый, таза булырга тиешләр. Ләкин бит трубалар җирдә аунап ятмый, кайдан аларны табарга?.. Хәер, унике кеше эзләргә тотынгач, табыла икән анысы да... Берничә көннән егетләр табып китергән трубаларны Рәхмәтуллин абзый бер-берсенә ялгап, әлеге зур мичнең аркасына илтеп кертте. Аннары, бисмилласын әйтеп, ягып та карады. Бәләкәй мичебез күңелле генә гөрләп яна да башлады. Ни әйтәсең оста кешенең эшенә?! Димәк, җылы булачак. Шулай итеп, гаять мөһим бер мәсьәләбез хәл ителде. Икенче бик мөһиме — утын мәсьәләсе иде. Утынны безгә беркайдан да бирмәячәкләр иде. Без аны бары үзебез табарга тиеш идек. Һәм без һәркайсыбыз барган-йөргән җиребездән ягарга ярарлык бөтен нәрсәне күтәреп кайта торган булдык. Бигрәк тә каршыбызда гына базар булуы безнең хәлне күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйтте... Әнә шулай торып киттек без байлардан калган таш йортның зур залында!

...Без унике кеше идек, дидем мин... Кемнәр иде алар? Уникегә туламы? Алтмыш елдан соң берәмләп искә төшерүе дә бик читен. Һәрхәлдә, күпчелек татарлар иде. Барыбыз да быелгы набор, әмма төрлебез төрлечә — яшь, кыяфәт белән генә түгел, характерлар белән дә. Берәүләребез аралашырга, якынаерга ярата, икенчеләребез читтәрәк торуны, ялгызрак булуны артыграк күрә. Берәүләр бик хәрәкәтчән, күп сөйли, икенчеләр сүзгә аз катнаша, тыңлап кына тора... Матди яктан да шулайрак — берәүләрнең өс-башы да бөтен, кесәсе дә буш түгел. Ә

икенчеләрнең фәкыйрьлеге йөзенә бәреп чыккан диярлек.

Мин инде Рәхмәтуллин абзый турында әйтеп үттем, тик менә исемен генә хәтерли алмыйм, Ибраһим түгел иде микән?.. Арабызда яшькә иң олы бу абзый иң дәртле һәм иң эшлекле бер кеше дә иде. Үзе буйга тәбәнәк, юантык, ләкин гаять хәрәкәтчән, хәтта көлгәндә дә тыела алмыйча үкчәсе өстендә бер әйләнеп куя торган иде.

Арабызда яшькә олырак тагын берәү — бу Мәсәгутов фамилияле Царицын егете... Исеме Зиннур иде бугай, шулайрак истә калган... Бик чибәр егет иде ул. Уртадан калкурак бик төз буйлы, ак чәһрәле, коңгырт чәчле, озын керфекле — аның бу матурлыгында әз генә Христоска охшашлык та бар иде кебек... Тик менә хәрәкәткә сүлпән, сүзгә саран, беркемдә дә эше юк, бары үзен генә белә — шулайрак тоелды ул безгә баштарак. Хәер, без аны сирәк күрә идек, чөнки иртә тора да каядыр китә, кич кенә кайтып тапчанына сузылып ята торган иде. (Мич киртләчендәге калай лампаның яктысы бик зәгыйфь, зал ярым караңгы, укып яки язып утырырлык түгел иде.) Ләкин тора-бара бу егет безгә күп яклары белән ачылды. Иң элек шуны белдек — ул Татар коммунистлар университетында (мәшһүр ТКУда) даими художник булып эшли икән. Плакатлар, лозунглар яза, стена газетасын чыгара, көне дә, ашау-эчүе дә шунда үтә. Мохтаҗлыкны белми диярлек. Әмма болардан да бигрәк, безнең матур егетебез, хәзергечә әйтсәк, күпкырлы талант иясе дә булып чыкты. Рәссамчылыктан башка тагын шигырь-поэмалар да яза, скрипкада да чибәр генә уйный, шулар өстенә ул бик оста сөйләүче дә икән әле. Туган якларын, татарларның ничек яшәүләрен, балык, җиләк-җимеш байлыкларын, аннары, шуларга ялгап, даладагы бакчаларда карбыз саклап ятканда марҗа кызларының аңа сагыз булуларын, әтисенең «малайны харап итәләр бит» дип һаман борчылуын бик кызык итеп кичләрен безгә сөйли торган иде. Тәрәзәләр зур, лампа зәгыйфь, бөтен әйләнәдә су эчен хәтерләткән серле ярым караңгылык — шунлыктандырмы аның әкиятләрен күпме тыңласаң да ялыктырмый иде. Кыскасы, без Мәсәгутовны яраттык. Ачык, гади, ягымлы, өстенлекләре белән масая да белми...

...Безнең торактагыларның барысы да диярлек әнә шундый интересный кешеләр, ягъни бер-берсенә охшамаган, һәркайсы үзенә бер тип иде. Мәсәлән, шул ук Гата Юсупов... Арабызда ул иң сәләтле һәм иң ярлы егет иде. Әмма һич кайгыра, борчыла белми торган бер пошамансыз!.. Бөтен эше — салам тутырган капчыгы өстенә

утырып, катыргы тышлы альбомына рәсем ясау... Күзенә ни күренсә, шуны ясый да утыра. Шәп карикатурист булмакчы иде ул... Аның төбе кубып, «авызы» ачылып торган ботинкалары бар иде. Шуның иң алама бер сыңарын каты кәгазьгә бик охшатып ясады да баш очына «Бу минем портретым!» дип кадаклап та куйды... Әнә шундый әкәмәт кеше!

Ләкин уникe кешенең һәркайсы турында болай яза китсәм, артык озынга сузылыр дип куркам. Тизрәк уртак мәсьәләләргә күчәсе килә... Тик шулай да бер егет — Мортаза Абдуллин турында кыска гына әйтеп китмичә булмас, ахры... Без — якташлар, яшьләребез дә бер чама, билгеле, без тиз якынайдык. Дөрес, башта талаштык, сугыша да яздык (ул минем язып маташуымнан көлгән иде), ләкин барыбер дуслашып киттек. Һәм бу дуслык бервакытта да өзелмәде. Архумаска бергә кергән егетләрнең бөтенесен дә диярлек мин әкренләп югалтып бетердем, тик ике кеше — Фәтхелислам һәм Мортаза белән генә якын бәйләнеш аларның соңгы гомерләренә чаклы дәвам итте.

Архумасны (соңыннан техникумны) бетерүчеләрдән бары Мортаза гына Ленинградтагы Художество академиясенә укырга киткән иде. Шунда дүрт ел укып кайткач, ул Татар академия театрында башта художник-декоратор, аннары баш художник булып эшләде. Менә шул чакларда без аның белән тагы да ныграк дуслашып киттек. Мортаза, ничек дим, бик оригиналь кеше иде. Кыяфәте үк башка, сәнгать әһеле икәнен әллә кайдан ук күрсәтеп тора: бик матур тарап куйган чем-кара бөдрә чәч, куе кара кашлар, ә йөзе кершән яккандай ап-ак! Үзен ул зәвыклы ханымнар шикелле карый иде, бик көяз иде, иң соңгы мода белән бик пөхтә киенергә ярата иде. Шуның өстенә Мортаза гаять үзсүзле, бик принципиаль бер кеше дә иде. Аңа җайлашуы җиңел түгел... Шул кискен характеры аркасында еш кына кешеләр белән бозылыша да торган иде. Әмма эчкерле түгел, ачу сакламый, яңадан берни булмагандай дуслыкны яңартырга әзер... Асылда, ул нечкә-йомшак күңелле иде — аның шулай икәнен миңа күп күрергә туры килде. Малай чагыннан ук уйнарга өйрәнгән скрипкасын ул бервакытта да үзеннән калдырмады. Әйтергә кирәк, татар көйләрен Мәсәгутовка караганда нечкәрәк тоеп, дөресрәк, үтемлерәк итеп уйный торган иде. Аеруча яратып уйнаганы «Минзәлә» көе иде мәрхүмнең...

Сугыш алдыннан Мортаза ни өчендер Казанны ташлап, Мәскәүгә китте. (Мин дә бу вакытта читтә идем.)

Сугыш башланып, армиягә алынгач, ул Фрунзе академиясендә художник булып эшләде. 1943 елның көзендә кыска гына вакытка фронттан Казанга кайтышлый без Мәскәүдә очраштык. Төне буе анын бүлмәсендә, каяндыр тапкан спиртын әз-әзләп кенә эчеп һәм салкын бәрәңге, әче суган белән закусить итеп, керфек тә какмыйча сөйләшеп чыктык. Бу безнең иң соңгы очрашуыбыз булды... Художник Мортаза Абдуллин 1945 елның, ялгышмасам, көзендә саркомадан үлеп китте — бары утыз биш яшендә! Дөнья шулай да вафасыз...

Ә хәзер яңадан үлемнең нәрсә икәнен дә белмәгән тап-таза, ять-яшь чакларыбызга кайтыйк әле. Караңгылы-яктылы залыбызда шаулап ятабыз, дәрт-теләк, уенкөлке хәттин ашкан, әмма... Әмма ләкин хәлләребез, дөресен генә әйткәндә, шәптән түгел иде. Менә инде сентябрь үтеп бара, ә безгә әле булса стипендия биргәннәре юк. Бик кысып кына тоткан акчаларыбыз чыгып бетте диярлек... Ашау яклары бик хөртиләнде. Җылы ашны атналар буенча күрмибез, бөтен ашаганыбыз пеклеванный икмәк белән көйгән касмаклы, кайнаткан сөт... Икмәкне чаттагы яһүд кибетеннән, ә сөтне йорт каршында гына сатып утырган марҗалардан алабыз. Күпме ашасаң да биздерми торган тәмле, туклыклы ризык... Аратирә мич авызында гына чәй кайнатып эчәбез.

...Лекцияләргә йөргән булабыз, мастерскойга йөргән булабыз, ләкин ачлы-туклы хәлдә укып маташуның бер дә кызыгы юк иде. Аптырагач, эш эзли башладык. Берәүләр каядыр йөк бушатырга китәләр, буявы, пумаласы булганнар вывеска-мазар язу кебек эш табалар, кыскасы, берәү дә тик ятмый, тамак кайгысы һәркемнең дә башына төшкән иде. Арада иң тук яшәгән безнең Рәхмәтуллин абзыебыз да Архумасның үзендә үк бер зур мичне сүтеп салу турында сөйләшеп кайткан иде (оста кешегә эш аяк астыннан да табыла икән). Үзенә ярдәмчеләр итеп ул Фәтхелислам белән мине алды. Атнадан артык без шул пычрак эшкә йөрдек. Башта сүтелгән мичнең ватыгын носилка белән ташый-ташый, аннары зур ялгашта көрәк белән бутап измә ясый-ясый куллар кабарып бетте. Минем мондый авыр эшкә беркайчан да җигелгәнем юк иде әле. Акчасы күпме генә булгандыр инде, әмма тәмам ватылып, тузан-пычракка батып эшләү бик туйдырды мине...

Стипендия мәсьәләсендә берничә тапкыр кәнсәләриягә кереп, сөйләшеп тә карадык. Эш бездән тормый, Наркомпростан тора, ул һаман суза бу мәсьәләне, диделәр безгә. Шуннан соң бер кичне җыелышкач, укучылар исе-

меннән Наркомпроска вәкил җибәрергә кирәк дигән фикергә килдек. Ләкин кемне? Берәүнең дә ни өчендер барасы килми. Рәхмәтуллин абзыйны, син олы кеше дип, кыстап карыйбыз, юк, якын да килми — янәсе, ул нәчәлниклар алдына барып, соранып йөрергә яратмый. (Тамагы тук, шуңа күрә яратмый торгандыр.) Ахырда Мамлеев дигән берәүне кыстый башладык. Дөрес, ул безнең зиннәтле залыбызда тормый, килеп-китеп кенә йөри, ләкин шома егет, русчасы да шәп, кыяфәт тә шәһәрчә — башында эшләпә, өстендә киң путалы сары пальто. Риза булды, тик иптәшкә кеше сорады — «ату берүземә генә скучно!» диде... Шуннан иптәшләр миңа ябыштылар: давай да давай, син җиңел сөякле, син йөрергә иренмисең, имеш... Минем, чынлап та, җәмәгать эшләре белән йөрүдән тәм таба торган чагым иде — артык кыстатмыйча, теләп диярлек риза да булдым.

Мамлеев белән без Наркомпроска ике тапкыр бардык. Наркомның үзенә үк, билгеле, керә алмадык. Ләкин шулай да, коридорда күпмедер таптанганнан соң, зуррак кешеләрнең берсенә кереп, авыр хәлебезне сөйләдек. Зур абзый безне тыңлады тыңлавын, әмма сүзен бик кыска тотты: юкка килеп йөргәнсез, егетләр, мөдирегез барысын да белә, кайтыгыз да аңардан сорагыз, ул аңлатыр, диде. Әлбәттә, мондый киңәш белән кайтып, иптәшләрне тынычландырып булмаячак иде, шуңа күрә без икенче көнне үк Кремль тарафларына тагын юл тоттык. Һәм бу юлы инде туп-туры Наркомпросның бухгалтериясенә барып кердек. Хәлебезнең никадәр авыр булуын сөйләп биргәч, андагы баш кеше безгә кыскача гына аңлатты: стипендия мәсьәләсе карала, тикшерелә, хәл ителергә тора, көтегез, тиздән алырсыз, диде... Волокита дигән нәрсә ул заманда ук шактый тамыр җибәреп өлгергән иде инде, шулай да карала, тикшерелә, тиздән алырсыз дигән сүзләр безне беркадәр тынычландырды. Торактагы көтеп ятучылар янына кайткач та, без аларны шул ук өметле сүзләр белән куандырырга тырыштык.

Тагын күпмедер көткәннән соң, ниһаять, стипендия мәсьәләсе хәл ителде. Тиздән исемлек игълан ителәчәк, диделәр безгә... Анысын гына көтәргә була... Һәм, берничә көн үтүгә, ул исемлекне дә чыгарып элделәр. Барыбыз да шуңа ябырылдык. Озак зарыгып көтүдәндер инде, берәү дә стипендиясез калу ихтималын, билгеле, күңеленә дә китерми иде. Әмма... бу ни хәл? — исемлектә бары минем генә фамилиям юк... Кат-кат исемлек буйлап карап төшәм — юк кына бит!.. Тәмам аптырадым, бер читкәрәк киттем, ни уйларга да белмим. Әллә

ялгыш төшереп калдырдылар микән?.. Кәнсәләриягә кереп, әдәп белән генә ни өчен исемлектә минем фамилиям юк икән дип сорадым. Һәм миңа әйттеләр: комиссия сезгә, хәлле кешенең баласы булганга күрә, стипендия бирүне кирәк дип тапмады, диделәр... Менә шул... Ә уку?.. Укырга хакыгыз бар, ләкин стипендиясез генә.

Моны ишетеп чыгу миңа бик авыр булды. Минем җылыйсым килде, ә бәлки, җылаганмындыр да, хәзер инде искә төшерүе бик читен... Хикмәт монда бер мине генә мәхрүм итүдә генә түгел иде — стипендиясез калу минем хәлемне бик нык читенләштерәчәк тә иде. Укуны, ихтимал, ташларга да туры килер, чөнки өйдән мин ай саен акчалата ярдәм көтә алмый идем. Өйдәге хәл миңа ачык: атакай сәүдәсен ташлады, әйтергә кирәк, бөлеп туктады, шуңа күрә дә тимер чыбыктан элгечләр, таба аслары үрергә тотынды. Йә, мондый хәлдә мин өйдән нинди генә ярдәм көтә алам?.. Юк, булмас, ышаныч бик аз... Әйе, төште башка авыр хәсрәт...

Көне-сәгате белән аңлап җиткермәсәм дә, бу минем социаль чыгышым аркасында күргән беренче бәхетсезлегем иде, өметләремнең беренче мәртәбә какшавы иде. Алай гына түгел, шактый озак елларга сузылган ачы язмышымның башы да булган икән ул... Тик мин әле моны уема да китерә алмый идем — миндә бары бүгенге көн кайгысы гына иде.

Егетләр беренче стипендияләрен алып кайттылар. Торакта бүген бәйрәм. Әмма ләкин эчү юк, бары тик ашау гына. (Эчүгә акча әрәм итүдән бигрәк, аның «тәмен» белгән-татыган кеше дә юк.) Иң мөһиме — туйганчы бер ашап калу һәм төрлесеннән авыз итү... Ак калач, ак май, каймак, хәлвә, ат казылыгы — моңарчы бик сирәк эләгә торган әнә шундый ризыклар... Әлбәттә, болай сыйлану бары бер генә тапкыр, чөнки бу стипендиянең һәр тиене исәптә (ялгышмасам, ул аена 9 сум иде шикелле). Ә студент, ач утырасы килмәсә, исәпли белергә тиеш.

Фәтхелислам да үзенең кадерле стипендиясен алып кайтты. Моңарчы безнең бөтен нәрсәбез, өстәге киемнән башкасы, һәрвакытта уртак булды. Бергә таптык, бер табактан ашадык. Хәзер дә ул шулай булып калды. Ләкин күпмегә кадәр?.. Һәрхәлдә, бер стипендиягә икәү яшәп булмаячак. Моны икебез дә беләбез, тик Фәтхелислам бу хакта бер сүз дә әйтми, димәк, минем үземә үз хәлем турында чынлап уйларга кирәк булачак.

Тукай урамы белән Париж коммунасы чатында таштан салган ике катлы зур гына күк йорт тора. Кайчан-

дыр ул «Бөрадарән Кәримовлар» матбагасы булган диләр, ә хәзер ниндидер тегү фабрикасының бер цехы бугай. Каршы чатта Галимҗан Баруди мәчете, аның күршесендә генә элекке «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең кирпеч биналары... Хәер, мин боларны соңыннан гына белдем. Ә менә чаттагы күк йорт белән тиз танышырга туры килде. Әллә ишетеп, әллә йөргәндә туры килеп, шул йортта китапханә барлыгын белдем. Билгеле инде, мин аңа кермичә уза алмадым. Һәм вакыт тапкан саен баргалап йөри дә башладым. «Шәрекъ китапханәсе» дип атала иде ул... Көзге кыска көннәр, озын күңелсез кичләр, барыр җир юк, эч поша, торак салкын һәм караңгы — менә мин якты эзләгәндәй шул китапханәгә барып, аның икенче катындагы тыгызрак, әмма бик тыныч, җылы залында утырырга ярата идем. Миңа калса, бу китапханә бик бай иде, бөтен иске һәм яңа әдәбият бар иде, революциягә хәтле чыккан барлык газета-журналлар анда саклана иде. Нәрсә генә сорасаң да бирәләр — ярамый, тыелган дип әйтү юк иде. Яңа килгән газеталарны карап чыккач, мин әнә шул иске журналларны ала торган идем. Бигрәк тә «Аң»ны карарга ярата идем. Яхшы кәгазьгә бик ачык басылган, рәсемнәре дә ачык төшкән — укырга кызыклы, күңелле, җиңел иде. Гарәп хәрефләре өйрәнер өчен, бәлки, авыр булгандыр, әмма бер өйрәнгәч үзеннән-үзе гаҗәп тиз укыла иде. Укый идек барысын да — искесен дә, яңасын да.

Китапханәгә йөрүчеләр әллә ни күп түгел иде. Берничә бабай, берничә кыз, тагын минем кебек яшьләр... Шушы соңгылар арасында мин барган саен бер егетне күрә идем. Ул да даими йөрүче, шулай ук иске газета-журналларны актарырга ярата. Ихтимал, шуңа күрәдер минем игътибарымны җәлеп итте бу егет... Миннән берничә яшькә олырак булыр, таза-төз гәүдәле, зур битле, күз кабаклары төшебрәк тора, кыскасы, матур түгел, әмма чын ирләргә генә хас ниндидер бер тарта торган көч бар үзендә... Очрашып, бер-беребезне күргәләп йөри торгач, без ахырда танышып киттек. Рабфак студенты икән, фамилиясе Ярмиев икән. (Исемен ни өчендер әйтмәде.) Беренче сөйләшүләрдән үк аның татар әдәбиятын — искесен дә, яңасын да — бик яхшы белүе ачыкланды. Гомумән генә түгел, җентекләп белә: кем кайчан нәрсә язган, кем кемне тәнкыйтьләгән яки кем кем белән бәхәсләшкән,— кыскасы, күп нәрсәдән хәбәрдар булып чыкты. Бу хәл мине аңа бик тиз якынайтты, ешрак күрәсе килә башлады, ә аның белән сөйләшүе ничектер бер күңел ихтыяҗына әйләнде. Әнә шулай очрашып, сөйләшеп йөри

торгач, без ансат кына дуслашып та киттек. Бу 1925 елның шыксыз көзендә булды, ә хәзер ничәнче ел — 1985 елга кердекме? — менә шуннан бирле бу дуслыкның өзелгәне юк. Алтмыш ел гомер... Япь-яшь егетләр идек, инде карт бабайлар булдык. Шушы озын гомер эчендә без бары сугыш вакытында гына бер-беребезне күздән югалтып тордык. Сугыш беткәч тә янә табыштык. Ләкин арабыз ерак, ул — Ташкентта, мин — Казанда. Әмма бу нәрсә безнең дуслыкны һич кенә дә киметмәде, киресенчә әле, саф итеп, нык итеп саклады. Мин, Ташкентка барсам, аны күрер өчен бардым, ул, Казанга кайтса, иң элек мине күрер өчен кайтты.

Кем соң ул минем шундый озын гомерле дустым? Таныш булыгыз — Габдерәхим Каюм улы Ярмиев, элекке Зөя өязе Олы Урсак авылында 1906 елны туган. Казанда Госрабфакны бетерә, Иваново шәһәрендә энергетика институтын тәмамлый. Инженер-электромеханик. Казанның яңа электростанциясендә дүрт-биш ел эшләгәч, Ташкентка күчеп китә. 1941 елдан партия әгъзасы. Тирән белемле, киң эрудицияле, шуның белән бергә бик гади, үтә гадел, намуслы кеше. Тик кызганыч, бөтен гомерен ул өйләнмичә, ялгыз буйдак булып уздырды. Болай «утырып» калуының сәбәбе, әйтүенә караганда, чынлап торып ярата алырлык хатын очрата алмаган... Тоже характер, әйтсәм әйтим! Картайгач та күнегеп беткән шул ялгызлыгыннан котылырга теләмәде. Бу хакта бәхәсләшеп киткән чакларыбыз да булгалады. Әлбәттә, мәхәббәтнең зарурлыгын мин дә инкарь итмим, ләкин картлыкның үз таләпләре бар бит әле... Картлык өчен иң хәтәре — ялгызлык!

«Вөҗдан» дигән әсәремне язганда, төп геройның прототибы итеп беркадәр аны, Рәхим дусны, күздә тоткан идем. Чөнки минем героем Ташкентта яшәүче ялгызак кеше булырга тиеш иде. Аннары алдауны, хыянәтне без икебез дә бер үк дәрәҗәдә яратмый идек.

...Теге чакта «Шәрекъ китапханәсе»ндә бары ике кеше эшли иде. Берсе аның, олырагы — озын гына буйлы чандыр кеше — китапханә мөдире. Икенчесе — тәбәнәгрәк буйлы, түгәрәк битле, зур соры күзле егет — китаплар биреп торучы. Баштарак мин аларның исем-фамилияләрен дә белмәдем, ләкин алар мине, еш килеп йөргәнгә күрәдер инде, таныйлар иде бугай. Чөнки көннәрдән бер көнне әнә шул китап биреп торучы үзе минем белән сүз башлады.

Әйтергә кирәк, минем хәлләр шәптән түгел иде. Матди ягым бик начарланды. Өйгә язып карадым. Аннан

күпмедер акча килде, ләкин бу юлга дип җибәрелгән акча иде. Хатларында бик үтенеп, миңа кайтырга кушканнар: «Өйгә кайтуның ояты юк, кайт, балам, насыйп булса, киләсе елда тагын барырсың»,— дигәннәр. Әмма минем Дәүләкәнгә һич тә кайтасым килми, ничек кенә юатмасыннар — оят бу... Андагы иптәш малайларга кайтуның сәбәбен ничек аңлатырга? — дөресен әйтергә көчем җитмәячәк, алдашырга телем бармаячак. Аннары малай халкы ышанмаячак та.

...Бик аптыраган көннәрдә Әбүбәкер абзыйларга кереп чыга идем. Ник кергәнемне юньләп аңлата да алмыйм, дөресен генә сөйләргә көчем дә җитми, ләкин алар өстемә карап дигәндәй хәлемне аңлыйлар иде шикелле. Миһербанлы асрау апа шунда ук мине кухняга алып кереп, ашарга утырта, ә Әминә апа чыгып киткән чагымда: «Йә, укулар ничек бара соң?» — дип юри сынагандай сораган була, мин исә башымны читкә борып кына: «Ярый, хәзергә әйбәт кенә бара»,— дигән булам. Шуннан ул башта ук учында тоткан берничә көмешне миңа тоттырып җибәрә иде. «Рәхмәт»,— ди идем мин көчкә генә, ә баскычларыннан төшкән чакта яшьләремне тыя алмый идем.

...Юк, ярамый болай, оят болай... Каңгырып йөрүне ничек тә бетерергә кирәк. Бердәнбер чара — тотарга да эшкә керергә!.. Башкача булмый, башкача мөмкин түгел. Уку кала икән — калсын (барыбер миннән рәссам чыкмас инде), җәйгә чаклы эшләрмен дә башка берәр уку йортына керергә тырышырмын. Әле вакыт узмаган, солдаттан кайтып та укыйлар хәзер.

Ниһаять, әнә шул карарга килдем мин һәм шул максат белән берничә мәртәбә хезмәт биржасына да бардым. Хәзерге укучыга, бәлки, сәер дә тоелыр, ул елларда Казанда эшсезләр күп иде, алар өчен хезмәт биржасы дигән нәрсә дә бар иде. Аның урнашкан җире Некрасов урамы чатыннан аз гына югарырак, хәзерге Куйбышев урамындагы өч катлы таш йортта иде. Эшсезләр һәр көнне иртән менә шул йорт каршына җыела торганнар иде. Тәгаен бер сәгатьтә биржадан кулына кәгазь тоткан кеше чыга да кай җиргә нинди эшчеләр кирәклеген кычкырып әйтергә тотына. Һөнәре туры килгәннәр шунда ук кулларын күтәреп, башкаларны этә-төртә тизрәк дәшүче янына барып басалар. Ләкин моның ише «бәхетлеләр» аз була иде — йөзләгән кешедән бер ун-унбишләп кенә... Биржа кешесе кулындагы кәгазен укып бетергәч, үзенә яраклы эш-урын чыкмаганнар сүлпән генә тарала... Һәр көнне иртәнге якта шушы хәл кабатлана. Эш көтүчеләр-

нең күбесе дәү агайлар, минем кебек «мыексызларга» таләп бөтенләй юк диярлек. Барган саен мин аннан бик өметсезләнеп кайта идем.

Әнә шулай бик аптырап йөргән чагымда, әлеге китап биреп торучы абый үзе минем белән иплэп кенә сүз башлады. Кайдан килүемне, кем булуымны сорашырга тотынды. Ул, ахрысы, минем авыр хәлемне чамалагандыр... Шуңа күрә мин аңа, үзе башлап кызыксынгач, барысын да яшермичә сөйләдем дә бирдем... «Инде ни эшләргә уйлыйсың?» — дип сорады ул миннән. Эшкә керергә теләвемне, көн дә эш эзләвемне әйттем мин аңа... Хәзер инде тәгаен генә искә төшерүе читен — әллә шул ук көнне, әллә икенче килүемдә бу абый мине теге өлкәнрәк абзый янына алып керде дә, кыскача гына нинди хәлдә калуымны аңлатып, егеткә ничектер ярдәм итәргә кирәк иде бит, диде. Шуннан алар тагын бераз үзара сөйләшкәч, өлкән абзый миңа сынабрак карап, исем-фамилиямне сораганнан соң, кулыма записка язып бирде. «Энем,— диде ул, бик ачык итеп,— менә бу записканы Проломный урамындагы китап магазинының мөдире иптәш Рәҗәповка илтеп тапшыр. Магазинның кайда икәнен беләсеңме?.. Белсәң, сыздыр... Рәҗәпов абзаң сиңа, бәлки, берәр эш табар».

Мин, чын ихластан рәхмәтемне әйтеп, тизрәк урамга ашыктым. Ләкин вакыт соң иде инде, магазиннар ябылган, караңгы торакка гына кайтырга туры килде. Нинди өметләр белән кайтуымны берәүгә дә сиздермәдем, хәтта Фәтхелисламга да. Булып бетмәгән эш турында алдан кычкырудан мин инде саклана башлаган идем... Төне буе адашып йөрүләр белән бәйләнгән буталчык төшләр күрә-күрә үткәргән начар йокыдан соң, иртә генә торып, бозлы су белән битне чылаттым да, канатлар үскәндәй, магазинга йөгердем. Билгеле, ашыкканмын, магазин тирәсендә әле бер җан иясе юк, аның ачылганын урам таптый-таптый көтеп алырга туры килде.

Хәзерге китап магазины белән бутамас өчен әйтергә кирәк, ул чактагы китап магазины Проломный (Бауман) белән Лобачевский урамнары чатындагы таш йортның беренче катында иде. Барлык йортларның аскы катлары шикелле үк бу да ниндидер купецлардан калган магазин булырга тиеш — эче тулы шүрлек, тәрәзәләре тоташ пыяла. Күптәннән инде монда беренче номерлы гастроном, ләкин аның китап магазины булган чакларын белүчеләр бардыр әле. Утызынчы елларның башларына чаклы яшәде ул. Ә урам аша чатта (хәзерге Татар ашлары йорты урынында) канцелярия һәм уку әсбаплары белән

сату итә торган икенче бер кечерәк магазин бар иде. Соңыннан бу магазинны да ашханәгә (әллә кафега) әйләндерделәр.

Магазин ачылгач, эченә кергәч, сатучыларның берсе миңа Рәҗәповны күрсәтте. Янына бардым, исәнләштем, записканы бирдем... Һәм карап торам, көтеп кенә түгел, беркадәр гаҗәпләнеп тә, сокланып та. Ничектер бигрәк пөхтә, чиста, көяз кеше икән. Өстендәге киемнәре дә элекке яшь купшы байларныкы шикелле — бик килешле утырган кара-зәңгәр бастон костюм, кардай ап-ак күлмәк, зур гына кара бантик, ә аякларында ялт иткән шиблетлар... (Болай киенүчеләр ул елларда бик сирәк очрый иде.) Мин шунда ук, бу абый электән үк китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән белгечтер, дип уйлап куйдым. Шундый фартовый кеше булуына карамастан, ул минем белән бик гади сөйләште. Башта записканы укыгач, үзалдына бераз: «Так, так!» — дип торды, аннары: «Вафаның туганымы?» — дип сорады. «Юк»,— дидем мин, кыюсыз гына. «Ну, ярар әләсә»,— диде гүя игътибарсыз гына һәм мин аның мишәр икәнлеген сизеп алдым. Тагын сорады: «Грамотаң ничек, эшләгәнең бармы?..» «Юк»,— дидем мин янә, бу юлы инде шүрли дә башлап. Кире борса, нишләрмен?.. Ахырда абзый кеше аз гына уйланып: «Курьер булып эшләргә ризамы?» — дип сорады. Гөнаһ шомлыгына каршы, мин курьерның нәрсә икәнен белми идем. Нәрсә дим, тоттым да: «Нинди эшкә дә риза»,— дип кенә җавап бирдем. Шуннан соң бу әйбәт кеше: «Ну, ярый, брат, иртәгәдән курьер булып эшли башларсың, сәгать унга килеп җит»,— диде һәм шуның белән сүз дә бетте. Абыем үз юлы белән китте дә барды. Нинди эш, нидән гыйбарәт, айлыгы күпме — ул хакта да әйтеп тормады. Хәтта гаризаны да эшли башлагач кына яздырып алды.

Мин, әлбәттә, бик шат идем, бигрәк тә китап кибетенә эләгүемә шат идем. Миңа калса, китап сәүдәсеннән дә яхшырак, мәдәнирәк бүтән сәүдә юк иде. Монда идән себерүче булып эшләсәң дә оят түгел иде кебек... (Хәлбуки идәнне миңа еш кына себерергә туры килде.)

Хуш, ә шушы яхшы урынга мине юнәлдергән, миңа шундый зур изгелек эшләгән кешеләр кемнәр иде соң? Записка язып бирүчене башта ук белдем — ул китапханә мөдире Вафа Бурнаш дигән кеше иде. Күпмедер вакытлардан соң мин аның атаклы шагыйрь Фәтхи Бурнашның бертуган энесе икәнен дә белдем. Ә менә Вафа абзый янына мине җитәкләп алып кергән егетнең исемен озак кына белмичә йөрдем. (Үзе әйтмәгәч, мин со-

рарга кыймаганмындыр инде.) Ләкин, йөри торгач, барыбер белдем — ул Габделхәй Хәбиб дигән кеше булып чыкты. «Шәрекъ китапханәсе»ндә күпме эшләгәндер — анысын әйтә алмыйм, әмма соңыннан ул татар матбугатында эшләп, журналист булып танылды. Ватан сугышында да журналист буларак фронт газеталарында эшләде. Сугыштан соң «Чаян» журналында җаваплы секретарь булып эшләгән чагында без Хәбиб абый белән шактый ук якынаеп та киткән идек. Күп кенә әйберләрем аның кулы аша узып, журнал битләрендә басылып чыкты. Гади, ачык, шат күңелле әйбәт кеше иде, мәрхүм.

Магазин сәгать унда ачыла — эшкә соңга калу куркынычы юк. Ләкин инде кич сәгать сигезләрдә генә кайтырга туры килә. Архумас белән арам өзелде. Җан сыкранды, билгеле, әмма өмет дигән нәрсә калды — тагын көзләр килеп җитәр, насыйп булса!

Торуым исә һаман шул ук торакта, Фәтхелислам белән бергә. Син хәзер студент түгел, монда торырга хакың юк дип, ичмасам, юри генә дә әйтүче булмады. Бу торакка бергәләп түккән көч һәм бергә кичергән нужа безне тәмам бертигез иткән иде инде.

Эшли торган урынымнан, әйткәнемчә, бик канәгатьмен. Эшем китаплар арасында. Сатучылар да, алучылар да башкарак монда — мәдәни халык. Приказчикларның барысы да шактый өлкән абыйлар — үз эшләрен яхшы белүчеләр булса кирәк. Приказчик дигәч тә хосусый сәүдә икән дип уйлый күрмәгез тагын... Ул елларда Казанда матбугат һәм нәшрият эшләрен берләштергән комбинат бар иде — магазин да менә шул комбинатныкы иде. Комбинатның җитәкчесе Вәли агай Шәфигуллин иде. Мин аны күреп тә беләм, чөнки кабинеты ни өчендер шушы магазинның түрендәге бер бүлмәдә иде. Кечерәк буйлы, карасурак йөзле (әзрәк кенә шадрасы да бар иде шикелле), аз сүзле тыныч-сабыр гына бер абый иде. Хәер, болай дип читтән карап кына әйтүем: үзе белән миңа бер тапкыр да сөйләшергә туры килмәде, хәтта аның революция вакыйгаларына актив катнашкан кеше булуын да мин соңыннан гына белдем.

Тагын бер тарихи шәхес турында әйтеп үтәргә кирәктер дип уйлыйм. Беренче көннәрдән үк мин кечкенә буйлы, кечкенә сакаллы, әмма озын ак мыегын орчыктай очлы итеп бөтереп җибәргән, күзлекле, җитез бер картка игътибар иттем. Кем булып эшләгәнен ачык кына белмим, һәрхәлдә, прилавка артында китап сатып тормый. Күбрәк ниндидер кәгазьләр тотып, магазин эчендә йөри, шүрлектән китаплар сайлый, шуларны үзе пөхтәләп

төрә — күрәсең, аның эше читтән килгән заказларны үтәү булгандыр. Исеме — Шәрәфетдин Шәһидуллин... Яше белән дә, кыяфәте белән дә ул мотлак иске заман кешесе, ләкин кем булуы мөмкин?.. Мин элекке газета-журналларны чыгаручы мөхәррир һәм наширларның мәшһүрләрен укып яки ишетеп беләидем инде, мәгәр Шәһидуллин фамилиясен бер дә очратканым юк иде шикелле... Ләкин, бер җирдә эшләгәч, тиздән миңа да мәгълүм булды: ул, баксаң, революциягә чаклы, сәүдә эшләре бик көчәеп киткән бер дәвердә, «Заман» исемле, төрле мәгълүматларны үзенә туплаган зур форматлы календарь һәм «Игъланат» дигән, ягъни бары игъланнардан гына торган газета басып чыгаручы нашир булган икән... Хәзер менә совет магазинында эшли, чөнки ул яхшы белгеч, ә белгечләрне бу вакытта эшкә бик тарталар иде. Әйткәнемчә, өлгер, җитез, күңелле карт иде. Күпме эшләгәндер, язмышы ни белән беткәндер — ул кадәресен әйтә алмыйм. Араларыбыз ерак, бер җирдә эшләвебез дә озакка сузылмады, шуның өстенә тормыш та бик тиз үзгәрә торган булып китте.

Минем эшем нидән гыйбарәт?.. Иң элек мин контора яки бухгалтерия әзерләп куйган төрле рәсми кәгазьләрне таратып йөрим. Моның өчен миңа искереп беткән бер брезент портфель белән кызыл тышлы зур гына контор кенәгәсе бирделәр. Башта әзерләнгән кәгазьләрне шул зур кенәгәгә тәртип белән язып чыгам да, аннары барысын портфелемә салып, тиешле җирләргә илтеп, кул куйдырып тапшырам. Бу — минем төп эшем. Һәм курьер дип аталуым да шул эшем өчен икән. Ләкин кәгазь таратып йөрүем озакка бармый — бер ике-өч сәгатьтән бетә торган иде. Калган вакытны инде мин, кичкә кадәр, ни кушсалар, шуны эшләп үткәрәм. Мәсәлән, приказчиклар өчен самовар куям, идән себерәм, түбәннән (магазин астындагы подвалдан) югарыга китап ташыйм, яки подвалдагы упаковщикларга тюклар тегәргә булышам. Читкә озатыласы китапларны тюклар итеп ике татар абзые тегәләр иде. Мин шуларга киндерләрен җәешеп, шпагатларын сүтешеп, китапларын өешеп булыша торган идем. Аннары һәр көнне төшке чәй вакытында Рәҗәпов абыйга азык кибетеннән ак булки белән чучка ите алып кайтып бирә идем. (Нигәдер бу абый, татар булуына карамастан, французский булки белән дуңгыз ботын бик яратып ашый иде.) Приказчиклар исә өйләреннән алып килгән үз ризыклары белән чәйләрен эчәләр иде. Мин дә алар янында үз сыныгым белән шикәрләп-чәйләп дигәндәй тамак ялгап ала идем. Кайчагында алардан да

миңа таба ашы кебек тәмле өлешләр тигәли иде. Тыштан кызгану күрсәтергә яратмасалар да, алар минем хезмәт хакына барып җиткәнче ни хәлдә яшәвемне аңлыйлар иде бугай. Әйбәт абзыйлар иде, бигрәк тә Мөбарәкша дигән өлкәне бик рәхимле иде.

...Әнә шулай уза иде минем эш көннәрем. Тик тотмыйлар иде мине, ләкин шулай да бернинди эш кушмаган чаклар да булгалый иде. Мондый чакта мин берәр аулак урында, шүрли-шүрли генә булса да, китап укып утырырга тырыша идем. Бу җәһәттән магазинның файдасын шактый күрдем дияргә дә ярый — теләгән китапны алып кайтып укырга да рөхсәт итәләр иде.

Әмма ничаклы тырышсам да бик мөһим бер нәрсәне исемә төшерә алмыйм: күпме хезмәт хакы алдым соң мин?.. Моны бит онытмаска тиеш идем лә, ә менә, ни хикмәттер, онытылган. Егерме дигән бер сан башымда әйләнә әйләнүен, әллә 21, әллә 23 сум, һәрхәлдә, шуннан да артык булмагандыр, мөгаен... Ул заманда хезмәт хаклары зур түгел иде, ләкин арзанчылык аркасында бәрәкәтле иде. Мин әле шул хезмәт хакыннан үземә яңа чалбар белән ботинкалар да алган идем.

Беренче хезмәт хакын калтыраныбрак санап алу һәм шуны эчке таза кесәгә салып кую ул үзе нindидер бер тылсымга ия дияр идем. Син үсә дә төшкәндәй буласың, үз-үзеңә ышаныч та арта, киләчәгеңә дә курыкмыйчарак карый башлыйсың... Аннары ул көнне, ягъни беренче мәртәбә кесәгә акча кергән көнне, нindидер гадәттән тышрак нәрсә эшлисе килеп китә. Мәсәлән, кинога керергә, циркка барырга яки инде бик тәмле, бик күп итеп ашап чыгарга!..

Мин әле, шуларның кайсын сайларга белмичә, Рыбнорядский (хәзерге Куйбышев) урамы буйлап әкрен генә кайтып барам. Шул чакта бер йортның ачык ишегенә күзем төште. Борыныма тәмле ис тә килеп бәрелгәндәй булды. Һәм мин, уйлап та тормыйча, шул ишектән кереп тә киттем. (Бу — өч катлы таш йорт,— Кольцодан менгәндә сул якта, Татсоюзның яңа магазинын үткәч тә — түбәнге катында хәзер дә әле кечкенә кафесы бар.) Кердем, агач баскычтан туры югары катка менеп киттем. Кечкенә зал, беркем юк диярлек, беренче буш өстәлгә утыруым булды — ак алъяпкыч бәйләгән официант янныма килеп тә җитте. Ул минем бик яшь булуыма карап, ахрысы, ышанмыйчарак:

— Сезгә нәрсә кирәк? — дип сорады.

— Ашарга кердем,— дидем мин.

— Бездә ресторан.

— Булсын... Ашарга бардыр бит?
— Ә нәрсә телисез?
— Нәрсә бар соң?
Официант аш исемнәрен әйтә башлады. Ләкин алар барысы да миңа ят, берсенең дә исемен отып алырлык түгел иде.
— Первый белән второй! — дидем мин, тиз генә аның сүзен бүлеп. Официант көлемсерәп, иңбашын җыерып куйды:
— Третий да кирәкме?
— Давай анысын да!
Шулай аңлашканнан соң, официант минем алдыма көмеш чәнечке, пычак, кашыклар тезеп куйды да кухняга таба китте. Менә мин ресторанда утырам, имеш!... Күреп белсәм дә, моңарчы бер тапкыр да керергә туры килгәне юк иде әле. «Нарпит» дигән җиргә кергәләгән бар иде. Аңа күбрәк безнең ише һәр тиенен исәпләп тотучылар керәләр иде бугай. Арзан, унбиш-егерме тиенгә кәбестә шулпасы белән тары боткасы яки кәтлит алып, тамакны әйбәт кенә туйдырып була иде. Икмәге — өстәлләрдә, анысы бушлай гына. (Бу «нарпит» та торабара ресторанга әйләнде. Хәзерге исеме «Чулпан» — Кольцода.) Хуш, инде булмаса, ресторанныкын авыз итеп карыйк.
Официант кечерәк миски белән аш китереп, минем тәлинкәмә бушатты. Исе дә тәмле, куе да икән үзе... Әчкелтемрәк бу ашны бик яраттым, рәхәтләнеп, хәтта кәефләнеп ашап бетердем. (Акча түләгәндә белдем, солянка булган икән ул.) Шуның артыннан зур гына тәлинкәдә, әйләнәсенә бәрәңге һәм төрле яшелчәләр салып, бияләй хәтле кыздырган ит китерде. Бу нигъмәтнең исем шәрифләре ничек булгандыр, әмма мин аны да бик яраттым, бөртеген дә калдырмыйча ялтыратып куйдым. Шуннан соң инде фәкыйрегез алдына кечкенә генә көмеш чәйнек белән каһвә дә килде. Сөте дә, шикәре дә бик кечкенә аерым савытларда, хәтта эчә торган кечкенә генә чәшкәсе дә уенчык кебек кенә иде. Кызы-ык!.. Тик ничегрәк итеп эчәләр икән бу каһвәне?.. Бәлки, әз-әзләп кенә озаклап эчәргә кирәк булгандыр — мин инде ике салып, ике йотуда бетереп тә куйдым.
Казанга килгәч бу минем беренче мәртәбә болай гарык булганчы сыйлануым иде... Ярый, аш булсын, актыгы булмасын! Хәзер инде һәммәсе өчен түләргә кирәк иде. Әлбәттә, бу унбиш тиенлек кенә ашау түгел иде, бәлки, ике мәртәбә кыйммәтрәк түләргә туры килер, ну чорт с ним!.. Официант кечкенә счетында шалт-шолт

салды да: «Сездән җәмгысе алтмыш тиен!» — диде... Әнекәем, алтмыш тиен?! Мин бермәлгә, ни әйтергә дә белмичә, телсез калдым. Кем уйлаган шул хәтле түләргә туры килер дип?.. Әмма берни эшләр хәл юк — түләргә кирәк, түләмичә булмый...

Сез минем болай хафага төшүем өчен бер дә гаҗәпләнмәгез. Чөнки алтмыш тиен ул минем өч күлмәк мәгыйшәтем дигән сүз... Онытмагыз, ак калачның кадагы өч тиен иде ул чакта!.. Шушы сыйланудан соң мин бер биш ел ресторан тирәсенә аяк та басмадым.

...Язмышны алдан юравы бик читен. Укырга дип ашкынып килеп, менә йомыш-юлга йөрүче малай булып киттем. Кайчагында уйлап куям: Казанда калмыйча кире Дәүләкәнемә кайтып китсәм, нәрсә булган булыр иде икән? Бер елдан тагын әйләнеп килер идемме икән, әллә бүтән тарафларга (мәсәлән, Урта Азиягә) китеп барыр идемме, яки бөтенләйгә Дәүләкәндә утырып калыр идемме?.. Һич әйтә алмыйм, әмма Дәүләкәндә утырып калу минем өчен иң аянычлы язмыш булыр иде. Бу кечкенә җирдә укырга да, эшләргә дә перспектива юк диярлек, күп булса, берәр волость (соңыннан район) оешмасында хисапчы-мазар булып калыр идем. Юк, түзмәс идем мин мондагы шартларга. Дәүләкән үзе, Димнәре-тугайлары җаныма никадәр якын булса да, башымны барыбер берәр якка алып чыгып китәр идем. Димәк, хәзергә эш табып Казанда калуым, һичшиксез, дөресрәк булгандыр — шулай юатам мин үземне киләчәк турында өметләнеп уйлаган чакларымда...

Без үзебезнең шыксыз торагыбызда кәефле генә яшәп ятабыз. Егетләр торалар да Архумаска йөгерәләр, ә мин эшкә... (Кайберәүләр ни өчендер урыннарыннан тормыйча ятып та калалар.) Кич, халык җыелгач, торак җанлана. Мичне ягып җибәрәбез, кәтилүкләрдә чәй кайнатып, ашап-эчеп алабыз. Егетләр ишеткән-күргәннәрен сөйлиләр. Уен-көлке, сүз-бәхәс барысы бергә... Әйтергә кирәк, егетләр бик ярлы яшиләр, тугыз сум стипендия аларның ашарларына да җитми, шуңа күрә һәркайсы нинди дә булса эш табып, акча эшләп алу ягын карый. Әгәр шуңа ирешсә, ул инде тук һәм шат. Байлык турында уйлау да, сөйләү дә юк. Ач булмаса, өстендә бер кат кием булса, студент шуңа бик канәгать. Ул чактагы аңлавыбыз буенча, байлык буржуйда гына булырга мөмкин, акча да әнә нэпманнар кулында гына. (Хәзергә!) Хәтта зур урыннардагы совет работниклары да байлыкның нәрсә икәнен белмиләр дип уйлыйбыз. Һәм аларга көнләшеп ка-

рау да юк иде. Бәлки, дәрәҗә-авторитетларына гына кызыгу булгандыр.

Кыскасы, ашау такы-токы, өс-баш юка булса да, күңел көр, зарлану юк, барысы да бик табигый, шулай булырга тиеш тә кебек иде. Яшьлекнең өстенлеге һәм кодрәте бу... Уйнау-көлү, кызык сөйләү, бер-берен үртәү һәм шаярту — менә арып кайткан егетләрнең бөтен эше шул диярдә дә ярый. (Китап уку, хат язу, ертык-сүтекне тегүдән кала.) Шаярту дигәннән, егетләрнең хыяллары бу юнәлештә бик шәп эшли иде. Бер генә мисал. Безнең арада һәркөнне диярлек бик соңга калып кайтучы бер иптәшебез бар иде. Бәшәр дип йөртә идек без аны... Менә шул Бәшәр барыбыз да йокыга киткәч кенә кайтып керә дә кыштыр-кыштыр йөрергә тотына һәм шуның белән ачуыбызны бик китерә иде. Ахырда егетләр моны кызык итәргә булдылар. Каяндыр таза бау табып, аның тапчанын шул бау белән түшәм уртасындагы әлеге тимер ыргакка күтәртеп, асып куйдылар. Берзаман егетебез, гадәтенчә, бөтенебез ятып беткәч, караңгы торакка кайтып керде, шак-шок басып, ята торган урынына барды һәм туктап, тынып калды. Ә без, йоклаган булып, тын да чыгармыйча тыңлап ятабыз. Бәшәр әкрен генә капшанып, тапчанын эзли башлады, шырпы яндырып та карады, ә тапчан юк кына бит... Бик аптырады малай, «ый-й» дигән рәнҗүгә охшаш бер аваз да чыгарды. Аннары сүгенеп, бәрелә-төртелә зал буйлап йөрергә тотынды. Егетләр исә уянган булып, кычкыра башладылар: «Нәрсә йөрисең мунча пәрие шикелле, көн дә йокы бозып, безобразие!.. Ят хәзер үк, югыйсә үзеңне дә типкәләп чыгарабыз!..» (Кайберәүләр, тәкатьләре бетеп, юрганнары астында буыла-буыла көләләр...) Бәшәр тагын бераз сукранып, әрле-бирле йөрде дә, тапчаны торган буш җиргә бишмәтен җәеп, ахырда йокларга ятты. Ә егетләр һаман аны үртиләр: «Иярәшеп алды бер нэпман кызына, понимаешь!.. Ә без монда аның кайнар пәрәмәч белән сыйланып кайтканын көтеп ятыйк, имеш!.. Булмый болай, хватит!..»

Хәлбуки Бәшәрнең хатын-кыз яныннан кайтуы бик мөхәл[1] иде. Үзе ул буе-сыны белән бәләкәй — арык кына, шуның өстенә кыюсыз-мокыт кына бер егет — белмим, нәрсәсе белән генә хатын-кызга ошый алыр икән?! Мөгаен, берәр җирдә эш табып, берәүгә дә әйтмичә, шунда эшләп йөрүе булгандыр.

Бичара, бу төнне ул, ихтимал, юньләп йоклый да алмагандыр, әмма иртәгесен тәмам яктыргач, күзен ачып

---

[1] *Мөхәл* — икеле.— *Ә.Е.*

җибәрсә, ни күрсен, моның тапчаны сәләмә матрасы белән ак түшәмгә терәлеп үк асылынып тора!.. Егет шаккатудан телсез калды диярлек, бары тик «ый-й» дигән шатлык авазы гына чыгарды, аннары инде үзе дә тыела алмыйча кычкырып көлеп җибәрде. Моның ише кызыклар безнең «ночлежка»да әледән-әле булып тора иде. Тик кайчагында шаулап көлү белән генә чикләнеп калмыйча, бик нык үпкәләшеп, хәтта тәпәләшүгә хәтле дә барып җитә идек. Бер җирдә өелешеп яшәгәч, шунсыз булмыйдыр, ахрысы.

Онытылмас борын тагын, минем өчен бик мөһим бер нәрсәне искә төшерәсем килә. Безгә хәтле Дәүләкәннән Казанга Гатаулла бабайның улы Хәбибрахман киткән иде. Без килеп бераз торгач та аны эзләп таптык. Бу табышу безне аеруча куандырды. Хәбибрахман инде медфакка кергән, укып йөри башлаган, Казанны безгә караганда яхшырак белә, шуңа күрә ул безнең өчен бер терәк тә булды. Асылда, безнең чын дуслык нәкъ менә Казаннан башланды да һәм гомеребез буена һич суынмыйча, өзелмичә дәвам да итте. Хәбибрахман хакында мин «Дәүләкән» өлешендә шактый тулы язып узган идем, шуңа күрә монда яңадан кабатланып тормыйм инде.

...Минем бит әле һаман да әдәбият дөньясы турында бер сүз дә әйтә алганым юк — сез дә, ихтимал, шуны көтә торгансыздыр. Мин бит башта ук кая, нинди тарихи җиргә, нинди хикмәтле калага килүемне белеп килдем. Белеп кенә түгел, зур өметләр баглап килдем. Казан ул татар мәдәниятенең үзәге, Казан ул татар әдәбиятының бишеге, шушында инде аның бөтен атаклы әдипләре һәм шагыйрьләре... Тукай үлгәнгә дә әле күп еллар узмаган, аның бөтен замандашлары исән-сау диярлек, шушында яшиләр һәм эшлиләр... Алардан башка монда хәзер күпме яңа әдипләр, яңа шагыйрьләр калкып чыкты. Мин аларның да кайберләрен, мәсәлән, Шамил Усмановны, Такташны укып та, ишетеп тә белә идем. Билгеле инде, минем Казанга килүдән беренче максатым уку булса, икенчесе, һичшиксез, шул әдип, шагыйрьләрне күрү, шулар арасына әкренләп булса да керү иде. Дөресен генә әйткәндә, килгән көннәрдән башлап, мондагы әдәбият дөньясы минем уемны гел үзенә тартып торды.

Ничек тә табасы иде аны, күрәсе иде!.. Һәм менә шул ук елның көз ахырында яки кыш башында булса кирәк, миңа бу мавыктыргыч дөньяның бусагасыннан, ниһаять, атлап керергә дә туры килде.

Мәгәр башта тере әдипләрдән кемне һич көтмәгәндә генә күрү бәхетенә ирешүемне язып үтим әле... Китап

магазинына барганда-кайтканда еш кына Ленин бакчасы аша үтеп йөри идем. Көннәрдән бер көнне менә шул бакча аша үтеп барам. Көз ахыры, агачлар инде шәрә, бакча юлларына сары яфраклар түшәлгән. Тын-буш юлларның берсеннән ак сакаллы кечерәк бер бабай тәгәрмәчле креслоны артыннан әкрен генә этәреп килә. Креслода пенсне кигән бер кеше утыра... Каршыма килеп җитмәс борын ук мин ниндидер бер күңел сизенүе белән креслодагы кешенең Фатих Әмирхан икәнен танып алдым. «Йа Хода!» — дидем ирексездән эчемнән генә һәм шунда ук адымнарымны әкренәйттем... Әнә шулай бик әкрен генә без якынлаштык. Иң мәшһүр әдип, бөек Тукайның замандашы, укып беләм, рәсемнәрен күреп беләм, гарип булуын да ишеткәнем бар иде — бәлки, шуңа күрәдер мин, ниндидер изге бер затка очрагандай эчке киеренкелек һәм дулкынлану белән бөтен дикъкатемне җигеп, аның йөзенә карап уздым. Ахрысы, шуңадыр өстендәге киемнәре хәтеремдә дә калмаган, тик башында фетр эшләпә иде бугай... Әмма йөзен яхшы хәтерләп калдым. Портретларына бик охшаган — озынча ак йөз, калын гына иреннәр, калын пенсне аша караган коңгырттрак зур күзләр... Тагы да күңелгә кереп калганы — аның карашы да, чырае да миңа ни өчендер бик уйчан-җитди булып күренде. Соңыннан, еллар узып искә төшергән чагымда да минем күз алдыма гел генә аның әнә шул уйчан-җитди кыяфәте килә торган иде. Димәк, хыялым эше генә булмаска тиеш бу. Бабай белән әдип минем яннан, корыган яфракларны кыштырдатып, сөйләшмичә әкрен генә уздылар. Бер арык кына егетнең туктый язып, йотылып карап үтүенә дә алар игътибар итмәделәр шикелле. Әллә тагын каршыларына чыгыйммы икән дип уйлаган идем дә, ярый әле андый әрсезлектән тыелып кала белдем.

Фатих Әмирханны икенче тапкыр күрүем «Сания» операсында булды. Өч кеше — Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәтов һәм Василий Виноградовлар тарафыннан язылган беренче татар операсы «Сания», мәгълүм булганча, 1925 елның июнендә, ягъни Татарстан республикасының 5 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә беренче мәртәбә куелган булган. Казанның мәдәни тормышында ул зур вакыйгадан саналган, ул хакта газеталар да күп язган, Галимҗан Ибраһимов премьера көнне пәрдә ачылыр алдыннан нотык та сөйләгән. Фатих Әмирхан үзе дә аның хакында, әсәр әле сәхнәгә чыкмас борын ук, моңарчы хыялларда гына йөргән опера сәнгатенең, ниһаять, бездә дә тууына сөенеп, махсус мәкалә бастырган.

Менә шул «Сания» яңадан 1926 елның гыйнварында уйналачак иде. Афишаларын күрүгә, миндә бик табигый

рәвештә көчле теләк туды — ничек кенә булса да барырга, карарга!.. Бу теләк сәнгатебез өчен күңелләрдә үзеннән-үзе уянган милли горурлык белән бәйләнгән иде. Аннары бит минем опера дигән нәрсәне күргәнем дә юк әле, ишетеп кенә беләм, ничек инде аны — үзебезнең саф татарча операбызны — күрмичә калырга мөмкин ди?! Әмма аңа әлегүе ансат булмаячак, хәзер кышкы театр сезоны, «Сания»нең икенче тапкыр гына уйналуы, халык, әлбәттә, ябырылып киләчәк. Хәер, чынлап җыласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр,— мин дә, йөри торгач, билетның иң арзанлысын, ниһаять, кулыма төшердем. Аның каравы минем урыным иң югарыда булачак.

Ләкин бер кимчелек шатлыгымны бозып, эчемне гел пошырып тора иде. Театрга киеп барырлык юньле киемем юк. Чиста ак күлмәгем бар, ә менә пинжәгем бик хөрти — җиң очлары сүсәргән, җитмәсә, бер терсәге дә тишелә башлаган. Бу кием белән ничек итеп бармак кирәк?.. Оят бит! Ярлылыкка күнеккән кеше дә театрга ертык кием белән бармый торгандыр инде. Нишләргә соң, егетләр?.. Ахырда, уйлана-борчыла торгач, үземчә бер хәйләсен таптым: пинжәкне эчтән киеп, аның өстеннән ак күлмәкне кидем дә билемне каеш белән кысып, буып куйдым... Бу чын, монда бернинди арттыру да, ялган да юк. Торактагы иптәшләр көлеп, мине тынычландырдылар да әле: «Сиңа болай кию килешә дә икән, әзрәк тулыланып киттең»,— диделәр. Әйе, бар иде, бар иде талдин нечкә, сылу чаклар...

Шулай итеп, мин пинжәк өстеннән күлмәк киеп, беренче татар операсын карарга бардым. Ә театрда халык! — үзе бер тамаша. Кемнәр генә юк. Укымышлы зыялылар, әдипләр, шагыйрьләр, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр һәм хәрбиләр, шулай ук укучы яшьләр — кыскасы, шәһәри Казанның бөтен каймагы җыелган булырга тиеш. Һәм шулар арасында килеш-килбәтләре белән үк аерылып торган шактый зур бер төркем — яңа байлар (нэпманнар) белән аларның тулы хатыннары... Ирләре иске заманча бик шәп тройка костюмнан һәм кара кәләпүштән, ә хатыннарының өстендә атлас та бәрхет, энҗе-мәрҗән дә асылташ. Болар әйтерсең опера караудан бигрәк үзләрен күрсәтер өчен килгәннәр...[1] Шул зиннәтләре белән алар күз явын алып, хуш исләр таратып

[1] Күптән түгел Исмәгыйль абзый Һилалов сөйләде: шул заманда алар белән бер йортта торган тегүче хатыннан нэпман бичәләре «Сания» операсына махсус киеп барыр өчен җитмеш күлмәк тектергән булганнар.— *Ә.Е.*

зур фойеда әкрен генә әйләнеп йөриләр. Әйе, гаҗәеп бер чуарлык һәм аермалык бүген монда... Әмма беренче татар операсы уяткан хисләр уртак һәм кәефләр дә бертөсле иде, минемчә.

Үз ишләремне дә караштырдым. Ләкин алар бик аз иде бугай, егетләрдән дә, кызлардан да минем тиңнәр күренмәде диярлек. Ә менә элеккеге студент формасындагы яшел тужуркалы, җиз төймәле җитү егетләр күренгәләде. Шулай ук кечкенә калфаклы зифа туташлар да күзгә чагылмыйча калмады. Мин аларга бик кызыксынып һәм ирексездән сокланып карадым — гүя алар үтеп киткән, инде яңадан кайтмас заманның сирәк кенә сакланып калган соңгы яшьләре иде... Кыскасы, үзем кебек өтекне һәм арыкны мин монда очратмадым. Мәгәр моңа бер дә көенмим, мине биредә этем дә белми, урыным да каядыр өченче катта, ичмасам, тыныч җан белән уенны карый алачакмын!

Хуш, инде «Сания»не тамаша кылыйк. Иң әүвәл, пәрдә ачылмас борын, сәхнә алдындагы чокырда утыручы музыкантлар, бер куе чәчле, какча гына кеше нечкә генә таягын селкүгә, төрле уен коралларында дәррәү генә уйнап җибәрделәр. Операның башымы, керешеме булса кирәк бу... (Увертюра дигән сүзне ишеткән юк иде.) Оркестр күпмедер уйнаганнан соң, пәрдә әкрен генә ачылды. Сәхнә бик түбәндә булгач, андагы бөтен нәрсә ничектер ерагаеп, кечерәеп күренә икән. Уйнаучыларның да мин иң элек баш түбәләрен күрәм. Әнә кырпу бүрек кигән егет, әнә кечкенә калфак кигән туташ, тагын әнә кама читле бүрек кигән бер агай да йөри. (Бусы Солтан Габәши уйнаган староста булып чыкты.) Алар барысы да оркестр уйнаган көйгә ияреп, үзара җыр белән генә сөйләшәләр, җыр белән генә аңлашалар. Мәсәлән, гапгади «Исәнме, абзый!» дигән сүзне дә җырлап-сузып әйтәләр. Опера шулай булырга тиеш тә инде ул — бу кадәресен генә без дә беләбез. Мин бик дикъкать белән тыңлыйм. Операның үзәгендә мәхәббәт вакыйгасы торуын мин башта ук аңладым диярге була... Музыка өзлексез уйный, геройлар өзлексез җырлыйлар, җыр-музыканың миңа ошаган урыннары күп, ошап бетмәгән урыннары да юк түгел, әмма, никадәр бирелеп тыңласам да, бер нәрсә мине һаман борчыды да торды: җыр белән сөйләшүне мин юньләп аңлый алмыйм икән. Нәрсә хакында сүз бара, бер-берсенә нәрсә дип әйтәләр — менә шуны тота гына алмыйм бит. Гаҗәп! Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне мин күбрәк хәрәкәтләренә, чырайларына, тавышларына карап кына чамалыйм. Ә сүз юк, сүз

миңа килеп җитми, шуның аркасында күп нәрсәне аңламыйча калам. Бу хәлгә аптырадым да, пошындым да, бәлки, урыным начарга күрәдер дип тә уйладым. Ләкин ничек кенә булмасын, операдан чын ләззәт алдым дип әйтергә телем бармый. Хәер, минем яшьтә һәм беренче генә мәртәбә караудa бу, бәлки, мөмкин дә түгелдер... Ә шулай да беренче татар операсын күрә алуыма бик шат булып, халык кичергән горурлыкны мин дә чын ихластан кичереп, мактанып та йөрдем.

Моңа инде күп еллар узды. «Сания» операсы күптән онытылды, әмма, гаҗәпкә каршы, бер хакыйкать шулай да сакланып калды. Соңыннан, тәмам дәү абзый булып җиткәч караган опералар белән дә шундый ук хәлне татырга туры килә иде. Нинди генә операга барсам да мин, билгеле, музыкасын тыңлыйм, бай декорациягә, зиннәтле киемнәргә карап утырам, ә менә җырлап әйтелгән сүзләрнең уннан берен дә тота-аңлый алмыйм. Шулай итеп, операга салынган фикер, мәгънә миңа килеп җитмичә кала. Бу бик зур оттырыш, чөнки мәгънәне мин сүздән табарга гадәтләнгәнмен. Ахрысы, шуңадыр опера мине бервакытта да чынлап торып җәлеп итә алмады. Ихтимал, бу минем бик зур кимчелегемдер, наданлыгыммокытлыгымдыр, ләкин «культурный» булып күренер өчен генә аңлыйм, яратам дип ялганлыйсым килми. Ә бит мин бала чактан ук җыр ишетеп, җыр белән сихерләнеп үскән идем. Алайса, хикмәт нәрсәдә?

...Бәлки, һәр сәнгатьнең үз вакыты бардыр. «Сания» операсы язылган елларда безнең татар тамашачысы бу бик катлаулы, бик нечкә сәнгатьне тиешенчә аңлап, кабул итү дәрәҗәсенә килеп җитмәгән иде әле. Операны заказ белән яздырып булса да, аны аңларлык тамашачыны махсус хәзерләп булмый, билгеле. Димәк, икесе дә бергәрәк өлгерергә тиештер инде. Тагы да ачыграк әйткәндә, һәрбер сәнгать халыкның мәдәни үсеше белән бәйләнгән рухи ихтыяҗыннан туса гына, аны җиңел аңлап та, табигый кабул итеп тә була торгандыр. Моның шулай икәнен безгә шул ук елларда үсеп киткән һәм, беренче нәүбәттә, Салих Сәйдәш исеме белән бәйләнгән музыкаль сәхнә әсәрләре бик ачык күрсәтте. Халык бу әсәрләрне бердән яратты, бердән кабул итте, чөнки ул инде «Галиябану»дан соң җыр-музыка кергән драма әсәрләрен көтеп кенә тора иде. Димәк, андый әсәрләргә ихтыяҗ тәмам өлгереп җиткән булган. Һәм шуннан соң инде операга да ерак калмый кебек. Ихтимал, аны тудыручылар шулай уйлаганнардыр да, әмма кайчагында якын араны да бик авыр үтәргә туры килә. Ләкин нихәтле

генә авыр булмасын, опера сәнгате Союздагы төрки халыклар арасыннан иң элек бездә туды (азәрбайҗанлылардан кала). Мәдәни тормышыбызда бу зур вакыйга иде, һәм халык аны шулай кабул да итте. Инде операны аңлау, ярату мәсьәләсенә килгәндә, бу төрле кеше өчен төрлечә — монда уртак кагыйдә булуы мөмкин түгел. Әгәр шулай икән, гаепләштән булмасын. Ә менә операның үзен беренче булып тәвәккәллек белән, фидакарьлек күрсәтеп иҗат итүче Габәши, Әлмөхәммәтов, Виноградовларны без истән чыгармаска һәм тирән хөрмәт белән, һичшиксез, яд итәргә тиешбез.

Сүзем бит минем Фатих Әмирханны икенче тапкыр күрүем турында иде. Нәкъ менә «Сания» операсында, кайчандыр үзе хыял иткән милли опера тамашасында!.. Антракт вакытында мин түбәндәге фойега төштем — читтән генә булса да шунда әйләнеп йөргән Казан публикасын әзрәк күзәтәсем килгән иде... Карасам, залга үтә торган ике ишек арасындагы стена буена Фатих Әмирханны креслосы белән чыгарып куйганнар. Минем игътибарым шунда ук аңа күчте. Якынрак бардым, ләкин инде әдипне аның үз геройларына охшаган студент формасындагы егетләр һәм калфаклы туташлар урап алганнар иде. Мин, билгеле, алар арасына кысылып керергә кыймадым, тик шулай да түгәрәкнең әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан килеп, әдипнең йөзен күрергә тырыштым. Егетләр һәм туташлар аңа комплимент һәм мактау сүзләре әйтәләр, ә ул, саран гына елмаеп, башын селеккәли, нидер әйтә дә шикелле, ләкин миңа ишетелми иде. Ә менә чырае, бакчада күргәндәгечә, һаман шулай җитди-уйчан иде (хәтта боеграк та кебек иде). Шулай торып калды әдипнең йөзе-чырае минем хәтердә һәм шулай гына саклана да хәзергә кадәр... Вакыт-вакыт хыялым эше түгелме икән бу дип шикләнеп тә куям, әмма барыбер Фатих Әмирханны башкача күз алдыма китерә алмыйм. Чөнки ул минем өчен бер үк вакытта гаҗәпләнү, кызгану һәм соклану катыш тирән ихтирам уяткан бөек әдип тә һәм гарип бер кеше дә иде. (Хәер, еллар узу белән кызгану тойгысы үзеннән-үзе диярлек бетте, чөнки рухи көчле фидакарь затларны гариплеге өчен генә кызгану мөмкин түгел икән.) Менә шул затны мин тере чагында күреп калу бәхетенә ирештем!

Ә нәкъ ике айдан инде Фатих Әмирхан дөнья белән дә бәхилләште. («Сания» операсы 16 январьда уйналган иде, Ф.Әмирхан 13 мартта вафат булды.) Зур үкенечкә каршы, мин әдипне озату вакыйгасын күрә алмадым. Нәкъ шул көнне мине магазин хезмәткәрләре исеменнән

ниндидер бер профсоюзлар җыелышына җибәргәннәр иде, бөтен көнемне бик гадел рәвештә шунда утырып үткәрдем. Хәлбуки күрүчеләр Фатих Әмирханны озату шактый хикмәтле булды дип сөйләделәр. Бер яктан, совет җәмәгатьчелеге Ирек мәйданында митинг ясап, нотыклар сөйләгәннәр, икенче яктан, әдипнең якыннары, мәрхүмнең васыяте буенча дип, муллалардан җеназа укытканнар. Һәм бу ике төрле озату каршылыксыз, шома гына узмаган булса кирәк.

Ул көннәрдә матбугат Фатих Әмирхан турында күп язды. Тукайдан соң татар әдәбиятында бу иң зур югалту иде. Моны һәркем диярлек шулай аңлады. Әмма Фатих Әмирханның нинди язучы булуына килгәндә, монда инде бик тиз катгый бер караш өстенлек алды: Фатих Әмирхан — буржуа язучысы!.. Үлүенә багышланган беренче мәкаләләрдә үк (мәсәлән, Г.Сәгъди мәкаләсендә) ул караш ачык әйтелгән иде, аннары, күп тә узмый, андый караш әдипкә көйдереп суккан тамга шикелле кырып та бетермәслек итеп ябыштырылды. Бу эштә Г.Толымбайский аеруча зур тырышлык күрсәтте. Әдипнең үлүенә бер ел тулу уңае белән ул болай дип язып чыкты:

— Фатих Әмирхан, буржуа сыйнфы сәнгатьчесе буларак, буржуа сыйнфы алга барганда алга барды. Буржуа сыйнфы бетүгә йөз тоту белән бергә ул да зәгыйфьләнде, төшенкелеккә йөз тотты. («Безнең юл», 2 нче сан, 1927 ел.)

Бусы әдипнең иҗатына карата әйтелгән сүзләр. Ә менә әдип үлгәннән соң ике ай да үтмәгәндер, аның басылмыйча калган әсәрләре турында ул, Толымбайский, мондый карар чыгарырга да өлгерде:

— Бу китапларның хәзерге вакытта эшче-крестьяннарга бер тиенгә дә кирәкләре юк. Шулай булгач, хәзерге көндә боларны бастырып тарату сәяси җинаять булачак. («Безнең юл», 5—6 нчы саннар, 1926 ел.)

Күрәсез, нинди рәхимсез хөкем!.. Әйе, төрлесен ишетергә, төрлесен күрергә туры килде. Ярый әле моның ише хәлләр саташулы авыр төш шикелле үтте дә китте. Мең шөкер, без Фатих Әмирханның исемен дә, бай мирасын да, баш очындагы мәрмәр ташын да югалтмадык[1]. Без аңа һәрвакытта баш иеп узабыз. Күптән юкка чык-

[1] Бу таш әдипнең каберенә 1927—1928 елларда куелган. Кара мәрмәрне Яңа бистәдә Әмирхановлар гаиләсе белән якыннан аралашып яшәгән Исхак Карташев Ленинградтан барып алып кайткан. Ташка «Әдип Фатих Әмирхан» дигән кыска гына сүзләрне бик матур итеп Кәлметов фамилияле кеше язган булган. Болар барысы да җәмәгатьчелектән җыелган акчага эшләнгән... Моны миңа Исхак абзыйның улы, сугыш һәм хезмәт ветераны Заһид Карташев сөйләде. — *Ә.Е.*

кан буржуазия түгел, ә татар халкы чын хуҗа аның үлемсез мирасына!..

Г.Толымбайский үзе дә бик кызганыч ул. Әдәбият күгендә Г.Нигъмәти ачкан биш йолдызның берсе иде бит... Әмма язмыш дигәнең аны да аяп тормады. Күктән җиргә сөрелгәндәй, бичара, юкка чыкты. Каберен дә белмибез. (Тагын бер шөкер итик: язганнары югалмады, ичмасам!) Малай чагымда кеше кулында гына бер китап күргән идем. Исеме «Үзеңә кайта» иде. Ни хикмәттер, укылмаган китапның исеме шушы көнгә кадәр күңелдә сакланган. Нидер аңлаткан булса кирәк ул миңа... Үзеңә кайта! — бик гыйбрәтле сүз бу, минемчә.

Әдәбият дөньясы... Ниндирәк икән ул?.. Бик мавыктыргыч та һәм куркыныч та кебек бу дөнья!.. Бигрәк тә минем ише ерактан килгән, үзенә әле бигүк ышанып та бетмәгән бер үсмер егеткә. Хәер, миннән соңрак килеп тә әдәбият дөньясына ансат кына кереп киткән һәм тиз арада түренә үк узарга өлгергән егетләр дә булды булуын... Ләкин мондый уңышны кешенең акылы, таланты, булдыклылыгы белән генә аңлатуы читен — монда заман белән бәйләнгән ниндидер объектив сәбәпләр дә булырга тиеш иде. Минем максатым исә, хәзергә бик тирәнгә кермичә, үзем күргәнне һәм үземә кагылганны сөйләү белән генә чикләнү — калган яклары тора-бара шулардан да, бәлки, беркадәр ачыкланыр.

Хуш, ничек таптым соң мин ул әдәбият дөньясының ишеген? Ирек мәйданындагы хәзерге Офицерлар йорты без килгән елларда комклуб дип атала иде. Көн дә яныннан үтеп-сүтеп йөрибез, ләкин эченә кергәнебез юк, анданиләр барын белмибез. Күпмедер вакыттан соң, әлеге ТКУда эшләп йөрүче Царицын егете Мәсәгуттән ишеттек: ул клубта атна саен татар язучыларының җыелышы була икән ләбаса! Бу хәбәр миндә шунда ук зур кызыксыну уятты: кемнәр, нинди язучылар җыела, нәрсәләр сөйлиләр анда, язучы булмаган кешегә дә керергә ярый микән? Мәсәгут, үзе дә ара-тирә ул җыелышларда булгалаганга күрә, миңа бик белеп: «Бернинди тоткарлык юк, пажалысты, барасың да керәсең!» — диде. Бу инде ноябрь ахырлары иде. Җыелышлар була торган нәүбәттәге җомганың киче килеп җиткәч тә, мин Фәтхелислам белән Мортазаны кыстый-кыстый ияртеп, әлеге шул комклуб дигән җиргә, ахшам кичәсенә ашыккан шәкертләр шикелле, шагыр-шогыр атлап киттек. Бардык, кердек, кемнәндер: «Язучылар җыелышы кайда монда?» — дип сорадык. Ул безгә: «Икенче катта, сул яктагы бүлмәдә»,— диде. Киң баскычтан юга-

ры күтәрелдек, борылмадагы галәмәт зур көзгедә кызарышкан йөзләребезне күреп калдык. Һәм, сулга борылып, коридор буйлап киттек. Кечерәк бер зал хәтле бүлмәгә сак кына, кыюсыз гына барып кердек. Җыелыш бара иде инде — безгә юньләп игътибар итүче дә булмады. Таза имән урындыклар монда рәткә тезеп куелмаган, һәркем үзе теләгәнчә куйган да утырган (кайберләре исә атланып та). Ишек төбеннән ерак түгел безгә дә буш урын табылды — әкрен-мыштым гына узып, без дә шунда чүгештек. Кеше әллә ни күп түгел, шулай да бер утызлап булыр. Минем чамадагылар да әзрәк күренә, күпчелеге исә егерме белән егерме бишләр арасындагы җитү егетләр. Шулардан да олыраклар берничә кеше генә. Өс-башлары да бик чуар. Юка пальто, бушлат, шинель, башларында кепка да фуражка — кыскасы, ни тапсалар, шуны кигәннәр, киемсалымга гүя полный талымсызлык! Тик менә кашне дигән нәрсә бик модага кереп бара икән. Өсләреннән салсалар да, кашнены муеннан алу юк. Аның бер башын алга, икенчесен артка салындырып куялар — моны кайбер язучыларның фоторәсемнәрендә дә, бәлки, күргәнегез бардыр.

Ярый, болары кайбер вак-төякләрне искә төшерү генә... Мине иң кызыксындырганы — кемнәр монда һәм нәрсә турында сүз алып баралар? Берсен дә әлегә танымыйм. Сөйләүченең фамилиясен әйтсәләр генә белеп калам. Ләкин монда трибуна юк, һәркем утырган җиреннән генә тора да сөйли башлый, күбесенең фамилиясен әйтеп тә тормыйлар. Менә кара бер егет ялкынланып гүя нотык сөйли — кем ул, Ходa белсен!

Хәлбуки мин әле Дәүләкәннән үк ике яңа язучыны белеп дигәндәй килгән идем. Болар — Шамил Усманов белән Һади Такташ. Соңгысының «Җир уллары» дигән китабы безгә дә килеп җиткән иде. Элегрәк шигырь белән язылган сәхнә әсәре яки озын шигырьләр бездә сирәк укыла иде, без әле, дөресен генә әйткәндә, аларның «тәмен» дә белеп җиткерми идек. Әмма «Җир уллары» һәм аның ахырындагы «Үтерелгән пәйгамбәр», «Таң кызы», «Нәләт» кебек шигырьләре безнең әдәбият сөючеләрне берьюлы әсир итте дә куйды. Кайберәүләр аларны яттан да шашынып сөйләп йөри башладылар... Мин үзем дә, билгеле, ул шигырьләрдән биһуш булган идем... Менә шуларны язган Такташ дигән кеше бармы монда, булса, кайсысы, ничек итеп танырга?

Шамил Усманов исеме дә миңа яхшы таныш иде. Хикәяләрен укыганым бар, аннары «Канлы көннәрдә» дигән драмасы бездә кат-кат уйналган да иде. Ул абый да биредә булырга тиештер инде.

...Соңгы вакытларда колакка тагын Нәҗми белән Кутуй дигән исем бик еш керә башлады. Бик зәһәр шагыйрьләр булса кирәк. Алар да мондадыр, әлбәттә. Тик бераз кетәргә генә кирәк, ачылмыйча калмаслар, явыллар, мишәр әйтмешли...

Әмма сүз, бәхәс нәрсә турында соң монда? — башта шуны белик әле. Алай, баксаң, монда күбрәк берәр әсәр — шигырьме, хикәяме — укып, шуның хакында кызу сүз алып баралар икән. Әйтергә кирәк, сөйләшү бик хөр бара. Торып сөйләүче, әсәрне чөеп мактаса да, бетереп ташласа да, әйтергә теләгәнен яра да сала. Тыйнакланып, хәтер саклап тору юк. Мәгәр еш кына укылган әсәрне онытып, бөтенләй башка мәсьәләгә күчеп, үзара талашыр дәрәҗәдә бәхәсләшеп тә китәләр. Бер-берсен шулай ук аяп тору юк, теләнә ни килсә, шуны тота да чәпи. Тыңлавы бик кызыклы, тагын ни ишетермен дип көтеп кенә торасың һәм шуның белән бергә үзеңне ничектер энәләр өстендә утыргандай итеп тә тоясың...

Беренче килүебездә мин кемнәрне күрүемне дә, ниләр ишетүемне дә хәзер инде ачык кына исемә төшерә алмыйм. Әмма комклубтагы бу шау-шулы җыелышларга бик теләп йөри башладым. Әле беркемгә билгесез үсмер егет кенә булсам да, бу инде минем әдәбиятка якынаюым, язучылар арасына керә башлавым иде. Хыялның әкренләп чынлыкка әйләнүе... Озак та үтми, мин инде монда Такташны да, Кутуйны да, Кави Нәҗмине дә, Гомәр Галине дә, Хәсән Туфанны да, Толымбайскийны да күрдем, танып калдым, сөйләгәннәрен дә ишеттем. Болар — атаклылар, боларны тиз белеп була, ләкин алардан әле яшьрәк, танылып өлгермәгәннәр дә аз түгел — миңа, беренче нәүбәттә, менә шундыйлар белән әкренләп танышырга кирәк булачак иде. Билгеле, бу җыелышларга йөрүчеләрнең иң зур күпчелеге укучы яшьләр иде. Үзләре язалармы-юкмы, әмма мондагы бәхәсләрне тыңларга да, кирәксә, бәхәскә кереп китәргә дә яраталар. Алар арасыннан үзләрен өстен тотулары һәм кискен чыгышлары белән бигрәк ТКУ студентлары аерылып торалар иде.

Дәүрәк язучылардан Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Әмириләрне мин монда очратмадым. Шулай ук Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кәрим Тинчурин кебек зур язучыларның да килеп чыкканнары булмады. Бу, әйткәнемчә, бары яшьләр җыелышы гына иде. Төп үзәге дә аның Такташ, Нәҗми, Кутуй кебек егерме биштән узмаган язучылар иде. Шул ук елнымы, әллә соңракмы, ул җыелышлар «яшь язучылар түгәрәге» дигән исем белән йөртелә дә башлады.

Һәр җыелыш кемнең дә булса берәрсенең күтәреп

килгән әсәрен укудан башлана. Аны бик игътибар белән тыңлыйлар. Аннары инде сүз китә, сүз кыза, бәхәсләр кабына. Ул чакта ни сөйләсәң дә ярый иде кебек. Ягъни шул заманның әдәбиятындагы төрле агымнарга иярүчеләр һәркайсы үз юлын аклый, яклый һәм башкаларга да тагарга тырыша. Тарихтан мәгълүм ки, бездә ул чакта Кутуйны футурист, Нәҗмине имажинист, Такташны символист дип йөртәләр иде. Мәгәр агымнары төрле булса да, максатлары бер: иң элек аларның һәркайсы иске әдәбияттан баш тарта, иске язучыларның берсен дә үзе өчен авторитет дип санамый (хәтта Тукайны да). Һәркайсы иске буржуаз әдәбият урынына яңа, пролетариат әдәбияты булырга тиеш дип бара, шуны кайгырта, шуның өчен җанытәне белән көрәшергә әзер тора. Аннары инде һәркайсы яңа эчтәлеккә яңа форма кирәк дигән карашны алга сөрә. Ә нинди форма пролетариат әдәбиятына яхшырак туры килә — менә бу мәсьәләдә инде алар кылычларын уйната башлыйлар. Һәркайсы үзенекен мактый, башкасын яманлый, бары үз «агымы» өчен сугыша. Хәер, сугыша дип әйтү артыграк булыр, чөнки алар үзара бик дуслар, берберсенә сәяси гаеп тагу юк әле ул чакта, кызып бәхәсләшәләр дә көлешә-көлешә таралышалар.

Күп нәрсәдән хәбәрсез булганга күрәдер инде, мин ул җыелышларда сөйләгәннәрнең барысын да аңлап та бетерми идем. Мәсәлән, нәрсә ул имажинизм? Кайдан килгән нинди җәнлек?.. Күпме ишетсәм дә, ачык кына белә алмадым мин аны. Мәгәр җыелышларның барышы, кабатлап әйтәм, бик кызыклы иде. Катнашучыларның «исемле» яки «исемсез» булуларына карамастан, үзләрен бертигез итеп тотулары, берәүдән дә курыкмыйча иркен-кыю сөйләүләре, авторитетлар белән дә артык хисаплашмаулары миңа да ошап киткән иде. (Дөрес, мин моңарчы күбрәк иске әдәбиятны укып үскәнгә күрә, иске язучыларның, Галимҗан Ибраһимовтан кала, һәммәсен дә диярлек себеренеп түгүләрен ничектер күңелем белән кабул итеп бетерә алмый идем. Ләкин моны барысы да пролетариат әдәбияты хакына эшләгәч, бәлки, шулай кирәктер, шунсыз булмыйдыр дигән уй да ирексездән башка килмичә калмый иде.)

Җыелышларның әнә шул хөрлеге белән мавыгып булса кирәк, мин дә бер килүемдә кул күтәреп сүз сорарга җөрьәт иттем. Дәүләкәндә яза башлап та Казанга килгәч бетергән бер әйберем бар иде — менә шуны мондагы дәү абыйларга, әйдә, ни булса, ул, дип, тәвәккәлләп укырга булдым. Миңа рөхсәт иттеләр, исем-фамилиямне сорадылар. Тордым, кулымдагы озын кәгазьләрне калтырата биреп, кызу гына укый башладым. Мондый урында бе-

ренче генә укуым булгач, мин үземнең ничек, яхшымы-начармы, укуымны юньләп ишетмәдем дә диярлек. Ләкин мин тотлыкмыйча тиз укырга күптән өйрәнгән идем инде. Бәлки, шуңадыр, мине тынлык саклап, игътибар белән тыңладылар кебек — һәрхәлдә, шулай тоелды миңа укыган чагымда. Ә менә укып бетергәч, кемнең дә булса сорау бирүен яки торып берәр төрле фикер әйтүен белмим, юк, һич кенә дә хәтерли алмыйм. Әмма бер нәрсә бик нык хәтеремдә торып калды: Гомәр Гали дигән язучы кулымдагы кәгазьләрне: «Кая, энекәш, бу нәрсәңне миңа биреп җибәр әле»,— дип, миннән сорап алды. Мин аның «Безнең юл»да эшләгәнен белми дә идем, ләкин, абый кеше сорагач, бирдем дә җибәрдем. Ни өчен, нинди максат белән алганын сорап та тормадым... Ә күпмедер вакыттан соң Гомәр Гали минем шул әйберемне, яртылаш кыскартып, «Озын көй тыңлаганда» дигән исем белән «Безнең юл»да басып та чыгарды (1926 ел, март саны). Һич көтелмәгән гаҗәеп бер эш булды бу минем өчен... Беренче тапкыр дөньяга басылып чыгуым, җитмәсә, «Безнең юл» кебек иң дәрәҗәле, иң күренекле бер журналда!.. Әгәр шул санны ачып карасагыз, сез анда Галимҗан Ибраһимов һәм Габдрахман Сәгъди мәкаләләрен, Такташ, Кутуй, Туфан шигырьләрен, Толымбай, Гомәр Гали хикәяләрен күрерсез — әнә кемнәр арасына килеп кергән бит без фәкыйрегез дә!..

Билгеле, минем шатлыгым баштан ашкандыр инде, ләкин озакка бармагандыр, дип уйлыйм. Чөнки журнал битләрендә чыгу ничектер җиңел иде ул чакларда. Әнә күрдегез, бер Гомәр Галинең теләге җитте минем әйберне журналда басу өчен... Һәм әнә шулай ансат кына чыгып, тиз арада танылып китүчеләр дә аз булмады — яшь көчләр өчен әдәбиятка киң юллар ачылган иде бу бик кызыклы һәм шау-шулы вакытта...

Инде минем әйбернең үзенә килгәндә, ул шәкертләрчә ияреп язылган нәсер сыман бер парча иде. Эчтәлеге болай: Шәйморат исемле башкорт агае кырын ятып, озын көй тыңлаганда үзенең үткәнен — бишенче ел революциясе вакытында җирле алпавытка каршы баш күтәрүен, шуның өчен төрмәләрдә утыруын, Себер җибәрелүен, анда күргән газапмихнәтләрен күз алдыннан кичерә. Бу, әлбәттә, миңа китаптан күчкән. (Революциясен дә, алпавытын да, төрмәсен дә минем бит күргәнем юк.) Әнә шул укып белгәнемне озын көй белән бәйләп, аңа сыйнфый мәгънә салып, язып чыкканмын инде. Бәлки, шуның өчен ул журналга кереп тә киткәндер. Әгәр дә ки мин моңлы башкорт көен тыңлаганда үзем ниләр кичергәнемне язсам, ул нәрсә, ай-һай, болай ансат кына үткән булыр идеме икән?!

Кыскасы, уйламаган-көтмәгәндә генә мин әдәбият дөньясына беренче адымны атладым. Һәм, әйтергә кирәк, бу минем иң җиңел адымым булган икән. Башка инде ул кабатланмады.

1926 елның июнь башларында без, өйләребездән бергә чыгып киткән ике егет, шулай ук икәү бергәләп Дәүләкәнебезгә кайтып китәргә булдык. Фәтхелисламның уку-лары тәмамланды, ә мин эшләгән җиремнән расчет алдым. Язга чыгу белән үпкәләремнең начарлануын сизеп, Әбүбәкер абзый Терегуловка күренгәч, хәтерлисездер, ул миңа тизрәк Дәүләкәнемә кайтып китәргә кушкан иде. Ә законлы отпускага бик ерак иде әле, шул сәбәпле китап магазиныннан аерылырга туры килде. Без инде болай да Дәүләкәнебезне бик сагынган идек һәм, озын юлга күп вакыт әрәм итмәс өчен, әкрен йөзгән пароходка утырмыйча, кызу чапкан поезд белән кайтуны артыграк күрдек. Рузаевкада Уфа якларына китүче поездга күчеп утырганнан соң, Самара аша тәүлек ярым дигәндә үзебезнең кечкенә станциябезгә кайтып та төштек. (Ә пароход белән Уфа аша кайтканда биш тәүлек киткән булыр иде.)

Ахрысы, алдан хәбәр иткәнмендер инде, каршы алырга атакай белән энем станциягә килгәннәр иде. Беренче мәртәбә читтән, ерак җирдән кайтканга күрә, алар мине чак күтәреп кенә алмадылар. Мондый сөенечле, мондый бәхетле каршы алуны мин бүтән татымадым да шикелле. Хәтта сугыштан исән-сау кайтып кергән чагымда да! Мин әле Дәүләкәнгә беренче кайтуымда газиз бала идем, дөрес, буй җиткән, инде үз көнемне үзем күрә башлаган, әмма барыбер кадерле-газиз бала идем. Ихтимал, атакайның бу хәтле шатланып каршы алуында сагыну гына түгел, мине егет итеп күрү горурлыгы да булгандыр... Инде өчәүләшеп өйгә кайтып кергәч, инәй, бичара, сүзен дә әйтә алмыйча, бары юеш иреннәре белән минем битемнән үбеп алды. Сабый чагымда үпкәннәрен хәтерләмим, соңыннан күпме җирләрдән йөреп кайткан чакларымда да мине болай үпкәне булмады — бердәнбер онытылмыйча сакланганы, шушы беренче кайтуымда кабаланып, ыңгыраша биреп үбүе булды. Тамгасы битемдә калмаса да, күңелемдә гомерлеккә җуелмаслык булып калды.

Мин Казаннан матурланып кайткан идем. Буйга да сузыла төшкәнмен, чәчләрем дә алкаланып тора, битем дә чәчәктәй бик чиста — кыскасы, малай чакның «кытыршылыклары» бетеп, нәфис кенә, нечкә генә егет булып киткәнмен... Ә инәй, бичара, кечерәйгән, инәй бер могҗизага караган шикелле миңа түбәннән авыру

күзләре белән исе китеп карый. («Матурлык» хикәясен исегезгә төшерегез.) Гүя ышанып та бетә алмый — арык, чирләшкә малайдан бер ел эчендә шушындый бер сылу үсеп чыгар икән!..

Мин әзрәк мактанып ташладым бугай. Ләкин дөресе шулай, читтә уздырган елга якын вакыт минем егет булып өлгерүемне чынлап та тизләткән, күрәсең. Тик шунысы аяныч, Казан шикелле данлыклы бай каладан кайткан бу сылу егетнең кесә ягы бик такыр иде. Хезмәт хакым бәләкәй булгач, расчет вакытында миңа акча, билгеле, аз тиде. Шул акчадан мин әле үземә чалбар белән ботинкалар да алдым. (Югыйсә өстем бик хөртиләнгән иде.) Инәйгә бүләк итеп бер батист яулык та алдым, энемә дә нидер алдым бугай, тагын нәрсә? — бәлки, кәнфит, хәлвә кебек әзрәк кенә кучтәнәчем дә булгандыр инде. Хәзер аларның һәркайсын искә төшерү мөмкин түгел, ләкин шулай да бер нәрсәне яхшы хәтерлим — акчамны ничек тә тотып бетермәскә тырышкан идем. Казан хәтле Казаннан бөтенләй буш кул белән кайтып керүнең оят булачагын мин, әлбәттә, аңлый идем. Һәм кесәмдә минем бер җиде-сигез сум акча да кайткан иде. Ул чактагы арзанчылыкта бу вак-төяк расходка җитәрлек ярыйсы гына «сәмән» иде.

Июнь аеның тансык матур көннәре... Тузып, искереп бетәргә өлгермәгән Дәүләкәнебез бер көе тын һәм тыныч кына яшәп ята. Ни өчен без бу ни шәһәргә әйләнмәгән, ни чын авыл булып кала алмаган тузанлы зур саланы шулкадәр яраттык икән?.. Беренче нәүбәттә, бай табигате — якты Диме, киң тугайлары, камышлы күлләре, ак балыклары өчендер инде. Дәүләкәнгә кайту ул безнең өчен әнә шул байлыкка, гүзәллеккә кайту иде. Әйе, без, читкә китүчеләр, барыбыз да аңа гашыйк идек, аңа ашкына идек. Дәүләкән хакында мин күп яздым, яңадан кабатлыйсым килми, тик шулай да әйтмичә үтә алмыйм: әгәр миндә шушы көнгә кадәр Дәүләкәнне күпме-азмы сагыну тойгысы сакланып калган икән, ул башлыча минем Казаннан кайтып йөргән әнә шул 1926—1927 елларга туры да килә инде. Иң элек, бу еллар Дәүләкәннең иң тук, иң тыныч, иң имин вакыты иде. Базарлар бай, азык-төлек күп керә, шуның өстенә арзанчылык та. Билгеле, төрле кешенең хәле төрлечә, берәүләр таза, икенчеләр зәгыйфь тора, әмма ризыкка интеккән, хәерчелектә яшәгән кеше юк иде диярлек. Кечкенә урында аз гына хезмәт хакы алып эшләгән кешенең дә тамагы тук, өстенә киеме бар иде. Холера вакытында йорт башын югалткан ятим семьялар да йә базарчы кертеп, йә тегермәннәргә капчык ямап, ару гына торып яталар иде.

Шулай ук безнең үз хәлебез дә бер дә зарланырлык түгел иде. Бурадай сыерыбыз бар, тавыкларыбыз бар, су буеннан әпен-төпен үрдәкләребез кайта. Шулар өстенә безнекеләр күркә дә асрый башлаганнар. Ишегалдында ата күркә яман кабарынып, «голдыр-голдыр» гайрәт чәчеп, озын сыйраклы котсыз чебиләрне саклап йөри. Ә бу чебиләр, зурайгач, җилдә симерер өчен коймага, хәтта абзар кыекларына очып менә башлыйлар. Кыскасы, сөт, катык, каймак, йомырка үзебезнеке, күпме ашасаң да җитәрлек, көн дә базардан берәр кадак яшь тәкә ите алып керәбез, шуның өстенә Акколайдан дус башкорт көн саен бер чирек кымыз да кертеп калдыра. Шулай итеп, мин атам өендә курортник булып ятам.

Бу имин, тыныч елларда Дәүләкәндә яшьләр дә күбәеп китте. Кичәге малайлар, үсмер кызлар бүген инде егетләр һәм туташлар булып җиттеләр дияргә дә ярый. Искеләргә бу яңалар да кушылып, Дәүләкәнне бөтенләй җанландырып җибәрделәр. Һәртөрле уеннар, күңел ачулар, концерт-спектакль куюлар шушы чакларда аеруча бер көчәеп алды. Яшьләр арасында татулык бар иде әле, иҗтимагый нигездә дошманлашулар үзен артык сиздерми иде — мондый хәлләр соңрак, 1928—1929 еллардан башлап, кинәт бик куәтләнеп китте.

Әмма мин хәзер ул елларга кире кайтып, һәммәсен дә искә төшереп, тәфсилләп язып тора алмыйм. Бу язманың алдагы өлешләрендә өзек-өзек булса да шактый нәрсә язылды инде. Бәлки, миңа Казаннан кайтып йөргән шул биш-алты елым турында гына бераз язып үтәргә кирәктер... Әйткәнемчә, беренче кайтуым 1926 елны, ә соңгысы 1932 елда булды. Бусында өйләнеп, яшь кәләшем белән кайткан идем. Шуннан соң инде үзебезнең йортның бусагасыннан бүтән атлап керергә туры килмәде. Гаҗәп!.. Илле елдан артык вакыт эчендә Дәүләкәнгә ничә мәртәбәләр кайтып, кайткан саен йортыбыз янына барып, каршысында торып, капкасыннан керсәм дә, өй ишеген ачып керергә ничектер җөрьәт итә алмадым.

Ярар, булмаса... Инде әлеге кайтып-китеп йөрүләрдән күңелдә ниләр генә сакланып калды соң?.. Бу бит минем егет булып өлгергән, көч җыеп чибәрләнгән елларым иде. Бер дә бетмәс-үтмәстәй булып тоелган, әмма очкан коштай үтеп киткән яшьлегем!.. Барысы да булып узды гомернең төштәй иң кыска шушы дәвере эчендә — татлы хыяллар, яшерен өметләр, керсез дуслыклар, уңышсыз мәхәббәт, сызлану-сыкранулар, дөньяны бары якты, кешеләрне бары яхшы итеп күрергә теләүләр һәм шул ук кешеләр тарафыннан кагылу-сугылулар — әйе, барысы да булып узды... Һәм шушы төрле-

сен татырга туры килгән бик кыска-тыгыз дәвернең Дәүләкәнгә тигән өлешендә минем өчен баштагы берике елы гына азмы-күпме искә төшерерлек һәм сагынып сөйләрлек булып калды. Хуш, нәрсә минем исемдә соң, нәрсәне мин хәзер дә сагынам?

...Ике ел рәттән без, Дәүләкән яшьләре, Ачлы күлгә бардык. Сезнең «сәхрәгә чыгу»ны ишеткәнегез яки укыганыгыз бардыр — элекке заманда ял итү, күңел ачу өчен табигатьнең иркен, матур бер җиренә аш-сулар белән чыгуны әнә шулай дип атыйлар иде. Менә без дә мәшһүр күл буена, өч көнгә сәхрәгә чыгарга булдык. Моны Дәүләкән тегермәннәре биргән акчага комсомол оештырды. (Дәүләт кулына күчкән зур тегермәннәр акчаны комсомолга «агарту эшләре» өчен бирә торган булгандыр инде.) Башта, билгеле, актив тарафыннан зур гына хәзерлек үткәрелде. Егетләрдән һәм кызлардан концерт программасы да төзелде (бер-ике авылга да керергә тиеш идек). Шулай ук азык-төлек, савыт-саба, балта-пычкы кебек кораллар да әзерләнде. Аннары Ачлы күлгә кемнәрне алып бару мәсьәләсе хәл ителде. Сайлаганда, иң беренче нәүбәттә, әдәп белән дисциплинага игътибар ителде. Бигрәк тә әдәпкә таләп зур иде, чөнки халык арасына чыгабыз, ә комсомол үзен бу җәһәттән бик сакларга тырыша иде. Инде соңгысы — ничек бару мәсьәләсе. Ачлы күл Дәүләкәннән кимендә бер утыз чакрым булыр. Әйбер күп, күтәреп кенә барырлык түгел. Ул елларда әле аркага таудай рюкзаклар асып йөрүне белми идек. Димәк, атлар кирәк. Аларны атлы кешеләрнең малайларыннан сорарга туры килде: җигеп килсәң, барасың, килмәсәң — юк! — диделәр аларга... Шулай итеп, уникe җигүле ат волкомол йорты янына җыелды. Барынча киенгән, көязләнгән егетләр һәм кызлар, кечкенә төенчекләрен тотып, вакытыннан иртә килеп тә беттеләр. Бер-ике атка бөтен әйберләрне төяп, шулар өстенә зур казанны да каплап, калган арбаларга дүртәр-бишәр кеше утырышып, җомга көн сәгать уннар тирәсендә Ачлы тарафларына кузгалып киттек.

...Кырга чыккач та, алдагы арбаларның берсендә гармун тартып җибәрделәр. «Җомга»ны сиптерәләр генә. Шунда ук арба тирәсенә җыр яратучылар җыелышып та алдылар һәм китте җырлау, очынып-шашынып җырлау, ара-тирә өздереп сызгырып та җибәрәләр — һавадагы тургайлар тавышы да ишетелмәс булды. Бар иде әле ул чакларда Дәүләкәннең тургайлар белән ярышырлык җырчылары!..

Баручыларның иң күбесе минем чамадагы унҗидеунсигез яшьлек егетләр белән кызлар иде. Арабызда иң зурлар Зөфәр белән Сәетгали булгандыр — алар инде

егермедән узган комсомоллар, безнең белән җитәкчелек итүчеләр... Юл буенча диярлек гармун тавышы тынмады, җыр туктамады. Без, яшьрәкләр, арбаларга юньләп утырмадык та — кыр буйлап һаман куышып та чабышып бардык. Мин Гыйззетдин абзый кызы Мәрьямне куа-куа хәлдән таеп беттем. Бөтенесен кычкыртып куып тотам, ә бу болан баласын һич кенә дә җитеп булмый бит... Кызганыч, спорт ярышлары булмаган без яшь чакларда. Хәзер инде Мәрьям дә җитмеш биш яшьлек карчык... Шулай үтә икән ләбаса гомерләр!..

Төштән соңрак Корыятмаска барып җиттек. Бу Ачлы күл таулары артына, уйсурак җиргә урнашкан бер генә урамлы башкорт авылы — бәлки, Корыятмас дигән исеме дә шуңардан килә торгандыр... Безнең җитәкчеләр шунда ук мондагы «актив»ларны эзли башладылар, кызларыбыз, кайбер йортларга кереп, андагы кызлар, яшь бичәләр белән танышырга тотындылар. Ләкин бу бәләкәй генә авылда бернинди «актив» юк иде бугай, эзләсәләр дә андыйны тапмадылар, әмма бераздан кызыксынып, сүзсез-йомык кына егетләр һәм кыюрак кызлар безнең тирәгә җыелдылар. Арага керергә дә, кермәскә дә белмичә, күзләрен ялтыратып, бер читтә генә өелешеп торалар. Аларны, әлбәттә, тартырга кирәк иде. Башкорт яшьләре, гадәттә, күмәк уеннарны бик яраталар. Әле печәнгә төшкәнче, җәйнең иң хозур чагында бер авыл яшьләре икенче күрше авылга барып, шундагы яшьләр белән ындыр артында яки су буенда күмәкләшеп уйный торганнар иде. Менә шуны яхшы белгән безнең кызлар, урам чирәмендә түгәрәк ясап, чаштыр-чоштыр биергә дә тотындылар, аннары барыбыз бергә «сакчылы», «әйләнбәйлән» кебек уеннарны да башлап җибәрдек. Өелешеп, түземсезләнеп һәм чакыруны көтеп кенә торган авыл яшьләре «әйдәгез!» дию белән шунда ук уенга кушылып та киттеләр. Ул чакта әле авылның баерак кешеләрен ачыктан-ачык «кулак» дип атау юк иде һәм аларның кызларын, егетләрен дә арага кертәләр иде. Тәңкәле җилән киеп, озын чулпылар таккан кызлар яки кара чалбар белән күн итек кигән егетләр әнә шундый хәллерәк йортлардан килеп кушылганнардыр инде. Шул рәвешчә, бергә уйнап танышканнан соң, кызлары — кызларыбызны, егетләр — егетләребезне бүлешеп, үзләренә чәйгә дә алып керделәр. Читтән килгән үз ишләрен әнә шулай кунак итү — башкорт яшьләренең бер матур йоласы иде.

Ә кичен, көтү кайтып халык бушый төшкәч, кемнеңдер коймасы буенда ачык һавада концерт та бирдек. Тамашага яшьләр генә түгел, өлкән агайлар, җиңгиләр, хәтта, иңенә тунын салып, бабайлар да килгәннәр иде... Әй-

тергә кирәк, концертыбыз безнең шәп узды. Арада Гөлсем һәм Маһирә кебек матур җырчыларыбыз, Зөфәр кебек оста гармунчыбыз, Әпәләй кебек бик шәп биючебез дә бар иде. Мондый концертның бу авыл тарихында беренче генә булуыдыр, ахрысы, җыелган халык, хәтта тиктормас бала-чага да биһуш булып, шылт та итмичә тыңладылар. Һәм безнекеләр дә кечкенә авылның йолдызлар да тыңлап торган зәңгәр күге астында, читән койма буенда, бер-берсен алыштыра-алыштыра, бөтен белгәннәрен, бөтен дәртләрен биреп бетерергә тырыштылар. Инде соңгы җыр, соңгы уен тынгач та, өлкәннәр вак балаларын җитәкләп китеп бетсәләр дә, яшьләр һич тә таралырга теләмәделәр. Кызлары безнең кызлар яныннан китмәделәр, егетләре исә бездән аерылмадылар. Дөрес, үзләре башлап сорашмыйлар да, сөйләшмиләр дә, бары елмаешып, безнең авызларга карап кына торалар — гүя бездән тагын нидер көтәләр. Алар өчен генә киң урамны да гармун белән бер-ике тапкыр әйләнеп, беренче әтәчләр кычкырып тынгач кына йортларга таралыштык. Кызларыбызны өйләргә алып керделәр, ә без башкортның яшел «бесән» китереп өйгән абзар түбәсенә үрмәләдек. Арулуыбыз шул дәрәҗәгә җиткән икән, хуш исле печәнгә бату белән сеңдек тә киттек. Иртән «җитәкчеләребез» уятып йөрмәсә, бәлки, төш җиткәнче дә йомшак абзар башыннан төшә алмаган булыр идек.

Атларны җиккәннәр, урам буена тезелешкәннәр. Кырыклап кешенең җыелып беткәнен көтәләр. Өлкәннәребездән Зөфәр белән Сәетгали дә әле күренмиләр, нindидер эш кырып йөриләр, ахрысы... Чынлап та, бераздан алар таза гына бер йортның капкасыннан ике яшь тәкә күтәреп чыктылар. Бу ни хикмәт? — дип көтеп торабыз. Аяклары бәйләнгән тәкәләрне болар бер арбага китереп салдылар. «Нәрсә, әллә конфисковать иттегезме?» — дип сорыйбыз. «Юк,— диләр, көлеп,— сез гуҗларны сыйлар өчен тегермән акчасына сатып алдык...» Алар моны Дәүләкәннән чыгып киткәндә үк уйлап куйганнар икән. Бер арбага каплап салган зур казан да шушы тәкәләр өчен, имеш!..

Әйтергә кирәк, ул чакларда акча тоту мәсьәләсендә контроль йомшак булса да, гаделлек бик көчле иде. Бер тиенне исраф итү юк, йомып калу да, әлбәттә, юк иде. Гомумән, акчага, байлыкка, зиннәтләргә табыну яшьләр арасында үзе бер начар эштән санала иде.

Ниһаять, унике ат тезелешеп, бу сөйкемле, тын авылдан чыгып киттек. Корыятмас яшьләре арбаларыбызга тотынып, авыл очына кадәр озата бардылар. Әмма аларның берсе дә, чакырып карасак та, Ачлы күлгә хәтле

барырга җөрьәт итмәде. Күрәсең, алар «комсомолга ияреп» китәргә әле өлгереп җитмәгәннәр иде.

Ачлы күл таулар аша туры гына барганда, Корыятмастан ерак булмаска тиеш. Ләкин ат юлы шактый урау булып чыкты. Бара-бара төш вакыты җитә язды. Ахырда бер калкулык өстеннән алдыбызда кинәт кенә күлнең бер башы ачылды. Без инде аңа килеп тә җитә язганбыз икән — түбәндә генә тип-тигез су өсте көмештәй тонык кына ялтырап ята.

Ачлы күл түгәрәк түгел, ә озынча күл — буе сигез чакрым чамасы, иңе өч чакрым булыр. (Шулай дип әйткәннәре хәтердә калган.) Даны еракларга таралган бу күлне беренче мәртәбә күрүем. Әмма шулай да Ачлы күл миңа бик таныш кебек, чөнки аның хакында күп ишеткәнем бар. Аннары Мәҗит Гафуриның «Зыятүләк белән Сусылу» әкияте буенча да ул минем хыялыма нык кереп калган иде. Халык арасында таралган даны исә, беренче нәүбәттә, бу күлнең шифалы булуына ышану белән бәйләнгән. Якын тирәдән генә түгел, ерак авыллардан килеп тә аның комында күмелеп ятканнар һәм гаҗәеп саф, йомшак суында коенганнар.

Күлнең көньягында да тау, төньягында да тау — гүя ул кайчандыр тоташ булган зур тауны икегә аерган да, шуларның уртасына кереп яткан. Әнә каршыда гына Нора тауның күлгә киселеп төшкән текә кызыл яры да күренеп тора. Мәгәр каршыдагы Нора белән бирге яктагы тау кайчандыр бербөтен булгандыр дип күз алдына китерүе читен. Нора — шәп-шәрә ялгыз тау, ә монда таулар өстендә таулар өелеп тора. Алар биекләр, аларның күл өстендә үк стенадай басып торганнары бар, шулай ук күлдән читенеп, киң аланлык ясаган урыннары да бар. Кыскасы, без килеп туктаган бу якның таулары да мәһабәт-матур, иркен аланлыклары да куе үлән, әрәмәлек, карт агачлар белән капланган... Һәм бары бу якта гына кайчандыр текә таулардан кубып төшкән зур өстәл, хәтта кечерәк келәт хәтле кызгылт ташлар да күл читендә генә яталар. Шул ташларның суга кереп торган берсендә Сусылу чәчен тарап утырган, имеш. (Аны хәзер дә «Сусылу ташы» дип йөртәләр икән.) Күл асты патшасының бу сылу кызы, шаһзадә Түләкнең үзенә якынлашуын сизгәч, таштан тизрәк суга сикергән, ләкин озын кара чәчләре күпмедер вакыт су өстендә батмыйча торган, менә шул чакта егет тә тиз генә сикереп, кызның батарга өлгермәгән чәчләреннән эләктереп алган да Сусылу артыннан күл төбенә төшеп тә киткән, имеш!.. Әнә шулай сакланып калган минем хәтердә Гафури кулы белән язылган әкиятнең кызыклы бер күренеше!..

Хуш, ә без күлдән аз гына өстәрәк, тау итәгенең яшел чирәмле тигезрәк бер җиренә чегән таборы булып урнаштык. Әйбәт урын, су да якын, яр кырыенда куе әрәмәлек тә бар, читтәрәк ялгыз карт агачлар да үсеп утыра — тагын ни кирәк?! Атларны тугардык, әйберләрне бушаттык. Ләкин башка эшләргә тотынганчы, барыбыз бердән кубып, иң элек су керергә төштек. Күлнең чите буеннан-буена тыгыз ак комлык. Ул шундый чиста ки, адәм ташлап калдырган бер генә дә чүп тапмассың монда!..

Яр астына төшкәч, кызларыбыз сулга китеп, бер зур таш артына ышыкландылар, ә без уңга китеп, комлыкта гына чишендек. Ул чакта инде бөтенебез трусиклардан булсак та, егетләр белән кызлар бары аерым коеналар иде. Бу мәсьәләдә кызларыбыз шундый кырыслар, бергә коену түгел, якынрак бара башласаң да, чәрелдәп тавыш чыгаралар... Ярый, алардан башка да рәхәт безгә — әх, суы да суы!..

Әйткәнемчә, зур күлнең бөтен әйләнәсе ак комлык. Төбе тап-такыр. Бер җирендә дә камыш үсми, бер генә төшендә дә мәте юк. Чөнки күлнең бөтен әтрафы төрән кермәгән чирәм җир. Туфрак та, чүп тә аңа агып төшмәгән. Башкортлар күлне әнә шулай саклаганнар. Үзләре дә аның ярына утырмаганнар һәм читләрне дә җибәрмәгәннәр. Мәгәр революциягә чаклы ук әле Нора тау яклап, күлнең көнчыгыш очына бер урыс авылы килеп утырган. (Рөхсәтсез утырган дип әйтәләр иде.) Исемен дә инде хәтерләмим, ләкин без барып йөргән вакытларда шушы салам түбәле бик озын авыл гына Ачлы күл буен «бизәп» тора иде.

Су кереп чыккач, безнең барыбызны да яңадан «мәйданга» (яр башына) җыйдылар. Килмичәрәк торганнарны кычкырып, дәшеп алдылар. Сүз җитди булды, җитәкчеләр тарафыннан таләпләр каты куелды. Бөтен эш — ашау-эчү, су керү, уеннар оештыру, тауга менү, кырда йөрүләр бары бергә, бары бер үк вакытта гына булырга тиеш. Таралышып йөрүләр, төркемнән аерылып китүләр, бигрәк тә парлап йөрү каттый рәвештә тыела. Бу соңгысы әллә ничек сәер дә иде. Ни өчен егет белән кызга кайчагында икәүдән-икәү генә сөйләшеп йөрергә ярамый?.. Моның ни гаебе бар?.. Әмма — юк, ярамый, бу коллектив, коллективтан берәүнең дә аерылып йөрергә хакы юк, янәсе!

Без Ачлы күл буенда ике көн яттык. Ничек ял итүебезне, ниләр эшләвебезне тәфсилләп язып тормыйча, җыеп кына әйткәндә, вакытны монда гаять күңелле уздырдык. Безнең бәхеттән бу ике көн гел аяз, гел эссе булып торды. Көне буе диярлек судан чыкмадык, җылы комда аунадык. Һәм шушында ята торгач, бер зур гына ЧП да булып алды. Хөсәен исемле иптәшебез тоткан да күлнең

аръягына ялгызы йөзеп чыгып та киткән. (Ә күлнең киңлеген бу төштә өч чакрым диләр.) Егетнең чыгып киткәнен без соң гына шәйләп алдык — күл уртасына таба бер кара нокта бара да бара: нәрсә бу, кем бу? Хөсәен күренми, Хөсәендер, мөгаен, диделәр. Аптырап калдык, курка калдык, ә башлыкларыбызның гаять ачуы килде. Йодрыкларын төйнәп, авыз эчләреннән генә сүгенеп, су читендә арлы-бирле йөрергә тотындылар. Ләкин егетне кычкырып та, сызгырып та туктатып булмаячак — ул инде бик ерак киткән иде. Бөтенебез су читенә тезелешеп, һаман ераклаша барган «кара нокта»га карап торабыз. Кайбер кызларыбыз шыңшый да башладылар... Бер дә кызыклы тамаша түгел шул, күңелгә төрле шомлы уйлар да килә — ни булып бетәр моның ахыры?..

Ике егетебез аның артыннан йөзеп китмәкче дә булганнар иде, ләкин башлыкларыбыз җибәрмәделәр: берәү урынына өчәү батсагыз, бик күпкә китәр, диделәр. Мәгәр Хөсәен арабызда яшькә олырак та, тазарак та һәм тыйнаграк та егет иде. Үз хәлен, үз чамасын белмичә, башбаштакланып кына ул мондый хәтәр эшкә бармаска тиеш иде югыйсә. Башына тай типмәгән булса!..

Һәм менә бервакыт «кара нокта» күздән дә югалды. Кая китте, ни булды? — без хәтта тыныбызны алудан туктадык. Күп тә калмаган шикелле иде бит, күп тә... Ә бераздан күлнең аргы читендә нечкә генә бер карачкы күренде. Әнә безгә карап, кулын да күтәрде бугай... Бу ул, бу Хөсәен! — Шатлыктан без дә кулларны күтәреп, аңа «ура» кычкырдык. Бер мизгелдә курку, шомлану, ачу — барысы да юкка чыкты. Алар урынына һәркайсыбызда ирексездән соклану, горурлану, хәтта «аның урынында нигә мин түгел?!» дигәнрәк көнләшү дә туган кебек булды.

Хөсәен Нора тавының рус авылына караган итәгенә барып чыккан иде. Хәзер ул әнә шуның ярында ясап куйган мәрмәр сын шикелле басып тора. Яңадан бу якка да йөзеп чыга башламасын дип, безнең башлыклар ике атка ике җиңелрәк егетне атландырып, аргы якка чаптырдылар. Күлнең көнчыгыш башыннан әйләнеп барганда Норага әллә ни ерак түгел иде.

Ә кичкырын, бөтенебезне җыеп, Хөсәеннең бу кыюлыгын бик каты хөкем итү булды. Әгәр дә мәгәр яңадан мондый башбаштаклык эшләсәң, белеп тор, беркая алып чыкмыйбыз, ияртмибез, диделәр аңа. Хөсәен, тезләрен чәнчеп җиргә утырган килеш, бөтен шелтә-тиргәүләрне ничектер иренеп кенә тыңлады. Үзен аклап бер сүз дә әйтмәде... Әмма күпме генә шелтәләмәсеннәр, аңа сокланып карамыйча мөмкин түгел иде. Һәм соңыннан да

барысы онытылып, тик Хөсәеннең Ачлы күлне иңләгән дигән даны гына торып калды.

Шушы ЧПдан башка бүтән бер хәтәр эш тә булмады. Күп уйнадык, күп көлдек, күп җырладык, Ачлы тауларының иң биекләренә менеп йөрдек, хуш исле чәчәкләр, шифалы үләннәр, балтырган-какылар җыеп кайттык. Ә кичләрен учак әйләнәсендә төрле кызык-мәзәкләр сөйләшеп утырдык. Гаҗәп, көне буе йөреп, сулар кереп аруга карамастан, монда бер дә ятып йоклыйсы килми иде. Таң җиле исеп, аркаларны кымырҗыта башлагач кына кызларыбыз куышка, ә без арбаларга тарала торган идек... Һәм, үләнгә тышаулап җибәргән атларның пошкыруын ишетә-ишетә, чоңгылга чумгандай, тирән йокыга да китә идек.

...Тагын көн туа, кош-кортлар уяна, күл башыннан ашыкмыйча гына кояш күтәрелә. Йоклыйсы иде бит әле, тагын әзрәк кенә йоклыйсы иде, әмма юк, булмый, үзең тора алмасаң, аягыңнан сөйрәп торгызалар: Ачлыга йоклап ятар өчен килмиләр!..

Чынлап та, безнең әйләнәдә сихри дөнья түгелме соң?! Таулар, ялан-сәхрәләр, урман-әрәмәлекләр... Һәм шулар уртасында Ачлы күл яшел каймалы биниһая зур таш табактагы үтә күренмәле су шикелле, көмеш көзгедәй тонык кына елтырап, тик урыны-урыны белән генә сөттәй ак пар көйрәтеп ята... Бәлки, әле яңарак кына үзенең дүрт кырлы зур кызыл ташында озын чәчләрен тарап утырган Сусылу да безнең килгәнне ишетеп, тизрәк күл төбенә чумгандыр... Тирән серле, тылсымлы ич бу әкиятләргә кергән Ачлы!.. Әмма адәми зат күптән инде табигатькә баш июдән, аның сафлыгын, тынычлыгын саклаудан туктады... Барысына да тик ул хуҗа! Әйдәгез, егетләр, без дә чапыр-чопыр кереп китик, булмаса!..

...Шулай башланды безнең икенче көнебез дә. Монда бик мөһим бер нәрсәне әйтәсе калган икән әле... Теге Корыятмастан алып килгән ике яшь тәкәне беренче көнне үк Сәетгали белән ике егет читтәге карт имән төбенә илтеп суйдылар, әйбәтләп тунадылар, түшкәсен бүлгәләп кызларга бирделәр. Ә кызларыбыз ике көн рәттән зур казанда ашын пешерделәр. Ачык һавада, яшел чирәмдә әкрен генә кайнап пешкән тәкә итенең һәм шулпасының тәмлелеген әйтеп кенә бетерерлек түгел иде. Торыпша җәйгән зур табын әйләнәсенә аяк бөкләп яки кырын ятып ашаган бу ашны соңыннан да берәү дә тиз генә оныта алмагандыр. Әле шуны да әйтергә кирәк: монда бернинди эчү дигән нәрсә юк. Аны уйлаган, теленә алган кеше дә юк. Комсомол абыйлар тыйганга күрә генә түгел, ә эчүнең тәмен, нәрсә икәнен белмәгәнгә күрә... Без яшь чакта аракыны өйгә дә кертмиләр иде.

Агудан сакланган шикелле саклаланалар иде аңардан... Эчкән кеше — беткән кеше, дип әйтә торган иде минем атакай да... Шуның өстенә мәдрәсәдә укыганда хәмер эчүнең шәригать тарафыннан катгый рәвештә тыелганын, «билкөлли харам» икәнлеген, аны истигъмаль[1] итүчеләрнең туп-туры җәһәннәмгә озатылачагын безгә тукып кына тордылар... Шулай итеп, ата-ана тәрбиясе, шәригать куркытуы һәм комсомол тыюы безнең дәвердә бер вакыткарак туры килде. Шуңадыр, ахры, без озаграк бозылмыйча тордык. Безнең арада бер генә тәмәке тартучы да юк иде әле. Әнә нинди саф чакларыбыз булган икән ләбаса, әкәмәт!..

Өченче көнебездә, кояш белән бергә торып, сулар кереп, чәйләр эчкәннән соң, кайтырга җыена башладык. Атларны җиктеләр, әйберләрне арбага салдылар. Бу эшләрне бетергәч, гүя саубуллашыр өчен барыбыз да күл читенә җыелыштык. Кызларыбыз суга тәңкә дә ташладылар: «Хуш инде, Ачылыкай, үпкәләп калма!» — диделәр аңа, тере җан иясенә дәшкәндәй... Кузгалып киткәч тә, без һаман әле артыбызга борылып карый-карый бардык. Тик серле-тын күлебез тау артына күмелгәч кенә, аерылышуыбыз белән инде килешкәндәй булдык.

Кайтканда да юл буе җырлаудан, уйнаудан, төшеп йөгерешүләрдән туктамадык дисәм дә ялган булмас. Моның хак икәнен кайтып җиткәч мин бик шәп тойдым... Инәйнең пешереп көткән ашын ашаганнан соң, яткан идем, тәмам сеңеп йоклавыма карамастан, минем колагымда берөзлексез әкрен генә гармун тавышы һаман чыңлап торды. Гүя су өстендә чайкалган шикелле музыка кочагында тибрәнеп йоклыйм, имеш!.. Өч көн буена тыңлаган җыр-гармун тавышы кешегә бу кадәр дә сеңәр икән!

Еллар узды, күп хәлләр онытылды, ә менә Ачлыга барып кайтуыбыз онытылмый, хәтерләрдә һаман да саклана. Хәзер инде ул «баруларга» катнашкан, уйнаган-көлгән, җырлаган-биегән яшьләрнең күбесе юк, үлеп беттеләр. Мин исән дә тагын өч кенә кешене беләм: Маһирә, Мәрьям һәм Гөлсем карчыкны... Тик менә Гөлсемне егерменче елларның ахырыннан бирле күргәнем юк. Төсе-бите белән чибәр японкаларга охшаганрак, бик сөйкемле һәм бик нечкә җанлы бер кыз иде ул... Бик матур җырлый да иде. Спектакльләр куйганда беренче героинябыз иде... Күпләр аңа гашыйк та иде... Чәчәктәй нәфис, нечкә хисле кызыбыз нindirәк икән менә хәзер?.. Күрәсе дә килә, күрергә дә куркам. Бәлки, минем үземә

[1] *Истигъмаль итү* — куллану, файдалану.— *Ә.Е.*

дә күренергә кирәкмидер инде. Барысы да искечә, Ачлы буйларында йөргәндәгечә генә саклансын — шулай кадерлерәк.

Яшьлек, саф, пакь, гөнаһсыз яшьлек, таң алдыннан күргән кыска төш кебек кенә булып калды. Әмма яшьлекнең үзен сагынудан да бигрәк, минем өчен иң мөһиме яшьләр арасындагы татулык иде. Без әле бер-беребездән читләшергә, ятлашырга, хәтта дуслык җепләрен дә өзәргә өлгермәгән идек. Тик, нихәл итәсең, озакка бармады бу дәвер. Ике-өч ел да үтмәгәндер, яшьләрнең шактый өлеше, көчле җил туздыргандай, төрле якка чәчелеп тә бетте. Кайберләренең кая киткәнен дә белүче булмады.

Сугыштан соң, илленче еллардан башлап, Дәүләкәнгә еш кына кайтып йөрсәм дә, Ачлы күлгә бер генә тапкыр да барып чыгарга туры килмәде. Теләк, әлбәттә, бар иде, күрәсем бик килә иде, ләкин ул теләкне берничек тә гамәлгә ашырып булмады. (Транспорт юк, җәяү барырга ерак, ә җитәкчеләрдән сорарга кыюлык җитмәде.) Кайткан саен шулай, фарыз эшне үти алмагандай, китек күңел белән китеп барырга туры килә иде... Ә еллар һаман уза торды, Ачлы да миннән гүя ераклаша барды, кайтып күрә алуыма өмет тә бетә язган иде. Әмма безнең бу «Жигули»лар заманында еллар буена үтәлмәгән теләгең бер көн, бер сәгать эчендә дә үтәлергә мөмкин икән. 1983 елның август урталарында авылдашым профессор Сөләйман Еникеев миңа шалтыратты.

— Әмирхан, без иртәгә өч кеше минем машинада Уфага чыгып китәбез, теләсәң, сине дә алабыз,— диде ул.

Шунда ук минем телемә, моңарчы йоклап яткан уйны кемдер төртеп уяткандай, үзеннән-үзе бер сорау килде:

— Ә Ачлы күлгә тиябезме?

— Әбәзәтелне! — диде Сөләйман.

— Алайса барам.

— Иртәгә сәгать җидегә урамыңа чыгып тор!

— Булды!

Һәм, шулай итеп, икенче көннең иртәсендә, без, дүрт Каргалы төмәне, «Жигули» машинасында Уфага таба чыгып та киттек. Баручыларның миннән кала берсе, Сөләйманның якын дәдәсе (аталары бертуган) Рәүф абзый, икенчесе Сөләйманның бертуган энесе, күптән түгел гарәп илләреннән кайткан инженер Фәрит иде. Машинаны да бик җилле генә ул алып бара. Юлыбыз Чистай, Әлмәт, Бөгелмә аша. Артык кызу чапмадык, урман ышыгында туктап ял да иттек, Чистай белән Бөгелмәне дә карап уздык.

...Хәзер инде юлыбыз — туп-туры Ачлы күлгә... Хәер,

юл үзе бик турыдан түгел иде, Бүздәк аша шактый урап барырга туры килде. Икенче көнне генә без Ачлы буйларына барып чыктык. Ләкин Сөләйманның башта Кыдырач авылына керәсе килде — малай чагында атасы белән шул авылда булгалаган икән. Ярый, малай чак хакына без риза, бәлки, анда кымыз да булмасмы әле... Киттек Кыдырачка... Ул Ачлыдан биш-алты чакрым читтә иде. Урманлы тау буена утырган урта зурлыктагы башкорт авылы. Киң генә урамыннан карана-карана барып, ахырда колхоз идарәсе каршында туктадык. Сөләйман килеп йөргән чакларда атасының монда якын танышлары булган, хәзер инде алар юк... Бердәнбер сугыла торган капка — ул да булса колхоз идарәсе... Кердек, исәнләштек, кемнәр икәнебезне әйттек. Колхоз председателе үзе юк иде, ләкин телефон белән эзләп таптылар — озакламый килеп тә җитте. Кул биреп таныштык. Безнең Казан чаклы ерак җирдән килеп чыккан кешеләр булуыбыз аны бераз аптырашта калдырды шикелле. Ләкин әзрәк сөйләшеп, безнең дә шушы якларда туыпүскән кешеләр икәнебезне белгәч, ул, ниһаять, тынычланды, хәтта беркадәр ачылып та китте. Сәрвәр Әюпов фамилияле бу сабыр-басынкы гына егет үзе дә бирегә председатель булып Дәүләкәнгә якын гына Исмәгыйль авылыннан килгән икән. Мин дә бит инде Дәүләкәннеке — шулай итеп, без якташлар да булып чыктык.

Аның колхозына, Кыдырачтан башка, Ачлыга якын тагын берничә авыл керә икән, шуңа күрә колхозның исемен дә «Ачлы күл» (башкортча «Аслы күл») дип калдырганнар. Һәм бик дөрес эшләгәннәр. Халык телендә борыннан яшәп килгән, җире-суы белән бәйләнгән матур исемнәрне колхозга биреп саклау, миңа калса, бик күркәм эш. Туган-үскән илгә хөрмәтне дә бик көчәйтә ул.

Кызу эш өсте булуга карамастан, Әюпов иптәш вакытын бездән кызганмады. Кырлар буйлап чабудан туктамаган үз машинасына мине һәм Сөләйманны утыртып, «Жигули»ны исә артыннан ияртеп, безне Ачлы күлгә алып китте. Авыл читендәге кымызчылар өеннән зур гына савытка кымыз да салдырып алып чыкты. Борылмалы юллардан барып, Буранголны да үткәч, безне Нора тавына алып менде... Менә сиңа Ачлы күл... Ачылыкай!.. Нора өстеннән бөтен иңе-буе белән күренеп ята. Әнә бер башы, әнә икенче башы, әнә нәкъ каршыда моннан илле җиде ел элек килеп, безнең «сәхрә кылып» яткан урыннарыбыз... Күл читендәге зур, кызыл ташлары да ята икән әле... Мин үзем хискә тиз бирелүчән кеше, хыялымнан бервакытта да чыкмаган шушы җиргә ашкынып килдем, әмма — ни гаҗәп! — мин тыныч, мин берни дә кичер-

мим, мин тик искә генә төшерергә тырышам. Ничек аңларга мондый хәлне?.. Артык күп еллар үтеп китү моңа сәбәп микәнни, шуның аркасында үзеңнең үткәнеңә битараф калып була микәнни?.. Ераклашу һәм ятлашу — шушымыни инде ул... картлык галәмәте?!

Әйе, каршымдагы «Ачлы» — шул ук «Ачылы», зураймаган да, кечерәймәгән дә кебек, тик көне бүген җилле булганга күрә, күл өсте җыерчыкланып, караңгыланыбрак тора. Шулай да мин аңарда шактый зур үзгәреш күрдем: кайчандыр таш табактагы су шикелле чип-чиста күлнең хәзер күп кенә җирен камыш басып киткән... Кайдан бу камыш, сәбәп нәрсәдә?.. Элекке заманда Ачлы әйләнәсендәге җирләрнең тәрән кермәгән чирәмлек булуын әйткән идем бугай. Башкортлар аны шулай саклаганнар... Безнең заманда исә ул чирәм җирләрне чәчү кырларына әйләндергәннәр. Ел да сөрәләр, ел да нидер чәчәләр һәм ел да кар, яңгыр сулары сөрелгән җирнең туфрагын күлгә агызып төшерә. Менә шуңардан күлдә камыш, күлдә ләм, һәм табадай төбе дә аның баткакка әйләнеп бара торгандыр. Күл өчен бу зарарлымы? Камышлар, ләмнәр һаман шулай баса барса, Ачлыдан нәрсә калыр? Элек бит Ачылы чисталыгы белән дан тота иде, шифалы санала иде. Халык, сихәт теләп, аның комында күмелеп ятарга, суында коенырга килә иде.

Нора өстендә Кыдырач кымызын да эчтек, Сөләйманның энесе безне фотога да төшерде — инде кузгалырга да ярый иде. (Председательнең вакыты белән дә исәпләшмичә булмый.) Ләкин Ачылыдан тиз генә аерылып та китәсе килми, бигрәк аргы якны да бер әйләнәсе килә иде. Шунда бит инде күл буеның иң матур урыннары... Кайчандыр йөргән, таптаган җирләр... Әюпов туган, минем теләкне сизгәндәй, безгә шул яктагы ял базасында кунып китәргә тәкъдим итте. «Алай буламы соң?»— дип сорагач, ул кыска гына итеп: «Эшлибез аны»,— диде. Без бер-беребезгә караштык та риза булдык.

Базаның директоры Дәүләкән кешесе икән — Әюпов безне менә шуңа ерактан килгән кунаклар итеп тапшырды. Директор безне ике катлы йортның югарыдагы ике бүлмәсенә урнаштырды. Шунда ук ашау-эчү дә тәкъдим иттелде. Ләкин без башта чыгып, йөреп кайтырга булдык.

Базаның урнашкан җире өч ягын да тау әйләндереп алган, ачык ягы Ачлыга карап торган, зур бер аланлык иде. Тау буйларында куе агачлык, ачыграк урыннарда билдән куе үлән, тик аланлыкның урта бер җире генә яшел чирәм. Без менә шул чирәмдәге сукмактан күлнең ярына килдек, уңайлырак җиреннән су читенә — комлыкка да төштек.

Бу инде Ачлы үзе, аның борын-борыннан ук кошларны, җәнлекләрне, кешеләрне үзенә тартып торган көмештәй саф суы. Ялкау гына чайкалып, читендәге комлыкны «ялап» ята... Кереп карыйсы иде бит, теге еллардагы кебек колач салып, бер иңлисе иде бит!.. Дәрт сүнүен сүнмәгән дә, тик дәрманны кайдан алырга?.. Юлдашларга карыйм, Рәүф абзый белән Сөләйманның керергә исәпләре юк, куркалар... Ә менә Сөләйман энесе Фәрит чишенде дә кереп тә китте. Салкынмы, тирәнме дип тә тормады егет!.. Юк, болай булгач, миңа да куркып тору оят. Бер яшьлектә, бер картлыкта — тапшырдык!..

...Чишенеп керүгә, Ачлы өтеп алгандай итте. Берике тапкыр чумып, чиркануны качыргач кына йөзеп киттем. Ничава, түзәрлек. Суы шундый ук чиста да, йомшак та икән, йөзүе дә ничектер җиңел һәм рәхәт!.. Әйләнеп килеп баскан идем, төбе дә тап-такыр. Моннан ярты гасыр элек тә шулай түгел идеме соң?! Юк, тиз генә бирешмәс әле бу асыл күл, борынгы сафлыгы, чисталыгы, әкиятләре белән сакланыр әле ул!.. Көче-кодрәте зур аның, тик кеше дигәнең кадерен генә белсен иде!

...Сулар кереп, чистарып-җиңеләеп кайтуыбызга мул табын әзер иде. Безне ике чибәр генә татар кызы кунак иттеләр. Казаннан ук килүебезне белгәнгә күрәдер инде, үзләренчә чын хөрмәт күрсәтергә тырыштылар.

Шулай кәефле генә ашап-эчеп, күңелле генә сөйләшеп утырганнан соң, без, кызларга рәхмәт әйтеп, үзебезнең бүлмәләргә кердек. Көне буе машинада селкенү, монда да шактый йөрү бик җиткән икән — без йомшак урыннарга тизрәк сузылу ягын карадык. Башта һавага чыгып кердек, караңгы инде төшкән, кош-корт та йоклаган, тауларда һәм Ачлы өстендә тирән, сизгер тынлык...

...Иртә генә торып, кызлар хәзерләгән чәйгә утырдык. Хәлебезне белергә тагын директор керде. «Әюпов килгән иде»,— диде ул безгә... «Кайчан?» «Кичә төнлә... Сезнең йоклаганны белгәч, кире кайтып китте...» Бик үкендек без бу эшкә, ник уятмадыгыз, дип зарыбызны да белдердек... Ихлас, чынлап кызгандык Сәрвәр туганны... Күпме эш, күпме мәшәкать аның өстендә, йокы юк, ял юк, җитмәсә, без менә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бер артык йөк булып төштек үзенә... Әмма шуңа да карамастан, эшләреннән ычкыну белән, йокы сәгатьләрен калдырып килгән ләбаса!.. Бәлки әле, безнең янда бераз язылып, әзрәк сыйланып та, Татарстан яңалыкларын да ишетәсе килеп утырыр өчен килүе булгандыр... Кызганыч, бик кызганыч!.. Гаҗәп кешеләр бу колхоз председательләре — бигрәк тә район үзәгеннән читтәге, артык мактамаганнары... Сабыр, түзем, күндәм, һәм шуңа

күрәдер инде ул бүгенгедәй кырыкка ярылырдай бер вакытта безнең эше узгынчы кунакларга сый-хөрмәт тә күрсәтергә тиеш әле... Әлбәттә, без Сәрвәр Әюпов алдында бик бурычлы идек. Ул монда яңа яшь председатель икән. Әйтүенә караганда, «Аслы күл» колхозы үткән ел беренче мәртәбә ил алдындагы йөкләмәләрен үтәгән, быел да үтибез дип бик нык ышанып тора. Менә бездән дә аңа иң изге теләк һәм иң зур рәхмәт!.. Ә безгә исә хәерле юл!

Бу сәфәр, әйткәнемчә, 1983 елның августында булды. Сез, хөрмәтле укучым, бәлки, игътибар да иткәнсездер инде — минем кайчандыр булып киткән җирләремә әйләнеп кайтуым яки кайчандыр миңа якын булган кешеләр белән яңадан очрашуым кырык-илле еллардан соң гына кабатлана. Ни өчен бу чаклы күп еллар узгач кына дип гаҗәпләнергә мөмкин... Мин менә хәзер шуның сәбәпләрен ачмакчы булам. Бу исә шушы озын язманың иң җитди ноктасына җиттем дигән сүз.

Вакыт — рәхимсез, сиздермичә генә үтүен белә. Инде август аена да кердек, Дим буйларының иң киеренке һәм иң күңелле зур эше — печән өсте дә үтеп китте. Киң тугайлар печән кибәннәре белән чуарланды. Аларга карагач, ничектер ямансу-моңсу да һәм... җанга җиңел дә булып китә. Ямансу, чөнки кадерле җәй үтеп бара, җанга җиңел, чөнки күз алдында әнә нинди муллык!.. Моны күрмичә һәм моңа сөенмичә мөмкин түгел. Чәчәкле, хуш исле болын үләнен ашаган сыерларның сөте нинди куе, сарыкларның ите нинди тәмле, атларның күңелләре нинди көр булачак! Мин Дим буеның ризыкларын татып калган кеше, тәме-ләззәте әле дә онытылмый кебек, шуңадыр инде су буендагы болыннар миңа бик якын да һәм бик кызганыч та!

...Үтте, сизелмичә дә калды, менә китәр көннәребез дә җитте. Фәтхелислам белән Хәбибрахман үзләренең уку йортларына кайтырга тиешләр, минем өчен исә ул мәҗбүри түгел. Мин ирекле кеше, расчет алып кайткан кеше, миңа китмәскә дә була, яки теләсәм кайсы якка чыгып китә алам. Әмма мин студент шикелле үк Казанга ашкынам, Казансыз мин инде тора алмыйм, язмышым минем шунда, күрәчәкләрем мине шунда тарта. Әлбәттә, ап-ачык максатым бар: мин быел, һичшиксез, берәр уку йортына керергә тиешмен. Башкача ярамый, башкача мөмкин түгел, хәтта әдәбиятка керү дә минем өчен ул хәтле үк зарури түгел. Дөрес, язучы булу хыялы миндә яши, әмма аның өчен дә бит белем алу кирәк.

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку,
Илтеп күккә җиткән уку,
Уку, уку, уку,—

ди бит әнә Сәгыйть абзый Рәмиев тә!..

Кыскасы, без яңадан Казанга юл тоттык. Әйтергә кирәк, былтыр гына әле Казан каласы күпләр өчен әллә кайда бик еракта кебек иде, чакырып-дәшеп тә берәүне дә кузгатып булмый иде, быел исә, Шәвәлидән күрмәли дигәндәй, безнең арттан шактый гына яшьләр иярделәр. (Бүтәннәр салган сукмактан атлавы җиңелрәктер, ахрысы.) Шулар арасында Казак Усман да бар иде. Без берберебезне бик аз белә идек, Дәүләкән кебек кечкенә җирдә торсак та, юньләп аралашканыбыз булмады. Ләкин ниндидер бер эчке сизенү белән мин аның миңа начар караганын тоеп йөри идем. Һәрхәлдә, мин аңардан яхшылык көтми идем... Төрле вакыттарак килеп, уку йортларының бусагаларын таптап йөри торгач, кызларыбыз белән егетләребезнең кайберләре Татрабфакка, кайберләре исә педтехникумга керделәр. Ә Казак Усман туп-туры совпартшколага барып кергән дип ишеттек. Ул Дәүләкәннең «карт» комсомолы, ихтимал, направление белән килгәндер дә... Гомумән, социаль чыгышы әйбәтләргә һәм комсомолларга укырга керүе ул чакларда бик җиңел иде.

Минем укырга керү мәсьәләсе шактый ук катлаулы иде. ВУЗга мин керә алмыйм, чөнки урта белемем юк. Димәк, башта урта белем алырга кирәк. Моның өчен нинди уку йортын сайларга?.. Аның әле стипендиясе белән торыр җире булуы да минем өчен бик мөһим, чөнки өйдән миңа ерак калада яшәрлек ярдәм булмаячак — мин моны белеп үк килдем.

Казанда ул елларда эшче-крестьян яшьләренә махсус урта белем бирә торган ике зур уку йорты бар иде. Берсе аның — Татрабфак, икенчесе — университет каршындагы Госрабфак (ягъни дәүләт рабфагы)... Уйлап тордымтордым да менә шушы Госрабфак дигәненә сугылып карарга булдым. Социаль чыгыш ягыннан минем анда үтүем икеле иде. Шулай да формаль яктан караганда үтәргә дә тиеш кебекмен. Кулымда атайның кустарь булуы турында белешмә бар — сатуын ул 1925 елның язында ук ташлаган иде. Ә дөньяга килгән чагымда атам-анам авылда торганнар, чын крестьян булганнар — димәк, чыгыш ягыннан да туры киләм дигән сүз... Шул рәвешчә, мин крестьян гаиләсендә туган кустарь баласы буларак, рабфакка үттем. Ә менә атайның крестьянлыкны ташлап, кустарь булганчыга кадәр унбиш ел буена сату итүе йомылып кал-

ды, дөресрәге, миннән анысын сорамадылар, ә мин инде үзем аны әйтеп тормаганмындыр, билгеле. Бу бит 1926 ел иде, чыгыш мәсьәләсендә артык төпченү булмагандыр, ахрысы. Чөнки ул елны мулла, сәүдәгәр балаларыннан төрле уку йортларына керүчеләр аз булмады. (Рабфакларда да алар бар иде.) Социаль чыгышка аеруча әһәмият бирү, каты таләп кую һәм яшереп кергәннәрне күпләп сөрү бераз соңрак, 1927—1928 елларда башланды. Бу «кызык» вакытлар турында сүз булыр әле.

Ә бүгенгесе көндә мин Госрабфак студенты!.. Казан университетының аудиторияләрендә укып йөрим. Островский урамындагы торак йорттан урын бирделәр, стипендия дә тәгаенләделәр. Күпме икәнен хәтерләмим, һәрхәлдә, студентларча яшәргә җитәрлек (чамалап кына тотканда) — хәзер инде «белем гранитын» тешләрне сындырмыйча ипләп кенә кимерәсе калды. Әмма «кимерүе» җиңел түгел иде, чөнки бөтен укулар рус телендә бара, ә саладан килгән татар малайларының русчасы — үзегезгә мәгълүм инде! Хәер, мондагы укытучыларыбыз барысы да диярлек университетның үзеннән яки элекке гимназияләрдән — чәйнәп салгандай бик шәп төшендереп бирә торганнар иде.

Казанда укырга килгән татар яшьләре елдан-ел күзгә күренеп арта бара. Былтыр да аз түгел иде, быел исә аеруча күп... Кайдан гына килмәгәннәр — Себер, Урал, Донбасс, Оренбург, Әстерхан, Саратов, Сембер, мишәр яклары Касыйм, Тамбов, Пензадан — кыскасы, санап та бетерерлек түгел. Әмма иң күбесе Башкортстаннан — татар һәм башкортның иң күп җиреннән. Тиз арада Казанда аларның үзләренә аерым Башземлячество дигән җәмгыятьләре дә оешты.

Хәзер инде татар яшьләре бөтен ВУЗларда һәм техникумнарда укып йөриләр. Шулай да аларның аеруча күп тупланган берничә «ноктасы» да бар иде: болар Көнчыгыш педагогия институты (ВПИ), Татрабфак, педтехникум, театр техникумы һәм РТЯ, ягъни татар телен гамәлгә ашыру курслары. (Кайчагында, көлеп, «Рокыя курслары» дип тә атыйлар иде.) Боларга керүе дә җиңелрәк булгандыр, ахрысы... Укучылары да, әйтергә кирәк, бик дәртле яшьләр иде, үзләрен бик хөр тоталар, әдәби хәрәкәткә дә бик актив катнашалар иде. (Билгеле булганча, соңыннан язучы булып танылып китүчеләрнең дә бик күбесе шулар арасыннан чыкты.) Бу уку йортларының кайберләрендә, мәсәлән, Татрабфак белән педтехникумда атна саен диярлек әдәби кичәләр була торган иде. Хәзерге Фәннәр академиясе филиалының утырышлар залында үтә иде ул кичәләр. (Монда Татрабфак

иде.) Уеннар кызып җиткәч кенә, залга Такташ белән Кутуй килеп керәләр — алар инде яшьләрнең кумиры, ә кумирлар, үзегез беләсез, соңгарак калып йөриләр. Шуңа күрә аларны шаулап-алкышлап каршы да алалар.

Мин монда ТКУны телгә алмадым әле. Ягъни Татар коммунистлар университетын... Заманында бу бик танылган уку йорты иде. Урнашкан җире башта Горький урамындагы хәзерге травматология институтында булса, соңыннан Арча кырындагы элеккеге Духовная академия бинасына күчте. Укучылары да политик җәһәттән бик чарланган үткен-чая егетләр иде — шул елларның әдәби хәрәкәтендә алар бик актив роль уйнадылар.

Мине дә, билгеле, әдәбият дөньясы бик кызыксындыра иде. Укуга дигән вакытны кысып булса да әдәби кичәләргә, язучылар җыелышына йөрергә тырыша идем... Ниләр бар соң бу әдәбият дөньясында, кемнәр нәрсә эшлиләр анда?.. Сорауны болай зурдан куйгач, укучының да миннән, табигый, күпне көтүе ихтимал. Хәлбуки мин бит әле әдәбият дөньясының ишеге тирәсендә кереп булмасмы дип йөрүче бер яшь студент кына — минем кебекләр аз түгел иде ул тирәдә... Кыскасы, һәм ерак, һәм югары әле ул дөнья миннән!.. Нәшрият белән редакцияләрнең дә кайда икәнен юньләп белмим әле мин... Бердәнбер барып йөргән җирем әлеге шул «яшь язучылар түгәрәге»... (Аның да оештыручысы кем дә җитәкчесе кем — миңа билгесез.) Һәр җыелышта диярлек Такташ, Кутуй, Нәҗми, Туфан кебек инде танылып та, шактый ук шау-шу да кузгатып өлгергән һәм популяр да булып киткән шагыйрьләр катнаша иде. Болар әдәби хәрәкәтнең лидерлары!.. Күпчелек исә беренче адымнарын гына атлаучылар, исемнәре әле яңа-яңа гына ишетелә башлаган бик тынгысыз яшьләр... Һәм бу яшьләр, сүз алсалар, теге танылган лидерларны да еш кына аяп тормыйлар иде. Шуңар күрәдер, ахрысы, өлкән яшьтәге исемлерәк язучылар монда юньләп күренмиләр яки бик сирәк кенә килеп чыккалыйлар иде. (Мәсәлән, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Садри Җәләл кебекләр.) Тиргәлсә дә, сүгелсә дә бердәнбер даими йөрүче өлкән кеше — кайсыдыр техникумда татар әдәбиятын укытучы һәм тәнкыйтьче Хәйретдин агай Вәли иде. Бу актив адәм тотлыга-тотлыга сөйли, бәхәсләшергә ярата, шуның аркасында аңа үзенең шәкертләреннән дә каты гына эләгә торган иде. Утызынчы елларның башында булса кирәк, бу кешене әдәбияттан бөтенләй кысып чыгардылар.

Быел, ягъни 1926 елның көзендә, Казанга читтән укучылар күп килгәнгә күрәдер инде, әдәбият түгәрәгендә дә шактый гына яңа кешеләр күренә башлады. Алар-

ның кайберләре яшькә миннән олырак иде бугай, ләкин, тулаем алганда, барысы да миңа тиңдәш бер чамадагы егетләр иде. Тиңдәшләр булгач, мин аларны тизрәк белергә дә тырыштым һәм озакламый йә сорашып, йә танышып һәркайсын белдем дә диярлек. Өчесе Башкортстаннан килгән: Фатих Кәрим, Сәгыйть Агиш, Мирсәй Әмир, ә берсе Әстерхан егете Габдрахман Минский булып чыкты. Шул ук көзне булса кирәк, Гази Кашшаф (ул чакта Кәшшаф Гази) белән дә таныштым, Әсгать Айдар белән Демьян Фәтхине дә күрдем. Фатих Хөсни белән соңрак очраштык шикелле... Кыскасы, таныш-белешләрем күбәйде. Мәгәр мин аларның берсе белән дә артык якынаеп китә алмадым. Бәлки, төрлебез төрле җирдә укыганга күрәдер, ә бәлки, субъектив сәбәпләр дә булгандыр. Мин, мәсәлән, кешенең үзе тарафыннан әзрәк кызыксыну сизмәсәм, аңа якынаерга ничектер җөрьәт итә алмый идем... Кешеләр белән мин, гомумән, авыр танышам — бу минем күптәнге бер кимчелегем.

Тагын бер бик мөһим моментны әйтергә кирәктер: әле генә мин атаган иптәшләр барысы да диярлек әдәбиятка кыю һәм җиңел кереп киттеләр. Озак та үтми, аларның исемнәре газета-журнал битләрендә еш кына күренә дә башлады. Билгеле, алар талантлы егетләр иде, әмма талант өстенә башка сыйфатлары да булгандыр инде. (Мәсәлән, тәвәккәллек, тырышлык, үзенең көченә нык ышану кебек сыйфатлар.) Аннары, рус әйткән «везение» дигән нәрсә дә бар бит әле: кайчагында кешегә бәхет капкасы ачылып кына тора!.. Менә, әйтик, Габдрахман Минский — мәһабәт, матур, ягымлы, кыланышларында әзрәк аристократлык та сизелгән Әстерхан егете — тиз арада Такташ, Кутуй, Туфан кебек авторитетлар белән якынаеп, аларның үз кешесе булып китте... Исеме дә аларныкына кушылып йөри башлады... Дөрес, яшьрәк, дәрәҗә дә түбәнрәк, әмма аңа зур киләчәк юрадылар.

Мирсәй Әмир, хикәяләр язу белән генә чикләнмичә, шулай ук бик тиз үзен әдәби хәрәкәтнең актив эшлеклесе итеп тә күрсәтә башлады. Мужикларча салмак кына, әмма туры бәреп, усал чыгышлар ясый торган иде ул... Ике Фатих — Хөсни белән Кәрим — шулай ук күзгә күренеп күтәрелә баралар. Язганнары газета-журналларда чыгып кына тора... Фатих Кәрим, шуның өстенә, Минский шикелле үк, Такташ белән дә якынаерга өлгерде. Күрәсең, зур шагыйрь белән яшь шагыйрьне бер-берсенә тарткан нindидер рухи уртаклык булгандыр инде.

Минем үз уңышларым исә алай мактанырлык түгел иде. Бик аз язам, дөньяга аз чыгам. Чыкканнары да вактөяк әйберләр генә... Миннән шагыйрь чыкмасын мин

белдем инде, әмма күңел дигәнең шигырь сыманрак нәрсә язуны һаман сорап кына тора. Мондый хәл, әлбәттә, минем яшьлегем белән бәйләнгән булырга тиеш. Ул заманда безнең әдәбиятта «нәсер» дигән бер жанр яшәп килә иде. (Ак шигырь дә диләр аны.) Минем әле «Аң» журналында бу нәсерләрне укыганым бар иде. Соңгы елларда бездә аның зур остасы булып Мәхмүт Максуд абый танылды... Нигә миңа да үземне шул «нәсер»дә сынап карамаска?.. Чәчмә сүзгә сәләтем бар кебек, әнә «Озын көй тыңлаганда» дип аталган һәм «Безнең юл»да басылган беренче әйберем дә нәсер иде бит... Һәм мин ул нәсерләрне язгалап карадым, аларның кайберләре шул ук журналда басылып та чыктылар. Ләкин берәүнең дә игътибарын алар үзләренә юньләп җәлеп итмәделәр бугай... Чынлап та, күләмнәре белән бик кечкенәләр, мәгънә ягыннан да сайлар, кыскасы, шома гына язылган вак кына әдәби парчалар. Бәлки, аларның зур журналга үтүе дә шул «шома» теле аркасында гына булгандыр... «Телең бар» дип әйтә торганнар иде миңа әдәбияттагы танышбелешләр дә...

Әмма, юк, нәсер белән генә ерак китеп булмаячак иде. Җитди прозага тотынган чагында гына берәр төрле хикмәт килеп чыгуы мөмкин иде. Мин моны үзем дә аңлыйм кебек, тик менә зур эшкә ничек итеп тотынырга гына белмим... Беренче кышта моңа, билгеле, уку да комачаулык иткәндер — дәресләр күп, укуы шактый авыр, таләпләр дә зур иде. Миңа бигрәк тә укудан артта калырга ярамый иде... Бусы тышкы сәбәп, әмма бик җитди эчке сәбәп тә бар иде. Нәрсә турында, ничек итеп язарга? — менә иң төп сәбәп, миңа калса, шушы сорауда иде бугай... Дөрес, бу һәрбер язучы алдында торган гомерлек сорау, иллә мәгәр ул сорау минем алдыма башта ук ничектер аеруча җитди-үткен булып килеп басты. Әйе, башта ук мин бернәрсәне аңлагандай булдым: мин ияреп кенә яза алмыйм икән, миңа үземнекен табарга һәм үзем хис иткәнчә язарга кирәк икән. Ә заман бик катлаулы, мин әле яшь, тәҗрибәсез,— тынгысыз дөньяга яңа чыгып кына киләм,— билгеле инде, миңа «үземне табу» бер дә ансат булмады. Бик озакка сузылды ул аптырап эзләнүләр...

Язу эше кешенең характеры белән дә, шәхси язмышы белән дә һәм заман шартлары белән дә бик тыгыз бәйләнгән. Характерымны хәзергә әйтеп тормыйм, ә менә язмыш белән шартлар турында сөйләмичә булмый... (Бу ике нәрсәнең бер-берсеннән аерылгысыз булуы аңлашылса кирәк.) Әлбәттә, мин үзем кичергән, үземә кагылган кадәресен генә сөйләячәкмен.

Казанга килеп торган шушы ел ярым-ике ел эчендә миңа нәрсә ачылды, нәрсә күрдем мин? Барысыннан да элек революциянең дәвам итүен күрдем дип әйтер идем (яки тойдым дип). Әйе, ихлас, Октябрьдән башланган революциянең бездә һич туктаганы юк икән, хәзер ул иске дөньяны тәмам бетереп, яңасын кору өчен дәвам итә һәм итәчәк икән... Нэп дигән нәрсә ул кыска гына чигенү, вакытлы гына тынып тору булган, имеш! Аның шулай буласын башта ук сизәргә мөмкин иде инде, чөнки иске дөньяга нәфрәт-ачу нэп вакытында да бетеп тормады. Әзрәк йомшарып, тыныбрак торган чагы, бәлки, булгандыр, иллә мәгәр тиз арада яңадан көчәя башлады... Революциянең максаты изге — сыйныфларны бетерү юлы белән башта социализм, аннары коммунизм төзү... Ә моның өчен бөтен иске дөнья калдыкларына, барлык эксплуататор сыйныфларга каршы рәхимсез каты һөҗүм алып барырга кирәк, диләр. Һәм бу һөҗүм иҗтимагый тормышта булсын, идеология фронтында булсын, шул җөмләдән әдәбият өлкәсендә дә бик тиз җәелә һәм отыры көчәя бара иде. Әдәбиятта ул һөҗүм үзен аеруча нык сиздерә башлады — без моны Фатих Әмирханны җирләгән чакта ук инде күреп уздырган идек.

Кыскасы, минем Казанга килеп, укый һәм язгалый башлаган чагым әнә шундый хәтәр бер вакытка туры килде. Хәтәр дим, чөнки бөтен фронт буйлап көчәя барган һөҗүмнең миңа да китереп бәрүе мөмкин иде. Иң элек, билгеле, чыгыш ягыннан. Социаль чыгыш өчен укудан куып чыгарулар башланган иде инде. 1927—1928 елларда ул, аеруча көчәеп, бер кампания төсен алды дияргә дә була. Гадәттә бу фаш итү юлы белән эшләнә иде. Фәлән-фәләнев — мулла яки сәүдәгәр малае, дип язып бирсәләр, артык тикшереп тормастан куалар да чыгаралар. Эш шуңа кадәр барып җитте ки, кайбер мулла малайлары, үзләренә шик-шөбһә төшмәсен өчен, бүтәннәр өстеннән әләк язып бирә башладылар. Әләккә теләсә нәрсә язып була, шуңа күрә ул — әләк тә. Бу очракта инде синең укырга бик сәләтле булуың да, җәмгыятькә файдалы кеше булырга теләвең дә коткара алмый.

Социаль чыгыш мәсьәләсе ул елларда шундый зур бер әһәмияткә ия булган, күрәсең, хәтта газета-журнал битләрендә шигырь бастырган кайбер яшьләр имзаларыннан соң «ярлы баласы» яки «эшче баласы» дип тә өстәп куялар иде. Мәгәр алар арасында да алдашучылар булган икән. Бер вакытны минем Ярми дустым (былтыр «Шәрекъ» китапханәсендә танышкан егетем) журналда чыккан шигырь астындагы «ярлы баласы» дигән сүзнең «ярлы»сын сызды да өстенә «кулак» дип язып куйды. Мин, гаҗәпләнеп: «Нигә алай итәсең?» — дип сорагач,

ул тыныч кына: «Беләм мин ул малайны, безнең күрше авылдан, атасы настоящий кулак!» — дигән иде.

Әйткәнемчә, «фаш ителү» куркынычы минем өчен дә бар иде. Чыгыш мәсьәләсендә хәзер ташлама юк. Әгәр берәрсе минем атайның кайчандыр аяк өсте булса да сату итеп йөрүен куертып язса, шул инде җиткән, рабфак белән бәхилләшергә туры киләчәк. Хәзерге көндә бит атам сату итми, кустарьчылык белән шөгыльләнә дип акланып маташу да ярдәм итмәячәк. Былтыр һәм быел Казанга укырга килгән Дәүләкән яшьләренең миңа мөнәсәбәтләре төрлечә. Берәүләрнең бик яхшы, икенчеләрнең яхшы да, начар да түгел, ә кайберләрнеке корысалкын гына... Шулай булуы бик табигый — адәмнәр арасында мөнәсәбәтләрнең беркайчан да бертөрле генә була алганы юк әле. Кыскасы, алар арасында миңа хәерхаһлары[1] булган шикелле, һичшиксез, кырын караучылары да булырга тиеш иде. Бу соңгылары арасыннан, әйткән дә идем бугай, минем өчен аеруча хәтәре — ул да булса Казак Усман иде. Дәүләкәннән мондагы совпартшколага да килеп кергәч, ул инде миңа карата «сыйнфый уяулык» күрсәтмичә калмас дип көтә идем.

Хәлбуки без бер-беребезне бик аз белә идек. Бер үк Дәүләкәндә үскән малайлар булсак та, мин, мәсәлән, аның атасы кем булуын да, кайда торуларын да ачык кына белми идем. Мәктәптә укыганда да, җәйләрен уйнап йөргәндә дә, үсә төшеп, концерт-спектакльләргә катнашкан чакларда да миңа аны күрергә дә, аның белән аралашырга да туры килмәде. Шулай ук үзенә тиңрәк Зөфәр, Әфтах кебек өлкәннәр тирәсендә дә ул йөрмәде — кайда булган, нишләгән, кемнәр белән аралашкан — Хода белсен!.. Дәүләкән читендә Выгон дигән руслар гына яши торган бер урам бар иде, бәлки, шундагы рус малайлары арасында үскәндер, чөнки торулары шул якта иде бугай... Аның кебек татар-башкорт яшьләре белән аралашмыйча өлгергән егетләр бездә дә булгалады. (Мәсәлән, Әпәләй дигән бик шәп биюче дә шундыйлардан иде.)

Казак Усманны якыннанрак белгән иптәшләр аны бик һавалы-коры кеше диләр иде. Миңа исә аның белән бары Казанда гына әзрәк очрашырга туры килде. Бер тапкыр кемгәдер ияреп аңа барып та чыккан идем. (Совпартшкола торагына.) Әйе, чынлап та, егет үзен эре һәм горур тота белә икән шул. Кыяфәт тә шундыйрак — җитди чырай, салкын күзләр... Әмма мине аның бер көтелмәгән сыйфаты бик гаҗәпләндергән иде: ул, бак-

---

[1] *Хәерхаһ* — теләктәш.— *Ә.Е.*

саң, Чехов хикәясендәге табут ясаучы Яков кебек скрипкада уйный икән ләбаса! Хәер, ул үзе башлап бу хакта бер сүз дә әйтмәде. Тик китәр алдыннан мин, стенада эленеп торган скрипканы күреп: «Бу кемнеке, кем уйный?» — дип сорагач кына, Казак Усман гади бернәрсә турында әйткәндәй: «Мин уйныйм!» — дип кенә куйды. (Менә сиңа коры кеше!) Кызганычка каршы, уйнаганын ишетергә туры килмәде, чөнки ул үзе андый теләк сиздермәде һәм без дә ни өчендер үтенеп-сорап тормадык. Электән килгән табигый якынлык булмагач, коры сөйләшеп утыру белән генә чикләндек тә чыгып киттек.

Мондый очрашудан соң миндә икеләнү, ике төрле уйлау ирексездән башлана иде. Бердән, Казак Усманга ышанмавым, миңа каршы ни дә булса эшләр дигән шигем үзеннән-үзе көчәя иде кебек; икенчедән, үзе ул очрашканда начар карашын берничек тә сиздермәгәч, яхшы ук тынычланган кебек тә була идем. «Чынлап та,— дип уйлый идем мин,— ни өчен әле ул миңа каныгырга тиеш?! Әллә минем атайның таш магазиннар тотмаганын белмиме ул, Казак Усман тоже Дәүләкән егете?! Монда әле чыгышлары белән миннән хуҗераклар да укып яталар, ә минем хакым булмасын, имеш!..» Әнә шулай ачынып уйлый идем мин, һәрбер адәм баласы шикелле тискәре якны киметебрәк, уңай якны исә арттырыбрак...

Хәлбуки ай артыннан ай уза, укулар әйбәт кенә бара, ахырда кышкы каникул да килеп җитә. Ә минем тирәдә хәзергә һичнәрсә булганы юк. Без әле, мондагы авылдашлар, каникул вакытында Дәүләкәнебезгә кайтып, атна-ун көн буена уеннар, кичәләр үткәреп, дөньясын бер шаулатып та киттек. (Һаҗәр белән беренче мәртәбә кинога баруым шул чакта булды.) Казанга кайту белән тагын студент тормышы, тагын укулар башланды. Инде җылы язга да күп калмады... Уку елының ахырына якынлашабыз, бәлки, тынычланырга да вакыттыр, онытырга, һәртөрле шик-шөбһәләрне күңелдән чыгарып ташларга?! Әмма... юк, тынычланырга иртәрәк булган икән әле. Көннәрдән бер көнне торак йорттагы бүлмәгә кайтып керсәм, минем караваттагы мендәр өстендә записка ята. Кулга алу белән белдем — Казак Усманнан!.. Минем исемне «Әмир» дип түгел, «Амир» дип куйган. (Дәшкәндә дә ул шулай русчалап «Амир» дип дәшә торган иде.) Кызык, нинди йомышы төште икән моның, минем бүлмәгә беренче мәртәбә аяк баскан бик важный иптәшнең?.. Хәер, мин шулай уйлап алганчы, кыска гына запискагы бер күз ташлау белән укып та чыктым. Анда болай дип язылган иде: «Амир, син рабфактан үзең чыгып китмәсәң, без сине кудырабыз, учти шуны!» Имза юк, билгеле, ки-

рәге дә юк. Аңладык, төшендек... Шулай да мин бүлмәдәш иптәштән: «Кемнәр килгән иде?» — дип сораган булдым. Ул: «Ике егет килгән иде,— диде,— берсе кәкрерәк борынлы, ак чырайлы, икенчесе — арык кына, кара чәчле»,— дип тә өстәде... Ну, билгеле инде, аксылы — Казак Усман, карасы — һәрвакыт аңа тагылып йөрүче Хәйдәр... Бу егет миңа күптән таныш, кайчандыр бергә мәдрәсәдә дә укып йөрдек, үткән көз генә безгә ияреп килеп Татрабфакка керде, ләкин укуының рәте-юне булмагандыр, чөнки электән үк кемгә дә булса ияреп йөрергә гадәтләнгән бер ялкау иде. Менә бит монда да тапкан ияртүчене — алгы тәгәрмәч кайдан барса, арткысы да шуннан барачак, әлбәттә.

...Алай, мәсьәлә ачык. Егетләр миңа ультиматум куйганнар: рабфактан табаныңны ялтырат!.. Бу нәкъ Казак Усманча: башта үзенең өстенлеген, көчен күрсәтергә теләгән ул!.. Яшерен донос язып бирүгә караганда, бу әйбәтрәк тә түгелме соң әле?! Миңа уйланырга вакыт бирә, үз иркем белән чыгып китәргә мөмкинлек бирә! Бу бит әле үзенә күрә олы җанлылык күрсәтү дә, шайтан алгыры!.. Молодец, Казак!.. Синең миңа укырга ирек бирмәсеңне мин күптән белеп тордым, әмма менә болай эшләвең өчен сиңа хәтта рәхмәт тә әйтергә була!

Әйе, мин артык борчылмадым, записканы тагын бер кат укыдым да ертып ташладым... Һәм, бер дә баш ватып тормыйча, укуны да хәзергә дәвам итәргә булдым. Ультиматумның срогы юк бит, нигә ашыгырга?.. Казак Усманга бит мине үз ихтыярына буйсындыру мөһимрәк, бәлки әле, каршына барып минем ялваруымны да көтә торгандыр... Анысы булмаячак, әлбәттә, ә рабфактан чыгучыкмау мәсьәләсен мин үзем хәл итәчәкмен. Усман иптәшкә хәзергә әле көтәргә туры киләчәк.

Укуларны дәвам иттерергә күп калмаган иде. Тагын ике айдан мин беренче курсны тәмамларга тиеш идем. Насыйп булырмы-юкмы, ләкин балта чапканчы, кискә җан тарта ди — һичнигә карамыйча, укуны тәмамларга кирәк иде... Апрель-май да узды, июньгә дә кердек, һәм мин бәла-казасыз гына беренче курсны, ниһаять, бетереп чыктым... Хәзер инде мөһим бер мәсьәләне — кая китүне хәл итәргә кирәк иде. Минем хәлдәге студент өчен җәйне берәр җирдә эшләп үткәрү яхшырак булган булыр иде, әлбәттә, мәгәр, башта әйткәнемчә, үпкәләрем таза түгел, чахоткага әйләнү куркынычы бар, ә бу афәттән котылу өчен миңа яхшы һава, таза ашау кирәк. Боларны мин Дәүләкәнемә кайтып кына таба алам, билгеле... Аннары бөтенесе кайтканда мин генә кайтмыйча калсам, моны качу-яшерену дип аңлаулары да бик мөмкин иде.

Шуңа күрә тоттым да, үземә дус һәм дошман булган егетләрдә калмыйча, Дәүләкәнгә, атам йортына кайттым.

Һәртөрле фаный исәпләрдән дә бигрәк туган өйгә тарткан иң көчле нәрсә — ул да булса, һичшиксез, сагыну иде. Гаҗәп иде бу... Бер кыш эчендә тузанлы Дәүләкән үзе дә, бөтен әтрафындагы табигать тә, аеруча шунда калган дуслар да шулкадәр сагындыра иде ки, бер генә җәй кайтмыйча-күрмичә калу да үкенечле бер зур югалту булып тоела башлый иде... Бәлки, бүтәннәр өчен ул алай ук та булмагандыр, иллә мәгәр мин кул-аягым белән шул Дәүләкәнгә, шундагы дусларга бәйләнеп беткән идем. Кайткан саен беренче көннән үк шулар арасына кереп китәм, шулардан һич аерыла алмыйм, хәтта атам-анама күрсәтмәгән игътибарны да күбрәк аларга күрсәтә идем... Ахмак яшьлек!..

Ул чакларда мин бик актив малай идем. Үземнән зуррakларга кушылып, бөтен уеннарга, кичәләргә, компанияләргә чын ихластан катнашып, чаба-чаба йөри идем. Миндә җәмәгать эшенә зур дәрт бар иде, ни эшләсәм дә бары күңел кушуы буенча гына эшли идем һәм, билгеле инде, ярақлашу дигән нәрсәне бөтенләй уйлый да белми идем. (Хәер, соңыннан да ярақлашу-ялагайлану кебек бик «кирәкле» сыйфатлар минем табигатемә ят булып калды.) Мине күптән белгән дусларым да миңа ышаналар, мине үз-якын итәләр иде, һәрхәлдә, алар тарафыннан бернинди дә хөсетлек сизми идем. Әмма ләкин шул ук вакытта миңа кырын караучыларның да барлыгын беләм... Булмыймы соң!.. Монда бит әле миңа ультиматум куйган Казак Усман — Хәйдәрләр компаниясе дә бар. Хәйдәр безнең арада һаман көлеп-шаркылдап йөри, ә менә Казак бик сирәк күренә иде. Гаҗәп бу кеше — үз тиңнәре белән уйнапкөлеп йөрүне бөтенләй белми диярлек — әллә тәкәбберлегә кушмый, әллә инде сүлән шикелле читтән генә күзәтергә ярата?! Ул мине онытмаган шикелле, мин дә аны оныта алмый идем — тик аның турында уйламаска гына тырышам. Дөнья күңелле, кояшлы, рәхәт — кадерен белеп калырга кирәк ләбаса!.. Тукта, оныта язганмын, шушы җәйне бит Һаҗәр Ысłак егетенә ияреп китте... Казактан башка да булган икән минем гамьнәрем...

Инде китәр вакытым якынлашкач, бер дустым миңа сер итеп кенә әйтте: «Беләсеңме, Казак Усман сине батырырга чамалый бит, өстеңнән язып, шуңа кайберәүләрдән кул да куйдырган»,— диде. Мин төпченепсорашып тормадым — кемнәр кул куйганын юри беләсем килмәде. (Йә араларында ышанычлы дуслар да булып куяр.) Ә Казакның иртәме-соңмы кара ниятен үтәячәген мин инде белеп тора идем.

...Август урталарында (башкалардан алданрак) миңа бердәнбер изгелек теләүче, хәер-догада торучы атам-анамны бераз аптырашта калдырып, тагын шулерактагы таш калага китеп бардым.

Минем өстән рабфакка «материал» килгәнме-юкмы, мин моны бервакытта да ачык кына белә алмадым. Чөнки рабфактан мин үзем, үз теләгем белән чыгып киттем. (Бу турыда рәсми белешмә дә миндә сакланган икән.) Әйткәнемчә, социаль чыгыш өчен уку йортларыннан чыгару шушы елның көзендә аеруча көчәя башлаган иде. Хәлләр шундый булгач, мин инде үз аягым белән чыгып китүне артыграк күрдем, билгеле.

1927 елның көзе, озакламый Бөек Октябрьгә дә ун ел тулачак. Әмма революция дәвам итә!.. Моны һәркем үз язмышында татый. Хикмәт нәрсәдә?..

Мең кеше дә кеше, бер кеше дә кеше. Бер кешегә авыр, газаплы, ә мең кешенең аңарда эше юк. Бу — революция законы, меңнәр мәнфәгате өчен аерым кеше язмышы белән хисаплашып тормый ул!..

...Авыллардан, заводлардан, шахталардан укырга ябырылып яшьләр килә. Хезмәт иясләренең үз белгечләре, үз укымышлылары булырга тиеш. Яңа җәмгыять хәзер шуңа мохтаҗ... Димәк, чыгышлары белән чит саналганнар читкәрәк китеп торырга, әнә шул меңләп килгән чын эшче-крестьян яшьләренә юл бирергә тиешләр. (Дөресрәге, читләрне юлдан куарга кирәк.) Бик аңлаешлы түгелме соң бу? Әлбәттә, аңлаешлы... менә хәзер!.. Мин бит бүген язам, илебез үткән юлны ачык күреп, үземчә дөрес нәтиҗә ясыйм. Ә теге чакта, ягъни 1927 елның көзендә, мондый ачык аңлау миндә мотлак булмагандыр, аңлау урынына ризасызлык һәм рәнҗү булгандыр. Чөнки мин дә бит адәм баласы, укыйм дип, җәмгыятькә файдалы кеше булыйм дип, шушы таш калага ашкынып килгән яшь кенә бер шәкерт!.. Юк, дуслар, бер дә җиңел булмагандыр миңа икенче тапкыр укудан аерылулар... Әмма ничек тә түзәргә, күтәрергә, киләчәктән өметне өзмәскә кирәк иде.

Социаль чыгыш белән бәйләнгән кеше язмышының инде бер уңай мисалын китерү дә бик урынлы булыр дип уйлыйм. Минем белән бергә килгән Фәтхелислам дусны Казан әйтерсең көтеп үк торган — ишекләрен киң ачып каршы алды ул ятимлектә үскән бу грузчик баласын! Текә баскычтан менгәндәй, Фәтхелислам гаҗәп тиз югары күтәрелде. 1931 елны төзүче-инженерлар институтын уңышлы тәмамлады. Шунда ук аспирантурада калып, аны бетергәннән соң, кандидатлык яклый, доцент исемен ала, башта декан, аннары укыту эшләре буенча директорның

урынбасары булып билгеләнә. Ә сугыш алдыннан инде Фәтхелислам Мансур улы Хәкимовны төзүче-инженерлар институтының ректоры итеп билгелиләр. Менә аның ун ел эчендә үткән юлы. Билгеле, бу чыгыш нәтиҗәсе генә түгел иде — яшьтән үк укырга бик сәләтле булу өстенә, ул үзен зур дәүләт эшләрен үти алырлык булдыклы, тырыш, чын коммунист итеп тә күрсәтә белде. (1931 елдан партия члены.) Сугыш вакытында да ул фронттагы бер авиачастьта «Смерш» (контрразведка) начальнигы булып хезмәт итә, орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Фашизмны тар-мар иткәннән соң, Казанга кайтып, сугыш елларында ябылып торган институтны яңадан ачып, беренче көненнән үк шуның ректоры булып эшли башлый. Институт өчен яңа бина да салдыра. Шулай дәвам итә аның җаваплы һәм зур дәрәҗәле хезмәт юлы. Бу вакыт эчендә ул берничә мәртәбә Казан шәһәр Советының депутаты булып та сайлана. Җыеп кына әйткәндә, аның язмышы да бөек революция нәтиҗәсе иде, әлбәттә!

Фәтхелислам әнә шулай үсеп-күтәрелеп китсә дә, безнең арадагы яшьтән үк башланган дуслык бетмәде-өзелмәде. Күрәсең, Дәүләкәннән икәү бергә җитәкләшеп чыгып китү безне бер-беребезгә яхшы ук бәйләп өлгергән булган — төрле сәбәпләр аркасында ерагаеп торган чакларда да без бу бәйләнешне ничектер күңелебездә саклап, аңа тугрылыклы булып кала алдык.

Илленче елларның башларында безнең янда гына дүрт катлы таза бер йорт салып куйдылар. Менә шул яңа йортның өч бүлмәле әйбәт, иркен квартирасына Фәтхелислам да гаиләсе белән күченде. Шулай итеп, Дәүләкәндәге шикелле, без яңадан күршеләр булдык һәм, билгеле инде, ешрак очраша да, үзара йөрешә дә башладык.

...Берәр уңай белән мәҗлес үткәргәндә, Фәтхелислам безне дә бервакытта да диярлек чакырмыйча калмый иде. Ә кунаклары аның, үзе кебек, институт кешеләре яки төзүче-инженерлар була торган иде. Әйбәт җыештырылган залда, яхшы закускалар, төрле эчемлекләр куелган зур өстәлнең ике ягына кадерле кунаклар тезелешеп утыра, ә табынның түр башында, бәрхет тышлы йомшак креслода Фәтхелислам Мансурович үзе утыра... Кайчандыр бүкәнгә утырып пима төпләгән, ачлы-туклы яшәгән ярлы малай!.. Бүген исә ул түр башында хаклы рәвештә утыра, чөнки ул мәҗлес хуҗасы һәм зур бер институтның ректоры, әмма иң гаҗәбе — аңарда шушы өстенлеге белән һичбер төрле эреләнү дә, масаю да юк. Киресенчә, ул үзен бик табигый тота, гүя искитәрлек берни дә юк монда, тик үз бәясен яхшы белүчеләрдә генә була торган бәйсезлек белән горурлык чамалы гына сизелә аңарда.

Ләкин болары да аның «ректор» булуыннан килгән нәрсә түгел иде. Мин менә аны күптән белүче кеше буларак әйтә алам: безнең Фәтхелисламда яшьтән үк үзен һәрвакыт, һәр урында әнә шулай дәрәҗәсен төшермичә акыллы-тыйнак тота белү бар иде. Мондый сыйфат яхшы тәрбия алган, эчке культурага ия кешеләрдә генә очрый бугай... Ә үтә ярлылыкта атасыз үскән Фәтхелисламга кайдан килгән ул?! Күп сыйфатлар, билгеле, нәселдән килә, ихтимал, атасы яки анасы ягыннан сакланып килгән әнә шундый күркәм бер сыйфат аңа да күчеп калгандыр. Ул бит үз гомерендә бер тапкыр сүгенгән кеше дә түгел. Мулла балаларында булмаган әдәп-инсаф бар иде аңарда!..

...Шулай да язмышның серләренә (яки мәкерлегенә) төшенүе бик читен. Кеше тормышта барысына да ирешә, әмма иң кадерлесен югалта. Менә Фәтхелислам белән дә шундыйрак хәл булды: илле яшеннән үк диабет белән авырый башлады, бик озак җәфаланды, ахырда шул авырудан үлеп тә китте... Әйе, әйтәсе дә түгел, үкенечле үлем!.. Яшәргә тиешле һәм хаклы кеше иде әле ул!..

Инде минем мәсьәләгә күчик. Уку турындагы сүзне ничек тә ахырына кадәр җиткерергә кирәк булыр... Күргәнегезчә, миңа рабфактан китәргә туры килде. Әмма уку теләге миндә сүнмәде, яшем үтмәгән, вакыт бар, киләчәктә берәр уку йортына керә алырмын әле дигән өмет, әлбәттә, калды. Тик моның өчен миңа үземнең социаль хәлемне яхшыртырга, ягъни башта кая да булса кереп, тагын күпмедер эшләргә кирәк иде.

Ярый, шулай карар да кылдык, ди. Әмма кая кереп, кем булып эшләргә?.. Казанда эш табуы җиңел түгел, эшсезләр дә бар иде әле ул елларда... Шуннан мин кая да булса читкә китү турында уйлана башладым. Озакламый Җәләй исемле бер танышымны очраттым (ул да минем кебегрәк бер хәлдә икән) — кайдадыр укыган, ни өчендер ташлаган, шулай ук эш эзли икән. Менә шул иптәш әйтте миңа: «Урта Азиядән укытучылар җыяр өчен вәкил килгән, шуны табып, сөйләшеп карыйсы иде»,— диде. Мин дә риза булдым моңа... Шул вәкилне эзләп, без Наркомпроска киттек. Барган чакта мине һаман бер уй борчыды: укытучылык — бик дәрәҗәле зур эш, мин шул эшкә ярыйммы, юкмы? Дөрес, рабфакта бер ел уку да минем белемемне шактый үк арттырган иде, һәрхәлдә, укырга-язарга өйрәтерлек кенә чамам бар иде. Әмма тәҗрибә дә, документ та — бернәрсәм дә юк, һәм җибәрүләренә ышанычым да бик аз иде. Мәгәр Урта Азиядә ул чакта

укытучыларга зур кытлык булгандыр инде, вәкил иптәш безне бик хуп дип, берсүзсез укытучылар итеп җибәрергә риза булды. Тиз арада тиешле кәгазьләрне дә язып бирде, шуның өстенә, тимер юлда скидка белән барыр өчен, литер дигән нәрсә һәм күпмедер акча да кулыбызга тоттырды... Әнә шулай ансат кына һәм тиз генә эшләнеп ташлана иде кайбер эшләр ул заманнарда!..

Без инде, иңебезгә канатлар чыккандай, тиз генә юкбар әйберләребезне култык астына кыстырып, вокзалга төштек тә күңелгә ничектер якын тоелган, әмма күз күрмәгән кайнар кояшлы ерак илгә ансат кына китеп тә бардык. Юлыбыз Мәскәү аша Сәмәркандка чаклы иде... Әмма... кызык бу язмыш дигәнең, кайвакытта һич көтелмәгән борылыш ясый да куя!.. Булгалады андый хәлләр минем белән дә, һәм менә беренчесен монда — Мәскәүгә килеп җиткәч — татырга туры килде... Ташкент поезды төнлә генә киләсе булганга күрә, без көн буе диярлек башкала белән иркенләп танышып йөрдек. Минем бит аны беренче генә күрүем, шунлыктан аның бик буталчык урамнарын, төрле зурлыктагы, төрле төстәге йортларын, андагы бихисап кибет-магазиннарын карап йөрү гаҗәп кызыклы иде. (Гомумән, мин беренче күргән шәһәрләрне исем китеп карап йөрергә яратам.) Мәгәр буталчык Мәскәүнең кай җирләрен күрдек, кай төшләрендә булдык — мин аны беркайчан да әйтеп бирә алмас идем. Билгеле, Кызыл мәйданнан башкасын.

Шулай, күпмедер йөреп арганнан соң, иптәшем, бүтән барыр җир калмагандай, көтелмәгән бер тәкъдим ясады:

— Әйдәле Татбаш бюрога[1] кереп чыгыйк, анда niләр бар икән.

Мин икеләнә калдым: шундый зур җиргә безне кертәләрме соң?!

— Кертәләр! — диде иптәшем,— анда минем бер танышым эшли...

Ярый алайса, киттек... Озакламый ничәдер катлы чибәр генә бер йортка барып кердек. (Безне туктатучы да, документ сораучы да булмады шикелле — шулайрак хәтердә калган.) Ничәнчедер катка мендек һәм зур гына бер бүлмәнең ишеген ачтык. Анда, Җәләйнең танышыннан башка, тагын берничә кеше үз өстәлләре артында нидер эшләп утыралар иде. Кердек, исәнләштек, Җәләйнең танышы янына утырып, әкрен генә сүзгә дә керештек. Ләкин бераздан бүлмәдәге бүтән иптәшләр дә безнең белән кы-

---

[1] Ул елларда партия Үзәк Комитеты каршында Татар-башкорт бюросы дигән бер орган эшли иде.— *Ә.Е.*

зыксындылар булса кирәк, торып, якынрак килеп, җайлап кына сораша башладылар: кемнәр без, нишләп йөрибез, кайларга таба китеп барабыз?.. Без кыскача гына сөйләп бирдек. Шуннан соң араларыннан бер дәүрәк абзый безгә Казанда бирелгән кәгазьләрне күрсәтергә кушты. Без аныmоны уйламыйча гына чыгарып бирдек. Ул барысын да ашыкмыйча гына карады, аннары бик гади генә итеп безгә әйтте: ни өчен әле сез әллә кайдагы Сәмәркандка китеп барасыз, безнең үзебездә эш беткәнмени? Әнә Донбасс шахтерларына укытучылар җитми. Юк, туганнар, без сезнең юлыгызны үзгәртергә мәҗбүрбез... Рәхим итеп, Донбасска китәсез, юлы да кыска, эш тә анда җитәрлек!..

Шулай диде дә, безнең ризалыкны да көтмичә, икенче берәүгә яңа кәгазьләр әзерләп, безгә бирергә кушты. Әле дә хәтерлим, литердагы «Сәмәрканд»ны кызыл кара белән сызып, өстенә Донбасс каласының исемен язып куйдылар.

Шулай итеп, Татбаш бюродан безне, ике мәхлукны, ак пахта иленнән кара күмер иленә борып чыгардылар. Бу, әлбәттә, юнәлешне генә түгел, безнең язмышларны да, әйткәнемчә, икенче якка бору иде. Мәгълүм ки, ул елларда Урта Азиягә киткән татар яшьләренең бик күбесе шунда торып, төпләнеп тә калды. Кем белә, бәлкем, мин дә туган якларга кире борылып кайта алмаган булыр идем. «Туган җирдән туйган җир яхшырак» дигән мәкаль сыман сүзне дә соңыннан анда яшәүче кайберәүләр авызыннан ишетергә туры килде... Бу, әлбәттә, элек иде.

Донбасс үзәге ул заманда Юзовка дигән шәһәр иде (хәзерге Донецк). Без менә шул округ үзәге урнашкан шәһәргә җибәрелгән идек. Аңа килеп җитү белән без Донбасста икәнебезне бик ачык сиздек: мондагы һавада төчкелтемрәк күмер исе дә газ исе иде... Беренче тапкыр иснәргә туры килгән бу сәер исләр безгә бераз гына дәрт тә өстәп җибәрде — без бит данлыклы бөтен Россия кочегаркасында!

Округ партия комитеты каршында ул чакта татар бүлеге эшли иде — кулыбыздагы язулар белән менә шунда барып кердек. Хәтеремдә, бүлектә партия эшләре буенча Сафаров дигән абзый, ә комсомол эшләре буенча ак чырайлы, арык кына Ширинский дигән егет эшли иде. (Соңыннан татарлар арасында эшләү бетерелгәч, алар икесе дә Казанга кайттылар. Бервакыт Ширинский безнең Татиздатта да эшләде.) Алар безне бик әйбәт каршы алдылар һәм тиз арада икебезне ике якка эшкә дә җибәрделәр. Минем ликбез укытучысы булып бара торган җирем Буденовское рудоуправление дип атала иде.

Чынлап та, кызык заманнар булган икән. Уйлап ка-

рагыз, һәрбер рудоуправление карамагында татар шахтерлары арасында ана телендә укыту-агарту һәм культура эшләре алып бару өчен махсус куелган, хезмәт хакы алып эшләүче ике кеше була торган иде. Аларның берсен — парторг, икенчесен профорг дип йөртәләр иде. Менә шулар, иңнәренә кыр сумкасы асып, шахтадан шахтага җәяү йөреп, әнә шул бик кирәкле изге эшләрен алып баралар иде. Күбесе кайчандыр үзе шахтер булган яки гражданнар сугышында катнашкан урта яшьләрдәге гаҗәп тыйнак, ярлы, өс-башлары да хөрти генә, әмма үз эшләренә беткәнче бирелгән гадел коммунист абыйлар иде алар. Казармаларга килеп, шахтерларны үз тирәләренә җыеп, ялкынлы үгет-нәсихәт сөйлиләр, киңәшләр һәм белешмәләр бирәләр (сезонникларның һәртөрле сораулары күп була), еш кына бик каты бәхәсләшеп тә китәләр... Аш вакытына туры килсәләр, уртак казаннан берәр җамаяк аш та ашыйлар, ләкин шахтер сузган аракыдан катгый рәвештә баш тарталар, мәгәр аштан соң каты махорканы бармак юанлыгы төреп, бик тәмләп тарта торганнар иде. Мин алар кулында бервакытта да папирос күрмәдем — ахрысы, хезмәт хаклары да чамалы гына булгандыр инде...

Әнә шундый җәяүле агартучыларның берсе мине зур гына бер шахтага илтеп урнаштырды да инде. Ул Шакиров фамилияле, чегәндәй кап-кара бер мишәр абзые иде. Казармаларга алып кереп, шахтерлар белән дә таныштырды. Икәү бергә укый-яза белмәүчеләрнең күпме икәнен ачыклап, исемлекләрен төзеп, группалар оештырдык. Шундый ук эшләрне тагын ике шахтада башкардык — мин бер-берсенә якын торган өч шахтада укытырга тиеш идем.

Бу эшләрне шулай тәмамлагач, Шакиров абзый миңа кайбер киңәшләр биреп (мәсәлән, укытканда нык торырга, таләпчән булырга кушып), үз юлы белән җәяүләп кенә бүтән шахталарга китеп барды... Инде эшкә керешкәнче, үз хәлем турында да берничә генә сүз.

Иң элек кайда тору мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде. Килгән көнне үк шахтком кешесе мине поселоктан бер ярты чакрым чамасы читтәрәк, үр өстендәрәк ялгыз гына торган зур бакчалы бер йортка илтеп куйды. Йорт үзе дә зур, таза, уникеләп бүлмәсе бар, идәннәре паркет, мичләре ап-ак чынаяк кирпечтән — кайчандыр монда шахта хуҗасы үзе торган булса кирәк. Хәзер исә нигәдер бөтенләй буш диярлек, бары ике бүлмәсендә генә ике ялгызак кеше торып яталар икән. Өченчегә менә мин килдем. Бүлмәне минем үземә сайларга куштылар. Берничәсен ачып караганнан соң, мин бер кечерәгендә то-

рып калдым. Монда өстәл белән караватбар, аннары тәрәзәсе дә бакчага караган иде... Шулай тора башладым мин бу бай ташландык йортта. Әмма теге ике аерым торучыларны бер дә сизмим, аяк тавышларын да ишетмим — бүлмә аралары ерак, аннары иртә китеп, соң гына кайталар да булса кирәк. Бер дә күренмәгәч, алар миңа ничектер өрәкләр шикелле булып тоела башлады... Әллә ничек сәер дә, серле дә, һәм ялгыз зур йорт үзе дә көннәр буе тирән тынлыкка чумып утыра иде.

...Ә монда сентябрь ае бик җылы, бик йомшак, бик тымызык иде. Буш сәгатьләремдә ялгыз башым бакчага чыгам. Үләннәр инде саргайган, агачлар әле яшел. Монда алма, груша, кара җимеш агачлары күп, җирдә җыелмыйча сибелеп яткан груша, сливалар күп, койма буйларындагы вак куакларны кызыл карлыган сырып алган — беренче мәртәбә шуны кабып карагач, үземне ничектер алпавыт имениесендә кебек хис иткән идем. Бәлки, кызыл карлыганны моңарчы ашап карамаганга күрә, миндә шундый реакция булгандыр... Һәм тагын да иң гаҗәбе — менә хәзер дә үз бакчамда үскән шул карлыганны капсам, әлеге хуҗасыз йорт, ташландык бакча күз алдыма килә — гүя мин Чехов заманындагы иске, таныш бер имениегә яңадан борылып кайткандай булам...

Шулай да кызыклы, серле, аз гына әчпошыргыч ул ямансу йорттан миңа озакламый чыгып китәргә туры килде. Шахтер абзыйларга якынрак торырга кирәк иде. Тиздән, кемнеңдер ярдәме белән, мин поселоктагы әйбәт кенә бер украин гаиләсенә нахлебник булып кердем. Ягъни тору урыны һәм ашау-эчү хуҗадан, ә мин шуның өчен аена егерме биш сум түләргә тиеш идем. Шулай итеп, минем тормыш ансат кына көйләнде. Хәзер инде, култык астына дәреслек белән дәфтәр кыстырып, өч шахта арасында мәгърифәт орлыгы «сачып» йөрисе генә калды. Шахтерлар сменалап эшләгәнгә күрә, укыту эшләре дә шуңа көйләнгән иде: иртән икенче сменага төшүчеләрне, ә кичке якта беренче сменадан кайтучыларны укытам. Һәр шахтаны атнасына ике тапкыр йөреп чыгам. Укыта торган җирем сезонниклар яшәгән озын баракның «кызыл почмагында»... Ишектән керүгә тәрәзә яклап такта белән генә бүлеп алынган бу кечкенә бүлмәдә бер-ике озын өстәл, берничә озын эскәмия һәм стенага сөяп куйган кара такта тора — без, мөгаллим буларак, шул такта янына басып, ана телебездә дәрес алып барабыз. Тыгыз, әлбәттә, ләкин группалар зур түгел, сыябыз.

Биредә бер мөһим моментны әйтеп үтмичә булмый: һәр шахтада диярлек татар шахтерлары бер-берсеннән шактый нык аерылган ике төркемгә бүленә иде. Берсе

һәм күбрәк өлеше — акча эшләр өчен авылдан килгән сезонниклар. Боларның тамыры авылда, хуҗалыклары да авылда — инде өйләнергә яки йорт торгызырга кирәк булса, алар күмәкләшеп шахтага киләләр. Төп максатлары акча эшләү булгач, алар эштән башканы белмиләр, кирәксә, ике смена да эшлиләр, бернинди конфликтка кермиләр, күп эчүдән дә тыелалар, акчаны кысып кына тоталар — кыскасы, тырыш, уңган, күндәм шахтерлардан саналалар. Минем укучыларымның да күбесе шулар иде. Әйбәт егетләр, инсафларын югалтып бетермәгәннәр, миңа да искечә күбрәк «мөгаллим» дип дәшәләр иде... Бу халык авылда кыр эшләрен бетереп, сентябрьдә генә килә, ә апрельдә инде, җыйган акчасын учлап, чемодан-капчыгын бүләкләр белән тутырып, кайтып та китә.

Икенче төркем исә шахтаның үзендә төпләнеп калган, йорт-җире, гаиләсе белән торучы шахтерлар иде. Кайбер шахталарда бу төркемне дә күп диләр, ләкин мин торганында бер биш-алты гына йорт булгандыр. Болар инде чын мәгънәсендә шахтер — эше дә, тормышы да бары шахта белән генә бәйләнгән. Поселокта да алар мөхтәрәм кешеләрдән санала — таза торалар, йорт-җире дә таза, сыер да асрыйлар. Аннары шахта төбендә күмер ташып сукырайган атларны алып менеп суялар икән. (Билгеле, күпмедер түләп.) Итен сезонникларга саталар, ә үзләре ел әйләнәсе симез казылыктан өзелмиләр.

Бу төркемнән миңа укырга йөрүче булмады. Аларның инде яшьләре дә олы, бала-чагалары да үсеп килә, ихтимал, әзрәк укый-яза да белә торганнардыр. Парторг Шакиров та аларны укырга кыстап маташмады... Шулай да мөхтәрәм абзыйларның берсе менә мине, юньләп мыек та чыкмаган ябь-яшь егетне, бер зур бәйрәмдә үзенә кунакка чакырган иде. Бу инде безнең халыктагыча «мөгаллим»гә хөрмәт күрсәтү билгесе иде. Халык бит, кайда гына яшәсә дә, үзенең гореф-гадәтләрен сакларга тырыша.

Ә тулаем алганда, Донбасска килеп, шахтерлар арасында эшләү минем өчен һәр җәһәттән гыйбрәтле дә, файдалы да булды. Иң элек мин шахтаның нәрсә һәм шахтерның кем икәнен белдем. Җир өстендә эшләсәм дә, берничә тапкыр смена белән бергә, кулга шахтер лампасы тотып, шахтага да төштем, егетләрем эшләгән забойларда да булдым. Әйтергә кирәк, ул чакларда шахтада бернинди механизация юк иде әле, шахтерның бердәнбер эш коралы — кәйлә, шуның белән ул утырып та, ятып та каты күмерне чаба. Авыр һәм хәтәр хезмәт. (Забой ишелеп, күмер астында калулар да булгалый.) Пычрак эш. Күмер тузаны кулга, биткә батып керә, кат-кат

юып та бетми — шахтерны әнә шул «сөрмә»ләреннән дә танып була. Эше беткәч, көн яктысына ул, морҗадан төшкәндәй, кап-кара булып килеп чыга. Ялгышмасам, ул чакта ук инде шахтерның эш көне алты сәгатьтән артмый иде.

Үземдә укыган егетләрнең һәм укымаган абзыйларның да миңа мөнәсәбәтләре яхшы иде. Алар тарафыннан бу егет бик яшь бит әле, ни күргән дә ни белә ул дип, санга сукмыйча карауны мин бервакытта да тоймадым. «Атаң кем?» — дип сораучы да булмады. Беренче тапкыр мин монда җан тынычлыгы татыдым.

Шулай ук рус, украин кешеләре белән дә арам һәрвакыт кешеләрчә әйбәт булды. Электән үк инде алар татарга ияләшкәннәр, ят күрмиләр, яшәү һәм эшләү гел бергә диярлек. Инде үзем торган украин гаиләсендә мин бер семья кешеседәй яшәдем. Кызганычка каршы, хуҗаларның исемнәре онытылган, ә менә балаларыныкы шушы көнгә кадәр ничектер сакланган: җиткән кызлары — Катя, үсмер малайлары Сергей исемле иде. Шуларга ияреп, мин киногa да бара идем.

Поселокның барак тибындагы бер катлы озын гына клубы бар, шунда атнасына берничә мәртәбә кино күрсәтәләр, ә кинодан соң, эскәмияләрне стена буена этәреп, танса башлап җибәрәләр. Тансасыз бер кино да узмый торган иде. Гади генә киенгән егетләр һәм кызлар шунда ук дәртләнеп, чоштыр-чоштыр әйләнергә дә тотыналар... Хәзер дә әле үкенәм шул чакта танцевать итәргә өйрәнмичә калуыма, югыйсә бит Катя туташ, әйдә өйрәтәм, дип, мине кыстап та караган иде. Әлеге дә баягы кыюсызлык! Кайтып китәргә көчем җитмичә, бер читтә, әллә кемдәй, уйчан-ялгыз гына карап утырган булам. Хәлбуки миңа игътибар итүчеләр дә булган икән. Бервакытны хуҗа малае Сергей кулыма записка китереп тоттырды. Укыйм, русча: «Әгәр теләсәгез, без таныша да алабыз»,— дип язылган иде. Кемнән бу?.. Әзрәк эссе дә булып китте миңа... Сергейдан сорыйм, ул каршы якта утырган бер кызны ымлап кына күрсәтте. Кыз безнең якка карамаска тырышкан булып, кырын-текә генә утыра. Ә записканы хәйләкәр язган — инициативаны миннән көтә... Туташым бик бай, бик модный киенгән, помада-пудралар сылап бик нык бизәнгән һәм шуның белән тутый коштай бүтәннәрдән аерылып та тора. Күрәсең, гади шахтер кызы гына түгелдер... Әмма, Ходаем, йөзе-бите аның шадра ич! — бернинди бизәнү дә яшерә алмаслык шадра!.. Кирәк ләбаса!.. Күзләре матур, иреннәре тулы, гәүдәсе дә сылу гына булса кирәк... Кызганыч, бик кызганыч! Әйе, мин аны чынчынлап кызгандым, мәгәр танышырга да, озатырга да үзем-

не мәҗбүр итә алмадым. Һәм курыктым да мин, кызның яратып китүеннән курыктым, чөнки кешене кызгана торган йомшаклыгым бар, Алла сакласын!..

Клубка барган саен аның, горурлыгын сакларга тырышкан хәлдә, барыбер нидер көтеп һаман миңа каравын үзем дә тоя идем. Авыр хәл. Нишләргә дә белмим. Килмәскә, күренмәскәме әллә?! Ләкин тора-бара бернәрсәне аңладым: монда егетләр, кызлар ишсез йөрмиләр икән. Чынлапмы, юри генәме, һәрбер егетнең һәм кызның йөргәне бар. Безнең Катяның да егете бар, клубтан кайткан саен ишек төбендә сәгатьләр буенча сөйләшеп торалар... Ата-анасы да бер сүз дә әйтми... Димәк, монда ялгыз булырга ярамый, ялгызны бик тиз күрәләр, ә танышып китүләре бик ансат икән. Мин торган йорт каршында гына су колонкасы бар иде. Көн дә бер-ике тапкыр шул колонкага тыгыз пальто кигән бер зифа гына кыз килә иде. Ап-ак чырайлы, кап-кара күзле чын хохлушка!.. Әлеге дә баягы Катя орыша-орыша мине менә шул чибәр белән таныштырды. Исеме Женя икән. Бик шат табигатьле, юктан да тәңкәләр сипкәндәй көлеп җибәрергә ярата... Шулай итеп, мин дә көтмәгәндә генә ухажер булып киттем. Билгеле, аякларга да эш артты. Клубта Женя белән бергә утыра башлагач, теге йөрәкне ирексездән сызландырган кыз да миңа нидер өмет итеп караудан туктады.

Минем матди ягым да монда бик яхшырды. Сәгатьләп түлиләр, эш хакым аена туксан-йөз сумга чаклы барып җитә. Нахлебник булып торган өчен хуҗаларга аена егерме биш сум түлим, ә шуннан артканы кесәмдә әйбәт кенә утырып кала. Ул чакта муллык иде әле, арзанчылык иде. (Мәсәлән, бостоннан теккән костюм кырык-кырык биш сум тора иде.) Безнең поселокта атна саен кечерәк кенә базар була иде. Көзге байлык, якын-тирә хуторлардан бричкаларга төяп алма, груша, карбыз, кавын китерәләр. Май, каймак, үзләре тутырган колбаса, көйдергән чучка баласы — тагын әллә ниләр керә торган иде. Йомры вак кавыннарның тәмле хуш исен бүген дә онытканым юк әле. Кыскасы, Донбасстагы шикелле минем хөр, иркен, мул торганым башка бервакытта да булмады. Аннары әллә һавасы килеште, әллә таза ашау нәтиҗәсе — үпкә авыруым да шушында ябылып бетә язды.

Әмма һәрнәрсәнең, һәр рәхәтнең бер ахыры килеп җитә. Кыш үтеп язга керү белән укыту эшләре сүрелә башлады. Ә майда инде, сезонниклар китеп беткәч, бөтенләй туктады. Минем дә эшем, ниһаять, төгәлләнде. Көзгә чаклы мин буш... Май ахырында, тиешле расчетларны алганнан соң, өс-башымны әйбәт кенә юнәтеп,

өйдәгеләрнең һәркайсына бүләкләр дә алып (беренче мәртәбә!), калган ярыйсы гына акчамны да учлап, мин, Мәкәрҗәдән кайткан шикелле, бик һәйбәт кәеф белән Дәүләкәнемә кайтырга чыктым. Хуҗаларым, кайбер таныш-белешләр, шулар арасында көләргә дә, җыларга да әзер торган шомырт күзле «хохлушкам» да бик җылы итеп, «тагын да килегез!» дия-дия мине озатып калдылар. Һәрбер торып киткән җир — бигрәк тә тыныч, бәхетле торган җир — күңелләрдә озак саклана. Башта сагындырып йөдәтә, яңадан барасы килеп китә, аннары вакыт узу белән әкрен генә ераклаша, тоныклана, әмма барыбер гомер ахырына чаклы онытылып бетми. Донбасс белән дә шулайрак булды. Бер-ике тапкыр күрер өчен генә булса да барырга талпынып карадым, ләкин минем өчен анда кызык калмаган иде инде. Утызынчы елларның башыннан татар шахтерлары арасында ана телендә агарту, укыту эшләре бетерелде. Бу эшләрне алып бару өчен махсус куелган кешеләр — һәртөрле парторглар, профорглар да таралышып беттеләр. Мәгәр тормышларын электән үк шахта белән бәйләгән татар шахтерлары үз урыннарында һәмишә калдылар.

* * *

Ясиноватая дигән зур станциядә поездан поездга күчеп утырганнан соң, мин Пенза — Самара аша исәнимин Дәүләкәнемә кайтып җиттем. Өйдәгеләр исән-саулар, билгеле, олыгая төшкәннәр, атакайга инде илле алты яшь, инәйгә әзрәк артыграк та булырга тиеш. Елдагыча минем кайтуыма бик куандылар, бу юлы бигрәк тә, чөнки мин дә инде, үсә-зурая төшү белән бергә, әнә Донбасс кебек җирләргә барып, укытучы булганмын, акча эшләгәнмен, бөтенәеп, бүләкләр белән кайтканмын — әйе, минем өчен ниләр уйлап юануларын аларның йөзләреннән дә «укып» була иде... Үзләре бер көе тыныч кына торып яталар, сыерлары сөт бирә, кош-корт асрыйлар, карт тимерчыбыктан таба асларын һаман да үрә икән.

Кыскасы, инәй әйтмешли, Ходай җан биргәнгә юнь бирә.

Дәүләкәннең үзе турында да, анда үткәргән ялым турында да бу юлы язып тормыйм, җитәр, бер үк нәрсәне күпме язарга була?! Дөрес, үзгәрешләр бар: Дәүләкән әкрен генә үсә, җанлана, авылдан килгән яңа кешеләр дә күренә... һәм без дә үсәбез, без инде чын егетләр, кызларыбыз да чын туташлар. Яңа хисләр, яңа уйлар, яңа гамьнәр безнең башларда... Читкә китүчеләр дә әкренләп арта бара, ләкин күпләп китү юк әле, ансы соңрак булачак.

Минем өчен исә зур үзгәреш — быел күршемдә Һаҗәр юк. Хәтерлисездер, ул былтыр Ыслак егетенә ияреп киткән иде. Мин буш хәзер, җаным зынҗырлардан азат, тик сагышлардан гына азат түгел...

Тагын нәрсә?.. 1928 ел нэпның соңгы елы булса кирәк. Бу инде шактый нык сизелә. Вак-төяк сәүдәсен бөлеп яки үзе белеп ташлаучылар арта бара икән. Авылларда да икмәк тирәсендә хәлләр отыры кискенләшә, дип сөйлиләр... Тагын бер елдан илдә «бөек борылыш» башланачагын әле ачык кына белүче юк. Ләкин шулай да ул борылышның давыл шикелле якынлашып килүен халык инде ничектер сизеп тора. Берәүләр аның килеп җитүен кулларын уа-уа көтә, икенчеләр дәшми, колак сала һәм уйлана, өченчеләр исә чынлап курку-борчылу кичерә булса кирәк... Бөтен кешенең язмышын тамырдан үзгәртәчәк ул «бөек борылыш» — бишектә яткан сабыйныкына чаклы!.. Тик әле берәү дә хәзергә ачык кына күз алдына китерә алмый үзенең шәхси язмышын. Бүгенгесе белән яши адәм баласы!

Менә мине дә язмышым һаман Казанга дәшә, Казанга өстери. Гүя зур илдә минем өчен бүтән урын юк, гүя укып белем алыр өчен бүтән шәһәр беткән. Ләкин Казан ычкындырмый, Казан тарта. Ул татар мәдәниятенең кыйбласы, татар әдәбиятының үзәге — шушы якты рәшә минем хыялымда уйнаклый, шуңа омтылам, шуңа таба барам мин. Мәгәр аңа илтеп җиткерәсе юлның минем өчен ничаклы озын буласын һич тә чамалый белмим. Гомеремдә күп мәртәбә алдады мине хыялым!..

Заманның кая таба барганын бик иртә шәйләүчеләр була. Безнең Дәүләкәндә ашлык җыеп озатучы бер бай яһүт бар иде. Шуның Яшка (Яков) исемле улы 1927 елны ук атасын ташлап чыга да комсомолга керә. Бу үзенә күрә бер вакыйга төсен ала, Яшка бөтенләй геройга әйләнеп китә... Әйләнмичә, атасыннан баш тарткан ич ул!.. Аркасыннан гына сөймиләр малайның! Яшка шулай берничә ай төрле җирдә кунгалап, дәшми-тынмый гына йөри дә, аннары, нindидер сылтау табып, каядыр җылы якларга таба китеп тә бара. Ә күпмедер вакыттан соң атасы да, монда эшен бетереп, йортын сатып, мыштым гына шул ук тарафларга сыздыра. Молодец, Яшка!

Иртә кузгалган кошлар шикелле, мин дә августның беренче яртысында ук Уфа аша тагын Казанга юл тоттым. Елга якын аерылып торганга күрә, мондагы хәлләрне ачык кына белми идем. Ниләр бар, ниләр көтә безне бу тынгысыз калада?.. Уку йортларының тулай тораклары бу вакытларда әле буш тора. Мин дә РТЯ курсларында укучы бер танышым янына вакытлыча кереп тордым.

(РТЯның бер тулай торагы Гоголь урамында тыштан бик матур, ләкин эченә карболка исе сеңеп беткән ак йортта иде. Хәзер бу йортта безнең филармония.) Көн дә шәһәр буйлап анда-монда баргалап йөрим. Һәм иң беренче кеше итеп урамда һич көтмәгәндә генә Сәгыйть абый Сүнчәләйне очраттым. Безгә ул якын кеше, бала чагымнан ук күреп беләм — әлбәттә, бу очрашуга бик куандым. Бәлки, берәр ярдәме тимәсме дигән өмет тә күңелемә килгәндер. Ләкин Сәгыйть абыйда ниндидер сүлпәнлек сизелә иде, гүя үз кайгысы үзенә җиткән, шуңадыр, ахры, минем хәлем белән күп кызыксынмады. Азрак сөйләшеп торды, язасың икән, журналда хикәяңне күрдем, тырыш, ташлама, диде. (Шул елны «Безнең юл»да «Вакытсыз сулды» дигән хикәям басылган иде. Соңрак ул хикәя турында Садри абзый Җәләл дә миңа берничә җылы сүз әйткән иде.) Сәгыйть абыйның кайчандыр Тукай белән якын мөнәсәбәттә булуын, хатлар язышуын мин белми идем әле. Әмма төскә ничектер затлы-чибәр, үзенә бер йомшак-ягымлы тавышлы, беренче карауга шактый һавалы-горур күренгән, ләкин нигәдер гел генә уйчан-моңсу Сәгыйть абыйга минем хөрмәтем генә түгел, мәхәббәтем дә зур иде. Ул былтыр Казанга килеп, бер ел чамасы татар мәдәнияте йортында гыйльми сәркәтип булып эшләгән, хәзер аны ташлаган, яңадан Уфага китәргә җыенып йөри икән. Казан урамында очраклы рәвештә генә бу безнең иң соңгы очрашуыбыз булды, шуннан соң инде миңа аны бүтән күрергә туры килмәде.

Язу турында сүз чыккач, бу урында шуны да әйтеп китү кирәктер дип беләм. Донбасста чакта өч шахтада укытып йөргәч, мин язуга бер дә вакыт арттыра алмадым. Казан газеталарына бары берничә хәбәр җибәрү белән генә чикләндем. Ләкин, Дәүләкәнгә кайткач, Донбасс турында очерк сыман бер әйбер язган идем. Казанга килгәч тә мин аны «Татарстан» газетасына кертеп бирдем. Шактый вакыт ятканнан соң, сентябрь ахырларында гына ул нәрсә «Кара күмер илләрендә» дигән исем белән газетада бер подвал булып басылып чыкты. Өлкә газетасының икенче битендә «подвал биләү» яшь язучы өчен зур дәрәҗә инде ул, билгеле... Әмма, Ходаем, нишләткәннәр минем әйберне?! Башыннан ахырына кадәр брак булып чыккан лабаса, бер генә сүзен дә танырлык һәм укырлык түгел! (Хәрефләр кәгазьгә яртылаш кына төшкән.) Бары мәкаләнең исемен дә минем фамилияне генә укырлык... Бу, һичшиксез, брак иде — әйтерсең юри үч итеп шулай чыгарганнар. Газетаның бөтен тиражы да шундый булып чыкканмы — әйтә алмыйм, тикшерергә туры килмәде, әмма кулымда сакланган нөсхәдә

исемем бар, әйберем юк! Газеталарда аерым сүзләр, хәтта җөмләләрнең бозылып басылуы гадәттә еш очрый, илләмәгәр бөтен бер подвал текстны танымаслык итеп чыгару — валлаһе-әгъләм — тарихта булды микән?! (Казынырга яратучылар «Кызыл Татарстан»ның ул номерын, бәлки, эзләп тә табарлар.) Әгәр газетаның бөтен тиражы да шулай бозылып чыккан булса, минем Донбасс турында язганым эзсез югалды дигән сүз.

Хуш, төп максатка килик әле... Төп максат укырга керү иде бит... Ләкин кая, ничек итеп?.. Казанда уку йортлары күп, мәгәр кайсына гына керим дисәң дә, синнән «социаль чыгышыңны» сораячаклар. Дөресен генә әйтсәң — алмаячаклар, ә алдашу юлына басасы килми. Хәтта атамның бүгенге көндә кустарьчылык белән шөгыльләнүен, үземнең исә ике кыш инде хезмәт итүемне күрсәтеп үтә калсам да, миңа барыбер тынычлык булмаячак. Әлеге Казак Усман һәм аның койрыклары өстемнән «бывший сатучы малае» дип язып бирәчәкләр. Һәм куылыр өчен шул җитә дә калачак, чөнки «бывший» да ул чакта бик начар исәптә йөри иде. Гомумән, уку йортларын «чит элементлар»дан чистарту, нәкъ шушы 1928 елдан башлап, аеруча көчәйде. Кем син, нинди кеше синнән чыгачак — артык тикшереп тә тормыйлар. Инде танылып өлгергән шагыйрь Фатих Кәримне дә мулла баласы дип техникумның соңгы курсыннан чыгарып җибәргәч, башка, чыгышы «начар» егетләргә һәм кызларга нәрсә генә көтәргә кала?!

Керердән элек, чыгарыңны уйла, дигәннәр тәҗрибәле картлар... Менә мин дә көне-төне шул хакта уйларга мәҗбүрмен: нишләргә, ничек итеп бу каты төенне чишәргә? Асылда, бит сүз тормышта үз урыныңны табу турында бара. Ул урынны мин уку аша гына таба алырмын дип уйлый идем. Шуның өчен менә өченче тапкыр Казанга да килдем... Хәлбуки минем өчен уку йортларына юллар хәзергә ябык икән әле, тагы да күпмедер көтәселәр бар икән, инде алай-болай итеп керә алсаң да, соңыннан юк кына берәр әләк аркасында сөрелүең дә бик мөмкин икән. Ә сөрелеп чыгу, керми торуга караганда, күп тапкыр әшәкерәк түгелме соң?!

Казан урамнарында әнә шундый авыр уйларга бирелеп, каңгырып йөргән чакта, миңа Яңа бистәгә, мех фабрикасы ачылуга багышланган тантанага ничектер барып чыгарга туры килде. Бу вакыйганың буласын газетада эшләүчеләрнең берәрсе әйткәндер, ахрысы, чөнки мин редакциягә ара-тирә кергәләп йөри идем... Август ахырлары булгандыр, көннәр эссе, трамвайлар ул якка йөрми — тирләп-пешеп җәяүләп кенә киттем. Ачылачак фаб-

рика Зур Ямашев урамының аргы башында ук икән, мин барып җиткәндә, тантана башланган иде инде... Фабрика ихатасына шактый гына халык җыелган, митинг бара, кызыл комач белән әйләндереп алган трибунадан кайнар нотыклар сөйлиләр. Тын гына яткан татар бистәсендә яңа фабрика ачылу зур вакыйга, иптәшләр, бу — илне индустрияләштерүнең башы булачак, диләр сөйләүчеләр... Соңыннан кунакларга фабриканың эчен дә күрсәтеп йөрделәр. Хәтта иң ахырдан татар ашлары белән чәй дә эчерделәр.

Мондый тантананы минем беренче күрүем иде, ул миңа бик ошады, ничектер рухландырып та җибәрде. Шушы рухлану белән кайтып, мин яңа фабрика турында тиз генә мәкалә дә язып ташладым. Эпиграф итеп мәкалә башына Такташның «Ә урамда, язның килерен белми, җылап утыра песи малае...» дигән шигъри юлларын да язып куйдым. Һәм ул нәрсә берничә көннән «Кызыл Татарстан»да «Яңа гудок» дигән исем белән басылып та чыкты. Исеменә игътибар итегез: иң мөһиме — фабриканың озын трубасы икән!.. Мәкаләнең үзен дә мин «Таңнарның тынлыгын ертып, мәчетләрнең диварларын тетрәтеп, тагын бер яңа гудок Яңа бистә өстендә үкерә башлады...» дип бетергәнмен. (Моны укыгач, ирексездән, үземә «Калай әтәч!» дип әйтәсем килеп китте: дөньяны дер селкетергә бик ярата идек без ул чакта!) Мөһим бер вакыйга турында төпле, тыйнак кына итеп язасы урында, кызганычка каршы, әнә шулай чаманы белмичә шапырынып язганмын икән шул мин дә!

...Ярый, фабрика ачылды, мәче тиреләрен мех итеп чыгара да башлады ди, ә миңа нәрсә эшләргә соң? Болай яшәп булмый бит. Ашарга ризык, кунарга урын кирәк ләбаса!.. Ахырда мин, озак баш ватып тормастан, тагын шул ук Яңа бистә якларына тәпиләп кенә киттем. Баруым яңа фабрикага кереп булмасмы дигән өмет белән иде. Һәм, бәхетемнән димме, мине фабрикага учетчик итеп алдылар. Шул рәвешчә, 1928 елның җылы көзеннән башлап, мин яңарак кына туган, ләкин тиз арада даны таралган «Меховой»да эшли башладым. Кем әйтмешли, дөнья бу!.. Әле кайчан гына ачылу тантанасында кунак булып йөргән идем, ә хәзер менә җилкәмдә эт-мәче тиреләрен ташыйм.

Әйтергә кирәк, Казанда мех эшләп чыгару бик тиз үсеп китте. Егерме сигезенче елны беренче фабрика ачылса, ике-өч елдан инде аның икенче, өченче, хәтта дүртенче фабрикалары да сафка бастылар. Миңа шуларның икенчесе белән өченчесендә дә эшләргә туры килде. Дүрт ел эчендә мин мехлар танырга өйрәндем, мех сортлау цехы-

ның мөдир ярдәмчесе дә булып эшләдем, ахырдан күпмедер вакыт БРИЗ[1] мөдире дә булып тордым. Меховойларда эшләү минем яшьлегемдә тирән эз калдырды, искә төшерерлек хәлләр дә аз булмады, ләкин мин аларның берсенә дә тукталып тормыйм, чөнки төп сызыктан читкә тайпыласым килми. Ә төп сызык — әлеге шул уку мәсьәләсе... Бу мәсьәләдә дә Меховойларда эшләүнең файдасы тиде дияргә була — миңа да, ниһаять, укырга юл ачылды.

Казанда ул елларны хезмәтне фәнни оештыру институты бар иде. (Русча — ИНОТ.) Урнашкан җире Горький урамында, радиокомитетка каршы, хәзерге поликлиника бинасында иде. Ә мин үзем шуннан ерак түгел, түбәндәрәк, Куйбышев (ул чакта — Кооперативная) урамында тора идем.

ИНОТ — гадәттәге югары уку йорты түгел, аның эше фәнни тикшеренүләр алып бару һәм производстволарга ярдәм итү, ләкин ул үз тармагы өчен кирәк булган кадрларны хәзерләү белән дә шөгыльләнә иде. Менә шул институт каршында берзаман психотехниклар хәзерләп чыгару өчен бер еллык семинар оештырыла. Әллә үзем белеп, әллә җибәрү буенча — хәзер инде әйтә дә алмыйм — мин шушы семинарга 1932 елның башында кереп, 1933 елның январенда аны уңышлы гына тәмамлап, «психотехник» дигән исем алып чыктым (таныклыгы хәзер дә үземдә саклана)... Хуш, кем инде ул психотехник, нindirәк белгеч, һәм эше аның нидән гыйбарәт?.. Әгәр онытып бетермәгән булсам, мин аны болай аңлатыр идем: психотехник ул производствода эшләүче кешенең психологиясен һәм физик сәләтен өйрәнү нигезендә аның эш урынын һәм эш алымнарын мөмкин кадәр рациональ итеп оештыручы белгеч — шушы аның төп эше, төп бурычы... Безне шуңа өйрәттеләр. Без фабрика-заводларга барып, андагы эшчеләрнең ничек эшләүләрен махсус методлар ярдәме белән күзәтергә, өйрәнергә һәм уңай якка үзгәртергә тиеш идек. Төп максат, билгеле, һәр эшченең эшен җиңеләйтү белән бергә, эшләп чыгаруын арттыру иде.

Психотехника ул үзе Америкада туган нәрсә, аны уйлап чыгаручы һәм гамәлгә куючы, ялгышмасам, Тэйлор дигән бер инженер булган. Капиталистик производствога аның зур файдасы тигән булырга тиеш — менә шуннан аны бездә дә куллана башлаганнар иде.

Семинарны уңышлы гына бетергәнгә күрә һәм производствода эшләвемне күздә тотып булса кирәк, мине

[1] *БРИЗ* — рационализаторлар һәм уйлап табучылар бюросы.— *Ә.Е.*

шул ук институтның үзенә эшче-аспирант итеп алдылар. Эшче-аспирант булу өчен монда югары белемле булуың шарт түгел, шуның белән ул, әйтик, вузлардагы аспирантлардан аерыла да. Укырга сәләтең булса, башың бераз эшләсә, шул җиткәндер, ахрысы... Мине дә бер үк вакытта махсус программа буенча укытырга һәм эшләтергә дә тиешләр иде.

Шулай итеп, мин 1933 елның башыннан институтка күчеп, әйбәт кенә стипендия алып, укый да, эшли дә башладым. Хәзер инде абзагыз «фән кешесе», фәнни тикшеренүләр алып баручы — урау юллар белән булса да төп максатыма, ниһаять, ирешәм бугай... Эшләр ничава, әйбәт кенә бара, психотехниканы яратып та киткән идем, ләкин... татарның бер усал мәкале бар: хәерченең итәгенә бодай салсаң... карга килеп чүпли, имеш!.. Нәкъ шуның шикелле сыймады минем бәхетемә «фән кешесе» булулар, тагын җимерелде дә төште барысы да. 1934 елга кергәч, безнең институтта «психотехника» дигән нәрсәне фән буларак бетерделәр. Баксаң, ул, ягъни психотехника, капиталистик илдә эшләүчеләрне тагы да ныграк эксплуатацияләү өчен туган нәрсә икән (әлбәттә, шулай), шуңа күрә аңа безнең социалистик производствода урын булмаска тиеш, кирәге юк, бетерелергә тиеш!.. Бу институтның үзендә туган караш түгел иде, ул каяндыр югарыдан боерык рәвешендә килде булса кирәк. Инде психотехника үзе фән буларак бетерелгәч, аның өчен кадрлар әзерләп азаплануның да кирәге бетте. Миңа да башны түбән салындырып, иләшеп, яратып өлгергән институтым белән хушлашырга туры килде. Алай гына да түгел, ике ел ярым шуңа бөтен өметемне баглап, укып йөрүләрем төтен шикелле юкка чыкты да куйды.

...Мәрхүм атакай бик аптырауга төшкән чакларында, өзгәләнеп: «Ик-ки, егетләр!» — дип әйтә торган иде. «Эх» кына җитми, ул көчсез... Менә миңа да, башны селкә-селкә, «Ик-ки, егетләр!» диясе генә калды.

Хәер, кайберәүләр, бәлки, кашларын җыерып: «Монда ул кадәр уфтанырлык нәрсә бар?!» — дип әйтерләр. Һи, исең киткән, психотехниканы бетергәннәр! Әллә бер аны гынамы? Шул ук елларда педагогия институтларында «педагогия» дигән бер предметны да бетергәннәр иде. Аннары сугыштан соң да кайбер фән тармакларын зарарлы яки кирәксез табып, «ябулар» булгалады. Аңа карап, дөньяның беткәне, прогрессның туктаганы юк лабаса!..

Бик дөрес, дөньяның беткәне юк, һәм тормыш та дәвам итә. Без дә аның арбасыннан төшеп калмадык, озын юллар үтеп булса да кайбер нәтиҗәләргә дә ирештек. Сүз

тик монда шул юлны ничегрәк үтү турында гына бара. Һәркемнең бит үз юлы... Күрдегез инде, минем юлым уңышлы булып чыкмады. Ләкин моның белән мин, башкаларның да юлы шулай булды, дип әйтергә җыенмыйм. Совет вузларын бетереп чыккан мулла һәм сәүдәгәр балалары ул елларда да аз булмады. Тик шулай да аларның күпчелеге миннән бер-ике ел алданрак кереп, укуларын бетерергә өлгерделәр, яки инде миннән шактый соң килеп, башкарак вакытка туры килделәр. (1934 елны булса кирәк, Сталин авызыннан: «Атасы өчен улы җавап бирми»,— дигән сүз чыкканын ишеткән идек — менә шуннан соң, укырга кергәндә, социаль чыгышка артык зур әһәмият бирми башладылар шикелле...) Ә минем укырга омтылуым егерменче елларның ахырына, нәкъ менә «чит элементлар»га каты һөҗүм барган вакытка туры килде. Нишлисең, заманның барышы шулай булгач?! Аның каравы, меңнәрчә эшче-крестьян яшьләре нәкъ шул елларда төрле совет вузларын бетереп чыктылар... Теге кашын җыеручы иптәш бик дөрес әйтә: минем укымыйча калуымнан прогресс энә очы кадәр дә оттырмады. Ләкин шулай да мин үз хәлем турында язуны кирәк таптым, чөнки бу да без кичергән тарихның бер сәхифәсе иде.

* * *

...Инде мин әдәбият дөньясына күчәргә тиеш. Сүз минем язучы булырга азаплануым турында барачак. (Казанга килүдән икенче максат шул иде бит.) Ләкин ул еллардагы әдәбият дөньясы миңа ургылып аккан язгы ташуны хәтерләтә. Шавы әле дә булса колагымда... Һәм менә бүген дә гүя шул хәтәр елганың ярында аптырап басып торам: ничек кенә итеп бу болганчык ташуны кичәргә икән? Кыюлык та җитәргә тиеш, укучыны да өркетмәскә кирәк! Төрлечә баш ватып карадым. Баштарак бик тәфсилләп язарга да уем бар иде. Аннары бу гаять җаваплы «теманы» ерып чыга алмам, буталып бетәрмен дип курыктым да, әллә бөтенләй язып тормаска микән дигән фикергә дә килгәндәй булдым. Әмма... язучы була торып, ничек инде язучылык язмышың турында дәшми калырга мөмкин ди?! Ярамый ич, булмый ич алай! Ахырда, җанны артык кыйнамас өчен, тоттым да шундый карарга килдем: язарга, иллә мәгәр, бары үземә кагылган кадәресен генә! Миңа кагылганы — минеке, мин беләм, җавабын да үзем бирәм... Калганында минем эшем юк. Тарихны тулырак белергә теләүчеләр әнә китапларга мөрәҗәгать итсеннәр — әдәбият дөньясын яктырткан төрле әсәрләр бездә аз түгел.

Мин кыскача гына сөйләп күрсәтергә теләгән дәвер егерменче елларның икенче яртысы белән утызынчы елларның беренче яртысына туры килә, ягъни бер алтыҗиде ел вакытны эченә ала. Минем дә уналты белән егерме өч яшьләрдәге чагым була... Менә шушы елларда инде миңа азрак язгаларга да, әдәбият дөньясында бераз кайнашып йөрергә дә туры килгән иде. Әгәр бу елларга тулаем кыска гына характеристика бирергә кирәк булса, мин аны революциянең дәвам итүе дип атар идем. Әйе, 1917 елны башланган социалистик революция нәпны кысрыклый-кысрыклый дәвам итмәктә! — мин моны Казанга килеп, бераздан язучылар арасына керә башлагач ачык сизгәндәй булдым. Һәркемнең үзенә дә, эшенә дә бары сыйнфый көрәш күзлегеннән карый торган замана иде бу!..

Бу вакытларда Казанда әдәбият дөньясы, Тукайчарак әйтсәк, шәп кенә кайнамакта иде инде. Революциядән соң гына мәйданга күтәрелеп чыккан яңа, яшь көчләр — Шамил Усманов, Һади Такташ, Кави Нәҗми, Г.Толымбайский, Гомәр Гали, Гадел Кутуй (аз гына соңрак Хәсән Туфан) — менә шулар ул чакта әдәби хәрәкәтнең үзәгендә торалар. Алардан шактый өлкән, революциягә чаклы ук инде яза башлаган Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин кебек абыйлар аз гына читтәрәк һәм өстәрәк торалар иде бугай — хәер, мин моны үзем чамалап кына әйтәм. (Яшьләр җыелышында алар сирәк күренәләр иде.) Әдәбиятның танылган бәхәссез лидеры, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимов иде. Әмма аны да бары шәһәр күләмендәге зур җыелышларда гына күрә идек.

Ул елларда Казандагы барлык иске әдип, шагыйрьләр дә, Тукайдан кала, исәннәр иде әле. «Искеләр» булып саналсалар да, алар барысы да кырык яшьләр чамасындагы кешеләр иде. Мин аларның күбесен үзем күрдем — Фатих Әмирханны, Галиәсгар Камалны, Җамал Вәлидине, Гали Рәхимне, Габдрахман Сәгъдине, Садри Җәләлне, хәтта «Заман» календарен чыгарган Шәрәфетдин Шәһидуллинны да — китап магазинында бергә эшләдек. Бу абыйларның күбесе, язу эшләрен ташламасалар да, әдәби хәрәкәттән, билгеле, читтә торалар иде. Хәер, бер Габдрахман абзый Сәгъди генә яшь язучылар җыелышына чакыру буенча доклад яки лекция сөйләр өчен килгәли иде. Гадәттә, ул тулы гына чибәр хатынын ияртеп килә торган иде, һәм докладын тыңлаганнан соң аны, бик каты тәнкыйть итеп, озатып җибәрәләр иде.

Әмма нәрсә хас иде соң ул чактагы әдәби хәрәкәткә?.. Бер сүз белән генә әйткәндә, көрәш, кискен көрәш!.. Һәм отыры көчәя барган көрәш дип тә өстисем килә... Мин

җыелышларга йөри башлаганда, бу көрәш төрле измнар, ягъни әдәби агымнар арасында гына бара кебек иде, шуңа күрә андагы бәхәсләр никадәр кызу-кайнар булсалар да, артык хәвефле түгел иде әле... 1927 елны миңа, хәтерләсәгез, Казаннан китеп барырга туры килде. Егерме сигезенче елның көзендә яңадан Казанга килеп, җыелышларга йөри башласам, монда көрәшнең характеры бик нык үзгәргән — ул инде ачыктан-ачык сәяси төс алган. Бу инде көрәш кенә дә түгел. Ә чын мәгънәсендә һөҗүм — бөтен искегә, иске әдәбиятка, иске язучыларга каты һөҗүм!.. Әлбәттә, бу пролетариат әдәбияты өчен буржуаз әдәбиятка каршы һөҗүм иде. (Фатих Әмирханны башта ук буржуаз әдәбиятның атасына әйләндерделәр, ә соңга табарак хәтта Тукайга да чират җитте — аны вак буржуа шагыйре ясадылар.) Озакламый татар пролетариат язучылары ассоциациясе төзелде һәм «һөҗүм» сүзе әдәби журналның исеменә дә күчте: «Безнең юл» урынына «Атака» чыга башлады.

Иске язучыларны «попутчиклар» («юлаучылар») дип кенә йөртәләр иде. Аларны да үзләренә аерым бер оешмага тарткан булдылар («Совет язучылары җәмгыяте» дип атала иде шикелле), ләкин анда да чистарту ясап кайберләрен чыгарып та җибәрделәр. Мин, мәсәлән, Садри Җәләлне, Ченәкәйне, тагын кемнедер «чистартканда» булдым. «Чистарту» махсус оештырылган хөкем итү белән бер диярсең, чөнки монда «чистартылучы»ны гел гаепләү, гел кара ягу, әллә кайчангы гөнаһларын казып чыгару — мәгәр аның хезмәтләре яки язганнары турында бер яхшы сүз, бер аклау сүзе юк. Шуларның барысын да үзе күргән Ярми дустым күптән түгел Ташкенттан миңа язды: «Хәтерлисеңме, Садри Җәләлне «чистарткач», ул, бичара: «Ник кенә шул «Дим буенда»ны яздым икән!» — дип утырып җылады!» Хәтерләмәгән кайда ул! («Дим буенда» — Садри Җәләлнең революциягә чаклы ук язган романы.) Эш шуңа кадәр барып җитте ки, «искеләр»не җыелышлардан куып чыгара башладылар. Әле дә күз алдымда: «Мәдәният йортында» язучыларның чираттагы җыелышы башлангач кына ТАПП[1] җитәкчеләреннән берәү торып: «Монда Хәсәнгата казый малае Габәши утыра икән, без аның җыелыштан чыгып китүен таләп итәбез»,— диде... Һәм беренче татар операларын язышкан композитор Солтан Габәши, торып, бүреген батырып киеп, бөкрәеп кенә залдан чыгып китте.

«Искеләр»гә генә түгел, яңаларга да чират җитте —

---

[1] *ТАПП* — Татарская ассоциация пролетарских писателей — Пролетариат язучыларының Татарстан ассоциациясе.— *Ә.Е.*

ТАППның үзендә дә чистарту башланды. Мин бу чистартуның нәтиҗәләрен матбугаттан гына укып белдем: тәнкыйтьче Гази Кашшаф белән шагыйрь Демьян Фәтхине ТАППтан чыгаралар, ә Һади Такташны, берәүгә дә куелмаган каты таләпләр куеп, нык кисәтү белән генә калдыралар... Такташка инде байтактан бирле йә үзенә, йә язганнарына каныгу бара иде, ә хәзер әнә гомеренең соңгы елында каты тәнбиһ[1]!.. Олы шагыйрьнең «Киләчәккә хатлар»ы әнә шул бәйләнүләргә биргән җавабы булмады микән дип уйларга да бик мөмкин.

Әмма ул елларда иң күп, иң нык кыйналган кеше, мөгаен, шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнаш булгандыр... Әйтергә кирәк, бик мәһабәт, мөлаем бер кеше иде ул. Газеталарда аның хакында ниләр генә язмадылар! Ахырда «солтангалиевчелек»кә бәйләп, аны (һәм Галгәф дигән тагын бер язучыны) махсус тикшерү җыелышы үткәрелә. Мин үзем ул җыелышта булмадым, ләкин шуның стенографик отчеты итеп чыгарылган китап соңыннан кулыма килеп керде. Укып карагач, исем-акылым китте — ниләр генә өймәгәннәр аның өстенә! Әлбәттә, бу ачыктан-ачык хөкем итү җыелышы булган. Бурнашның иҗаты турында махсус куелган доклад та «Сарайлар, ханнар, князьләр, морзалар шагыйре Фәтхи Бурнаш» дип аталган! Кыскасы, бөтен иҗатын юкка чыгарганнар... Җитмәсә, шул җыелышта Кутуй мәрхүм: «Фәтхи Бурнаш иҗатына без «Сулф»[2] исеменнән егерме бишенче елны ук үлем карары чыгарган идек»,— дип тә әйткән... Моны мин элек белмәгән идем, укыгач, хәйран калдым — кирәк бит шулхәтлегә барып җитәргә!

Хәлбуки дөнья бит ул, мишәр абзаң әйтмешли, күләса — әйләнә дә бер баса! Озак та үтми, Кутуйның да баш өстендә яшен чатнады: «җидегәнчелек»тә гаепләнеп, берничә ел әдәбияттан аерылып торды. Билгеле, «җидегәнчелек» соңыннан бер уйдырма булып табылса да, мәрхүм Кутуйга аның азабын шактый ук татырга туры килгән иде. Шунсы тагын аяныч-көлке — Тукай клубындагы бер җыелыштан инде Кутуйны, Бурнаш белән икесен бергә, куып чыгаралар. Моның кайбер шаһитлары хәзер дә исәннәр әле...

Әлбәттә, болар барысы да яхшы ният белән — пролетариат әдәбияты хакына эшләнә. (Ул чакта «совет әдәбияты» дип сөйләмиләр иде әле.) Бәхәскә урын юк, авыз ачарга ирек бирмиләр, кешене түгел, үзеңне яклап та бер сүз әйтә алмыйсың... Ләкин ызгыш-талашларга, «фаш

---

[1] *Тәнбиһ* — кисәтү.— *Ә.Е.*
[2] *Сулф* — сул фронт.— *Ә.Е.*

итүләргә» карамастан, әдәбият яши, язучылар яза, нәкъ шушы тынгысыз елларда «Тирән тамырлар» да, «Урал эскизлары» да, «Киләчәккә хатлар» да дөньяга килеп чыга. Тормышның серләренә исең китәр! Мәрхүм Кутуй да бит үзенең иң яхшы әсәрен — «Тапшырылмаган хатлар»ны нахакка гаепләнү ачысын татыганнан соң иҗат итте.

Әмма иң аянычы шунда ки, бу яңа әдәбият өчен шулкадәр аяусыз сугышкан яңа көчләрнең үзләренә дә ахыр чиктә бер үк фаҗига килде — гүя үзләре тырыша-тырыша дөрләтеп җибәргән утта янып, көлгә әйләнделәр... Боларны искә төшерү бик авыр, онытасы, хәтердән йолкып ыргытасы килә — әмма ләкин тарих битләреннән берничек кенә дә җуеп ташлавы мөмкин түгел, кала, барыбер кала ул! Шулай ук гаделлек тә үлми, бетми, юкка чыкмый, соң булса да өскә калкып чыга ул! Мең шөкер, партиянең кыю тәвәккәллеге аркасында, нахакка харап булучыларның («искеләр»нең һәм «яңалар»ның), үзләре булмаса да, һич югы, исемнәре акланып кайтты.

Минем әдәбияттагы беренче адымнарым әнә шундый елларга туры килде. Беренче адымны җиңел генә ясасам да, әллә ни ерак китә алмадым. Мин бик яшь идем әле, бик тиз хискә бирелүчән идем... Уйлыйм ки, укырга керү мәсьәләсендә туган авырлыклар минем рухымны төшергән булырга тиеш. Борчып торган кайгың барында нәрсә генә яза аласың?! Аннары тәҗрибә бик бәләкәй иде бит әле, еш кына күңелдә туганны ничек итеп язарга белмичә азапланып бетә торган идем. Шигырь бөтенләй чыкмый, мин моны башта ук белдем, шуңа күрә «нәсер» дигән чәчмә парчалар язгалап карадым. Хикәяләр язуга 1928 елдан башлап кына керештем. (Алар да күп түгел.) «Дус кеше» исемле повестем 1929 елны аерым китап булып чыкты. Тагын нәрсә? Колхозлашу башлангач, «Яз баласы» дигән повесть язган идем, ансы, ни сәбәптер, дөньяга чыкмыйча калды... Кыскасы, иҗади активлык җәһәтеннән мин замандашларымнан шактый артта калдым һәм язучы буларак ныклап танылa да алмадым. Бәлки әле, бу хәерлегә дә булгандыр. Әмма шуңа да карамастан әдәбият әһелләре миңа игътибар итәләр, мине исләрендә тоталар. Җай чыкканда исемемне җыелышларда һәм матбугат битләрендә телгә дә алгалый торалар. Мәгәр бервакытта да мактап түгел, гел каты тәнкыйтьләп тә сүгеп... Мин аларны монда кабатлап тормыйм, бик беләсе килгән кеше үзе эзләп табар...

Ләкин хикмәт нәрсәдә соң? Ни өчен миңа мондый игътибар? Бер дә юкка гына түгелдер ич?! Билгеле, күпмедер гаеп минем үземдә дә булган булырга тиеш.

Ахрысы, мин катлаулы заман өчен ипсезрәк кеше булып туганмындыр инде. Иң элек, тартай теленнән табар дигәндәй, миңа күбрәк җыелышта-мазарда чыгып әйткән берәр сүзем өчен кыйналырга туры килә иде. Хәлбуки сүзгә бик нык колак сала торганнар иде, хата сүз өчен гафу итү юк иде, ә минем авыздан, күрәсең, дөресе белән бергә хатасы да ычкынгандыр инде. Һәм, гадәттә, мине язган әйберләрем өчен түгел, әнә шул әйткән сүзләр өчен тотып «пешерәләр» иде. Тик мишеньга бер әйләнү генә кирәк, шуннан соң инде сиңа җай чыккан саен бәрә торалар (хәтта гөнаһсыз сүзең өчен дә), чөнки моның бер куркынычы юк, беркем алдында җавап бирәсе дә юк, ә «уяулык»ны күрсәтер өчен бу бик әйбәт сылтау... Кыскасы, мин элек тә һәм соңыннан да язсам, ота, сөйләсәм, оттыра торган бер кешегә әйләнеп киттем.

Иҗат эше минем өчен башта ук шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйләнгән күңел һәм намус эше иде. Мин бары үзем белгәнне, үзем ышанганны гына язарга тиеш дип уйлый идем. Ләкин бер бәхәс чыкканда миңа әйттеләр: син үзең белгәнне, үзең уйлаганны эчеңдә калдыр, ә безгә без таләп иткәнне яз! — диделәр. Әмма үз күңелеңдә тумаганны заказ буенча гына язу? — Юк, мин моны аңлый да, кабул да итә алмый идем. Характерым белән мин әрсез, үҗәт кеше түгел, ишектән кусалар, тәрәзәдән керә белмим, ә кемгә дә булса ярау-ялагайлануны гомумән табигатем күтәрми иде. Шуңадыр инде миңа вакыт-вакыт бик авыр булып китә иде. Андый чакта ирексездән күңелгә Чеховның «Ненавижу насилие во всех ее формах!» дигән сүзләре килмичә калмый иде. Әйе, дөньяга күз ачылыр-ачылмас хаклы-хаксызга төрлечә кыерсытуларны шактый гына татырга туры килде — тышка чыкмыйча эчтә кипкән күз яшьләре дияр идем мин аларны... Хәер, ул чакта гынамы соң?!

...Әкренләп мин әдәбияттан еракլаша башладым. Өметле эш күренми иде ул тирәдә минем өчен, ә яшәргә, көн итәргә, семьяны карарга кирәк иде. Илдә чыпчык үлми, дигәннәр. Безгә дә насыйбы табылмасмыни?! Аеруча өметемне әлеге хезмәтне фәнни оештыру институтына баглаган идем... Шул рәвешчә, утызынчы елларның беренче яртысыннан алып мин язудан туктадым һәм әдәбияттан киттем... Китәр алдыннан дип әйтимме, «Көзнең бер киченде» дигән вакыйгасы бик куркыныч хикәя язган идем, ул ничектер «Совет әдәбияты»нда басылып та чыкты. Шуның белән тәмам, бетте, туктадык. Аннары озакламый миңа читкә дә китеп барырга туры килде.

1937 елның җәендә Кырымда ике ай чамасы дустым Хәбибрахман карамагында яшәдем. (Ул үзе мине чакы-

рып алган иде.) Хәвефле вакыт, җан тыныч түгел, кая барырга, нишләргә белмичә аптыраган чагым... Китәр вакыт җиткәч кенә Хәбибрахман мине кыстый-кыстый Ялтага, Галимҗан ага Ибраһимов янына алып барды. Сүз дә юк, авыру әдип белән бу очрашуның миңа тәэсире бик зур булды. Әгәр мин 1955 елны партия Үзәк Комитетына Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп хат язганмын икән, әнә шул 1937 елда әдипне үз күзем белән күрү миңа ул хатны тәвәккәлләп язарга, һичшиксез, ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

Язу белән бер сихерләнеп өлгергән кешегә аңардан тәмам айнуы бик читен булса кирәк. Еллар буе язып та дөньяга чыга алмаган, ләкин шуңа да карамастан язуыннан туктамаган фидакарьләр дә була бит әле. Менә мин дә, еллар үтеп, әзрәк тынычлана төшкәч, шул «җүләрләр» шикелле тагын бер талпынып карарга булдым. 1940 елны Үзбәкстанда чакта бер комедия язып, шуны Казанга, Риза Ишморат исеменә җибәрдем. Ә Казанда нәкъ шул чакларда сәхнә әсәрләренә ябык конкурс игълан ителгән булган икән. Риза абзый минем әйберне дә, чын исеме урынына «Шәмгун» дигән девиз куеп, тоткан да шул конкурска биргән. Конкурс барышында комедия өч кеше кулында булып, өч рецензия язылган — Риза абзый ул рецензияләрне соңыннан миңа җибәрде. Аларның берсе — Муса Җәлилнеке, икесе — Ибрай Гази белән Рахман Ильясныкы. Билгеле, үз фикерләрен алар әсәрнең авторы кем икәнен белмичә язганнар (конкурс ябык бит), Ибрай Гази белән Рахман Ильяс үзләренең русча язылган ярты битлек кенә рецензияләрендә комедияне каттый рәвештә кире какканнар. (Ягъни әсәр, аларча, бөтенләй яраксыз, тик Ибрай Гази гына иң ахырдан: «Әсәрнең теле яхшы, талантлы кеше язган булса кирәк»,— дип өстәп куйган.) Ә менә Муса Җәлил үзенең ике биттән артыграк рецензиясендә әсәргә иренмичә тулы анализ ясап, башта аның уңай, отышлы якларын күрсәтеп чыга, аннары инде аерым-аерым кимчелекләренә туктала. Әйтергә кирәк, чын җаваплылык тоеп, кеше әйберсенә мөмкин кадәр игътибарлы һәм гадел булырга тырышып язылуы белән Мусаныкы тегеләрнекеннән бик нык аерылып тора. (Бу рецензияләрне мин югалган дип йөри идем, ләкин быел иске кәгазьләрне актарган чакта табылдылар. Хәзер үземдә сакланалар.)

Иртә уңмаган — кич уңмас, кич уңмаган — һич уңмас, диләрме әле, шуның шикелле минем бу талпынып каравым да өметләнеп көткән нәтиҗәне бирмәде. Яңадан инде мин сәхнә әсәре язарга тотынып та карамадым. Сәхнә әсәре — оста итеп «ясау»ны сорый торган жанр. Ә мин ясый белмим — яза гына беләм икән.

Шуннан соң бер ел да үтмәде, гарасат купкандай, кинәт дәһшәтле сугыш башланды. Ил өстенә килгән бу куркыныч афәт көне-сәгате белән бөтен кешеләрне тигезләде дә куйды, бөтен халыкны Ватанны саклап калу өчен изге сугышка дәште һәм күтәрде. Бер ай да үтмәгәндер, мине дә алып, фронтка озаттылар.

Сугышның рәхимсез каты үз кануннары бар. Солдаттан алып генералга чаклы шул кануннарга беткәнче буйсынырга мәҗбүр: кая кушсалар — шунда барасың, кая куйсалар — шунда торасың... Җиңү хакына үлемгә керү дә әнә шул канун белән бәйләнгән.

Менә миңа да өч ел ярым хәрәкәттәге армиядә булып, рядовой солдат өстенә төшә торган барлык фронт михнәтләрен татырга туры килде. Дөрес, алгы сызыкта булмадым, чөнки безнең ротаның вазифасы башка иде, ләкин, әлеге каты канунга буйсынып, мин дә кая куйсалар — шунда тордым, кая җибәрсәләр — шунда бардым.

Әмма, иң гаҗәбе, әнә шундый гадәттән тыш шартларга барып эләгүемә карамастан, миндә ничектер үзеннән-үзе язасы килү теләге кабынды. Күргәннәр шулкадәр яңа, шулкадәр зур, куркыныч, фаҗигале һәм гыйбрәтле иде ки, аларның һәммәсен дә эчкә сыйдырып бетерү генә һич тә мөмкин түгел кебек иде. Сугыш әшәке нәрсә, кешенең табигатенә каршы нәрсә, берәүнең дә үләсе килми, сөйгән ярыннан аерыласы яки балаларын ятим калдырасы килми — миллион солдаттан сорап чык, һәркайсы шулай диячәк, үләсем килми, диячәк. Әмма инде иленә-йортына басып кергән дошманга каршы ул бөтен ачу-нәфрәтен туплап сугышырга, үтерергә һәм үләргә әзер... Күрәсең, болар барысы да, өлешчә генә булса да, тышка чыгарга, кәгазь өстенә төшәргә юл эзләгәндер инде.

Мин форсат эзли башладым. Күңелемдә күргәннәрдән туган уем бар — шуңардан бушаныр өчен миңа аулак урын кирәк. Ниһаять, 1941 елның җәендә, запас полкта чакта, кыска ял вакытларында иптәшләрдән яшеренеп кенә «Бала» дигән беренче хикәямне яза алдым. Яшеренеп кенә дим, чөнки нидер язып маташуыңны, бигрәк тә язучы икәнеңне сиздерергә ярамый — шунда ук ялгыз ак каргага әйләнеп калуың мөмкин. Солдатлар һәр җәһәттән бертөсле булырга тиеш, берәүнең дә башкалардан аерылып торырга хакы юк. Аннары бернинди командир да сиңа хикәят язып утырыр өчен бер сәгать тә вакыт бирмәячәк — хатны да һәрбер солдат, буш вакытны көтеп алып, кайда туры килсә, шунда тиз-тиз генә сызгалап ташлый... Ә бит солдат өчен өеннән хат алу яки сагышларын өенә язып җибәрү бердәнбер юаныч!

Шулай да мин өч ел дәвамында, энә белән кое казыгандай, берничә хикәя яза алдым: «Бала»дан соң «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге» — менә бөтен язганым... Язылган берсен Казанга «Совет әдәбияты»на җибәрә тордым, һәм, гаҗәпләнүемә каршы, алар барысы да җиңел генә басылып та чыктылар.

Сугыш кыры — үлем кыры булса да, мин әнә шул хикәяләремдә яшәү турында, терекләкнең үлемнән көчлерәк булуы турында язарга тырыштым... Юк, үлем терекләкне бервакытта да җиңәчәк түгел!..

Бу иман бөтен кешегә хас икән. Мәсәлән, сугыш кырында һәр көнне йөзләп-меңләп кеше кырылса да, бер генә солдат та үзенең шулар арасында үлеп ятуына ышанмый. Бәлки, акылы белән монда егылып калуның никадәр тиз, никадәр ансат булуын аңлый да торгандыр, әмма күңеленнән барыбер ышанасы килми, өметен бер генә минутка да өзми, яралансам да исән калырмын әле, Ходай кушса, дип эченнән генә үзен юата. Ихтимал, шушы үлмәсенә ышану аны ут эченә алып та керә торгандыр.

Безнең ротада командирлар һәм политруклар еш алмашынып торды. Аларның төрлесе булды, ләкин соңрак килгәннәрдән Левченко фамилияле политрук солдатларга аеруча ошаган иде. (Сүзеннән бигрәк кайгыртуы белән.) Миңа да аның мөнәсәбәте әйбәт кенә иде... Язгалап маташуымны ничектер белгәч, бер очрашканда ул миннән сорады: «Сержант, син нинди телдә язасың?» Мин, кыенсынып кына: «Татар телендә»,— дидем. (Кыенсынуның сәбәбе — татарча язуымны ачыктан-ачык яратмаучыларны да күрергә туры килгән иде инде.) Политрук, үкенгән сыман: «Алай икән, без аңларлык түгел икән шул! — дип куйды, аннары, нидер уйлап, тиз генә өстәде: — Хәер, ротада татарлар байтак кына бит, нигә шуларга укымаска, ә, сержант?!» «Ярыймы соң?» «Ник ярамасын? Даже кирәк ул, мин үзем аны сезгә оештырам!» — диде политрук, гүя мине рухландырырга теләп, һәм озак та үтми, беркөнне кичкә табан, эштән һәм посттан азат барлык татар, казакъ, үзбәкләрне (аның өчен барысы да татар!) урман кыюендагы ачыклыкка җыйды. Бер утызлап кеше куе үләнгә аякларын бөкләп, түгәрәкләнеп утырдылар. Политрук кыска гына кереш сүз әйтте, мине алларына бастырып, үзенчә зурлап таныштырды, аннары «берәр шәп кенә әйбер» укып җибәрергә кушты. Мин шул чакта солдатларга «Ялгыз каз» дигән хикәямне укыдым. Әлбәттә, уңайсызланып, шикләнә-шикләнә укыдым, чөнки бик күпне күргән, ут эченнән дә өтелеп чыгарга өлгергән, күбесе инде олы яшьтәге солдатларга бер япа-ялгыз каз турындагы хикәя ошамас, вак, әһәмиятсез нәрсә булып кына

күренер дип курыккан идем. Әмма... нәтиҗә һич көтелмәгәнчә килеп чыкты: хикәяне шылт та итмичә тыңладылар һәм бик яраттылар. Хикәя аларда әллә никадәр истәлекләр уятты, шуларны сагынып яки уфтанып исләренә төшерделәр — кыскасы, тансык бер мәҗлескә җыелгандай тарала алмыйча, шактый озак утырдылар. Билгеле, моның сәбәбе хикәя «шәп» булудан гына түгел иде. Хикмәт шунда ки, дошманны «әһ» тә димичә үтерә алган солдат җан иясе хайваннарны сугыш җирендә аеруча ярата, аларга бервакытта да кул күтәрми, киресенчә, сакларга тырыша, хәтәр-куркыныч җирдән аларны куып җибәрә. Бу әлеге дә баягы адәми затның тереклеккә бөтен җаны-тәне белән бәйләнгән булуыннан килә — хикәя исә аңардагы шушы табигый инстинктны көчәйтеп кенә җибәргәндер, күрәсең...

Мәгълүм ки, татар язучыларының да бик күбесе фронтларда булдылар, фашист илбасарларына каршы сугыштылар, кайберләре сугыш кырында газиз башларын да салдылар. Әмма шунсы бик гыйбрәтле — кем кайда, нинди генә шартларда сугышмасын, берсе дә каләменнән аерылмады, Ватанга мәхәббәтен һәм дошманга нәфрәтен юеш окопта ятканда да яки башын палач балтасы астына салганда да язуыннан туктамады... Мин исемнәрен китереп тормыйм, сез аларны яхшы беләсез. Шуңа күрә үземнең фронт шартларында язгалавымны зур фидакарьлектән санамыйм, тик шулай да фронтка әләккәч кенә яңадан язарга теләк уянуын, азмы-күпме яза алуым, ниһаять, журнал битләрендә басылып та чыгуым минем өчен бик тә әһәмиятле иде. Бу бит, насыйп булса, әдәбиятка яңадан кайта башлавым дигән сүз!

...Каты-канлы сугыш көтелмәгән дәрәҗәдә озакка сузылды. Аның кайчан бетүе турында кешеләр күпме төшләр күрмәде, күпме юраулар булмады! Әмма иң түйдырган, үзәккә үткән нәрсәнең дә ахыры бер килеп җитә. Исәннәр, ниһаять, күрделәр бәдбәхет сугышның да ахырын! Бөек Җиңү көне!.. Шатлык-сөенечнең чиге булмады, һәм кайтмый калганнар өчен түгелгән ачы күз яшьләре дә аз булмагандыр ул көнне...

Адәм барсын да күтәрә, барсына да түзә — чөнки яшәргә кирәк аңа, яшәргә! Канындагы мәңгелек тереклек авазына буйсынып ул кайгыларын онытырга, җиңнәрен яңадан сызганырга тиеш. Сугыш бетте — михнәт бетте дип тынычланырга иртәрәк. Эш әле бик күп булачак, авырлык, кытлыклар да булачак, бәлки, тамак та тиз генә туймас, өс-баш та тиз генә бөтәймәс, мәгәр сират күперен кичкәннәргә имин, тыныч, тук тормыш, һичшиксез, киләчәк. Ил әнә шул юнәлештә атлый хәзер...

Минем үз хәлемә килгәндә дә шөкер генә итәрлек. Гаиләм исән, картлар исән, сугыш алар өчен дә бетте — мин үзем март аенда ук армия сафыннан азат ителгән идем. Башта «Совет әдәбияты»нда бик аз гына эшләп алдым. Аннары радиокомитетка күчтем, әдәби-драматик тапшыруларны оештырып йөрим, айлык хезмәт хакым килеп тора... Җәйге һәм көзге айларда сугыш беткән җирләрдән бер-бер артлы язучылар кайттылар, берьюлы әдәбият дөньясы җанланып, союзда очрашулар, аралашу-йөрүләр ешаеп китте. Миңа күңелле иде. Иске дуслыклар яңарды (аеруча Әхмәт Фәйзи белән), яңа дуслар да табылды. Кайтучыларның күбесе фронт газеталарында эшләгәнгә күрәдерме, погонлы офицерлар иде, ләкин монда инде без погоннарны салганбыз, майор да юк, рядовой да, барыбыз да әдәбият әһелләре — үзара мөнәсәбәтләр дә җылы, дусларча иде. Әйткәнемчә, безне башта ук дәһшәтле сугыш тигезләгән иде, һәм шушы Ватан хакына туган бик кадерле тигезлекне без әле тоеп яши идек.

Әйтергә кирәк, минем кебек яңадан әдәбиятка кайтырга тырышкан кеше өчен бу тигезлек белән татулыкның әһәмияте аеруча зур иде. Нәкъ шул чакларда мине фронтта язган хикәяләрем өчен Язучылар союзына да алдылар... Әмма... ни гаҗәп! — дөнья миңа бер елмайса, артыннан ук тагын чыраен сыта! Нигә ул алай, сәбәп нәрсәдә? Инде тынычландым, инде миңа да юллар ачык дигәндә генә һич көтелмәгән бер хәл мине тәмам аптыраšта калдырды. Нәрсә булды дисезме?

...Әлеге фронт хикәяләремне Татиздат кечкенә бер китап итеп чыгарырга булды. Биш-алты гына хикәя кергән бу кәгазь тышлы кечкенә җыентык минем күп еллардан соң дөньяга чыгачак беренче китабым иде. Билгеле, мин аның чыгуын бик көтә идем... Менә шуның сигнальные килгәч кенә, минем үземә әйтеп тә тормыйча, әлеге «Ялгыз каз» хикәясен китаптан чыгарып ташлаганнар. Мин, белеп алгач та, нәшрият редакторларына йөгереп бардым: «Нигә, ни өчен?», «Ярамый»,— диләр. «Ни өчен ярамый?», «Ярамый, вәссәлам!» — аңлатып тору да юк... Китапның редакторыннан сорагач, ул да төшереп калдыру ягында, хикәя идея ягыннан тотрыксыз, имеш!.. Ходаем, ни дигән сүз бу?! Шуннан соң мин тиз генә союз идарәсенә гариза язып бирдем — әлбәттә, яклауларына бик нык ышанып... Күпмедер вакыттан соң, берничә кеше җыелып, миннән башка гына гаризаны караганнар... Нәтиҗәсен миңа мөхтәрәм бер язучы әйтте: «Хикәягезне китаптан чыгарып ташлап бик дөрес эшләгәннәр!» — диде ул, хәтта тавышын да калынайта төшеп... (Ачуы килгәндә аның шулай тавышын калы-

найтып, һәр сүзенә басым ясап әйтә торган гадәте бар иде.) Шуның белән мәсьәлә хәл ителде — хикәя китаптан төшеп калды... Мин хөрмәтле язучы белән бәхәскә кереп тә тормадым, чөнки хикәядә һичбертөрле гаеп юклыгы миңа көн кебек ачык, ә бу эшнең төбендә бөтенләй башка сәбәпләр ятканын икенче җирдән эзләргә кирәк иде. Хәер, артык эзләп торасы да юк: мин үзем кеше һәм язучы буларак кемнәргәдер ярамый идем. Бары шулай гына аңларга мөмкин иде бу хәлне ул чакта.

— Тукта! — диярсез, бәлки, сез.— Болай ук катгый нәтиҗә ясарга иртәрәк түгелме? Бер хикәя мисалында гына... Китаптан берәр әсәрне төшереп калдыру нәшрият практикасында булгалап тора... Сезнең нәтиҗә рәнҗү аркасында гына тумады микән?!

Әйе, шулай булуы да бик мөмкин... Ләкин менә сезгә тагын бер мисал. 1948 елны мин күптән уйлап йөргән «Тауларга карап» исемле хикәямне бетереп, «Совет әдәбияты»на илтеп бирдем. Үтмәде, басмадылар. Мин монда берәүнең дә фамилиясен атап тормыйм, алар барысы да хөрмәткә лаек зур язучылар иде. Журналда утыручы әнә шундый хөрмәтле язучыларның берсе хикәянең ни өчен «үтмәвен» борын эченнән генә миңа болай аңлатты: «Хикәягездә сүз күп, хәрәкәт аз, аннары хискә бирелеп язылган»,— диде... Ярый, шулай да булсын ди. Әмма басмас өчен бу сылтау гына җитәме? Ул үзе романнар язучы, ә мин хикәя, повестьлар язам. Хәлбуки әдәбиятны аңлаган кеше белергә тиеш — хикәя кайчагында эчтәлеге белән романга торырлык та булып чыга. Классик әдәбияттан моның мисалларын күп табарга була. Минем монда хикәямне мактап торасым килми, татар әдәбиятын укучыларга ул билгеле булырга тиеш — уналты елдан соң мин аны кыскартыбрак булса да «Азат хатын»да бастырып чыгардым, аннары инде ул бөтен җыентыкларыма да керде. Укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан аның хакында миңа мактаудан башка сүз ишетергә туры килмәде. Ләкин мин бит теге чакта «үтмәү»нең сәбәбен ничектер аңларга тиеш. Сәбәбе нәрсәдә? Зарарлы әсәрме яки начар язылганмы? Юк, берәү дә моны исбат итеп маташмый. Димәк, миңа тагын шул ук нәтиҗәне ясарга туры килә: хикәя үзе ничава да, авторы әллә ниндирәк. Ипсез кеше, чыкмый торуы әйбәтрәк!

Алдарак телгә алынган «Нәгыймә Таҗдарова» монографиясе белән дә шундый ук «бәхетсезлек» килеп чыкты. Заказ буенча килешү нигезендә язылган әсәрне ВТО (театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге) тотты да кабул итүдән баш тартты. (Гази Кашшаф, мәрхүм, аңа бик төпле, уңай рецензия дә язып биргән иде югыйсә.) Баш тарту-

ның сәбәбен хәзер инде әйтә дә алмыйм, әмма отказ бирүче үзе гаять үзсүзле кеше иде. Ахыр чиктә миңа монография өчен гонорарны да суд аша алырга туры килде.

Бер-бер артлы килеп торган бу «казалар» минем хәлемне бик читенләштерде. Матди яктан да бик кыйналдым... Ә мораль ягын әйтеп торасы да юк! Гүя кемнәрдер миңа юри менә аяк чалалар — ирексездән, теләмәсәм дә, шулай уйларга мәҗбүр идем. Бик химаясез идем мин ул чакта...

Ләкин бит әле мин — союз члены, язарга хаклы гына түгел, тиешле дә кеше. Язу инде — төп эшем, төп кәсебем... Тик мин акча табар өчен күбрәк тәрҗемә белән шөгыльләнәм, хәтта кеше өчен дә тәрҗемә иткәләдем. Әмма бу «кәсеп» мине һич тә канәгатьләндерә алмый иде, мин дә үземнекен язарга тиеш — кырыкка җитеп киләм бит инде... Башта уйлар күп, күңелдә ышаныч аз, нәрсәгә тукталырга да белмим.

Ахырда якын дустым Хәбибрахманга барып зарымны сөйләдем. Ул, әдәбияттан читтә торса да, заманны бик яхшы аңлый иде. Миңа әйтте ул: «Син үтә современный бер әйбер язып ташларга тиеш — шул гына синең хәлеңне җиңеләйтәчәк!» — диде.

Әлбәттә, бу дөрес киңәш иде. Хуш, нәрсә «үтә современный» хәзер? Менә ил алдында беренче нәүбәттә торган зур бурычларның берсе — колхоз хуҗалыгын тизрәк аякка бастыру — һичшиксез, бик кирәкле тема. Авылны элек мин яхшы ук белә идем, ләкин сугыштан соңгы авыл белән танышлыгым аз... Шуны истә тотып, союздан бер айлык иҗат командировкасы алдым да Апас районындагы Әтрәч авылына китеп тә бардым. Бу кыш үзәге иде, ә яз башында шул ук районның икенче читендәге Балтай авылына барып, тагын бер өч атна «колхозны өйрәнеп» яттым. Бик файдалы булды минем бу барып «ятуларым» — күп нәрсәне күрергә һәм аңларга ярдәм итте. Кайткач инде шушы ике авылда күргән-ишеткәннәрдән чыгып, мин колхоз темасына ашыкмыйча гына, әдәби ягы да әйбәт булсын дип тырыша-тырыша, биш-алты табаклык бер повесть яздым. Исемен дә үтә заманча «Рәхмәт, иптәшләр!» дип куйдым. (Ә дөресен әйткәндә, исем табуда осталыгым юк диярлек.)

...Повесть җиңел үтте, җиңел басылды. Мәшәкатьсез генә аерым китап та булып чыкты. Тәнкыйть тә яхшы каршы алды. Хәтта теге «Ялгыз каз»ны суйган мөхтәрәм язучы да повесть турында берничә мактау сүзе әйтте... Менә бит ул «үтә современный» әсәр язуның файдасы! Абзагызның эше көйләнә бит болай булгач!.. Язучы буларак минем дәрәҗәм дә үсә төште, позициям дә бераз ныгыды кебек... Дөрес, соңрак мин үзем ул отышлы әсәрнең берәү дә әйтмәгән

бер кимчелеген сиздем сизүен... Кимчелек аның исемендә үк иде. Ягъни авыл советы сессиясендә каты тәнкыйть ителгән ферма мөдире Нургали (повестьның төп герое), соңыннан үзенең хатасын аңлап, тәнкыйть итүчеләргә күңеленнән рәхмәт укый башлый!.. Йә, фальшь түгелме бу? Кемнең кайчан тәнкыйть итүчеләргә рәхмәт укыганы бар әле? Тот капчыгыңны! Ә бәлки, киләчәктә укырлар?! Нигә көләсез? Әдәбият алга да карарга тиештер ләбаса!..

Шулай да повестьның үзенә рәхмәтне әйтергә кирәктер — ул минем авыр хәлне шактый ук җиңеләйтте. Инде уңышны беркетер өчен тагын шундыйрак бер отышлы нәрсә язасы иде дә бит, ләкин мин, тиле, чыгымчы аттай, яңадан буразнаны боза башладым. «Саз чәчәге» исеме белән бер райком секретаренең обывательгә әйләнүе турында повесть яздым. Аннары, ул гына җитмәгәндәй, зурраграк «Рәшә»не дә язган булдым. Бусы инде «коеп куйган» обыватель турында... Бик кыенлык белән булса да, алар журнал битләрендә басылып та чыктылар. Иллә мәгәр «Рәшә»не китап итеп чыгара алмыйча йөдәп беттем... Билгеле, алар икесе дә тәнкыйтькә юлыктылар. Бигрәк тә «Рәшә» китап булып чыккач, бер философ аны бөтенләй тетеп ташлады... Үрмәләп менгәндә генә мин тагын түбәнгә тәгәрәдем бугай... Хәер, повестьларны яклап чыгучылар да табылды, аеруча яшьләр арасыннан... Шулай итеп, фикерләр капма-каршы икегә аерылды, ләкин аларның кайсысы өстенлек алачак — бу кадәресен вакыт кына хәл итәчәк иде.

...Кыскасы, мин әдәбиятка авыр кердем, озак кердем. Бик озак мин үземне язучы дип атарга да кыймыйча йөрдем. (Тыйнаклыктан түгел, ә үземә ышанып бетмәүдән.) Әйберләрем авыр уза, кат-кат төзәтергә туры килә, күп бәхәс-тартышлардан соң гына үткәреп була торган иде. (Редакторлар гадәттә «шиклерәк» әйберне үткәрмәскә тырышалар, чөнки соңыннан берәр төрле җәфасы килеп чыгарга мөмкин, ә үткәрмәгән өчен беркем алдында да җавап бирәсе юк.) Кайчагында әнә шулай тауга каршы таш тәгәрәткәндәй азапланырга туры килә иде.

Ләкин моның сәбәбен бары редакторларга гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. (Ул да бит ике башлы түгел, басып чыгарган һәр сүзе өчен җаваплы.) Миңа калса, авырлыкларның төп сәбәбен әдәбиятның үзеннән эзләргә кирәк. Фикер аңлашылсын өчен тагын сугыш вакытын искә төшерик. Ул чакта әдәбият алдында бер генә изге бурыч иде — Ватанны яклау... Һәм язучы да үзенең каләмен бары әнә шул бөек максатка хезмәт иттерә — башкасында аның хәзергә эше юк. Шуңа күрә, әгәр яза алсаң, бастырып чыгаруы да авыр түгел иде.

Сугыш бетеп, тыныч тормыш башлангач, әдәбиятның да бурычлары, билгеле, катлауланды. Өстәвенә әлеге вульгар социалогизм яңадан көчәйде, каяндыр конфликтсызлык теориясе килеп чыкты... Нәрсә турында ничек итеп язарга?.. Мондый сорау һәр заманда һәрбер язучыда туа, әмма җавабын һәркем үзенчәрәк табарга тырыша. Һәм шушы төп мәсьәләне хәл иткәндә язучының тормышта күргәннәре дә, заманны аңлавы да, ниһаять, характеры да чагылмыйча калмый...

...Менә миңа да үз җавабымны табарга кирәк иде. Күргән-кичергәннәрнең бу китапта язылган кадәресен сез беләсез инде, ә язылмый калганы аның тагы да күбрәк, һәрхәлдә, «материалым» җитәрлек дип әйтәсем килә. Һәм бу «материал» турыдан-туры заман белән бәйләнгән, билгеле, шуңа күрә мин заманны һәрвакыт каты тоеп яшәдем дип әйтә алам, әмма аның һәр дәверен, һәр борылышын яхшы аңлап бардым дип әйтергә җөрьәт итмәс идем. (Ә кемнең заманны аңлап бетергәне бар?!) Ул бит өзлексез үзгәреп торган чиксез диңгез! Кыскасы, минем бу хакта артык җәеләсем килми, чөнки язучының заманны ничегрәк аңлавын аның әсәрләреннән эзләргә кирәк... Язучы үзе нәрсә әйтмәс — бакырны алтын итеп күрсәтүчеләр дә очрый кайчакта.

Инде характерга килсәк, моны язучының үзеннән башка кем генә аңлата алыр икән?! Бик четерекле, нечкә эш бит — әсәрдә язучының үз йөзен күрү... Халыкта «мал иясенә охшый» дигән сүз бар, бәлки, шуннан чыгыбрак аңлатырга кирәктер... Мин, мәсәлән, һәр эштә гадилекне, табигыйлекне яратам һәм әсәрләремне дә мөмкин кадәр гади, табигый итеп язарга тырышам. Мин шулай ук ачык, ихлас булуны яратам һәм әсәрләремдә дә фикернең ачык, хисләрнең ихлас булуына омтылам. Аннары, мин ялганны, фальшьны, ялагайлыкны бер дә яратмыйм һәм язган чакта шулар начар ис шикелле әсәремә кермәсен дип бик сакланам. Янә мактануны да, дан артыннан чабуны да бер дә яратмыйм, һәм, сез күрәсездер, минем геройларым күбесенчә бик тыйнак, инсафлы кешеләр.

Тагын нәрсә? Иҗат — изге гамәл. Әдип, Тукай әйткәнчә, дөньяга «күкрәк тәрәзәсен» ача. Бу минутларда ул һәртөрле тормыш ваклыкларыннан арынган булырга тиеш. Иҗат өчен иң кирәге — җан тынычлыгы. Әмма минем тыныч җан белән эшкә утырган чакларым сирәк булгандыр... Шуңадыр, ахрысы, мин үземнең язучы булып китүемә әле дә еш кына гаҗәпләнеп куям.

Ә шулай да унике-унөч яшемдә үк күңелемдә туган хыялыма, әкренләп үрмәли торгач, ирештем, ниһаять! Хәер инде мин шактый танылган карт язучы... Аксакал!

(дип тә җибәрәләр.) Язучылык — минем төп кәсебем. Кәеф юк дип тормыйм, көн дә эшенә ашыккан хезмәткәр шикелле, мин дә көн саен диярлек эшемә утырам. Арыган чакларым була, туйган чакларым да була, ләкин дә бизгән чакларым булмый. Бизү — яшәүнең мәгънәсен югалту булыр иде.

Язу — акыл һәм йөрәк эше — миңа калса, иң авыр эш. Таләпләр күп, җаваплылык бик зур. Менә шул җаваплылыктан курыкмас өчен, төрле таләпләр алдында югалып калмас өчен, язучы иң элек, ничек дим, үзенең төп максатын билгеләргә тиеш (кыйбласын дип әйтергә дә ярый). Ә максат ул — нәрсәгәдер инану, нәрсәнедер бик нык теләү дигән сүз... Бары шул нигездә генә иҗат итәргә мөмкин.

Моны раслар өчен үземнән мисал китерсәм, гаеп итмәссез дип уйлыйм. Баштарак әйткәнемчә, фронтка эләгеп, сугышның нәрсә икәнен күргәч, миндә яңадан котылгысыз язу теләге уянды. Сугыш — коточкыч афәт, әмма тереклек үлемнән көчлерәк! Менә шушы үзеннән-үзе диярлек күңелдә яралган уй-теләк, инану мине иң кыен шартларда да кулыма каләм алырга мәҗбүр итте дә инде.

Сугыштан соң да миңа шундый бер көчле теләк, шундый бер якты маяк кирәк иде. Хәлем авыр, язучы булып каламмы-юкмы — минем алда әнә шундый читен мәсьәлә тора. Ә теләксез һәм маяксыз юл табу мөмкинмени? Әмма нәрсә теләргә, нәрсәгә омтылырга соң минем газиз башка?! Мин гаделлеккә бик мохтаҗ идем, минем төрле шикшөбһәләрдән котыласым килә иде, ихтимал, шулар нәтиҗәсендә булса кирәк, миндә ирексездән «Кешеләр гадел, намуслы булсын иде!» дигән теләк туды. Һәм шушы ихлас теләк минем иҗатымда төп максатка да әйләнде: кешеләр гадел, намуслы булсын! — менә нәрсә хакына мин язарга тиеш.

Иллә мәгәр кешеләрне яхшырту өчен аларның кимчелекләрен фаш итәргә кирәк булды. Нәтиҗәдә, «Саз чәчәге», «Рәшә», «Әйтелмәгән васыять», «Вөҗдан» кебек әсәрләр язылды. Алар хакында бәхәсләр туды, каты тәнкыйтьләр дә ишетергә туры килде. Ләкин дә әлеге ихлас теләгем миңа ул тәнкыйтьләрне күтәрергә, үземне хаклы дип санарга бик нык ярдәм итте.

«Рәшә»дәге Зөфәр Сабитов үз бәхете өчен генә яшәүче һәм бу бәхетне бары байлыктан гына эзләүче тип иде. Ул әле «инсафлы» егет, эчми-тартмый, дәүләт малын да үз кулы белән урламый. (Аңа китереп кенә бирәләр.) Шулай да кайбер тәнкыйтьчеләр Зөфәр Сабитовны безнең җәмгыять өчен типик түгел дип таптылар. Хәтта

чынбарлыкны бозу дип тә бәяләделәр... (Рәшә кояш яктысын каплый, янәсе!) Ә тормыш нәрсә күрсәтте? «Рәшә» язылганнан соң биш-ун ел да узмагандыр, Зөфәр ише «типик» булмаган кешеләр безнең җәмгыятьтә, яңгыр артыннан калыккан гөмбәләр шикелле, берьюлы ишәеп китте. Байлык артыннан куу, малга табыну, хәрәм юллар белән акча табарга тырышу социаль бер чиргә әйләнде дияргә дә ярый. Мин инде бу чиргә дучар булган кешеләрнең әхлакый яктан да әкренләп бозыла башлавын — комсызлык, көнчелек, хәйлә-мәкер, икейөзлелек, алдашу-ялганлау кебек гадәтләргә бирелеп китүләрен әйтеп тә тормыйм.

Авыруын яшергән — үләр, диләр иде элек. Хак сүз. Әлбәттә, мин моның белән тормышның якты-уңай якларын да, гадел, намуслы кешеләрнең күбрәк булуын да һич инкарь итмим. Әмма безнең җәмгыятьнең тазалыгы өчен борчылу, аңардагы кимчелекләр өчен көенү, шуларны фаш итүдән курыкмау һәм бетерергә өндәү, миңа калса, һәрбер намуслы язучының патриотик бурычы ул. Асылда, язучының гражданлык йөзе дә шуның белән билгеләнә түгелме соң?! Моның өчен классик әдәбиятны искә төшерү дә җитсә кирәк.

Мәгәр укучы, бу абзый үзе болай әйбәт кенә икән дә, тик менә башкалар гына начар икән шул, дип уйлый күрмәсен. Юк, мин үземне башкалардан һич тә аерырга теләмим. Мин дә кеше, һәм кешегә хас кимчелекләр миндә дә бар. (Аларны санап тормыйм — йә арттырып җибәрермен.) Гомумән, беркемне дә, шул җөмләдән, язучыны да, идеаллаштырырга ярамый. Безнең барыбызга да — гади эшче һәм колхозчыдан алып галимгә һәм министрга чаклы — әкренләп булса да һаман камилләшергә һәм яхшырырга кирәк. Һәр җирдә, һәр эштә бары тик гадел һәм намуслы булып калу безнең төп кешелек сыйфатыбыз булырга тиеш. Социалистик җәмгыятебезнең тазалыгы, сафлыгы һәм раслануы шуңа бәйләнгән ахыр чиктә... Бигайбә, мин башкача уйлый алмыйм!

...Инде миннән: «Ярый, аңладык, соң үзегез язучы буларак язмышыгыздан канәгатьме?» — дип сораулары мөмкин. Тулаем алганда, канәгать, билгеле... Иң мөһиме — язганнарымны укучы кабул итте, укучы яратты. Ә мин моны язучы өчен иң зур мөкяфәттән[1] саныйм. Шулай ук тора-бара өлкән язучылар да, яшьрәкләр дә, әдәби тәнкыйть тә мине таныды, тану гына түгел, артыграк мактый да башлады. Кыскасы, әкренләп барсы да — исеме

[1] *Мөкяфәт* — хезмәт бәрабәренә бирелгән бүләк.— *Ә.Е.*

дә, даны да, бүләге дә килде миңа... Дөрес, кайбер канәгатьсезлек күңелдә саклана саклануын — мәсәләң, аз сәяхәт иттем, дөньяны аз күрдем, нәфислек белән гүзәллекне дә аз күрергә туры килде — ә боларны мин язучы кеше өчен бик зарури нәрсәләр дип саныйм... Инде байлык белән мәхәббәткә килгәндә, бала чактан ук хәтердә сакланган бер мәзәкне искә төшерергә була.

...Акколай авылының бер башкорт малае урамда иптәшләренә мактана икән:

— Һәй, тәмле лә һуң аккалас!

— Китсе! Әллә ашаның?

— Агаем Эткол базарында бер мәрйәнең ашаганын карап торган,— димеш малай, эре генә.

...Мәзәк аңлашылса кирәк!

Хәер, зарлану язык булыр. Язучының бәхете — язганнарында. Әйткәнемчә, мин канәгать. Иҗат юлымның башы никадәр авыр булса да, ахыры, шөкер, уңышлы булып чыкты дип әйтә алам. Дөрес, һәр уйлаганымны яза алдым, һәр язганымнан канәгатьмен дип әйтергә җөрьәт итмәс идем. Бу инде һәрбер язучы өчен дә шулайдыр. Чын язучы гомере буена өч вакыт эчендә яши: үткәнне онытмый, бүгенгене күрә, киләчәкне уйлый... Үлгәндә дә ул солдат шикелле алга карап үлә торгандыр...

Бөек Гоголь: «Минем исемем үземә караганда бәхетлерәк булыр»,— дигән. Мин, әлбәттә, Гоголь түгел, аның сүзләрен үземә күчерергә дә уйламыйм, әмма кайбер олы шәхесләрнең исемнәре, үзләренә караганда, чыннан да, бәхетлерәк була. Тарихта моның мисаллары күп — безнең Тукай, Җәлил, Сәйдәшне искә төшерү дә җитә. Аларның бәхетләре — мәңгелек!.. Андый бәхет үзе эзләп таба лаеклы кешесен... Дәгъва итү мөмкин түгел.

...Алты елдан артыграк оясыз буйдак булып йөргәннән соң, мин 1931 елның көзендә Гөлсем исемле сылу гына кызга өйләндем. Бик гадәти һәм табигый эш, билгеле... Тик шулай да өйләнүнең нәрсә икәнен ничектер кыскача гына аңлатасы килә. Халыклар телендә «Рубиконны үтү» (яки кичү) дигән кинаяле бер әйтем бар[1]. Мәгънәсе — хәлиткеч кыю адым ясау... Нәтиҗәсен алдан күреп бетерү мөмкин түгел. Әмма адымның үзен кеше ышанып-теләп ясый,— бусы бәхәссез. Өйләнү әнә шундыйрак нәрсә ул, минемчә.

Ә 1932 елның җәендә инде мин яшь хатыным белән беренче һәм соңгы мәртәбә Дәүләкәнгә кайттым. Вок-

---

[1] *Рубикон* — борынгы Галлия белән Италия чигендәге елга исеме.— *Ә.Е.*

залда безне атакай каршы алды. Йортыбыз станциядән әллә ни ерак булмаса да, ул, яшь килен хөрмәтенә, безне бер башкорт агаеның читән тарантасына утыртып алып кайтты... Әйе, соңгы кайту, соңгы күрү, соңгы йөрүләр... Дөньяның бик үзгәргән чагы — билгеле, кечкенә Дәүләкән дә үзгәрмичә калмаган... Тыштан искечә диярлек, шул ук урамнар, шул ук йортлар, тик тормыш башка да кешеләре бүтәнчә. Минем белән бергә үскән, йөргән егетләр һәм кызларның күбесе юк — йә укырга, йә эшкә киткәннәр, ә кайберләрен ерак җирләргә озатканнар. (Ата-аналары белән бергә.)

...Көймәләргә төялеп, гармун-җыр тавышлары белән су буйларын яңгыратып Димдә йөрүләр, кичләрен киенешеп «гүляткә» чыгулар, Бәлдәй клубында концерт, спектакль куюлар юк — әллә вакытлыча, әллә бөтенләйгә сүнгән, беткән иде.

Ял вакытыбыз беткәнче инәйнең майлы коймакларын, куе каймакларын ашап, көннәребезне күңелсез, сүлпән генә үткәрдек тә яңадан Уфа аша үзебезнең ислетузанлы ташкалабызга юнәлдек. Шуннан соң миңа егерме ике ел Дәүләкәнне «онытып» торырга туры килде.

Әмма бу кайтуыбызның бик мөһим бер нәтиҗәсе булды. Шактый гына сөйләшү-киңәшүләрдән соң, атакайларны да Казанга күчерергә кирәк дигән карарга килдек. Икесе дә картаеп баралар, энем дә каядыр читтә йөри, килерләре юк диярлек, карап торган бер сыерлары бар, ләкин аны асравы да читен булачак, чөнки кышын базарга печән бөтенләй чыкмый башлаган... (Дим тугайларына карап, печәнсез утыр, имеш!..) «Ни булыр, нәрсә көтә безне?» — ди атакай, авыр көрсенеп.

Соңгы ике елда Дәүләкәндә икеме-өчме колхоз төзелгән булган, ләкин бу «бөек борылыш» минем картка бөтенләй кагылмаган, чөнки ул крестьян түгел, аты-туны да юк, кыскасы, заман барышыннан читтә торып калган кешеләрнең берсе. Ә андый «торып калучылар» Дәүләкән кебек ни авыл, ни шәһәр була алмаган җирдә байтак кына икән.

Менә шундый хәлдән чыгар өчен нишләргә кирәк?.. Уйлаштык-киңәштек тә хәзерге шартларда бергә оешып яшәүдән башка чара юк дигән нәтиҗәгә килдек. Шуннан соң инде йортны исән-имин чагында сатып, атакай белән инәй быелдан да калмыйча безнең янга күчеп килергә тиеш булдылар.

Әлбәттә, аларга картайган көннәрендә гомер иткән җирләреннән кубарылып күчену җиңел эш түгел иде. Борын заман кешеләр биш-алты буын һичкая кузгалмыйча бер урында яшәгәннәр (мәсәлән, шул ук Каргалы

кешеләре), ә хәзер җил куалаган «пәри арбасы» шикелле алар каядыр тәгәрәргә тиешләр. Безнең атакай 1910 елны Каргалыдан Дәүләкәнгә күчеп килә. Аңа ул чакта әле утыз алты яшь кенә булган һәм ике авыл арасы да кырык чакрымнан узмаган. Икесе дә аның өчен туган туфрак, ә Дәүләкәнне ул аеруча яратып яшәде... Инде менә шуның бәрәкәтле туфрагыннан тамырың белән кубарылып, мең чакрымдагы күз күрмәгән таш калага күчеп кара син!.. Әмма, әйткәнебезчә, бүтән чара юк.

Шул ук 1932 елның көзендә, йортыбызны ниндидер бер оешмага алты меңгә сатып, октябрь урталарында булса кирәк, атакай белән инәй Казанга күчеп килделәр. Үзләре белән бары кием-салымнарын гына алган булганнар, ә бөтен йорт әйберләрен зур сандык-әрҗәләргә тутырып, «малый скорость» белән багаж итеп җибәргәннәр. Күпмедер вакыттан соң алары да исән-имин килеп җитте.

Атайлар миңа дип килделәр бит инде. Ә мин үзем дә ул чакта хатынның әниләрендә торып ята идем. Кешеләрнең күңелләре киңрәк булган, күрәсең, әби дигәнем өч җиткән кызы өстенә минем картларны да сыйдырды...

Ишектән керүгә тәрәзәсез дөм караңгы кечкенә бүлмә бар иде — аларны шунда урнаштырдык. Артларыннан килгән сандык-әрҗәләрен ишегалдындагы утын сараена «төйгечләп» тутырдык. Кыш чыкканчы алар шунда яттылар — ни хикмәттер, тиюче булмады.

Билгеле, «әбиләр» өстендә озак яту мөмкин түгел иде — мин үзебезгә торыр урын табу хәстәренә керештем. Картның кулында йорт саткан акчасы, ул аны күз карасыдай саклый, безнең исәп менә шул акчага кечерәк кенә булса да бер йорт табу иде. Язга чыккач, мин бу эшкә чынлап торып тотындым. Казанның йөрмәгән җирен калдырмаганмындыр, шулай да күбрәк шәһәрнең югары ягыннан эзләдем. Күп игъланнарны укып, күп урамнарны таптап йөри торгач, мин ахырда Арча кырыннан бер кечкенә агач йорт таптым. Хуҗасы — ялгыз бер хатын. Йортның өч бүлмәсе, кухнясы һәм тышкы коридорында зур гына чоланы бар. Ишегалдында бүрәнәдән салган сарае, утынлыгы, кар базы һәм безне бик кызыксындырган, йорт артында буш яткан бер биш сотый чамасы җире дә бар икән. Кыскасы, бу йорт күңелгә хуш килде, һәм без хуҗа хатын белән ничек тә килешү ягын карадык. Мәгәр бер кыенлык чыкты: йортның кухня белән янәшә зуррак бүлмәсендә ирле-хатынлы ике кеше тора икән. «Алар чыгачакмы соң?» — дип сорагач, хуҗа хатын туп-туры: «Чыгара алсагыз»,— дип кенә җавап бирде. Алаймыни, ә эш нәрсәдә?.. Баксаң, бу үзләрен «элекке партизаннар» дип атаган ирле-хатынлы

кешеләр кайчандыр законсыз рәвештә аның бүлмәсенә басып кергән булганнар. Билгеле, зур гауга чыккан, айларга сузылган ызгыш-талаш киткән, ләкин хуҗа хатын, күпме тырышса да, барыбер аларны куып чыгара алмаган. Киресенчә әле, тегеләр үзләре моны төрлечә җәберли, кысрыклый башлаганнар... Ялгыз башым мин аларга каршы тора алмыйм, ди хуҗа хатын, шуңа күрә йортымны сатып китәргә дә булдым, ди... Без икеләнә калдык. Нишләргә?.. Күңелгә охшап өлгергән, бәясе дә безнең көч җитәрлек бу гаугалы йортка аяк атлап керергәме-юкмы? Тәвәккәл — таш йоткан, дидек тә, килешергә булдык, чөнки без инде «партизан»нан түгел, иблиснең үзеннән дә курыкмас хәлгә килеп җиткән идек. Килешенгән бәясен тулысынча түләп, алу-сатуны тиешле урыннарда рәсмиләштереп, үзебезнең инде законлы йортыбызга төянеп тә килдек. Безнең килү, хуҗа хатынның чыгып китүе бер көн эчендә булды. Шуның аркасында теге «партизаннар» хуҗалар алышынганын ничектер абайламыйча калдылар. Әмма безнең күченгәнне күргәч, аларның кашлары җимерелде. Шунда ук безгә карата бик агрессив булачакларын сизендек, ләкин күрмәмешкә салынып, тыныч кына урнаша бирдек. Без бит әле өч ир кеше (энемнең дә Казанда чагы), аларга артык игътибар итмәскә дә була иде.

Хәер, соңрак та без тыйнаклык һәм чыдамлык сакладык, йортның законлы хуҗасы булсак та, аларны чыгару турында сүз кузгатмадык — безгә хәзер беркем белән берниндди низагка кермичә генә урнашу, төпләнү, торып китү кирәк иде. Картлар исә безнең аеруча юашлар, ничек тә тату булырга тырышалар, ләкин бу куркудан гына түгел, ә якын күрше белән дошманлашып яшәүне белмәүдән, өйрәнмәгәннән иде.

Әмма тегеләр беренче көннән үк диярлек безгә шактый күп этлекләр эшләп карадылар. Бигрәк тә җиз самовардай җирән, таза хатыны бичара инәйне бик җәфалады. Инәйнең эше гел кухняда, үзе бер авыз сүз русча белми, ә җирән марҗа аңа акыра да җикеренә, мичкәплитәгә якын җибәрми, савыт-сабаларын алып ыргыта, җылы су салып куйган комганын да берничә мәртәбә ишегалдына чыгарып атты. Инәйнең утырып елаган чаклары булды. Ләкин ул түзде — Ходай үзе аңа түзәргә кушкан иде.

Инәй генә түгел, барыбыз да түзәргә тырыштык, чөнки аларны тыярлык көч-чара бездә юк иде. Шуны чамалап булса кирәк, алар безгә каршы этлекнең зуррагын да эшләделәр — «чит элементлар» өстебезгә басып керде дип, донос та яздылар. (Кечкенә түгәрәк сакаллы, пөхтә

генә йөргән минем картны алар «бывший мулла» дип уйлаганнар.) Миңа кайбер урыннарга барып акланырга да туры килде.

Әмма гаҗәбе шунда ки, болар бүген этлек эшләп, иртәгә шуны оныта торган кешеләр иде. Аларның яраткан эше — карта сугу... Икәү генә уйнап туйгач, хатын белән мине дә берни булмагандай үзләренә карта сугарга чакыралар иде, һәм көлешә-талаша «подкидной»ны уйнап та чыга идек... Кайчагында җирән марҗаның ире — шоп-шома елтыр битле, базык-йомры гына Сембер мишәре — «бывший мулла» белән сөйләшер өчен безнең якка да чыгып утыра иде...

Без инде бу «фатирчылар»дан бервакытта да котыла алмабыз дигән фикергә дә килгән идек. Ләкин... бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына, диләрме әле — шуның төслерәк һич көтелмәгән котылу бәхетенә без дә ирештек. Кышны да үткәреп, җәйгә чыккач, боларга Ташкенттан бер пар кунак килде. Ходай бирмеш һәр көн ашадылар-эчтеләр, таңга кадәр шаулап утырдылар, көндезләрен шәһәргә, бакчаларга чыгып йөрделәр. Мәгәр ки, безнең шанлы Казаныбыз кунакларга, ни сәбәптер, бер дә ошамаган, һаман үзләренең Ташкентларын, андагы мул-тук тормышны «үтереп» мактыйлар икән... Мактау белән генә чикләнмичә, хуҗаларны да үзләре белән бергә Казанны ташлап китәргә бик кыстаганнар булса кирәк... Ә безнең «партизаннар» — теләсә нинди мәсьәләне дә артык баш ватмыйча гына чишәргә өйрәнгән кешеләр. Бәс, Ташкент Казаннан шәбрәк булгач, алар тоталар да, кунакларына ияреп, җылы, җимешле якка китеп тә баралар. Шулай итеп, безгә бүлмәне бушатыр өчен кыл да кыймылдатырга туры килмәде.

Дөресен генә әйткәндә, без аларның чынлыкта кемнәр булуын да белмичә калдык.

Хәзер инде үзебез генә хуҗа булып, тыныч кына яшисе калды. Атакай, алтмышын тутырса да, нык, җегәрле карт әле, инәй дә бер генә көн дә эшсез торырга өйрәнмәгән. Алар, үз сүзләре белән әйткәндә, тормыш корырга яраталар — төпле итеп, ныклы итеп — яшәүнең мәгънәсен дә шуннан гына табалар. Өченче тапкыр инде аларның яңа урында, яңабаштан «тормыш корулары» — зарланмыйлар, авырсынмыйлар, тик бер Ходайдан иминлек кенә телиләр. Без исә таяныч һәм булышчы — шуңа ышанып килделәр дә алар.

Аерым ишегалды булгач, башта тавык-чебеш үрчетә башладылар, аннары тәвәккәлләп сыер да алдылар. (Кошкортсыз, сыерсыз торуны алар тормышка да санамыйлар иде.) Ул елларда безнең йортлар каршында иркен генә

ялан бар иде, шунда терлек йөри, көтү дә җыелып, шуннан Казанка буена төшеп китә торган иде. Әмма сугыштан соң, бигрәк тә соңгы унбиш-егерме ел эчендә, бу тирәләр шулкадәр үзгәрде ки, хәзерге биек йортларда торучылар мондагы яланны да, тирән чокырны да, кечкенә агач чиркәүне дә, билгеле, күз алларына да китерә алмыйлар. Без үзебез дә утыз биш ел күршеләр белән аралашып яшәгән бәләкәй йорттан зур йортка — шуның өч бүлмәле, санузеллы бер «секциясенә» кереп бикләндек. Күптән инде вак йортлар сүтелеп, бакчалар киселеп бетте.

...Янә килеп, атакай йортыбыз артында буш яткан биш сотый чамасы җирне әкренләп бакчага әйләндерде. Аның өчен бу бөтенләй яңа эш иде. Әмма шуңа карамастан ул, йөреп-сорашып һәм бик күп көч салып, менә дигән бакча үстерде. (Билгеле, минем дә шактый көчем керде.) Безнең бакчада Казан туфрагында үсә торган җимеш агачларының барысы да бар иде. Мәгәр шуларның иң шәбе Владимирский дип аталган кара чия агачы иде. Карт аны каяндыр читтән алып кайтып утыртты. Якынтирә бакчаларда да бу чия бик сирәк күренә иде. Безнең туфрак килеште булса кирәк, бик тиз алындылар, өчдүрт ел эчендә яшьрәк алмагачларны да узып киттеләр — алар чәчәк атканда бөтен бакча ак күбеккә күмелә торган иде... Чия, гомумән, әрсез агач, бу «кара»ның да үсентеләре күп була иде — без аларны сорап килгән таныш-белешләргә күп өләштек. Кайбер язучыларның бакчаларында да безнең татлы чия хәзер дә әле үсеп утыра торгандыр.

Без килгән заманда хәзерге шикелле Казанның бөтен әтрафын әйләндереп алган бакчалы дачалар юк иде (яки бик аз булгандыр)... Җимеш бакчалары күбрәк шәһәр читендәге вак йортлар ихатасында гына үсә иде. Ул бакчаларга язын сыерчыклар килә, чәчәк вакытында бөтен тирә-юне хуш ис белән тула, монда җылы җир исе аңкыган тынлык хөкем сөрә, монда кеше дә үзен табигатькә якынрак тоя иде. Менә безгә килгән таныш-белешләр дә бакчабызга кермичә, «сөбханалла» дип сокланмыйча һәм җимешләрен өзеп капмыйча китмиләр иде.

Мәгәр безнең үзебезгә бакчалы йортыбызда бөтен бер гаилә булып, оешып кына яшәргә туры килмәде. Заманы шундый тынгысыз-киеренке иде... Кыскасы, төрле сәбәпләр аркасында, миңа Казаннан өч тапкыр китеп торырга туры килде. Унике ел вакытның алты ел ярымын читтә уздырдым. (Шуның өч ел ярымы фронтта узды.) Энем дә сугышка чаклы ук эш эзләп Урал якларына чыгып киткән иде.

...Авыр сугыш елларының газап-михнәтләрен язып торуның кирәге бармы икән? Бик мәгълүм нәрсә... Минем картларга, хатын-балаларга да җан асрау, әлбәттә, җиңел булмаган. Ләкин шулай да ничектер яшәгәннәр, аяктан егылмаганнар, исән калганнар.

Сугыштан соң без тагын бер ояга җыелдык. Энем дә фронттан исән-сау кайтты. Яшәү шартлары, билгеле, җиңел түгел иде, ләкин аңа әллә ни исебез китми, чөнки сугыш җиңү белән бетте, без исән калдык. Хәзер инде, башта хыял иткәнчә, бергә оешып кына, җиң сызганып тора башларга кирәк... Кирәк тә бит, әмма тормыш дигәнең явыз каенанадай берәр төрле әшәкелек эшли дә тора. Без кайтканда сәламәт кенә йөргән инәй җәй ахырына таба ничектер, әкрен генә хәлсезләнә башлады. Эче авыртудан зарланды, ашаудан калды. Күзгә күренеп саргайды һәм ябыкты... Шулай да ятмаска тырышты, йөреп азапланды, ләкин барыбер ятарга мәҗбүр булды. Күрәбез, инәйнең хәле шәптән түгел, ниндидер әшәке чир ябышканга охшый. Ул вакытта врач чакыртулары авыр иде, ярый әле үзебезнең якын туганнардан Рөкыя апа белән Суфия — икесе дә врачлар — килеп карадылар. Инәйнең янына утырып, хәлен сорашып, әйбәтләп карагач, иреннәрен кысып, бер-берсенә карашып, уйланып тордылар да әйттеләр:

— Җиңгәчәйне берәр яхшы хирургка күрсәтергә кирәк,— диделәр. Һәм ул чакта дан тоткан хирурглардан профессор Харитоновны чакырырга куштылар.

...Андый мәшһүр белгечнең өйгә килүенә ышаныч аз иде, шулай да мин Вишневский клиникасына барып, үтенеп карарга булдым. Һәм, гаҗәпкә каршы, бу зур гәүдәле, мәһабәт профессор үтенечемне кире какмады. Адресны язып алды һәм иртәгә фәлән сәгатьтә көтәргә кушты. (Бу инде аның тарафыннан врачлык вазифасын үтәү генә түгел, бер татар карчыгына карата олы җанлылык күрсәтү дә иде, минемчә.)

Икенче көнне без, Хөзер Ильясны көткәндәй, аны көтеп алдык. Әйткән сәгатендә килде, чишенде, инәй янына узды, без ашыгып куйган урындыкка утырды, авыруга бераз карап торды да минем аша хәлен сорашты, шуннан соң инәйнең күкрәген тыңлады, ап-ак таза кулы белән күлмәк аша гына эчен кат-кат баскалап карады — инәй шул чакта бик ыңгырашты... Карап бетергәч, профессор кулын әйбәтләп юды да өстәл янына рецептлар язарга утырды. Шул чакта безгә инәйнең хәлен дә аңлатты: бавырында яман шеш булса кирәк, бердәнбер чара — операция, әмма авыр операцияне җитмештән узган карчык күтәрә алмас, диде. Язып калдырган дару-

лары авыртуны басар өчен — инәй шуларны эчеп, тыныч кына ятарга тиеш икән... Без профессорга кат-кат рәхмәтләр әйтеп, урамга чаклы озатып калдык. (Билгеле, без аңа күпмедер гонорар да бирдек — ул шуны карамыйча гына пальто кесәсенә салды.)

Инәйдә яман шеш — бу рак дигән сүз... Ләкин ракның ни дәрәҗәдә әшәке авыру булуын, аңардан котылу мөмкин түгеллеген без әле яхшылап белми дә идек. (Һәр заманның үз авырулары була, күрәсең. Без тиф, туберкулез, эч киту, бизгәкләрне күреп уздырдык, ә рак белән йөрәк авыруы сугыштан соңгы елларда гына көчәеп китте.) Хәлбуки атаклы профессор үзе килеп карап киткәч, бездә ниндидер өмет тә туган кебек булды. Аның язып калдырган даруларын эчергәч, инәйнең үтә газаплы авырулары да гүя басыла төште. Әмма ул, мескинә, иртә яуган кар шикелле көннән-көн сыза-бетә барды. Шулай ук өзелер микәнни?.. Атакай көне-төне яныннан китмичә аны карады. Ә көннәрдән бер көнне инәй аңардан мунчага илтеп юындыруын сораган. Өч ай буена урын өстендә хәрәкәтсез яткан авыруның бу соравы бик аңлашыла иде, әмма моны ничек итеп үтәргә?.. Шәһәр мунчаларының берсенә дә, билгеле, алып барып булмаячак... Ярый әле, ерак түгел, Клыковка очында бер танышларның ак мунчалары бар иде — атакай үзе барып, иплəп кенә сорагач, ягарга рөхсәт иткәннәр. Мунчаны кызу гына ягып уздыргач, атакай кайтып, инәйне әкрен генә торгызып, аякларына пима, өстенә бәрхет тышлы төлке тунын кидереп, минем ярдәмем белән бәләкәй чанага утыртып, сак кына тартып алып китте. Числосын ачык кына хәтерләмим, ләкин бу салкын декабрь ае иде һәм беренче кар да җиргә яткан иде инде.

Шактый вакыт узганнан соң, кызарган-тиргә баткан атакай үзе генә мунчадан кайтып керде. Без куркудан коелып төштек: «Ни булды?» «Алып кайтырлык хәлем калмады,— диде атакай, өзек-өзек сулап.— Бар инде, улым, син алып кайт...»

Мин тиз генә өстемә киеп, бүрекне эләктереп, мунчага йөгердем. Барып керсәм, инәй мунча алдында, такта стенага авыша биреп, утырып тора — аягында пималары, өстендә туны... «Инәй, мин сине алырга килдем»,— дидем һәм ике куллап сак кына күтәреп алдым — ул кипкән көлтә кебек җип-җиңел иде. Шул чакта гына инәй миңа дәште: «Улым, синмени бу?» — диде һәм аның күкрәгеннән үзенекенә һич охшамаган сабый балаларныкыдай бик нечкә, зәгыйфь кенә тавыш чыгып куйды. Йөрәгем әллә нишләп китте, тез буыннарым хәлсезләнде — бу инде дөньядан китә башлаган кешенең тавышы иде. Инәйнең

көннәре генә түгел, сәгатьләре дә санаулыга калганын мин шул чакта бик ачык сизгәндәй булдым.

Әйе, ул, бичара, мунчага илтүне юкка гына сорамаган икән. Аңлаган-көткән һәм үзенең соңгы сәгатьләрен саф килеш, пакь килеш каршы алырга теләгән... Чынлап та, ике-өч көннән инәйнең хәле кичкә табан кинәт начарланды, телдән калды, беребезне дә танымас булды. Атакай баш очына утырып Ясин чыга башлады. Ул төн буе инәй яныннан кузгалмады... Өй эче тып-тын, тик ике кызым гына татлы йокыда... Серле-хәтәр мизгелне көткәндә күңелгә ниләр генә килми. Чыкмаган җанда өмет бар, диләр — без дә могҗиза булмасмы дип көткән идек, әмма могҗиза булмады. Иренеп кенә ата башлаган салкын-томанлы таңда инәй, ниһаять, йокыга талгандай, тавыш-тынсыз гына дөньядан үтте...

Өебезгә кергән беренче зур үлем, беренче иң зур хәсрәт... Әҗәленә тигән чир икәнен белсәк тә, җан өшеткеч газапларын күреп торсак та, ана кешенең үлеме белән килешүе бик авыр — гүя үз гомереңнең иң газиз өлеше синнән китә, әйләнәңдә һәм күңелләрдә шунда ук салкын бер бушлык туа...

Мөселман йоласы буенча мәетне озак тотарга ярамый, үлгән көнендә үк җирләргә дә кирәк иде. Без энем белән загска бару, кабер казыту кебек эшләр артыннан йөрдек, ә карчыклар инәйне юып, кәфенләп, барлык шәригать кушканнарны үтәп, озатырга әзерләделәр. Мөмкин кадәр җиренә җиткереп, күркәм итеп «Алла хозурына» озату бичара атакайның ул көнне бердәнбер кайгысы һәм юанычы иде бугай...

Әзерләп бетүгә, ике җигүле ат та килде. (Ул чакта автобус дигәннәрнең эзе дә юк иде.) Юрганга төргән инәйне иплә кенә чыгарып, үрәчәле чанага салдылар. Чанага атакай, энем, мин, тагын якыннардан бер-ике кеше тезләнеп утырдык. Икенче үрәчәле чанага озата баручы картлар утырдылар. Әкрен генә кузгалдык. Капка төбендә «бабушка» белән саубуллашырга килгән күрше-тирәдәге марҗа түтиләр, кайбер ир-атлар, үзебезнең якыннарыбыз боек кына өелешеп калдылар.

Мәчеткә Кабан күле аша гына, халыкның өйлә намазыннан чыгуына барып җиттек. Инәйне мәчет ихатасына кертеп, чиста карга куйдык. Намаздан чыккан мулла һәм картлар шунда кыска гына җеназа укыдылар. Мин бер читтә басып кына тордым. Шул чакта күңелгә сәер генә бер уй килде: бу шәригать йолалары кешенең хәсрәтен бераз җиңеләйтмиме икән? Читтән генә карап торсам да, шуңа охшаш бер халәт мин дә кичерәм түгелме соң?! Кеше юкка гына уйлап чыгармагандыр ул йолаларны...

Җеназа укылганнан соң, мәетне яңадан чанага салып, зиратка киттек. Кабер әзер, казучылар, көрәкләренә таянып, көтеп торалар иде. Кыска көн инде сүнеп тә бара, шуңа күрә җирләүне кызу тоттылар. Инәйне, юрганын ачып, кабер якасына куйгач, энем белән миңа кабергә төшәргә куштылар... Һәм без, «ике бөртек», инәйнең ак кәфенгә төрелгән юка-җиңел генә гәүдәсен ипләп кенә алып, ләхеткә куйдык. (Хәтерлисездер, кечкенә бала чагыбызда безне «Хәдичәттәйнең ике бөртеге» дип йөртәләр иде.) Кабердән чыккач та, мин тизрәк бер читкә киттем...

Җирләү беткәч, меңләгән каберләр арасында тагын бер яңа кабер калдырып, без караңгы төшкәндә генә суынып беткән өебезгә кайтып кердек. Мондый көнне барысы да онытыла — ашау-эчү дә, хәтта ни дә булса уйлый алу да!..

...Уйлар соңрак килә башлый... Җитмеш өч яшендә үлеп киткән инәй бу дөньяда ни генә күрде? Бәлки, кыз чагында, яшь килен булып төшкән вакытларында дөньяның беркадәр ямен күреп калгандыр, әмма гомеренең иң күп өлешен гел эш-мәшәкатьтә азап-борчылу белән, бигрәк тә безнең өчен ут йотып үткәрде. Безнең белән бит ул юньләп яши алмыйча да калды — без «Сак белән Сок» шикелле ничә тапкыр икебез ике якка киттек тә югалдык. Мондый хәл өчен кем генә, нәрсә генә гаепле булмасын, иллә мәгәр бичара ана алдында билгеле бер гаеп тоймыйча, гомер буе үкенү хисе кичермичә калу мөмкин түгел. Һәм, әйтергә кирәк, бу үкенү хисе, бәгырьдәге сызлавык шикелле, шушы көнгә кадәр, инәй яшеннән узып китсәм дә, мине һаман да ташлаганы юк әле... Ана бик яшьли үлеп китсә дә ана, ә баласы — сакалы агарып бетсә дә бала — мәңге бурычлы бала!..

Инәйнең үлемен бигрәк тә атакай бик авыр кичерде. Асылда бит алар бөтен гомерләрен диярлек икәүдән-икәү генә уздырдылар — бу исә, илле өч ел буена бер-берсенә гел мохтаҗ булып яшәү дигән сүз... Михнәте-рәхәте, шатлыгы-кайгысы — барысы аларның бергә булган. Шуңадыр инде атакай инәйне бик озак оныта алмады, безгә һаман «инәгез кебек зат иясен, юк, тапмассыз» дип сөйләде, ә күңеле тулып киткән чакларда үзалдына әкрен генә: «Ятим калдым ласа!» — дип җылап та ала торган иде. Без аның бу «йомшаклыгына» гаҗәпләнә идек, хәтта кәефебез дә кырыла иде, чөнки картлыкта ялгыз калуның нинди зур бәхетсезлек булуын без әле уйлый да белми идек.

Әмма үлгән артыннан үлеп булмый — инәйдән башка гына яшәп ятабыз. Сугыштан соңгы еллар безнең өчен җиңел булмады. Алдарак күрдегез инде, минем әдәбият

тирәсендә эшләрем бик авыр бара иде. Кәеф начар, баш бөлгенлектән чыкмый, киләчәгем дә билгесез... Ә атакай һаман үткәнен сагынып сөйли, минем исә сагынып сөйләрлек бернәрсәм дә юк әле. Миңа киләчәкне уйларга, киләчәкне кайгыртырга кирәк. Менә шул нигездә безнең араның салкынаеп киткән чаклары да булгалады. Янәсе, ул сату итмәгән булса, миңа да болай азапланырга туры килмәс иде... Билгеле, мондый уй кәефнең бик начар вакытында гына туа торган иде. Югыйсә мин атакайга андый гаеп ташлауның бер ахмаклык кына булуын яхшы аңлый идем. Октябрь революциясе аның гомерен нәкъ урталай бүлде (кырык өч яшендә була ул шул чагында). Димәк, аның яшьлеге, өлгергән ир чагы, барлык өмет-хыяллары теге заманда торып кала. Ә ул заманда сату итү хәләл кәсеп, законлы бер эш булып саналган... Йә, шуннан соң ничек итеп кешене, ник сәүдәгәр булдың? — дип гаепләргә мөмкин ди?! Атакай яхшы укый, яхшы яза белә иде, әгәр социаль революция бер илле ел алданрак килсә, ул да, билгеле, сәүдә юлы белән китмәгән булыр иде. Яки, киресенчә, революция бер илле елга соңга калса, хәзерге минем замандашларымның күпмеседер сәүдәгәр, мулла, мәзин булып китәрләр иде. Нигә, шулай түгелмени?.. Асылда бит кешенең кем булуын үз дәверенең иҗтимагый шартлары билгели. (Әйтик, элек мулла буласы урынга, безнең шартларда галим булып китә...) Юк, мин атамны берничек тә гаепли алмыйм...

Алар, ягъни атам белән анам, гади кешеләр иде, гадел кешеләр иде, «ярамый, гөнаһ!» дигән нәрсәне беләләр иде. Һәрхәлдә, иманы да, чын аңы да булмаган хәзерге берише бәндәләрдән алар кешелек сыйфатлары белән күп өстеннәр иде... Һәм мин моны бер аларга карата гына әйтмим. Күптән күзәтеп киләм: чын инсафлы кешеләр борынрак заманның авыл картлары, әбиләре, укымышлы зыялылары арасында, ни хикмәттер, ешрак очрый иде. Күрәсең, аларга әхлак кагыйдәләре нәселдән үк күчә килеп, каты тәрбия белән кереп калгандыр.

Атакай инәйдән калып, унөч ел яшәде. 1958 елның шул ук декабрь таңында, озак авырудан соң, сиксән дүрт яшендә вафат булды. Каберләре янәшә, зыяратның көнбатышында, Тукай яныннан кереп киткәч... Инәйгә гади ташны атакай үзе яздырып куйдырган иде. (Ташта «Нигъмәтҗан зәүҗәсе» дигән сүзләр дә бар.) Атакайга шундый ук ташны мин куйдырдым. Соңрак тимердән гади генә чардуган да эшләттем... Каберләренә баргалыйм. Еллар уза, ташлар да туза, мин үзем дә әкренләп аларга якынлашам...

Дөньяда ике генә бәхәссез хакыйкать бар: туу һәм үлем. Без менә шул ике араны узабыз. Һәм үзебезне белә башлаган көннән алып, иң якыннарыбызны — ата-ана, кардәш-ыру, дус-ишләрне югалта-югалта килеп җитәбез соңгы сәгатебезгә... Һәммәсен искә төшереп бетерерлек тә түгел. Әле шушы әсәрне язу дәвамында да кемнәрне генә югалтмадым!.. Срур тутакай, Гыйниятулла абзый, Хәбибрахман, Рәшид, Рәхим дусларны... (Боларның кайберләре хакында, онытмаган булсагыз, бу китапта язып та узган идем.) Аларның һәркайсы китапның баш өлешләрен укыганнар иде, үз фикерләрен миңа телдән яки хат аша әйткәннәр иде, инде ахырын көтәләр иде... Әмма, кызганычка каршы, минем китап алар өчен, чынлап та, укылып бетмәгән соңгы китап булып калды.

Мин бик озакка сузылган шушы озын язманың ахырына якынлашып киләм. Соңгы сүземне дә әнә шул үлгән һәм исән яшәгән дусларыма багышлыйсым килә. Кеше кешедән башка яши алмый — бу да аксиома!.. Дус кирәк, сердәш кирәк, ярдәм кулын сузучы кирәк. Шуларсыз безнең әйләнәбездә салкын бушлык хасил булыр иде. Мин, табигатем белән кешегә тиз генә якыная алмасам да, чын дуслар табу ягыннан үземне бәхетле булдым дип әйтә алам. (Сүз монда вакыт сынавын узган гомерлек дуслар турында гына бара.) Шулай ук үземнән күп олы иске буын кешеләре белән аралашуның да миңа йогынтысы зур булды. Бу җәһәттән ике җизни тиешле кешенең минем язмышымда никадәр мөһим роль уйнауларын әйтмичә уза алмыйм. Аның берсе Шәриф Хәмидулла улы Сүнчәләй — аның хакында китапның алдагы өлешләрендә язган идем инде. Икенчесе — Закуан Сафа улы Богданов... Казандагы төзүче инженерлар институтының кафедра мөдире, математик, геодезия белгече, сугыштан соң Ленин ордены белән бүләкләнгән татар укымышлысы... Заманында Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә дә укыткан... Шәриф җизни дә, Закуан җизни дә татарча һәм русча төпле белемне революциягә чаклы алганнар. Мин аларның үз телебездә бик иркен сөйләшүләренә һәм матур язуларына һәрвакыт соклана торган идем.

...Миңа яшьтән үк алар белән якыннан аралашырга туры килде. Очрашулар, утырышулар, сөйләшүләр күп булды. Һәр икесе дә табигатьләре, тәрбияләре һәм кешелек сыйфатлары белән затлы-өстен кешеләр иде. Һәрхәлдә, минем өчен — мин аларның үрнәк булырлык кешеләр икәнен һәрвакытта тоеп яшәдем. Алар миңа бервакытта да мораль укымадылар, әмма аларның «өстен торулары» мине гүя түбәнгә тәгәрәүдән гел саклап килде.

Кешенең кешегә йогынтысы гаҗәп икән ул. Кайчагында чын затлы кешене күреп кенә белү дә сине әдәп киртәсендә тота. Мисал рәвешендә бер гыйбрәтле хәлне искә төшерәсем килә...

Закуан җизнинең Василий Андреевич Яблоков дигән якын танышы бар иде. Бу — Казан университетының карт профессоры, үтә интеллигент бер кеше, борынгы дворяннар нәселеннән булса кирәк. Бер үк урамда торгач, алар, ягъни Закуан җизни белән профессор Яблоков, кичләрен гел бергә йөрергә чыга торганнар иде. Достоевский урамының очына хәтле килеп, тимер юл чокыры буенда озак кына йөргәннән соң, алар безнең бакчага кереп, бераз ял итеп китәләр иде. Закуан җизни атакай белән сөйләшергә ярата иде. Өйдә булсам, мин дә яннарына чыгып утыра идем.

Ләкин аларның болай дусларча бергәләп йөрүләре һич көтмәгәндә өзелде дә куйды.

1965 елның кышында өрлектәй тап-таза Закуан җизни, грипптан соң инсульт булып, кинәт үлде дә китте. Әйтерсең кышкы салкын аяз көндә яшен сукты — шундый вакытсыз һәм мәгънәсез үлем булды бу. Ә арык-юка гына гәүдәле карт профессор калды. Җизнидән соң озак яшәде әле ул. Һәм шушы миннән бик күпкә өлкән мөхтәрәм кеше урамда очрашкан саен, минем белән эшләпәсен күтәрә төшеп, иелә биреп, кул кысып исәнләшә башлады. Һәрдаим: «Ваше здоровье?» — дип бер генә сорау бирә, аннары яңадан эшләпәсен күтәрә төшеп, кулны кыса да ашыкмыйча гына үз юлы белән китеп тә бара... Ходаем, ни өчен мондый нәзакәтлелек, мин бит аңа беркем дә түгел ләбаса?! Тик бераз ияләшә төшкәч кенә, картның бу нәзакәтлелеген әзрәк аңлагандай булдым: мин бит Закуан Сафичка туган тиешле, ә Закуан Сафич аның иң хөрмәт иткән кешесе булган... Бәс, шулай булгач, очрашканда кулны кысып, исәнлекне сорамыйча үтеп китәргә ярыймы соң?! Бу тәрбия, егетләр, безнең бик күбебезгә җитмәгән тәрбия!..

Инде замандаш дусларыма килгәндә, аларның барысы да диярлек әдәбиятны яраткан, күп укыган, ләкин әдәбияттан читтә торган кешеләр иде.

Менә Хәсән дустым Җәгъфәров! Педагог, тәҗрибәле укытучы, озак еллар техникум директоры булып торды. Күп укыган, күпне белә, китапка комсыз, кыю фикерле, бәхәсне бик ярата — очрашканда төннәр буе утырсак та безгә вакыт җитми, сүз бетми кала. Сугыштан соң яңадан табышып, менә кырык ел инде йә очрашып, йә даими хат язышып торабыз.

Хәсәннең күптән инде туган иле Татарстанга кайтырга теләге бар иде. 1979 елны ул шушы теләген, ниһаять,

гамәлгә дә ашырды: Азнакайга кайтып, бик чибәр йорт алып, төпләнеп, җәмәгате Алидә белән шунда тыныч кына тора башлады... Азнакайны алар яраттылар, халкы белән дә җиңел аралаштылар, Хәсән үзе тиз арада төпле, абруйлы бер кеше булып та танылды. Әмма, шуларның берсенә дә карамастан, алар дүрт кенә ел торып, йорт-җирләрен саталар да яңадан Үзбәкстанга китеп тә баралар. Беренче карашка гаҗәп тоелган бу хәлнең бик җитди бер сәбәбе килеп чыга: аларның өч уллары, киленнәре һәм оныклары һәммәсе дә тегендә, ә болар монда икәүдән-икәү генә... Дөрес, Хәсәннең башта ук исәбе — егетләрнең берәрсен үз яннарына кайтару иде. Мәгәр өчесенең берсе дә кайтырга теләп, ашкынып тормый. Чөнки «туган җир» дигән газиз төшенчә ата белән бала өчен бер үк түгел икән... Егетләр Үзбәкстанда туып үскәннәр, шунда тамыр җибәргәннәр, менә шул инде аларның туган туфраклары да!.. Атага үзенеке никадәрле якын булса, боларга да үзләренеке шулкадәр үк якын, кадерле. Мәсьәлә ачык, бәхәскә урын юк!.. Шулай итеп, ата белән анага икесенең берсен сайларга туры килә: монда туган туфрак иде, ә тегендә газиз балалар!

...Былтыр яз без Мөршидә ханым белән аларда кунакта булдык. Монда инде Азнакайдагы шикелле яшел кырлар да, иркен йорт та, зур бакча да юк, әмма, аның каравы, көн дә диярлек хәлләрен белеп торган уллары, уңган киленнәре, бер-бер артлы үсеп килгән оныклары бар — бәхетләре тулы, тормышлары түгәрәк.

«Сөт калыр, Ватан китәр!» — дигән ич Дәрдмәнд тә. Ул моны бөтен кауменә (халкына) карата әйткән, әмма шагыйрьнең әйткәне аерым язмышларда да чагыла түгелме соң?!

Мин тагын мәрхүм Рәшит дустымны тирән юксыну белән исемә төшерәм. Без фронтташ дуслар идек, кырык беренче елның июлендә бер эшелонга төялеп фронтка киттек, бер частька эләктек, сугыш беткәнче диярлек бергә хезмәт иттек. Тик армиядән бушавыбыз гына бер вакытка туры килмәде — мин 1945 елның язында ук бушадым, ә ул калды һәм бик озакка... Сугышның сәер бер хикмәте дип әйтергәме инде, фронтка нестроевой булып кына эләккән минем шушы гаять тыйнак-юаш дустым сугыш беткәч тә армиядән китәргә теләмәде. Гүя ул шунда үзенең туган йортын да, яраткан эшен дә тапты — бөтен гомерен соңгы көненә кадәр армия хезмәтенә бирде. Нәкъ кырык ике ел өзлексез хезмәт итеп, рядовой солдаттан майор дәрәҗәсенә менеп җитте. Каты авырып, Казанга кайткан чагында да аның өстендә погонлы

китель иде әле[1]... Әмма ул һич тә сугыш кешесе түгел иде.

Рәшит Таһир улы Ильясовны укучыларга якыннанрак таныштырасым килә. Ул безнең мәшһүр мәгърифәтче галимебез Шиһабетдин Мәрҗани токымыннан, ягъни Рәшитнең әнисе Нәгыймә апа Мәрҗани кызының кызы булган. Әтисе — Таһир Ильяс, шулай ук тарихта мәгълүм кеше, дин әһеле, гарәп теле буенча зур галим, «Әлмөфит» дигән беренче гарәпчә-татарча зур сүзлекне чыгаручы да ул... Революциягә кадәр «Мөхәммәдия»дә укыткан, егерменче елларның башында күпмедер вакыт «Шәрекъ академиясе»нең профессоры да булып торган. («Шәрекъ академиясе» дип ул чакта хәзерге педагогия институтын атаганнар булса кирәк.)

Рәшит әнә шундый нәселдән. Ләкин ул үзе турында күп сөйләргә яратмый иде, шуның аркасында мин аның ата-бабасын шактый еллар узгач кына белдем. Рәшит мәрхүмне әүлия бер кеше иде дисәм дә, һич арттыру булмас. Үтә инсафлы, үтә әдәпле иде ул — үз гомерендә бер тамчы хәмер капмады, бер тапкыр да төтен суырмады. Хәтта фронт шартларында да!.. Монда кешенең җанын тиз күреп була. Күпме тапкырлар бик әшәке бомбежкаларга эләккән чакларыбыз булды, җаныбыз табаныбызга китә иде, ә бу ак чырайлы, күзлекле егет шул чакта да тынычлыгын җуймады, аз гына да куркукаушау күрсәтмәде.

Сугыштан соң табышкач, без хатлар язышa башладык. Рәшитнең хатлары да саф татарча матур, акыллы язылган була иде. Миннән биш яшькә кечерәк булса да һәм иске мәдрәсәне күрмәсә дә, ул гарәп телен дә әйбәт кенә белгән икән. (Бала вакытында атасыннан белеп калырга өлгергән.) «Соңгы китап»ның баш өлешләрендә хата киткән гарәп сүзләрен төзәтеп миңа хат та язган иде. Кырык ел читтә, башка халыклар арасында яшәсә дә, Рәшит үзенең туган телен дә, туган әдәбиятын да, туган халкының күркәм сыйфатларын да онытмады, җуймады, һәрвакыт кызыксынып, белеп торырга тырышты. Бабасы Мәрҗани кебек «бөтен» кеше иде, мәрхүм!..

Мин монда барлык замандаш дусларымны санап чыгуны максат итеп куймадым. Алай итсәм, сүз бик озынга китәр иде... Кемнәр, ниндирәк кешеләр белән якыннан аралашуымны күрсәтер өчен шушы телгә алынган ике-өчесе дә җиткәндер дип уйлыйм. Хуш, алар миңа кайсы яклары белән якын, кадерлеләр?..

[1] Ул 1983 елның ноябрендә вафат булды.— *Ә.Е.*

Без — замандашлар, бер үк чорларны кичергән кешеләр, бер-беребезне күптән инде яхшы беләбез, һәм шушы нигездә башланып та китте безнең арадагы дуслыклар. Әмма дуслыкны чын иткән, нык иткән нәрсә — бер-береңә ышану... Кеше булып калуыбызга ышану дияр идем мин. Хәтерләр калганда да, бәхәсләр туганда да — теләсә нинди хәлләрдә дә!.. Әнә шундый ышану туган иде безнең арада да. Бик кадерле нәрсә ул ихлас дуслык!

Ләкин сездә, укучым, «Ни өчен язучы дусларыгыз турында бер сүз дә юк?» дигән сорау туарга бик мөмкин. Әйе, мин алар турында язуны хәзергә калдырып торырга булдым. Даими аралашып яшәгән кешеләр хакында арттырмый-киметми һәм берәүне дә үпкәләтми язуы шактый четерекле-читен эш...

...Шулай да... әмма шулай да мин бер шагыйрь турында кыскача гына булса да әйтмичә уза алмыйм. Ул үзе дөньяда күптән юк инде, ләкин исеме аның телләрдән төшмәс булды... Әйтергә теләгәнем — Муса Җәлил турында... Мин аның белән егерменче елларның икенче яртысында танышкан идем. Һәм, ни хикмәттер, шушы читтән Казанга вакытлыча гына килеп йөргән шагыйрьгә шактый ук якынлашырга да өлгердем. Шулай итеп, Муса белән дусларча аралашу бер биш-алты ел дәвам итте, ләкин 1934 (яки 1935) елдан алып сугыш башланганчыга кадәр безгә бүтән очрашырга туры килмәде. (Бу вакыт эчендә мин Казаннан ике мәртәбә китеп тә тордым.) Хәзер менә Мусаның без аралашкан чаклардагы кыяфәтен, шәхси сыйфатларын, хәтердә кайсы яклары белән сакланып калуын арттырмыйча-киметмичә күз алдына китерергә тырышам. Җыйнак бәдәнле кечерәк кенә егет. Үзе дә, өс-башы да гади генә. Холкы-тотышы белән тыйнак, күп сөйләргә яратмый — бигрәк тә үзе турында, инде сөйли башласа, хис кешесенә хас булганча, бераз кабаланыбрак, дулкынланып сөйли (кызганыч, миңа аны бер тапкыр да трибунадан тыңларга туры килмәде), кешегә мөгамәләсе йомшак, тыңлый белә, фикерен уйлап әйтә, үзен өстен кую яки мактану дигән нәрсә аңарда юк, шулай ук акыл сатарга, кеше өйрәтергә дә яратмый иде, минемчә. Тагын нәрсә?.. Безнең бит әле дәртле яшь чакларыбыз — билгеле инде, уен-көлке, җыр-музыканы бик ярата идек. Белмим, кем генә ул чакта менә сугыш булыр да, Муса барыбызны да таң калдырырлык батырлыклар эшләр дип уйлый алды икән?! (Мөгаен, Мусаның үзенә дә андый уй юри генә дә килмәгәндер.) Ул бит шагыйрь, нечкә күңелле шагыйрь — ә шагыйрьне без канлы сугыш кырында түгел, бәлки, шигърият бакчасын-

да күрергә гадәтләнгәнбез. Һәм аның кыюлыгын да ялкынлы сүзләреннән көтәбез... Шуңадыр, ахрысы, мин хәзер дә әле Мусаның тәненә уратылган чәнечкеле тимерчыбыкны өзәргә омтылган һәйкәлен хәтеремдә яхшы сакланган чын, тере Муса итеп таный алмыйм. Әмма аңлыйм, бу инде образга әверелгән Муса, һәм без аны әнә шулай фашизм зынҗырларын өзүче образ итеп кабул да иттек.

...Язмышның серләренә төшенеп бетәрлек тә түгел. Сугыш башланудан берничә ай элек кенә Муса Җәлилне, үзенең соравы буенча, Язучылар союзы идарәсе председательлегеннән азат иткән булганнар. Әгәр шул урынында калган булса, ихтимал, аны фронтка җибәрмәсләр дә иде. Әмма язмыш аңа икенче бер бөек миссияне йөкли: ул газиз башы бәрабәренә бөтен дөнья алдында фашизм тырнагына эләккән татар солдатларының йөзләрен акларга тиеш була... Һәм үти ул бу гаять куркыныч изге миссияне үзенең унбер көрәштәш иптәше белән бергә!.. Кайдан бу батырлык? Мусаның үзенә килгәндә, минем, беренче нәүбәттә, аның батырлыгын тыйнаклыгы һәм шагыйрь җанлы булуы белән бәйлисем килә... Һәрхәлдә, мин Мусаның батырлыгын аның табигатеннән аерып карый алмыйм. Ул минем өчен абстракт образ түгел, ә конкрет тере кеше — үлсә дә, легендага әйләнсә дә!..

Инде менә язманың ахырына да җиттек. Тәмамларга вакыт. Болай да бик озакка һәм бик озынга сузылды. Хәлбуки мин бөтен белгәнемне һәм уйлаганымны монда язып бетердем дип әйтмәс идем. Мөмкин дә түгел бу, чөнки безгә вакыт хуҗа, без вакыт таләбенә буйсынабыз. Укучы да моны исендә тотсын иде.

Язманың «Соңгы китап» дип аталуын күпләр яратмадылар. «Соңгысы булмасын!» дигән теләк белдерүчеләр дә булды. Рәхмәт аларга!.. Илебез бик әһәмиятле, бик җаваплы чорны кичерә. Партия халыкка әйтте: «Социализмны камилләштерергә кирәк»,— диде. Сүз дә юк, бу һәркемнең күңелендә яткан кайнар теләге, һәм бу изге теләк, бу бөек максат өчен яшәргә дә, эшләргә дә була әле...

...Әнә шул якты өмет белән без дә хәзергә каләмебезне куйдык. Хушыгыз!..

Литературно-художественное издание

*Амирхан Еники*
*(Еникеев Амирхан Нигметзянович)*

**СОЧИНЕНИЯ**

**в пяти томах**
**том 4**

*Страницы прошлого*
*Воспоминания*

(на татарском языке)

Нәшрият мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.03.2003. Форматы $84\times108^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 25,20+фор. 0,21. Шартлы-буяу оттиск 25,73. Нәшер-хисап табагы 27,46+форз. 0,36.
Тиражы 5000. Заказ Я-154.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.